«ЯР ЧАЛЛЫ ДӘҮЛӘТ ПЕДАГОГИКА УНИВЕРСИТЕТЫ»
ФЕДЕРАЛЬ БЮДЖЕТ ЮГАРЫ БЕЛЕМ БИРҮ УЧРЕЖДЕНИЕСЕ
ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ТҮБӘН КАМА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ МӘГАРИФ ИДАРӘСЕ
ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ТҮБӘН КАМА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ МУСА ҖӘЛИЛ ИСЕМЕНДӘГЕ “1 НЧЕ ГИМНАЗИЯ” МУНИЦИПАЛЬ БЮДЖЕТ ГОМУМИ БЕЛЕМ БИРҮ УЧРЕЖДЕНИЕСЕ

# Сөй гомерне, сөй халыкны, сөй халыкның дөньясын

Түбән Кама
2023

**УДК 37.01**

Федераль бюджет югары белем бирү учреждениесенең «Яр Чаллы дәүләт педагогика университеты» психолого-педагогик һәм мәхсус дефектологик белем бирү кафедрасы, Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы башкарма комитеты мәгариф идарәсе, Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районының Муса Җәлил исемендәге “1 нче гимназия” муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесе карарлары белән басыла

Төзүчеләр:

1. Мухаметшин Азат Габдулхакович, педагогика фәннәре докторы, профессор, Федераль бюджет югары белем бирү учреждениесенең «Яр Чаллы дәүләт педагогика университеты» беренче проректоры
2. Хәзрәтова Фирүзә Вакильевна, педагогика фәннәре кандидаты, Федераль бюджет югары белем бирү учреждениесенең «Яр Чаллы дәүләт педагогика университеты» психолого-педагогик һәм мәхсус дефектологик белем бирү кафедрасы мөдире
3. Хөснетдинова Резидә Рөстәмовна, психология фәннәре кандидаты, Федераль бюджет югары белем бирү учреждениесенең «Яр Чаллы дәүләт педагогика университеты» психолого-педагогик һәм мәхсус дефектологик белем бирү кафедрасы доценты
4. Шәрәфетдинова Зимфира Габдрахмановна, филология фәннәре кандидаты, Федераль бюджет югары белем бирү учреждениесенең «Яр Чаллы дәүләт педагогика университеты» башлангыч һәм мәктәпкәчә белем бирү теориясе һәм методикасы кафедрасы доценты
5. Хабибуллин Ильнур Ильдарович, Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районының Муса Җәлил исемендәге “1 нче гимназия” муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесенең директоры
6. Хайруллина Гульназ Рашитовна, Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районының Муса Җәлил исемендәге “1 нче гимназия” муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесенең татар теле һәм әдәбияты укытучысы
7. Хайруллина Гульнара Илсуровна, Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районының Муса Җәлил исемендәге “1 нче гимназия” муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесенең информатика укытучысы
8. Сөнгатуллина Ләйлә Мөхәмәтовна, Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районының Муса Җәлил исемендәге “1 нче гимназия” муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесенең татар теле һәм әдәбияты укытучысы

9. Галимова Гөлфинә Салихҗановна, Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районының Муса Җәлил исемендәге “1 нче гимназия” муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесенең татар теле һәм әдәбияты укытучысы
10. Әгълиуллина Фәйрүзә Фазыловна, Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районының Муса Җәлил исемендәге “1 нче гимназия” муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесенең башлангыч сыйныф укытучысы

**Сөй гомерне, сөй халыкны, сөй халыкның дөньясын** = Жизнь люби, люби отчизну, всё чем жив родной народ: (Укытучылар һәм укучыларның эзләнү-тикшеренү, проект һәм иҗади эшләре Бөтенрәсәй Форумы материаллары=Материалы всероссийского форума)/ - Түбән Кама, 2023. – 478 б.

Җыентыкта “Сөй гомерне, сөй халыкны, сөй халыкның дөньясын” Бөтенроссия форумында катнашучы укытучы һәм укучыларның доклад тезислары урын алды.

Җыентык материаллары гомуми белем бирү укытучысының инновацион эшчәнлегендәге төп аспектларны үз эченә ала: мәгарифкә яңалык өстәү, яңа педагогик технологияләр һәм методикалар кертү, укучыларның интеллектуаль-иҗади эшчәнлеген оештыру, инновацион педагогик проектларны һәм программаларны тормышка ашыру, мәктәп имиджын булдыру һәм уңай тәрбия мохите тудыру өстендә эшләү. Искәрмә: язмаларда автор орфографиясе һәм пунктуациясе сакланды.

Автор редакциясендә басыла

**УДК 37.01**

Эчтәлек


**Беренче бүлек. Укытучылар чыгышы.** 5

Александрова Алсу Исмәгыйль кызы. Татар телен заманча, кызыклы һәм эффектив укытуда интернет мәйданчыкларының роле 7

Аменова Эльмира Зөфәр кызы, Аменова Диләрә Ильнар кызы. Укучыларның иҗади эшчәнлеген һәм сәләтен үстерү ысуллары 12

Ахметзянова Лилия Мөхтәр кызы. Укучыларның сөйләм телен үстерүдә сүзлек диктантлары белән эш алымнарын куллану 14

Әхмәтҗанова Тәскирә Фатыйх кызы, Әхмәтова Миләүшә Индус кызы. Белем бирүдә коммуникатив технологияләр куллану аша сәламәт, белемле шәхес тәрбияләү 21

Валиева Рузалия Саедовна. Унарлы вакланмаларны тапкырлау 26

Гайнетдинова Гөлназ Фәнис кызы. Мөслим төбәге язучыларына багышланган интерактив уен 29

Галимова Гөлфинә Салихҗан кызы, Гыйздатуллина Эльмира Мирзаһит кызы. Укучыларга рухи-әхлакый һәм патриотик тәрбия бирү 37

Ганиева Рузилә Фәвәдис кызы. Ныклы белем алуга омтылган укучылар тәрбияләү 39

Гарипова Лилия Рәүф кызы, Гарипов Расим Фаиз улы. Тарихта эзле инсан 41

Гәрәева Гөлнара Риан кызы. Татар теле һәм әдәбияты дәресләрендә модельләштерү технологиясен куллану 45

Гимазетдинова Римма Әхәт кызы, Минехузина Ләйсән Рафис кызы. Балаларның сөйләм телен үстерүдә үстерешле уеннарның роле 49

Гиниятуллина Алсу Рафис кызы, Сибгатуллина Гульчачак Гайнетдин кызы. Күңел бизәге 51

Гыймранова Илсөяр Гарәфетдин кызы.Теле һәм әдәбияты дәресләрендә укучыларның иҗади сәләтен үстерү алымнары 54

Жуковская Руфина Касим кызы. ФДББС шартларында рефлексия - заманча дәрес өчен кирәкле шарт» темасына мастер-класс 57

Зарипова Әнисә Газизуловна. Татар әдәбияты дәресләрендә Р. Фәхреддин мирасын куллану 61

Исмагилова Ильсияр Гамирзяновна. Чәчмә әсәргә анализ (Гаяз Исхакыйның “Ул әле өйләнмәгән иде” повесте буенча) 64

Кульмухаметова Зульфия Эдуардовна. Галиҗәнап сүз 70

Куряева Людмила Петровна. Уку процессында креатив фикерләү үсеше технологиясе 79

Минегалиева Ләйсән Ризатовна, Аглиуллина Файруза Фазыловна. Укыту процессында яңа педагогик технологияләрне куллану 81

Мифтахова Эльмира Флур кызы. Әдәби әсәрләр өйрәнүнең нәтиҗәле алымнары 82

Мөбарәкшина Рузилә Рәшит кызы. Туган тел дәресләрендә укучыларда дәрескә уңай мотивация формалаштыру алымнары 85

Муратова Лариса Миншаех кызы, Шаймухаметова Фәнзилә Мирзанур кызы. Туган як тарихын өйрәнүдә яңа алымнар. 86

Насыйрова Миләүшә Сәлмән кызы. Эзлим, табам, ачам 91

Нәбиуллина Ландыш Илдус кызы. Туган тел дәресләрендә синквейн алымын куллану 94

Ризванова Фәнүсә Минигали кызы. Балалар язучысы буларак, Муса Җәлилнең ватанпәрвәрлек хисләре тәрбияләүдәге роле 98

Сайфутдинова Фарида Хасаншиновна. Әдәби әсәрләр укуга кызыксыну уятуда уен технологиясе 100

Сәлимова Гүзәлия Рәшит кызы, Фәрхетдинова Фәнирә Гарәф кызы. Рус телле балаларны татар телен өйрәнүгә теләк тудыру чаралары 105
Солтанов Радик Ибраһим улы, Солтанова Зөбәрҗәт Фиркат кызы. Башлангыч мәктәптә әйләнә-тирә дөньяны өйрәнү дәресләрендә пропедевтик тарих курсы өчен милли-региональ компонент материалларын куллану 108
Сөнгатуллина Ләйлә Мөхәмәт кызы, Хәйруллина Гөлназ Рәшит кызы. Һөнәр сайлау-җаваплы эш 114
Фалахиева Ильмира Ризатдин кызы, Миннегалиева Гөлназ Сәләхетдин кызы. Проект эшчәнлегенең өстенлеге 119
Фатхуллина Гузял Фагим кызы, Халикова Нурсина Далиф кызы. Яшь буында толерантлык тәрбияләү 121
Хайруллина Лилия Аркадьевна. Татар теле һәм әдәбияты дәресләрендә проект методын куллану 123
Хайруллина Лилия Миннефаяз кызы. Татар теле һәм әдәбияты дәресләрендә инновацион технологияләр куллану 128
Хакимова Рамзия Риф кызы, Нурмиева Резеда Равил кызы. Уен – җитди эш 139
Харисова Чулпан Сәгыйть кызы. Татар әдәбияты дәресләрендә укучыларның функциональ грамоталылыгын үстерү методлары (алымнары) 146
Хөсәенова Энҗе Абрамовна. Уен технологиясе кулланып, русс телле укучыларның коммуникатив компетенциясен үстерү 151
Шәймәрдәнова Мөслимә Габделхәй кызы. Дәрес темасын үзләштерүгә кызыксыну уяту алымнары 155
Якупова Венера Бадуртдиновна. Укытуның яңа шартларыннан – нәтиҗәләргә 158
**Икенче бүлек. Укучылар чыгышы.**
Абдульманов Демид. Бөек Ватан сугышы – минем гаиләм хәтерендә 162
Абрарова Ильвина, Сафиуллина Адилә. Бөек Ватан сугышы ветераны Демидова Екатерина Ивановнаның тормыш һәм сугышчан юлы 164
Арсланов Айдар. Шигъри сәяхәт 178
Әсхадуллина Айзилә. Сугышның да үз романтикасы... (Шагыйрь йөрәкле солдат - Гыйләҗев Фаекъ Гыйләҗетдин улы.) 179
Афанасьева Лиана. Көек-Ерыкса авылы микротопонимнары 186
Ахметзянова Ясмина. Туган ил 195
Буланова Диана. Үткәннәрдән калган ядкарь буйлап... 196
Валиева Камилла. Батыр солдат һәм шагыйрь Хәйретдин Мөҗәйнең Бөек Ватан сугышы чоры иҗатында солдат образы 202
Валиева Лейла. Нургатина Раиля Раифовна, татар теле һәм әдәбияты укытучысы 213
Вәлиуллина Гүзәл. Театр тарихы һәм театр сәхнәсендә балкыган йолдызлар 223
Газетдиов Раяз. Муса абыйга 241
Галактионова Регина. Исеме җырларда җырлана 242
Галиуллина Алинә. Әби-бабаларыбыздан калган уеннар 252
Гарипов Габделкәрим. Авыл күрке- мәчет 260
Гарипова Эльвина. Укытучы һөнәре : кичә, бүген, иртәгә 267
Гилемханова Язилә. Табиб һөнәре (хирург белгечлеге мисалында) 274
Гилязова Нурзиля. Сезгә әйтер сүзем бар! 281
Гыйрфанов Сөләйман. Җәлил һәйкәле 286
Домолазова Анастасия. Такталачык авылы топонимик атамаларының килеп чыгышы 287
Еремеева Ильвина. Иске Рәҗәп авылы топонимикасы 295
Закиров Рөстәм. Үткәнен оныткан халыкның киләчәге юк 302

| | |
|---|---|
| Зиганшин Билал. Татар телендә сленглар | 308 |
| Кадырова Камилә. Минем гаиләм авыллары исемнәренең мәгънәсе | 320 |
| Кәримуллна Әдилә. “Түбән Кама”, “Хатлар язам” шигырьләре | 323 |
| Низамов Ранил, Карга боткасы – язны каршы алу тарихы һәм традицияләре | 324 |
| Мөбарәкшин Илгиз. Туган ягым | 330 |
| Нуретдинова Рәзилә. Муса Җәлил эзләреннән | 332 |
| Раимова Самира. Һәйкәл булып баса ветераннар | 337 |
| Рәхмәтуллин Кәрим. Исемемнең мәгънәсе – тормышымның билгесе | 344 |
| Салимов Ильгам. Дөньяны бары тик Тынычлык яшәтә, яшәртә | 348 |
| Туктамышев Әмир. Инфокоммуникацион мохиттә татарча терминнар | 354 |
| Фәзуллина Илина. Ач, шигърият, серләреңне! | 369 |
| Фаттахова Айлина. Алтын бөртекләр | 376 |
| Федорова Карина. Укытучым - тәрбиячем минем | 377 |
| Федорова Милена. Бишек җырларының яшь буынны тәрбияләүдәге роле | 380 |
| Хәбибуллин Давид. Казан кремленың саклану системасы | 395 |
| Хайруллина Ясмина. Кушаматлар аша нәсел тарихы | 404 |
| Хәмидуллина Гөлшат. Бишек җырларының кеше тормышында тоткан урыны | 410 |
| Ханова Нурзилә. «Дару», «Бәхет» ( хикәя) | 417 |
| Хәсәнҗанов Шамил. Вакыт елгасы | 421 |
| Хикматуллина Ляйсан. Минем иҗатка кызыксынуым | 430 |
| Хузин Данил. Муса Җәлил һәм спорт | 433 |
| Шәмсивәлиева Ясминә. Башы бер, мәгънәсе мең... (Галимҗан Ибраһимов “Кызыл чәчәкләр” повесте буенча) | 440 |
| Шәмсиева Алсу. Әдип Маликовның “Яшьлек утравым” повестеның поэтик ономастикасы | 445 |
| Шарифуллин Данир. Халкым җәүһәрләре – зур мирас | 455 |
| Шәйхетдинова Рүзилә. Туфан Миңнуллин әсәрләрендә мифик образлар | 462 |
| Юнысова Ралия. Татар хатын-кыз баш киемнәренең милли-сәнгати үзенчәлекләре | 467 |
| Яковлева Карина. Иҗат җимешләре | 472 |

## Кереш сүз

Һәр милләттә исеме телгә алынуга ихтирам уята торган шәхесләр була. Муса Җәлил әнә шундый исемнәрнең берсе. Юк, ул исем генә түгел, бәлки тирән мәгънәле символ да. Чөнки бу исемнең синонимнары булып батырлык, кыюлык, каһарманлык, талантлылык, ватанпәрвәрлек,тугрылык кебек тирән мәгънәле сүзләр тора. Шагыйрь Муса Җәлил үзенең бөтен гомерен туган иленә, туган халкына багышлаган. Аның бөтен тормышы — героик тормыш ул. Муса Җәлил шигырьләрендә туган халкының азатлыгы өчен көрәштә үзен корбан итәргә әзер торган көрәшче образы тудыра, үзе дә халык эше өчен соңгы сулышына кадәр аяусыз көрәшә. Ул халык эше өчен көрәшергә биргән антын тиңдәшсез батырлык, искиткеч ныклык белән үти, үз халкының азатлыгы өчен гомерен бирә.

Республикабызда бу герой исемебелән аталучы урамнар, мәдәният үзәкләре бар. Түбән Камада урнашкан безнең 1-нче номерлы Гимназия дэ Муса Җәлил исемен горур йөртә. Федераль бюджет югары белем бирү учреждениесенең «Яр Чаллы дәүләт педагогика университеты» психолого-педагогик һәм мәхсус дефектологик белем бирү кафедрасы, Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы башкарма комитеты мәгариф идарәсе, Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районының Муса Җәлил исемендәге “1 нче Гимназия” муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесе тарафыннан 2023 елнын 15 февралендә “Сөй гомерне, сөй халыкны, сөй халыкның дөньясын” Бөтенрәсәй Форумы үткәрелде. Форумның максаты укытучылар һәм укучыларның фәнни-тикшерү эшчәнлегенә кызыксыну уяту. Мәктәп укытучылары һәм укучыларны үзләренең эзләнү-тикшеренү, проект һәм иҗади эшләрен тәгъдим иттеләр. Конкурс эшләре 8 юнәлеш буенча кабул ителде һәм эксперт комиссиясе тарафыннан бәяләнде. Чыгыш ясау нәтиҗәләре буенча җиңүчеләр диплом, сертификатлар белән бүләкләнде һәм аларның эшләре әлеге җыентыкка кертелде. Беренче бүлектә укытучыларның хезмәтләре, ә икенче бүлектә мәктәп укучыларының проектлары урын алды. Тәгъдим ителгән эзләнү-тикшеренү, проект һәм иҗади эшләр төрле көнүзәк проблемаларны күтәрәләр: анда туган тел проблемасы да, тарихны өйрәнү үзенчәлеге дә, патриотик тәрбия дэ, химия, биология, физика фәннәре сораулары да, милли тәрбия дэ чагылыш тапты. Бу яшь буынның битараф булмавын, киләчәгебезнен өметле булуын, безнең чорда да “җәлилчеләр” булуын тагын бер кат исбатлый.

Халык тормышы турында кирәген генә белеп иҗат итүче Җәлил гомере җырга әверелде. Ул җыр безгә тыныч кына яшәргә, хуш күңелле, битараф булырга ирек бирми; безне янарга, дөрләргә өйрәтә, халыклар бәхете өчен көрәшкә өнди.

## Беренче бүлек. Укытучылар чыгышлары.

*Александрова Алсу Исмәгыйль кызы,*
*Татарстан Республикасы*
*Түбән Кама муниципаль районы*
*“Аерым фәннәрне тирәнтен өйрәнүче*
*27 нче гомуми урта белем бирү мәктәбе”*
*муниципаль бюджет белем бирү*
*учреждениясенең югары категорияле*
*татар теле һәм әдәбияты укытучысы*

### “Татар телен заманча, кызыклы һәм эффектив укытуда интернет мәйданчыкларының роле”
### (Google Clsassroom мәйданчыгы үрнәгендә)

Татар теле - халыкара мәйдандагы зур абруйлы телләрнең берсе. Шулай булгач, ул үзен саклаучы, хөрмәт итүче халкына дәүләт теле буларак хезмәт итәрлек тулы көчкә ия. Туган телебезне камилләштерү, үстерү – дәүләт күләмендәге җитди һәм әһәмиятле бурычларның берсе. Татар теленең кулланылыш даирәсен киңәйтүнең, аны үзләштерүне тиешле дәрәҗәгә күтәрүнең төп юлы – рус мәктәпләрендә укучыларга татар теле һәм әдәбиятын сыйфатлы, нәтиҗәле итеп укыту. Шуңа күрә, заман таләбе бүгенге көндә татар телен укытуда зур үзгәрешләр сорый. Укытучыларыбыз алдына «Татар телен ничек укытырга», «Дәресләрне ничегрәк кызыклы итеп үткәрергә?» дигән сораулар килеп баса. Шулай булгач, заман укытучылардан яңалык, үзгәрүчәнлеккә омтылуны таләп итә.

Укыту процессында яңа педагогик технологияләрне куллану яңа метод һәм алымнарны үстерүгә, укытучыларга эш стилен үзгәртеп, яңача эшләргә, педагогик системада структур үзгәртеп коруларны гамәлгә ашырырга ярдәм итә. Бу исә педагогик процессны оештыруга һәм аның белән идарә итүгә үзенчәлекле бурычлар куя. Татар телен инновацион технологияләр белән укыту – уку процессын яңача оештыру дигән сүз. Аның мөһим мәсьәләләре булып өйрәнелә торган фәнгә кызыксыну уяту, укучыларның танып-белү эшчәнлеген үстерү, аралашу процессында үзара аңлашу һәм ярдәмләшү мохите тудыру, укучыларның иҗади сәләтләрен ачыклау һәм үстерү тора.

Соңгы вакытта барлык фәннәр буенча да, шул исәптән татар теле һәм әдәбиятыннан да, мәгълүмати ресурслар саны артты. Интернет торган саен уку-укыту эшчәнлегендә файдалана алырлык мөмкинлекләргә ия була бара. Интернет челтәре укучыга һәм укытучыга кирәкле мәгълүматны төрле урыннан эзләп табу шартларын тудыра.

Татар теле дәресләрендә цифрлы белем бирү ресурсларын куллану укучыларда уку, язу күнекмәләрен формалаштыру һәм үстерү, кирәкле материал табу, укучыларның сүзлек запасын баету, татар телен өйрәнүгә мотив формалаштыру кебек бурычларны үтәргә

мөмкинлек бирә. Бүгенге көндә “Ана теле”, “Сәлам” дәреслеге сайтлары, TATARSCHOOL порталы, “Татар иле” энциклопедиясе сайты, “Әйдә! Online” кебек ресурсларны укучылар, эти-әниләр һәм укытучылар бик теләп кулланалар. Болар – күп очракта татар телен мөстәкыйль рәвештә өйрәнер өчен булдырылган проектлар. Мәктәпләр өчен дә эчтәлек ягыннан сыйфатлы, балалар өчен кызыклы, заманча технологияләрне кулланып ясалган электрон платформалар әлегә юк. “Учи.ру”, “Фоксфорд”, "ЯКласс", "Инфошкола" кебек ресурслар төрле фәннәрне, темаларны үзлектән һәм дистанцион үзләштерү мөмкинлеген бирә, ләкин аларның берсендә дә татар телле курс юк. Бу проблема дистанцион уку вакытында бигрәк тә кискен чагылды. Күпчелек укытучыларга татар теле дәресләрен WhatsApp мессенджеры ярдәмендә үткәрергә туры килде. Бүгенге көнә татар телендә белем бирүче, балалар белән аралашу, белемнәрен тикшерү мөмкинлеге булган интернет мәйданчык булдыру иң әһәмиятле бурычларның берсе.

Дистанцион уку шартларында минем алдымда укыту процессын ничек башкарырга, укучыларның мөстәкыйль эшен ничек оештырырга һәм аларның биремнәренең үтәлешен ничек контрольдә тотарга дигән сорау туды. Дистанцион уку өчен тәкъдим ителгән барлык вариантларны өйрәнеп, мин Google Classroom мәгариф платформасына сайладым.

Google Classroom мәйданчыгы дистанцион уку вакытында белем бирү процессын алып барырыга ярдәм итсә, ә гадәти белем бирү вакытында өстәмә һәм мөстәкыйль белем алу мөмкинлеге киңәйтә. Укучылар бу мәйданчыкта интернет ресурслар белән танышалар, интерактив күнегүләр эшлиләр, бер-берсенең хезмәтләренә бәя бирә һәм төзәтмәләр кертә алалар.

Google Classroom - Google компаниясе тарафыннан махсус мәгариф учрежденияләре өчен ясалган өстәмә белем бирү тарату, тикшерү һәм билге кую мөмкинлеге булган веб-сервис.

Бу мәйданчыкта:

• класс/курс булдыру;
• класска /курска укучыларны җәлеп итү;
• уку һәм өстәмә белем бирү материалларын булдыру;
• укучыларга биремнәрне тәкъдим итү;
• укучыларның биремнәрен бәяләү һәм аларның барышын күзәтү;
• укучыларның аралашуын оештыру мөмкинлекләре бар.

Укучылар класс бүлмәсенә шәхси код буенча чакырыла ала. iOS и Android мобиль кушымтасы кулланучыларга фоторәсем төшерергә, аларны биремнәргә беркетергә, башка кушымталардан файллар белән алмашырга мөмкинлек бирә. Укытучы укучының бирем үтәлешен күзәтеп бара, билге куеп, эшне кире кайтара, өстәмә бирем бирә, комментарияләр яза ала.

Үземнең хезмәтемдә мин Google Clsassroom мәйданчыгын түбәндәге формаларда кулланам:
-дәрескә әзерләнү өчен конспектлар төзим, дәрес материалларын курс тасмасында урнаштырам (аудиофайллар, видео, сайтларга сылтамалар);
- дәрес этапларында төрле эш формаларын оешырам:
а) өй эшен тикшер этабында - Google сыйныфында билгеләнгән һәм башкарылган өй эшләрен тикшерү;
ә) белемнәрне актуальләштерү этабында -тасмага урнаштырылган видео яки рәсемнәрне куллану (күпчелек вебсайтлар һәм кушымталар хәзерге вакытта Google Classroom белән интеграцияне хуплый. Мәсәлән, викторинада укытучы тематик сүзлек ясый һәм аны сыйныфка «сыйныфта бүлешү» төймәсенә басып тәкъдим итә ала. Gookwidgets кушымтасы, Google Classroom да киң кулланыла, шулай ук дәресләрне җанландырырга ярдәм итә);
б) белемнәрне тикшерү этабында - Google формалары, тестлар үзләштерү дәрәҗәсен автоматик рәвештә күрсәтергә мөмкинлек бирә.

Google форма сервисы мөмкинлекләрен тагын бер кат ассызыклыйм. Алар безгә интерактив режимда төрле сорауларны сайларга, эзлеклелеген һәм җавап вариантларын үзгәртергә, реаль вакытта җавапларны күзәтергә һәм мәгълүматны һәм нәтиҗәләрне анализларга мөмкинлек бирә. Ягъни, укыту нәтиҗәләрен педагогка уңайлы һәм укучыларга аңлаешлы формада контрольдә тоту бу мәйданчыкта бик җайлы башкарыла.

Шулай итеп, Google Clsassroom мәйданчыгы педагог өчен яхшы ярдәм. Педагог белән укучылар арасында бу мәйданчыкны куллану үзара бәйләнеш процессын күпкә тизрәк, җиңелрәк һәм нәтиҗәлерәк итә. Әгәр педагог Google класста интеграцияләнгән төрле вебсайтлар һәм кушымталар белән мөмкин кадәр күбрәк кулланырга тырышса, уку процессы укучылар өчен кызыклырак, динамик һәм нәтиҗәлерәк була.
Мин сезгә 9 нчы сыйныфның рус төркемнәре өчен төзелгән Google Clsassroom мәйданчыгын тәкъдим итәм.

Иң беренче чиратта интернетта Google Classroom мәйданчыгын булдырылды.
https://classroom.google.com/h
https://classroom.google.com/c/Mjc2ODY2NDkxMzk4

Аннан Google Classroom мәйданчыгына укучылар тупланды. Моның өчен укучыларның WhatsApp төркеменә шәхси код буенча класс бүлмәсенә чакыру җибәрелде.
https://classroom.google.com/r/Mjc2ODY2NDkxMzk4/sort-last-name

9 нчы сыйныф программасына нигезләнеп, интерактив күнегүләр һәм интернет чыганакларга сылтамалар әзерләнде һәм укучыларга тәкъдим ителде:

1.“Без Татарстанда яшибез” темасына интерактив күнегүләр һәм интернет чыганакларга сылтамалар әзерләү

Бирем №1. “Без Татарстанда яшибез”
темасына интерактив күнегү
https://learningapps.org/10449926
https://classroom.google.com/c/Mjc2ODY2NDkxMzk4/a/Mjc2ODcxMDE0NTg0/details

Бирем №2 .“ Без Татарстанда яшибез”
(милли киемнәр)
https://learningapps.org/view2087326
https://classroom.google.com/w/Mjc2ODY2NDkxMzk4/tc/Mjc2ODY2NjEzMzU3

Бирем №3. “ Татарстан Республикасы”
(онлайн викторина)
https://classroom.google.com/c/Mjc2ODY2NDkxMzk4/a/Mjc2ODcxMDE0NjU4/details
https://www.triventy.com/join

2.“Һөнәр сайлау - җаваплы эш” темасына интерактив күнегүләр һәм интернет чыганакларга сылтамалар әзерләү, кроссворд төзү

Бирем №1. “Һөнәрләр” темасына кроссворд
https://classroom.google.com/c/Mjc2ODY2NDkxMzk4/a/Mjg2MTI1NDgwMTY1/details

Бирем №2. “Һөнәрләр” темасы
(сүзләрне рәсемнәр белән тоташтырырга)
https://learningapps.org/view837005
https://learningapps.org/view4663052

Бирем №3. "Һөнәрләр" бүлеге буенча тест
https://docs.google.com/forms/d/e/1FAIpQLSemv0ALw4_FmyIafSB1WA5VTy2ocspApC5YR3RgC8y06OP0CQ/viewform

Бирем №4. "Һөнәрләр" темасына онлайн-викторина
https://classroom.google.com/c/Mjc2ODY2NDkxMzk4/a/MjkyMDI0ODA2NTUy/details
http://triv.in/187869

Бирем №5. "Һөнәрләр" темасына видеоязма
https://www.youtube.com/watch?v=x6_weXaUuTs

3. “Сәламәтлек – зур байлык”темасына интерактив күнегүләр һәм интернет чыганакларга сылтамалар әзерләү

Бирем №1. «Сәламәтлек» темасына интерактив күнегү
https://learningapps.org/view1046186

Бирем №2. «Сәламәтлек» темасы

(сүзләрне рәсемнәр белән тоташтырырга)
https://learningapps.org/view11295149

Бирем №3. «Тән әгъзалары» темасына видеоязма
https://classroom.google.com/w/Mjc2ODY2NDkxMzk4/t/all

Бирем №4. «Сәламәтлек» темасына тест
https://quizlet.com/ru/558722279/%D0%A1%D3%99%D0%BB%D0%B0%D0%BC%D3%99%D1%82%D0%BB%D0%B5%D0%BA-flash-cards/

4.“Бөек Ватан сугышы” темасына интерактив күнегүләр һәм интернет чыганакларга сылтамалар әзерләү

Бирем №1. Беренче Советлар Союзы Герое Никита Кайманов (өстәмә чыганаклар)
https://ursaevo.ucoz.net/publ/26-1-0-166

Бирем №2. «Бөек Ватан сугышы турында әсәрләр» темасын онлайн-викторина
http://triv.in/199694
https://classroom.google.com/c/Mjc2ODY2NDkxMzk4/a/MzUxNzI2NzE0MTA5/details

Бирем №3. «Беркем дә, бернәрсә дә онытылмый...» Google Презентация
https://classroom.google.com/w/Mjc2ODY2NDkxMzk4/t/all
https://classroom.google.com/c/Mjc2ODY2NDkxMzk4/a/MzUxNzI2OTEyMjQ5/details

Һәр биремнән соң укучыларның биремнәре бәяләнде, эш барышын күзәтү ясалды һәм нәтиҗәләр анализланды.

Google Classroom мәйданчыгында эшне алга таба дәвам итү күздә тотыла. Татар теле һәм әдәбияты укытучыларын җәлеп итеп, һәр сыйныф өчен махсус интернет мәйданчыклар (платформалар) ясау планлаштырыла.

*Аменова Эльмира Зөфәр кызы Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы «22 нче гимназия» муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесенең беренче категорияле татар теле һәм әдәбияты укытучысы Аменова Диләрә Ильнар кызы Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районының Муса Җәлил исемендәге “1 нче гимназия” муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесең чит телләукытучысы*

**Укучыларның иҗади эшчәнлеген һәм сәләтен үстерү ысуллары.**

Бүген укучының иҗади сәләтен үстерү – җәмгыятьнең мөһим проблемаларыннан берсе. Соңгы вакытта укытуда, федераль дәүләт белем бирү стандартларына күчү сәбәпле, әлеге проблема бигрәк тә актуаль. Яңача белем таләпләренә нигезләнеп, укучыларның иҗади активлыгын үстерү, белемнәрне мөстәкыйль рәвештә куллана белүче, заманга яраклашкан шәхесләр тәрбияләү –укытучылар алдында торган төп бурыч.

Укытучы галим дә, компетентлы шәхес тә, укучыларга үрнәк өлге һәм чын дус та булырга тиеш. Әнә шундый югары сыйфатларга ия булганда гына ул үз укучыларыннан уңай нәтиҗә көтә алачак, заман таләпләренә яраклашкан сәләтле шәхесләр тәрбияли алачак. Ә заман таләпләре бүген бик югары.

Ә нәрсә соң ул сәләт? Кешедә ул кайдан һәм кайчан барлыкка килә? Баланың сәләтлеме юкмы икәнен ничек белергә? Сәләтне ничек үстерергә? Иҗади эшчәнлек белән сәләтнең бәйләнеше нәрсәдә чагылыш таба? Гомумән, бу проблемага кагылышлы сораулар барыбызны да уйга сала. Сәләтлелек дигәндә без укучының акыл үсешенең югары дәрәҗәсен күзалдында тотабыз.Укытучы өйгә биргән эшләр белән генә чикләнмичә, өстәмә әдәбият укучы, өстәмә биремнәрнәр үтәүче балаларны сәләтле балалар рәтенә кертергә була. Әгәр бала сәләтле булса, ул тәкъдим ителгән мәгълүмәтләрнең саны һәм сыйфаты белән генә канәгатьләнергә теләми, һәм андыйлар үзләренә югарырак таләпләр куя торган мәктәпләрдә тырышыбрак укырга омтылалар.

Аңлы, белемгә омтылучан балалар тумыштан сәләтле яисә тиешле тәрбия алу нәтиҗәсендә үзләренең иптәшләреннән камилрәк акылга ия булулары белән аерылып торалар.Сәләтне үстерү өчен балаларның фәннәр буенча биремнәрне һәм үзләре алдына куелган бурычларны эзлекле һәм системалы үтәүләренә ирешү сорала. Һәр укучы сәләтле, ләкин аның сәләтен күрә һәм үстерә белергә кирәк. Максатка ирешү өчен балада ихтыяр көче

тәрбияләргә, максатын билгеләргә, аңа ирешү өчен бөтен көчен, сәләтен, игътибарын тупларга өйрәтергә кирәк. Шушы сәләтләргә ия булган укучы гына, эти-әни һәм укытучы белән берлектә, тормышка яраклы шәхес булып тәрбияләнә ала.

Мәктәбебезнең күпсанлы сәләтле, тырыш һәм дә талантлы балаларын һәръяктан танып, ача белү, аларга ярдәм кулы сузу – мөгаллимнән дә зур сабырлык таләп итә. Шунлыктан, үз чиратыбызда без дә аларны вакытында күреп алырга, тиешенчә ярдәм күрсәтергә тырышабыз, югыйсә, баладагы теләсә нинди сәләт, талант үсеше тоткарланырга, кайбер очракта хәтта юкка чыгарга да мөмкин.

Бу юнәлештә эшләгәндә берничә мәсьәләне хәл итәргә кирәк була. Аларның беренчесе — укучыларда белемнең үсеш дәрәҗәсен бик тиз һәм төгәл билгеләү һәм, шуның белән бәйләнешле рәвештә, дәресләрнең тема һәм формаларын планлаштыру вариантларын төгәл фәнни нигезләп сайлап ала белү.

Икенчесе — дәрестә үсеш дәрәҗәләре һәм әзерлекләре төрлечә булган укучыларның тиешле белем алуына ирешү, дәресләрдә нинди алым һәм эш формалары кулланырга кирәклеген билгеләү.

Өченчесе — дәрестә укытучы-укучы арасында үзара аңлашу булдыру.

Укучыларның белем дәрәҗәсен үстерү өчен укытучылар төрле алымнар кулланалар. Хәзерге вакытта укучыларның сәләтләрен арттыруның берничә принциплары эшләнгән. Аларның беренчесе-өйрәнгән материалны кат-кат кабатлап укыгач кына истә кала; икенчесе-төп фикерләрне ачыклау,аерып күрсәтү; өченчесе-укучыда чынбарлыкны тою хисе, төрле мәгълүматларны исәпләп карау,тормышта үзеңә юнәлешне билгеләү күнекмәсе булдыру; дүртенчесе-һәр дәрестә математик язу күнекмәләрен кабатлау; бишенчесе-һәр дәрестә мәҗбүри рәвештә 10-15 минутлык мөстәкыйль эшләр эшләү; алтынчысы- укучыларның белемен һәр көнне тикшерү.

Сәләтле балалар белән эшләүдә яңа эш алымнары һәм төрләре, яңа мөмкинлекләр, дәресләрне яңача оештыруның яңа юнәлешләре барлыкка килә.

Балаларның ни дәрәҗәдә сәләтле булулары укучыларның бер-берсенең белемен тикшерү, проектларны яклау, дәрес-конференцияләрдә, семинарларда ачык күренә.

Олимпиадалар уздыру – укучыларның иҗади һәм танып белү сәләтен активлаштырырга, талантлы балаларны ачыкларга мөмкинлек бирә, белем туплау белән кызыксынуны арттыра. Олимпиадаларга әзерләнгәндә, төрле эш алымнары кулланыла. Укытучы белән укучы арасындагы әңгәмәләр, фикер алышулар, тест биремнәрен үтәү, яңа чыккан фәнни китаплар, методик кулланмалар белән танышып, өйрәнеп бару зур әһәмияткә ия. Дәресләрдә бу укучыларга, темаларны үткән вакытта, өстәмә чыганаклардан файдаланырга, иҗади эзләнергә кушыла.

Фәнни конференцияләргә әзерләнүнең дә укучылар сәләтен үстерүдә зур әһәмияте бар. Бирелгән тема буенча укучы өстәмә чыганаклардан файдаланып әзерләнә. Үзен кызыксындырган сорауларга җавап эзли. Теманы тулысынча ачып бирү өчен, берничә чыганактан файдалана. Үзенең дәлилләрен берничә галимнең фикерләре белән ачыклый. Монда укучының мөстәкыйль фикер йөртүен, эзләнүен, нәтиҗә ясавын ассызыклап үтәргә кирәк.

*Ахметзянова Лилия Мөхтәр кызы,*
*Татарстан Республикасы Әгерҗе районы*
*муниципаль бюджет белем учреждениесе*
*Салагыш урта гомуми белем бирү мәктәбенең*
*I категорияле татар теле һәм әдәбияты*
*укытучысы*

**Укучыларның сөйләм телен үстерүдә сүзлек диктантлары белән эш алымнарын куллану**

Бүгенге көндә, татар телен укыту мәсәләсе киеренке хәл рәвешен алган заманда, татар теле укытучыларының укучылар, ата-аналар, милләтебез алдында җаваплылыклары тагы да артты. Башка милләт кешесе генә түгел, хәтта үз милләтеңнән булган кешенең дә “Нигә кирәк ул татар теле? Аның белән ерак китеп булмый” дигән кебек фикерләрен ишеткән хәлдә туган телгә карата хөрмәт һәм кызыксыну уяту укыту-тәрбия эшендә яңа алымнар куллануны таләп итә.

Туган телебезнең, әдәбиятыбызның асыл җәүһәрләрен укучы күңеленә җиткерүнең нинди үтемле юлларын табарга? Иҗади фикерләү сәләтләрен, грамоталылыкларын ничек үстерергә? Үз теленнең, үз милләтеңнең кеше өчен иң кадерле, изге төшенчәләр булуын ничек төшендерергә?

Мин, туган тел һәм әдәбият укытучысы буларак, туган тел һәм әдәбият дәресләрен укучы өчен мөһим тормыш дәресләре дип саныйм. Әдәби әсәрләрне, текстларны анализлаганда укучыларны уйландыра торган проблемалы сораулар бирәм, һәр укучының уйлануына һәм үз фикерен әйтүенә ирешергә тырышам.

Татар теле һәм әдәбиятын укытуда предметара бәйләнешләр куллану, һичшиксез, укучыда белем алуга кызыксыну хисе уята. Ул гына да түгел, телне гамәли рәвештә үзләштерүгә этәрә. Менә шуңа күрә дә мин татар теле һәм әдәбияты дәресләрендә предметара бәйләнеш булдыруга зур игътибар бирәм. Федераль Дәүләт белем бирү стандарты

нигезләрендә дә бу төп игътибарга алына: универсаль уку күнекмәләрен яисә метапредмет компетенцияләр формалаштыру дигән сүз.

Татар теле дәресләрендә алган белемнәрне ныгыту максатында әдәбият материалларын бик уңышлы кулланырга була: татар язучыларының әсәрләреннән файдалану, шигырьләрне сәнгатьле уку; грамматик категорияләрне кабатлаганда мәкаль-әйтемнәрне, табышмакларны, җырларны файдаланырга мөмкин.

Язу – телнең график формасы, ул – гаять әһәмиятле аралашу чарасы. Орфография язу теленең тәртипкә салынган кагыйдәләрен, дөрес язу юлларын үз эченә ала.

Урта мәктәп укучысы орфографияне өйрәнү нәтиҗәсендә үз фикерен җиңел итеп грамоталы язу, аңлап һәм тиз уку дәрәҗәсенә ирешергә тиеш.

Текст эчтәлеге ягыннан төзек һәм кызыклы булырга мөмкин, әмма анда орфографик хата булса, ул уңай бәяләнә алмый. Хаталы язуны уку авырлаша, әйтергә теләгән фикер дөрес аңлашылмый, ниһаять, ялгыш язу кешенең грамотасызлыгын күрсәтә, аның дәрәҗәсен төшерә.

Әдәби тел грамматик закончалыклар, орфоэпик һәм орфографик кагыйдәләр белән нормалаша. Әмма теләсә кайсы телдәге күренеш һәм фактларның барлык үзенчәлекләре дә аерым кагыйдә һәм искәрмәләрдә чагылып бетмәскә мөмкин. Бу хәлне искә алмау китап, газета һәм журнал битләрендә төрлечә язуга сәбәп була.

Логик яктан дөрес фикер йөртә белү һәм үз фикереңне ачык һәм анык, кирәгенчә кыска һәм матур итеп, татар әдәби теленең грамматик, лексик һәм орфографик нормаларына туры китереп бирә белү грамоталылыкның киң мәгънәсе булса, орфографик һәм пунктуацион грамоталылык исә аның тар мәгънәсе була. Кеше үзенең сөйләмен дөрес төзеп, әдәби тел нормаларына туры китереп һәм язма рәвештә башкаларга грамоталы итеп бирә һәм логик фикер йөртә белсә, ул тулы грамоталы була ала.

Орфографик күнекмәләр җитәрлек булуның зур гамәли әһәмияте булуын истә тотып, укучыларга орфографик грамоталы булуның әһәмиятен аңлатып эш итү уңай нәтиҗәләр бирә: бердән, кеше дөрес язмаса, аны уку техникасы авырлаша, икенчедән, язучы бирергә теләгән фикерен дөрес биреп җиткерми, яки аннан икенче яисә ялгыш мәгънә аңлашыла һәм, өченчедән, ялгыш язу кешенең грамотасызлыгын күрсәтә, аның дәрәҗәсен төшерә һәм ул уңай бәяләнә алмый.

Татар телендә орфографик нормалар нигездә 2 сәбәп аркасында бозыла:

1. җирле диалект үзенчәлекләре тәэсирендә(сөйләгәнчә язу);
2. татар телендә әйтелеш белән язылыш арасында зур аерма булу сәбәпле.

Авыр һәм катлаулы эшләрнең берсе булып орфографиягә өйрәтү исәпләнә. Чөнки ул укучыларның төрле яклы һәм катлаулы психик эшчәнлегенә, алар үзләштерергә тиешле

материалның төрлелегенә һәм күп кенә кагыйдәләрне үзләштерә алуларына бәйле. Бу эшне уңышлы алып бару өчен, төрле метод һәм алымнар кулланып эш итәргә һәм, максатка ярашлы итеп, аларны сайлап ала белергә, шулай ук психологик һәм методик якны алда тотып эш итәргә кирәк була.

Укучыга эш биргәндә, аны эшләү алымын җентекләп аңлату, аны эшләгәннән соң гына икенче эш бирү, өйрәнә торган орфограмманың авырлык һәм җиңеллек дәрәҗәсен, укучының орфограмманы ничек үзләштерүен истә тотып эш итү, язма эшләрнең төрен һәм санын билгели белү һ.б. шундый методик таләпләрне үтәгәндә генә максаткаирешеп була.

Кайбер укучылар орфограммаларны үзләштереп җиткермәсә, алар белән аерым эшләү, яңа орфограммаларны өйрәнүгә бәйләп, аны кабатлап тору һәм, шул рәвешчә, укучыларга ныклы күнекмәләр бирү – укытучының изге бурычы.

Метод һәм алымнарны, орфографик күнегүләрне мөмкин кадәр төрләндерү, аны эшләр белән бәйләү орфографиягә өйрәткәндә уңай нәтиҗәләр бирә. Нигездә, грамматика дәресләрендә кулланылган түбәндәге метод һәм алымнар белән эш итәбез: күчереп язу, грамматик-орфографик анализ, диктантлар язу, орфографик-грамматик уеннар, сүзлекләр белән эш, төрле күнегүләр, мөстәкыйль һәм иҗади эшләр үткәрү (изложение, сочинение, эш кәгазьләре язу) һ.б.

**Күчереп язу** укучыларны дөрес язарга өйрәтү дә уңышлы алымнардан санала. Ләкин аны, әзер текстны турыдан-туры механик рәвештә күчерүгә кайтарып калдырмыйча, билгеле бер орфографик бирем белән катлауландырырга кирәк. Шул вакытта гына укучының эш белән кызыксынуы, мөстәкыйль активлыгы үсә һәм ул нәтиҗәле була.

Аны түбәндәге төр биремнәр белән катлауландырырга мөмкин: төшеп калган хәрефләрне яки кушымчаларны өстәп күчереп язу; бирелгән тексттан калынлык һәм аеру билгеләре булган сүзләрне ике баганага күчереп язу; билгеле бер аваз хәрефләренең яки морфемаларның асларына сызып, күчереп язу; тактада, дәреслектә, карточкаларда бирелгән тексттагы бер форманы икенче форма белән алыштырып күчереп язу; әдәбият белән бәйләнешле күчереп язу. Ул болай үткәрелә: әдәбият дәресендә өйрәнгән текст буенча укучыларга сорау бирелә. Шул сорауга җавапны укучы тексттан таба һәм эчтән яки әкрен укып, шуны дәфтәренә күчереп яза. Бу алым укучының сөйләү һәм язу телен үстерүгә дә, дөрес язу күнекмәләре булдырырга да һәм әдәбият белән бәйләргә дә ярдәм итә.

**Диктантлар.** Укучыларны дөрес язарга өйрәтү максаты белән, укытучылар төрле төр диктантларны уңышлы үткәреп киләләр. Ул орфографиягә өйрәтү методикасында булган башка төр методик алымнар арасында әһәмиятле урын алып тора. Диктант орфограммаларны үзләштерү өчен генә түгел, бәлки грамматика дәресләрендә укучыларның алган белемнәрен ныгыту, аны алдагы эшләрендә файдалана белү, сөйләү һәм язу телен үстерү һәм сүзлек

запасын арттыру максаты белән дә үткәрелә. Шулай ук укучыларга төрле яклы тәрбия бирү дә күздә тотыла. Мәктәптә түбәндәге диктант төрләре уңышлы үткәрелә: иҗади диктант, сайланма диктант, искәртмәле диктант, аңлатмалы диктант, ирекле диктант, сүзлек диктанты, сынама (танышу-тикшерү) һәм контроль диктант.

**Орфографик сүзлекләр белән эшләү.** Дәрестә һәм өйдә төрле язма эшләрне, биремнәрне үтәгәндә, теге яки бу сүзне язарга кыенсынган очракта, укучылар орфографик сүзлекләрдән файдалана алалар.

Алардан системалы файдалану аркасында, укучыларда күзәтүчәнлек үсә, сүзләргә һәм хәреф составы ягыннан анализ ясау күнекмәләре камилләшә; авыр язылышлы сүзләрне хәтерләрендә ныгыталар һәм, шул рәвешле, бу эш орфографик хаталарны булдырмаска да ярдәм итә; орфография буенча методик алым һәм күнегүләрне төрләндерергә, орфографиягә бәйләнешле лексик эшләрне оештырырга, аларны кабатларга мөмкин була; укучыларны орфографик сүзлекләрдән файдаланырга өйрәтүнең әһәмияте зур.

Шулар арасыннан мин татар теле дәресләрендә укучыларның грамоталылыган үстерү юнәлешендәге эш тәҗрибәм белән уртаклаша алам. Билгеле булганча, татар теленең сүзлек составында гарәп, фарсы, рус теленнән һәм рус теле аша башка телләрдән кергән сүзләр бик күп. Татар теленең үз сүзләре арасында да, алынмалар арасында да кыен язылышлы сүзләр күп. Укучыларның грамоталылыгын күтәрү максатыннан мин укучылар өчен “Сүзлек диктантлары” төзедем. Алар алфавит тәртибендә урнаштырылган. Шулар нигезендә һәр класста сүзлек диктантлары өстендә эш алымын куллануны укучыларның грамотолылыгын күтәрүдә һәм сүзлек запасын баетуда уңышлы алым дигән нәтиҗәгә килдем. Һәр сүзлек диктантыннан соң, берничә грамматик бирем бирелә. Укучы ул биремнәрне үтәп, тел гыйлеме буенча төрле белемнәрен искә төшерә.Иң соңгы бирем итеп шушы сүзлеккә кергән сүзләр кергән берничә халык мәкале бирелә. Шул мәкальләрдәге фикерне ничек аңлавын белдереп, укучы 8-10 җөмләлек текст яза. Шул рәвешле, кыен язылышлы сүзне ул берничә тапкыр үзе дә кулланып, дөрес язылышын кат-кат күрә, иҗади фикер йөртү сәләтен дә үстерә, сөйләмен, хәтерен халык авыз иҗаты җәүһәре белән дә баета.(Кушымта)

Укучыларның дәрестән тыш эшчәнлеге федераль дәүләт стандартлары таләпләрен тулысынча тормышка ашырырга мөмкинлек бирә. Дәрестән тыш эшләр белем бирү процессының бер өлеше булып тора. Шуңа күрә, укучыларның белемнәрен тирәнәйтү, эстетик зәвыгын үстерү, дөньяга карашларын формалаштыру, иҗади сәләтләрен үстерү максатыннан, мәктәптә сыйныфтан тыш эшләрне оештыруга да нык игътибар итәргә кирәк.

Татар теле буенча аларның төрләре гаҗәеп күп: телдән журнал, бәйгеләр, викториналар, диспутлар, иҗат түгәрәкләре, галимнәр, язучылар белән очрашулар, экскурсияләр,конференцияләр һ.б. Бу эшләрнең барысы да төп программа материалын

тирәнтенрәк өйрәнүгә, киңәйтүгә, укучыларыбызның телебезгә, мәдәниятебезгә карата кызыксынуларын арттыруга хезмәт итәргә тиеш.

Дәрестән тыш эшләрне оештыруда  эзләнү характерындагы эшләр бирү бик отышлы дигән нәтиҗәгә килдем. Башта укучыларга аерым темаларга эзләнү характерындагы эшләр бүлеп бирәм. Шул эшләрнең нәтиҗәсе буларак газета яки альманах чыгарыла. Бу юнәлештәге эшне башкарганда, укучылар укытуның коммуникатив нәтиҗәләренә ирешәләр. Коммуникатив нәтиҗәләр үз эченә әңгәмәдәшеңне тыңлый белү, аралаша белү сәләтен, парларда яки күмәк эшли белү күнекмәләрен ала.

Мәктәбебездә урнашкан “Туган як музее” укучыларга өчен зур иҗади  чыганак булып тора. Музей материалларын эзләнү-тикшеренү эшләрендә уңышлы кулланабыз. Һәр экспонат – зур кыйммәткә ия. Авыл тарихына, табигатенә, ономастикасына, якташ язучыларга һәм башка сәнгать әһелләренә багышланган тикшеренү эшләребез белән укучылар төрле конкурс, конференцияләрдә катнашып, дипломнарга лаек булдылар.

Укучыларның иҗади сәләтләрен үстерүдә район күләмендә үткәрелә торган “Көмеш каләм” иҗат фестиваленең дә роле бик зур. Монда төрле мәктәп укучылары үзләренең иҗади көчләрен сыныйлар. Алар “Яшь шагыйрь», «Яшь журналист», «Яшь  хикәяче” секцияләренә бүленеп, бирелгән тема буенча иҗади эш башкаралар. Салагыш мәктәбенең бу җәһәттән дә горурланырлыгы бар: һәр елны укучыларыбыз алдынгы урыннарны яулап алып баралар. “Әгерҗе хәбәрләре”, “Яңарыш” газеталары  битләрендә дә укучыларыбызның иҗат җимешләре даими басылып тора.

Туган тел укытучысы булу –зур җаваплылык ул. Гаиләсендә татарча сөйләшергә җай тапмаган, татарча бер әдәби китап укырга яратмаган  ата-аналарның балаларында туган телгә хөрмәт хисе уяту, милли сыйфатлар тәрбияләү, милли үзаң уяту – һәммәсе туган тел укытучыларын борчый торган сораулар. Милләтнең саклануы турыдан- туры телгә бәйле. Әби-бабаларыбыз үз телләрен, йола-бәйрәмнәрен күпме гасырлар аша югалтмыйча,  саклап алып килеп безгә тапшырганнар, нинди генә авырлыкларны үтмәгәннәр. Тарихтан гыйбрәт итеп алырлык мисаллар бихисап...

Мин  һәр дәресемә зур җаваплылык хисе белән, дулкынланып, шатланып керәм. Әнә алар – миңа кызыксыну тулы күз карашларын төбәгән татар кызлары-уллары. Милләтебезгә хас йөз сызыклары күзләремне иркәли. Күңелләренә мәрхәмәтлелек, игелеклелек орлыкларын, зиһеннәренә белем нигезләрен, телләренә туган телебезнең сүз байлыгын күбрәк салып калдырырга иде аларның.

Кушымта

**Сүзлек диктанты №1**

Автобиография, автовокзал, автограф, агымсу, адәм, алиһә, ахирәт, ахмак, ахры, ахыры, ахрысы, ашъяулык, аһәң (ле), ашханә, авыру, афәт, архив, адрес, акбүз , ай-һай, аттестат, архитектор, атмосфера, аккордеон,аягүрә, ач-ялангач, аръяк, аккургаш, аппликация.

**Биремнәр:**

1. Кушма сүзләрне күчереп алырга, тамырларын билгеләргә.

2. 2 иҗекле алынма сүзләрне күчереп язарга.

3. Сингармонизм законына (рәт гармониясенә) буйсынган сүзләрне күчереп язарга.

4. Сүзләрне сүз төркемнәре ягыннан билгеләргә.

5. Аръяк сүзенә фонетик анализ ясагыз.

6. Түбәндәге татар халык мәкальләренең мәгънәсен сез ничек аңлыйсыз? Шул турыда аңлатып, 50 сүздән дә ким булмаган текст языгыз. Текстыгызда кереш сүз һәм кереш җөмләләр кулланыгыз.

***1) Ашның тәме тоз белән, адәмнең яхшылыгы сүз белән.***

***2) Адәмнең хөрмәт күрүе дә, хурлык күрүе дә үз кулында.***

**Сүзлек диктанты №2**

Бәхет, бәхәс, бәла, бәһа, берөзлексез, берсүзсез, билләһи, биниһая, беркатлы, бәхилләшү, беркем, бернәрсә, беркайда, бернинди, берьяклы, берьюлы, бәгырь, бәгърем, баһадир, берсекөн(гә), борщ, борынгы, бөтендөнья, бассейн, баштанаяк, баштүбән, башкала, берара, бервакыт, бертигез, бухгалтер.

1. Бөтендөнья сүзенә фонетик анализ ясагыз.

2. Беркем, бернәрсә, беркайда, бернинди сүзләре – алмашлыкның кайсы төркемчәсенә карый? Бу сүзләрне юклык алмашлыклары буларак тагын ничек кулланырга була?

3. Баһадир, борынгы сүзенә синоним табып, җөмлә төзеп языгыз.

4. Беркатлы кеше дип нинди кешегә әйтәбез?

а) икейөзле

ә) тиз ышанучан

б) ялагай

5. Кайсы сүз “Сүз көрәштерү” фразеологизмының мәгънәсенә туры килә?

а) бәхилләшү

ә) бәхәсләшү

б) берләшү

6. Түбәндәге татар халык мәкальләренең мәгънәсен сез ничек аңлыйсыз? Шуларның берсен сайлап алып, 50 сүздән дә ким булмаган текст языгыз. Текстыгызда кереш сүз һәм кереш җөмләләр кулланыгыз.

***1) Бәхет башы – тәүфыйк.***

***2) Үткен тел – бәхет, озын тел – бәла.***

***3) Һәркем үз бәхетенә үзе сәбәп.***

**Сүзлек диктанты №3**

Вазифа, вәгазь, вәгъдә, вәхши, варис, водолаз, военкомат, вөҗдан, васыять, варенье, винегрет, велосипед, вәкаләт.

1. Бирелгән сүзләрне, в хәрефенең 2 аваз белдерүен исәпкә алып, 2 төркемгә бүлеп языгыз.

2. Сингармонизм законына буйсынган сүзләрне күчереп языгыз.

3. Хәреф саны белән аваз саны туры килмәгән сүзләрне транскрипциядә күрсәтегез.

4. Бу сүзләр арасында намус сүзенә синоним булган сүзне күчереп языгыз.

5. Васыять сүзенә фонетик анализ ясагыз (1.Сүзне иҗекләргә бүлеп язарга, басымын билгеләргә. 2. Сүздәге аваз һәм хәрефләрнең санын билгеләргә. 3. Сузык авазларга һәм тартык авазларга аерым-аерым характеристика бирергә)

6. Түбәндәге мәкальләрнең икесен дә кулланып, 50 сүздән ким булмаган текст языгыз. Мәкальләрдә әйтелгән фикер белән сез килешәсезме? Язмагызда үзегез белән булган вакыйга турында язсагыз була.

***1) Вәгъдә – намус көзгесе.***

***2) 2) Вөҗданы пакь – йөзе ак.***

***(Шул рәвешле алфавит тәртибендә биремле диктантлар дәвам итә)***

**Кулланылган әдәбият**


1. Камаева Р.Б.,Мөхәммәтҗанова А.Х. Федераль белем бирү стандартларын тормышка ашыруда татар теле һәм әдәбияты укытучысына фәнни-методик ярдәм / төз.: – Казан: ТРМҮИ, 2015.

2. Сафиуллина Ф.С. Татар теленә өйрәтүнең фәнни-методик нигезләре - Казан, 2001.

3. Сафиуллина Ф.С., Зәкиев М.З. Хәзерге татар әдәби теле.- Казан, 2002

4. Татар халык иҗаты. Мәкальләр һәм әйтемнәр. – Казан, 1987.

5. Татар теленең орфографик сүзлеге. – Казан, 2017.

*Әхмәтҗанова Тәскирә Фатыйх кызы,*
*югары категорияле татар теле һәм әдәбияты*
*укытучысы Әхмәтова Миләүшә Индус кызы*
*Татарстан Республикасы Түбән Кама*
*муниципаль районы муниципаль бюджет*
*гомуми белем бирү учреждениесе "Аерым*
*фәннәрне тирәнтен өйрәнүле 15 нче гомуми*
*урта белем бирү мәктәбе"нең I нче категорияле*
*татар теле һәм әдәбияты укытучысы*

## Белем бирүдә коммуникатив технологияләр куллану аша сәламәт, белемле шәхес тәрбияләү

Федераль дәүләт белем бирү стандартының мәктәп алдына куйган бурычларын үтәп укучыларда предмет нәтиҗәләре генә түгел, ә шәхси һәм метапредмет нәтиҗәләре булдырып, универсаль уку гамәлләре формалаштыра алсак, бала мәктәптә алган белем-күнекмәләрне укыту-тәрбия процессында гына түгел, ә реаль тормышта да куллана ала

Татар теленнән укыту-методик комплектларының концептуаль нигезе -аның коммуникатив һәм танып-белү юнәлеше.

Коммуникатив юнәлеше укучыларга телне аралашу чарасы буларак үстерү, кирәкле мәгълүматлар туплау, телдән һәм язма сөйләмне камилләштерү мөмкинчелеге бирә.

**Коммуникатив эшчәнлек** бер-береңне тыңлый һәм аңлый белүне, мәгълүматны тулы һәм төгәл кабул итә һәм тапшыра белүне, үз фикереңне диалогта һәм монологта башкаларга җиткерә белү күнекмәләрен үстерүне үз эченә ала.

- Бүгенге көндә ике татар баласының аралашуына игътибар итсәк, алар русча аңлашалар. Минем уйлавымча, бу - бүгенге көннең зур проблемасы. Татарча сөйләшергә, татар теленә мәхәббәт, татар баласы булуы белән горурлык хисен тәрбияләүдә укытучының роле гаять зур.

- Менә шуларны күз алдында тотып мин түбәндәге **методик тема** өстендә эшли башладым: **"Белем бирүдә коммуникатив технологияләр куллану аша сәламәт, белемле шәхес тәрбияләү"** һәм бу проблеманы чишү юлларын эзли башладым. Моның өчен мин интернет челтәре аша , төрле сайтларга чыгып, төрле методик материаллар укып, эзләнеп үземә кызыклы булган төрле эш формалары тупладым. Минемчә, бу алымнар гади, аңлаешлы, конкрет, нәтиҗәле, ә иң мөһиме, көндәлек тормышта кулланырдай, кирәкле белемнәр бирә

торган булырга тиеш. Коммуникатив эшчәнлекне оештырганда парларда, төркемнәрдә, индивидуаль эшләүгә өстенлек бирәм.

- Бүген мин сезнең игътибарга аларның берничәсен тәкъдим итәм.

- Алга таба без төркемнәрдә эшләрбез. Ике төркемгә бүленү өчен, һәркайсыгызга сүзләр язылган карточкалар алырга кирәк, рәхим итегез. Шул сүзләрдән җөмләләр җыеп төркемнәргә берләшергә.

**(Туганягы кирәк кешегә. Туган ягым гөлләр иле.)**

1) Беренче бирем. Исемнәрегезнең беренче хәрефләрен кулланып сүз төзергә, сузык авазлар өстәргә мөмкин.

**Бу бирем команданы берләштерү өчен , команда рухы булдыру өчен кулланыла, бернинди дә белем бирү максаты күз алдында тотылмый.**

- Хәзер үзегез төзегән җөмләләргә әйләнеп кайтабыз. Шул җөмләләргә таянып фаразлагыз әле, без бүген нәрсә турында сөйләшербез? Ә безнең туган ягыбыз ул? (Татарстан)

- Әйдәгез, бергәләп үзебезгә максатларны билгелик. ( Һәр төркем бер максат яза , кәгазьләр тактага беркетелә).

**1 нче бирем.**

1)Сезнең алда кәгазьләр ята. Уртада “Туган як “дип язылган. Төркемдәге һәр кеше шул темага бер җөмлә яза.

2) Хәзер шул җөмләләрдән текст төзибез.

**Укытучы: бу эшне белемнәрне актуальләштерү, кабатлау этапларында, белем байлыгын, сүзлек запасын билгеләү өчен кулланам. Ул бер-береңне тыңлый һәм аңлый белү, мәгълүматны кабул итеп үз фикереңне әйтә, үзгәртә, тулыландыра белүне үз эченә ала.**

***Биремнәрне тикшерү.*** Кайсы төркем эшне беренче тәгәлли, шул төркем беренче чыгыш ясый.

1 нче төркемдәге бер кеше текстны укый. Икенче төркем текст буенча бер сорау бирә.

2 нче төркемнән бер кеше укый.*(1 нче төркем әйткән җөмләләр кабатланырга тиеш түгел.)* Беренче төркем текст буенча сорау бирә.

***Рефлексия:*** Бу биремне үтәгәндә нинди кыенлыклар очрады? Сез аларны ничек чиштегез?

**2 нче бирем. Текст буенча эш. (калын хәрефләр белән бирелгән сүзләр бар).**

**Текст.**

1920 елның 27 маенда ТАССР төзелү турындагы Декрет басыла. 1940 нчы еллар ахырында ТАССР тарихында яңа мөһим чор башлана. Бу

елларда Ромашкино, Баулы, Зәй нефть чыганаклары ачыла һәм үзләштерелә. Шул чордан башлап, республикада нефть чыгару күләме туктаусыз үсә. 1971 елга республика җир астыннан беренче миллиард тонна кара алтын чыгарыла, икенче миллиард тоннаны нефтьчеләр 1981 елда таба.
1950-1970 нче елларда сәнәгать предприятиеләре интенсив үсеш кичерә. 1959 елда Казанда органик синтез заводы төзелеше башлана. 1961 елда Түбән Кама нефть химиясе комбинатына нигез салына. 1969 елда Кама автомобиль заводы төзелеше башлана.

1990 елда Дәүләт суверенитеты турындагы декларацияне игълан итү 1920 елда ТАССР төзелү турындагы Декретта билгеләнгән дәүләтчелекне торгызу процессының табигый дәвамы була.

1992 нче елдан бирле республиканың рәсми исеме- Татарстан Республикасы. Татарстанның Конституциясе 1992 нче елда кабул ителде. Татарстанда иң **югары** орган - Дәүләт Советы. Татарстанның ил башлыгы- Президент. Татарстанның **беренче** Президенты Минтимер Шәймиев 1991 елда сайланды. Хәзер Татарстанның Президенты Рөстәм Миннеханов.

1991 елның 29 нчы ноябрендә Татарстан Республикасының Дәүләт флагы булдырылды.

1992 нче елның 7 нче февралендә Татарстан Республикасының Дәүләт гербы кабул ителде.

1992 нче елның 8 нче июлендә "Татарстан Республикасы халыклары телләре турында" Татарстан Республикасы Законы кабул ителде. Татар теле рус теле белән **тигез** дәрәҗәдәге дәүләт теле дип иглан ителде.

1993 елның 14 нче июлендә Югары Совет сессиясендә Татарстан Республикасының Дәүләт гимны кабул ителде. Аның авторы – композитор Рөстәм Яхин.

1) 1 нче төркем калын хәрефләр белән бирелгән сүзләргә синонимнар таба.

2 нче төркем калын хәрефләр белән бирелгән сүзләргә антонимнар таба.(тикшерү)

**Укытучы: бу эш төре 2 максаттан булырга мөмкин: 1 -сүзлек запасын баету, тулыландыру, 2 - текстны тирәнтенрәк өйрәнү. Бу очракта автор ни өчен бу сүзне кулланган дигән сорау белән биремне катлауландырырга була. Безнең максат сүзлек запасын баету, шуңа күрә без беренче вариантта тукталабыз.**

2) Текстка исем бирергә. Татарстан, туган як сүзләрен кулланмаска.(тикшерү)

**Текстка исем биргәндә еш очрый торган сүзләрне, исемнәрне кулланмау креатив фикерләүне үстерүгә юнәлдерелгән.**

3) Текст буенча өч сорау төзергә: бер катлаулы, ике гади сорау. (тикшерү)

**Укытучы: сораулар төзегәндә нечкә һәм калын сораулар алымын кулланам. Нечкә сорауга тексттагы җөмлә белән генә җавап биреп була. Ә калын сорау текстны тирәнтенрәк өйрәнүне, ачыклуны, логик фикерләүне таләп итә.**

**Укытучы.(сорау төзегәндә)** Бу эш алымнары хезмәттәшлекне оештыру, бер-береңне тыңлый һәм аңлый белү, мәгълүматны тулы һәм төгәл кабул итү, кирәкле мәгълүматны табу һәм тапшыра белү күнекмәләрен формалаштыруга, аңлы уку күнекмәләрен, сөйләм телен, креатив фикерләү сәләтен үстерүгә, сүзлек запасын баетуга юнәлдерелгән.

***Рефлексия.*** Текст белән эшләгәндә кайсы бирем сездә кыенлыклар тудырды?

**3 нче бирем. Иҗади эш.**

**Татарстан, яратам, ямьле, тәмле сүзләрен рифмага салып шигырь иҗат итәргә.**

***Слайд.***

**Рифма-** (грек. “ярашучанлык”) ике яки берничә шигырь юлының охшаш (аваздаш) сузык яки тартык авазларга тәмамлануы.

**Рифмалаштыру ысуллары:**

- Янәшә / парлы рифма (аабб)
- Аралаш рифма (абаб)
- Камаулы-божралы (әйләнмә) рифма (абба)

**Укытучы: у биремне дә ике төрле итеп тәъдим итәргә мөмкин. 1 – шул сүзләрне кулланып шигырь иҗат итәргә, 2- аерым сүзләрне рифмага салып шигырь иҗат итәргә, бусы инде катлаулырак.**

**Бу алым телдән һәм язма сөйләмне үстерү, алган белемнәрне гамәли куллана белү күнекмәләрен камилләштерүгә, логик, иҗади фикерләүне юнәлдерелгән. Белемнәрне ныгыту этабында кулланам**.

***Биремнәрне тикшерү***

***Рефлексия.*** Иҗади биремне үтәү сездә нинди кыенлыклар тудырды?

Өч биремне үтәү барышында да рефлексия бер үк төрле булды. Әлбәттә бу дәрес этабын төрле формада үткәрергә мөмкин. Башлангыч сыйныфларда эшләгәч уен формасын үзем кулайрак күрәм.

**4. Әйдәгез уйнап алабыз. “Интервью” уены.**

Мин журналист, ә сез чит илдән, чит төбәкләрдән Татарстанга экскурсиягә килгәнсез. Сез безнең дәрестә бүген утырдыгыз, күпмедер белемнәр тупладыгыз. Нәрсәләр белергә өлгердегез икән, шуны беләсем килә.

- Татарстан белән сезнең беренче генә танышуыгызмы?
- Татарстан турында нинди мәгълүматлар тупладыгыз?
- Аның турында сездә нинди фикерләр туды?

- Ничек уйлыйсыз, Татарстанның чит ил туристлары өчен ачыкланмаган яклары калдымы икән?

- Сезгә Татарстанда күңелле яллар телим. Бездә ял итү өчен урыннар бик күп. Галиәскәр Камал театрына барырга тәкъдим итәм.

**Рефлексия.**

- Без эш барышында бергәләп максатлар билгеләгән идек. Без аларга ирештекме? Смайликлар белән үз фикерегезне күрсәтегез әле

- Сез ничек эшләдегез?

(*миңа җиңел булды, .........*

*Миңа кыен булды, чөнки .......)*

Киләчәктә кыенлыклар тумасын өчен нишләргә кирәк?

*Вәлиева Рузалия Сәед кызы, Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы Муса Җәлил исемендәге "1 нче гимназия" муниципаль бюджет белем бирү учреждениесенең беренче категорияле математика укытучысы*

Тема: Унарлы вакланмаларны тапкырлау.

Максат: Унарлы вакланмаларны тапкырлау кагыйдәсен кулланып мисаллар чишәргә, үз белемнәрен бәяләргә өйрәтү;

-Укучыларның телдән исәпләү күнекмәләрен һәм логик фикерләү сәләтен үстерү;

-Туган ягыбызга мәхәббәт , игътибарлылык, белем алуга омтылыш, компьютер кулланып фәнгә кызыксынучанлык тәрбияләү.

Җиһазлар: дәреслек, компьютер, презентация, тест, җаваплар өчен таблица, карточкалар, домино-карточка, магнитлы такта.

Дәрес барышы:

I. Оештыру моменты.

II. Өй эшләрен тикшерү.

Һәрбер укучыга тест язылган карточка таратыла.

Тест

1 нче вариант

1.Исәпләгез: 3,34 + 28,7

а) 32,04; б) 31,41; в) 31,04; г) 62,1.

2. Исәпләгез: 33,08 – 3,8

а) 32,7; б) 3,27; в) 29,28; г)30,28.

3.Исәпләгез: 0,24 • 6

а) 14,4; б) 0,144; в) 144; г) 1,44

4. Исәпләгез: 0,635 • 10

а) 63,5; б) 0,00635; в) 6,35; г)6350

5. 0,9 + 0,0003 + 0,000007 разрядына таркатылган нинди сан бу?

а) 0,937; б) 0,903007;

в) 0,90307; г) 0,900307.

6. 6,7489 санын унынчы өлешкә кадәр түгәрәкләгез:

а) 6,8; б) 6,7; в) 6,75; г) 6,749

2 нче вариант

1. Исәпләгез: 6,35 – 3,5

а) 2,85; б) 3,3; в) 6; г) 3,85.

2. Исәпләгез: 32,4 + 5,27

а) 85,1; б) 37,97; в) 38,97; г)37,67.

3.Исәпләгез: 0,72 • 4

а) 0,288; б) 2,88; в) 28,8; г) 288.

4. Исәпләгез: 4,547 • 100

а) 0,4547; б)45,47; в)454,7; г)4547

5. 0,6 + 0,004 + 0,00005 разрядына таркатылган нинди сан бу?

а) 0,604005; б) 0,600405

в) 0,645; г) 0,60405.

6. 0,56501 санын йөзенче өлешкә кадәр түгәрәкләгез:

а) 0,6; б) 0,57; в) 0,565; г) 0,56

Укучыларның җавапларын язу өчен таблица:

Фамилия, исеме______________________________класс______

| Укытучы бәясе | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| Бирем номеры | 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 |
| Дөрес җавап | | | | | | |

Укучыларга җавапларны тикшерү өчен плакат:

| | 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 |
|---|---|---|---|---|---|---|
| 1в | а | в | г | в | г | б |
| 2в | а | г | б | в | г | б |

1, 2 балл – “2” ле

3, 4 балл – “3” ле

5 балл – “4” ле

6 балл – “5” ле

Укучылар бер-берсе белән эшләрен алмашып үзләре тикшерәләр һәм билге куялар.

III. Белемнәрне актуальләштерү.

Натураль саннарны натураль саннарга, унарлы вакланмаларга тапкырлау буенча телдән исәпләү күнекмәләрен ныгытуга мисаллар язылган карточкалар белән эш.

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| 25 х 4 | 30 х 7 | 2,5 х 100 | 1,4 х 2 | 3,2 х 3 |
| 125 х 8 | 5,6 х 10 | 32,5 х 10 | 92 х 0,01 | 4,2 х 2 |
| 20 х 5 | 0,4 х 100 | 20 х 0,1 | 132 х 0,1 | 1,2 х 4 |
| 45 х 2 | 0,02 х 10 | 0,3 х 3 | 14 х 0,01 | 2,3 х 3 |

IV. Яңа тема аңлату.

Укучыларга бер мәсьәлә бирелә һәм алар алдында проблема куела, ничек итеп бу мәсьәләне чишәргә мөмкин .

Турыпочмаклыкның иңе 2,7 см, буе 1,4 см га тигез. Бу турыпочмаклыкның мәйданын табарга кирәк?

а=2,7 см = 27 мм

в=1,4 см =14 мм

S=?

Турыпочмаклыкның мәйданын ничек табабыз:

S=а • в

S=27 • 14 =378 мм2 = 3,78 см2

2,7 • 1,4=3,78 см2

Компьютерда унарлы вакланмаларны тапкырлауга мисаллар карау. Һәрберсен укучылар белән бергә эшләү юлларын карау, үзләре кагыйдәне чыгарып карыйлар һәм соңыннан компьютердан укыйлар.

Дәфтәрләргә тема язу.

V.Физкультминутка

Домино – карточка уены. Такта алдына карточкалар тезеп куела. Беренче командага 6 домино, икенче командага 7 домино куела. Магнитлы тактага алар дөрес итеп тезеп төшәргә тиешләр.

Укучылар безнең домино уеныннан соң нинди сүз килеп чыкты. Бәлки берәрегезнең бу кеше турында ишеткәне, яки ул кешене күргәнегез бардыр.

Әйе, чыннан да ул безнең якның яшь шагыйре, ул да сезнең кебек үк шушы мәктәптә укыган, шушы сез утырган парталар артында белем алган. Бүгенге көндә аның “Сагышлар да алтын була икән... “ дигән китабы басылып чыкты.

Менә бүген мин сезне аның бер шигыре белән таныштырып китәм.

“Бишегеңнән ләхеткәчә гыйлем өйрән”,

Ошбу сүзләр борынгыдан безгә килгән .

Сүзләр хаклы, сүзләр төгәл – яхшы беләм,

Истә тотсаң, комга тимәс тормыш көймәң.

Тууыннан башлап туплый кеше үзенә акыл,

Һәм дә эзли фани җирдә яшәү хакын.

Гыйлем белгән, әхлак сөргән бәндәләргә

Белегез сез, дускайларым, Аллаһ якын!

VI. Белем һәм күнекмәләрне формалаштыру.

Дәреслек белән эш

№1364(а-г)

а) 354,2 • 0,1 = 35,42;

б) 248,34 • 0,1 = 24,834;

в) 3788,2 • 0,001 = 3,7882;

г) 2,8 • 0,1 = 0,28.

№1370(а-е)

| | |
|---|---|
| а) 6,25 • 4,8 = 30; | г) 12,6 • 7,8 = 98,28; |
| б) 85,8 • 3,2 = 274,56; | д) 0,8 • 0,92 = 0,736; |
| в) 74 • 4,9 = 362,6; | е) 2,5 • 0,37 = 0,925 |

Мәсьәлә: Данил Шәбезбаштан Яңа Балтачка классташы Илүзәләргә кунакка барырга уйлады. Ул 4,1 км/сәг тизлек белән 2,2 сәгать вакыт эчендә Илүзәләргә барып җитә. Шәбезбаш белән Яңа Балтач арасындагы ераклыкны табыгыз. Берәмлеккә кадәр түгәрәкләгез.

VII. Йомгаклау.

1. Унарлы вакланмага тапкырлау кагыйдәсен әйтеп бирегез.

2. Унарлы вакланмага тапкырлаганда, тапкырчыгышта цифрлар саны өтер белән аерырга тиешле саннан кимрәк булса нишләргә кирәк?

*Гайнетдинова Гөлназ Фәнис кызы*
*Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районы муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесе “Г.Тукай ис. Мөслим урта гомуми белем бирү мәктәбе”нең югары квалификацион категорияле татар теле һәм әдәбияты укытучысы*

## Мөслим төбәге язучыларына багышланган интерактив уен

**Максат:** Укучыларның Мөслим төбәгеннән чыккан язучылар турындагы белемнәрен тикшерү.

**Бурычлар:**

1. Якташ язучыларыбыз иҗатына багышланган интерактив уен төзү.
2. Укучыларның Мөслим төбәге язучылары турында мәгълүматларын арттыру.
3. Якташ язучыларыбызның иҗатларына карата хөрмәт, горурлык хисләре тәрбияләү.

**Актуальлеге.** Һәр халык үзенең язучыларын, шагыйрьләрен белергә тиеш, аларның иҗатын өйрәнүгә багышланган уеннарны, дәресләрне әзерләү теманың актуальлелеген тәшкил итә. Якташ язучыларыбызның иҗатларын өйрәнеп, аларны киң җәмәгатьчелеккә җиткерүне кирәк дип саныйбыз.

**Җиһазлау.** Сораулар язылган карточкалар, компьютер, төрле рәсем слайдлары.

**Уен тәртибе**. Уенда 2 команда катнаша. Өй эшенә: визитка әзерләү, исем, девиз сайлау, Мөҗәһит Әхмәтҗанов сайты буенча Мөслим төбәге язучыларының тормыш юлларын, иҗатларын өйрәнеп килергә

**Уен барышы**.

Залда тыныч кына күңелле татар көе яңгырый. Уенчылар үз урыннарын алалар.

**Алып баручы**. Хәерле көн, хөрмәтле укытучылар, укучылар! Бүгенге бәйгебезне без Мөслим төбәгеннән чыккан язучыларыбызга багышлыйбыз. Ике команда арасыннан зирәкләрен, булганнарын сайлап алырбыз. Якташ язучыларыбызның тормыш юллары, иҗатларына кагылышлы белемнәрегезнең нинди дәрәҗәдә булуын да ачыкларбыз. Бу ярыш, шуңа күрә иптәшләрегезне куллар чабып, аларга көч бирерсез дип ышанып калабыз.

1. Уенның тәртибе белән танышыйк:
    1) Сезгә 4 категориядән торган табло чыга;
    2) Һәр категориядә 4 сорау, 4 сорауның үз бәясе бар(10,20,50,100);
    3) Сорауга дөрес җавап бирсәгез, баллар сезнеке;
    4) Сорауга дөрес җавап бирмәсәгез, уен икенче командага күчә.

5) Категорияләрдә “Капчыктагы мәче” дип аталган сюрприз сораулар бар, алар чыккан очракта, уен чираты икенче командага күчә.
6) Уенда кайсы команда иң күп балл җыя, шулар җиңүче дип табыла.

2.Уеныбызның командаларының балларын санап баручы, бәя бирүче жюри составы белән дә танышыйк.

3. Ә хәзер сүзне командаларга бирәбез. Әйдәгез алар белән якыннанрак танышыйк.

(Һәр команда үзенең исемен, девизын әйтә, уенчылар үзләре белән таныштыралар. “Зирәкләр” командасы чыгышы, “Тапкырлар” командасы чыгышы)

**Алып баручы**. Булдырдыгыз укучылар. Шулай итеп, уенны башлыйбыз!

(Уен сораулары сөенариядә тәртип буенча бирелә, уен барышында кайсы категорияне, кайсы сорауны сайлап алу-бу һәр команданың ихтыяры).

**I категория. Сүз кайсы язучы турында бара?**

Якташ язучыларыбызның тормыш юлы, иҗатына кагылышлы 4 сорау.

**Категория-1, 1 нче сорау, дөрес җавап-10 балл.**

**Сорау: Сүз кайсы язучы турында бара?**

Читтән торып Казан дәүләт университетының тарих — филология факультетында укый. 1972 — 1981 — «Авыл утлары» газетасының баш мөхәррире. 1981 — 1982 — Мәскәүдә РСФСР Мәдәният министрлыгы каршындагы берьеллык Югары театр курслары. Ике дистәгә якын сәхнә әсәре авторы. Әлмәт Язучылар берлегенең, Ризаэтдин Фәхертдинов, Рафаэль Төхфәтуллин исемендәге премияләр лауреаты. Г.Тукай исемендәге Дәүләт бүләгенә лаек булды. 2014 нче елда аңа Халык Язучысы исеме бирелде. Мөслим районының Мактаулы гражданины Ә хәзер сүзне жюрига бирәбез.

**Дөрес җавап:** Фоат Садриев.

**Категория-1, 2 нче сорау, дөрес җавап-20 балл.**

**Сорау: Сүз кайсы язучы турында бара?**

Күбәк урта мәктәбен тәмамлаганнан соң, Казан дәүләт университетының татар теле һәм әдәбияты бүлегендә укый. Хезмәт юлын Мөслим район газетасы «Авыл утлары» нда башлап җибәрә. 1972 — 1983 — «Татарстан яшьләре» газетасы. 1983 нче елдан башлап хезмәтен Татарстан китап нәшриятында дәвам иттерә: матур әдәбият редакциясе редакторы, редакция мөдире, 1994 нче елдан нәшриятның баш мөхәррире. Гаяз Исхакый исемендәге әдәби бүләк иясе. Татарстан Республикасының атказанган сәнгать эшлеклесе.

**Дөрес җавап:** Харрас Әюп.

**Категория-1, 3 нче сорау, дөрес җавап-50 балл.**

**Сорау: Сүз кайсы язучы турында бара?**

Яңа Сәет. Үрәзмәт урта мәктәбен тәмамлагач, Казан дәүләт университетының татар филологиясе факультетында укый. Укыган вакытта ук «Чаян» журналы редакциясендә эшли башлый. Мәскәүдә СССР Язучылар берлеге каршындагы югары әдәби курсларны тәмамлый. Ул — «Мәкерле песи» исемле беренче татар балалар операсының либретто авторы. Күп кенә шигырьләренә көйләр иҗат ителгән. Татарстан Республикасының атказанган сәнгать эшлеклесе. М.Җәлил, Г.Тукай исемендәге дәүләт премияләре лауреаты.

**Дөрес җавап:** Зөлфәт**.**

**Категория-1, 4 нче сорау, дөрес җавап-100 балл.**

**Сорау: Сүз кайсы язучы турында бара?**

Күбәк урта мәктәбен тәмамлагач, колхозда механизатор булып эшли башлый. Минзәләдә шоферлык һөнәрен үзләштерә. Армия хезмәте. Комсомол оешмасы секретаре. Иске Карамалы мәдәният йорты директоры. Октябрь мәктәбендә укыта башлый. Тат. Бүләр мәктәбендә директор. 1984 нче елдан Чаллы шәһәрендә. КамАЗның автомобильләр җыю заводында слесарь-җыючы, бригадир, мастер. Казан дәүләт университетының тарих-филология факультетын тәмамлый. Шәһәр мәктәпләрендә тарих укыта**.**

**Дөрес җавап:** Факил Әмәк.

**II категория. Таныдыгызмы?.**

Икенче категориядә командаларга якташ язучыларның портретлары бирелә, укучылар аларны таныргa һәм исемнәрен дөрес әйтергә тиеш булалар. Сораулар арасында “Капчыктагы мәче” соравы бар, бу сорау категориянең тематикасыннан үзгә булачак.

**Категория-2, 1 нче сорау, дөрес җавап-10 балл.**

**Сорау: “Капчыктагы мәче”: Әхмәт Дусайлының чын исемен атагыз**



**Дөрес җавап:** Хәмәдишин Әхмәтҗан Хәсән улы.

**Категория-2, 2 нче сорау, дөрес җавап-20 балл.**

**Сорау:Таныдыгызмы?**



**Дөрес җавап:** Флюс Латыйфи.

**Категория-2, 3 нче сорау, дөрес җавап-50 балл.**

**Сорау:Таныдыгызмы?**



**Дөрес җавап:** Харрас Әюп.

**Категория-2, 4 нче сорау, дөрес җавап-100 балл.**

**Сорау:Таныдыгызмы?**



**Дөрес җавап:** Наис Гамбәр.

**III категория. Язучы кайсы яктан?**

Бу категориядәге сораулар язучыларыбызның туып үскән авылларына кагылышлы булачак.

**Категория-3, 1 нче сорау, дөрес җавап-10 балл.**

**Сорау:** Әхмәт Дусайлы кайсы авылдан?



**Дөрес җавап:** Дусайдан.

**Категория-3, 2 нче сорау, дөрес җавап-20 балл.**

**Сорау:** Мөҗәһит Әхмәтҗановның туган авылын атагыз.



**Дөрес җавап:Түреш.**

**Категория-3, 2 нче сорау, дөрес җавап-50 балл.**

**Сорау:**Шәмсия Җиһангированың туган авылын атагыз.



**Дөрес җавап:** Баек.

**Категория-3, 2 нче сорау, дөрес җавап-100 балл.**

**Сорау:**Эльмира  Шәрифуллина кайсы авылда туган?




**Дөрес җавап:** Симәк.

**IV категория.  Бу кайсы язучының китабы?**

Бу категориягә кергән сораулар язучыларның китапларына багышлана. Командалар китапларны танырга һәм аларның авторларын дөрес атарга тиеш булалар. Китаптагы автор исемнәре капланган. Сораулар арасында “Капчыктагы мәче” соравы бар, бу сорау категориянең тематикасыннан үзгә булачак.

**Категория-4, 1 нче сорау, дөрес җавап-10 балл.**

**Сорау:** Бу китапның авторын атагыз.




**Дөрес җавап:** Роза Хәбибуллина.

**Категория-4, 2 нче сорау, дөрес җавап-20 балл.**

**Сорау: “Капчыктагы мәче”-** Ләбиб Леронның чын исемен атагыз**.**



**Дөрес җавап: Леронов Лемон Лерон улы**

**Категория-4, 3 нче сорау, дөрес җавап-50 балл.**


**Сорау:** Бу китапның авторын атагыз.




**Дөрес җавап: Мөҗәһит.**

**Категория-4, 4 нче сорау, дөрес җавап-100 балл.**

**Сорау:** Бу китапның авторын атагыз.




**Дөрес җавап:** Зариф Мөэминов**.**

**Ә хәзер сүзне жюрига бирәбез. Рәхим итегез!**

**Мөслим төбәге язучыларына багышланган интерактив уеныбыз ахырына якынлашты. Җиңүче команданы чын күңелебездән котлыбыз!**

Бәйгене Харрас Әюп сүзләре белән тәмамлыйсы килә:

Тел ачкычы тели иде әнкәй,
Бүтән тагын нәрсә теләсен.
Туган телем!
Белгән бит ул минем
Ни кылсам да сиңа киләсем…
Байлыгымның олылыгын тоеп,
Ышанып керәм якты көнемә.
Дәверләрне ачар ачкычым бар—
Рәхмәт яусын туган телемә!

Туган телебез сагында торучы язучыларыбызга мең рәхмәт, үзебез дә туган телебезне саклыйк, туган төбәгебез Мөслим белән горурланып яшик, татарлар булуыбыз белән горурланып яшик, сез, укучылар, безнең милләтебезнең киләчәге!

*Галимова Гөлфинә Сәлихҗан кызы,*
*Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы Муса Җәлил исемендәге “1 нче гимназия” муниципаль бюджет белем учреждениесенең беренче категорияле татар теле һәм әдәбияты укытучысы,*
*Гыйздатуллина Эльмира Мирзагит кызы, Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы Муса Җәлил исемендәге “1 нче гимназия” муниципаль бюджет белем учреждениесенең югары категорияле инглиз теле укытучысы*

## Укучыларга әхлакый һәм патриотик тәрбия бирү

Милли мәгарифне туган як тарихын, татар халкының гореф-гадәтләрен, йолаларын белмичә өйрәнү мөмкин түгел. Шуңа күрә 1987 елда тарих укытучысы Юнысова Гөлсинә Исмәгыйль кызы материаллар җыю һәм туган якны өйрәнү музеен булдыру буенча тырышып эшли башлый.1997 елның 20 февралендә гимназиядә Туган якны өйрәнү музее ачыла. 1999 елда музей паспортлаштырыла. Музейның максаты һәм бурычлары: укучыларның танып белү һәм тикшеренү эшчәнлеген активлаштыру; аларның иҗатын үстерү; укучыларны ата-бабаларның мәдәниятенә, традицияләренә җәлеп итү, туган якка мәхәббәт тәрбияләү; укучыларда

гражданлык һәм патриотизм тәрбияләү; укучыларның игътибарын туган якның тарихын һәм мәдәниятен саклау проблемаларына җәлеп итү; музей коллекцияләрен формалаштыру һәм тулыландыру, экспонатларны саклауны тәэмин итү, музей фондларын исәпкә алу. Гимназиянең туган як тарихын өйрәнү музее үзенең эшчәнлек елларында белем бирү һәм тәрбия процессында мөһим звенога әверелә. Музей һәм мәктәпнең тәрбия проектлары, мәктәп һәм музей чаралары, экскурсия эшчәнлеге, музей советы эше, укучыларның тикшеренү эшчәнлеге, ветераннар белән очрашулар, батырлык дәресләре аша үсеп килүче буынга гражданлык-патриотик тәрбия бирүне оештыру кебек уртак эшләр  даими рәвештә алып барыла. Мәктәп музее материалларын белем бирү һәм тәрбия процессында куллануны өч юнәлешкә бүлеп була: тикшеренү эше, сыйныфтан тыш дәресләр, дәресләр.

"Тикшеренү эшчәнлегендә" без балалар белән күп кенә тикшеренү һәм иҗади хезмәтләр яза алдык, алар Бөтенроссия,республика конференцияләре һәм конкурслары призерлары булдылар. “Шинельсез солдатлар” (1 урын Бөтенроссия конференциясендә), “Әбиемнең истәлекләре” (3 урын республика конференциясендә), “Интернационалист сугышчылар-гимназиябезнең горурлыгы” (2 урын республика конференциясендә), «Бөек Ватан сугышы: белем, хәтер, хезмәт» (1,2 һәм 3 урын) һәм башкалар. Гимназиянең туган якны өйрәнү музее базасында хәрби-патриотик һәм башка юнәлешләрдәге айлыклар һәм чаралар уза, аларны гамәлгә ашыру нәтиҗәсендә тарихка, мәдәниятькә, үз халкына тотрыклы кызыксыну күрсәтелә. Массакүләм-спорт һәм хәрби-патриотик эш айлыгына әзерлек кысаларында уртак чаралар үткәрелә: Батырлык дәресләре, Әфганстанда һәлак булган сугышчы-интернационалистларның туганнары, Бөек Ватан сугышы ветераннары һәм тыл хезмәтчәннәре белән очрашулар, сафка тезелү һәм җырлар смотры.

Музей активистлары сыйныфтан тыш чараларда төрле тематик акцияләр үткәрәләр. "Яхшылык акциясе», «Ленинград блокадасы», «Солдатка хат», «Җиңү трамвае», «Георгий тасмасы», «Үлемсез полк», «Җәлилчеләр» кебек акцияләре, төрле муниципаль конкурсларда катнашалар,мәсәлән,«Солдат булып тумыйлар», «Татарстан- җырлы туган ягым», герой - шагыйрь Муса Җәлил иҗатына багышланган, хәрби җырларны инсценировкалау конкурсы.

Гимназия музеенда беренче экспозиция Советлар Союзы Герое Муса Җәлил иҗатына багышланган. Шулай ук монда сугышчы –интернационалистларга багышланган бүлек бар.Ә гимназия холлында Әфган сугышчыларына мемориаль такта эленеп тора. Безнең гимназиядән алар өчәү: Гыйльманов Фәнил, Хәсәнов Раиф, Гаптриев Каниф. Әфганстанда хәрби бурычын үтәгәндә һәлак булган, өчесе дә бер сыйныфтан.

Патриотик тәрбия булдыру мөмкинлеген өйрәнү һәм апробацияләү максатыннан түбәндәге социаль проектлар да булдырылды:

1) «Безнең туган як» проекты. Әлеге проектны гамәлгә ашыру кысаларында ата-аналар һәм өстәмә белем бирү берләшмәләре белән милли мәдәният көннәрен үткәрү оештырыла. Әлеге проектның максаты-төрле халыкларның милли гореф-гадәтләренә, йолаларына һәм диннәренә толерантлык тәрбияләү;

2) «Серле сандык» проекты. Бу проект кысаларында милли архитектура тарихы буенча конкурслар, викториналар, рәсем күргәзмәләре, төрле дәрәҗәдәге смотрларда, конкурсларда катнашу оештырыла. Проектның максаты: укучыларның татар телен һәм татар мәдәниятен,Россия тарихын өйрәнүгә мотивациясен арттыру, мәктәп музее экспонатларын тулыландыру, татар халкы традицияләре белән танышу;

3)«Без – Җиңүнең оныклары» проекты кысаларында рәсемнәр, шигырьләр, әсәрләр конкурслары, сугыш һәм хезмәт ветераннары белән очрашулар, батырлык дәресләре, Җиңү көненә багышланган митинг үткәрү, патриотик акцияләр, төрле дәрәҗәдәге смотрларда, конкурсларда катнашу оештырыла. Проектның максаты: укучыларның гражданлык-патриотик тәрбияләү дәрәҗәсен күтәрү.

Әлеге проектларны гамәлгә ашыру эше экспозицияләр,тикшеренү, иҗади проектлар булдыруны күздә тоткан иҗади эшчәнлеккә нигезләнгән. Мәктәп тарихын,туган як кешеләренең көнкүрешен һәм мәдәниятен өйрәнгәндә, балалар элеккеге традицияләр белән танышып кына калмыйлар,ә яңа традицияләр өчен нигезләр дә булдыралар (Батырлык дәресләре, патриотик җыр конкурслары, патриотик акцияләр, эзләнү эше, төрле тарихи вакыйгаларның шаһитлары белән очрашу-әңгәмәләр). Шулай итеп, нәкъ менә мәктәп музее үсеп килүче буында гражданлык һәм патриотизм кебек сыйфатларны тәрбияләүдә зур роль уйный, аларның гражданлык компетентлыгын, мөстәкыйльлеген үстерүгә ярдәм итә. Мәктәп музееның төп бурычы -рухи, әхлакый тәрбия. Мондый тәрбия үз тамырларын, туган илен яратырга, якташларының батырлыклары белән горурланырга һәм алардан үрнәк алырга өйрәтә.

*Ганиева Рузилә Фәвәдис кызы,*
*Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы “Түбән Кама – Адымнар” муниципаль бюджет белем бирү учреждениесенең I категорияле башлангыч сыйныф укытучысы*

**Ныклы белем алуга омтылган укучылар тәрбияләү**

Русия Президенты Владимир Путин имзалаган “Русия Федерациясенең 2024 елга кадәр үсешенең стратегик бурычлары һәм илкүләм максатлары турында” дип аталган документта мәгариф өлкәсенә аеруча зур урын бирелә, демография һәм сәламәтлек саклау юнәлешләреннән соң, ул өченче булып телгә алына. Бу аңлашыла да: балалар, яшьләр – безнең өметебез, аларның белем дәрәҗәсенә, сыйфатына илебезнең киләчәк яшәеше турыдан-туры бәйле.

Указның 5нче пунктында әйтелгәнчә, мәгариф өлкәсендәге гомумдәүләт проекты берничә төп максатка ирешүне күздә тота: Русия мәгарифенең глобаль көндәшлеккә сәләтен күтәрү, илнең гомуми белем бирү сыйфаты буенча дөньяның әйдәп баручы 10 дәүләте исәбенә керүен тәэмин итү; Русия Федерациясе халыкларының рухи кыйммәтләре, тарихи һәм милли традицияләре нигезендә гармонияле үсеш алган һәм социаль җаваплы шәхес тәрбияләү.

Шуңа да бүген мәгариф системасы алдында хәзерге тормышта үз урынын табарга, яңа шартларда яшәргә сәләтле шәхес тәрбияләү җаваплылыгы тора. Кечкенәдән үк баланы шәхес итеп күрү, сәләтен күрергә, ачарга, үстерергә ярдәм итү, белемнәрне үзләштерүгә теләк, омтылыш уяту тора. Моның өчен кирәкле шартлар тудыру, белем алуга сәләтле, үз фикерен яклый, раслый белә торган, сораулар бирә белүче, яңа белем алуга инициативалы булган укучы тәрбияләү – һәр укытучының максаты һәм бурычы. Заман бездән укучыларның сәләтләрен төрле яклап үстерүне, алган белемнәренең дәвамлы булуына ирешүне, һәр нәрсәгә үз фикерен әйтә алырдай, эзләнүчән, кызыксынучан укучылар тәрбияләүне таләп итә.

Белгәнебезчә, хәзерге җәмгыять өчен укучыларның төрле фәннәрдән тирән белемле булуы гына җитми. Аларның мәктәп программасының база курсын ныклап үзләштергән дигәне дә алган белемен таныш шартларда гына куллана белә, көтелмәгән хәлләр килеп туганда иҗади фикерли, яңа идеяләр белән яши, мөстәкыйль эш итә алмый. Шуңа да әзер белемнәрне үзләштерүдән һәр укучының мөмкинлеген һәм үзенчәлеген күздә тоткан мөстәкыйль танып белү эшчәнлеге дәрәҗәсенә җитүе – әлеге мәсьәләне хәл итүнең бер юлы. Хәзерге башлангыч класс укытучысының максаты да баланы укырга, язарга, санарга гына өйрәтеп калырга түгел,

ә универсаль уку күнекмәләре формалаштырып, балаларны проект эшчәнлеге, уеннар, проблемалы уку мәсәләләре аша белем алуга кызыксындыру, аны алып барырга өйрәтү тора. Минем уйлавымча, укучыларны фәнни-тикшеренү, проект яклау эшләренә тарту һәм эзләнү нәтиҗәләрен укыту - тәрбия процессында куллану – белем бирүнең иң нәтиҗәле алымнарыннан берсе. Аның төп максаты укучыларны мөстәкыйль фикерли, эзләнә һәм иҗади эшли белергә өйрәтүдән гыйбарәт. Иң мөһиме – укучы яңа белем алырга тиеш. Бу эшчәнлекнең эпиграфы итеп түбәндәге юлларны кулланыр идем: «Сөйлә миңа – мин онытырмын, күрсәт миңа – истә калдырырмын, кызыксындыр мине – өйрәнермен». Проект методы укытучы һәм укучыларның яхшы әзерлеген, сыйныфның һәм иҗади төркемнәрнең үзара килешеп эшләүләрен таләп итә.

Белгәнебезчә, фәнни эшкә әзерлек дәресләрдә башлана. Без, укытучылар, үзебезнең һәр укучыбызның уңышларын һәм уңышсызлыкларын дәрестә ачык күрәбез. Үзлектән эш башкарганда укучының аны теләк белән яки теләксез башкаруын ачык аңлыйбыз. Шуңа күрә фәнни-тикшеренү эшләренә әзерлекне дәресләрдә башларга кирәклеге беркем өчен дә яңалык түгел. Эш алдыннан  укучылар белән берлектә иң беренче актуаль проблеманы формалаштырабыз. Укучыга белем җиткерелми, проблеманы тикшерү барышында алар аны үзләре эзләп табалар. Шуннан чыгып, без укучылар белән башкарылачак фәнни эшнең максатын, бурычларын, өйрәнү объектын билгелибез. Укучылар фәнни эш алымнарын үзләштерә. Эзләнү эшләре 3 этапта башкарыла.

1 нче этап. Аңлату эшләре алып бару.

2 нче этап. Мәгълүмат туплау.

3 нче этап. Көтелгән нәтиҗәләрне билгеләү.

Соңгы этапта укучыларыбыз үз эшләре турында хәбәр итәләр, презентацияләр ясыйлар, эшләрен анализлыйлар һәм яклауга чыгалар. Яклау үз сыйныф укучылары каршында үткәрелә.  Мин фәнни-тикшеренү эшләре белән моннан күптән кызыксына башладым һәм бу эшкә үземнең укучыларымны әкренләп җәлеп иттем.

Шуны да истә тотарга кирәк: эшнең уңышлы килеп чыгуы аның дөрес оештырылуына бәйле. Монда укытучы, укучы һәм ата-ана хезмәттәшлеге бик әһәмиятле. Укытучы-киңәшче, юнәлеш бирүче, төзәтмәләр кертүче, рухландыручы, илһам өстәүче булса, укучы-эзләнүче, идеяне тормышка ашыручы, мәгълүмат җыючы, фикерләүче, күзәтүләр нигезендә модель төзүче, барлыкка килгән нәтиҗәләрне анализлаучы, тәҗрибәләр үткәрүче, интернет материалларын кулланучы.  Ә инде ата-аналарны җәлеп итү бик отышлы: ата-ана бала тормышында актив катнаша башлый.

Гомумән, укучыларны фән дөньясына алып керү, кызыксындыру, аларны тикшеренү эшләренә җәлеп итү – заман таләбе. Балаларны  эзләнү-тикшеренү белән шөгыльләндерә алу

бик зур мөмкинлекләр ача. Укучыларның сөйләм телен, иҗади сәләтен үстерергә ярдәм итә. Укучыларда үз көченә ышаныч туа, алар үзләре туплаган тәҗрибә белән үзләрен көчле итеп сизәләр. Әгәр дә без җәмгыятьнең алга таба үсүен теләсәк, һәр укучының үсешен тәэмин итәргә тиешбез.

*Гарипова Лилия Рәүф кызы, Гарипов Расим Фаиз улы Татарстан Республикасы*
*Түбән Кама муниципаль районы*
*“Каенлы урта гомуми белем бирү мәктәбе” муниципаль бюджет урта белем бирү учреждениесенең укытучылары*

**Тарихта эзле инсан**

Милли дәүләтчелеген югалтканнан соң, татар халкы аяусыз эзәрлекләүләргә, коточкыч милләтне юк итү сәясәтенә дучар ителә. Шуңа карамастан, үзенең милли асылын, телен, динен, моңын, гореф-гадәтләрен саклап, аларны алдагы буыннарга тапшырып килә. Милли барлыкны саклауда аеруча белем- мәгърифәт зур роль уйный. Халыкка белем һәм тәрбия бирүдә армый- талмый хезмәт түккән зыялыларыбыз шактый. Алар арасында исеме, эшчәнлеге күпләргә таныш булган Таҗетдин Ялчыгол да үзенә лаеклы урынны алып тора. Галим Д. Гарифуллинның “Чырагы нур сибә бүген дә” китабында түбәндәге юллар бар: “Галимҗан Ибраһимов Таҗетдин яшәгән чорны характерлап: “... Бөтен ислам дөньясын каплап, авыр таш булып басып яткан тимер катлау 19 нчы гасырның яртыларына таба төрле җирдән чатный, ярыла башлады. Кыю ирләр аның басуына чыдый алмый, җимереп өскә чыга башладылар”, дип язды. Т. Ялчыгол да үз халкын агартуга юнәлтелгән хезмәте белән искелекне чатнатуга, яра башлауга чөй кагучыларның берсе була.” [2]

Т. Ялчыгол- халкыбыз тарихының катлаулы чорында яшәгән әдип; татар теле, гарәп, фарсы, госманлы кебек теллләр белгече; шәрык гыйлеме, мәдәниятен өйрәнгән галим; педагог; табиб; дин әһеле; тарих, әдәбият, фәлсәфә, медицина, хокук, илаһият китаплары авторы.

Күпкырлы талант иясе 70 еллык гомеренең өчтән ике өлешен безнең Зәй буенда үткәрә. 1792-1799 нчы елларда Каенлы авылында яшәсә, 1799-1824 нче елларда Кызыл Чапчак авылында гомер итә. Димәк, гомеренең 32 елын, иң гайрәтле чорын Каенлы һәм Кызыл Чапчакта яшәгән.

Шуңа күрә татарның бу мәгълүм шәхесен без хаклы рәвештә үзебезнең якташыбыз дип исәплибез.

Кызганыч, Т.Ялчыголның Каенлы чоры турында истәлекләр бик аз сакланган. Авылдашыбыз Фәхри абый Шәрәфиев “Каенлы авылы тарихы” китабында аның турында бераз искә ала. “Каенлыда ярыйсы ук шөһрәт, дан алган табиб, шагыйрь Таҗетдин Ялчыгол

яшәгән. Тик бу хакта авыл тарихына караган материалларны җыюда хезмәтләре кергән авыл картлары - Фәсхи Кәбиров, Сәлах Мөфтиев, Ризатдин Исламов- берничек тә хәбәрдар булмаганнар, ”- дип яза. [6]

20нче гасырның 70-80 нче елларында Фәхри абый Каенлыга килгән тел - әдәбият, тарих белән кызыксынучы күренекле шәхесләр белән шактый очраша. Алар арасыннан Гомәр Саттаров, Хатыйп Миңнегулов, Рәгъде Халитов, Равил Фәхретдинов, Хәләф Корбанов, Альберт Фәтхине искә ала. “1986 нчы елның июль аенда СССР Фәннәр академиясенең Башкортстандагы тел- әдәбият һәм тарих институты филиалы хезмәткәре Галәветдинов Ишмөхәммәт Гыйльметдин улы безгә килеп керде. Аның Таҗетдин Ялчыгол эзе буенча йөрүе була. Галимгә Т. Ялчыголның Татарстанның берничә районындагы Зиреклеләрнең кайсында яшәгәнлеген ачыкларга кирәк була. Аның белән сөйләшү икебезгә дә күп нәрсәләрне ачыкларга ярдәм итте”,- дип яза Фәхри ага[6]

Хатыйп абый Миңнегулов Каенлыга килүе турындагы истәлекләреннән: “Миңа 1995 нче елның 21 нче октябрендә Зирекле авылында булырга туры килде. Аны Каенлы, Татар Җиреклесе дә дип йөртәләр. Бу авылда мин пенсионер укытучы Фәхри ага Шәрәфиев белән очраштым. Ул төрле чыганакларга нигезләнеп, авыл тарихын язган. Фәхри ага раславынча, Каенлының шактый халкы Мамадыш ягындагы Кече Сөн һәм Усали авылларыннан күчеп килгән. Таҗетдин Ялчыгол, әтисен җирләгәннән соң, Җирекле авылына күчеп килә. Күрәсең бу авыллар арасында бәйләнешләр көчле була. Әдипнең Сөннән нәкъ менә Җиреклегә килүе дә, мөгаен, шуның белән аңлатыла. Фәхри ага Шәрәфиев фикеренчә, Таҗетдин Ялчыгол Җирекледә 9 ел яши.”[5]

Галим Дамир Гарифуллинның да Т. Ялчыголның Кама аръягына килеп урнашуы турында үз фикере бар: “Каенлыга килгәндә аңа 24 яшь була, мөгаен , ул инде өйләнгән булгандыр, биредә балалары да тугандыр. Аннан ул Кызыл Чапчак авылында яши, крестьян балаларына дәресләр бирә.”[2]

Кызыл Чапчакта яшәве турында да мәгълүматлар аз табылган. Шулай да Т. Ялчыголның улы - Җәләлетдин хәзрәт тарафыннан әтисе үлгәннән соң язылган шигырьдә түбәндәге юллар бар:

...Акләнеп берничә еллар Зәй буенда мәсхәне,
Бере мәргуптер Кызыл илдә балалары үскәне.[4]

Әлеге шигырьдә, Ялчыголның Зәй буенда тереклек итүе, балаларының Кызыл илдә ( Кызыл Чапчакта) үскәнлеге, Таҗетдин бик диндар, гыйлемле булуы , зур омтылыш белән дәрес бирүе әйтелгән.

Таҗетдин Ялчыголның гаилә коруы, 7 бала әтисе булуы турында да бик кызыклы материалларга тап булырга туры килде. Элегрәк Т. Ялчыгол Каенлы авылында башлы - күзле

булган дип фаразлыйлар. Яшь язучы- галим Рөстәм Галиуллинның Таҗетдин Ялчыголга багышланган “Васыять” исемле тарихи романында Таҗетдин хәзрәтнең Каенлыга килгәч гашыйк булуы һәм өйләнүе турында әйтелә: “...башына ак яулык бөркәнгән, бөрмә итәкле чәчәкле күлмәктән, аягына читек кигән кызның иңендә көянтә- чиләк. Үзе исә, гадәт буенча, авызын каплаган. Кием – килбәтенең затлы булуына карап, Таҗеддин чамалады: төшеп калган ата кызы түгел иде бу.

- Мин- Гомәр кызы Миңлебикә!- диде кыз... Ул чибәр авылның иң укымышлы, хәлле кешеләрнең берсе булган Гомәр абзыйның кызы булып чыга.” [1]

Д. Гарифуллин Т. Ялчыголның тәрҗемәи хәле белән кызыксынуын дәвам итә, соңгы елларда кайбер табылдыклар аны битараф калдырмый. Язучы яшәгән авылларның тарихын өйрәнү белән бергә, шул чактагы җан исәбен алу материаллары белән дә таныша. Әлеге материалларда Т. Ялчыголның хатыны- Биксолтан Ишмәмбәтова икәне билгеле була. “Биксолтан абыстай кайсы авылда туган икән дигән сорау да тынычлыгымны югалтты. Эзләнә торгач, мин аның Таҗетдин Ялчыгол мулла булган Кызыл Чапчак авылы кызы икәнлеген ачыкладым. Әтисе Ишмәмәт Калметов икән. Авылда Калметовлар йомышлы татарлар катламына караган. Алар Казан адмиралтейтствосына теркәлгән булган һәм күп кенә өстенлекләрдән файдаланганнардыр. Биксолтан абыстай дәрәҗәле гаиләдән чыккан, күп бала тапкан, барысын да яратып, эшкә һәм укырга өйрәтеп баккан. Таҗетдин Ялчыголга бик ныклы терәк, бик тә кирәк булып гомер сөргән., аның белән урыннан – урынга күчеп, ачысын һәм төчесен эчеп яшәгән.”[3]

Р. Галиуллиның “Васыять” әсәренә тагын бер кат игътибарны юнәлтәбез: язучы - мәгърифәтченең Каенлыдагы эшчәнлеге турында мондый юллар бар: “Т. Ялчыгол Җирекле ( Каенлы) авылында имам һәм мөдәррис булганнан соң, үз алдына дүрт ниятне тормышка ашырырга карар кылды. Ул шәкертләрен, тал чыбыгы белән суктырып, таяк белән кактырып тәрбияләмәячәк. Аларга иң зур җәза өстәмә эш булыр. Өстәмә эш дигәндә, утын яру, кар көрәү, идән юу кебек эшләр түгел, үзе язган китапларны күчерү эше өстәлер.” [1]

Әйе, чыннан да, Таҗеддин хәзрәт Каенлыда хөрмәтле укытучы да, мулла да, табиб та булып танылa. Т. Ялчыгол сәламәтлеге какшаган авылдашларына гына булышып калмый, ә аның янына күрше Керәшен Җиреклесе авылыннан да ярдәм сорап килгәннәр.

Т. Ялчыголны күпкырлы талант иясе дип искәртеп үттем инде. Беренче чиратта ул язучы бит әле. Аның язма мирасы тиешенчә барланмаган һәм өйрәнелмәгән. Безнең якларда яшәгәндә дә гыйльми хезмәтләрен, әсәрләрен язган. Галимнәр фикеренчә, “Хәдисел- баб”ка шәрехне Каенлыда яза. Урта Азиянең күренекле шагыйре суфый Аллаһыярның “Сөбател- гаҗизин” (“Көчсезләрнең ныклыгы”, “Гаҗизләргә терәк”...)әсәренә шәрех- “Рисаләи Газизә” әсәрен 1806нчы елда Кызыл Чапчакта төгәлләнгән дип саныйлар . Таҗетдин Ялчыголның

кайда яшәвенә игътибар итсәң, әлеге иң танылган әсәре – “Рисаләи Газизә Каенлы авылында языла башланган дип әйтеп була. Әдип шулай ук Кызыл Чапчакта: “Кафия”китабына шәрех- “Әл- касыйдәтел- кафия”, “Рисаләи әййүһа әл-вәләд китабына шәрех-”“Ваемсызларны искәртү” ;Кодуринең “Холасател җәүһәри” әсәренә шәрех- “Мөфатихел- Кодури” “Хикмәтел- Һидаяга шәрех”- “Мөфатихел- Һидая”; “Тәлхис” кә шәрех-“Фәваиде - әшрәфийят”; “Тәгълимет- тарик” һәм “Китабе бәһтәрин” китапларына шәрех – “Фәваиде – җәлалийәт”; медицина турындагы “Гыйльме тыйб” китабына шәрех- “Фәваиде-бәһаийәт” һәм ”Тәрҗемәтес- салат"– “Тәгълимес- салайа”га шәрехләр яза.[7]

Алда әйтелгәнчә, Кызыл Чапчакта “Рисаләи Газизә”не тәмамлаганын икәнлеген белдек. Бу вакыйга турында Р. Галиуллин болай дип яза:

“Таҗеддин хәзрәтнең “Рисаләи Газизә” китабын тәмам кылу хәбәре Кызыл Чапчакта гына түгел, тирә- юньдәге авылларга да таралды. Хәзрәтнең үз шәкертләре дә, башка мәдрәсәләрнең гыйлемле хәлфәләре дә, күчереп язар өчен аңардан кульязманы биреп торуын үтенеп мөрәҗәгать итә башлады. Инде үз мәдрәсәсендәге гыйлемле шәкертләрнең дә, мәхәлләдәге ушлы ир- атларның да уңай фикерләрен ишеткәч, Таҗеддин хәзрәтнең күңеле күтәрелде. Ул үзенә хас дәрт белән инде күптәннән ниятләнгән тарих китабын язарга кереште.”[1]

Чыннан да, Х Миңнегулов, Д. Гарифуллин кебек күренекле галимнәр исбатлавынча, 1806 нчы елда Т. Ялчыгол “Тәварихы Болгария” әсәрен язган. Бу әсәр жанры белән шәҗәрәи, ягъни нәсел-нәсәбне чагылдырган кечкенә күләмле, 41битле генә була.

Татар халкын агартуга юнәлтелгән хезмәте белән искелекне чатнатуга, яра башлауга чөй кагучыларның берсе булган Таҗеддин Ялчыголның Каенлы, Кызыл Чапчак авылларында яшәп, иҗат итүе турында менә шундый аз күләмдә генә мәгълүматлар табылган. Татарстан тарихы һәм татар әдәбияты дәресләрендә 18 – 19нчы гасыр башы чорын үткәндә Таҗеддин Ялчыгол турында өстәмә рәвештә менә шушы табылган материаллар белән дә укучыларны таныштырырга була. Балалар күңелендә күренекле язучыга карата хөрмәт уятабыз, аның белән горурлану хисләре тудырабыз. Киләчәктә дә Т. Ялчыголның тормыш һәм иҗат юлын өйрәнүне дәвам итәрләр. Бу күренекле шәхеснең Каенлы, Кызыл Чапчак чоры турында да яңа материаллар белән танышырбыз дип ышанып калабыз.

Докладны әзерләгәндә түбәндәге әдәбият кулланылды:

1.Р. Галиуллин “Васыять” Казан, Татарстан китап нәшрияты, 2017, 116 бит, 171-173 бит, 203бит,

2. Д. Гарифуллин “Чырагы нур сибә бүген дә” Казан, “Сүз”нәшрияты, 2009, 36 бит, 44бит,

3. Д. Гарифуллин “Табышмаклы гомер иясе”, “Казан утлары” № 7, 2018, 166 бит,

4.Д. Гарифуллин “Табышмаклы гомер иясе”, “Мирас” №7 2018, 116 бит,

5.Х. Миңнегулов “Рухи пакълеккә өндәгән китап” “Мирас”- 1998, №10, 13 бит

6. Ф. Шәрәфиев “Каенлы авылы тарихы”, Түбән Кама, “Гүзәл” типографиясе, 2013, 13бит, 14бит.
7. Т Ялчыгол “ Рисаләи Газизә”, Казан, “Хозур” нәшрияты, 2014, 8 бит.

*Гәрәева Гөлнара Риан кызы,*
*Түбән Кама шәһәренең аерым фәннәрне тирәнтен өйрәнүче 10 нчы урта мәктәбенең 1 нче категорияле татар теле һәм әдәбияты укытучысы*

**Татар теле һәм әдәбияты дәресләрендә модельләштерү технологиясен куллану**

Укыту процессында яңа педагогик технологияләрне куллану - яңа метод һәм алымнарны үстерергә, яңача эшләргә ярдәм итә. Без, татар теле һәм әдәбияты укытучылары, дәрестә өйрәнгән теманы җиңел юл белән үзләштерә торган, белем сыйфатын күтәрүгә файдалы булган технологияләрне кулланырга тырышабыз.

Профессор Ә.Рәхимовның " Иҗади үсеш технологиясен" дәресләрдә куллану да уңай күренеш. Бу технология өч өлештән тора. Беренчесе - төшенчәнең эчтәлеген һәм аңа билгеләмә бирү буенча эш итү ысулын гомимиләштерү, икенчесе - укучылар эшчәнлеген төркемнәрдә оештыру, өченчесе модельләштерү.

Модельләр, схемалар белән эш итәргә даими өйрәткәндә, фәнни сөйләм кыскара, автоматлаша һәм фикергә әверелә. Шул рәвешле, тыштан материальләшкән чара укучыларның фикерләү чарасы булып хезмәт итә башлый.

Модельләштерү дәреснең аерым бер этабы буларак кертелә. Модель төзү - иҗади эш. Аның аша укучылар төшенчәнең үзенчәлекле билгеләрен һәм эчке бәйләнешләрен ачалар. Шул нигездә, ул белем алуга кызыксыну уяту чарасы да булып тора.

Модельләштерү дәрестә төшенчә өстендә эш белән нык бәйләнгән. Төшенчә формалаштыру - дәреснең мөһим этабы. Модельләштерү дигәндә теоретик мәгълүматны кыска бер фикер итеп схематик рәвештә күз алдына китерү һәм кәгазьгә төшерү күздә тотыла.Модельләштерү вакытында теоритик мәгълүмат туплана, классификацияләнә һәм кирәкле мәгълүматны югалтмыйча мөмкин булганча кыскартыла . Мондый кыскартылган вариантны истә калдыру да җайлаша.

Мәсәлән, мин башлангыч сыйныфларда “Мөстәкыйль сүз төркемнәрен” өйрәнгәндә, модель төзү һәм төшенчәгә билгеләмә бирүне түбәндәгечә башкарам: төркемнәргә баштарак әзер модель(матрица) таратыла һәм бу модельдәге сораулар урынына укучылар җавапларны

язарга тиеш булалар. **(Кушымта №1)** Соңыннан бу эш һәрбер сүз төркемен өйрәнгәндә кулланыла,шулай итеп укучылар традицион дәресләрдән аермалы буларак, сүз төркемнәре турында кагыйдә сөйләү урынына, сүз төркеменең билгеләрен үз эченә алган модельне тутырып куялар. Бу эш алымы өйрәнгән сүз төркемнәренең морфологик билгеләрен ныгыту өчен бик ярдәм итә.

Мин бүген "Сыйфат " темасын үткәндә модельләштерү алымын куллану тәҗрибәм белән уртаклашам.

Бу алым бик гади . Укучылар , модель дәфтәренең бер битен ачып, өскә, уртага **сыйфат** дип язып куялар. Безгә бүген сыйфат сүз төркеменең билгеләмәсен китереп чыгарырга һәм шул билгеләмәнең моделен шушы дәфтәргә эшләп куярга кирәк булачак.

- *Укучылар, әйдәгез , менә бу җөмләләрдән сыйфатларны табыйк әле.*

*Салкын кыш җитте.*

*Төннәр озынрак, ә көннәр кыскарак.*

*Урамнар ап-ак карга күмелде.*

*Һавада зәңгәрсу болытлар йөзә.*

- *Ә хәзер сыйфатлар ачыклап килгән сүзләрне табыгыз.(кыш, төн,көн,кар,болытлар)*
- *Болар нинди сүз төркемнәре ? ( Исемнәр)*
- *Шулай булгач, сыйфатлар нәрсәләрне белдерәләр инде? (Предметларның билгесен)*
- *Менә хәзер ук төшерәбез һәм модельгә шуны язып куябыз.*
- *Сыйфатның нәрсә белдерүен яздык , хәзер сыйфат турында нәрсәләр язарга тиеш булабыз?( Сорауларын)*
- *Ә хәзер сорауларны модельгә язып куйыйк.*
- *Ә хәзер түбәндәге җөмләләргә карыйбыз.*

*Алсуның курчагы матур, Гөлназныкы тагын да матуррак.Ә Миләүшәнеке бик тә матур.*

- *Бу җөмләләрдә сыйфатларга игътибар итик әле.Анда нинди сыйфатлар бар? (Матур,матуррак,бик матур ).*
- *Матур сыйфаты нинди билгеләрне күрсәтә?(Сыйфат предметның билгесен төрле дәрәҗәдә булуын күрсәтә)*
- *Димәк,сыйфатлар нәрсә белән төрләнә?( Дәрәҗә белән)*

Модель тәмам. Укучылар укытучы белән берлектә билгеләмәне китереп чыгардылар һәм шул билгеләмәне модельләштерделәр.

Модельләштерү эшен башка төрле дә оештырырга мөмкин. Мәсәлән,  укучыларга әзер билгеләмә бирелә һәм укучылар мөстәкыйль рәвештә үзләре модель төзиләр.

Киресенчә, әзер модельне биреп билгеләмә чыгарырга кушарга да момкин. Шулай ук модель  төзүне өй эше итеп тә бирергә була. Укучылар , фантазияләрен эшкә җигеп, модельнең тышкы күренешен кызыклы итеп тә эшли алалар.

Дәреснең  укучылар  белеменә бәя   бирү этабында укучыларга мөрәҗәгать итәм:

Укучыларга, кем сыйфат турында билгеләмәне модельгә карамыйча , мисаллар китереп сөйләп бирә, аңа 5ле куям. Кем бер-ике тапкыр модельгә сүз төшереп , мисаллар китереп сөйли, аңа 4 ле куям. Кем модельгә карап мисаллар китереп сөйли , аңа 3 ле була.

Укучыларны билге белән кызыксындыру әлбәттә инде үзенекен эшли.  Укучылар модельләштерү вакытында үз алларына модельне дөрес итеп төзү максатын гына тугел, ә аны истә калдыру максатын да куялар.

Тел фәннәрен укытканда модельләштерү  алымын  уңайлы һәм алыштыргысыз  алым дип саныйм.

Татар әдәбияты дәресләрендә дә алган модельләштерү технологиясе белем һәм күнекмәләр формалаштыру өчен иң кулай алымнарның берсе булып тора.Мәсәлән,нинди дә булса язучының әсәрен өйрәнү барышында укучылар  геройларга характеристика бирергә өйрәнергә тиешләр. Ләкин характеристика бирү барлык укучыларга да җиңел бирелми.Чөнки аларның сөйләм телләре ярлы булу сәбәпле,иптәшләре янында чыгыш ясарга оялалар.Менә шул авырлыклардан котылу өчен,безгә модельләштерү технологиясе ярдәм итә. Түбәндәге модельне эшләү өчен,башта әзер килеш бирелә**.(Кушымта №2)** Укучылар геройның исемен уртага язалар һәм түгәрәкнең бүленгән 4 өлешенә геройның характер билгеләре күрсәтелә.Мәсәлән,укучылар Х.Такташның “Алсу” шигырен өйрәнгәннән соң, кызга төркемнәрдә сыйфатлама бирделәр.

1)Тышкы кыяфәте:кара бөдрә чәчле,яшь,чибәр

2)Уңай-тискәре яклары:+ шаян,ачык йөзле,шат,яхшы укый;- әзрәк усал

3)Башка геройлар белән мөнәсәбәте:дусты Газзә белән һәрвакыт шаяралар,егетен шаяртып хат яза һ.б.


4)Синең аңа мөнәсәбәтең?

Минемчә, бу модельне берничә геройга берьюлы да,аерым-аерым да куллану отышлы+ булачак.

Татар теле һәм әдәбиятын укытуны камилләштерүнең чиге юк, фәкать эзләнергә, яңалыкка омтылырга, билгеләнгән максатка кыю барырга гына кирәк. Йомгак итеп, шуны әйтер идем: әгәр дә укытучы дәрестә күрсәтмәлекне житәрлек дәрәҗәдә кулланса,төрле уен

ситуацияләре,сөйләм күнегүләре,инновацион технология элементларыннан дөрес файдалана белсә,ул, һичшиксез, эшендә уңышка ирешәчәк.

Кушымта №1




Кушымта №2



*Минехузина Ләйсән Рафис кызы, Гимазетдинова Римма Әхәт кызы,*
*Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районының "25 нче гомуми үсеш төрендәге балалар бакчасы" Муниципаль Бюджет Мәктәпкәчә белем бирү учреждениесенең тәрбиячеләре*

## Балаларның сөйләм телен үстерүдә үстерешле уеннарның роле

Балаларны үз ана телендә сөйләшергә, аралашырга өйрәтү, туган телебезне ярату, аңа карата ихтирам тәрбияләү бүгенге көндә дә иң мөһим мәсьәләләрнең берсе булып тора. Балаларның авазларны дөрес әйтеп, җөмләләрне дөрес төзеп, үзләренең уй фикерләрен тиешле эзлеклеклелектә, ашыйкмыйча сөйли белүләренә ирешү өчен, сөйләм үстерү юнәлешендә даими эш алып барырга кирәк. Ә бу максатларны тормышка ашыруда төрле чаралар кулланып була.

Балаларның сөйләмен үстерүдә уеннарның әһәмияте зур. Уен – шөгыльдә алынган белемнәрне ныгыту чарасы да ул. Уен мәктәпкәчә яшьтәге баланың танып белү эшчәнлеген, иҗади фикерләвен һәм сөйләмен үстерә, уенда бала үзе белмәгәнне өйрәнергә, аны эшләргә омтыла. Шуңа да безэшчәнлекнең һәр төрендә үстерелешле уеннар кулланырга тырышабыз

### Дидактик уен “Хикмәтле түгәрәкләр”

**Максат**:Балаларның иҗади фикерләү сәләтен,тел байлыгын үстерү.

**Бурычлар**: Сүз байлыгын арттыру,гади диалогта катнаша белү, сөйләмнең грамматик төзелешен формалаштыру,сүзләрне отып алу аша хәтер,зиһен үстерү,татар теленә кызыксыну уяту.

**Яшь үзенчәлекләре:**4-7 яшьлек балалар өчен

Уен үз күчәре тирәсендә әйләнүче өч түгәрәктән тора.Һәр түгәрәк алты секторга бүленгән. Аларның һәркайсына рәсемнәр ябыштырылган. Бала 1-2-3нче түгәрәкләрне әйләндереп, кирәкле рәсемнәрне каракаршы куя, сүрәтләрне атый. Тәрбияче белән диалогта катнаша. Темалар буенча рәсемнәрне алмаштырырга мөмкин.

**Темалар:**

*Гаилә

*Уенчыклар

*Җиләк-җимешләр

*Йорт хайваннары

*Кыргый хайваннар

*Савыт-саба

4яшь-2 түгәрәк

5 яшьтән-3 түгәрәк

7 яшь-4 түгәрәк өстәлә

**Уеннарның төре:**

“Бир-мә” уенында бала 1-нче түгәрәктәге бер рәсемне сайлап ала, аннан соң 2-нче түгәрәктәге бер рәсемне сайлап ала, ике түгәрәктәге рәсемнәрне кара- каршы туры китерә. Бала рәсемнәрдәге сүрәтләрне атый һәм тәрбияче белән диалогка керә.
Бала: Әби ( бабай, әни, әти, малай, кыз), туп бир.
Тәрбияче: Мә, туп (курчак, куян, аю, эт, песи).

”Рәхмәт” уенында бала 1-нче түгәрәктәге бер рәсемне сайлап ала, аннан соң 2-нче түгәрәктәге бер рәсемне сайлап ала, ике түгәрәктәге рәсемнәрне кара- каршы туры китерә. Бала рәсемнәрдәге сүрәтләрне атый һәм тәрбияче белән диалогка керә.

Әйе-юк” уенында бала 2-нче түгәрәктәге бер рәсемне сайлап ала, аннан соң 3-нче түгәрәктәге шундый ук бер рәсемне сайлап ала, ике түгәрәктәге рәсемнәрне кара- каршы туры китерә. Бала рәсемнәрдәге сүрәтләрне атый һәм тәрбияче белән диалогка керә. ( 1-нче түгәрәкне алып куярга да мөмкин)

Тәрбияче: Туп (курчак, куян, аю, эт, песи) чиста?
Бала: Әйе, туп (курчак, куян, аю, эт, песи) чиста (матур).
Тәрбияче: Ә бу туп (курчак, куян, аю, эт, песи) чиста?
Бала: Юк, туп (курчак, куян, аю, эт, песи) пычрак.

“Бир-мә” уенында бала 1-нче түгәрәктәге бер рәсемне сайлап ала, аннан соң 3-нче түгәрәктәге бер рәсемне сайлап ала, ике түгәрәктәге рәсемнәрне кара- каршы туры китерә. Бала рәсемнәрдәге сүрәтләрне атый һәм тәрбияче белән диалогка керә. ( 2-нче түгәрәкне алып куярга кирәк)
Бала: Әби ( бабай, әни, әти, малай, кыз), туп бир.
Тәрбияче: Мә, туп (курчак, куян, аю, эт, песи).
Бала: Туп (курчак, куян, аю, эт, песи) пычрак.
Тәрбияче: Туп (курчак, куян, аю, эт, песи) ю.

*Гиниятуллина Алсу Рафис кызы,*
*Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районының «35нче лицей» муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесенең татар теле һәм әдәбияты укытучысы*
*Сибгатуллина Гульчачак Гайнетдин кызы, Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районының "аерым фәннәрне тирәнтен өйрәнүче 27 нче урта гомуми белем бирү мәктәбе" муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесенең югары категорияле татар теле һәм әдәбияты укытучысы*

## Күңел бизәге

**Сөйлә миңа- мин онытырмын,**
**күрсәт – истә калдырымын,**
**кызыксындыр- өйрәнермен.**

**Максат:** милли традицияләребез нигезендә ятучы кыйммәтле, милли, әхлаклы сыйфатларны саклау;

**Бурычлар:**

- укучыларны татарлар халкының сәнгатьте, милли татар орнаменты белән таныштыру;
- татар халык бизәк элементларын кулланып, брошка ясарга өйрәтү;
-эш барышында куркынычсызлык кагыйдәләрен үтәү;

**Кирәкле материаллар:** Өлге (шаблон), кайчы, клей, фетр һәм бархат тукыма, эләктермә, бизәкләр, интерактивная доска.

Татарлардан рухи мирас белән бергә матди мәдәният өлкәсенә караган мирас та калган. Шундыйларның берсе — халыкның өс киеме. Өс киеменең бик борынгы төрләре, әлбәттә, безгә килеп җитмәгән. Ә инде җиткән кадәресе халкыбызның кабатланмас иҗади көчкә ия булуын күрсәтә. Хатын-кызларның өс һәм баш киеме белән бизәнү әйберләре дә тыгыз бәйләнгән. Гасырлар буена халык бу эшкә үзенең кул көчен генә түгел, бәлки матурлыкка омтылышын хыялын, эстетик зәвыгын да салган.

Кешелек дөньясы һәрвакыт матурлыкка омтылып яшәгән. Гүзәллек белән янәшә үзең дә шәфкатьлерәк, мәрхәмәтлерәк булырга тырышасың. Матурлык безне кара уйлардан

коткара, явызлыктан саклый. Безнең әби-бабаларыбыз элек-электән матурлыкка омтылганнар. Татар халкы тегәргә, чигәргә яраткан, биеп, җырлап, уйнап күңел ачкан. Һәр бизәк, кул эше кыз баланы тәрбияләүнең, кияүгә бирү, хатын кызга хас сыйфатларга өйрәтүнең бер ысулы булган.

Дәүләт башлыгыбыз, Рөстәм Миңнеханов 2023 елны Милли мәдәният һәм традицияләр елы дип игълан итте. Милли җәүһәрләрнең кыйммәтле мирас икәнлегенә төшендерү, аларны сакларга кирәклеген ассызыклау һәм төшерү өчен мастер - класс оештырырга булдык.

Инде халкыбызда болай диләр:

**“Сөйлә миңа- мин онытырмын, күрсәт – истә калдырымын, кызыксындыр- өйрәнермен”**. Менә без дә сезне кайбер бизәкләр белән таныштырабыз. Бизәкләргә игътибар итик. Бизәкләрдә без кыңгырау, лалә чәчәкләрен күрәбез, шул ук вакытта ярым түгәрәкле рәсемнәр дә бар. Ә төсләренә килгәндә ачык төсләр: кызыл, сары, яшел, зәңгәр.

- **Табышмак әйтәм**:

- Яз көнендә бакчада кызыл-сары патша кызы (Лалә чәчәге).

Әйе, дөрес. Лалә чәчәге – татар халкының милли бизәге дә, аның белән калфакларны, түбәтәйләрне, алъяпкычларны бизиләр.

Менә бүген без сезнең белән ләлә чәчәге рәсеме белән түш бизәге язарбыз.

ЭШ планы:

1. Кирәкле материаллар һәм куркынычсызлык кагыйдәләре белән таныштыру;
2. Лалә чәчәгенең өлгесен 3 төсле фетрга сызу;
3. Кызыл, сары, яшел фетрлардан сызылган элементларны кисү;
4. Үрнәккә карап ябыштыру;
5. Әзер түш бизәгенең артына фетр ярдәмендә булавка беркетү.

Йомгаклап шуны әйтәсем килә, милли киемнәребезне истә тотып аны киләчәк буыннарга җиткерү безнең бурычыбыз, милләтебезгә булган хөрмәтебез. Яхшыны – яманнан аера белгән, матурлыкны яраткан, гореф – гадәтләрен онытмаган балалар киләчәктә үз юлларын табарлар дип ышанып калам.

35 нче лицей укытучысы Гыйниятуллина Алсу Рафисовна, 27нче мәктәп укытучысы Сибгатуллина Гөлчәчәк Гайнетдиновна



*Гыймранова  Илсөяр Гарәфетдин кызы,*
*Түбән Кама муниципаль районы кайбер фәннәрне тирәнтен өйрәнүче 27нче номерлы муниципаль бюджет белем бирү учреждениесе 1нче категорияле татар теле һәм әдәбияты укытучысы*

**Теле һәм әдәбияты дәресләрендә укучыларның иҗади сәләтен үстерү алымнары**

Кемне генә сокландырмас,
Укытучы хезмәтенең чын җимеше.
Балаларына ана телен бүләк итә-
Менә нинди бөек хезмәт аның эше...

Кешенең иң матур истәлекләре, иң изге хыяллары, иң беренче шатлык- куанычлары аның балачагы яки үсмер чоры белән бәйләнгән була. Менә шушы матур истәлекләр арасында шактый ук зур урынны мәктәп, балачак дуслары һәм, әлбәттә инде, укытучылар алып тора.

Укытучы һөнәрен саклау-тынгысызлык, эзләнү юлын сайлау, үз-үзеңә искиткеч таләпчән булу, көндәлек тырыш, эзлекле хезмәт юлын саклау дигән сүз ул. Үз эшенең остасы булу өчен, мөгаллим һәм тәрбиячеләргә балаларның ни дәрәҗәдә сәләтле булуын белеп эш итү мөһим.

Сәләтне үстерү өчен, балаларның фәннәр буенча биремнәрне һәм үзләре алдына куелган бурычларны эзлекле һәм системалы үтәүләренә ирешү сорала.

Ә иҗади үсеш технологиясе, белем алу процессы белән беррәттән, акыл хезмәте культурасы һәм дисциплинасы тәрбияли. Укуда уңышларга ничек ирешелгәнен төшендерә, балаларны үз-үзләренә һәм үзара контроль ясарга өйрәтә. Тырышып эшләү, яхшы нәтиҗәләргә ирешү балада аннан-моннан эшләгән эшкә, эшсезлеккә, гамьсезлеккә түзеп тора алмау гадәте тәрбияли. Иҗади үсеш технологиясе укырга теләк, илһам, авырлыкларны җиңеп чыгу шатлыгы бирә. Ә балаларда, үз чиратында, уңышлылык хисе тудыра. Аларның нерв системасына да уңай йогынты ясый. Димәк, бала дәрестә теләп эшли, шактый катлаулы проблемаларны чишә, арымый, талчыкмый, аның сәламәтлегенә дә зыян килми.

Шат, якты хисләр тудыручы хезмәттән башка бәхетле балачакны күз алдына китереп булмый. Укучының акыл хезмәте, укудагы уңышлары-аның рухи тормышы, эчке дөньясы ул. Бала үз хезмәтендә уңышлар күрми икән, ул чакта белем алуга омтылыш, очкын сүнә. Шуңа күрә дә укуда хезмәт шатлыгы кичерә, кыенлыкларны җиңеп чыгу белән горурлана алырлык

эшләр укучы балага күбрәк бирелергә тиеш. Укудагы уңыш балаларга аврлыкларны җиңеп чыга алырлык энергия бирә. Иҗади эш эшләгәндә балалрның уңышлары белем дәрәҗәләре шактый югары икән, димәк, аларның рухи сәламәтлекләре дә нык дигән сүз. Үз хезмәте белән горурланмаган кеше чын кеше була алмый.

Башлангыч сыйныф укучылары, шулай ук 5-6 нчы сыйныф укучылары да бирелгән иҗади эшне зур теләк һәм тырышлык белән башкаралар. Гадәттә, эш өйдә олылар ярдәме белән башкарыла. Димәк, ата-аналар белән бергә башкарылган күмәк эш барлыкка килә, бу эш ата-аналарда да, балада да зур кызыксыну уята, эзләнеп эшләргә, логик фикерләргә мөмкинлек тудыра. Тырышып эшләгән күмәк эштән югары бәя бирерлек матур гына хезмәтләр-иҗади җимешләр туа.

Иҗади эш төрләре бик күп. Шуларның берсе буларак-китапчыклар иҗат итү турында өйрәтергә була. Китапчыклар иҗат итү-күпкырлы эш: фикерләү сәләтен үстерә, эзләнеп эшләргә өйрәтә, фантазияне, логик фикерләү дәрәҗәсен арттыра.

Эш төрләренә күз салсак, түбәндәгеләрне әйтергә була: китапчык иҗат итү өчен күп авторларның әсәрләре белән танышырга кирәк булачак. Димәк, бала китаплар белән эшли, аларның матурлыгына соклана, шигырь, әкиятләр, хикәяләр белән таныша. Алар арасыннан бер темага туры килә торганнарын сайлый. Мәсәлән, безнең китапның исеме -“Урманда”. Бала логик фикер йөртә, мондый исемле китапта нинди темага әсәрләр булырга мөмкин? Бала эзләнә: Урманда кемнәр яши? Урманда нәрсәләр үсә? Нинди кошлар бар? Без урманга йөрибезме? Ни өчен безурманга барабыз? Урман безгә нәрсә бирә? Табигатьне саклау ни өчен кирәк? Бу сорауларга җавап тапканнан соң, “Урман” темасына нинди исемдәге әсәрләр язып буласын аңлыйбыз, аннан соң инде шигырь, табышмак, әкият, хикәяләр эзли башлыйбыз. Язучы-шагыйрҗләр белән танышабыз, аларның исемнәрен истә калдырабыз. Шигырь һәм проза әсәрләрен дөрес язу алымнарын өйрәнәбез. Эш вакытында балалар татар халык авыз иҗаты әсәрләре белән дә танышалар. Укучы бу өлкәдә дә җитәрлек белем ала, бу хәлләрне аерым автор түгел, ә халык иҗат итүе турында күңеленә сеңдереп калдыра.

Китапчыкта тәкъдим ителгән әсәрләргә рәсемнәр ясау да бала өчен кызыклы һәм файдалы эш. Баланың фантазиясе үсә, матурлыкка соклана белергә өйрәнә. Китапларның матур бизәкле, төрле төсләрдән ясалган рәсемнәре булуы да уңай нәтиҗә бирә-балада кызыксыну уята., китапны укып чыгарга теләк тудыра. Шулай булгач, китапның бизәлеше зур әһәмияткә ия, дип санап була.

Ясаган нәкъ менә шушы китапчыкта балаларның табигать күренешләре белән кызыксынучанлыгын үстерү, татар халык авыз иҗаты әсәрләре аша укучыларның сүз байлыгын арттыру, эш барышында өлкәннәргә булышу теләге уяту да бу эшнең максаты була.

Китапчыкларны әти-әниләр белән берлектә эшләү, уйлавыбызча, гаилә белән эшне җайга сала. Иҗади эшнең шундый төрен сайлап укучы берьюлы өч бурычны хәл итә:

- укучының укуга, дәрескә кызыксынуын уята;
- укучылар ата-аналары белән үзара ышаныч һәм хезмәткә нигезләнгән мөнәсәбәтләр урнаштыра;
- хезмәткә, чиста-пөхтә эшләүгә омтылыш арта.

Укучыларда иҗади эшләргә кызыксыну уяту, сөйләм телен үстерү, аралашу культурасы булдыру максаты белән, еш кына дәресләребездә кулланып килгән иҗади эш алымы-әкият, хикәя яки шигырь язу эшләрен дә уңышлы һәм шул ук вакытта отышлы дип тә әйтергә була. Мондый биремле эшләр укучы тормышына әледән әле яңарыш, яңалык өстәп тора.

Бу төрдәге эш алымнарына әзерлек алдан ук алып барыла. Ел дәвамындаа укучылар төрле темаларга (сыйныфтан тыш укыган китаплар, каникулларны ничек уздыру, табигатҗ турында матур эчтәлекле җөмләләр язып киләлә, кечкенә хикәяләр төзиләр).

Ләкин бу иҗади эшләр бертөрлерәк, инша рәвешендә генә була. Тора-бара балаларның кызыксынулары сүрелә төшмәсен өчен, укучыларның игьтибарын җәлеп итәрдәй, аларны бергә туплый торган эш төрләре дә бар. Шуңа мисал итеп, “Яшь хәбәрчеләр” түгәрәге оештыруны әйтеп үтәргә кирәк булу урынлы. Түгәрәктә һәр укучы үз фикерен язып кына калмый, ә башка укучыларның да фикерен тыңлый, үз кимчелекләрен дә күрә ала. Һәм иң мөһиме-күмәк эш башкара ала. Эш үрнәкләрен бергәләп уку, уңай һәм тискәре якларын күрсәтү, кирәк булса, өстәмәләр кертү кебек эшләр укучыларда бу төр эшкә гел омтылып торуны күрсәтте.

Өйгә кайтып, укучылар әти-әниләренә үз иҗат җимешләрен күрсәтергә онытмады. Ә әти-әни, әлбәттә инде, үз чиратында бу минутларда баласы өчен горурлану, куану хисләре кичерә.

Язмаларның темалары төрле-төрле булса да, укучылар теләге белән төркемнәргә бүленеп эшләү алымнары да кулланыла. Һәр төркем үз эшен җиренә җиткереп эшләргә тырыша, чөнки ни генә язсалар да, ул бит төркемнең иҗат җимеше-төркемнең йөзе.

Гомумән, эшчәнлекнең мондый формасы нәтиҗәгә ирешүнең бер юлы. Укучыларның иҗади сәләтен, сөйләм телен үстерә, дөньяга карашын киңәйтә, битараф булмаска өйрәтә. Балалр бертөрлелектән бик тиз туялар. Ә мондый түгәрәкләрдә колач җәеп эшләргә, хыялланырга шартлар бар.

Нәтиҗә ясап шуны әйтергә була, бары тик балаларның сәләтләрен күреп, дөрес юнәлештә эш алып барганда, мөгаллимнең эш нәтиҗәсе күзгә күренә, үзенең эшеннән канәгатьләнү хисе таба ала, һәм уңышлы шәһес тәрбияләүнең үрнәге булып тора. Дәресләрдә

информация-белемгә, ә белем күнекмәләргә әверелә. Укытучы һәм укучыда үз көченә ышаныч туа, алар үзләрен үзләре туплаган тәҗрибә белән көчле итеп сизәләр.
Әгәр дә без җәмгыятьнең алга таба үсүен теләсәк, һәр укучының, һәр шәһеснең үсешен тәэмин итәргә тиешбез.

*Жуковская Руфина Касим кызы*
*Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районының "Аерым фәннәрне тирәнтен өйрәнүче 16нчы урта гомуми белем бирү мәктәбе" муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесенең беренче категорияле башлангыч сыйныф укытучысы*

**«ФДББС шартларында рефлексия - заманча дәрес өчен кирәкле шарт» темасына мастер-класс**

ФДББС нигезләнеп төзелгән дәрестә рефлексия этабы иң кирәкле этап булып тора.

Нәрсә соң ул рефлексия?

Сүзлекләргә мөрәҗәгать итсәк, рефлексия – ул үзанализ, үзбәя, “үзеңне эчке яктан карау” дип аңлатыла. Ә инде дәрестә куллану ягыннан карасак, рефлексия ул – укучы һәм укытучының уку процессын камилләштерергә мөмкинлек бирүче уртак эшчәнлеге. Ул, укучыларның үз торышларын бәяләү, үзләренең хисләренә анализ ясау, эшчәнлек нәтиҗәләрен бәяләү булып тора.

**Рефлексия ни өчен кирәк?**

Әгәр бала:

- бу теманы ни өчен өйрәнүен, киләчәктә аңа ни өчен кирәк булуын аңласа;
- бу дәрестә нииди максатларга ирешелүен аңласа;
- бу эшкә ул үзеннән нинди өлеш кертүен аңласа;
- үзенең һәм сыйныфташларының эшләрен адекват рәвештә бәяли белсә,

... уку – укыту процессы кызыклыга әйләнә, белем алу һәм бирү бала өчен дә, укытучы өчен дә җиңеләя.

Рефлексия өлешен кайчан үткәрергә дигән сорау туа. Әлбәттә инде, без рефлексияне дәреснең төрле этабында үткәрә алабыз.

Дәрес этабы кебек үк функциясе ягыннан рефлексия берничә төргә бүленә. Бу төрләрне белү, укытучыга дәрес планын төзегән вакытта алымнарны берләштерергә мөмкинлек бирә.

Түбәндәгеләрне карап китик:

**1. Эчтәлек буенча:** символик, телдән һәм язмача рефлексия.

Символик рефлексия төрендә укучы символлар ярдәмендә билге куя. Бу карточкалар, жетоннар һ.б.) булырга мөмкин.

Телдән – укучы үзенең уй-тойгыларын , үзенең хисләрен телдән әйтеп бирә алуы.

Язмача – бу төр иң авыр төр һәм ул күп вакытны таләп итә. Әлбәттә, бу төрне дәрес материалын йомгаклаганда куллану отышлы.

**2. Эшчәнлек формасы буенча:** коллектив, төркемнәрдә, фронталь һәм индивидуаль.

Рефлексиянең бу төрен кулланганда укучыларны өйрәтү җиңелрәк булачак. Башта – сыйныф белән эш, аннары – төркемнәрдә, аннары – берничә укучыдан сорау. Бу инде, әлбәттә, укучыларны мөстәкыйль эшләргә өйрәтәчәк.

**3.** Үткәрү формасы буенча : анкета, сорау-җавап, рәсем һ.б.

**4. Функциясе буенча:**

физик – өлгерде – өлгермәде, авыр – җиңел һ.б.

сенсор – кызык-кызык түгел, уңыйлы-уңайсыз

интеллектуаль – аңлады-аңламады ,авырлыклар очрады һ.б.

**5. Максат буенча рефлексия 3 төркемгә бүленә: эмоциональ хәл һәм кәеф рефлексиясе, эшчәнлек рефлексиясе һәм материал эчтәлеге буенча рефлексия.**

**I. Кәеф рефлексиясе.**

Эмоциональ – ул укучының кәефен , уку материалын үзләштерү хисен күрсәтә. Бу гадәттә безнең еш кулланыла торган төр. Ошады/ошамады, кызыклы / кызыксыз, күңелле /моңсу.

Бу төр укытучыга сыйныфның гомуми кәефен күрсәтә. Теманы укучы аңлаган, аңламаганмы икәнлеген ачып сала.

**Бу төр рефлексияне** 1 нче сыйныф укучылары белән дә үткәрү җайлы. Безнең кул астыбызда күп кенә таратма материаллар смайликлар бар. Аларны куллану бик отышлы. Бармакларны аска, өскә күтәреп күрсәтү дә бала өчен иң җайлы ысул. Теманы аңлаткач, ныгыту күнегүләре эшләгәч үткәрү уңайлы. Дәрес башында хис рефлексиясен сыйныфның кәефен белү өчен , сыйныф белән контакт оештыру өчен үткәрәбез. Темага туры килгән көй кую, хисле шигырь уку, цитаталар китерү. Моннан соң укучыдан “Син нәрсә тойдың?”, “Кәефең ничек синең хәзер?” дип сорау отышлы булачак. Шулай итеп, беренчедән, укучылар үзләренең торышыларын билгели алачаклар, икенчедән, үз күзлекләреннән чыгып эш итәчәкләр һәм бу теманы кабул итүгә зур этәргеч бирәчәк.

Шулай ук “Импульс” , “Кар бабай” кебек төрләр дә укучының хис – тойгысын, кәефен аңлау өчен бик отышлы кулланылачак.

**“Импульс”** - укучылар түгәрәккә басалар һәм бер-берсенең кулларын тоталар һәм кулны әкрен генә кысу исәбеннән бер-берсенә импульс җибәрәләр. Импульс укытучыга әйләнеп кайтканнан соң укытучы “Мин яхшылык импульсы җибәрәм”, “Мин яхшы кәеф импульсы таратам” диеп укучыларны дәрескә әзерли.

**“Кар бабай”** – дәреснең төрле вакытында эшләтеп алып була. Укучылар кар бабайга төрле төстәге жетоннарны беркетәләр: кызыл – яхшы кәеф, яшел – тынычлык, зәңгәр – күңелсез, моңсу.

**Пейзаж.** Укучыларга ике картина бирелә. Бер картина салкын төсләр белән ясалган, моңсу. Ә икенче картина – җылы төсләрдән тора, матур, күңелле. Укучылар кайсы ошый шуны сайлап алачаклар.

**II. Эшчәнлек рефлексиясе.**

**Бу төр рефлексия укучыларга** уку материаллары белән эшләү алымнарын аңларга һәм иң уңай юлларын эзләү мөмкинлеге бирә. Өй эшләрен тикшерү вакытында, дәрес материалын ныгытканда, проектларны яклаганда кулланырга кирәк. Ул укучыларга эш төрен аңларга ярдәм итә, үзенең эшчәнлек активлыгын анализларга этәрә, укуда булган пробелларны ачыклый.

**Ничек үткәрергә:**

**Уңыш баскычы** – һәр баскыч – бер эш төре. Эш күп эшләнелгән саен баскычтагы кеше дә өскә күтәрелә.

**Уңыш агачы .** һәр яфракның үз төсе була: яшел – барсы да дөрес эшләнгән, сары – авырлыклар очраган, кызыл – хаталары күп. Һәр укучы агачны үз яфрагы белән бизи.

**Вагоннар.** Һәр вагон аерым күнегү, эш өчен бирелә. Мәсәлән, дәресне ныгыту этабында 3 күнегү эшлисез икән, 3 вагон булачак. Укучыларга кайсы вагонның күнегүе авыррак бирелгәнне билгеләү өчен, шул номерлы вагонга кеше,хайван яисә жетон куярга кирәк булчак. Яисә киресе- җиңел эшләнелгән номерлы вагонга...

Шулай ук, укучыларга үз эшчәнлегенең активлыгын күзәтеп бару өчен мондый эш тә тәкъдим итәргә була:

**“Тамгалар” «V»** - укытучы соравы буенча җавап бирдем, ләкин җавап дөрес түгел. **«W»** - укытучы соравы буенча җавап бирдем, җавап дөрес . «|» - үзем җавап бирергә теләдем, әмма җавап дөрес түгел. «+» - үзем җавап бирергә теләдем, җавап дөрес . **«0»** - җавап бирмәдем.

Шушы нәтиҗәләр буенча укучылар үзләренең белемнәрен анализлый алалар.

**III. Материал эчтәлеге буенча рефлексия**.

Рефлексиянең бу төрен дәрес ахырында, яки дәрес этапларын йомгаклаганда кулланырга була. Ул укучыларга тема эчтәлеген аңларга ярдәм итә, үз эшчәнлегенең эффективлыгын бәяләргә этәргеч бирә.

**Ничек үткәрергә:**

Укучыларга сүзтезмәләр "болыты" ягъни клешелар бирелә һәм алар шул сүзтезмәләрне дәвам итәргә тиеш. Мәсәлән, интерактив тактада төрле вариантлар язылган слайд чыга:

- мин бүген белдем...

- авыр булды...

- мин аңладым, ...

Һәр укучы 1-2 сүзтезмәне ала һәм дәвам итә. Бу рефлексияне телдән дә, язмача да эшләргә була.

**График :** тактада таблица бирелә

| **Дәреснең максаты** | **+ (бар да аңлашылды)** | **- ( берни дә аңламадым)** | **? ( кызыклы, тагын да күбрәк белергә телим)** |
|---|---|---|---|

Таблицада дәрес максатын башлангыч сыйныфлар өчен үзе язсаң өлкән сыйныфлар белән үзләре үк максат куярга мөмкин. Дәрес ахырында укучылар шул максатларга ирешелгәнме, юкмы икәнлекләрен калган графаларда күрсәтәләр.

| | |
|---|---|
| **Анкета. Дәрестә мин эшләдем** | **Актив/пассив** |
| **Мин дәрестә үз эшем белән** | **Кәнәгать/ Кәнәгать түгел** |
| **Дәрес минем өчен ...** | **Кыска/озын тоелды** |
| **Дәрестә мин..** | **Ардым/армадым** |
| **Минем кәефем ...** | **Күтәрелде/төште** |
| **Дәрес материалы миңа...** | **Аңлашылды/аңлашылмады** |
| **Өй эше миңа** | **Файдалы булды/ зынлы булды** |
| | **Кызыклы/ кызыксыз иде** |
| | **Җиңел/авыр** |
| | **Кызык/кызык түгел** |

**Фразеологизм яисә мәкаль.**

Укучы үзенә килешле фразеологизмны яисә мәкальне сайлап ала.

• ***суга җибәргән балык кебек***

• ***баш тубал булды***

• ***агым уңаена йөздем***

**“Плюс-минус-кызык”**

**“П”** – ошаган эш төре языла, мәгълүмат тупланыла.

**“ М” –** ошамаган эш төре, аңлашылмаган һәм кирәк булмаган мәгълүмат тупланыла.

**“К” –** укучылар дәрестә очраган барлык кызыклы фактларны язалар, укытучыга булган сорауларын урнаштыралар**.**

Бу төр бигрәк тә укытучы өчен бик кызык рефлексия төре. Чөнки ул укытучыга дәресне укучылар күзлегеннән карарага ярдәм итә һәм җитешсезлекләрне ачып сала.

Материал эчтәлеге буенча рефлексия төрләре күп һәм аларны монда санап бетерү мөмкин түгел. Кайберләре: “Синквейн”, “Кластер”, “Инсерт”,”Пәрәвез”.

Йомгаклап шуны әйтәсем килә, үз дәресен укучы өчен кызыклы һәм файдалы итеп үткәрергә теләгән укытучы заманча дәрестә рефлексия этабының әһәмиятен аңлап эшләргә тиеш. Рефлексия без гадәтләнгәнчә, дәреснең йомгаклау этабында гына үткәрелергә тиеш түгел, ә аның төрле этабында чагылыш табарга тиеш. Ул үткән теманы,юлны аңлауга, һәркемнең уйланган, аңлашылган әйберләрен уртак копилкага җыюга юнәлдерелгән. Аның максаты-дәрестән төгәл нәтиҗә белән китү генә түгел, ә мәгънәле чылбыр төзү, үз алымнарыңны башкаларның алымнары белән чагыштыру да. Ул укучының дәрестә алган белемен генә, кагыйдәләрне генә истә калдыруы түгел, ә дәрестәге үз эшчәнлеген бәяләве, аны киләчәктә куллана алуы. Шул чакта бездән замана таләп иткән мөстәкыйль фикер йөртүче, конкурентлыкка сәләтле укучы үстерәчәкбез.

*Зарипова Әнисә Газизуловна*
*Татарстан Республикасы Түбән Кама*
*муниципаль районы  Бакый Урманче исемендәге*
*“2 нче гимназия” муниципаль бюджет белем*
*учреждениесенең югары категорияле*
*татар теле  һәм әдәбияты укытучысы*

## Татар әдәбияты дәресләрендә  Р. Фәхреддин  мирасын куллану

“Кеше булу өчен гыйлем белән күркәм холык кирәктер, һәм дә боларны бер - берләреннән аеру дөрес булмас”, - дип язып калдырган татар халкының тарихын, мәдәниятен өйрәнүгә багышланган халкыбызның күренекле мәгърифәтчесе, фикер иясе, язучы һәм

мөгаллим Р. Фәхреддин. Хезмәтләрендә милләтне белемле һәм тәрбияле итү белән бергә, балага әдәп - әхлак кагыйдәләрен яшьтән үк сеңдереп үстерүгә зур игътибар бирә, шәхес тәрбияләүне һәм камилләштерүне үзенең төп максаты дип саный.

Татар әдәбияты дәресләрендә әсәргә анализ ясаганда, геройларның эш- гамәлләренә, вакыйгаларга бәя биргәндә, Р. Фәхреддиннең "Тәрбияле бала", "Тәрбияле ана", "Шәкертлек әдәпләре", "Нәсыйхәт", "Адабе тәгълим" хезмәтләрен кулланам.

Ә. Еникинең "Матурлык" хикәясендә Бәдретдиннең шәкертләр алдында әнисеннән уңайсызланмавы аны зурлый. Мәсәлән, "Нәсыйхәт. Тәрбияле бала" китабында бирелгән үгет-нәсыйхәтләрне укып фикер алышырга мөмкин. "Алтыннан да кыйммәтле, оҗмах нигъмәтләреннән дә кадерле булган нәрсә тәрбияле баладыр. Ана һәм ата өчен тәрбияле бала кебек олы байлык һич булмас. Тәрбияле бала дөньяда җанга шатлык һәм ахирәттә йөзгә әхлак китерер. Тәрбияле бала дөнья байлыгына да бирелмәс бер дәүләт".

Ф. Хөснинең "Йөзек кашы" әсәрендә Айдар образына характеристика биргәндә, Р. Фәхреддиннең "Нәсыйхәт" китабының "Шәкәртлек әдәпләре" бүлегеннән түбәндәге өзекләрне китерергә була.

"Һәрадәм баласы үзен-үзе тәрбияләргә һәм камилләштерергә тиеш, буй җиткән һәр кеше үзен-үзе тәрбияли ала".

"Гүзәл холык - бик файдалы бер камиллектер... Гүзәл холыкның файдасы күбрәк вакытта башкалар өчен була, берәүнең гүзәл холыклы булуыннан гомумхалык файда күрә"

Димәк, адәм баласы үскән саен үзенең холкында булган тискәре сыйфатларны киметә, ә яхшы сыйфатларны арттыра барырга, үз тормышына карата мәгънәле яшәү рәвеше сайларга тиеш.

Ш. Камалның "Буранда", А. Гыйләҗевнең "Җомга көн кич белән", Ә Еникинең "Әйтелмәгән васыять", Т. Миңнуллинның "Әниләр һәм бәбиләр", М. Җәлилнең "Ана бәйрәме" әсәрләрен анализлаганда, Р. Фәхреддиннең "Ата- ана" бүлегендә бирелгән нәсыйхәтләрне китерергә була: "Олыларны, ата- аналарны хөрмәт итү савап китерер, дөнья тормышының тынычлыгын арттырыр"

Ф. Әмирханның "Нәҗип" хикәясендә Нәҗипнең һөнәр табу юнәлешендә эзләнүләренә нәтиҗә ясаганда, Р. Фәхреддинең тәгълиматларын китерү уңышлы булыр дип уйлыйм. "Һич нәрсәсе юк адәм фәкыйрь түгел, бәлки һөнәре һәм тырышлыгы юк адәм фәкыйрьдер..."

Г. Ибраһимовның "Кызыл чәчәкләр" әсәрендә Солтанның тырышлыгына, хезмәт сөючән булуына, эти- әнисенә карата ихтирам, хөрмәт, олылау сыйфатларына бәя биргәндә "Тәрбияле бала" әсәрендә бирелгән нәсыйхәтләргә таянырга була. "Хезмәт күрсәткән кешеләр һәрвакыт хөрмәттә булырлар вә якын күрелерләр, моны исә үзегез дә сизәсездер. Хәлбуки сезнең ата- аналарыгыз сезгә иң авыр вә мәшәкатьле хезмәтләрен иттеләр вә һаман да итәләр...

Моның өчен һәрникадәр аларның хезмәтләренә карышмавыгыз вә мәшәкатьләренең хакын үтәвегез мөмкин булмаса да- һаман аларга ихлас белән хезмәт итүче һәм аларга хөрмәт күрсәтүче булыгыз!"

Заманыбызның авыр бер мәсьәләсе, кешелекне упкынга сөйрәүче эчкечелек чирен ярып күрсәтүче Р. Мөхәммәдиевнең "Ак кыялар турында хыял" әсәрендә табигать баласының язмышында кешеләр тормышында тамыр җәйгән афәт күзәтелсә, Х. Сарьянның "Бер ананың биш улы" әсәрендә Раббани ихтыяр көче булмау, җаваплылык тойгысын югалту, эчү аркасында фаҗигага юлыга. Әлеге әсәрләрне өйрәнгәндә, Р. Фәхреддиннең "Җәвамигуль – кәлим шәрхе" китабыннан өзек китерелә: "Исерткеч- төрле бозыклыкларның анасыдыр. Исерткеч эчү әхлакны боза, сәламәтлекне җибәрә. Исерткеч белән шөгыльләнүче кешеләрнең нәселләре начарлана".

Р. Фәхретддин "Гыйлем әхлак" китаплар тупланмасының тугызынчы кисәге булган "Адабе тәгълим" исемле китапның беренче бүлеген "Гыйлем. Мөгаллим. Тәрбия" дип атый. Мөгаллимә укучыга төпле белем бирү белән беррәттән, дөрес юнәлеш бирергә, рухи яктан камил, иҗади мөмкинлекләрен тормышка ашырырга сәләтле шәхес тәрбияләргә тиеш. Әлеге китапта мөгаллимнәргә кагылышлы 13 вазифаны һәм түбәндәге өзекләрне Ф. Яруллинның "Сез иң матур кеше икәнсез", "Т. Миңнуллинның "Үзебез сайлаган язмыш", Г. Исхакыйның "Мөгаллим", М. Мәһдиевнең "Фронтавиклар" әсәрләрен өйрәнгәндә кулланырга мөмкин. "Укытучы булсагыз, шәкертләрне кагыйдә буенча тәрбия кылыгыз. Холыкларын гүзәлләндерегез, хәлләренә яраклы гыйлемнәрне өйрәтегез, гомерләрен әрәм итмәгез. Шәкертләр өчен җаваплы булачак кешеләренә иң беренче дәрәҗәдә булганнары-мөгаллимәр белән мөдәррисләр икәнлеген онытмагыз". "Укытучылык - иң бөек һәм изге бер хезмәт урыныдыр ки: бу юлда никадәр мәшәкать тартылса да, аларның барысы да рәхәтлеккә хисапланылса, урынлыдыр"

"Күршеләрегез белән гүзәл мөнәсәбәттә булыгыз, алар белән дус торыгыз, шатлык вә хәсрәт вакытларында хәлләрен сорагыз, хезмәтләре булса күрегез, алар өчен даими догачы булыгыз",- дип ассызыклый Р. Фәхреддин "Нәсыйхәт" китабының "Күршеләр" бүлегендә. Мондый нәсыйхәтләргә Аяз Гыйләҗевнең "Әтәч менгән читәнгә" әсәрен өйрәнү барышында тукталу отышлы.

Һ. Такташның "Мәхәббәт тәүбәсе", Г. Исхакыйның "Ул әле өйләнмәгән", Г. Кутуйның "Тапшырылмаган хатлар" әсәрләрен өйрәнгәндә "Никах вә өйләнү" бүлеге белән танышу, әңгәмә кору, өзекләр уку укучыларны мөстәкыйль тормышка әзерли. "Никах- һәр милләтнең нигезедер. Нихаклашып өйләнешү бетсә, милләт тә бетәр. Бу- бер- илаһи канундыр", "Иргә барган чагында ир булачак кешенең акчасыннан элек холкын, нәселеннән элек динен, гүзәлегеннән элек һөнәрен сорагыз вә үзегезгә тиңдәш булганнарын сайлагыз".

Бүгенге көндә татар әдәбияты дәресләрендә шәхес тәрбияләүдә, укучыларга әхлак тәрбиясе бирүдә  халык традицияләрен, гореф – гадәтләрен, татар халкының әхлакый кыйммәтләрен туплаган Р. Фәхреддин хезмәтләрен әдәби әсәрләр белән бәйләп өйрәтү бик отышлы.

Әдәбият

1.Ризаэтдин Фәхретдин. «Шәкертлек әдәбе». – Казан: “ Иман “, 2002, 3 – 5 б.

2. Ризаэддин  Фәхреддин. Җәвамигуль-кәлим шәрхе.- Казан: “Рухият” 2005

3.Ризаэддин Фәхреддин: Тормыш юлы. Иҗади мирасы: Дәреслек-хрестоматия / Төз.: Р.Ш.Шаһиев. – Казан: РИЦ “Школа”, 2005

4.Балаларга үгет- нәсыйәт. –Казан:”Дом печати”, 2001

5.Фәхреддин Р. Нәсыйхәт.- Казан:”Мәгариф”, 2004

*Исмәгыйлева Илсөяр Гамирҗан кызы,*

*Түбән Кама шәһәре инглиз телен тирәнтен өйрәнүле 33нче мәктәпнең югары категорияле татар теле һәм әдәбияты укытучысы*

**Чәчмә әсәрләргә анализ**

**(Гаяз Исхакыйның „Ул әле өйләнмәгән иде”повесте буенча )**

Әдәби әсәрне аңлау, кабул итү һәр укучының шәхси күзаллавы аша бара. Ләкин автор әйтергә теләгән фикерне, ул күтәргән проблеманы аңларга теләсәк, әдәби әсәрне анализлый белергә тиешбез.

Әдәби әсәргә анализ ясаганда киңәшләр:

1. Әсәрне иҗат иткән язучының кайсы чорда, нинди шартларда яшәгән һәм иҗат иткәнлеген исәпкә ал. Язучы иҗат иткән тарихи шартларны билгеләгәндә генә, әсәрдәге вакыйгаларга, андагы образларга, тел, стиль һәм милли үзенчәлекләргә дөрес бәя бирергә мөмкин. Монда ук әсәрнең кайсы елда язылуын күрсәт.

2. Әсәрнең нинди жанрда язылуын һәм бу жанрның үзенчәлекләрен ачыкла. Һәр жанрның үзенең анализ элементлары, аермалыклары барын да истә тот.

3. Әсәрне дөрес итеп, игътибар белән укып чык. Кычкырып уку, эчтән уку, кеше укыганны күзәтеп бару, сайлап уку, йөгерек уку һ.б. форманы сайлый аласың.

4. Эчтәлекне сөйләп чык (тулысынча, өлешчә яки сорауларга җавап рәвешендә).

5. Әсәрне өлешләргә бүл (вакыйгаларның үзгәрүеннән, образларның гамәлләреннән, язучының фикерләре үзгәрүеннән чыгып, әсәрне өлешләргә бүлү – анализның мөһим элементы).

6. Әсәрнең төзелешен, композициясен күз алдына китер. Сюжетын билгелә: төенләнешен, вакыйгалар үстерелешен, кульминацион ноктасын, чишелешен ачыкла.

7. Әсәрнең темасын билгелә. Гадәттә тема анализның башында ук ачыклана. Әсәрнең нәрсә турында булуы, нинди хәлләрне ачыклавы, нәрсәгә багышлануыннан чыгып, аның темасы билгеләнә.

8. Әсәрдәге образларны, геройларны билгелә, аларны төркемлә, төп һәм ярдәмче образларга бүл. Аларның үзара мөнәсәбәтләрен, каршылыкларын, эшләрен күрсәт. Образларны сөйләмнәренә, тышкы кыяфәтенә, тышкы һәм эчке дөньяларына, характерларына бәя бир. Геройлар яшәгән, формалашкан мохиткә игътибар ит.

9. Әсәрдә булган сурәтләүләргә: чагыштыру, каршы кую, тасвирлау, әсәр телендәге образлы сүзләр, фольклор элементларына игътибар ит һәм аларның әһәмиятен ач.

10. Әсәрнең эчтәлеген үзләштергәннән соң, язучының төп фикерен - әсәрнең идеясен билгелә.

11. Әсәрнең милли үзенчәлеген, аның халыкчанлыгын, татар һәм дөнья әдәбиятында тоткан урынын билгелә.

12. Әсәр турында үзеңнең фикереңне әйт: ул нинди тәэсир калдырды?

Һәр жанрга анализ бирүнең үзенең анализ элементлары, аермалыклары бар (лирик, драма һәм чәчмә әсәрләргә).

Чәчмә (эпик) әсәргә анализ тәртибе

1. Жанры.

2. Темасы (әсәр нәрсә турында?).

3. Идеясе (автор нәрсә әйтергә теләгән?).

4. Проблемалар.

5. Сюжет элементлары (пролог – экспозиция – төенләнеш – вакыйгалар үстерелеше – кульминация – чишелеш – эпилог).

6. Образлар системасы (төп һәм ярдәмче, актив һәм пассив, уңай һәм тискәре).

7. Портрет.

8. Интерьер.

9. Табигать күренешләре.

10. Әсәр кем исеменнән сөйләнә?

11. Әсәрнең теле.

12. Әсәрнең әһәмияте:

- эстетик кыйммәте,
- тәрбияви әһәмияте,
- әсәрнең татар әдәбиятында тоткан урыны.

Гаяз Исхакыйның “Ул әле өйләнмәгән иде “повесте мисалында чәчмә әсәргә анализ карап үтәрбез .

-Мәдәни-тарихи анализ юлы белән эшләгәндә, әдәби әсәр милли тарих, иҗтимагый хәл-вакыйгалардан аерылгысыз карала. Әдәби әсәр сурәтләнгән чор, аның чынбарлыкка туры килүе, типик образлар тудыра алуы ягыннан бәяләнә. “Ул әле өйләнмәгән иде” әсәре XX йөз башы татар тормышында очрый торган күренешне сурәтли. Повесть 1916 елда языла, 1918 елда басылып чыга. Белгәнебезчә, бу чорда патша хөкүмәтенең руслаштыру сәясәте әле бетмәгән. Г.Исхакый татар халкының киләчәге турында уйлана, руслашып юкка чыгу куркынычы зур булуын аңлата.

-Әсәрдәге төп геройлар типик. Мәсәлән, Шәмсетдин- татар яшьләренең типик вәкиле.Чыннан да XX йөз башында буржуаз революция нәтиҗәсендә күп кенә мәдрәсәләрдә шәкертләр укыту программалары белән килешмичә чуалышлар оештыралар. Аларның күбесе мәдрәсәне ташлап чыга һәм үзләренә тормышта урын эзли.Шәмси дә алар белән.

-Шәмси образында автор татар яшьләренең рус культурасына якынаюларын күрсәтә.Чыннан да XX йөз башында алдынгы фикерле кешеләр (бигрәк тә яшьләр) рус культурасына якынаялар. Шәмси белән Анна рус театрына еш йөриләр. Куелган спектакльләрнең темасы, идеясе турында бәхәсләшәләр.Бу вакытта татар театры үзенең туу чорын гына кичерә, 1нче спектакльләр 1906 нчы елда Казан, Оренбург шәһәрләрендә куела, ә рус сәхнәсендә бәхәсләшерлек, фикер алышырлык әсәрләр куела.

- Гаяз Исхакый бу әсәрендә рус кызы Аннаның олы мәхәббәтен сурәтли. Ул мәхәббәте хакына теләсә нинди корбаннарга да әзер, хәтта диненнән язарга да. Ни өчен Шәмси Аннаны һәм балаларын мөселман диненә чыгармады соң?. Бу хәлгә дә тарихи аңлатма бар. Ул чорда русларның мөселман диненә чыгуы бөтенләй күзәтелмәгән. Ә киресенчә, катнаш гаиләдә туган балалар рус милләтен арттырганнар. Патша хөкүмәтенең 3 гасыр алып барган христианлаштыру политикасы үзенең нәтиҗәләрен биргән.

Анна бәхетле була аламы ? Тарихи- мәдәни яктан аңлатканда,бу мөмкин хәл идеме?

Шәмсигә Анна белән бәхетле булырга аның алган дини тәрбиясе, традиция, йолалар төрлелеге комачаулый. Шәмси үзен мөселман кызына өйләнсә генә тулы бәхетле итеп хис итәчәк. Тик ул кыз нәкъ Анна кебек булырга тиеш. Әсәрдә Шәмси күп кенә кызлар белән танышып карый, тик Аннага охшаганын таба алмый. Тарихи яктан бу хәлгә аңлатма да бар.

Чөнки XX йөз башларында укымышлы татар кызлары бик аз булган. Мәдрәсәләрдә ир-егетләр генә укыган. -Татар кызларының тиешле белем алмаулары татар егетләренең рус кызларына өйләнүләренә китергән.

Гаяз Исхакый әсәрендә, шул чорның очрый торган типик вакыйгаларына таянып, татар халкының милләт буларак юкка чыгу куркынычы проблемасын күтәрә. Урыс менталитеты көчләп тагылган чорда катнаш гаиләдә туган балалар руслашканнар, рус теле аларның туган теленә әйләнгән.

Ә хәзер әдәби анализга күчик:

- 1.Жанры – повесть. Повесть ул – вакыйгалар, геройлар язмышы киңрәк планда бирелгән, сюжет сызыклары тармакланган хикәядән күләмлерәк эпик жанр.
- 2. Темасы - катнаш никах.
- Идеясе: милләтне милләт итеп

саклауның нигезе гаиләдә.

- Проблемасы: катнаш никах проблемасы
- 3нче слайд Сюжет Элементлары-
- Экспозиция: очрашып йөрүләре
- Төенләнеш: беренче тапкыр Анна

өенә кайту .

- Кульминацион нокта: Аннаның авырлы булуы.

Аннаның балалар белән чиркәүдән чыкканнарын күрү мизгеле. Чишелеш: әниләре марҗа булгач,

балалары да марҗа була.”Шулай

булырга тиеш, шулай булды да...”

Образлар системасы: Анна һәм Шәмси – төп бразлар.

- Әдәби әсәрне образлар бирелеше аша анализлаганда, образларның үзенчәлекле сыйфатларын күзәтәбез, образның бирелешен бәялибез, авторның аңа мөнәсәбәтен билгелибез, образга салган фикерне-идеяне күрергә тырышабыз.

“ Ул әле өйләнмәгән иде” повестенда 2 төп образ – Шәмси һәм Анна. Аларның үзара мөнәсәбәтләрен, каршылыкларын, эшләрен күрербез. Образларның сөйләмнәренә, тышкы кыяфәтенә, тышкы һәм эчке дөньяларына, характерларына бәя бирербез. Геройлар яшәгән, формалашкан мохитне дә ачыклап китәрбез.

1нче укучы - Төп образларның берсе булган Анна повестьта тулы ачылган. Ул чибәр, тырыш, бик уңган, үз хезмәте белән көн күрүче хатын-кыз. Шәмсинең беренче тапкыр Анна

тора торган фатирда булуы турындагы өзекне укып китәсем килә.” Шәмси кереп баскач та, аптырабрак китте. Озын  гына, биек кенә бүлмә, тәрәзәсендә ап-ак пәрдә. Уң якта ак кына караватка җете ак мендәрләр өелгән, ап-ак юрган белән өртелгән. Сул якта зур гына диван аксыл киемендә һаваланып тора, тәрәзә янында зур гына өстәл. Аңарга ап-ак эскәтер җәелгән.” Язучы бу өзектә ак деталеннән бик оста файдаланып, Аннаның тырыш, пөхтә, эшкә булган хатын-кыз икәнен күрсәтергә тели. Бу сыйфатларның Аннага хас булуына әсәр сюжетында бик күп дәлилләр бар.

2нче укучы- Анна алдынгы карашлы хатын-кыз. Ул әдәбият- сәнгать яңалыклары белән һәрчак танышып бара. Бик еш театрга йөри. Үзе укыган рус классиклары әсәрләренең төп фикерен Шәмсигә дә аңлата ала. Шәмси сүзләре белән әйтсәк, Анна Шәмсигә “... ике ел буенда тулы мәгънәле тормыш  бирде. Хәятка каршы күзе ачылуга, рус дөньясын танырга, рус мәдәниятен белергә хәлфә  булды”

3нче укучы. - Минемчә, Анна ярата белә. Мәхәббәтендә ул- тугры дус, идеал хатын. Ул иренең һәр теләген тоя, Шәмсигә һәр төрле ләззәтне бирергә әзер. Мәхәббәте, яраткан кешесе өчен ул барын да эшләргә әзер. Шәмсигә дәваланырга кирәк булгач, Анна хәтта эшен дә ташлый, аны дәваларга алып китә. Анна Шәмсинең татар кызына өйләнү максатын белеп яши, аның теләгенә каршы килми. Хәтта кызлар белән танышуына шартлар да тудыра. Мәсәлән, татар кичәсенә баргач, Шәмсинең кызлар белән танышырга теләвен белгәч, Анна:

“ - Әлбәттә, кирәк. Сиңа инде өйләнергә вакыт  йиткән, ләкин карап алырга кирәк. Менә мин дә карашыйм әле,- диде. Шул сүзне кыз эзли торган энесенә тутасы әйткән кебек әйтте вә театрга баргач та Шәмсидән аерылып китте.”

4нче укучы. -Анна тормышка тиз яраклаша, тормыш итә  белә. Бу  сыйфат бүгенге көн кешесенә дә бик кирәк дип уйлыйм. Ул бер төрле эштән дә курыкмый. Һәр җирдә көн итәр өчен эш таба белә. Мәсәлән, Шәмсине дәваларга алып баргач, ул хуҗа хатынны тегү эшләренә өйрәтә, кызларына  дәрес сабаклары бирә.

- Анна оста хуҗабикә һәм  югары зәвыклы хатын. Финляндиягә ял итәргә баргач, аның төрле-төрле ашлар пешерүенә, өстәлне матур итеп әзерләвенә, барысына да өлгерүенә шаккатасың. Аңа мәхәббәте көч бирәдер дигән уйга киләсең.

-Образ үзенә идея, фикер сыйдыра. Аннаны һәрьяктан камил хатын-кыз итеп сурәтләп, автор нинди фикер җиткерергә тели соң?

Шәмси әсәрнең башыннан алып ахырына кадәр үз идеалына туры килгән, ягъни һәрьяктан Аннага охшаган мөселман кызы эзли, ләкин таба алмый. Анна  образында идеал хатын-кыз образы тудырып,  Гаяз Исхакый алгы планга татар кызлары арасында алдынгы карашлы, белемле, мөстәкыйль фикер йөртә һәм тормыш алып бара ала торган кызлар әз булуын  әйтергә тели.

5нче укучы

Аннаның  бәхетле булырга хакы бар иде. Минем уйлавымча, аның бәхетсезлегендә Шәмси гаепле. Шәмси Аннаның мөселман дине кануннарын кабул итәргә әзер булуын да күрми. Балаларын чиркәүгә алып баруы да чарасызлыктан гына икәнлеген беләбез. Автор моңа дәлилләр дә китерә.  “Аннаның Шәмсигә мөнәсәбәте һаман искечә булды. Ул һаман аны кадерләде, һаман аның өчен генә яшәде. Һаман аның тормышын мул-тулы иттерергә тырышты. Ләкин аңарда да Шәмсинең китүеннәнме, югалуыннанмы курку бетмәде. Үзенең тормышының тазалыгына иманы ныгымады, һәрвакыт өмет берлән өметсезлек арасында торып, аның күңелен көчсезлек, зәгыйфьлек бер хис биләде. Аның күңелендә әллә нинди, күренми-беленми  торган куәткә  шул хәлне, шул бәхетле хәлне сакласын өчен сыгыну уе туды. Ул да Шәмси күрмәгәндә чиркәүләргә бара,чукына башлады.”

Укытучы - Шәмси образы да әсәрдә тулы ачылган. Яшьлегендә  ул мәдрәсә тәртипләре белән килешмичә, Казан мәдрәсәсен ташлап чыга һәм тормышта үзенә урын эзли. Ул төрле шәһәрләрдә була, үзенә ошаган эш эзли. Эш эзләүдә ул зур активлык күрсәтә. Шәмсинең бу сыйфаты бүгенге көн  яшьләренә дә бик кирәк дип уйлыйм.

6нчы укучы

- Минем уйлавымча, Шәмси  үзен генә ярата. Ул Аннаны да , Аннага охшаган мөселман кызын да  яратырга сәләтле түгел. Ул тормыштан тәм табарга, рәхәт күрергә генә күнеккән. Ул Аннаны   бала тапкач,  бик авыр хәлендә  ташлап  китә. “ Шәмсигә кинәттән мөһим бер эш берлән Төркстанга китәргә тугры килгәнгә, ул Аннаның терелеп йитүен дә, баланың яшәрлекме-түгелме икәнен дә белмәенчә сәфәргә чыкты.”

Әсәр төп герой- Шәмсетдиннең  икеләнүләре, уйланулары, хыяллары белән үрелгән. Ул “тагы, менә, насыйп булса, диндә иркенлек булыр да мөселман итәрмен, баермын да Истанбулга барып яздырып килермен, зурая башлагач, мөгаллимә  алып,мөселманча тәрбия иттерермен,-дип, күңелен юата килде”.  Повесть шул уйланулар белән төгәлләнә дә. Автор безгә татар җәмгыятендә Шәмсетдиннең  эчке каршылыгын җиңәрлек көч юклыгын әйтергә тели.

Бу повесть аркылы автор нинди фикер әйтергә теләгән?

-Ике милләт вәкиле корган гаиләдә бик күп каршылыклар килеп чыгарга мөмкин. Мәсәлән , бала тугач, аңа исемне татарча кушаргамы, русчамы? Чукындырыргамы, юкмы? Сөннәткә утыртыргамы, юкмы? Бала белән гаиләдә нинди телдә аралашырга? Үлем-китем була калса, аны соңгы юлга христианча озатыргамы, мөселманчамы? Бу мәсьәләләрнең берсе дә бәхәссез, шома гына чишелми: һәр як юрганны үзенә таба күбрәк тартырга тырыша. Менә шул вакытта башлана да инде гаиләдә ыгы-зыгы.

-Әсәрдә башка милли мохиткә эләгүнең татар кешесен үзеннән-үзе милли җирлектән һәм яшәү рәвешеннән аеруы һәм аның нәсел тамырлары коруга китерәчәге күрсәтелә. Автор фикеренчә, мондый гаиләләр бәхетле була алмыйлар. Г. Исхакый кеше бәхетен гаилә бәхете белән бәйләп карый. Минемчә, Шәмси гомере буе икеләнеп яшәр, Анна исә үз диненә бервакытта да хыянәт итмәс, моны ул Шәмсигә белдермәскә тырышыр. Ике арага алдау керсә, гаилә нык була алмас.

Әсәрнең бүгенге көн өчен дә актуаль булуы белән килешәсезме?

-«Ул әле өйләнмәгән иде» повесте бүгенге көндә дә актуаль. Олы фикер иясе Гаяз Исхакый бер гасыр элек үк безнең бүгенге тормышыбызны күз алдына китергән. Бүгенге көндә дә нәкъ шул әсәрдәгечә катнаш никахлы гаиләләр бик күп. Мондый гаилә балалары ике милләтнеке дә була алмыйлар, дип уйлыйм. Анна белән Шәмсинең мәхәббәтләре бик матур булса да, киләчәкләре юк. Ә Шәмсинең киләчәге бөтенләй юк, чөнки Анна балаларын үз динендә тәрбияли. Бу - Шәмсинең олы бәхетсезлеге дә, фаҗигасе дә.

Гаяз Исхакыйның бу әсәре кешеләрне уйланырга, тормыш коруга җитди карарга чакыра, ә төрле милләт вәкилләренең үзара гаилә коруга карашлары аеруча ачык булырга тиеш. Бу очракта халыкның дингә ышануларын да, гореф-гадәтләрен дә истән чыгарырга ярамый.

*Кульмухаметова Зульфия Эдуардовна,*
*Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районының «Адымнар - Түбән Кама "полилингваль белем бирү комплексы" муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесенең башлангыч сыйныф укытучысы*

**“Галиҗәнап Сүз (тел һәм әдәбият дәресләрендә, укучыларның сөйләм телен баету, сүзлек запасын арттыру, иҗади фикерләвен үстерү максатыннан, критик фикерләү технологиясеннән синквейн алымын куллану)” темасына мастер-класс эшкәртмәсе.**

Сүз – телнең төп берәмлеге. Ул аерым лексик мәгънә белдерүдән тыш, җөмләләрдә урын ала, коммуникатив берәмлек буларак, кешеләрнең бер-берсе белән аралашуын тәэмин итә.

Зурмы, кечкенәме булуына карамастан, һәркем үз телендәге сүз байлыгының күпмедер өлешен генә белә һәм файдалана. Әлеге өлеш аның шәхси сүзлек запасын тәшкил итә. Ул үз чиратында актив һәм пассив сүзлеккә бүленә.

Бүгенге мәктәп укучысы лексиконы әйләнә-тирә дөньяны, тормышны танып-белү һәм гаммәви мәгълүмат чаралары хисабына тулылана. Пассив сүзлектәге барлык сүзләр дә укучы сөйләмендә активлашып китми. Бу аралашу барышында кыенлыклар китереп чыгара. Укучының актив сүзлек запасы никадәр бай булса, аның сөйләме дә шул кадәр төгәл, аңлаешлы булачак. Аралашуга куйган максатка да андый укучы тизрәк ирешәчәк.

Узган гасыр чигендә югары сыйныф укучыларының сүзлек байлыгы 15-20 мең сүз тәшкил иткән. Бүгенге көндә исә яшүсмерләр туган тел – татар әдәби телендә күп тапкырга әзрәк сүз ярдәмендә аралашалар, туган телдә белмәгән сүзләрен рус телендә кулланалар, чит тел алынмаларын һәм сленг файдаланалар.

Шуңа күрә укучыларның ана телендә сүзлек запасын баету – ана теле һәм әдәбияты дәресләрендә мөһим бурыч. Ул ике максатка хезмәт итә:

1)сүзлек запасын сан ягыннан арттыру һәм бу лексиканы сыйфатлы камилләштерү, ягъни актив сөйләмгә кертү;

2)яңа үзләштергән һәм инде таныш булган сүзләрне дөрес файдалану күнекмәләре формалаштыру .

Әлеге максатларны лексика, фразеология буенча махсус дәресләрдән тыш, тел һәм әдәбиятның барлык темалары буенча оештырылган дәресләрдә тормышка ашырып була. Моңа ярдәм итүче эш алымнары, күнегүләр шактый. Аларны шартлы рәвештә 2 төркемгә бүләргә мөмкин:

1) Лексик күнегүләр (сүзнең мәгънәсен аңлауга юнәлдерелгән);

2) синтетитик күнегүләр. Алар ярдәмендә берничә бурыч бергә хәл ителә (телнең төрле бүлекләренең үзара бәйләнешенә нигезләнә).

Тел дәресләрендә сүзлек диктантлары язу, аңлатмалы сүзлек белән эшләү, сүзнең әйтелешен өйрәнү, сүзтезмәләр төзү, тәрҗемә итү, сүзнең синоним, антоним парларын билгеләү, кроссворд, шарада, анаграммалар, сканвордлар чишү, сүзләр рәтендәгн артык сүзне билгеләү беренче төр күнегүләргә карый.

Икенче төр күнегүләр исә катлаулырак, алар укучының берничә тема, тел һәм әдәбият фәннәре буенча булган белемнәренә нигезләнә. Мәсәлән, тексттагы фигыльләрне фразеологик тезмәләр белән алыштырып күчереп язу, төрле исемнәргә карата аңлату рәвешендәге язмалар иҗат итү,иҗади изложениеләр язу һ.б.

Икенче төр күнегүләрне креатив фикерләү технологиясеннән синквейн алымы белән тулыландыру отышлы. Ул, үз чиратында, сүз төркемнәре буенча белемнәрне камилләштерә, бәйләнешле фикерне үстерә һәм укучыларның иҗадилыгын арттыра.

Нәтиҗә ясап, шуны әйтергә кирәк: укучының сүзлек байлыгын арттыру буенча эш тукталырга тиеш түгел. Бүгенге көндә укучыларыбыз тарафыннан мәгънәләре анык булмаган сүзләрне сөйләмнәрендә аңлы активлаштыруга укытучының туктаусыз хезмәте, эзләнүләре, белем бирүнең төрле технологияләрендәге нәтиҗәле алымнарны өйрәнеп куллануы аша ирешергә мөмкин.

**Мастер-классның максаты**: тел һәм әдәбият дәресләрендә, укучыларның сөйләм телен баету, сүзлек запасын арттыру, иҗади фикерләвен үстерү максатыннан, креатив фикерләү технологиясеннән синквейн алымын куллануның өстенлекле якларын ачу. Укытучыларны әлеге алымны дөрес уздыру методикасы белән коралландыру, укучыларның сөйләм телен баету максатыннан, эш алымнарын төрләндерегә омтылыш булдыру.

Укучыларның сүзлек запасын баету- ана теле һәм әдәбияты укыту курсының мөһим бурычы.

Сүзлек запасын арттыруга ихтыяҗ төрле сәбәпләр нәтиҗәсендә барлыкка килә. Әйләнә-тирәдәге тормыш, китаплар уку, гаммәви мәгълүмат чаралары , укучыларның белемен арттыру белән бергә, аларны моңа кадәр таныш булмаган сүзләр белән дә очраштыра. Тел һәм әдәбияты укытучысының бер вазифасы – укучыларны әйләнә-тирәдәгеләр белән аралашу барышында кулланырга мөмкин һәм кирәк булган сүзлек запасы белән тәэмин итү һәм аны төрле күнегүләр ярдәмендә актив сөйләмгә кертү.

**Мастер-классның барышы**

**(мастер-класс компьютер презентациясе ярдәмендә үткәрелә)**

*Слайд №1. Укытучы турында мәгълүмат.*

Хәерле көн, хөрмәтле коллегалар! Сезне үземнең укытучы остаханәсендә күрүемә мин бик шат. Мин-Колмөхәммәтова Зөлфия Эдуард кызы, Нурлат районы “Иске Чаллы урта гомуми белем мәктәбе” МБГБУ укытучысы.

Мастер-классның темасын бергәләп ачу өчен, фокус группа – ярдәмче төркемнәр игътибарына табышмак тәкъдим итәм. Аның җавабы- Җирдәге иң көчле корал исеме. *(Табышмак презентациянең 2 нче № слайдында ачыла)*

*Слайд №2.* Күренми дә, тотылмый да. Үзе - хәнҗәр, үзе – ук. Аннан ачы, аннан татлы, Аннан хәтәр нәрсә юк. ( Ярдәмче төркемнәрнең табышмакка җаваплары тыңлана. Күтелгән җавап варианты- сүз.)

- Җавабыгыз өчен рәхмәт. Җавап кабул ителде, дөрес җавап- сүз. Чыннан да, сүз – Җирдәге иң көчле корал. Сүзнең көче гасырлар дәвамында сыналган, расланган. Әлеге көч әдипләрне иҗатка рухландырган. *(3 нче номерлы слайд ачыла.)*

Сүз әйтергә тәвәкәллек кирәк,
Сүз йөрәккә ялкын үткәрә;
Сүз киптерә, төп башына терәп,
Сүз меңнәрне яуга күтәрә.
Сүз зиһенне кайрый кайрак кебек,
Сүз сафларны ипли корычтай;
Сүз көрәшкә чыга байрак кебек,
Сүз дошманны кисә кылычтай,- дип язган Г. Афзал.

Әйдәгез, бергәләп, мастер-классыбызның темасын билгелик. Фикерләрегезне тәкъдим итегез. (фикерләр тыңлана) Фикерләрегез өчен бик зур рәхмәт, коллегалар, Сез әйткән вариантлар, һичшиксез, минем мастер-классымның темасы булырга хаклы. Мин исә аны "Галиҗәнап сүз" дип атадым. (4 *нче номерлы слайд ачыла.*)

Сүз - телнең лексик берәмлеге, аның энҗе-мәрҗәннргә тиң хәзинәсе. Сүздән башка сөйләм оешмый. Сөйләм – кешедә культуралылык чагылышы. Сөйләм- фикер көзгесе.

Бүгенге укучы үз фикерен башкаларга ана телендә җиткерүдә нинди кыенлыкларга очрый? Бу - фикер эзлексезлге күрсәткечеме, әллә укучының актив сүзлегендә сүз ярлылыгы чагылышымы? Бу сорауларга җавап табу өчен, эшче төркемнәргә ситуатив күнегү тәкъдим итәм.

*(5 нче номерлы слайд ачыла. )*

**Ми штурмы, атака:** Күз алдыгызга китерегез, сез- чит планета вәкилләре. Җиргә разведкага китәчәк кардәшегез Җир телен өйрәнергә теләми. Тел белүнең мөһим икәнен, сүзлек запасын баетуның уңай якларын күрсәткән аргументлар әзерләгез. (Җаваплар язу өчен чиста кәгазь битләре, ручкалар алдан әзерләнә.) - 1 минут вакыт бирелә.

Без дә, укучыларыбыз да бу Җиргә вакытлыча һәм билгеле бер вазифалар башкару өчен килгән. Үзебезгә йөкләнгән вазифаны башкару өчен, туган телнең мөмкинлекләрен дөрес файдаланабызмы? Фикеребезне башкаларга җиткерү өчен сүз байлыгыбыз җитәрлекме? Телне белмәү нинди куркынычларга китерергә мөмкин? Бу һәм сөйләм ярлылыгына кагылышлы башка сорауларга җавапны белер өчен, сүзне эшче төркемнәргә бирәбез. Рәхим итегез.

(Төркемнәр чыгышы тыңлана. Җаваплар чиратлашып тыңлана, кабатлауларны төшереп калдырырга кирәклеге искәртелә. Көтелгән җавап үрнәге: тел белмәсәң, ачка үләчәксең; Җирдәгеләр сөйләгәнне аңламаячаксың; миссияңне үти алмаячаксың; үз

фикерләреңне Җирдәгеләргә җиткерә алмаячаксың; тел белмәсәң, җирдә көндәлек ихтыяҗларыңны да үти алмаячаксын һ.б.)

-Җавапларыгыз өчен бик зур рәхмәт, тел белүнең өстенлекләрен бик дөрес ачтыгыз. Ә чит планета кешесен кем белән чагыштырыр идегез? (Җаваплар тыңлана, темадан читкә китү куркынычы булса, мастер-класс темасына бәйле комментарийлар бирелә.)

Чыннан да , бүгенге мәктәп укучысын алдагы күнегүдәге чит планета вәкиле белән тәңгәлләштерү нигезсез түгел. Димәк, чит планета вәкиле өчен сез язган аргументлар бүгенге көндә яртылаш виртуаль дөньяда яшәгән, татар лексикасын шартлы рус теле кыскартылмаларына, ишарәләргә алмаштырып баручы, гаиләсендә әти-әнисе, өлкән буын вәкилләре белән аралашуда кыенлыклар кичерүче мәктәп укучысы өчен дә әһәмиятле булып чыга.

Хөрмәтле катнашучылар, Сез укучыларның сүзлек байлыгыннан канәгатьме? (төркемнәрнең фикерләре тыңлана)

Әйе, чыннан да, укучыларда сүз байлыгы җитми, һәм бу - сөйләм барышында укучының кирәкле сүзне табалмый, исенә төшерә һәм әйтә алмый интегүе буларак чагылыш таба.

*(6 нчы слайд ачыла.)* Төркемнәрдә эш (бирем карточкаларга языла, һәр төркемнән берәр кеше әлеге карточканы чыгып ала). Эш өчен 1 минут вакыт бирелә.

| 1 нче төркемгә эш: | 2 нче төркемгә эш: |
|---|---|
| Укучыларда сүзлек дефицитын китереп чыгарган сәбәпләрне языгыз | Укучыларда сүз байлыгы җитмәгәнлекне күрсәтүче фактларны языгыз |

(1 минуттан соң нәтиҗәләр тыңлана.)

Көтелгән җавап үрнәге:матур әдәбият әсәрләре укымау

- ватсап , интернет аша аралашканда, сүзләр урынына смайликлар куллану

-ата-аналар белән аралашмау яки ата-аналар белән туган телдә аралашмау (укучылар русча яхшырак сөйләшә, әмма иҗади биремнәр үтәгәндә, рус теленнән дә авырлыклар кичерәләр)

-көндәлекләр алып бармау

-сүзлекләр, белешмәлекләр укымау

- укучыларның ихтыяҗларын канәгатьләндерерлек радио һәм телетапшыруларның татар телендә алып барылмавы һ.б.

(Гадәттә, 1нче төркем, сәбәпләрне язганда, укучылар эшчәнлегенә генә туктала, шуңа күрә, җавапларны тыңлаганда, мөһим сәбәпнең берсе- укытучының нәтиҗәле эш алымнары файдаланмавы икәнлеген әйтү кирәк, белем бирүнең субъект-субъект мөнәсәбәте икәнлеген

искәртү мөһим . Укытучыларның фикерләре тыңлана, кирәк дип табылса, төзәтүләр, өстәлмәләр кертелә.)

Төркемнәр чыгышына нәтиҗә ясап, укучының сүзлек байлыгын арттыру китап уку белән туры пропорциональ икәнлеген ассызыклыйсым килә. Ягъни укучы күпме күбрәк китап укыса, сөйләмдә сүзләр дә шартлы рәвештә шул кадәргә арта.

*( 7 нче слайд ачыла)* Хөрмәтле катнашучылар, ә укучылар, бигрәк тә, исем сүз төркеменнән булган нинди сүзләрне куллануда авырлык кичерә? (фикерләр тыңлана, мөмкин җаваплар: абстракт төшенчәләрне белдерүче сүзләр, гомумкешелек кыйммәтләре атамалары һ.б.)

Чыннан да, телевизор экраннарында кат-кат әйләндерелүче реклама ролигы текстларын яттан белүче укучыларыбыз гомумкешелек кыйммәтләре атамаларын куллануда авырлык кичерәләр.

Әдәбият укытучысы буларак, укучыларда гомумкешелек кыйммәтләре тәрбияләү- безнең вазифабыз. Татар теле һәм әдәбияты укытучысы буларак, без бу бурычны ничек тормышка ашыра алабыз? (залдан җаваплар кабул итү: әдәби әсәр тукымасы аша, аны уку, кабул итү, анализлау, образларга характеристика бирү, әсәрдән автор позициясен табу, әсәрне язылган чоры һәм бүгенге чор белән бәйләү һ.б.)

Намус, әдәп, сабырлык, игътибар, хөрмәт, тәртип кебек төшенчәләрнең асылын аңлау һәм аны укучылар сөйләменә кертү безнең дәресләрдә тормышка ашырыла. Укылган һәр әсәрдән без бала шәхесен формалаштыруга, аңа уңай йогынты ясарга тиешле әхлак сыйфатларын әсәр яссылыгында табып, образларга, вакыйгаларга характеристика бирү аркылы тәкъдир итәргә тиеш.

*(8 нче слайд ачыла)* Укучының билгеле төшенчә буенча алган белемен тел һәм әдәбият дәресләрендә креатив фикерләү технологиясендәге синквейн алымы аша ныгытырга мөмкин.

Синквейн – 5 юллык шигъри рифмалашмаган әдәби әсәр. Үз чиратында бу алым укучыны сүз төркемнәрен аерырга, предметка туры килүче сыйфат, фигыльләрне дөрес кулланырга ярдәм итәчәк. Ул укучыларның бәйләнешле сөйләмен һәм иҗади фикерләвен үстерә.Уздыру методикасы гади, 1-2 мәртәбә укытучы җитәкчелегендә, укытучы ярдәме белән башкарганнан соң, башлангыч сыйныф укучылары да мөстәкыйль башкарып чыга ала торган эш алымы.

Синквейн калыбын слайдта күрә аласыз.

| Юллар тәртибе | Сүзләр саны | Сүз төркеме | Сораулары яки эчтәлеге | Мисал |
|---|---|---|---|---|

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| 1 нче юл - **тема** | 1 сүз | Исем (атама, термин) | Кем? Нәрсә? | Юмартлык |
| 2 нче юл | 2 сүз | сыйфат | Нинди? Кайсы? Кайдагы? | Ихлас, соклангыч |
| 3 нче юл | 3 сүз | Фигыль | Хикәя фигыльнең төрле заман сораулары | Уйлата, шатландыра, сөйдерә |
| 4 нче юл | 4 сүз | Төрле сүз төркемнәре | Темага карата үз мөнәсәбәтеңне белдерүче фраза, җөмлә (афоризм, мәкаль, цитата) | Һәр кешедә булсын берүк |
| 5 нче юл | 1 сүз | Исем (атама, термин) | Темага (1 нче юлдагы исемгә) карата синоним сүз яки ассоциатив сүз | Игелек |

-Хөрмәтле катнашучылар, Сезгә слайдтагы үрнәк нигезендә абстракт төшенчәләргә карата синквейн иҗат итәргә кирәк булачак. Мин сүзләрнең аңлатмалы сүзлектәге мәгънәсен укыйм, игътибарлы булыгыз.

1 нче төркемгә бирем: исем, берәр нәрсә эшләр өчен алдан корылган уй, план; теләк (**ният**) (синонимнары: карар, теләк) (татар теленең аңлатмалы сүзлеге. Өч томда. 2 нче том.-К.: ТКН, 1979.-445нче бит)

2 нче төркемгә бирем: исем. 1 нче мәгънәсе: сөенү хисе, шатлык; 2 нче мәгънәсе: сөенечле, шатлыклы хәбәр (**сөенеч**) (синонимнары: куаныч, шатлык) (татар теленең аңлатмалы сүзлеге. Өч томда. 2 нче том.-К.: ТКН, 1979.- 713нче бит).

Төркемнәрдә эш өчен 1 минут вакыт бирелә.

Нәтиҗә ясап, шуны әйтергә кирәк: укучының сүзлек байлыгын арттыру буенча эш тукталырга тиеш түгел. Бүгенге көндә укучыларыбыз тарафыннан мәгънәләре анык булмаган сүзләрне сөйләмнәрендә аңлы активлаштыруга укытучының туктаусыз хезмәте, эзләнүләре, белем бирүнең төрле технологияләрендәге нәтиҗәле алымнарны өйрәнеп куллануы аша ирешергә мөмкин.

Игътибарыгыз өчен бик зур рәхмәт.

Литература:


1. Агапова Л.В. Индивидуальные задания по фразеологии. - «Русский язык в школе», 1998, №3.
2. Арсирий А.Т. Занимательные материалы по русскому языку: Кн. для учащихся. – М.: Просвещение, 1995.
3. Волина В.В. Веселая грамматика. – М.: Знание, 1995.

4. Косолапкова А.А. Работа над словом на уроках синтаксиса. - «Русский язык в школе», 1986, №1.

5. Кузнецова Н.В. Русский язык и культура речи: Учебник. – М.: ФОРУМ: ИНФРА-М, 2008.

6. Пузанкова Е.Н. Языковое развитие учащихся при обучении русскому языку.- «Русский язык в школе», 1992, №2.

*Куряева Людмила Петровна,*
*Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы 19 нчы урта мәктәбенең югары категорияле татар теле һәм әдәбияты укытучысы*

**Уку процессында креатив фикерләү үсеше технологиясе**

Хәзерге мәктәптә тормыш проблемаларын чишүнең иҗади ысулларын үзләштерүгә, үз-үзеңне тәрбияләүгә юнәлдерелгән креатив фикерләү технологиясен куллану актуаль. Педагогның роле, барыннан да элек, укучыларның мөстәкыйль танып белү эшчәнлеген оештыру призмасы аша карала. Креатив фикерләүне үстерү технологиясе-укучыларда үзара бәйләнештә һәм үзара бәйләнештәге фактларны, күренешләрне һәм процессларны анализлау сәләтен формалаштыруга юнәлтелгән стратегияләр һәм алымнар җыелмасы.Урта мәктәпнең уку процессында креатив фикерләү технологиясен куллану укучыларның мөстәкыйль эзләнү иҗат эшчәнлеген активлаштыруга, уку, фәнни һәм практик бурычларны, үз-үзеңне оештыру һәм белем бирү күнекмәләрен чишүгә юнәлтелгән интеллектуаль күнекмәләрне формалаштыруга ярдәм итәчәк. Креатив фикерләүне үстерүнең педагогик технологиясе нигезендә өч этаптан торган дәрес модуле ята.

Беренче «Чакыру»  этабы укучыларны белем бирү процессына җәлеп итүгә, өйрәнелә торган темага кызыксыну уятуга, булган белемнәрне актуальләштерүгә һәм алга таба өйрәнү юнәлешен билгеләүгә юнәлдерелгән. Бу этапта төрле хәйләләр ярдәмендә (баш мие һөҗүме, эчтәлекне фаразлау, проблемалы сораулар һ.б.) педагог укучыларга яңа теманы өйрәнергә тәкъдим итә. Укучылардан бу мәсьәлә турында белгәннәрен сөйләргә һәм алар өчен әлегә билгеле булмаган һәм белергә теләгән нәрсәләр турында уйлаулары таләп ителә. Шулай итеп, укучылар яңа материалны тикшерү өчен үз максатларын һәм мотивларын үзләре формалаштыралар. Чакыру этабында креатив фикерләү технологиясен куллану үрнәге булып мәктәптә туган телне өйрәтү практикасында «дөрес һәм дөрес булмаган раслаулар» куллану

хезмәт итә ала. Укытучы дәрес башында әле өйрәнелмәгән тема буенча берничә раслау тәкъдим итә, алар арасында укучыларга «дөрес» ен сайларга һәм җавапларын нигезләргә кирәк. Мәсәлән, «Синонимнар» темасын өйрәнгәндә, балаларга мисал өчен түбәндәге раслаулар бирелергә мөмкин: 1) Синонимнар – төрле яңгырашлы һәм язылышлы сүзләр, ләкин бер үк яки бик якын мәгънәгә ия. 2) Бер сүз төркеменнән булган сүзләр генә синоним була алалар һ.б. Мондый методик алым ярдәмендә дәрес башында ук укучылар тема буенча белгәннәрен, ә нәрсә алар өчен яңалык булганын ачык күрә алалар. Уку материалы белән танышканнан соң, укучыларга бу дәгъваларга кире кайтырга һәм дәрестә алынган мәгълүматны кулланып аларның дөреслеген бәяләргә кирәк булачак.

Икенче этап «Аңлап җиткерү» яңа мәгълүмат алу белән бәйле, аны аңларга һәм булган белемнәр белән чагыштырырга кирәк. Бу этапта укытучы җитәкчелегендә укучылар үзләре алдына куйган сорауларга җавап бирәләр, танып белү һәм үзаңлау процессын мөстәкыйль күзәтәләр. Гуманитар фәннәрне укыту практикасында нәтиҗәле алымнарның берсе - “Блум кубигы” исемле техника тора (“Атагыз...”, “Ни өчен...”, “Аңлатыгыз...”, “Тәкъдим итегез...”, “Уйлап табыгыз...”, “Бүлешегез...”). Яңа уку материалын ныгыту өчен укучыларга мондый биремнәрнең берничә вариантын тәкъдим итәргә мөмкин. Шулай итеп, мәсәлән, «Синонимнар» темасы буенча «Блум кубигының" берсен тутыру өчен “ синоним сүзләрнең иң мөһим шартын әйтегез" һ. б. дигән биремнәр булырга мөмкин.

Өченче этап «Рефлексия» алынган мәгълүматны гомумиләштерүне һәм өйрәнелә торган материалга шәхси мөнәсәбәт формалаштыруны күздә тота. Бу этап белемнәрне практик куллану, яңа идеяләрне һәм төшенчәләрне гомумиләштерү, яңа алынган белемнәрне исәпкә алып үз карашларыңны яңадан аңлату белән характерлана. Рефлексия этабында креатив фикерләү технологиясен куллануның яхшы мисалы булып уку процессында «синквейн» алымын куллану тора. Балаларга дәрестә өйрәнелгән темага биш юлдан торган шигырь язарга тәкъдим ителә.Ул билгеле бер модуль буенча төзелергә тиеш: 1 юл – бер сүз белән күрсәтелгән синквейн темасы, гадәттә исем. 2 юл-ике сыйфат яисә сыйфат фигыль белән теманың тасвирламасы. 3 юл - күрсәтелгән тема кысаларында эш тасвирламасы өч сүз, гадәттә фигыльләр. 4 юл-авторның бу темага мөнәсәбәтен чагылдырган дүрт сүздән гыйбарә. 5 юл – бер сүз, беренче юлдагы сүзгә синоним. Мәсәлән, синквейн ярдәмендә укучылар «Синонимнар» темасы буенча тикшеренү объектын белүләрен күрсәтә ала. Мәсәлән, синонимнар – ачыклаучы, бизәүче – алыштыралар, конкретлаштыралар, баеталар – сөйләмне якты, төгәл ясыйлар – байлык. Шулай итеп, синквейн мәгълүматны йомгаклау, фикерне берничә мәгънәле сүздә, сыйдырышлы һәм кыскача әйтемнәрдә белдерү сәләтен үстерә, укучыларның иҗади сәләтен үстерергә ярдәм итә.

Димәк, урта мәктәпнең уку процессында креатив фикерләү технологияләрен куллану укучыларның танып белү мәнфәгатьләрен һәм сәләтләрен формалаштыруга һәм үстерүгә, мөстәкыйль эзләнү эшчәнлеген активлаштыруга ярдәм итә.

**Кулланылган әдәбият:**


1. Галицких Е.О. Диалог в образовании как способ становления толерантности. М.: Академический проект, 2004. 240стр.

2. Сорина Г.В. Креативное мышление: история и современный статус // Вестник Московского университета. Серия 7. Философия. №6, 2003. Стр. 97-110.

3.



*Минегалиева Ләйсән Ризат кызы, Аглиуллина Фәйрүзә Фазыл кызы, Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы Муса Җәлил исемендәге “1 нче гимназия” муниципаль бюджет белем бирү учреждениесенең башлангыч сыйныф укытучылары*


## **Укыту процессында яңа педагогик технологияләр куллану**.

Бүгенге җиһан катлаулы, тиз үзгәрүчән. Шуның белән бәйле рәвештә мәгарифнең дә яңа шартларда яшәргә сәләтле кеше тәрбияләүдәге җаваплылыгы арта бара. Социаль-тарихи һәм мәдәни процессның шундый субъекты булып һәрьяктан камил, рухи яктан үскән шәхес тора. Ул шул мохиттә яшәргә сәләтле булу белән бергә анда актив эшләү күнекмәләренә дә ия булырга тиеш. Хәзерге шартларда «мәгариф» дигән төшенчә үзе дә үзгәрә башлады. Ул элегрәк мәктәптә укыту процессы белән генә тиңләштерелсә, хәзер киңрәк мәгънә ала бара. Хәзер безнең илдә дөнья мәгариф тирәлегенә керүгә юнәлтелгән яңа мәгариф системасы урнаша бара. Бу эш педагогик фәнгә һәм укыту-тәрбия процессына сизелерлек үзгәрешләр кертә.

Яңа педагогик технологияләрне куллануның төп максаты - белемле, тәрбияле, тормышта үз юлын табарга әзерлекле, яхшыны яманнан аера, тиешле карар кабул итә белгән шәхес тәрбияләү.  Моңа мәгълүмати технологияләр дә нык тәэсир итә. Бүгенге мәгълүмати технологияләргә нигезләнгән мәгарифнең нәтиҗәлелеге файдаланыла торган технологияләрнең төренә генә түгел, ә бәлки педагогик эшнең сыйфатына да бәйле. Технологик инновацияләр педагогик метод һәм алымнар эчтәлегенең баюына китерә, шуның белән бергә алар педагогика үсешенә тулаем тәэсир итә.

Укыту процессында яңа педагогик технологияләрне куллану яңа метод һәм алымнарны үстерүгә, нәтиҗәдә, укытучыларга, эш стилен үзгәртеп, яңача эшләргә, педагогик системада структур үзгәртеп коруларны гамәлгә ашырырга ярдәм итә. Бу исә педагогик процессны оештыруга һәм аның белән идарә итүгә үзенчәлекле бурычлар куя. Инновацион технологияләр белән укыту -уку процессын яңача оештыру дигән сүз. Аның мөһим мәсьәләләре булып өйрәнелә торган фәнгә кызыксыну уяту, танып-белү активлыгын үстерү, аралашу процессында үзара аңлашу һәм ярдәмләшү мохите тудыру, укучыларның иҗади сәләтләрен ачыклау һәм үстерү тора.

Заман уку-укыту эшчәнлегенең барлык тармагына да үзгәрешләр кертә, безгә, укытучыларга да, яңа таләпләр куя. Сыйфатлы белем бирү өчен, мәгариф өлкәсендә модернизацияләү кирәклеген аңлап, без дә дәресләребездә инновацион технологияләр кулланып эшләргә тиеш. Нәрсә соң ул инновация? Инновация- латин сүзе. Безнең телгә тәрҗемә итсәк,"яңарту,яңалык,үзгәртү" дигәнне аңлата. Педагогик инновация- ул укучыны укыту һәм тәрбияләү эшен яхшыртуга юнәлдерелгән үзгәрешләр. Бүгенге педагогик инновациянең төп бурычы- педагогка кирәкле яңалыкларны туплау-җыйнау,өйрәнү һәм классификацияләү. Белем бирүнең нәтиҗәлелеген күтәрү укыту процессының яңа, тагын да нәтиҗәлерәк технологиясен эзләүне таләп итә. Технология инновацион процессларда тулысынча яңартыла. Ул исә укыту процессы субъектларын-укытучының да, укучының да тирәнтен әзерлекле булуын таләп итә. Бу хәзерге заман дәресен оештыру өчен зарури. Шуны да истә тотарга кирәк: укытуның традицион системасында булган иң яхшы алым, методларны куллана, үстерә барып эшләгәндә генә, инновацион технология яхшы нәтиҗәгә ирешүгә ярдәм итә ала. Хәзерге заман дәресе проблемалы ситуацияләрдән, мәгълүмати технологияләрдән башка үстерешле була алмый.

Тәрбияле, белемле, бар яктан булган шәхес, ягъни көндәшлеккә сәләтле укучы тәрбияләү өчен заман белән бергә атлау, укучыларны кызыксындырырлык яңа технологияләр кулланып эшләү мөһим. Бүгенге мәктәп шартларында педагогларның шәхескә бик сак якын килә белү сәләтенә, тирә-юнь белән аралашканда балаларга фәнни- нигезле тәэсир итүне булдыруга юнәлтелгән педагогик технологияләргә ия булуы зарури. Инновацион технологияләрнең нигезен тәшкил итә торган эшлекле һәм рольле, имитацион уеннар укучыларның оештыру сәләтен, икътисади фикерләү дәрәҗәсен экологик культурасын үстерергә ярдәм итә. Төрле дидактик шоу рәвешендә уздырыла торган уеннар да кызыксыну уята. Алар мөстәкыйль эзләнү эше нәтиҗәсе, талантлы , сәләтле балаларны иҗади эзләү чарасы да булып тора.

*Мифтахова Эльмира Флур кызы,*
*Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районның “14нче лицей” муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесенең югары категорияле татар теле һәм әдәбияты укытучысы*

**Әдәби әсәрләр өйрәнүнең нәтиҗәле алымнары**

Хәерле көн, исәнмесез хөрмәтле кунаклар! Сез текст белән эшләгәндә авырлыклар кичерәсезме? Нинди авырлыкларга очрыйсыз?
*Җаваплар: (тәрҗемәдә, аңлашылмаган сүзләр очрый, анализ ясаганда).*
Бүгенге мастер-классымда сезне әдәби әсәр өйрәнүнең нәтиҗәле алымнары белән таныштырасым килә.
Мастер классны уңышлы үткәрер өчен өч төркемгә бүленеп утырырбыз.
**I.** Ә хәзер сезнең алдагы тартмаларны ачып карап андагы күргән рәсемнәрне, әйберләрне бер сүз белән әйтеп карыйк әле *(өч төркемгә өч тартма бирелә, уртак сүз – **туган көн** сүзе килеп чыгарга тиеш)*.
Бу бәйрәм нинди уй кичерешләр белән бәйле? (*сөенеч, шатлык, бәхет...*)
-Кунакларны ничек каршы аласыз? Бүләк биргәч ничек сөенәсез? Дустыгыз килмәсә ничек борчыласыз? Шушы ситуацияләрне уйнап күрсәтергә кирәк (*һәр төркемгә бер ситуация бирелә*).
**II.** Димәк, без бүген туган көн турында сөйләшербез. Резеда Вәлиеваның “Туган көндә” әсәре аша нәтиҗәле алымнар белән танышырбыз.
1 нче өстәл, сез текстны 3 өлешкә бүләсез һәм кисәсез: башлам, төп өлеш һәм бетем. Бу **өлешләргә бүлү алымы** өстендә эш.
2 нче өстәл һәр абзацка исем бирәсез. Бу **исем бирү алымы**.
3 нче өстәлгә бирем: тексттагы һәр абзацтан 1 яки 2 шәр ачкыч сүз табып астына сызыгыз. Бу **ачкыч сүзләр алымы**.
*1 минут вакыт.*
**Аудитория белән эш (*төркемнәр текст өстендә эшләгәндә аудитория белән серле тартмалардагы рәсемнәр буенча эш башкарыла*).**
Коллегалар, сез төркемнәр чыгарган нәтиҗә белән килешәсезме? Серле тартмадагы рәсемнәрне, әйберләрне сез нинди сүз белән берләштерер идегез? Фикерләрегез өчен рәхмәт. Без сезнең белән образлар өстендә эшләдек. Әлеге алым “Фаразлау” дип атала. Ә “Туган

көндә” хикәясе нәрсә турында дип уйлыйсыз? (*фикерләр тыңлана: бәйрәм, кунаклар, бүләк бирү*)

Безнең уйларыбыз туры килерме, әсәр нәрсә турында булыр? Бу сорауга төгәл җавапны төркемнәрне тыңлагач бирербез.

*Вакыт чыкты.*

Хәзер сүзне төркемнәргә бирик. Әйтегезче, бирелгән эшләрне текстны укымыйча башкарырга мөмкин идеме? Бу алымнар укучыларда әсәрне укып чыгуга этәргеч бирә, аларда кызыксыну уята.

Беренче алым – “Өлешләр” дип аталды. Ничек уйлыйсыз, ни өчен кирәк бу алым? Җаваплар тыңлана: *(Бала конкрет фикерли: әсәрнең башын, төп өлешен һәм бетемен билгели).*

Икенче алым – “Исем кушу” дип атала. Ул ни рәвешле ярдәм итә? Җаваплар тыңлана: *(һәр абзацка исем бирү план рәвешендә килеп чыга һәм балага эчтәлекне аңларга ярдәм итә)*

Өченчесе – “Ачкыч сүзләр” дип атала.

Алымнарның кайсысы эчтәлекне тирәнрәк аңларга ярдәм итә? *(ачкыч сүзләр, исем кушу)*

**III.** Акка кара белән язылган текст. Баланың аны төсле итеп күрәсе килә. Бу очракта нәрсә эшли алабыз?

Иллюстрацияләр белән эш башкара алабыз.

1 өстәл – сөлешләргә рәсемнәр сайлыйсыз.

2 өстәл - геройларның эчке кичереш-эмоцияләрен төсләр белән билгелибез. Төсләр арасыннан, әсәргә туры килгәннәрен сайлап алыгыз.

3 өстәл - ассоциатив образлар белән эшлисез. Тапкан ачкыч сүзләргә табигатьтән ассоциацияләр сайлыйбыз – **образ сурәтләү алымы**.

**Аудитория белән эш (*төркемнәр текст өстендә эшләгәндә аудитория белән серле тартмалар белән эш башкарыла*).**

<u>*Тартмаларда: мәтрүшкә, әрем, ипи.*</u>

Ассоциатив образлар белән эшләүнең төрле юллары бар. Өченче төркем образ-сурәтләр алымы белән эшли.

Ә мин сезгә әлеге алымның тагын бер төрен тәкъдим итәм. Бирелгән тартмаларны ачып иснәп карагыз әле. Әлеге исләр сезгә нәрсәне хәтерләтә, әлеге исләр белән бәйле нинди әсәрләрне атый аласыз. Бу **тоемлау-сиземләү алымы** дип атала.

*Төркемнәр җавап бирә. Рәсемнәр эленә.*

Сыйныфта төрле балалар утыра. Белем дәрәҗәләре уртача, югары булган балалар бар. Иҗади фикер йөртүче балаларга биремнәрнең кайсы төрен тәкъдим итәр идегез?

*Көтелгән җавап: Өченче өстәлнекен.*

**IV.** Әсәрнең идеясын аңлауда, балаларның герой хис-кичерешләрен үзләре аша үткәрүләре дә ярдәм итә. Мин сезгә хәзер әсәрне өлешләргә бүлеп уйнап карарга тәкъдим итәм. Киемнәрне сайлагыз.

**Уйнап карау.** *Һәр өстәлдән берәр герой.*

Әсәрдә автор әйтергә теләгән фикерне әйтеп карыйк әле. Әсәрдә 3 герой, 3 буын вәкиле, бер гаилә әгъзалары. Сез - әби, сез-әни, ә сез – кыз. Укучыларга, залда утыручыларга нинди киңәш-фикерләр әйтер идегез?

Без әле генә ике алым кулландык. **“Җанлы театр”** һәм **“Фикеремә колак сал”**. Белем дәрәҗәләре югары булган балалар әзерлексез дә уйнап күрсәтергә мөмкин, башкаларга әзерлек өчен вакыт бирелә.

**Рефлексия.** “3-2-1” алымы.

Коллегалар, кулыгызга 3 таш алыгыз. Сез, нинди 3 алымны дәресегездә кулланыр идегез?

Ә хәзер ике таш алыгыз. Мастер-класс вакытында нинди хис-тойгы, эмоцияләр кичердегез? Икесен атагыз.

1 таш алыгыз. Мастер-классымны бер сүз белән бәяләгез.

Ташларны ваза-аквариумнарга салыгыз. Нәрсә булды? (*Су артты).*

Нәкъ әнә шулай мин дә сезнең тәҗрибәгезне баета алган булсам, максатыма ирештем дигән сүз. Бик зур рәхмәт!

*Мөбарәкшина Рузилә Рәшит кызы, Татарстан Республикасы*
*Түбән Кама муниципаль районының*
*«32 нче гимназия»*
*муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесенең беренче категорияле туган тел һәм әдәбияты укытучысы*

## Туган тел дәресләрендә укучыларда дәрескә уңай мотивация формалаштыру алымнары

- Исәнмесез! Хәерле иртә! Без бер-беребез белән күрешкәндә исәнләшәбез. Без дә хәзер сезнең белән “Исәнләшү” уенын уйнап алырбыз.

**1. Игра “Исәнләшү”.** Для этого надо встать в круг парами друг против друга. Здороваемся за руки, начиная с правой руки, чередуя правую и левую руку. При этом должны говорить

“Сәлам” и “Исәнме” называя имена. Когда дойдем до своей пары, кружимся. Это также элемент татарского танца.

Начали под музыку.

- Рәхмәт. Утырыгыз. Сез бүген бик матур! Әйдәгез бер-беребезгә комплиментлар әйтик әле. Иңбаш партнерларга комплиментлар әйтегез.

**2. Комлименты.**

**3. Сценка. (2 укучы берсе әни, икенчесе малай. Әнисе улын ачулана)**

- Әни нишли?

- Малаен ачулана.

- Ни өчен ачулана? Әни кеше баласын кайчан ачулана?

- Тыңламаса, берәр ярамаган эш эшләсә.

- Ә инди ярамаган эшләр бар?

- Сүз тыңламау, каршы әйтү, “ике”ле алу һ.б.

- Ә хәзер әйдәгез мультфильм карыйбыз. Биредә малай нинди ярамаган эш эшләгән?

**4. “Су анасы” мультфильм карау.**

- Сез ничек уйлыйсыз малай яхшымы, начармы?

- Ә хәзер **әкияткә анализ** ясыйбыз. Моның өчен безгә эшләпәләр ярдәмгә килер.
  Урыннардан торабыз. Үзегезгә ошаган эшләпәне сайлагыз.
  1. Ак эшләпә. Әкияттән фактларны табыгыз.
  2. Сары эшләпә. Тексттан бары тик уңай якларны гына санап чыгыгыз.
  3. Кара эшләпә. Вакыйгаларның тискәре яклары турында  гына сөйләгез.
  4. Кызыл эшләпә. Хикәяне укыгач нинди хисләр туа?
  5. Яшел эшләпә. Әкиятне кайда кулланырга мөмкин?
  6. Зәңгәр эшләпә. Текст буенча гомуми нәтиҗәләр чыгарыгыз.

- Дәресебезгә йомгак ясап, шуны әйтергә була: Кеше әйберен алу начар гадәт. Гадел булырга, начар гадәтләрне булдырмаска, кеше әйберенә тимәскә кирәк.
- Игътибарыгыз өчен рәхмәт! Сау булыгыз!

*Муратова Лариса Миншаех кызы,*
*Шаймухаметова Фәнзилә Мирзанур кызы,*
*Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районының Бакый Урманче исемендәге “2 нче гимназия” муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесенең югары категорияле укытучылары*

**Туган як тарихын өйрәнүдә яңа алымнар.**

Хәзерге заман җәмгыятенең нигезен һәрьяктан һәм гармоник үсешкә ирешкән, тирәнтен фикерли ала торган һәм иҗади сәләткә ия булган шәхес тәшкил итәргә тиеш. Хәзерге шартларда укучыларның үзләренең социаль мөмкинлекләрен гамәлгә ашыру, тормышта үз урыннарын табу, үз-үзләрен камилләштерү мәсьәләләре бик кискен куела. Шуңа күрә заман укытучыдан иҗади эшли белүне таләп итә. Педагогик эшчәнлектә иҗадилек – бу, беренче чиратта, яңалыкка, үзгәрүчәнлеккә омтылу.

Бүген укытучы, иҗади шәхес буларак, күп укырга, әдәбият һәм сәнгать өлкәсендәге яңалыклар белән таныш булырга; укучылар алдында гына түгел, хезмәттәшләре арасында да хөрмәт һәм дан казанырга, эчке һәм тышкы күркәм сыйфатларга ия булырга, сәламәт яшәү рәвеше кагыйдәләрен үтәргә, компьютер һәм видеотехника белән эшли белергә тиеш.

Соңгы елларда белем бирүнең нәтиҗәле, укучыларның танып – белү эшчәнлеген активлаштыра торган алымнар кулланыла башлады. Күп кенә педагоглар белем бирүгә укытучы һәм укучының максатка юнәлешле хезмәттәшлеге буларак якын килә; алар үзләренең һөнәри осталыкларын арттырырга; шәхси лабораторияләрен төрле кызыклы табышлар белән тулыландырырга омтыла. Бу – укытучының даими рәвештә теоретик белемнәрне үзләштерүе; фәнни – методик, белешмә һәм башка әдәбиятны, башка укытучыларның эш тәҗрибәсен җентекләп өйрәнүе нәтиҗәсе.

Тарих һәм иҗтимагый фәннәрне укытуда яңа педагогик технологияләр куллану өчен зур мөмкинлекләр бар. Иҗади эшләүче укытучылар тарихи мәгълүматлардан укучыларга белем һәм тәрбия бирү, аларның шәхесен үстерү максатында файдаланалар. Мөгаллимнең осталыгы укучыларның эшчәнлеген алдан күреп планлаштыруда; балаларның белем өстәүгә кызыксынуларын исәпкә ала белүдә; эшнең соңгы нәтиҗәләрен күзаллауда күренә. Укытучы тарихны өйрәтү барышында укучыларда гаҗәпләнү һәм кызыксыну, ризасызлык һәм теләктәшлек, шатлык һәм көенеч, мәхәббәт һәм нәфрәт, ниһаять, ихтирам һәм соклану кебек сыйфатларны уята ала икән, димәк, ул иҗади эшли.

Укытучыларга хәзер эш методларын, ысул, форма һәм чараларын сайлап алуда тулы ирек бирелде. Тарих фәнен укытканда белем бирүнең актив методларыннан файдалану хәзер әһәмиятле бурычларның берсе булып тора.

Педагогика фәнендә укыту – тәрбия эшенә яңалык кертүнең методик һәм технологик яклары аерып карала. Аерма исә мондый: традицион методика укытучы өчен алгоритмнар тәгъдим итә; ә технология укытучының да, укучының да иҗади эшләвенә йөз тота. ЮНЕСКО мәгълүматлары буенча, хәзерге вакытта дөньяда педагогик технологияләрнең дүрт тибы бар:

- аралашуга нигезләнгән коммуникатив – үстерешле укыту;
- белемнәрне үзләштерү технологиясе;
- укыту – тәрбия процессын тоташ  компьютер системасыннан файдаланып оештыру;
- хәзерге заман телевизион аралашу мөмкинлекләреннән файдалану.

Укучыларның иҗади һәм фикерләү сәләтен, мөстәкыйльлеген үстерү – төп методик максатларның берсе булып тора. Укучыларның иҗат мөмкинлекләрен ачыклау өчен, дәресләрне дәрес-әңгәмә, дәрес-проект, дәрес-семинарлар итеп уздырырга мөмкин. Аларның һәрберсендә балалар бер – берсе һәм укытучы белән фикерләшә, аралаша. Бала психологиясен, ярыш принцибын истә тотып, төрле алымнар куллану дәреснең нәтиҗәлелеген арттыра, укыту процессын кызыклы итә, активлаштыра, укучыларның сәләтен үстерергә ярдәм итә.

Яңа педагогик технологияләрнең бер өлеше – тестлар һәм логик биремнәр. Алардан яңа материалны өйрәнгәндә, гомумиләштерү, йомгаклау дәресләрендә, катнаш дәресләрдә файдаланып, укытучы укучыларның иҗади сәләтләрен үстерә.

**Тестларның төрләре:**

- тәгъдим ителгән җаваплардан дөресен сайлап алу;
- тарихи вакыйгаларның эзлеклелеген билгеләү;
- тарихи терминның теге яки бу чорга, илгә туры килү-килмәвен ачыклау;
- логик чылбырлар;
- тарихи шәхесләрнең исемнәрен тарихи мәгълүматлар, фактлар белән тәңгәлләштерү;
- тест-схемалар;
- күп librnokталар урынына төшереп калдырылган сүзләрне кую.

**Биремнәрнең төрләре:**

- хронологик таблицалар төзү;
- ике яки аннан күбрәк тарихи вакыйгаларны чагыштыру;
- теге яки бу тарихи документка бәя бирү;
- тарихи вакыйганың үзенчәлекләрен әдәбияттан, газетадан алынган цитата ярдәмендә билгеләү;

- контурлы карталар белән эшләү;

- тарихи параллельләр үткәрү.

Иҗади эшләүче укытучыларга мондый эш алымнарының күбесе таныш; тарихны укытканда, аларны дөрес чиратлаштырып кулланырга кирәк. Һәр яңалык уңай нәтиҗә бирсә генә, үзен аклый.

Шулай ук тарих дәресләрендә интерактив методларны куллану да бик файдалы. “Интерактив” сүзе безгә инглиз теленнән кергән, ул бергәләп хәрәкәт итү дигәнне аңлата. Интерактив методы үзара ярдәмләшеп эшләү сәләтен яки берәр нәрсә яисә кем белән әңгәмә уздырган чакны аңлата. Интерактив укыту – ул, барыннан да элек, үзара ярдәмләшү белән үрелеп барган әңгәмә рәвешендәге укыту. Интерактив укыту барышында түбәндәге бурычлар хәл ителә:

- укучыларның коммуникатив сәләтен һәм күнекмәләрен үстерү, үзара дустанә мөнәсәбәт урнаштыру;

- команда составында эшли белергә, башкалар фикеренә колак салырга өйрәтү;

- рухи киеренкелекне юкка чыгару, дикъкатьлелекне арттыру, эш төрен ешрак алыштыру мөмкинлеге бирү.

5 – 9 нчы сыйныфларда уен катнашында узган һәм төркемләп эшләү технологияләрен безнең шартлар өчен яраклы дип саныйм. Дәресләрдә куллану өчен түбәндәге алымнар аеруча нәтиҗәле санала:

**1. “Бары берәр җөмлә” уены.** Һәр укучы бирелгән темага кагылышлы бер җөмлә әйтә. Бу исә аларның белемен тиз генә актуальләштерү мөмкинлеге бирә.

**2. “Чиста такта” уены.** Яңа теманы аңлатыр алдыннан класс тактасына сораулар, терминнар, даталар язып куела. Теманы аңлатканнан соң, укучылар ул сорауларга җавап табарга тиеш. Дөрес җавап бирелгән сораулар тактадан сөртелә бара. Укучыларның бурычы дәрес ахырына кадәр класс тактасын чиста калдырудан гыйбарәт. Әлеге уен укучыларның игътибарын яңа дәрес материалына юнәлтә.

**3. “Картинага җан керт” уены.** Укучылар картина буенча вакыйгада катнашучылар исеменнән сөйли. Бу исә аларның сөйләм телен, тарихи киңлектә һәм вакыт аралыгында ориентлашу осталыгын үстерә. Әлеге уенны дәрес материалын ныгыту этабында, кабатлау дәресләрендә куллану отышлы.

**4. Кыска чыгыш (спич).** Аерым бер текстны яки ишеткән бер хәбәрне тикшергәннән соң, укучылар 2-3 минут эчендә, әлеге темага багышлап кыска чыгыш әзерли. Бу алым яңа хәбәрне үз сүзләрең белән җиткерә белү, үз фикереңне әйтү мөмкинлеге бирә.

**4. “Синквейн” методы** (французчадан тәрҗемәсе “биш юллык шигырь”дигәнне аңлата).

1 нче юл – исемнән торган бер сүз, тема аталышы;

2 нче юл – теманы ике сыйфат белән тасвирлау;

3 нче юл – вакыйганы өч фигыль яки хәл белән сүрәтләп бирү;

4 нче юл – темага, беренче юлдагы сүзгә карата булган мөнәсәбәтеңне, хис-тойгыңны күрсәтүче канатлы әйтем;

5 нче юл – беренче юлдагы сүзнең төп асылын чагылдырган исем, беренче юлдагы сүзнең “синонимы”. Мәсәлән: **Сөембикә.**

**Акыллы, тугрылыклы.**

**Яраткан, ышанган, алданган.**

**Җәберләнсә дә, горур булып кала белгән!**

**Ханбикә.**

Шуай итеп, интерактив укыту - күптөрле методик алымнардан һәм уеннарны файдалану мөмкинлеге бирә торган диалог рәвешендәге метод. Ул укучыларның иҗади сәләтен үстерергә ярдәм итә, чөнки иҗади эшчәнлек үзләштерелә торган темага катнашы булганлыгын күрсәтә; балаларда тарих дәресләренә карата уңай мөнәсәбәт тәрбияли; укучылар төрле ситуациядә алган белемнәрен файдалана ала; аларны үз фикерләре белән уртаклашырга һәм үз уй-хисләрен сүз белән (язмача яки телдән) белдерергә өйрәтә.

Укучы уку эшчәнлегендә үзе актив катнашса гына ныклы белем һәм күнекмәләр формалаша. Укучыларның эшчәнлеген оештыруда дәресләрдә түбәндәге алымнарны куллануны әһәмиятле дип саныйм.

**Хәтерләү сәләтен үстерү.** Бу алым дәреснең актуальләштерү этабында яки яңа материалны аңлату алдыннан кулланыла. Ул укучыларда хәтер, игътибарны үстерү, материалны терәк сигнал формасында истә калдыру максатына хезмәт итә. Тема өчен әһәмиятле булган 10 – 15 сүз сайлап алына. Укучыларга игътибарны тупларга кушыла. Сайланган сүзләр әйтелә, укучылар хәтердә калдырган сүзләрне дәфтәрләренә яза. Аларны алдан тактага язып, каплап куярга да мөмкин. Ул күз йөртеп чыгарлык вакыт аралыгында гына күрсәтеп алына. Аннары укучыларның ничә сүзне дөрес язганлыгы тикшерелә. 10 сүздән 8-9 ы дөрес булса- баланың хәтерләү сәләте әйбәт; биштән азрак булса – начар. Начар хәтерлеләргә, әйтик, мондый киңәш бирелә: йокларга яткач, бүген көне буе күргәннәреңне исеңә төшер яки дәрестә үтелгән теманы кабатлап чык – хәтерең яхшырыр. Сүзләр терәк сигнал формасында үтелгән материалның төп эчтәлеген чагылдыра, укытучы, шуларга нигезләнеп, яңа материалны аңлата.

**Сәләтлеләр конкурсы.** 1 укучы алга чыгарыла. Башкалары аңа үтелгән темалар буенча сораулар бирә, ул очколар туплый. Ринг, мәсәлән, укучы файдасына 7 : 3 (10 сорау) яки 4 : 1 исәбенә тәмамланырга мөмкин. Дәрес саен шулай иң зирәк укучылар ачыклана бара. Бу алым

сәләтлеләрне ачыкларга, аларда кыюлык, тапкырлык, уйлап табучанлык сыйфатлары, аралашу культурасы тәрбияләргә ярдәм итә.

**Карта буенча сәяхәт итү.** 2 укучы тактадагы картадан, башкалар атласларында укытучы әйткән обьектларны таба, алар турында сөйли.

**Кроссвордлар чишү** – һәркемнең яраткан шөгыле, шул ук вакытта тарихи терминнарны ныгыту эше булып тора. 10 – 15 сүздән торган гади генә кроссвордларны һәр укучы төзеп килә ала. Укучылар аларны үзара алмашып, кызыксынып, ярыша – ярыша чишәләр.

**Акыл тизлеген тикшерү.** Тактада, кайбер хәрефләре төшереп калдырылган сүзләр язылган. Укучылар сүзләрне табалар . Терминнарны ачыклаучы өстәмә сораулар да бирелергә мөмкин. Бу эшкә классның үсеш дәрәҗәсенә карап, 5 минут чамасы вакыт бирелә, җиңүчеләр ачыклана.

**Укучыларга иҗади эшләү** өчен темалар тәкъдим ителә. Алар, китапханәдә һәм интернетта эзләнеп, реферат яза, эшләр бәяләнә, яхшы эшләр укучылар конференциясендә дә чыгыш ясау өчен тәкъдим ителә.

Уку материалы яхшы үзләштерелсен өчен дәресләрдә шулай ук **чагыштыру алымын** файдалану да әһәмиятле. Ул балаларның логик фикерләвен үстерә, төрле вакыйгаларны анализлый белергә өйрәтә. Күренешләрнең, вакыйгаларның, күренекле тарихи шәхесләрнең охшаш һәм аермалы якларын күрсәткәндә, аларны тасвирлаганда бу алым бик кулай

Укучыларга төпле белем бирү максатында дәресләрдә **төркемләп эшләү алымын** куллануны отышлы дип саныйм. Әлеге алым укучыларда бердәмлек, оешканлык, бер-береңә ярдәм итү, коллективизм кебек күркәм сыйфатлар тәрбияләргә ярдәм итә. Бу очракта класстагы укучылар 3 яки 4 төркемгә бүленә. Аларның һәркайсына, көчле укучылар белән беррәттән, тарихны уртача дәрәҗәдә һәм йомшаграк үзләштерүче балалар да керә. Һәр төркемдәге иң яхшы укучы консультант итеп билгеләнә, һәм ул иптәшләренең белемен бәяләүдә укытучыга ярдәм итә. Укучыларның иҗади эшчәнлеген, логик фикерләү сәләтен үстерү максатыннан чыгып, балаларга шәхси якын килеп, биремнәр тәгъдим ителә.

Стандарт булмаган мондый алымнарны алга таба да дәвам итеп булыр иде. Әйтеп кителгән бу алымнар укучыларның иҗади эшчәнлеген, танып-белү активлыгын арттыра, хәтердә саклау, фикерләү сәләтен үстерә.

Һәр укучы – шәхес. Һәр укучы чынбарлыкны үзенчә күрә, дөньяны танып белергә омтыла. Укытучы һәм укучының үзара хезмәттәшлеге нәтиҗәсендә генә дәреслектәге мәгълүмат – белемгә, ә белем күнекмәгә әйләнә.

*Насыйрова Миләүшә Сәлмән кызы,*
*Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районның “14нче лицей” муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесенең югары категорияле татар теле һәм әдәбияты укытучысы*

**Эзлим, табам, ачам**
**(Эвристик технология аша иҗади шәхес тәрбияләү)**

Исәнмесез, хәерле көн, хезмәттәшләрем! Мин 14 нче лицейның татар теле һәм әдәбияты укытучысы Насыйрова Миләүшә Сәлмән кызы. Минем методик темам “Туган тел һәм әдәбияты дәресләрендә универсаль уку гамәлләре формалаштыру, укучыларның иҗади һәм мөстәкыйль фикерләү сәләтләрен үстерү” .

27 ел дәверендә нинди генә методик тема өстендә эшләмәдек. Һәр методик теманы тормышка ашырыр өчен нинди генә технология кулланмадык.

Тартмага күз салсак, нәрсәләр бар икән?

Җыелганнар ди бер тартмада укыту технологияләре.

- Мин иң заманча технология, миннән башка дәресләр күңелсез була, балаларның укырга теләге булмый, - дип **интерактив технология** сүз башлады.
- Ә минем ярдәм белән укытучыларга җиңелрәк, вакытны дөрес бүләбез, һәр эшнең үз кысалыгы бар, - дип җавап кайтарды **Сингапур технологиясе**.
- Ой, вакыт бүләләр алар, менә минем белән ничек күңелле?! Музыка, көлү, бер урында утырырга кирәк тә түгел, - кызып сөйләде **Уен технологиясе**.
- Музыка белән ерак китәрсең. Минем белән укучылар алган белемнәрен калыпка салып, туплап барабыз. Файдам күп шул минем, - диде масаебрак **Рәхим технологиясе**.
- Ә миннән башка укучыларның фикерләү сәләте бик акрын артыр иде. Башка сыймаслык нинди фикерләр тудыра алам мин, - дип сөйләнде **Яхин технологиясе**.
- Шулай шул, уйлап карасаң ничә гасыр үткән кебек, ләкин мин һәрвакыт яңалыкка тартылам. Шунлыктан, мине онытмыйлар, - дип сөйләде **Эвристик технология**.

Эвристик укыту технологиясе “бертуктаусыз яңалык ачу” дигәнне аңлата. Грекчадан “эзлим”, “табам”, “ачам” мәгънәсендә. Тарихына күз салсак, бу технология Сократ, Руссо, Л.Н.Толстой, Махмутов хезмәтләрендә чагылыш таба. Бу технология укучыларның мөстәкыйльлеген үстерүгә, хакыйкать ачуга үз фикерләре һәм тикшеренүләре белән белем алуга ярдәм итә.

Сезне үземнең мастер классыма чакырам. Рәхим итегез!

Исәнмесез куллар белән,

Исәнмесез күзләр белән,

Исәнмесез авыз белән,

Шулай иткәч күңеллерәк.

- Эшне башлаганчы, ике төркемгә бүленәбез. Моның өчен мин ике лидер билгеләдем. Ә алар үзләренең төркемнәрен туплый. Чиратлап.
- Рәхмәт. Утырыгыз.
- Тактага игътибар итәбез. Сезгә өч рәсем бирелгән. Бу рәсемнәрне нәрсә берләштерә? Нинди сүз?

*Уңыш*

1. **Төп өлеш.**

- Дөрес, димәк без бүген сезнең белән уңыш турында сөйләшербез. Үз алдыбызга нинди максат куярбыз икән? Мин сезгә йолдызлар бирдем. Һәрберегез йолдызга үз фикерегезне языгыз һәм йолдыгызларыгызны күк йөзенә урнаштырыгыз. Лидерлар башлый, калганнар иптәшләрегезнең фикере белән танышыгыз, әгәр дә фикерегез туры килә икән йолдызларны янәшә урнаштырыгыз, туры килмәгән очракта бер-берсеннән ераграк куегыз. Эшне башлыйбыз.
- **ЙОЛДЫЗЛЫ КҮК алымы** – тема буенча максат һәм бурычлар кую ысулы. Йолдызлар күп җыелган урын төп максат итеп билгеләнә.
- Фикерләрегез белән танышып чыгыйк. *(Уңыш сүзен ачыклау; төрле якларын тикшерү; төрле методлар белән танышу)*
- Алга таба эшне дәвам итәбез. Тактада нинди рәсем күрсәтелгән? *Магнит.* Әгәрдә магнит уртасына уңыш сүзен урнаштырсак, аның янына тагын нинди сүзләр ябыштырып булыр иде. Төркемнәрдә киңәшләшеп эшлибез, тапкан сүзләрегезне язып барыгыз.
- **АССОЦИАЦИЯ**ләр билгеләү эвристик технологиянең бер алымы. Бу алымны дәресләремдә еш кулланам. Ассоциация уйлай балаларның фикер йөртү сәләтен арттыра. Шулай ук алынган мәгълүматны озак вакытка хәтердә калдыру өчен кулай.
- Язган сүзләрегез белән танышып китик. *(дәрәҗә, шатлык, тантана, җыю, эш, җиңү, акча, сәләт, байлык, көзге, бәхет, хезмәт, нәтиҗә).*
- Шушы сүзләргә таянып, уңыш сүзенә аңлатма биреп карагыз. Мин сезгә стикерлар өләшәм, шунда аңлатмаларны язабыз. Шулай ук тактада ике зур стикер урнаштырам, фикерегез кайсы аңлатмага күбрәк туры килә шул стикер янына үзегезнекен ябыштырасыз.
- **СТИКЕРЛАР АША ДИАЛОГ алымы.** Бу алым фикерләүнең визуаль, кинестетик һәм ишетү аспектларын үстерү максатында кулланыла, халык алдында «чыгыш ясау»кирәк булмаганлыгы аркасында бик күп укучылар өчен уңайлы.

- *1 стикер. Иген, җиләк-җимеш, яшелчә һ.бларның җыелган күләме, чыгышы.*
- *2 стикер. Нинди дә булса эшнең уңышлы тәмамлануыннан булган нәтиҗә, казаныш.*
- Димәк, без уңышның ике төрен билгеләдек. Үз стикеларын беренче төргә ябыштырган коллегалар беренче өстәлгә күчә, ә икенче төргә ябыштырганнар икенче өстәлгә күчә.
- Алга таба һәр төркем үз юнәлешендә эшли. Мин сезгә карандашлар һәм битләр бирәм. Шул биттә язылган биремнәрне үтәгез.
- Сезнең игътибарга **МОЗАИКА алымы.** Бу алым укучыларда җаваплылык хисе тәрбияли, гомуми эшкә керткән өлешнең әһәмиятен аңлауга ярдәм итә.
- Коллегалар, сез әзерме? Нинди рәсемнәр ясадыгыз, нәрсә килеп чыкты?
- Әйе, һәр төркемнең үз юнәлешендә булган аңлатмага кагылышлы рәсемнәр ясый алдыгыз, рәхмәт.
- Эшебезне дәвам итеп, үз юнәлешегезнең картасын да ясап карагыз. Сезгә бирелгән карталарда төп тема язылган. Бу алым “вживания” дип атала. Үзегезне *уңыш* дип хис итеп карагыз һәм картаны тутырыгыз.
- **КАРТА ЭМПАТИИ алымы.** Үзеңне башка образда тоеп кару, кабул итүнең иң шәп юлы. Күзәтү объектына үтеп керү, ихтыяҗларын ачу юлы.
- Фикерләрегез белән таныштырыгыз. Бик матур, рәхмәт. Без сезнең белән уңыш төшенчәсен бөтен яклап карадык. Хәзер сезгә бу сүзнең символын ясарга тәкъдим итәм.
- Димәк, уңыш сүзен төрле яклап карадык. Рәхмәт бик зур. Йомгаклап әйтәсе килгән сүзем шул, яңа мөмкинлекләргә һәм зур казанышларга ирешүгә юллар ачылсын, күңелле вакыйгалар еш булып торсын, шәхси мөнәсәбәтләр игелеклелек, шәфкатьлелеккә корырсын, һәрнәрсәгә һәм һәр кайда уңыш юлдаш булсын. Ышанычлар күбрәк тормышка ашсын, уңыш һәм бәхет ешрак елмайсын! Сезгә нык сәламәтлек, оптимизм, көчлә рух һәм даими уңыш телим!
- Хәрмәтле коллегаларым, сезгә күрсәтеп, таныштырып китәсе килгән методларым әлегә шушылар.
- **СТОРИЧ алымы.** Һәрберегездә метод язылган тасмалар бар. Такта янына киләбез. Монда өч предмет: чемодан, кәрзин, иттарткыч. Чемоданга сезгә ошаган һәм үзегез белән аласы методларны салабыз, кәрзингә ошамаган, ташлап калдырасы методлар салына, ә иттарткычка ошады, ләкин үз дәресем өчен ничек кулланасын аңламадым дигән методларны салабыз.

  Бик зур рәхмәт!

*Нәбиуллина Ландыш Илдус кызы,*
*Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районының "Аерым фәннәрне тирәнтен өйрәнүле 15 нче урта гомуми белем бирү мәктәбе" муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесенең югары категорияле башлангыч сыйныф укытучысы*

**Туган тел дәресләрендә синквейн алымын куллану**

Мин үземнең мастер-классымны “Тел – белемнең ачкычы, акылның баскычы” дигән татар халык мәкале белән башлап китәсем килә.

Телне белү, аның белән дөрес эш итү – сүз байлыгына ия булу дигән сүз. Кеше тел ярдәмендә фикерен үтемле, төгәл, мавыктыргыч, тәэсирле итеп белдерә ала, күп төрле фәннәр үзләштерә, гыйлем туплый. Тел – белемнең ачкычы, акылның баскычы – дип юкка гына әйтмәгән халкыбыз. Димәк, тел кешенең гыйлем дәрәҗәсен, интеллектын гына билгеләп калмый, акыл дәрәҗәсен һәм фикерләү сәләтен дә күрсәтә.

Һәр укытучы һәм тәрбияче үзенең дәресләрен яхшы сыйфатлы, нәтиҗәле итеп үткәрергә, төрле методик алымнарны файдаланырга, укучыларга төпле белем бирергә тырыша. Моңа ничек ирешергә? Татар телен укытуның методик базасын ничек киңәйтергә? Телгә балаларның кызыксынуын ничек булдырырга? Шушы сораулар иҗади эшләүче укытучыларны һәм тәрбиячеләрне бик тә борчый.

Хөрмәтле коллегалар! Мин сезне бүгенге мастер класста балаларның сүзлек запасын баета, эчтәлек сөйләүгә әзерли, идеяне билгеләргә өйрәтә, бала үзен шагыйрь итеп хис итә һәм барлык балалар да башкарып чыга ала торган эш төрләренең берсе — сиквейн алымы белән таныштырасым килә.

Нәрсә соң ул синквейн?

Синквейн фразцуз теленнән кергән сүз, 5 дигәнне аңлата. Ул рифмалашмаган бишьюллык шигъри формада язылган кыска әдәби әсәр. Билгеле план буенча языла, предметны (төшенчәне) ачыклый.

Синквейнны язу тәртибе:

1нче юл. Теманы ачыклаучы сүз, исем. Яки Нәрсә? *Соравына җавап бирә торган сүз.*

2нче юл. Теманы сурәтли торган ике сыйфат. Нинди?

3нче юл. Синквейн темасына хас булган 3 фигыль. Нишли?

4нче юл. Теманың эчтәлеген ачучы фраза, җөмлә. Ул баланың темага мөнәсәбәтен күрсәтә.

5нче юл. Баланың темага карата үз фикерен бер сүз белән чагылдырган нәтиҗә, ассоциация. (резюме).

Хөрмәтле коллегалар! Мин сезне үземнең укучыларым татар теле дәресләрендә төзегән сиквейн белән таныштырып китәсем килә.

Синквейнның темасы төрле булырга мөмкин.

Көз

Сары, яңгырлы.

Коела, ява, салкыная.

Агачлардан алтын яфраклар коела.

Матурлык.

Кыш

Салкын, карлы.

Туңдыра, шатландыра, бүләк итә.

Кыш бабай бүләкләр алып килә.

Яңа ел.

Матур, чиста,

Үсә, яхшыра, яши.

Мин туган шәһәремне яратам

Ватан.

Каюм Насыйри

Белемле, күпкырлы

Укыткан, белгән, өйрәнгән

Мин К. Насыйридан үрнәк алам

Галим.

Хөрмәтле коллегалар! 1нче сыйныфларда синквейн алымын ничек кулланырга була соң?

- Уенчык ярдәмендә.
- Рәсем ярдәмендә.
- шартлы билгеләр белән.

Шулай итеп, Синквейн алымы иҗади сәләтләрне үстерергә, дөрес бәяләргә, үз карашыңны булдырырга  өйрәтә. Зур күләмле информацияне гомумиләштерергә, катлаулы мәсьәләләрне гадиләштерергә булыша. Синквейнны язуның төгәл тәртибе укучының фикерен дөрес формалаштырырга, төп фикерне билгеләргә ярдәм итә. Мондый иҗади эш башкару –

җиңел, күңелле, файдалы. Сөйләм теле камилләшә, авыр төшенчәләр үзләштерелә. Һәм иң мөһиме халык мәкалендәгечә “Сөйләсәң, сүзнең маен чыгар”  дигәндәй Синквейн төзү укучыдан, баладан уку материалында иң мөһим элементларны табуны, йомгак ясауны һәм шуны берничә сүз белән (кыска итеп) әйтеп бирүне таләп итә.

Хөрмәтле коллегалар! Бүгенге мастер классымның темасы итеп “Туган теле дәресләрендә синквейн технологиясен куллану” ны алдым. Минем максатым сезне шул технология белән таныштыру һәм үз дәресләрегездә дә синквейн технологиясен кулланырга өйрәтү.

Һәм бүгенге сөйләшүебезне Наҗар Нәҗминең “Татар теле” шигыре белән дәвам итәсе килә.

Татар теле.

Туган җирең Идел буе,
Һәр телнең бар Туган иле.
Туган җирең кебек назлы,
Җырдай моңлы татар теле.

Ак алъяпкыч бәйләсәләр,
Өзелеп тора кызлар биле.
Кызлар кебек шат чырайлы,
Ачык йөзле татар теле.

Халкың кебек уңган да син,
Хезмәттә син көне-төне.
Ир-егетләреңдәй дәртле,
Гайрәтле син, татар теле.

Ассалар да, киссәләр дә
Үлмәдең син, калдың тере.
Чукындырган чагында да
Чукынмадың, татар теле.

Яндың да син, туңдың да син,
Нишләтмәде язмыш сине.
Дөньяда күп нәрсә күрдең,
Әй, мөкатдәс Тукай теле.

Төрмәләргә дә яптылар
Җәлил белән бергә сине.
Төрмәләрдә дә килмешәк
Булмадың син, татар теле.

Зинданнарны ярып чыктың,

Ялкынланып чыктың кире,

Хәтта фашист тегермәне

Тарта алмады анда сине,

Әй син, батыр татар теле!

- Сездә Татар теле нәрсә белән ассоцияләнә? Җилкәдәш партнерларыгыз белән сөйләшеп алыгыз.
- Беренче номерлы коллегаҗавап бирә
- ….
- Карагыз әле, Татар тел – ул …
- Хөрмәтле коллегалар, әйдәгез эш нәтиҗәбез итеп Татар теле темасына синквейн төзик.
- Сезнең алда ватманнар, концтоварлар. Сез шигырь юллары белән бер рәттән иҗадилыгыгызны да җигеп, рәсемнәр куллана аласыз.

Сүземне йомгаклап , синквейн алымының өстен якларын санап китәсем

килә:

- Тема буенча лексик материал үзләштерелә, сүзлек байлыгы арта
- Эчтәлекне кыскача сөйләүгә әзерли
- Тәнкыйди һәм креатив фикерләүне камилләштерә
- Ассоциацияләр ярдәмендә алган белемнәр ныгытыла
- Катлаулы информация гомумиләштерелә
- Укучы үзен шагыйрь итеп хис итә
- Бөтен укучы да яза ала.

Балаларны матур, дөрес, төгәл итеп сөйләргә өйрәтү татар теле дәресләренең төп бурычларыннан санала. Бер яктан, сөйләм аң, фикерләү үсеше белән тыгыз бәйләнгән, сөйләм ярлылыгы фикер үсешен тоткарлый. Икенче яктан, телне яхшы белми торып сүз сәнгате булган әдәбиятны да аңлап, тоеп, кичереп булмый. Минемчә, бу метод укучыларны кызыксындырып кына калмас, ә уйландырырга, фикер йөртергә мәҗбүр итәр.

Игътибарыгыз өчен рәхмәт, сезгә авыр әмма ләкин, игелекле, изге эшегездә иҗади уңышлар телим.

*Ризванова Фәнүсә Минигали кызы,*
*Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы «29 нчы урта гомуми белем бирү мәктәбе» муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесенең беренче категорияле татар теле һәм әдәбияты укытучысы*

**Балалар язучысы буларак, Муса Җәлилнең ватанпәрвәрлек хисләре тәрбияләүдәге роле**

Үсеп килүче яшь буында туган илен, җирен ярату, халкы белән горурлану, кирәк очракта, туган җирен саклап көрәшкә күтәрерлек шәхес, гражданин тәрбияләү җәмгыятебезнең бурычы. Билгеле, патриотик аң формалаштыру үзеннән-үзе генә түгел, эзлекле алып барыла торган эш. Ул өйдә, гаиләдә башланып, балалар бакчасында дәвам иттерелеп, мәктәптә тагын да үстерелә. Патриотик тәрбия бирүдә, ватанпәрвәрлек хисләре тәрбияләүдә әдәбият дәресләре аша зур нәтиҗәләргә ирешергә мөмкин.

Туган илләренең батыр уллары дип без Казан ханлыгы чорында Кол Шәриф, Мөхәммәдьяр исемнәрен телгә алсак, соңрак чорда М.Җәлил, А.Алиш, Ф.Кәрим кебек шагыйрь һәм язучыларның исемнәрен атый алабыз. Әлеге шәхесләрнең үрнәк булырлык тормыш юллары, алар калдырган иҗат – туган илгә мәхәббәт тәрбияләүдә гаять файдалы материал. Ватанпәрвәрлек хисләре тәрбияләүнең иң югары ноктасы булып герой-шагыйрь М.Җәлилнең тормышын, иҗатын, батырлыгын үрнәк итеп кую торадыр.

Муса Җәлил – героик язмышлы шагыйрь. Аның шигъри батырлыгы яшәү батырлыгы белән кушыла. Ул фаҗигале, ләкин һәркемне көнләштерерлек, горурланырлык.

М.Җәлилнең күпкырлы иҗатын балаларга аталган шигырьләреннән башка күз алдына китереп булмый. 20 нче елларда әдәбият мәйданына килеп кергән Муса Җәлил балалар әдәбиятында бай иҗади мирас калдыра. Шагыйрьнең балалар поэзиясе үзенең тематик киңлеге белән аерыла. Туган ил, аның белән горурлану, халык азатлыгы, бәхете өчен көрәшү, хезмәт сөю, Ватан өчен кирәкле кеше булып үсү кебек мотивлар әдипнең шигырьләренең үзәгендә. Бу мотивлар шагыйрьнең беренче шигырьләреннән алып (“Бәхет”) гомеренең соңгы көннәрендә иҗат ителгән “Моабит дәфтәрләре” әсәрләренә кадәр якты нур булып сызылып баралар.

Балалар үзләренең Ватанын яратырга, халык бәхете өчен көрәшкә әзер торырга тиеш. М.Җәлилнең бөтен иҗаты булып шушы фикер уздырыла:

Сез назлап үбегез гөлләрне,
Хуш истән күңелегез ачылсын.
Җир бирде сезгә шат көннәрне,
Йотып тир, кан һәм яшь  тамчысын.

Шагыйрьнең патриотик  әһәмияткә ия булган шигырьләре белән бергә сабыйларча эчкерсезлек белән тасвирланган табигать күренешләре дә (“Яңгыр”, “Чишмә”), хезмәттә тәрбия (“Бакчада өмә”, “Лагерьда”, “Уен”, “Беренче  дәрес”), кошлар һәм хайваннар тормышыннан алып язылган мавыктыргыч вакыйгалар да (“Күке”, “Маэмай”, ”Карак песи”), балаларның үз тормышына караган, тәрбияви көчкә ия булган шигырьләре дә ( “Сәгать”, “Чаңгы шуганда”) гаҗәеп зур поэтик югарылыкта иҗат ителгән.

Әдипнең шигырьләрендә һәрвакыт шат күңелле, бәхетле хезмәт, шатлыклы нокталар гына чагылмый. Үзенең поэзиясендә ул ике дөнья, ике капма-каршы  язмыш турында уйланырга мәҗбүр итә. Шагыйрьнең тагын бер тематикасы (“Ятимнәр”, “Ятим бала”, “Джим”) ачлык, ялангачлык, ятимлек, тигезсезлекне  тасвирлый.

Европа  өстендә сугыш янагач һәм халыкара мөнәсәбәтләр кискен борылыш алгач, Җәлил фашизмга каршы көрәшкә керә. Ул балалар өчен танылган “Джим” поэмасын яза. Бәләкәй немец кызының кичерешләре, борчылулары, интегүләре  аша шагыйрь фашистларның һәм расистларның кешелексезлекләрен ача. Поэманың сюжеты реаль вакыйгаларга таянып язылган.

Әлеге поэмадан соң Җәлилнең иҗатында патриотик нокталар, мотивлар артып китә. “Йолдызлар”,  “Көчек”, “Дуска”, “Соңгы көрәшкә” шигырьләрендә ул гади формада балаларга Ватанны саклау, героизм, уяулык турында сөйли. Сугыш еллары поэзисендә дә  әлеге темалар кулланыла, батыр совет солдаты образы  тудырыла (“Чыршы”, “Кыш бабай”).

М.Җәлил “Кечкенә иптәшләр” балалар журналының редакторы, “Октябрь баласы” журналын оештыручыларның берсе була. Аның инициативасы белән  “Октябрь баласы” журналында “Музыка почмагы” рубрикасы ачыла.  Шагыйрь Җәүдәт Фәйзи,  Латиф Хәлиди кебек композиторлар белән иҗатлык итә. 1940 нчы елда  ул текстлар һәм җыр ноталары булган “Балалар өчен беренче альбом” чыгара. Альбомда “Кәккүк”, “Карак мәче”, “Беренче дәрес”, “Чишмә”, “Май”, “Сәгать” кебек җырларны туплый.

Муса Җәлилнең балаларга аталган иҗаты  жанрлар буенча күпкырлы. Аның хикәяләре (“Чуар”),  пьесалары (“Буксир”), курчак театры өчен сценарияләре (“Пионер-петрушка”) бар. Ләкин татар балалар әдәбиятына ул, беренче чиратта, шагыйрь булып керә. Ул аны үз заманына хас булган җәмәгать идеяләре, проблемалары, ватанпәрвәрлек хисләре, сәнгать чаралары һәм жанрлар үсеше белән баета.

М.Җәлилнең балалар өчен язылган шигырьләре бүгенге көндә дә әһәмиятен югалтмаган. Әдәбият дәресләрендә укучылар аларны яратып өйрәнәләр. Шагыйрьнең әсәрләре балаларны илебезнең чын гражданнары итеп тәрбияләүдә мөһим роль уйныйлар, Ватанны һәм халыкны сөюче шәхес булырга өндиләр, туган илгә, җиргә мәхәббәт тәрбиялиләр.

*Сайфутдинова Фарида Хасаншиновна,*
*Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районының «26нчы урта гомуми белем бирү мәктәбе» муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесенең югары категорияле татар теле һәм әдәбияты укытучысы*

## Әдәби әсәрләр укуга кызыксыну уятуда уен технологиясе.

**Кереш.**

Мин - әдәбият укытучысы."Әдәбият-безнең мәктәпләребездә кешенең күңелен, җанын тәрбияләүче бердәнбер фән",-дип язган чорыбызның күренекле шәхесе, танылган драматург Туфан ага Миңнуллин. Ничек итеп балаларны бу фән белән кызыксындырырга? Китап укуга ихтыяҗ тудырырга? Аңа нинди юллар белән ирешеп була? Бу сораулар бүгенге көндә бик актуаль. Мин, укуга мотивация, кызыксыну уяту өчен,төрле алымнарга,заманча яңа технологияләргә мөрәҗәгать итәм.

Мин мастер-классымның темасын "Сәйлән җыю" уены дип атадым. Уен-төпле белем бирүдә, дәресне кызыклырак итүдә ярдәм итүче бер алым,чара.Уен баланың шул фән белән кызыксынуын арттыра, мөстәкыйльлеген, ихтыяр көчен, акыл эшчәнлеген, зирәклеген, тапкырлыгын үстерә, аны милли бердәмлек рухында тәрбияли, билгеле бер максат куеп эшләргә өйрәтә.

Сәйлән балаларга кечкенәдән таныш.Сәйлән чигү- безнең халкыбызның борынгы сәнгать төре. Сәйлән белән чигелгән милли киемнәргә,түбәтәй-калфакларга карап,кемнәр генә сокланмый икән?! Ә сәнгать әсәре тудыру өчен,тырышлык,матурлыкны тою,фантазия,хыллана белү кирәк.

Әдәбият дәресенә сәйләннең ни катнашы бар диярсез сез? Без чәчелгән сәйләннәр кебек таралган мәгълүматны бербөтен итеп җыеп, үзебезнең иҗат җимешебезне тудырырбыз.

Бу уенның тарихы бик еракларга барып тоташа.Немец язучысы,Нобель премиясе лауреаты Герман Гессе "Игра в бисер" китабында бу уенны серле,тормыш кебек аңлаешсыз

дип атый.Уенның максаты- фән һәм сәнгатьнең төрле өлкәләренә караган әйберләрнең үзара бәйләнештә булуларын һәм охшашлыкларын ачыклау.Бу уен-интеллектуаллар уены,фикерләр көрәше уены.

"Культура" каналында Игорь Волгин җитәкчелегендә "Игра в бисер" тапшыруында әдәбиятның иң актуаль әсәрләре турында фикер алышалар. Бу тапшыру 2016 нчы елда телевизион ТЭФИ премиясенә лаек булды.

**Әзерлек этабы.**

Мин бу уенны үз мастер- классымда тәкъдим итәм.Әзерлек этабында сезнең хозурыгызны бер картинага юнәлтәсем килә. (Рәссам Абрек Абзгильдинның “Дәрдмәнд” картинасы.)

-Бу картина кемгә багышланган?

-Портрет булмаса,сез аның Дәрдмәндкә багышланганын белер идегезме?

- Сезгә нәрсә ярдәм итте?

1.киеме

2.диңгез темасы

3.китап

4. алтын

5.җил һ.б.

Без, сәйләп кебек бөртекләп мәгълүмат җыеп,бер фикергә килдек:бу картина халкыбызның күренекле шәхесе Дәрдмәндгә багышланган.

**Төп өлеш.**

Эшебезне ике юнәлештә алып барырбыз.

1-фокус-группага бер әсәрдән төрле өлкәләргә караган текстлар таратам.Шушы өзекләрне анализлап,сез әсәрнең исемен табарга тиеш буласыз.Билгесезлектән төп **мәгънәне,фикерне** табасыз.Эшли башладык.Фикерләшеп эшләгез.

2- фокус-группага картина карарга тәкъдим итәм.

-**Бу рәсем кемгә багышланган?** Әле яңа гына табадан төшкән.Сезгә таныш түгел. Рәсемдә бу шәхеснең тормышындагы күп вакыйгалар сурәтләнгән.

Автор күренекле шәхес турында бик күп мәгълүмат туплаган. Аның белән мондагы һәр кеше шәхсән таныш түгел, якыннан белүчеләр булырга да мөмкин.Әмма аның исеме һәрберегезгә билгеле.Кемдер аңа табына, кемдер соклана. Бу шәхес татар әдәбиятында, фәндә бик югары урын алып тора. Рәсемгә карап,кайсы чорда яшәвен табарга авыр түгел.Монда мәгълүмат сәйләннәр кебек чәчелгән. (Һәр кеше бер вакыйга турында сөйли)

1-авыл

2-туган йорт

3- табигать

4-мәктәп

5- сталинизм

5-сугыш,уку йорты

6-диңгез

7- университет

8- Тукайга табыну

9.”Җидегән чишмә”

Без сөйләннәребезне җыеп бетердек. Әйе,бу картина Татарстанның халык язучысы, Г.Тукай премиясе лауреаты М.Мәһдиевка багышланган.

**Укытучы сүзе.** Икенче төркемдәгеләр Мөхәммәт Мәһдиевнең бер әсәреннән төрле темага караган өзекләр укып, бу әсәрнең исемен табарга тиешләр.Укылган өзекне ничек итеп атар идегез?

**Фокус-группа өчен әсәрдән өзекләр** (өзекләрне киметергә була)

**1 нче тема**

“Табигатьнең иң моңлы,иң сагышлы вакыты -май ахыры.Бу көннәрдә кояш нуры әллә ниткән зәңгәр томан аша төшә,көньяктан җылы җил исә.”

“Бөтен дөньяны дымлы,салмак чәчәк исе урап алган.Бакчада йөз инструментлы оркестрдай сандугач тавышы...”

“Менә беркөнне көз үзе килеп җитте.Таңда авыр гына кырау төште. Кырау көйдергән бәрәңге сабагы исе дөньяны баскан,ул ис көзендә бер генә иртәдә була.Шул көнне урман төрле төскә кереп чуарлана башлый,шул көнне көньякка таба торналар кузгала Зәңгәр күкнең гөмбәзендә -бик биектә аларның тылсымлы әкияттәге кошлардай сихри тавышлары авыл өстенә ишетелә.Күк түбәсендәге сихри музыка үзәкне өзә.

-Торыл-л-лыйк! Торыл-л-лыйк!..”

**Нәтиҗә:** бу өзекләр **.туган җир** турында.

**2 нче тема**.

“Шушындый малны кулга төшергәч, бер “пәнҗеки” җәлләп торырга!-диде Сорочи базары спекулянты. “ (Арго сүзләр)

“Кайнана... киленнең канын эчте... мәктәптә озак торасың дип йөрәген бозды”. (Фразеологизм)

“Поезд үзенең эчендә әллә никадәр шатлык, әллә никадәр фаҗига, кайгы-хәсрәт төяп йөртә” җөмләсендә “фаҗига”, “кайгы-хәсрәт” синонимнары, “шатлык” сүзенең антонимнары булып, янәшә килгәннәр

“И дөнья! Кайвакытта синең шатлыгың газаплы, ә кайгың ләззәтле була “ (оксюмороннар)

“Рус теле укытучысы бик төз гәүдәсе, кызыл иреннәре, биек үкчәле туфлилары һәм чәчен төзәткәләгән саен сирпелеп киткән затлы хушбуй исе белән ул бала итәкле, изелгән киез итекле, бумази чалбарлы укытучыларның барысыннан да аерылып тора иде.”(эпитетлар)

“Смирно!” командасы секундның йөздән бер өлешен алдымы, юкмы, шартлап чыкты”.(Гипербола)

“Хан кызыдай киленне аның әти-әнисе икәүләп кабул иттеләр.Әйтерсең,бу-затлы көмеш подноска куелган бер өстәллек фарфор чынаяклар өеме иде “ (Чагыштырулар)

**Нәтиҗә: үзенчәлекле стиль, үзенчәлекле тел-сурәтләү чаралары** бик уңышлы кулланылган.

**3 нче тема**.

“Без синең белән япь- яшь көе бер институтны тәмамлаган идек инде.Ул- Бөек Ватан сугышы институты.Ул- гаделлек,бөтен җир шары халыклары өчен изгелек институты иде.”

“Таныш көйне ишетүгә,Минҗамал сикереп торып биергә чыкты.Минҗамал идәннән бөтен үчен алды:үзен мәңгегә ирсез калдырган фашистларны таптады,берөзлексез "мал курмысы" хакында сөйләп үзәгенә үтә торган кайнанасы белән кайнатасын да салып изде,берөзлексез үзгәреп торган уку программаларын да таптап йөрде- барысы да булды.”

**Нәтиҗә**: әсәрдә **сугыш** фаҗигасе

**4 нче тема.**

“Физика укытучысы шкафлары куелган класста укучылар белән көн-төн ятты. Физика буенча вузга керергә бер 15 кеше әзерлим ,-дип котчыккыч эш башлады..Каникулда мәктәп гөрләп торды.”

“РОНОдан кәгазь килеп төште:унынчы класс укучылары сочинениене чит мәктәпкә барып язасылар икән...

“Русча сочинениедән бер генә икеле дә куелмау -мәктәп тарихында зур вакыйга иде,монда рус теле укытучысының күпме тырышканын һәркем аңлады.

**Нәтиҗә:** бу өзектә **мәктәп, укытучы** тормышы турында мавыктыргыч итеп язылган.

**5 нче тема.**

“Шул җырларның көйләре әле дә истә калган, әмма сүзләрен инде онытканмын.”

“Бәлки, ул да ел буе әнә шул якты истәлек белән рухланып, дәртләнеп яшидер?” “Солдат уставыннан тыш, этинең алып кайткан байлыгы – истәлек өчен солдатлар биргән открыткалар.”

“Аһ,шайтан!Узган ел ут җибәргән язгы төн аның хәтеренә төшкәндә йөрәк шулай сулыгып ала икән.”

“Бар иде җиңүчеләр булып Варшава урамына килеп кергән чаклар.Бар иде 45 нче елның язында азат итүче булып,немец шәһәрләреennә узган вакытлар”

**Нәтиҗә:** бу өзекләрдә **хәтер концептының** төрле мәгънәләре күрсәтелгән. Авторда **хәтер:вакыт, истәлек, эз, байлык, тарих.**

**6 нчы тема.**

Яз-кыз бала өчен иң хәтәр вакыт.

Педагогика дигән фән сине бөтенләе белән дә йотарга риза.,аның фикеренчә,чын тәрбияче- үзенең бөтен гомерен мәктәпкә багышлаган кеше.

Иртән йокыңнан торып эшкә килешеңә һич тә көтелмәгән хәл ишетәсең килсә- мәктәптә эшлә.

Укытучы укытып картаймый,инспекторның дәрескә керүеннән картая.

**Нәтиҗә:** автор әсәрдә тормыштагы берәр гыйбрәтле хәл турында сөйли дә афоризм булып китәрлек **нәтиҗә-резюме** ясап куя**.**

**7 нче тема.**

-Әнием! Ул шулкадәр яхшы кеше.Мин аны көн саен күреп кенә торыр идем. Әнием!Татьяна да шул хисләрне кичердеме икән Евгенийны күргәч?Наташа Ростова да шул хисләрне кичергән түгелме соң?Нигә миңа ярамый?

-Ярамый,кызым.Син- комсомолка. Алар- дворян кызлары.

Инде унынчыларның авылдан китәренә нибары ун көн калды.Ул йомылды,кеше белән сөйләшмәслек булды.Бу мәхәббәт мәңгелек,кеше аңламаслык җырга әйләнде,бу җырны ике генә кеше ишетә һәм аңлый иде..

**Нәтиҗә: мәхәббәт** темасы яктыртылган.

**8 нче тема.**

Кырык бишенче елның тугызынчы маенда мин рейхстаг стенасына үземнең фамилиямне язып куйдым.Штык очы белән тырнап яздым.Татар егете ...дип,имзамны куйдым.Безнең бу җиңүнең әһәмияте тарих картайган саен арта барыр! Без- 45 нче ел егетләре!

Бу көйне Җиңү бәйрәме көнне сәхнәдә өч фронтовикның уйнавы халык батырлыгына бөек ихтирам уята иде. Ватан сугышының бөтен моңы,сагышы,фаҗигасе,аерылышу кайгысы,көрешү дәрте,җиңү шатлыгы шушы көйгә сыеп беткән.Бу-сугыш кырларында үлеп калган шәһитләргә халыкның сәламе,матәм маршы иде.

Дөньяда 9 нчы май төне кадәр гүзәл төн булмас! Дөньяда 9 нчы майның әкияттәгедәй аксыл тын таңында галәм киңлегеннән торналарның сихри тавышы ишетелмәс!Бу төн-мәңге истә калыр!Бу төн- фронтовиклар төне!

**Нәтиҗә: җиңү** шатлыгы.

**Йомгаклау.**

Өзекләрне укып, анализлап, әсәрнең исемен таптык. Мөхәммәт Мәһдиев "Фронтовиклар" романында туган җиренә дан җырлый, сугыш фаҗигасен, җиңү шатлыгын күңелләргә үтеп керерлек итеп сурәтли. Укытучының кичерешләрен ничек оста тасвирлый ул. “Укытучының шатлыгы да, кайгысы да кешенеке кебек түгел...” һ.б.

Сәйләннәр кебек чәчелгән мәгълүматны туплап, нәтиҗә чыгардык, яңалык ачтык, күп нәрсәгә төшендек. Иҗатка мәхәббәт уятучы,эзләнү орлыклары салучы,укучыда үз-үзенә ышаныч уятучы укытучы булырга тиеш. "...Эзләнү-мөгаллим тарафыннан шәкерт рухына салынырга тиешле иң кыйммәтле,иң җимешле орлыктыр",- дигән Г.Ибраһимов.

*Сәлимова Гүзәлия Рәшит кызы,*
*Фәрхетдинова Фәнирә Гарәф кызы*
*Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы «Аерым фәннәрне тирәнтен өйрәнүле 16 нчы урта гомуми белем бирү мәктәбе” муниципаль бюджет белем бирү учреждениесенең югары категорияле татар теле һәм әдәбияты укытучылары*

**Рус телле балаларны татар телен өйрәнүгә теләк тудыру чаралары**

Телебез - безнең тарихыбыз да, киләчәгебез дә, безнең бурыч - туган телебезне күз карасыдай саклау, киләчәк буынга тапшыру.

Рус телле балаларга ничек татар теле дәресләренә кызыксыну уятырга?" дигән сорауны куям. Әлбәттә, балаларда татар телен өйрәнүгә теләк уятыр өчен, иң беренче чиратта, дәрескә кызыксыну уятырга кирәк. Бала мәктәпкә укырга килгәндә бик зур теләк белән килә. Укучыны мәҗбүриләп түгел, ә кызыксындырып, эмоциональ, эчтәлекле, эш формалары күптөрле булган дәресләр үткәрү - әнә шул теләкне сүндермәскә, белем һәм күнекмәләрне кызыксынып, актив үзләштерергә мөмкинлекбирә.

Дәрес балага авырлык китермәскә, киресенчә шатлык - бәхет алып килергә, дәрестән бала ләззәт, канәгатьләнү хисе алып чыгарга тиеш. Моны бары тик яңа фикерләүгә омтылган укытучы гына булдыра ала. Ул укучысын үз фикере, бәясе, үзенә генә хас тормыш тәҗрибәсе булган, иҗади сәләткә ия шәхес итеп кабул итә ала.

Укучылар нәтиҗәле эшләсен өчен, дәрестә уңай шартлар тудыруны беренче максат итеп куярга кирәк. Чөнки белем алу өчен кирәкле шарт, укучы белән укытучы арасында ышанычлы атмосфера, үзара ихтирам булырга тиеш. Мин дәресләрне укучыларның бер-

берсенә әдәпле сүзләр әйтү белән башлап җибәрәм. Алар дәрес башында ук эшкә тартылалар һәм дәрес буе актив эшлиләр.

Рус мәктәпләрендә укучы рус балаларының татар телен белү дәрәҗәсе һәм аралашу мөмкинлекләре төрлечә. Шуны исәпкә алып, дәресләремдә заманча белем бирү технологияләре кулланырга тырышам. Иң еш кулланыла торганнардан түбәндәгеләрне атап үтәр идем:

1. -шәхескә юнәлтелгән технологияләр:
   - дифференциаль укыту технологиясе;
   - үзара хезмәттәшлек педагогикасы технологиясе;
2. - укучылар эшчәнлеген активлаштыру һәм интенсивлаштыруга нигезләнгән педагогик технологияләр:
   -уен технологиясе;
   -проблемалы укыту технологиясе;
3. -уку процессын оештыру һәм идарә итүнең нәтиҗәлелегенә нигезләнгән педагогик технологияләр:
   - компьютер технологияләре.

Башлангыч сыйныфларда дәресләрне уеннар, күрсәтмәлелек кулланмыйча үткәрүне күз алдына да китереп булмый. Болар белән беррәттән дәресләрне үткәрү формалары да балаларның игътибарын җәлеп итүдә зур әһәмияткә ия: лекция, экскурсия, уен-дәресләр, ярыш-дәресләр һ.б. Шулар арасынна мин үз дәресләремдә уеннарга зур урын бирәм, чөнки башлангыч сыйныфларда татар теленә карата кызыксыну уятуда уенның роле бик зур.

Тел дәресләрендә исә теманы аңлатканда проблемалы ситуацияләр тудырам, һәр укучы шушы проблеманы чишүдә катнаша. Проблемалы эзләнү технологияләрен кулланганда укучыларда:

- проблеманы әйтеп бирә белү күнекмәләре формалаша;
- иҗади сәләтләре,күзаллау үсә;
- максатчанлык һәм оешканлык тәрбияләнә;

.Дәресләрдә гадәти булмаган алымнарны да кулланып эшләргә тырышам. Шул алымнарның берсе - проект эше. Проектлар методы укучы шәхесенең белем алуга иҗади якын килүенә юнәлтелгән укыту системасы ул. Ул мәктәптә укытучы җитәкчелегендә эшләнә торган мөстәкыйль эш. Проект эше укучыларда да, укытучыда да зур кызыксыну тудыра. Ул фикерләүне, сөйләмне, үз уйларыңны формалаштыра белү сәләтен үстерә. Проек эшчәнлеге барышында укучы коллективта эшләргә, үзенә бирелгән эшкә җаваплы карарга, куелган сорауларга җавап табарга өйрәнә.

Рус телле балаларга түбәндәге төрдәге проекларны кулланып була:

- тикшеренү ( проблемалы ситуациядән чыгу юлларын эзләү, көндәлек тормышта кирәк булырдай программалар тәкъдим итү);
- иҗади ( бәйрәмнәр яки конкурслар өчен презентацияләр, музыкаль бизәлеш, видеоклип һ.б.)
- мәгълүмати (темага караган мәгълүматларны җыю, аларны катнашучыларга тәкъдим итү, фикер алышу,нәтиҗә ясау);
- уен проектлар;

Татар теле һәм әдәбияты дәресләрендә проектлар методын куллану - укучыларның иҗади сәләтен үстерүгә этәргеч булып тора. Укучыларда яңа проеклар эшләү теләге туа һәм фәнгә карата кызыксыну уяна.

Бүгенге көн дәресләрен компьютер, интерактив такта, мультимедиядән башка күз алдына да китереп булмый. Укучыларда уку процессына кызыксыну уяту өчен стандарт методлар белән генә чикләнергә ярамый. Укыту процессын информатизацияләү мәгариф өлкәсендә гаять зур мөмкинлекләр тудыра.

Компьютер технологиясе вакытны нәтиҗәле кулланырга һәм бирү процессын тагын да кызыклырак, җанлырак итәргә мөмкинлек бирә.

Дәресләрдә презентацияләр, "Электрон белем бирү" сайтындагы татарча мультфильмнарны карап фикер алышабыз, "Цифрлы белем бирү ресурслары"на (ЦОР) куелган тематик күнегүләрне башкарабыз, "Ана теле" порталындагы видеоязмаларны, УМК га кушымта булып барган дисктагы текстларны тыңлыйбыз. Мультфильмнарны тавышсыз гына тыңлап, балаларга аларны үзләренчә "тавышландырырга" (персонаж булып сөйләргә) кушкан биремнәр дә бик кызыклы килеп чыга.

Гомумән фәннәрне укытуны камилләштерүнең чикләре юк, фәкать эзләнергә, яңалыкка омтылырга, билгеләнгән максатка кыю барырга гына кирәк.

Йомгак итеп шуны әйтер идем: әгәрдә укытучы дәрестә күргәзмәлекне җитәрлек дәрәҗәдә кулланса, төрле уен ситуаияләре, сөйләм күнегүләре, инновацион технология элементларыннан дөрес файдалана белсә, ул, һичшиксез, эшендә зур уңышларга ирешәчәк.

**Кулланылган әдәбият.**

1. Ф.С.Сафиуллина. Татар теленә өйрәтүнең фәнни-методик нигезләре. Казан.2001.

2. Ш.Әсәдуллин, Р.А.Юсупов. Рус телендә сөйләшүче балаларга татар теле укыту методика нигезләре. Казан.”Мәгариф”нәшрияты.1998.

*Солтанов Радик Ибраһим улы,*
*Солтанова Зөбәрҗәт Фиркат кызы,*
*Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы Муса Җәлил исемендәге “1 нче гимназия” муниципаль белем бирү учреждениесенең югары категорияле укытучылары*

**Башлангыч мәктәптә әйләнә-тирә дөньяны өйрәнү дәресләрендә пропедевтик тарих курсы өчен милли-региональ компонент материалларын куллану**

Илебез тирән үзгәрешләр чорын кичергәндә бу борылышлар кичерүләр беренче чиратта иҗтимагый фәннәргә кагыла. Туган якны өйрәнү, туган якка мәхәббәт тәрбияләү – милли-региональ компонент өлешләре. Тарих фәнен укытуның яңа концепцияләре нигезендә мәктәптә укытучыларга һәм укучыларга материаллар сайлап алу өчен күп мөмкинлекләр тудырылды. Ләкин болар бүгенге чор шәхесен тәрбияләү өчен җитәрлек микән?

Халыкара әхлак һәм хокук нормалары нигезендә һәр милләт үз телен, гореф гадәтләрен, йолаларын саклау, аларны ирекле рәвештә үстерү, милли балалар бакчалары, мәктәпләр, югары уку йортлары ачу хокукына ия. Педагог К.Д.Ушинский, һәр халыкның үзенә генә хас мәгариф системасы, үзенчәлекле тәрбия кагыйдәләре булырга тиеш, дип язган иде. Башка халыкларның мәгърифәтенә генә таянып эш итсәк, без милләтебезнең борын-борын заманнардан килгән белем бирү һәм тәрбия системасыннан ераклашырбыз.

Мәгълүм булганча тарих фәне алдына куелган төп максатларның берсе – укучыларны тәрбияләү бурычы. Бу өлкәдә барыннан да бигрәк – аларда патриотизм тәрбияләү. Патриотизм – ватанпәрвәрлек – грек сүзе, ул Ватаныңны, илеңне, халкыңны яратуны аңлата. Патриотик тәрбия - шундый затларның үрнәгендә, батырлык, талантлык, әхлакый сыйфатларга ия булу, героик көрәш традицияләре үрнәгендә тәрбияләү. Икенче яктан карасак, ул шулай ук Ватаның дошманнарына каршы нәфрәт сыйфаты булдыру да. Үз илеңнең символларына ихтирам һәм хөрмәт уяту да мөһим.

Әмма хәзерге шартларда балаларда ватанпәрвәрлек хисләре тәрбияләү җиңел эш түгел. Массакүләм мәгълүмат чараларының тискәре йогынтысы, яңа социаль-икътисади шартлар, идеалларның алмашынуы, милли мәсьәләрнең кайвакытта тиешенчә хәл ителмәве патриотик тәрбия бирүне нык катлауландыра.

Туган ил. Туган җир. Бу изге сүзләр һәркемгә таныш һәм кадерле. Ватан-пәрвәрлек дигәндә, без балаларны милли үзаңга һәм гражданлык хисенә ия булган шәхесләр, Ватанның

лаеклы уллары, кызлары итеп тәрбияләүне күз алдында тотабыз. Ватанпәрвәрлек – үз илеңә, туган җиреңә, халкыңа, табигатькә, милли традицияләргә, мәдәнияткә мәхәббәт ул.

Милли-региональ компонент элементлары балалар бакчаларында, башлангыч сыйныфларда ук керә. Әйләнә-тирә дөньяны өйрәнү дәресләрендә милли компонентлар белән танышу, төрле күзәтүләр, кешеләр эшчәнлеге белән танышу - болар бар да тарихи белемнәрнең башлангычы. Яшь буынның бүген алган тәрбиясе халкыбызның алдагы көнен билгели. Яшь буынга әхлак, патриотик һәм рухи тәрбия бирүдә нинди үтемле чаралар кулланырга соң?

Әлеге тема бүгенге көндә бик актуаль,чөнки үз тарихын белмәгән халыкның киләчәге юк. Моның өчен һәр бала үз гаиләсенең, туган җиренең тарихын белергә, шуның аша халыкка якынаерга тиеш. Шәҗәрәне өйрәнү нәсел-ыру традицияләрен, гореф-гадәтләрен, йолаларын, әдәп-әхлагын, шөгель-кәсепләрен белү һәм дәвам иттерү өчен кирәк. Шулай булганда гына яшь кеше милләт җанлы, үз халкының улы булып җитлегә ала, анда милли аңышанычлы формалаша.

Ватанпәрвәрлек тәрбияләү идеаллар – сугыш һәм хезмәт геройлары, талантлы язучылар, галимнәр, дәүләт эшлеклеләре һ.б. мисалында алып барыла. Укучыларны, барыннан да бигрәк, олы җанлы, әхлаклы, илнең прогрессив үсешенә өлеш керткән шәхесләр үрнәгендә тәрбияләү зарур. Инде ничә мәртәбә илебез тарихында бер төркем зыялы кешеләрнең авыр вакытта чит илгә китүне кулай күрүенә без дә гаепле түгелме соң? Моңа әхлакый бәя бирү безнең өстә дә түгелме? Балалар күңелендә өмет, киләчәкнең матур булуына ышаныч уяту – укытучының төп вазифаларыннан берсе.

Башлангыч мәктәптә тарих буенча пропедевтикада шундыйрак темалар тәкъдим итәргә була:

1) Татарларның исемнәре һәм кушаматлары. Алар нәрсә аңлата?
2) Нәсел шәҗәрәсе.
3) Кояш һәм ай календарлары. Һиҗри еллар исәбе.
4) Ватан нәрсәдән башлана?
5) Татар халкының урта гасыр шанлы дәүләте – Идел буе Болгары.
6) Идел буе Болгарында ислам динен кабул итү.
7) Идел буе Болгары шәһәрләре.
8) Татарлар атамасының килеп чыгышы.
9) Казан ханлыгы - үз чорының алдынгы дәүләте.
10) Россия империясендә хакимият һәм халык.
11) Күренекле мәгърифәтчеләребез – Каюм Насыйри, Шиһабетдин Мәрҗани.
12) Кавалерист кыз Надежда Дурова.

13) 1917 ел – Россия ут эчендә.

14) 1920 - 1930 еллар – якты киләчәккә омтылып.

15) Күтәрел дәү илем... (Татарстанлылар дошманга каршы сугышта)

16) Халкыбызның бөек улы Муса Җәлил.

17) Без нинди дәүләттә яшибез?

18) Мин – Россия гражданины.

19) Татарстан конституциясе кемнәр мәнфәгатен яклый?

20) Дәүләттә иң баш кеше кем?

21) Россия халыклары.

22) Татарстанда авыл хуҗалыгы үсеше.

23) Татарстан сәнәгать үсеше буенча башка регионнарга үрнәк.

24) Татарстанлыларның хезмәт җиңүләре.

25) Халкыбызның гореф-гадәтләре.

26) Татарстан мәдәнияте хәзинәләре.

27) Безнең бәйрәмнәр.

28) Туган ягыбызның тарихи һәйкәлләре.

29) Халкыбызның тарихын чагылдырган һәйкәлләр.

30) Музейга барабыз.

**Белемнәрне ныгыту өчен тестлар**

1. Ислам динен кабул иткәнче безнең борынгы бабаларыбызда кайсы хайваннар культы өстенлек иткән?

А) Йорт хайваннары.

Б) Ерткыч хайваннар.

В) Кыргый җәнлекләр.

Г) Тау бөркетләре.

2. Ай календаре буенча бер елда ничә көн була?

А) 365 көн.

Б) 354 көн.

В) 360 көн.

Г) 334 көн.

3. Безнең республикада татарлардан кала кайсы милләт кешеләре күпчелекне тәшкил итә?

А) Чувашлар.

Б) Удмуртлар.

В) Марилар.

Г) Руслар.

4. Болгар дәүләтендә кайсы шәһәрне рус кешеләре “Великий город” дип йөрткәннәр?

А) Суарны.

Б) Җүкәтауны.

В) Биләрне.

Г) Кашанны.

5. Түбәндәгеләрнең кайсы Болгар шагыйре?

А) Фирдәүси.

Б) Кол Гали.

В) Әхмәт ибне Фазлан.

Г) Ибне Батутта.

6. Ислам дине болгарларга кайсы илдән һәм халыктан килгән?

А) Гарәбстаннан, гарәпләрдән.

Б) Төркстаннан, төрекләрдән.

В) Монголиядән, монголлардан.

Г) Киев кенәзлегеннән, славяннардан.

7. Безнең көннәргә кадәр килеп җиткән бердән-бер архитектура истәлеге («Шайтан шәһәрчеге») Татарстанның кайсы шәһәрендә саклана?

А) Казанда.

Б) Тәтештә.

В) Чистайда.

Г) Алабугада.

8. Болгарның мәшһүр шагыйре Кол Гали әсәре:

А) Кисса-и Зөләйха.

Б) Кисса-и Гали.

В) Кисса-и Йосыф.

Г) Йосыф вә Зөләйха.

9. Алтын Урда дәүләтенең беренчел атамасы:

А) Чыңгыз иле.

Б) Җучи олысы.

В) Бату вилаяте.

Г) Тартария.

10. Урта гасырларда “татар” дип аталган кабиләләр кайда яшәгәннәр?

А) Урта Азиядә.

Б) Үзәк Азиядә.

В) Якын Көнчыгышта.

Г) Европада.

11. Казан дәүләтендә хуҗалык эшчәнлегенең төп төре:

А) Терлекчелек.

Б) Күчмә терлекчелек.

В) Игенчелек.

Г) Аучылык.

12. Казан ханының танылган аксөякләрдән торган киңәшләшү органы:

А) Корылтай.

Б) Җыен.

В) Диван.

Г) Дума.

13. Казан ханлыгы Явыз Иван тарафыннан яулап алынган ел:

А) 1500 ел.

Б) 1550 ел.

В) 1551 ел.

Г) 1552 ел.

14. Петр I патша чорында татар кешеләрен лашман газабы изгән. Лашман тарту дип нинди эшне атаганнар?

А) Җир сөрүне.

Б) Кораб төзү эшләрен.

В) Хәрби эшне.

Г) Урман кисүне.

15. Түбәндәгеләрнең кайсы композитор түгел?

А) Салих Сәйдәшев.

Б) Нәҗип Җиганов.

В) Солтан Габәши.

Г) Бакый Урманче.

16. Бөек Ватан сугышы елларында күпме якташыбыз Советлар Союзы Герое дигән югары исем алдылар?

А) 200 дән артык.

Б) 100 гә якын.

В) 50 дән артык.

Г) 150 гә якын.

17. Сугыштан соңгы елларда (1946) Татарстанда нефть кайсы районда табыла башлый?

А) Әлмәттә.

Б) Баулыда.

В) Азнакайда.

Г) Бөгелмәдә.

18. Бөек Ватан сугышыннан соң үсеп чыккан шәһәр:

А) Буа.

Б) Тәтеш.

В) Түбән Кама.

Г) Алабуга.

19. Татар халкының иң зур милли бәйрәме:

А) Кышны озату бәйрәме.

Б) Кич утыру.

В) Сабантуй.

Г) Өмә.

20. Казан шәһәрендә “очучы тәлинкә” гә охшаган бинада нәрсә урнашкан?

А) Театр.

Б) Цирк.

В) Стадион.

Г) Консерватория.

*Җаваплар:*1. Ерткыч хайваннар. 2. 354 көн. 3. Руслар. 4. Биләрне. 5. Кол Гали. 6. Гарәпстаннан, гарәпләрдән. 7. Алабугада. 8. Кисса-и Йосыф. 9. Җучи олысы. 10. Үзәк Азиядә. 11. Игенчелек. 12. Диван. 13. 1552 ел. 14. Урман кисүне. 15. Бакый Урманче. 16. 200 дән артык. 17. Баулыда. 18.Түбән Кама. 19. Сабантуй. 20. Цирк.

**Дәресләргә әзерләнү өчен әдәбият**

Баттал Һ.М. Казан төркиләре. – Казан, Татарстан китап нәшрияты, 1996.

Вәлиди Әхмәт-Зәки. Кыскачк төрек-татар тарихы. - Казан, Татарстан китап нәшрияты, 1992.

Саттаров Г.Ф. Татарстан АССРның антротопонимнары: татар авылларының исемнәре. - Казан, Казан университеты нәшрияты, 1990.

Фәхретдинов Р.Г. Мондадыр безнең бабайлар: археолог язмалары. – Казан, Татарстан китап нәшрияты, 1992.

Әхмәров Г.Н. Тарихи документаль җыентык. – Казан, Хәтер, 2000.

*Сөнгатуллина Ләйлә Мөхәмәт кызы, Хәйруллина Гөлназ Рәшит кызы,*
*Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы Муса Җәлил исемендәге “1 нче гимназия” муниципаль бюджет белем бирү учреждениесенең югары категорияле татар теле һәм әдәбияты укытучылары*

Без татар теле һәм әдәбияты укытучылары, күп еллар 5-11 нче сыйныф укучылары белән эшлибез. Быелгы уку елында башлангыч сыйныфларда да туган тел дәресләрен алып барабыз. Алар белән эшли башлау безнең эшчәнлегебезгә яңа буяулар өстәде. Өлкән сыйныфларда күбрәк сәләтле балаларга караган проект белән эш алып барабыз. Укыту процессында сәләтле балалар белән эш - иң өстенлекле эш юнәлешләренең берсе. Аның максаты - баланың табигый талантын үстерерү, үзаң тәрбияләү, сәләткә дөрес юнәлеш бирү. Халыкара татар теле олимпиадасында җиңүләр, предмет буенча республика олимпиадасында призлы урыннар яулау эшебезнең җимеше булып тора.

2020-2021 уку елында яңа проект өстендә эшли башладык. “**Һөнәр сайлау-җаваплы эш**” проектының нигезе- укучыларга кеше тормышында һөнәрнең бик мөһим урын тотуына төшендерү. Укучыларга тиешле белгечлек сайлап алу юнәлеше бирү. Һөнәр сайлауда җаваплылык хисе, җитди булу сыйфаты формалаштыру, гаилә тарихын өйрәнүгә этәргеч булдыру, һәртөрле хезмәткә, хезмәт кешесенә хөрмәт хисләре тәрбияләү.

Заманча эш алымнары белән уку- укыту процессын алып баручы бик күп коллегаларыбыз кебек, без дә, иҗади яктан якын килеп, мөстәкыйль белем алу, фән буенча эзләнү эшләре, камилләшүгә зур урын бирәбез. Җанлы һәм образлы сөйләм, югары мәдәниятле аралашу, хезмәтемнең һәр этабына мәгънә салу без җитәкчелек итә торган һәр биремне кызыклы һәм истә калырлык итә. Без иҗади кешеләр, шунлыктан һәр укучыга белем бирү белән беррәттән туган телебездә һәр яңгыраган сүзнең матурлыгын музыка, рәсем, сынлы сәнгать, театр белән бәйләп күрсәтәбез.

Үз өстеңдә һәрдаим эшләү, уку, уйлану гына үзенең нәтиҗәләрен бирә. Әлеге проект өстендә эшәүнең көтелгән нәтиҗәләре:

1. Укучының танып-белү эшчәнлеген үстерә;

2. Иҗади, эзләнү активлыгын камилләштерә, интеллектуаль сәләтенә бары тик уңай йогынты ясый;

3. Укучыларның коммуникатив мөмкинлекләрен ача, сөйләмне камилләштерә.

**“ Һөнәр сайлау-җаваплы эш ” проекты**

**Проектның кыскача эчтәлеге**

Әлеге проект 1-11 нче сыйныф укучылары өчен.

Предмет: Туган тел һәм туган тел әдәбияты

*Төп юнәлеше- эшче һөнәрләр белән таныштыру; шәхес, милли үзаң, кешелеклелек тәрбияләү; мөстәкыйль фикер йөртергә өйрәтү, эзләнү эшләре алып бару, нәтиҗәләрне критик бәяли белү.*

***Проектның максаты:***

- Укучыларга кеше тормышында һөнәрнең бик мөһим урын тотуына төшендерү.

***Проектның бурычлары:***

- Укучыларга тиешле белгечлек сайлап алу юнәлеше бирү.
- Һөнәр сайлауда җаваплылык хисе, җитди булу сыйфаты формалаштыру.
- Гаилә тарихын өйрәнүгә этәргеч булдыру.
- Һәртөрле хезмәткә, хезмәт кешесенә хөрмәт хисләре тәрбияләү.

***Эш методлары:***

- анкеталау, сораштыру;
- әңгәмә;
- тестлаштыру;
- тарихи килеп чыгышны анализлау,бәяләү;
- иҗади эшләр;
- проблемаларны өйрәнү методы.

***Эш формалары:***

- иҗади остаханәләр;
- төркемнәрдә эш;
- түгәрәкләрдә эш;
- интеллектуаль бәйгеләр;
- интеллектуаль марафон;
- предмет олимпиадаларында катнашу;
- индивидуаль план белән эшләү;
- фәнни-эзләнү конференцияләре.

***Эш этаплары:***

I этап – *аналитик* - баланың иҗади эшчәнлеге белем алуның төрле өлкәләрендә үсеш алырга мөмкин. Шуның белән бәйле, баланы төрле акыл эшчәнеген, сөйләм эшчәнлеген үстерүче, эзләп табу, танып белү, иҗадилыкка юнәлеш бирүче эшчәнлеккә этәргеч ясау.

II этап – *диагностик* – Баланың иҗади сәләтенә, танып белү сәләтенә шәхси якын килеп бәя бирү. Бу этапта төркемнәрдә эш формасын оештырабыз. Конкурслар, тренинглар, фәнни-эзләнү эшләре, иҗади зачетлар, проект биремнәре, интеллектуаль олимпиадаларда катнашулар оештырыла.

III этап – *укучыларда сәләтнең формалашу этабы*. Укучыларда тиешле белгечлек сайлап алу сәләте формалаша.

| **№** | **Планлаштырылган эш** | **Үткәрү вакыты** |
|---|---|---|
| 1. | «Әкияттә кунакта». Төрле һөнәрләр турында әкиятләрне сәхнәләштерү. | Сентябрь |
| 2. | Язучы Фәрит Имамов белән очрашу. Түгәрәк өстәл. | Октябрь |
| 3. | “Идел буе халыклары һөнәрчелеге”- проектлар бәйгесе. | Ноябрь |
| 4. | «Туган ягым - яшел бишек». Туган ягыбызда киң таралган эшче һөнәрләргә багышланган фотосурәтләр бәйгесе. | Декабрь |
| 5. | “Авылымның (шәһәремнең) күренекле кешеләре”. Авыл тарихы белән бәйле һөнәрләр турында мәгълүмат туплау. | Январь |
| 6. | “Милли бизәкләр”. Чигелгән, суккан, тегелгән борынгы милли кул эшләрен туплау. | Февраль |
| 7. | Әти- әниләр катнашында “Алтын куллар” дип исемләнгән кул эшләре остаханәләре. | Март |
| 8. | Халыклар дуслыгы йортында үткәрелүче милли бәйрәмнәрдә катнашу. | Апрель |
| 9. | Татар конгрессы белән берлектә “Җиңүгә китергән юллар” дип исемләнгән театраль күренешләрне сәхнәләштерү. | Май |

| | | |
|---|---|---|
| 10. | Татар язучылары, шагыйрьләре иҗатларында төрле һөнәрләрнең бирелеше буенча түгәрәк өстәлләр, иҗади пректлар. | Ел дәвамында |
| 11. | **“Һөнәр сайлау-җаваплы эш” дип исемләнгән дәрестән тыш чара** | Май |

***Нәтиҗәлелек критерийлары:***

1. Аңлы рәвештә эшче һөнәрләрнең мөһимлеген югары дәрәҗәдә өйрәнү.
2. Укучылар төрле дәрәҗәдәге олимпиада һәм бәйгеләрдә җиңү яулый.
3. Һөнәрләр белән бәйле конференция, бәйгеләрдә уңышлы чыгыш ясау.
4. Җәмәгатьчелек белән актив эш оештыру.

***Проектның нәтиҗәләре:***

- Һөнәрне үз мөмкинлегеңнән чыгып сайлау белеме дәрәҗәсе югары.
- Алган белемнәрне олимпиада, конкурс, иҗади проектларда куллана алу.
- Алган белемнәрне файдаланып “**Һөнәр сайлау-җаваплы эш**” проектының сценариесен төзү, җәмәгатьчелекне җәлеп итү.
- Проектның диск вариантын шәһәр мәктәпләренә тарату.

Проектның киләчәк үсеш перспективалары колачлы булыр, чөнки һөнәр сайлау алдында балалар күп очракта югалып кала. Әлеге проект, әлбәттә, укучыларга дөрес юнәлеш бирә . Барлык төр һөнәрләрнең асылын өйрәнгәч,  укучы үзен ирекле, белемле, ышанычлы итеп тоячак.

*Фалахиева Ильмира Ризатдин кызы,*
*Муса Җәлил исемендәге “1 нче гимназия” муниципаль бюджет учреждениесе югары категорияле биология һәм география укытучысы*
*Миннегалиева Гөлназ Сәләхетдин кызы,*
*Мамадыш шәһәре 1 нче номерлы гомуми белем бирү мәктәбенең югары категорияле*
*татар теле һәм әдәбияты укытучысы*

**Проект эшчәнлегенең өстенлеге**

Федераль дәүләт белем бирү стандартларына күчү шартларында укытучы эшчәнлегенең нәтиҗәле юнәлешләреннән берсе булып проектлар методы санала. Бу метод укучыларның өйрәнгән белемнәрен гамәли куллана белүләренә, мәгълүмати тирәлектә ориентлашу осталыкларына, иҗади фикерләү сәләтләренә нигезләнә.

Проектлар методы – укучы шәхесенең белем алуга иҗади якын килүенә юнәлтелгән укыту системасы ул. Ул мәктәптә укытучы җитәкчелегендә эшләнә торган мөстәкыйль иҗади эш. Проект эшчәнлеге – төпле фикере булган балалар тәрбияләү технологияләреннән берсе. Аның нигезе - тикшеренү эше.

Максаты: укучыларның шәхси үсешенә, уңышлы аралашуларына ирешү, аларны һәртөрле эшчәнлеккә иҗади якын килергә өйрәтү.

Проект эшчәнлеге укучыларда да, укытучыда да зур кызыксыну тудыра. Ул фикерләүне, сөйләмне, үз уйларыңны формалаштыра белү сәләтен үстерә. Проект эшчәнлеге барышында укучы коллективта эшләргә, үзенә бирелгән эшкә җаваплы карарга, куелган сорауларга җавап табарга өйрәнә.

Башлангыч сыйныф укучысы өчен проект эшчәнлеге шактый катлаулы. Балада көтелгән нәтиҗәгә ирешүгә кызыксыну булганда гына, проблеманы чишүдә уңай мотивация тудырып, аның эшкә дәртен, мөстәкыйльлеген үстерергә мөмкин. Кече яшьтәге мәктәп балалары белән проект-эзләнү эше алып барганда, аларның белем дәрәҗәсенең югары булмавын, дөньяны күзаллауларының, мөстәкыйль анализлау һәм игътибар туплау сәләтенең тиешенчә формалашып җитмәвен истә тотарга кирәк. Шуңа күрә укытучы башлангыч сыйныф укучыларын эзләнү эшчәнлегенең беренче адымнары һәм алгоритмнары белән таныштыра. Проект методының төп өстенлеге, минемчә, укучыларның яңа белем туплап кына калмыйча, белем туплауның, бердәм хезмәтнең нәтиҗәсен булдыруда.

Башлангыч сыйныфларда түбәндәге төрдәге проектларны кулланып була:

тикшеренү (проблемалы ситуацияләрдән чыгу юлларын эзләү, көндәлек тормышта кирәк булырдай программалар тәкъдим итү); иҗади (бәйрәмнәр яки конкурслар өчен презентация, музыкаль бизәлеш, фото коллаж, видеоклип һ.б.);
мәгълүмати (темага караган мәгълүматларны җыю, аларны катнашучыларга тәкъдим итү, фикер алышу, нәтиҗә ясау); уен-проектлар.

Проект эшләүнең түбәндәге этапларын билгеләп үтәргә мөмкин.

1. Әзерлек этабы, аны “кереш өлеш” яки “проектка кереп китү” дип тә атарга мөмкин:
-проектның темасын, максатын һәм проблемасын билгеләү;
-проблеманың әһәмиятен нигезләү;
-проект башкару өчен укучыларның шәхси теләкләрен искә алып, төркемнәргә бүлү.

Укытучы бу этапта укучыларга проект өчен төрле темалар тәкъдим итә. Укучылар үзләре тәкъдим иткән темалар карала. Бу этап проектның иң демократик өлеше булып тора.Теге яки башка теманы сайлату өчен укучыга басым ясау, укучы башкарырга теләгән проектны кире кагу рөхсәт ителми.Укытучы ярдәме белән, укучылар үзләре кабул иткән проектның проблемасын, сюжетын, максат һәм бурычларын билгелиләр, куелган максатны тормышка ашыру юлларын эзлиләр.

2.Эшчәнлекне планлаштыру һәм проблемаларны чишү этабы яки “эшчәнлекне оештыру” дип тә атасак була (информация эзләү да шушында керә ала):
-мәгълүмат чыганакларын барлау, аны җыю  һәм туплау;
-проблемалы ситуацияләрдән чыгу юлларын эзләү;
-киләчәк нәтиҗәне презентацияләү формасын һәм алымын сайлау.

Укучылар бу этапта мәгълүмат эзлиләр, җыялар, тәртипкә китереп анализлыйлар, эшне планлаштыралар; укытучы белән киңәшләшеп, киләчәк нәтиҗәне презентацияләү формасын һәм алымын сайлыйлар; әзерлек һәм планлаштыру эшенә үзбәя бирәләр.

3.Проектны тормышка ашыру:
-анализ юлы белән табылган мәгълүматларны бер бөтенгә берләштерү, нәтиҗәне дәлилле аңлату. Укучылар үзләре башкарган эшкә анализ ясыйлар, уңышларын һәм кимчелекле якларын ачыклыйлар, нәтиҗә чыгаралар.

4.Проектны яклау, проект эшчәнлегенең нәтиҗәләрен бәяләү этабы.

Укучылар проектны презентациялиләр, башкаларны эш нәтиҗәләре белән таныштыралар, сорауларга җавап бирәләр, эшчәнлекләренә үзбәя бирәләр.Бу этап бигрәк тә әһәмиятле булып тора.Һәрбер проект уңышлы тәмамланырга тиеш. Проект эшенә ата-аналарны да җәлеп итү бик отышлы, ата-ана бала тормышында актив катнаша башлый.

Укытучы: киңәшче, юнәлеш бирүче, төзәтмәләр кертүче, рухландыручы,
илһам өстәүче.

Укучы: эзләнүче, идеяне тормышка ашыручы, мәгълүмат җыючы, фикерләүче,күзәтүләр нигезендә модель төзүче, барлыкка килгән нәтиҗәләрне анализлаучы, тәҗрибәләр үткәрүче, интернет материалларын кулланучы, проектны яклаучы.

Ата- ана: укучыга кирәкле мәгълүматны табарга ярдәм итүче, идеяләрне тулыландыручы, иҗади бала белән бергә кызыксынучы, бала белән көндәлек аралашучы ролен үтәүче.

Балалар эшенең күрсәткече: 1-4 классларда рәсем, инша,табышмак, шигырь, сүзлек һәм башкалар булырга мөмкин.

Проект эшенең нәтиҗәсе: 1-2 классларда мәгълүмат тупланган китап яисә альбом, 3-4 классларда проект эше презентация, сценарий, фильм, каталог һ.б ярдәмендә башкарылырга мөмкин.

Укучыларга проект эшчәнлегенә йомгак ясаганда:

1.Проект эшендә нәрсә кызыклы булды?

2.Аеруча нәрсә ошады?

3.Нинди яңалыклар белдең?

4.Бу теманы өйрәнүне дәвам итәр идеңме?

5.Киләчәктә нинди проект эшен дәвам итәр идең? -кебек сораулар бирергә була.

Йомгаклап шуны әйтәсебез килә: проект методын кулланганда уйлау мөмкинлекләре киң ачыла, логик фикерләү дәрәҗәсе үсә, төрле чыганаклар белән мөстәкыйль эшләргә, төрле чыгышлар ясарга өйрәтә. Ә иң кыйммәте - аларда үз нәтиҗәләрен күргәннән сон иҗат дәрте кабынуы.

*Фатхуллина Гузял Фагим кызы, Халикова Нурсина Далиф кызы,*
*Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районының "Аерым фәннәрне тирәнтен өйрәнүле 15 нче урта гомуми белем бирү мәктәбе" муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесенең югары категорияле татар теле һәм әдәбияты укытучылары*

## Яшь буында толерантлык тәрбияләү

Бүгенге көндә толерантлык темасы аеруча актуаль, чөнки беренче планга ирекле үсү һәм яшәү өчен кирәкле булган кыйммәтләр һәм принциплар чыга.

Аралашу культурасы проблемасы - мәктәптә, тулаем җәмгыятьтә иң кискен проблемаларның берсе. Бер-береңә карата түзеп тору мөһим, әмма бу җиңел түгел. Бүгенге көнгә укуның беренче көннәреннән үк толерантлык культурасы тәрбияләү зарурлыгы барлыкка килә. Балалар мохитында кызулык, мәрхәмәтсезлек, усаллык киң таралган. Бу бик тә аяныч. Моңа сәбәпләр бик күп. Үзара килешмәүчәнлек һәм әдәп-әхлаксызлык, телевидение, балаларны чолгап алган мохит - интернет аша уку йортларына дә үтеп керә.

Татарстан мәгариф системасы да, бүгенге тынычлыкка омтылу, кеше хокукларын яхшы белү, толерантлык, хезмәттәшлек, әхлаклылык кебек сыйфатлар бик нык таләп ителгән шартларда алгы планга белемле, милли һәм чит милләтләр мәдәниятен яхшы белүче, хөрмәт итүче шәхес тәрбияләүне куя. Халкыбызның хәдисләрендә дә “Әхлак - тумыштан яки уку өйрәнү һәм гаилә тәрбиясе белән ирешелгән рухи халәт. Сөйләгән сүзләрендә, эшләгән эшләрендә, ясаган хәрәкәтләрендә күпчелек тарафыннан дөрес дип табылган нәрсәләрне үтәгән кешеләрне әхлаклы кеше диләр” диелә.

Нәрсә соң ул толерантлык? Толерант - латин теленнән кергән. Ул - түземлелек, сабырлык, кеше нинди генә милләттән булуына карамастан, аның фикеренә, гореф-гадәтенә уңай карау дигәнне аңлата. Кешене барлык физик һәм дини үзенчәлекләре белән хөрмәт итү, сүзенә колак салу, игътибарлы булу. **Беренчедән**, төп максатыбызның берсе балаларда бер-беренә хөрмәт хисләре тәрбияләү. Балалар башкаларны тыңлый белергә, аларның фикерләренә дә колак салырга өйрәнергә тиеш. Яңа технологияләргә, аерым алганда иҗади үсеш технологиясенә нигезләнеп укытканда без бу юнәлештә уңышларга ирешә алабыз. **Икенчедән,** толерантлыкны икенче милләт вәкилләренә, чит дин кешеләренә, аларның мәдәниятенә, гореф-гадәтләренә, йолаларына түземлелек дип атарга мөмкин.

Бер милләт вәкиленең икенчесенә карата булган түземлелек (толерантлык) хисләрен тәрбияләүдә әдәбият дәресләренең әһәмияте зур. Әдәбият укытучысына - ул рус әдәбятын укытамы, татар әдәбиятынмы - үз фәне белән генә чикләнергә ярамый. Аңа үзе укыта торган әдәбияттан башка бүтән халыклар әдәбиятын, ул әдәбиятның тарихын да яхшы үзләштерү зарури. Татар һәм рус әдәбиятларын чагыштырып өйрәнү, ягъни интеграцияләү яшь буында башка милләттән булган яшьтәшләренә карата кызыксыну һәм ихтирам хисләре тәрбияләүдә мөһим урын алып тора.

Әдәбият, уку дәресләрендә әкиятләр уку, иллюстрацияләрен карау, әңгәмәләр уздыру, әкиятләрне сәхнәләштерү, катнашучы геройлар белән очрашу балаларда уңай тәэсир калдыра. Халык иҗатының җәүһәрләре изге, саф, киң күңелле, ярдәмчел, игътибарлы, мәрхәмәтле образлар аркылы балаларны да шундый ук булырга чакыра. Татар халкының “Алтын бөртекләр” әкияте түземлелек, тырышлык, сабырлык сыйфатларын алгы планга чыгара.

Татарстан республикасы күпмилләтле дәүләт. Биредә татарлар, руслар, удмуртлар, чуашлар, марилар, башкортлар һәм башка бик күп милләт халкы яши. Балаларга шушы төрле милләт халкының яшәешен, мәдәниятен, гореф-гадәтләрен шулай ук уеннары, милли бәйрәмнәре (Сабантуй, Масленица, Питрау, Сөмбелә, Нәүрүз һ.б.) аркылы өйрәтү зарури.

Толерантлык, ягъни гади генә әйткәндә түземлелек ике яклы, хәтта күп яклы булганда гына нәтиҗә бирә. Түзем булу белән беррәттән милли горурлык хисләре тәрбияләү, балаларның милли үзаңын арттыру янәшә торырга тиеш. Без балаларны толерантлык рухында, башка кешеләрнең хокукларын һәм иреген хөрмәт итәргә өйрәтеп тәрбияләүнең нәтиҗәле механизмнарын табырга тиеш.

*Хайруллина Лилия Аркадьевна,*
*Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районының "2 нче Кама Аланы урта гомуми белем бирү мәктәбе" муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесенең югары категорияле татар теле һәм әдәбияты укытучысы*

## Татар теле һәм әдәбияты дәресләрендә проект методын куллану

Федераль дәүләт белем бирү стандартлары (ФДБС) шартларында укытучы эшчәнлегенең нәтиҗәле юнәлешләреннән берсе булып проектлар методы санала.

Укыту процессында яңа педагогик технологияләрне куллану - яңа метод һәм алымнарны үстерергә, яңача эшләргә ярдәм итә. Без, татар теле һәм әдәбияты укытучылары, дәрестә өйрәнгән теманы җиңел юл белән үзләштерә торган, белем сыйфатын күтәрүгә файдалы булган проектлар методын куллану уңай күренеш дип саныйбыз.

**Проект методы** - нинди дә булса проблеманы өйрәнү һәм гамәли нәтиҗәсен күрсәтү өчен укучыларның мөстәкыйль эшчәнлегенә нигезләнгән укыту методы.

**Проект методын куллану түбәндәге бурычларны үти:**

- Эш барышы телне өйрәнүгә теләк уята.
- Проект эшен оештыру барышында укучылар үз - ара аралаша, укытучы тикшерүче ролен түгел, киңәшче ролен үти.
- Укучыны билгеле бер тема өстендә иҗади эшләргә, төрле чыганакларны кулланып, үзаллы мәгълүмат табырга өйрәтә, уку эшчәнлеге активлаша.

- Бөтен уку процессы укучыга юнәлтелә, аның кызыксынуы, тормыш тәҗрибәсе, шәхси сәләтләре искә алына.

Укучылар эшчәнлегенә карап, **проект төрләре бишәү:**

1. **Эзләнү проектлары**. Бу проектның төгәл структурасы булырга тиеш. Нинди дә булса проблеманы чишүгә, эзләнүгә нигезләнгән. Күпмедер дәрәҗәдә ул фәнни-эзләнү эшләре белән дә тәңгәл килә. Ахырда нәтиҗәләр чыгарыла һәм киләчәктә дәвам итү өчен яңа проблемалар яктыртыла.

**Үземнең эш тәҗрибәсеннән түбәндәгеләр:**

- берәр язучының иҗаты буенча проблемалы сораулар куеп, эзләнү эшләре алып бару;( Илдар Юзеевның – мәхәббәт җырчысы, икәнен дәлилләү.)

- язучының берәр әсәренә лингвистик анализ ясау;

- балалар газетасы яки журналына күзәтү ясау.

Рус төркемнәрендә укучылар белән 5 сыйныфта теманы өйрәнгәннән соң әдәбият дәресендә бик яратып “ Салават күпере”, “ Көмеш кыңгырау” газета - журналлары буенча проект эшләре башкарабыз.(журнал тарихы, аның рубликаларын өйрәнү, үз иҗатлары шул журналларга җибәрү өстендә эшлибез, нинди рубрикага туры килүен тикшерәбез,һ.б ).

Сыйныфтан тыш вакытта (түгәрәк вакытында) милли йолаларны торгызу максаты белән “ Туй йолалары: үткәне һәм бүгенгесе” темасы буенча эзләнү проекты өстендә эшләдек. Проект барышында укучылар туй тарихын, аңа бәйле йолаларны өйрәнеп, бүгенге көнгә кайсы йолаларның килеп җитүен тикшерделәр.Республиканың төрле районнарында туй белән бәйле йолаларның сакланышын билгеләделәр.Бигрәктә укучыларны “ Яшь киленгә су юлы күрсәтү” йоласы кызыксындырды, шул йола буенча эзләнү эше башкардылар. Нәтиҗәдә,“ Яшь киленгә су юлы күрсәтү йоласы” буенча сценарий төзелде.Эшне дәвам итү өчен яңа максатлар куелды.

**2. Иҗади проектлар**. Структураның төгәллеге таләп ителми. Алдан якынча гына төзелә, ә эш барышында киңәйтелә. Эш нәтиҗәсе -продукт - бергәләп иҗат ителгән газета, буклет, инша, видеофильм, спектакль (инсценировка), бәйрәм.

Безнең мәктәптә Аулак өй, Карга боткасы, Нәүрүз, Яңа ел бәйрәмнәре үткәрелә. Бу уеннар үзенә бер проект эшчәнлеккә әйләнә. Балалар проблемалы сорау куеп, проектның эш планын төзиләр. Башта алар бу бәйрәм турында мәгълүмат туплыйлар.Тупланган белемнәрен уртаклашалар һәм гомумиләштерәләр. Проектны яклау эше итеп, шушы бәйрәмнәрнең берсен үткәрү алына. Соңыннан рефлексия ясала, бәйрәм турында фикер алышына.

Рус төркемнәрендә дәрестә инценеровкага урын бирәбез.“Тавык,тычкан һәм көртлек”, “ Койрыклар” әкияте белән дәрестә танышканнан соң, проект эше билгеләнә. Нинди рус әкиятенә ошаган, нинди аермалы яклары бар тикшерелә, геройларга характеристика бирелә, рольләргә бүленеп, төркемнәр чыгыш ясарга әзерләнә.

Югары сыйныфлар белән “Һөнәр сайлау” бүлеген тәмамлагач, проект эше башкарабыз.Укучылыр өчен “Ин куркыныч һөнәрләр” “Заманча һөнәрләр”, “ Онытылып баручы һөнәрләр”,“Иҗади һөнәрләр”, һ.б темаларга бүленеп төркемнәрдә, парларда эш башкарыла.Проектны яклаганда укучылар формасын үзләре сайлый, кемдер презентация рәвешендә, кемдер буклет рәвешендә эшләрен яклый,укучылырга бу эш төре бик ошый, эшне кызыксынып башкаралар.

**3.Уенлы (рольле) проектлар.** Шулай ук структурасының төгәл булуы мәҗбүри түгел, эш ахырына кадәр ачык булып кала. Мондый очракта балалар үзләренә нинди дә булса роль алалар. Ул әдәби персонаж да, уйлап чыгарылган герой яки әкият герое да, ситуациядән чыгып, эшлекле мөнәсәбәттә булган һөнәр иясе дә булырга мөмкин.

Мәсәлән, 4 сыйныфта Вахит Монасыйповның “Шифалы табиблар” хикәясен өйрәнгәннән соң укучыларда шифалы үләннәр турында күбрәк белү теләге уянды. Балаларга рольләр бүленеп бирелде: энциклопедист, табиб, журналист, рәссам. Энциклопедист үләннәрнең кайда үсүе, буе, озынлыгы, ничә ел яшәвен тикшерә. Табиб медицинада нинди урын алып торуы, текст буенча нинди авыруларны дәвалавын өйрәнә. Ә журналист халыкның көнкүрештә ничек файдалануы турында мәкалә яза.Рәссам дару үләннәрен рәсемгә төшерү биремнәре ала.

**4. Мәгълүмати проектлар.** Факт һәм статистикага нигезләнеп, берәр күренеш яки объект турында мәгълүмат җыюга корылган. Эзләнү проектындагы кебек төгәл структурасы булырга тиеш. Бу проект күп очракта эзләнү проекты элементлары белән үрелеп тә китә. Эш нәтиҗәсе-продукт итеп мәкалә, реферат, чыгыш, видео, презентацияләрне алырга һәм аны киң аудиториягә тәкъдим итәргә мөмкин.

Мәсәлән, берәр язучының тормыш юлы буенча эш оештырам.

**Язучы иҗаты буенча проект эше:**

- Портрет характеристика бирү;
- Бөек кешеләрнең язучы турында әйткән сүзләре;
- Язучының тормышы һәм иҗаты буенча презентация ясау ;
- Викторина төзү;
- Әсәрләре буенча иллюстрацияләр;
- Язучы һәм сәнгать ( музыка, сынлы сәнгать);
- Буклет чыгыру,

Үзебезнең төбәктән чыккан артистлар һәм аларның театр сәнгатенә керткән өлешләре темасына проект эше башкарылды.

**5. Гамәли проектлар.** Проект өчен тема сайлаганда, укучылар фикерен искә алу әһәмиятле. Моның өчен аларның кызыксынуларына (хоббиларына) игътибар итәргә кирәк. Эш

нәтиҗәсе-продукт алдан ук күзаллана һәм аның киләчәктә гамәли файдасы, ягъни кулланучысы булу шарт итеп куела.

***Мәсәлән түбәндәге эшләр үтәп була:***

- үзең төшергән фотосурәтләрне өстәп, сыйныф, мәктәп яки шәһәр тормышын яктырткан журнал чыгарып тарату;

- татар теле атналыгын яктырткан газета чыгару;

- берәр татарча видеодәресләр төшереп, Интернетка урнаштыру;

- әсәрләрне тәрҗемә итеп, китапханәгә китапчык тәкъдим итү.

- билгеле бер тема билгеләп мәкальләр туплау, аны китапчык итеп бастыру.

Рус төркемнәре яратып " Дүрт аяклы дусларыбыз" темасы буенча проект эшләре үти, видеопрезентацияләр әзерли.

7 сыйныфта(рус төркемнәре) "Милли киемнәр һәм бизәнү әйберләре" темасын өйрәнгәннән соң, мини -проект эшен башкарабыз.Һәр укучы үзенә ошаган милли киемне сайлап, аның тарихын, кулланышын, үзенчәлеген тикшереп, өйрәнеп, теләгән формада яклап чыга. (презентация, кул эшләре һ.б).

***Укучыларның проект эшләрен бәяләү:***

| **Бәяләү критерийлары. Анкета** | **Билге. Җаваплар.** |
|---|---|
| 1. Презентацияне бәяләү<br>• Кызыклы материал<br>• Матур бизәлеш<br>• Материалның бирелеше ( логик яктан)<br>• Презентацияне күрсәтү | |
| 2. Укучыларның телдән чыгышы:<br>• Аңлаешлы сөйләм<br>• Материалны дөрес аңлату<br>• Эмоцианальлек,сәнгатьле сөйләм | |
| 3.Публикацияне бәяләү<br>• Дизайн<br>• Статьялар сайланышы | |
| 4.Мондый эш төре ошадымы | |

| | |
|---|---|
| 5.Тагын нинди темага проект эше эшләр идең | |
| 6.Проект буенча синең сорауларың | |
| 7.Бәяләү нәтиҗәләре | |

**Татар теле һәм әдәбияты дәресләрендә**
**проект методын куллану.** *(мастер класс)*

**Проектның темасы:** “Сибгат Хәким – туган як җырчысы”.(Сибгат Хаким тормыш һәм иҗат юлын өйрәнү – шагыйрьнең юбилее уңаеннан).

**Проектның төре**: эзләнү – тикшеренү характерындагы эшчәнлек.

**Проектның максаты:** Сибгат Хакимнең тормыш һәм иҗат юлын тирәнтен өйрәнү.

**Проектның бурычлары:**

- Шагыйрьнең тормыш һәм иҗат юлын өйрәнү күнекмәләре формалаштыру;
- Укучыларның ораторлык сәләтләрен үстерү;
- Аларда югары әхлакый сыйфатлар тәрбияләү;
- Балаларга патриотик тәрбия бирү.

**Проектның эчтәлеге**

Проект тулысы белән Сибгат Хакимнең тормышын, иҗатын өйрәнүгә, укучыларда татар әдәбиятын өйрәтүгә кызыксыну уятуга юнәлдерелгән. Проект өстендә эш шагыйрьнең музеена видео- экскурция ясау белән тәгәлләнә.Проект укучыларны мөстәкыйль рәвештә информация табарга, аны анализларга, кирәк урында куллана белергә өйрәтә.

**Кирәкле җиһазлар:** Сибгат Хәким иҗаты һәм тормышы турында материаллар, Сибгат Хакимнең шигырь җыентыклары, язучы турында альбом, папка, файллар, принтер, диск, презентация, компьютер.

**Нәтиҗәсе**: эзләнү-тикшеренү эшләрен папкага туплау, презентация әзерләү, тыңлаучылар каршында чыгыш ясау.

**Проектны башкаручылар:** 11 нче сыйныфның ике төркем укучылары

**Проект өстендә эшләү этаплары:**

1. Сибгат Хакимнең тормыш һәм иҗаты турында тирәнтен өйрәнү .

Шагыйрь турында үстәмә материал туплау һәм презентация әзерләү.

2.Сибгат Хаким иҗатын тематикаларга бүлү, эзләнү – тикшерү эшенең юнәлешен билгеләү.

3. “Сибгат Хаким -туган як җырчысы” икәнен дәлилләү,шигырьләрен сайлау.

4. Эш бүлешү (чыгышлар, шигырьләр, компьютерда бастыру, презентация әзерләү).

5. Проектны яклау.

Проект эшендә катнашып, укучылар үзләрен кызыксындырган өлкәдә белемнәрен арттыру белән бергә

- үзләренә максат куярга, аңа ирешү юлларын планлаштырырга;
- мөстәкыйль мәгълүмат табарга, аны аерырга һәм гомумиләштерергә;
- үз эшләренә төзәтмәләр кертергә, контрольдә тотарга, бәя бирергә;
- бер-берсе белән килешеп, төркемнәрдә эшләргә;
- үз фикерен әйтү өчен тел чараларын кулланырга;
- аудитория алдында сөйләргә;
- башланган эшне ахырына кадәр җиткерергә өйрәнәләр.

Шулай итеп, уку-укыту эшчәнлеге ФДГББСның фундаменталь үзәген тәшкил итүче универсаль уку гамәлләре белән кораллана. Шундый эш алымнары ярдәмендә үткәрелгән дәресләр укучыларда телгә, әдәбият дәресләренә кызыксыну, сөю тәрбияли. Гомумән, иҗади дәресләр генә эзләнүчән, бай рухлы, зирәк, сәләтле шәхесләр тәрбияләүгә булышлык итә. Проект эшчәнлеге, минемчә, сүз тәрбиясеннән күчеп, тормышның үзендә һәм тормышның үзенә тәрбияләү юлын ача.

*Хайруллина Лилия Миннефаяз кызы,*
*Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районының 26нчы урта гомуми белем бирү мәктәбе» муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесенең беренче категорияле татар теле һәм әдәбияты укытучысы*

**Татар теле һәм әдәбияты дәресләрендә инновацион технологияләр куллану**

**Инновация турында төшенчә**

Мәгариф системасы гомер-гомергә традицион укыту методикасына нигезләнеп үсте. Әлбәттә инде, гасырлар буена тупланган тәҗрибәгә таянмыйча мөмкин түгел. Шулай да, тормыш бер урында тормый, заманалар үзгәрә бара. Димәк, яңалыкларны да исәпкә алмыйча эш итәргә ярамый. Бүген без техника зур тизлек белән үсеш алган инновацияләр чорында яшибез. Мәгълүмати технологияләр тормышның барлык өлкәләренә үтеп керде. Белем бирү өлкәсе дә моннан читтә калмады – заманча техника белән җиһазландырылган мәктәпләр барлыкка килде, укытуда яңа методик алымнар, технологияләр кулланыла,укучыларның

белемнәрен тиз генә тикшерергә мөмкинлек бирә торган күнегүләр һәм мәсьәләләр файдаланыла. Мәгарифне инновацион үстерү-республикабыз һәм илебез киләчәгенең нигезе. Шуңа күрә белем бирүдә инновацион юнәлешне үстерү-төп бурычларның берсе.
«Инновация» (яңа, заманча) термины XIX гасырдан ук кулланылышта йөри. Фәнни әдәбиятта «яңалык» һәм «инновация» төшенчәләре төрлечә аңлатыла. Яңалык-укыту процессына караган яңа чара (метод, методика, технология һ.б.). Әлеге чараны үзләштерү процессын инновация дип йөртәләр. Инновацион технологияләрне укыту процессында файдалану-белем бирү сыйфатын күтәрүдә бик нәтиҗәле чара ул. Чөнки алар укуга кызыксыну тудыра, уку материалын тирәнрәк үзләштерү теләге булдыра, укучыларның иҗади сәләтен үстерү мөмкинлеген бирә. Теләп башкарылган эш кенә истә кала, баланың сәләтен, аңын үстерә. Әгәр материалны үзләштерү авыр, бертөрле икән, укучының күңеле суына, телне өйрәнергә булган теләге бөтенләй сүнергә дә мөмкин.
Әйе, бүгенге җәмгыятьтә күнегелгән күп мөннәсәбәтләр,традицияләр үзгәрә. Мәктәптәге укучы белән укытучы мөнәсәбәтләре дә бөтенләй икенчегә әйләнде: укытучы да, укучы да иҗатчыга әверелә бара.
Яңа нәтиҗәләргә ирешү, конкурентлыкка сәләтле, җаваплы, инициативалы һәм компетентлы гражданнар тәрбияләү- инновацион белем бирүнең төп бурычлары шулар.
Заманча технологияләр белән эшләү, укытучының үз эшенә иҗади якын килүен дә таләп итә. Ул инде укытучы буларак кына түгел, режиссер, укучы, яки башка рольгә кереп. укыту процессын оештыра.
Инновацион технология эчтәлеген ачуда эшчәнлек, ирек, бербөтен шәхес, өйрәнүченең ихтыяҗлары, кызыксыну һәм башка шундый төшенчәләр файдаланыла.
Без, татар теле укытучылары, бары тик яхшы әзерлекле укытучы гынабелем бирүне югары дәрәҗәдә алып барырга, укучыларда тыңлап аңлау,сөйләү, уку, язу өлкәсендә ныклы белем һәм күнекмәләр булдырырга сәләтле икәнлеген аңлыйбыз.
Шулай итеп, инновацион технология төп максаты итеп укучының белем алу эшчәнлеген активлаштыруны күздә тота дип әйтү дөрестер.
Элегрәк укытучы яңа теманы бик матур итеп сөйли, ә укучы бары гади үзләштерүче ролен үти иде: бүген исә, укучы яңа теманы үзе эзләүче, тикшеренүче сыйфатында үзләштерергә тиеш дип карала. Укытучы бу очракта укучыларның актив фикерләү эшчәнлеген, акылын, зиһенен үстерү өчен юнәлеш бирүче, әйдәп баручы ролен үти. Хәзерге шартларда, мәгълүматның күләме тиз үскән вакытта, кирәген сайлап ала белергә, тәртипкә китерергә, бәләкәй генә ачыш ясап куана белергә өйрәтү, юл күрсәтү- уку - укыту өчен авыр эш. Укучы теманы уйлап, фикерләп, эзләнеп аңлый икән, әлбәттә, аның белеме ныклырак, төплерәк була. Мәктәптәге традицион, бер төрле үткәрелгән дәресләр арасында, гадәти булмаган

дәресләр үткәрү укучыларның хәтерендә ныграк кала. Ялкыткыч эш төрләрен һәр дәрестә кат-кат башкаруга караганда кызыклы ачышлар булганы укучының күңеленә тәэсир итә, аң-белемен киңәйтә, иҗади эзләнүгә теләк тудыра. Шуңа да соңгы вакытта укучының белем сыйфатын күтәрүдә, иҗади сәләтләрен үстерүдә яңа технологияләрне өйрәнү һәм дәрестә куллану турында күп сөйләнелә, языла.

Хәзер татар теле һәм әдәбиятын укыту күпкә катлауланды. Укытучы алдында җаваплылык артты: мәктәптә укытылган дистәләгән фәннәр арасында балага татар телен абруйлы итеп өйрәтү, балада шушы фәнгә карата гомер буена җитәрлек горурлык хисе тәрбияләү, туган тел матурлыгын онытылмаслык итеп күңеленә сеңдерү. Дәрес шәхес күңелен кузгатырлык булырга тиеш. Заманча технологияләр белән эшләү укытучының үз эшенә иҗади якын килүен дә таләп итә. Ул инде укытучы буларак кына түгел, режиссер, укучы, нинди дә булса эшкә (мәсәлән, уенга) җитәкчелек итә, консультант яки башка рольгә кереп, укыту процессын яңача оештыра.

Башта бу юнәлеш буенча төгәл фәннәр эшли башлаган. Хәзер исә татар теле укытучылары да башка фән укытучылары белән рәттән заманча технологияләрне файдаланып белем бирәләр. Бүгенгесе көндә татар теле һәм әдәбиятын укыту күпкә катлауланды. Хәзер укытучыдан бик күп нәрсә таләп ителә: мәктәптә укытылган дистәләгән фәннәр арасында балага татар телен абруйлы итеп өйрәтү, шушы фәнгә карата кызыксыну, горурлык хисе тәрбияләү, үз фәнеңне бик яхшы белү, балаларны яратудан тыш, аларның фикерләү сәләтен үстерү, уку-танып белү эшчәнлеген оештыру, рухи һәм физик үсешен тәэмин итү. Ә моның өчен мөгалимнән үз шәхесенә тәнкыйть күзлегеннән карау, яңалыкка омтылу, заман сулышын тоеп эшләү сорала. Бүгенге балалар мәгълүмати технологияләр белән бик иртә таныша. Хәзер балалар бакчасында ук заманча технологияләрне үзләштерү мөмкинлеге тудырылган. Әгәр дә элек мәктәп баласы өчен мәгълүмат чыганагы булып китап һәм мөгаллим торса, бүген ул барлык кызыксындырган сорауларга җавапны интернет челтәре аша да таба ала. Шуңа да хәзерге педагоглар үсмерләрне үз фәне белән кызыксындыру, аларның игътибарын җәлеп итү өчен төрле хәйләләр уйлап табарга — шул ук мәгълүмати технологияләрне үзләштерергә һәм аларны укыту процессында кулланырга тиеш. Уку-укыту процессына яңа технологияләрне кертеп җибәрү бүген көн тәртибенә куелган мәсьәлә.

Хәзерге көндә мәгълүмати белем чыганаклары уку-укыту системасында аерылгысыз бер тармак булып тора. Нәрсә соң ул мәгълүмати белем чыганаклары? Мәгълүмати белем чыганаклары - укыту процессын оештыруда мөһим булган фотосурәтләр, видеоматериаллар, динамик модельләр, тавыш язмалары һәм башка укыту материаллары ул . Шунлыктан мәктәпләр интерактив такталар, мультимедиа проектлары белән җиһазлана, дәресләрдә компьютерлар кулланыла.

Заманча технологияләрнең түбәндәге төрләрен күрсәтеп була: 1) шәхескә юнәлтелгән технологияләр;. 2) укучылар эшчәнлеген активлаштыру һәм интенсивлаштыруга нигезләнгән педагогик технологияләр; а) уен технологиясе; б) проблемалы укыту; в) аралашуга өйрәтү технологиясе. 3)уку процессын оештыру һәм идарә итүнең нәтиҗәлелегенә нигезләнгән педагогик технологияләр. а) терәк схемаларны кулланып, алга китеп укыту технологиясе; б) белем бирүнең компьютер технологияләре; в) интенсив белем бирү технологиясе.

**Заманча технологияләрне татар телен чит тел буларак укытканда куллану.**

Мин үземнең эш тәҗрибәмдә түбәндәге заманча технологоияләргә мөрәҗәгать итәм: 1) уен технологиясе; 2) компьютер технологиясе, проблемалы укыту технологиясе.

Уеннар файдалану укучыны белем алуга, укуга дәртләндерә, анда фән белән кызыксыну уята. Уен технологиясен яңа материалны аңлатканда һәм ныгытканда, сөйләм телен үстергәндә кулланырга мөмкин. Әлеге технология балаларның иҗади сәләтен үстерә, фикерләү дәрәҗәсен арттыра, дәресне җанландыра, кызыклы итә. Уйный-уйный белем алганда, телдән үзләштерә торган материал җиңел ныгытыла һәм мавыктыргыч була, балаларның күзәтүчәнлеге арта. Тик әлеге эш төрен оештырганда, мин укучыларның яшь үзенчәлеген истә тотып, аны дәрестә урынлы кулланырга тырышам.

Мәсәлән: 1нче сыйныфта фигыльләрне өйрәнгәндә укучылар “Ватык телевизор” уенын кызыксынып уйныйлар. Телевизор ватылган, тавышы юк. Бер укучы такта янына чыга. Мин аның колагына фигыльнең беренче формасын пышылдап әйтәм, укучы моны хәрәкәт белән күрсәтә. Калган укучылар фигыльне хәзерге заман формасында әйтеп бирәләр.

Һава торышын тасвирлаганда, төрле ситуацияләр бирәм, “Синоптиклар” уенын үткәрәм. Уеннарда шулай ук күрсәтмәлелек файдалану (киемнәр, уенчыклар, муляжлар, маскалар) яхшы нәтиҗә бирә. Аларны кулланып, кибеттә әйберләр алу, бүлмәне җиһазлау, өстәл әзерләү турында сөйләшергә, киңәшләшергә мөмкин. Рольле уеннарның ситуацияләрен укучылар үзләре дә тәкъдим итә. Иң кызык уеннарның берсе — курчак театры оештыру, әкиятләрне сәхнәләштерү. Сәхнәләштерелгән уеннар иҗади хыялны, уйлау сәләтен үстерә. Алар уку эшен җанландыра, төрләндерә, сөйләм телен үстерүгә уңай йогынты ясый.

Г.К.Селевко, үткәрү максатыннан чыгып, уеннарны берничә төркемгә бүлә:

-дидактик уеннар;

-тәрбияви уеннар;

-үстерешле уеннар;

-социальләштерүче уеннар.

Дидактик уеннарны укучыларның белем дәрәҗәсен, танып белү эшчәнлеген камилләштерү өчен кулланабыз. Тәрбияви уеннарны әхлак тәрбиясе бирү, рухи сыйфатлар, сәламәт яшәү рәвеше тәрбияләү максатыннан үткәрәбез. Укучыларның сөйләм телен

үстерүдә, эзлекле фикер йөртү сәләтләрен формалаштыруда үстерешле уеннар ярдәм итә. Укучылар бигрәк тә рольле уеннарны яраталар.Рольле уеннар укучыларның коммуникатив эшчәнлеген активлаштыра, үзара ярдәмләшү теләге тудыра.
Рольле уеннар диалогик сөйләмне үстерүдә бик нәтиҗәле чара булып тора. Мәсәлән, “Ашханәдә”, “Кибеттә”, “Базарда”, “Туган көнгә чакыру” кебек рольле уеннар бик кызыклы. Башлангыч сыйныфларда, мин бу алымны аеруча яратып кулланам. Рольле уенда парлап һәм төркем составында да катнашырга була. Төркем белән эшләгәндә, әкиятләрне үзгәртеп, тулыландырып, өстәмә сораулар ярдәмендә коммуникатив максатка ирешәм.

Проблемалы укыту технологиясе XIX гасыр ахырында кулланылышка керә. Ул Америка галиме Дж.Дьюн теориясенә нигезләнә. Проблемалы укыту-укытучының укучылар белән берлектә проблемалы ситуацияне хәл итү юлларын эзләү процессы. Балаларның фикерләү сәләте камилләштерелә, ныклы белем һәм күнекмәләр формалаша.Проблемалы укыту технологиясен кулланып укыткан укытучылар саны көннән-көн арта.
Укучыларда интеллектуаль көч яңа вакыйга, төшенчәләрне аңларга Һәм фикер аша үткәрергә тырышкан вакытта кыенлыкларга очраганда барлыкка килә һәм ул проблемалы ситуациянең тудырылуын, тема белән тирәнтен кызыксынуны, аны хисси кабул итүне һәм укучының ихтыяр көченә ия булуын таләп итә. Проблемалы укыту процессында укытучы уку-танып-белү эшчәнлеген фактларны анализлау нигезендә укучылар нәтиҗә Һәм гомумиләштерүләр ясарлык итеп оештыра. Эчке (логик-психологик) үзенчәлектән чыгып караганда укытучы аңлы рәвештә проблеманы ситуация тудыра торган дәресне проблемалы дәрес дип атыйлар. Шунысы да әһәмиятле: әгәр укытучы дәрестә уңай психологик халәт тудыра алса, уңышка китерәчәк ситуация уйлап таба алса, үз эшен яратса, укучыларны хөрмәт итсә, ул һичшиксез зур уңышларга ирешәчәк . Балалар үзләренә булган игътибарны күреп үзләрен ятратуларын, үзләренә ышануларын тоеп яшәргә тиеш.
Бүгенге балалар мәгълүмати технологияләр белән бик иртә таныша. Хәзер балалар бакчасында ук заманча технологияләрне үзләштерү мөмкинлеге тудырылган. Әгәр дә элек мәктәп баласы өчен мәгълүмат чыганагы булып китап һәм мөгаллим торса, бүген ул барлык кызыксындырган сорауларга җавапны интернет челтәре аша да таба ала. Шуңа да хәзерге педагоглар үсмерләрне үз фәне белән кызыксындыру, аларның игътибарын җәлеп итү өчен төрле хәйләләр уйлап табарга — шул ук мәгълүмати технологияләрне үзләштерергә һәм аларны укыту процессында кулланырга тиеш. Уку-укыту процессына яңа технологияләрне кертеп җибәрү бүген көн тәртибенә куелган мәсьәлә.
Хәзерге көндә мәгълүмати белем чыганаклары уку-укыту системасында аерылгысыз бер тармак булып тора. Нәрсә соң ул мәгълүмати белем чыганаклары? Мәгълүмати белем чыганаклары - укыту процессын оештыруда мөһим булган фотосурәтләр, видеоматериаллар,

динамик модельләр, тавыш язмалары һәм башка укыту материаллары ул . Шунлыктан мәктәпләр интерактив такталар, мультимедиа проектлары белән җиһазлана, дәресләрдә компьютерлар кулланыла.

Компьютер – укучы белән белемнәр системасы арасында арадашчы, белем алу чарасы. Компьютердан файдалану укыту эшчәнлеген баета, укыту процессын кызыклы, нәтиҗәле һәм иҗади итеп оештырырга мөмкинлек бирә. Компьютер сыйныф тактасын да, тарату материалын да, дәреслекләрне дә алыштыра ала. Аны куллану дәреснең нәтиҗәлелеген арттыруга ярдәм итә. Һәр укучының белем үзләштерүгә сәләте төрлечә була. Кайбер укучыларның ишетеп истә калдыру дәрәҗәсе өстенлек алса, күпчелек укучыларда күреп истә калдыруы өстен чыга. Менә шушы вакытта компьютер ярдәмгә килә. Чөнки мониторда барлык биремнәр матур, эстетик яктан камил эшләнә.

Үзем эшли торган 3 нче гимназиядә дә барлык шартлар тудырылган. Татар теле һәм әдәбияты кабинетлары компьютер, интерактив такталар , мультипроектор белән җиһазландырылган. Һәр дәрестә яңа технологияләр куллану мөмкинлеге бар. Презентацияләр төзегәндә, мин аның эченә бик күп материал: төрле схемалар, рәсемнәр, фотосурәтләр кертергә тырышам.

Мин үз дәресләремдә бик еш интерактив тактага мөрәҗәгать итәм, чөнки интерактив такта куллану дәресләрне тагы да мавыктыргыч, нәтиҗәле итәргә ярдәм итә. Мин рус төркемнәрендә эшлим. Әдәбият дәресләрендә без язучылар, шагыйрьләр турында прензентацияләр төзибез. Укучылар мөстәкыйль рәвештә фотосурәтләр, төрле схемалар, рәсемнәр белән прензентацияләр әзерлиләр. Биремнәрне матур итеп,эстетик яктан камил итеп башкарырыга тырышалар. Мәсәлән, 5 нче сыйныфта Г. Тукай, Ф. Кәримнең тормыш һәм иҗатлары турында укучылар прензентацияләр әзерләп килделәр. Укучылар бу биремнәрне теләп, авырсынмыйча башкардылар. Әлбәттә, ниндидер аңлашылмаучанлык булганда минем ярдәм дә кирәк була. Күпчелек укучылар материалны күреп истә калдыра, ә әлеге чараны куллану кирәкле мәгълүматны хәтердә калдырырга нык ярдәм итә. Шулай ук башка сыйныфларда да компьютер технологияләрен кулланабыз, бу инде беркем өчен дә яңалык түгел дип уйлыйм. Укытуны интенсивлаштыру өчен тестларны нәтиҗәле дип саныйм. Укучыларның теманы үзләштерү дәрәҗәсен тикшерү, белемнәрен бәяләү, ялгышларын ачыклау, аларны анализлау һәм төзәтү юлларын билгеләү өчен тестлар бик уңайлы. Компьютер технологияләре ярдәмен түбәндәге эш төрләрендә дә кулланам:Текст белән эшләү. Презентация ярдәмендә сүзлек, тикшерү диктантларын яки контроль күчереп язуларны тикшерергә уңайлы. Моның өчен мин бер слайдта хәрефләре төшеп калган яки хаталы текстлар бирәм. Эшне башкаргач, укучылар бер-берсе белән дәфтәрләрен алмашалар һәм алдагы слайд ярдәмендә тикшерәләр. Төшеп калган хәрефләр, хаталар башка төс белән

бирәм. Киләсе слайдта бәяләү критерияләре күрсәтелә. Укучылар билгеләрне үзләре куялар. Биредә укучыга җавап вариантларын сайлап алу гына түгел, аларның дөреслеген тикшерү мөмкинлеге дә тудырыла. Бер- берсен мактыйлар, хаталарны төзәтергә киңәшләр бирәләр. Төрле темага күрсәтмә материаллар һәм укыту ресурсларын бик күп табарга һәм аларны кабат-кабат файдаланырга мөмкин. Бу алым укучыларның белем сыйфатын үстерергә ярдәм итә. Укучылар интерактив тактага бик тиз күнегәләр. Зур экран бергәләп эшләргә мөмкинлек бирә. Сыйныфта интерактив тактаның барлыкка килүе хәтта иң проблемалы укучыларга да укуга карата карашларын үзгәртергә этәргеч ясый. Соңгы парта артында утырган бала кинәт активлаша һәм иҗади фикер йөртә башлый.

Шулай итеп интерактив такта укучыларда эшләү активлыгын гына арттырып калмый, ә яңа материалны һәр укучыга җиңел, аңлаешлы итеп җиткерергә дә ярдәм итә.

Шулай ук дәресләрдә Интернет ресурсларны куллану гаять зур мөмкинлекләр бирә. Интернет челтәре укучыга һәм укытучыга кирәкле мәгълүматны җир шарының төрле ноктасыннан эзләп табу шартларын тудыра.

Татар теле дәресендә Интернет ярдәмендә уку, язу күнекмәләрен булдыру һәм үстерү, кирәкле материал табу, укучыларның сүзлек запасын баету, татар телен өйрәнүгә мотив формалаштыру кебек дидактик бурычларны үтәргә мөмкин. Укучылар Интернет челтәрендә үткәрелә торган тестларда, викториналарда, конкурсларда, олимпиадаларда катнаша, яшьтәшләре белән аралаша алалар.

Соңгы вакытта шулай ук дәресләребездә сингапур структураларын куллана башладык. Сингапур методикасының максаты булып түбәндәгеләр билгеләнә ала:

- дәресләрдә, «өйрәтү структурасы»н кулланып, үзенчәлекле мохит булдыру;
- пассив, ваемсыз укучыларны кызыксынучан, бер-берсе белән эшлекле формада аралаша белүчеләргә, актив хезмәттәшлек итүчеләргә, кискен фикер йөртүчеләргә әйләндерү;
- укучының критик һәм креатив фикерләвен булдыру;
- укучыны кирәкле мәгълүматны мөстәкыйль эзләргә һәм табарга өйрәтү.

Әлеге методика биш модульне үз эченә ала: “Критик фикерләүне үстерү”, “Үзара хезмәттәшлектә белем бирү”, “XXI гасырда белем бирүнең үсеш тенденциясе”, “Проблемалы укыту”, “Инновацион төркемнәр булдыру”.

Әлбәттә, һәр модульне ныклап өйрәнергә, аның асылына төшенергә кирәк. Максатыма ирешү өчен, әлегә түбәндәге модульләрне өйрәнәм: «Үзара хезмәттәшлектә белем бирү» һәм «Критик фикерләүне үстерү».

«Үзара хезмәттәшлектә белем бирү» модуленең хасиятләре:

- укытучы тәкъдим иткән биремне укучылар парлап яки төркемләп эшлиләр;
- сыйныфтагы һәр укучы бер-берсе белән фикерләшә;

- укытучы тарафыннан җиткерелгән һәр мәгълүмат баланың хәтерендә кала һәм аны уйлау, фикер йөртүгә этәрә;
- сыйныфта һәр укучының актив эшчәнлеге күзәтелә.
«Үзара хезмәттәшлектә белем бирү» модуленә караган түбәндәге структураларны татар теле һәм әдәбияты дәресләрендә кулланам:
«Таймд пэа шэа» (Татар теле (5 нче сыйныф): «Эшли ала» конструкциясе)
"Микс-Фриз-Груп"(Башлангыч сыйныфларда физминуткалар үткәргәндә)
"Джот-Тотс" , "Тик-Тэк-Тоу"(4 сыйныф, татар теле, "Сыйфат")
"Раунд-Робин"(5 нче сыйныф, "Фигыльнең хәзерге заман формасы",татар теле)
"Намбэ-Ап"(физминуткалар, төрле сыйныф укучылары өчен)
Шул рәвешле, әлеге структураларны татар теле һәм әдәбияты дәресләрендә файдалану, укучыларны хезмәттәшлек итәргә, үз фикереңне җиткерә, башкаларныкын тыңлый белергә өйрәтә, төркемдә эшли белү күнекмәләрен үстерә, дәрестә һәр укучының эшчәнлеген активлаштыра.
Тагын бер үзенчәлекле модуль - «Критик фикерләүне
үстерү» модуле. Аның төп сыйфатлары:
- укучының критик һәм креатив фикерләве арта;
- белем алучы теге яисә бу тема, проблемага кагылышлы фикер төрлелеге булуы мөмкинлеге хакында белә;
- укучы кирәкле мәгълүматны мөстәкыйль эзләргә һәм табарга өйрәнә.
Сер түгел, укучылар матур әдәбият әсәрләрен бик аз укый.ләкин бер техник чара, иң яңа буын компьютер да тере җанлы әдәби әсәрнең үзен, аның телен, моңын, фикер тирәнлеген алыштыра алмый. Бигрәк тә-укытучының үзен, аның белем бирү процессын.
Баланы үзе теләп, мавыгып әдәби әсәр укырга укытучы өйрәтә. Моңа бары тик баланы яратып, аңа күңел җылыңны биреп , аның белән бергәләп рухи хезмәт башкарып кына ирешеп була! Җанлы аралашуны бер техник чара да алыштыра алмый.Педагогика фәнендә укыту-тәрбия процессы сыйфатын үстерергә булышлык итүче технологияләр бик күп. Укытуның һәр этабы өчен уку материалын аңлатуның иң уңышлы вариантын табу-укытучының бурычы

**Информацион технологияләр – укучыларның гомуми эрудициясен киңәйтүдә зур роль уйный.**

Татар теле дәрес буларак укытыла башлаганнан бирле (XVIII гасырда Сәгыйть Хәлфин эшчәнлеге белән бәйле) һәр чор укытучылары һәм методистлары укытуны камилләштерү ысул һәм алымнарын булдырырга тырышканнар. 21 нче гасырда укытучы һәм укучы арасындагы уңай эмоциональ халәт, укучыларда белем алуга мотивация булдыру,

балаларга төпле теоретик белем бирү белән беррәттән аларның сөйләм телен үстерүгә дә урын бирүне үз эченә ала. Бүгенге информацион технологияләр үсеше һәм техника алгарышы заманында исә татар теле һәм әдәбияты укытучысы алдына укучыларның гомуми эрудициясен киңәйтү максаты да килеп баса.

Әхмәт Зәки улы Рәхимовның “Укучыларның иҗади фикерләвен үстерү технологиясе”, Ф.Г.Казыйханова, В.С.Казыйхановларның “Иҗади үстерелешле технология”ләренә нигезләнеп, гомуми эрудицияне киңәйтү татар теле дәресенең коммуникатив һәм тәрбияви максатларын тормышка ашыру белән бергә үрелеп барырга, шул ук вакытта бирелгән теоретик белемне ныгытуга да хезмәт итәргә тиешлеге күз уңында тотыла. Татар теле дәресләрендә татар халкы этнографиясе һәм тарихы турында мәгълүмат бирү укучыларның гомуми эрудициясен киңәйтүгә йөз тота торган мәгълүматлар тупланмасын тәкъдим итү чарасы булып тора. ФГОС таләпләре буенча укучы дәреслектә эшчәнлекнең нәтиҗәсен, материалны үзләштерү дәрәҗәсен бәяләп барсын иде: “бусы - үземнеке, бусы - иптәшемнеке”. Бала мөстәкыйль тикшерү алып бара, йомгаклый, нәтиҗә чыгара, үзен-үзе бәяли. Укучылардан әледән-әле “Хаталы сүзне төзәтү”, “Махсус хата ясау”, “Мин нәрсәне беләм һәм нәрсә белмим?”, “Нәрсә эшләнде?”, “Эш ничек башкарылды?” кебек регулятив эш төрләренә җаваплар эзләтергә кирәк.

Мондый төр мәгълүматны презентацияләр, видеороликлар ярдәмендә тәкъдим итәргә мөмкин. Әлбәттә, аларны әзерләү һәм дәрес тукымасына кертеп җибәрү укытучыдан зур әзерлек таләп итә. Әзерлек барышында татар халкының этнографиясе һәм киенү рәвеше турында язылган күпләгән монографияләрне кулланырга мөмкин. Күрсәтмәлелек принцибын тормышка ашыру максатыннан татар халкының милли киемнәре, бизәнү әйберләре, эш кораллары, йорт-җире фоторәсемнәрен, әлбәттә, интернет сайтларыннан алырга мөмкин. Тик, минем күзәтүләремә караганда, андагы материал бик бай түгел, шуңа күрә укытучы үзе күпсанлы музейларда булырга, аларның экспонатлары белән якыннанрак танышырга һәм фотога төшереп, әлеге фотосурәтләрне үз презентацияләрендә куллана алырга тиеш.

Дәрестә әлеге төр мәгълүматны бирүне системалы итеп оештырырга була. Әйтик, 5 нче сыйныф укучыларына күбрәк рәсемнәр кулланылган, җиңел формадагы информация бирү кулайрак булса, шул ук вакытта уен элементлары белән аралаштыру да укучыларның информацияне кабул итү һәм белем алуга мотивация булдыру файдасына. Тора-бара, югары сыйныфларга якынлашкан саен, материалны катлауландыра барырга мөмкин, югары сыйныф укучылары фәнни-тикшеренү эше алып барып, үзләре дә аерым бер темага доклад, реферат, презентация әзерли ала.

Мондый төр дәресләр үткәрүнең актуальлеге бәхәссез. Беренчедән, бүгенге көндә мәктәпләрдә татар халкы тарихы бик аз күләмдә укытыла яисә бөтенләй укытылмый. Шуңа

күрә татар теле дәресләрендә, коммуникатив һәм тәрбияви максатларны күздә тотып, кызыклы этнографик-тарихи темаларны яктырту укучыларга үз халкының үткәне турында күпмедер күләмдә мәгълүмат биреп, аларда татар тарихын өйрәнүгә мотивация булдыра. Икенчедән, бүгенге көн укучыларында татар халкының гореф-гадәтләре, традицияләре турында күзаллау бик шартлы. Бигрәк тә зур шәһәрләрдә яшәүче балалар өлкән буын вәкилләре – әби-бабаларыннан читтә яши, шуңа күрә аларда татар халкының гасырлар дәвамында формалашкан гореф-гадәтләре турында хәбәрсез булып калуы ихтимал: “Әбиләрегез яшь чакта кульяулыклар чиккәндер, күргәнегез, сораганыгыз бармы?” - дип сорагач, балалар “без әби белән яшәмибез, ул аерым яши” яки “әби-бабай үлгән, йортлары сатылган инде”, диләр. Өченчедән, мондый тип информация укучыларда милли музейларга һәм аларның экспонатларына кызыксыну уята, укучылар музейга барыр алдыннан да күпмедер күләмдә мәгълүмат ала. Гомумән, социомәдәни компетенцияне тел материалы белән бергә үреп, диалогик яки монологик сөйләм итеп үткәргәч, укытучы үзе укучыларны музейга алып бара ала, музейга барырга теләк белдерүчеләр саны бермә-бер арта. Дүртенчедән, укучыларда татар халкының дөнья цивилизациясенең бер өлеше булуын, аның үз милли киенү рәвеше, күзаллаулары, гореф-гадәтләре, рухи һәм материаль байлыгы барлыгы турында фикер урнаша.
Ә тәрбияви максаты татар милли бизәкләре, татар халкының киенү үзенчәлекләре, гореф-гадәтләре, аш-су осталыгы, кулдан эшләнгән эш кораллары турында мәгълүмат бирү, укучыларда үз халкының гореф-гадәтләренә, этнографик үзенчәлекләренә ихтирам-хөрмәт уяту, горурлык хисе тәрбияләү булган дәресләр комплекслы тәкъдим ителсә, укучыларыбызда үз халкы мәдәнияте турында тулы күзаллау булдырырга мөмкин. Шул рәвешле бүгенге заман 21 нче гасыр укытучысы татар телен һәм әдәбиятын өйрәтү белән беррәттән, укучыларда, ягъни киләчәк буын вәкилләрендә, үз үткәненә, тарихына, мәдәни мирасына ихтирам-хөрмәт тәрбияли, димәк, һәр бала үз-үзен яратырга, әби-бабасын, әти-әнисен хөрмәтләргә өйрәнә.

**Йомгак.**

Хәзерге шатрларда татар телен дәүләт теле дәрәҗәсендә гамәлгә кертү өчен, объектив шартлар җитәрлек. Ә татар телен дәүләт теле дәрәҗәсенә күтәрү, иң беренче чиратта, мәктәпләр эшчәнлеге белән бәйле. Шунлыктан, татар телен чит аудиториядә укытуны мөмкин кадәр нәтиҗәлерәк итү – бүгенге көн педагогикасының мөһим бурычларыннан берсе. Ә уңай нәтиҗәләргә ирешүдә заманча технологияләргә таяну ярдәм итә ала.

Белем бирүдә заманча технологияләрне куллану ул - әхлаклы кеше тәрбияләү, педагогик технологияләр булдыруда фәннең роле арту, өйрәнгәнне тормышта куллана белү һәм башкалар.

Инновацион технология буенча татар теленә өйрәтү – уку-укыту процессын яңача оештыруны аңлата. Бу вакытта укыту процессы төп нәтиҗәгә - укучының актив коммуникатив эшчәнлеккә омтылуын алдан сизүгә, баланың хисси һәм интелектуаль мөмкинлекләрен файдаланып аралашуга юнәлтелә.

Дәресләремдә заманча технологияләрне кулланып мин түбәндәге нәтиҗәләргә ирешә алдым дип уйлыйм:

- укучыларның сөйләм теле яхшырды, сүзлек запасы баеды;
- татар мәдәнияте, сәнгате, әдәбияты турында күзаллаулары үсте;
- башлангыч сыйныфлар һәрбер укучыга иҗади эшләр портфолиосы булдырылды. Анда укучыларның иҗади эшләре тупланып бара. Укучылар мондый эшләрне бик кызыксынып һәм теләп башкаралар.
- компьютер технлогияләре куллану уку эшчәнлеген тагын да баетты;
- укучыларның иҗади эшчәнлеге артты.

Менә шундый юллар белән мин үземнең укучылармның сөйләм телен үстерү һәм камилләштерү өстендә эшлим. Эшемнең нәтиҗәсе буларак укыткан укучыларым ачык дәресләрдә, төрле конкурсларда, призлы урыннар алалар.

Алда язылганнардан нәтиҗә ясап, шуны әйтергә була: педагогика фәнендә укыту-тәрбия процессы сыйфатын үстерергә булышлык итүче технологияләр байтак. Укытучының бурычы – яңалыклар агымында югалып калмыйча, дөрес юнәлеш алу, һәр этап өчен уку материалын аңлатуның иң уңышлы вариантын табу. Иң мөһиме шул: заманча технологияләрне куллану алынган мәгълүматның 85%ка якынын, ә традицион технологияләр – 40% белемне хәтердә озак сакларга ярдәм итә.

**Кулланылган әдәбият**

1. Р.З.Хәйдәрова, Л.Ә.Гыйниятуллина. Рус телендә сөйләшүче балаларга татар теле укыту- Казан “Татармультфильм” 2013.

2. Әсәдуллин А.Ш., Юсупов Р.А. Рус телендә сөйләшүче балаларга татар телен укыту методикасы нигезләре. – Казан: Мәгариф, 1998.

3. Харисов Ф.Ф., Ч.М. Харисова, В.А. Гарипова.Рус телендә урта(тулы) гомуми белем бирү мәктәпләре өчен татар теле һәм әдәбиятыннан үрнәк программалар: 1-11 сыйныфлар; Казан: Татарстан китап нәшрияты,2011.

4. Сафиуллина Ф.С., Фәтхуллова К.С. Татарский язык. Интенсивный курс. – Казан: Хәтер, 1998; 1999.

5. Харисов Ф.Ф. Научные основы начального обучения татарскому языку как неродному. – Казань: Изд-во ТАРИХ, 2000. – 479 с.

6. Харисов Ф.Ф. Татар телен чит тел буларак өйрәтүнең фәнни-методик нигезләре / Русчадан Н.К.Нотфуллина тәрҗ. – Казан: Мәгариф, 2002.

Харисов Ф.Ф. Основы методики обучения татарскому языку как неродному. – СПб: филиал издательства «Просвещение», 2001. –

*Хакимова Рамзия Риф кызы, Нурмиева Резеда Равил кызы, Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районының "аерым фәннәрне тирәнтен өйрәнүче 10 нчы урта гомуми белем бирү мәктәбе" муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесенең югары категорияле татар теле һәм әдәбияты укытучылары*

**Уен – җитди эш**

Максат: татар теле **дәресләрендә** кулланыла торган **уен технологиясенең** укучыларның тел байлыгын арттыруда һәм укучыларның чит телне өйрәнүгә теләк булдыруда әһәмиятен күрсәтү. Бурычлар: уеннарның укыту процессында тоткан ролен ачыклау; **уен** төрләре белән таныштыру; **дәрестә** уенны урынлы куллану.

Укытучылар: Хакимова Рәмзия Риф кызы, Нурмиева Резидә Равил кызы

Мастер-классның барышы

Исәнмесез, хәерле көн!

-Укучылар тарихны да,биология, геграфияне дә, рус телен дә өйрәнәләр.

-Тарихны белү ни өчен кирәк?.....үткәннәрне, бүгенге көнне белү,...

-Географияне белү ни өчен кирәк?...илләрне, географик атамаларны белергә, кешеләр белән аралашу өчен.

-Математиканы белү ни өчен кирәк?.саннарга, көндәлек тормышта куллану өчен .....

-Татар телен белү ни өчен кирәк?....аралашу өчен

**-Әйе, дөрес. Татар телен аралашу өчен, телне саклап калу өчен өйрәнергә кирәк.**

**-Коллегалар. Мин Сезгә мәкальләр әйтеп китәм. Сез игътибар белән тыңлагыз һәм миңа әйтерсез, сүз нәрсә турында барганын.**

Сабыйга ат та ат, таяк та ат.

Сабый хөкеме-уен.

**-Нәрсә турында мәкаль?** - Әйе, уен турында.

**- Бөек педагог Антон Семенович Макаренко сүзләре буенча «Уенда бала нинди, шундый ук ул үскәч эшендә дә була. Шуңа күрә киләчәк әһелнең тәрбиясе иң беренче уеннан башлана».**

**- Мастер-классыбызның темасы:**

**“Уен-җитди эш!”**

Татар теле һәм әдәби уку дәресләрендә укытучы баланың югары сөйләм культурасын формалаштырырга, ишетеп аңлау, фикер йөртү, иҗади сәләтен үстерергә, сүзләрне дөрес әйтә белергә өйрәтергә, сүз байлыгын арттыру өстендә эшләргә тиеш. Моның өчен тиешле шартлар булдыру – укытучының мөһим бурычы. Укучыларның татар телен һәм әдәби укуны тирәнтен үзләштерүе өчен укытучыларга балаларда телгә кызыксыну уятырга, дәресләрне кызыклы итеп үткәрергә, төрле алымнар кулланып эшләргә, укучыларны актив сөйләмгә тартырга кирәк.

- Бүгенге мастер-класста укучыларда уен аша кызыксындыру уятуны күрсәтеп китәбез.

**- Уен, акыл эшчәнлеген камилләштерү белән бергә, белем, тәрбия бирү кебек максатларны да үз эченә ала.**

Педагогик уеннарның төрләре шактый:

**-дидактик максатларга карап;**

**-оештыру структурасына карап;**

**-яшь мөмкинчелекләренә карап;**

**-эчтәлек үзенчәлегенә таянып уеннар алына.**

**Педагогик процессның характеры буенча:**

- **укыту, контроль, гомумиләштерү, танып-белү, тәрбияләү, үстерү;**
- **репродуктив, продуктив, иҗади була.**

Уен методикасының характеры буенча:

- **предметларга, сюжетларга кагылышлы, рольле, эшлекле, театраль уеннар була.**















Педагогик уеннар балаларның хыялын уята, күтәренке кәеф булдыра, уңай эмоцияләр бирә.

Бары тик оста оештырылган уен гына балаларга татар теленә карата кызыксыну уята.

Татар телендә (башка телләрдәге кебек үк!) башта авазларны дөрес әйтә белергә кирәк!

W, а, о, ы ,э, ү, ә, җ, ң, һ.

Татар телендәге он (мука)-он га! (Она)

Минем күлмәгем яңа! диясе урынга...Минем күлмәгем яна!(горит) диючеләр дә бар.

Бер генә авазны дөрес әйтмәсәк тә икенче мәгънәле сүзләр килеп чыга.

Әй, сәлам!...Әй, салам!... га әйләнә.

Әгәр кибеткә керсәгез,дөрес әйтмәсәгез,сезгә калак урынына колак биреп тә чыгарырга мөмкиннәр!

Андый сүзләр бик күп: тун-туң, яшел-яшен, өч-оч, бул-бел...

-Монда авазлар белән дә уйнарга була: хор белән минем арттан кабатлап барыгыз!

хай-хәй, вай-бәй, ваги-ваги, авыл-давыл...

Бу өйрәтү алымын күпчелек башлангыч сыйныфларда авазлар өйрәнгән чорда кулланып була.

- Уеннарның популяр бер төркеме – театраль уеннар. Аларны төрле яшьтәге укучыларга тәкъдим итеп була.

Сүзләр  тизрәк истә калсын өчен мин театрлаштыру алымын, рольле уеннарны бик еш кулланам.  Ул балаларның иҗади эшчәнлеген артыра.

-Хөрмәтле, коллегалар.

“Сатучы” уенын уйнап карыйк әле! Ләкин төрле интонацияләр белән әйтергә кирәк булачак!

-Исәнмесез!

-Исәнмесез!

-Миңа туз бирегез әле!

-Туз????

-Ә! Тоз!

а) шушы диалогны хәйләкәр интонация белән әйтегез!

б) шушы ук диалогны конфликтлы интонация белән әйтегез!

в) шушы ук диалогны әдәпле формада әйтегез!

-Димәк,сез, тоз сорап ала беләчәксез! Дөрес әйтелешкә игътибар  итсәгез, җөмлә аңлашылачак. Дөрес хәрефне куеп әйткәндә генә син әйтергә теләгән җөмлә килеп чыга.

- Тавыш һәм видеоязмаларның киң таралуы, татар телендәге җырлар кайбер укучылар арасында бик популяр һәм аларның кызыксыну объекты булып торалар.

Шулай ук эмоциональ төсмер белән әйткәндә, ритмик кабатлаулар булганда сүзләр тиз истә кала!

-“Әпипә” җырын өйрәнгәндә сүзләрне авыр өйрәнүләренә игътибар иттем. Шул ук халык җырын –рэпка әйләндереп җырлаткач, укучылар җанланып киттеләр, күзләре яна башлады!

-Хөрмәтле, коллегалар! Хәзер сез дә “Әпипә” җырын **рэп** формасында, **хеппи** формасында җырлап карыйбыз!

-Әйдәгез, утырып аргансыздыр басып, хәрәкәтләр ясый-ясый җырласагыз да була!

Бас, кызым, әпипә,
Син басмасаң мин басам.
Бас, кызым,әпипә,
Син басмасаң мин басам.
Синең баскан эзләреңә
Мин дә китереп басам!

-Афәрин! Булдырдыгыз!

-Хәзер без сезнең белән тагын бер уен уйнап алырбыз. “Домино” уенын беләсез инде.Тик домино фишкалары урынына сүз тезмәләрне кулланабыз, ул сүз тезмәләрне дөрес тәртиптә җыйсагыз, шигырь килеп чыгачак.

**Кадерлә син китапны.**

Китап - киңәшчең синең,
Дустың, ярдәмчең синең,
Ул хөрмәткә бик хаклы
Кадерлә син китапны.
Почмакларын бөкләмә,
Битләрен дә ертма син,
Керле кул белән аны
Беркайчан да тотма син.
Көн дә укы син аны:
Китап - якын дустың ул.
Синең сорауларыңа

Җавап биреп торыр ул!

*Хәсән Шабанов.*

Шигырь нәрсә турында?   Китапны ни өчен кадерләргә кирәк?

-Афәрин!

Шигырьнең яңа сүзләре яхшы истә калсын өчен

мин дәресләремдә “Облако слов” – “Сүзләрдән болыт” программасын кулланам.

Коллегалар, авыр истә кала торган сүзләрне әйтегез.  (Китап, киңәшчең,  ярдәмчең, хөрмәткә бик хаклы, бөкләмә, ертма, керле.)

Бу сүзләрне мин “Сүзләрдән  болыт” программасына кертәм!

https://wordscloud.pythonanywhere.com/

-Карагыз әле! Нинди кызыклы болыт килеп чыкты! Боларга карагач яңа лексиканы истә калдыру җиңел.

Мин бу приемны урта сыйныфларда кулланам.

- Кечкенә классларда тел өйрәтү дәресләрендәге уеннарның иң яхшы варианты булып уенчыклар, төрле предметлар белән уйнау тора. Аларны бигрәк тә лексика керткәндә күрсәтмә материал буларак файдаланам.

А) -Минем кулда нәрсә,коллегалар?

-Әйе,уенчык камаз машинасы.

-Ул нинди төстә? Зурмы, кечкенәме? Аны кем йөртә? Нинди профессияне белергә кирәк? Шофер нинди булырга тиеш? Синең әтиең кем булып эшли? Гаиләгездә шоферлар бармы? КаМАЗ машинасын кайда чыгаралар? ...

Һәр тема буенча яңа лексиканы истә калдыру өчен “БУШ ТАКТА” уенын кулланып була.

Тактага берсе астына берсе сүзләр языла. Башлангыч сыйныфта 5-7 сүз, уртанчы сыйныфта 7-9 сүз куланып була. 9 сүздән дә артырырга ярамый, психолог яктан кеше исендә 9 сүздән артык истә калдыра алмый.

Н-Р:

1. КӨЗ
2. САЛКЫН
3. ҖИТТЕ
4. ТАЙГАК
5. УРАМ

Уен технологияләрен кулланганда түбәндәге шартларны үтәү мәҗбүри:

- уен дәреснең укыту-тәрбия максатларына туры килүе;
- яшь үзенчәлекләренә туры килүе.

Бирелгән уеннар дәрес материалын үзләштерүне җиңеләйтәләр, аларны бары тик тиешенчә белеп, кирәкле урында гына кулланырга кирәк. Һәрбер уен (фонетик, лексик, грамматик һ.б.) темадан чыгып сайланырга тиеш. Шул очракта гына ул телне өйрәнү процессында уңай нәтиҗәләр бирә.

Мастер-классыбызны үзем язган шигырь белән тәгәлләсем килә:

Әгәр укучы татар телен белсен, дисән!
Янып эшлә сүзләр өстендә!
Бала көне-төне ятлап кына
Исендә калдыра алмый һәр көндә!

Уят балада син кызыксыгну, дәрт.
Бала теләп, уйнап өйрәнсен!
Уен аша һәрбер бала җирдә
Йолдыз кебек янсын, дөрләсен!!!

Хакимова Р.Р.

*Харисова Чулпан Сәгыйть кызы,*
*Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районының "аерым фәннәрне тирәнтен өйрәнүче 11 нче урта гомуми белем бирү мәктәбе" муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесенең беренче категорияле татар теле һәм әдәбияты укытучысы*

## Татар әдәбияты дәресләрендә укучыларның функциональ грамоталылыгын үстерү методлары (алымнары)

Нәрсә ул «функциональ грамоталылык"? Функциональ белемлелек -мәктәптә уку вакытында укучылар ирешкән белем дәрәҗәсе һәм кешенең тормышның төрле өлкәләрендә стандарт тормыш бурычларын хәл итә алу мөмкинлеген күз алдында тота. Укучыларның функциональ грамоталылыгын тәэмин итү өчен татар теле һәм әдәбияты укытучысы нәрсә

эшли ала? Барыннан да элек, һәр укучыны Мәгариф киңлегендә таныту өчен оптималь шартлар тудыру. Моның өчен һәр яшьтәге мәктәп укучыларының уку мөмкинлекләрен белергә кирәк. Ягъни укучы :

1. Әйләнә-тирә дөнья белән хезмәттәшлек итәргә әзер булырга, ышанычлы адаптациягә ия булырга.

2.Әсәрләрне анализлый белү һәм фактлар белән чагыштыра белү, каршылыкларны билгели белү, булган ресурслар белән хәл итү юлларын таба белү.

3. Фәнне өйрәнүгә карата уңай омтылышта булу, фән даими кызыксыну һәм шулар нигезендә белем алуның алдагы баскычларында татр телен уңышлы үзләштерү.

4. Рефлексия күнекмәләренә ия булу, үзеңне читтән карый, үз эшеңне бәяли белергә тиеш.

Татар теле һәм әдәбияты укытучылары өчен функциональ грамоталылыкны формалаштыру шулай ук актуаль эш юнәлеше булып тора. Әдәби әсәрне укый башлаганчы без язучының яки шагыйрьнең кайсы чорда яшәгәнлеген, ул чорда нинди әдәби агымнар өстенлек иткәнлеген өйрәнәбез, шул вакыт аралыгына характеристика бирәбез. Чөнки автор иҗатына шул заман вакыйгалары турыдан-туры тәэсир итә, үз эзен калдыра. Бүгенге чыгышымда укучыларны тормышка әзерләү йөзеннән биреләчәк сорауларны һәм биремнәрне мисал итеп китерәм.

1. Югары сыйныф укучылары әдәбият теориясеннән  чорларга бүленешнең чикләрен белергә тиеш. 10 нчы сыйныфта борыгы әдәбият тарихын өйрәнсәк, 11 нчеләргә революциягә кадәрге һәм соңгы әдәбият тарихы бирелә (һәр чорны язарга һәм һәр чорның үз әдипләрен санарга).

***10нчы сыйныф***

*Борынгы һәм урта гасыр әдәбияты:*

-*болгар чоры;*

-*алтын урда чоры;*

-*казан ханлыгы чоры;*

-*XVII йөз әдәбияты;*

-*XVIII йөз әдәбияты.*

*XIX гасыр әдәбияты*

*XIX гасыр башы әдәбияты*

**11нче сыйныф**20 нче еллар әдәбияты

30 еллар әдәбияты

40-50 нче еллар әдәбияты

1960-2000 нче еллар әдәбияты

2.Һәр чорга караган әдәби агымга характеристика, билгеләмә бирергә була. Шуңа берничә мисал китерик.

Наданлыкны фаш итү һәм кире кагу, уңай геройларны мәгърифәткә, белемгә омтылган итеп сурәтләү, мохитнең кешене тәрбияләүдәге ролен күрсәтү, персонажларны кырт икегә бүлеп, ягъни уңайларын бик тә уңай итеп, тискәреләрен гел кара буяуларга манчып тасвирлау югарыда аталган әсәрләрдәге сәнгатьчә эшләнешнең нигезендә- **(МӘГЪРИФӘТЧЕЛЕК РЕАЛИЗМЫ)** ята. (10нчы сыйныф)

Мөселман кешесенең Аллаһка карата булган гыйшкын, аның белән кавышу идеясын алга сөргән ислам динендәге мистик һәм фәлсәфи агым **( СУФИЧЫЛЫК)** дип атала.(10нчы сыйныф)

Хыял-идеалдагыча яшәеш рәвешен күрсәтергә омтылу,ике катламлы тормыш моделен төзү- **(РОМАНТИЗМ).**

Геройның шәхси сыйфатларын, кайсыдыр бер ягы калкурак күрсәтелеп, кешене яшәеш алдында кечкенә һәм көчсез итеп тасвирлау-**(МОДЕРНИЗМ)**

3. Язучы һәм шагырьләрнең нинди агым тарафдарлыгы икәнлеген өйрәтү өчен мондый бирем кулланырга була, парлап язарга кирәк.

| | |
|---|---|
| Дәрдмәнд | Классицизм |
| Г.Ибраһимов | Романтизм |
| Г.Тукай | Модернизм |
| Ф.Әмирхан | Реализм |

**Дөресе:**

| | |
|---|---|
| Дәрдемәнд | Модернизм |
| Г.Ибраһимов | Реализм |
| Г.Тукай | Классицизм |
| Ф.Әмирхан | Романтизм |

4. Әсәрләрнең нинди агым белән иҗат ителүен истә калдыру өчен түбәндәге алым отышлы. Беренче баганага әсәр исеме язылса, икенчесендә агым төре.

Г.Исхакый “Жан Баевич” драмасы

М.Мәһдиев “Бәхилләшү” повесте

Мирсәй Әмир “Агыйдел” повесте

социалистик реализм

авыл реализмы

тәнкыйди реализм

**Дөресе:**

Г.Исхакый “Жан Баевич” драмасы тәнкыйди реализм

М.Әмир “Агыйдел” повесте социалистик реализм

М.Мәһдиев “Бәхилләшү” повесте авыл реализмы

5. Романтик иҗатка хас билгеләрне санагыз :

-тормышны идеаллаштыру;

-хыялдагыча яшәеш рәвешен күрсәтү;

-реаль законнар белән исәпләшмичә яшәү;

-чынбарлык белән конфликка керү;

-кеше иң камил зат буларак күрсәтелә.

6. Әдипләрнең яшәү чорын үсә бару тәртибендә күрсәтегез.

К.Насыйри

Г.Кандалый

М.Акъегетзадә

М.Акмулла

Ш. Мәрҗани

Г.Утыз Имәни

Г.Утыз Имәни

Г.Кандалый

Ш. Мәрҗани

М.Акмулла

К.Насыйри

М.Акъегетзадә

7. а) Түбәндәге исемлектән XIX йөздә реалистик проза әсәрләре иҗат итүче авторларны сайлап алып, яннарына берәр әсәрләренең исемен яз.

1) Хөсәен Фәезханов
2) Мартиньян Иванов
3) Каюм Насыйри
4) Салихҗан Кукляшев
5) Заһир Бигиев
6) Муса Акъегет
7) Риза Фәхретдинов
8) Закир Һади

б) Беренче реалистик роман язучы авторларны билгелә, астына сыз.

8. Романтизмның төп сурәтләү предметлары(әзер вариантлар бирелә):

1. Табигать
2. <u>кешенең хисләрне кичерү киңлеге, эмоциональ киеренкелек масштабы</u>
3. <u>кешенең рухи тормышы (эчке дөньясы, уй-кичерешләре)</u>
4. җәмгыять һәм шәхес арасындагы мөнәсәбәтләр
5. цивилизациянең әхлакка тәэсир итүе
6. <u>кеше яшәешенең мәгънәсе</u>

Дөрес дип исәпләгән пунктларны түгәрәккә ал.

9.Кайсы иҗат методында иҗат итү әдиптән тарихи чынбарлыкның конкрет сурәтләнешен таләп итә?

А) **реализм**

Б) романтизм

В) сентиментализм

10. Г.Тукайның романтик дип саналырга хаклы әсәрләренең өч-дүртен атагыз. **“Мәхбүс”, “Шагыйрьгә”, “Байроннан”, “Шагыйрь”** (1908), **(Ядкяр)”** (1908), **“Пәйгамбәр”**(1909)

11. Утызынчы еллар татар әдәбиятына хас үзенчәлекләрне санагыз.

12. 1940-1950 нче еллар әдәбиятында чагылган төп үзенчәлекләрне түбәндәге исемлектән + тамгасы куеп билгелә.

1) **реалистик прозаның алгы планга чыгуы**
2) халык авыз иҗаты әсәрләреннән килгән сурәтләү чараларын киң куллану
3) шигырь формасының иң үтемле әдәби форма булып өстенлек итүе
4) **аерылу, сагыну, ярату, туган илгә мәхәббәт хисләренең дәрәҗәсен бирергә омтылу**
5) **зур күләмле романнарның иҗат ителүе**
6) **туган ил, балалар темаларының калку куелуы**
7) милләт ирееге, язмышы мәсьәләләренең көчәюе
8) **яңа тормыш өчен көрәш, яңа җәмгыять төзү юлларын исбатлауны алга куйган әсәрләр иҗат ителү**
9) колониаль изелү мәсьәләләренең алга куелуы
10) мифологик образларга мөрәҗәгать итеп, идеаль тормыш сурәтләргә омтылу

13. .И.Юзеев үз әсәрләрен кайсы иҗат методына өстенлек биреп яза? **(романтизм)**

14. Түбәндәге әсәрләр нинди юнәлеш һәм иҗат методында язылган? Билгелә. М.Җәлилнең “Кызыл ромашка”, Н.Исәнбәтнең “Идегәй”, А.Гыйләҗевның “Әтәч менгән читәнгә”, И.Юзеевның “Өчәү чыктык ерак юлга”, Ә.Баяновның “Сәяхәтнамә” әсәрләре.

15. 90-нчы еллардан алып, бүгенге көн әдәбиятында нинди күренешләр булды, шуларны мисаллар белән дәлиллә. Бу чор әдәбиятында үзеңә ошаган әсәрләрен ата.

16. Казан ханлыгы чоры әдәбиятына хас үзенчәлекләр турында языгыз.

17. Түбәндәге әсәрләр нинди юнәлеш һәм иҗат методында язылган? Билгелә. Котбның "Хөсрәү вә Ширин", З.Бигиевның "Меңнәр яки гүзәл кыз Хәдичә", Г.Кандалыйның "Сәхипҗамалга", "Мулла белән абыстай" әсәрләре

18. Х1Х йөзнең беренче яртысы әдәбиятына хас төп сыйфатларны санап үтегез. Нинди традицияләрнең дәвам иттерелешен, нинди яңалыкларның пәйда булуын игътибарга алыгыз

Чыгышымның төп максаты – укучыларның белемнәрен системага салырга ярдәм итү, тормыш юлына басарга әзерләнергә юнәлеш бирү. Әдәбият белеме, әдәбият укытудагы үзгәрешләр әдәби агымнарны, әдәби әсәрләрнең кайсы чорда язылганлыгын төгәл белүне таләп итә, чөнки укучы боларны белми торып әдәби әсәрләргә анализы тулы булмаячак,күаллавы башка юнәлештә булырга мөмкин.

*Хөсәенова Энҗе Абрамовна,*
*Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы Кама Аланы икенче урта мәктәбе муниципаль бюджет белем учреждениесе югары категорияле татар теле һәм әдәбияты укытучысы*

**Уен технологиясе кулланып, русс телле укучыларның коммуникатив компетенциясен үстерү**

Җиһанда салкын кыш хөкем сөрә. Әле кайчан гына җылы, эссе җәйләр иде. Бар дөнья яшеллеккә күмелеп, бакчаларда, болыннарда кошлар сайрады, зәңгәрле-аклы, кзгылт-сары, тагын әллә нинди матур төсле күбәләкләр чәчәкләргә кунды.

Бар нәрсәне дә белүче бер акыл иясе булган. Аның бер укучысы моның киресен исбатларга теләгән һәм шулай кулына күбәләкне алган да учлары белән каплаган. Укучы укытучысыннан сораган "Әйт әле, укытучым, минем кулымда күбәләк үлеме, тереме?" – дигән. Ә үзе, тере дисә – үтерәм, үле дисә, очырам, дип уйлаган. Ничек уйлыйсыз, акыл иясе нәрсә дип җавап биргән? ("Барысы да синең кулыңда.")

Ә безнең сезнең белән, хөрмәтле коллегалар, кулларыбызда – балалар язмышы. Укчыларның безнең кулларда үзләрен яраткан, кирәкле, уңышлы итеп тоюлары бик мөһим.

Безнең бурычыбыз баланың кечкенә генә алга китешен дә күрү, аның уңышларына сөенү һәм баланы да сөендерә белү.

Мин – Хөсәенова Энҗе Абрам кызы. Беренче белемем – башлангыч сыйныф укытучысы, икенчесе – татар теле һәм әдәбияты уктучысы. Икесенә дә тугры булып, Кама Аланы бистәсенең 2нче гомуми урта белем бирү мәктәбе башлангыч сыйныфларының рус төркемнәрендә 29 ел татар теле һәм әдәбияты укытучысы булып эшлим. Гомуми педагогик стажым – 35 ел

Ботканы май бозмаган кебек, башлангыч сыйныфларда дәресләрне дә уен боза алмый.

Шулардан чыгып, мин үземә **“Уен технологиясе кулланып, русс телле укучыларның коммуникатив компетенциясен үстерү”** дигән методик тема сайладым. Компетенция сүзе нәрсәне аңлата соң? С.И. Ожеговның рус теленең аңлатмалы сүзлегендә компетенция сүзенең аңлатмасы мондый: “компетенция – круг вопросов, в которых кто-нибудь хорошо осведомлен”

Димәк, компетенция - нинди дә булса өлкәдә осталык. Мин дәресләремдә аралашу осталыгы үстерәм, дигән сүз.

“Коммуникатив эшчәнлек хезмәттәшлекне оештыруга һәм гамәлгә ашыруга юнәлтелгән. Ул партнерны тыңлый һәм аңлый белүне, мәгълүматны тулы һәм төгәл кабул итә һәм тапшыра, үзеңнең эш-хәрәкәтеңне партнер эш-хәрәкәте белән чагыштыра белүне үз эченә ала”, – дип ассызыклана яңа дәүләт стандартларында. Мондый эшчәнлек укучыларның уку эшчәнлеген үстерүдә төп ысулларның берсе булып тора. Коммуникатив компетенциянең нигезе башлангыч мәктәптә үк салына. Ә нинди алым, нинди технологияләр миңа яхшы нәтиҗәгә ирешергә булыша соң? Әлбәттә, бала яңа белем алган вакытта кулланылган актив технологияләр. Барлык актив технологияләр арасында кече яшьтәге мәктәп балалары өчен иң отышлысы, минем уйлавымча – ул уен технологиясе. Чөнки уенга омтылыш, сюжетлы уеннар белән мавыгу – бала өчен гадәти күренеш. Алар бу яшьтә уен эшчәнлегенә тиз тартылалар. Уен -балалар өчен уку да, хезмәт тә, уен – ул җитди тәрбия формасы да.

Рус телле балаларны татар теле белән кызыксындыру зур көч сорый. Аларның телне өйрәнүгә теләген сүндермәү, дәрескә кызыксыну һәм стимул булдыру өчен, дәрестә уеннар куллану нәтиҗәле. Уен вакытында укучының иҗат мөмкинлеләре ачыла, мөстәкыйльлеге арта, оештыру сәләте үсә. Уен кайбер балалар өчен хыяллану, кайберләренә күңелле ял итү чарасы да булып тора. Ә укытучы өчен уен – балаларны яхшырак аңлау, аларга тагын да ныграк якынаю чарасы да. Чөнки нәкъ менә уен вакытында укытучы һәр баланың нәрсәгә сәләтле булуын, аның оештыру мөмкинлекләрен яхшырак күрә ала, холкын, гадәтләрен

яхшырак аңлый. Уен ярдәмендә оялчан, үз эченә бикләнгән балаларны да уятырга мөмкин. Уендагы текстка, җырга кушылып, аның кагыйдәләрен үтәп, я булмаса, нииндидер роль башкарып, бала үз көченә ышанырга, эшләгән эшенә бәя бирергә өйрәнә, анда ярдәмләшү, игътибарлылык кебек сыйфатлар тәрбияләнә.

Укыту процессында уен эшчәнлеге төрле функцияләр үти:

- мавыктыргыч (бу уенның төп функциясе – мавыктырырга, күңелен күрергә, кызыксыну уятырга);

- коммуникатив (сөйләм диалектын үзләштерү);

- диагностик (уен барышында үз-үзеңне танып белү);

- милләтара коммуникацияләр (бөтен кешеләр өчен дә бер булган мәдәният кыйммәтләрен үзләштерү).

Коммуникатив универсаль уку гамәлләрен, бигрәк тә аралашу күнекмәләре формалаштырганда башлангыч сыйныф укучылары белән мин үз дәресләремдә уеннарның төрлесен һәм дәреснең төрле этапларында кулланам. Смайликлар ярдәмендә кәефләребезне, дәрескә булган мөгаләмәбезне күрсәтүне мин һәр дәресемнең ***оештыру өлешендә*** кулланам. Кечкенә генә бу уен төре дәрес башында ук балаларны җыя, уңай психологик халәт тудыра

***Фонетик күнегү*** үткәрү өчен фонетик уеннар кулланам : “Әйтеп бетер”, “Сүз уйлау”, “Исем уйлау”. Бу уеннарны мин авазларны, сүзләрне дөрес әйтү күнекмәләре формалаштыру, игътибарлылык өчен кертәм. Фонетик уеннар сөйләм органнары артикуляциясенең дөрес куелышын тәшкил итә.

***Алган белемнәрне актуальләштергәндә*** “Нәрсә югалды”, “Кар өеме” кебек уеннар бик отышлы. “Кар өеме”уены грамматик формаларны, җөмләдә сүзләр бәйләнешен һәм җөмлә төзү күнекмәләрен ныгыта (Укучы. Бу укучы. Укучы укый. Укучы мәктәптә укый. Укучы икенче мәктәптә укый. ...)

Укытучылар өчен булган белем бирү ресурслары битендәге тема буенча булган уен формасындагы биремнәр укчыларда татар теленә кызыксыну уята.

***Уку мәсьәләсен куйганда,*** кроссвордлар чишү, мультфильмнан, җырдан өзек тыңлау кебек биремнәр кулланам.

Ял минутлары уздырганда да уен элементлрына мөрәҗәгать итәм. Бу күптән үткән лексиканы искә төшереп торуда отышлы чара. Мәсәлән, сүзтезмәләрне, җөмләләрне рус телендә әйтәм, укучылар татарчага тәрҗемә итеп, хәрәкәтләр белән күрсәтәләр (мин тимераякта шуам, мин чәч тарыйм, мин бит юам һ.б.) Ел фасылларына хас булган билгеләрне өйрәнгәндә дә, укучылар билгеләрне төрле хәрәкәтләр белән күрсәтәләр (җил исә, буран, кар ява, яфраклар коела һ.б.). “Очты, очты” уены минем укучыларымның

яраткан уенына әверелде. Оча торган предметлар янына темага караган сүзләрне алыштырып, өстәп торам. Хәрәкәтле, тавышлы уеннардан тыш ял минутларында тыныч уеннарга да өстенлек бирәм. Мәсәлән, күзләр өчен булган күнегүгүләр язу дәресләрендә урынлы кулланыла.

***Теманы ныгытканда*** "Кайтаваз" (Укытучы акрын гына сүзне әйтә. Укучыларның бурычы – аны ишетү һәм кабатлау), "Акыллы попугай" (Укытучы нинди дә булса предметны белдергән рәсем күрсәтә, сүзне атый, укчылар дөрес булса гына кабатлыйлар.) уеннары бик отышлы. Шулай ук "Әйтеп бетер", Рифмалаштыру" уеннары өйрәнелгән лексиканы ныгытырга ярдәм итә.

"Иреннән укы" дигән уенда укучылар сүзне ирен артикуляциясе буенча аңларга тиешләр. (Дәфтәр, китап, бетергеч, каләм, көндәлек). Бу уен өйрәнелгән лексиканы ныгыту өчен кулланыла. "Портфель җыябыз" уены белән бу сүзләр тагын бер тапкыр кабатлана һәм укучыга мәктәпкә бару өчен портфель җыела.

Шулай ук укчыларның күзәтүчәнлеген үстерү өчен, уку-язу әсбапларын яңадан да таратыла. Моның өчен алар ахырдан кергән тәртиптә предметларны әйтергә тиеш булалар. Бу максат белән "Нәрсә бар?" (әйләнә-тирәдә мөмкин кадәр күбрәк әйбернең исемен атыйлар) "Кем күбрәк күрде" уеннары да дәресне җанландырып җибәрәләр.

Татар теленә өйрәтүдә рольле уеннарны куллану да әһәмиятле алым булып тора. Аларның өйрәтү мөмкинлекләре зур һәм тәкъдим ителгән ситуацияләрдә укучылар аның белән иркен эш итәләр. Рольле уеннар берничә этаптан тора: өйдә яки сыйныфта әзерләнү, сыйныфта уенны оештыру, йомгаклау этаплары. Уенны оештырганда, укытучы берничә факторны истә тотарга тиеш:

-сөйләм эшчәнлеге дәрәҗәсенең төрле булуын истә тотып, балаларга рольләрне дөрес бүлеп бирү;

- уенның нәтиҗәсе укучыларның хисси халәтенә бәйле булу;
- укучыларга яхшы таныш булган ситуацияләрне файдалану;
- үзара ярдәмләшү, телдә актив аралашу мохите булдыру.

Рольле уеннар диалогик сөйләмне үстерүдә бик нәтиҗәле чара булып тора.

Рольле уенда парлап һәм төркем составында да катнашырга була. Төркем белән эшләгәндә, экиятләрне үзгәртеп, тулыландырып, өстәмә сораулар ярдәмендә коммуникатив максатка ирешергә мөмкин. Мәсәлән, "Шалкан" экиятендәге шалкан үзе турында түбәндәгечә сөйләргә мөмкин: "Мин – шалкан. Мин сары, зур, тәмле". Шул рәвешчә, һәр герой үзе турында сөйләп китә. Укучылар бу уенда бик теләп катнашалар, бер-берсенә ярдәм итәләр.

Болардан тыш та төрле уен элементларын кулланам. Мәсәлән, "Мин чисталык яратам", "Кибеттә", "Базарда", "Туган көнгә чакыру" кебек рольле уеннар бик кызыклы. Алар тормыш белән бәйле. Аларны, гадәттә, шушы темаларга караган лексика һәм репликаларны өйрәнгәндә куллану уңай нәтиҗә бирә. Диалогик сөйләмне үстерүдә дә әһәмиятле чара булып тора. Телне авыр үзләштергән балаларда да кызыксыну уяна.

Татар теле дәресенә кызыксынуны арттыру өчен дәресләрдә төрле көйләр һәм җырлар кулланырга тырышам. Җыр күңел ачу моменты гына түгел, лексик запасларны арттыру, грамматик конструкцияләрне яхшырак үзләштерү чарасы да. Ул сүзне әйтү күнекмәләрен ныгыта, эстетик кабул итүгә тәэсир итә, коллективны туплый. Сыйныфта яхшы психологик климат урнаша, эмоциональ тонус арта. "Миңлебай", Күрсәт әле, үскәнем!", "Күз җыры" җырлы-биюле уеннар моңа мисал булып тора.

Һәр уен укучының танып белү эшчәнлеген активлаштыра. Уен аша өйрәнелгән материал тиз үзләштерелә һәм күпкә ныклы була. Дәресләрдә уен алымнарын куллану укучыларның белем дәрәҗәсен генә күтәреп калмый, телебезгә тирән мәхәббәт тә тәрбияли.

Мастер классымны Конфуцийның сүзләре белән тәгәллисе килә "Укытучы белән укучы бергә үсәләр". Дәресләребездә уен технологиясе кулланып, укучылар белән бергә үрелеп үссәк иде

Бу алымнарның барысы да татар теле һәм әдәбияты дәресләрендә укучыларның функциональ грамоталылыгын формалаштыруның төп индикаторлары булып тора. Чөнки укучы төрле ситуацияләрдә мәктәптә өйрәнгән мәгълүматны кулланырга белүче, башка кешеләр белән үзара хезмәттәшлек итә белүче , тиз үзгәрүчән дөнья шартларында яшәргә һәм эшләргә сәләтле булырга тиеш .

*Шәймәрдәнова Мөслимә Габделхәй кызы, ТР ТКМР "Югары Чаллы урта гомуми белем бирү мәктәбе" МБББУ-ның югары квалификацион категорияле татар теле һәм әдәбияты укытучысы*

**Дәрес темасын үзләштерүгә кызыксыну уяту алымнары**

Балаларда сабыйлыктан килгән күпне беләсе килү теләген ничек саклап калырга? Ничек милли үзаң тәрбияләргә, әхлак сыйфатларын, ватанпәрвәрлек хисләрен ничек булдырырга, тормышта үз юлларын табарга ничек ярдәм итәргә?.. Барлык шартлар булып та, укучылар ни өчен белемнәрен күтәрү өстендә эшләргә теләмиләр, аларның фикри ялкаулыгы каян

килә? Интернет аша бик күп сорауларга әзер җавап табу мөмкинлегеннән киләме бу? Әллә экраннар аркылы киң җәелдерелгән артык матур, рәхәт, ләззәтле яшәү рәвешен пропагандалауданмы? Бәлки укыту-тәрбия бирү өлкәсендәге җитешсезлекләр сәбәпледер?.. Әлеге мәсьәләләр мине, укытучы буларак та, өч ир баланың әнисе буларак та, җитди уйланырга, эзләнергә, уяу булырга этәрә.

Бүгенге укытучы илкүләм, дөньякүләм иҗтимагый-сәяси вакыйгалар белән танышып барырга, үзенең төгәл гражданлык позициясен булдырырга, милли проблемаларның нечкәлекләрен дә аңлый белергә, толерантлык сыйфатларына ия булырга һәм заманча техник чаралар белән таныш булырга тиеш.

Милләт мәсьәләсенә килгәндә, авыл җирлегендә телне, милли үзенчәлекләрне саклау киртәләрсез тормышка ашырыла кебек. Ләкин бу беренче карашка гына. Авылда яшәгән балага туган телдә аралашу, фикерләү – ул тормышның үзе. Ә чынлыкта мәсьәлә тирәндәрәк, минемчә.

Бүгенге мәктәп алдында торган иң беренче мәсьәлә – укучыларның БДИ- ларын уңышлы бирә алулары. Бу төр имтиханнар, татар теле һәм әдәбияты фәннәреннән тыш, барысы да рус телендә тапшырыла. Барлык фәннәрне дә татар телендә генә укып килгән яхшы укучы да югары нәтиҗәләргә ирешә алмаска мөмкин. Димәк, алдан күрүчән фән ияләре, имтиханнарны күздә тотып, төп темаларны ике телдә аңлатырга мәҗбүр. Шул сәбәпле татар мәктәпләренең күпчелеге (сүз авыл җирлегендә эшләүче мәктәпләр турында, ә шәһәрләрдә исә бу күренеш яңалык түгел) төп фәннәрне рус телендә алып барырга тырыша. Имтиханнарга әзерлек өчен булган әдәбият та бары тик рус телендә булса гына нәтиҗәле ярдәм итә ала. Ә бит дистәләгән еллар дәвамында нәтиҗәле эшләп килгән татарча дәреслекләр, фәнни хезмәтләр, телара терминологик сүзлекләр бар. Ә аларның тиздән кирәге дә калмас кебек. Чөнки бүгенге мәктәп программалары зур материалны үзләштерүгә каралган, төп фәннәрдән әһәмиятле (имтиханга кертелгән) темаларны ике телдә аңлатып торырга вакыт җитми. Теләсә дә, теләмәсә дә, фән иясе укучыларны имтиханга әзерли һәм, беренче чиратта, рус телендәге дәреслекләргә һәм шул ук телдәге махсус әдәбиятка таянып эшли. Якын киләчәктә безнең укучыларыбыз татар телен фән буларак татар теле һәм әдәбияты дәресләрендә генә өйрәнергә, ә башка фәннәрне рус теле аша гына үзләштерергә калмасмы? Бу үз чиратында татар теленең дөньяви гыйлем таратудагы әһәмиятле ролен, кулланылу дәрәҗәсен киметмәсме?

XX гасыр башында бөек шәхесләребез төгәл фәннәрне өйрәнерлек тел булырга хаклыгын раслаган, аны дөнья мәйданына чыгарган татар теленең камиллеген, төгәллеген, бөеклеген тою бәхетеннән мәхрүм калмасмы киләчәк буыныбыз?

Татар теле укытучысы ул – балаларга кызыклы түгел кебек тоелган фәннәрне дә мавыктыргыч, гадәти булмаган, шуның белән үзенә җәлеп итәрлек бер дөнья итеп тәкъдим итә алырга да сәләтле кеше. Заманча фикерләүче татар теле укытучысы ул, беренче чиратта, үз укучысының ихтыяҗын күрә белүче һәм һәр укучының шәхси мөмкинлекләрен исәпкә алып эшләүче дә.

Минемчә, хәзерге заман татар теле укытучысы тагын бер мөһим сыйфатка – мобильлеккә дә ия булырга тиеш. Чөнки бүгенге көндә мәгълүмат көннән-көн арта, аларны саклау, тарату чаралары да төрләнә, заманчалаша бара. Тиз арада җавапларын табу, хәл ителү таләп ителгән мәсьәләләр арта бара. Шуңа күрә укытучы тормышта яхшы ориентлаша белергә тиеш, чөнки ул укучы балалар гына түгел, ә аларның әти-әниләре өчен дә үрнәк. Ул укучыларын үз фәнен үзләштерүгә генә түгел, тормышта үз юлын дөрес табарга ярдәм итә, сәламәт рухлы шәхес булып үсү өчен шартлар булдыра, тормыш позициясенә дә, яхшылыкка да өйрәтә.

Бүгенге татар теле укытучысы заманча гаджетлардан дөрес файдалана белергә тиеш. Чөнки мәктәпләрдә дә бик күп төрле техник электрон җайланмалар, мәгълүмати-аралашу чаралары елдан-ел күбрәк кулланыла, цифрлашу мөгаллимнәрнең һөнәри осталыгын үстерү, тәҗрибә уртаклашу, заманча дәрес оештыру, балаларга тәрбия бирү өлкәсендә активлаша.

Укучыларда дәрес темасына, өйрәнеләчәк материалга кызыксыну уяту өчен, туган тел дәресләрендә еш кына үзебезнең җирле атамалар, үзебез яшәгән җирлек, авылыбыз, мәктәбебез турындагы мәгълүматлар белән мисаллар әзерлим, авылдаш, якташ язучылар әсәрләренә мөрәҗәгать итәм. Болай эшләгәндә укучылар активрак булалар, тел гыйлемен үзләштерү белән бергә туган җиребез тарихы белән дә таныша баралар. Мәсәлән, 5нче сыйныфта “Искергән сүзләр” темасын өйрәнү мәктәп музеенда үтте. Укучылар белән бергәләп тарихи сүзләрне музейда сакланган тормыш-көнкүреш кирәк-яраклары арасыннан таптык, аларны атап кына үтү тиз онытылыр иде, ә бу дәрестә балалар әби-бабаларыбыз кулланган әйберләрне күреп, тотып карап, аның ничек кулланылуы белән танышып үттеләр.

Шулай ук әдәбият дәресләрендә дә темага туры килгән җирле материалларны актив кулланам. Мәсәлән, халык авыз иҗатын өйрәнгәндә, авылдашлар язган бәетләр турында да сөйләшеп, кайберләрен укып китәбез. Җирле риваять, төрле ышануларны да укучылар бик яратып тыңлыйлар. Сугыш темасына багышланган әсәрләр үткәндә, сугышта һәлак булган авылдашлар исемлеге белән танышабыз, сугыштан килгән, мәктәп музеенда сакланган хатларны укыйбыз. Авылдаш каһарман, дүрт орден белән бүләкләнгән Фәйзуллин

Шәйхулла турындагы эзләнү эше, аның мәктәп музеенда сакланган соңгы хаты белән танышу да укучылага бик көчле тәэсир итә.

Материллар кул астында гына: кабинетта үзем әзерләгән “Авылым бәетләре”, “Авылым тарихы”, “Авыл хәтере”, “Сугыш чоры хатирәләре”, “Габидуллина Гасимә иҗаты”, “Сугыш ветераннары сөйли”, “Талантлы якташлар” кебек папкалар, “Туган як” газетасы тупланмасы, үзем әзерләгән күпсанлы презентацияләр бар.

Шулай ук соңгы елларда авыл мәдәният йортында, “Алтынчәч” балалар йортында музей почмаклары ачылу, шул ук мәдәният йортында, авыл китапханәсендә милли йолалар, авылыбызда күп еллар яшәп килгән гореф-гадәтләр белән танышу кичәләре үткәрелү, бу чаралар белән видеоязма аша да танышу мөмкинлеге дә дәресләрдә, дәрестән тыш чараларда нәтиҗәле кулланыла. Соңгы елларда авыл китапханәсе белән тыгыз элемтәдә булу, китапханә дәресләре үткәрү дә эзсез калмас дип уйлыйм.

Туган тел укытучы – күпкырлы кеше. Ул һәрвакыт өйрәнүдә һәм эзләнүдә, иҗатта, үз үсешендә ул беркайчан да тукталмый, чөнки Укытучы - киләчәккә юл алган яшь буынны белем белән коралландыручы, аны халкына, Ватанына тугры шәхес итеп тәрбияләргә омтылучы.

*Якупова Венера Бадуртдиновна, Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районының "29 нчы урта гомуми белем бирү мәктәбе" муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесенең югары категорияле татар теле һәм әдәбияты укытучысы*

## Укытуның яңа шартларыннан – нәтиҗәләргә

Хөрмәтле коллегалар, укытучылар өчен тәкъдим ителгән теманың бик актуаль булуына кызыгып, әлеге фикер алышу, тәҗрибә уртаклашу мәйданчыгында катнашырга булдым. Әйтер сүзем ике юнәлештә һәм алар бер-берсе белән тыгыз бәйле.

**Беренчесе:**

Элек-электән телләрнең статусы һәм аларның хокукый яшәү шартлары бик еш үзгәреп торган. Телнең үсешенә һәм сакланышына хөкүмәт тә, сәясәт тә гарантия биреп бетерә алмый. Телне татар милләте үзе сакларга, үстерергә, яшәтергә тиеш. Безгә – татар теле укытучыларына зур миссия йөкләнгән: татар балаларына дәрес материалын өйрәтү генә түгел, ә туган телебезне, милли эчтәлекне, татар рухын бала күңеленә сеңдерергә

тиешбез. Бүгенге көндә бу эш зур көч, сабырлыклар таләп итә. Күңел дә сүрелеп куйган чаклар күп, дәресләр кыскартылды, тел аз кулланыла, битарафлык хөкем сөрә. Зур сабырлыклар белән, бирелгән мөмкинлекләрне файдаланып, һәр дәрестә, һәр чарада, укучылар белән бергә булган һәр минутта балаларыбызга татар рухы сеңдерик, башка милләт укучыларына татар теленә, халкына карата хөрмәт хисләре уятыйк! Башкарган эшебез нәтиҗәсез калмаячак. Татар телсез яшәгән вакытлар булды ул узган гасырда да. Яшьлектәге танышым шәһәр җирлегендә үсте. Аларның гаиләсен гаҗәпләнеп күзәтә идем: әти-әнисе татарча сөйләшә, ике балалары русча гына җавап бирә. Ул чорлар өчен гадәти күренеш буларак, урамда ата-ана да баласы белән вата-сындыра русча сөйләшә. Бу егет тәртипле булып үсте, гомере буе җитәкчелектә эшләде, гаиләсе бар, Эдвард һәм Эвелина исемле балалар үстерделәр. Соңгы елларда еш күрештек. Машинасында "Сарман", "Сусау" кебек моңлы көйләрдән торган тезмәләр яңгырый, исем китте! Сорау бирми түзмәдем. "Син бит чит ил музыкасын гына санга суга идең, кем тыңлый бу көйләрне?" – дигәнемә ул кеше үзенең күңелен ачып салды. "Күп нәрсәләргә ирештем, эшем дә, гаиләм дә әйбәт булды. Гомерем үтеп барганда мин бер нәрсәгә генә үкенәм: татарча яшәмәгәнмен! Күңелгә сеңгән булган ул минем, әни сөте белән, әти-әнинең гаилә үрнәге белән дә. Атнага ике мәртәбә кергән татар теле дәресләрендә карт кына укытучы апабыз, укучыларны тыңлата алмагач, дәрес саен бер җыр куя иде. Ул чагында аларны тыңлап, хисләнеп утырганымны хәтерләмим. Укытучы апаның тырышлыгы бушка китмәгән, ике ел буе тыңлаган бу җырлар да татар рухы булып күңелгә сеңеп калган. Яши-яши менә шулар чыга, татарлыгымны яшәтә, шул көйләрне ишеткән саен бик кадерле, таныш, җанга рәхәт икәнен сиздерә. Бер генә үкенечем булды гомеремдә, татарча яшәми калганмын. Оныкларыма Ирек һәм Энҗе исемнәре куштырдым, балалар-киленнәр дә ризалашты, шуңа күңелем булды. Аларның җаннарыннан татарлык китмәсен дип яшим," – диде әңгәмәдәшем. Уйланыр җирлек бар, һәр чор кабатлана! Без, татар теле укытучылары, һәр дәрес саен балага рухи байлык сеңдерәбез икән, татар телен, туган телне өйрәтәбез икән, ул – бушка булмаячак. Нәтиҗәсе иртәгә үк күренмәсә дә, бала күңеленә татар рухы булып сеңәчәк. Яшүсмерләрдә битарафлык хөкем сөрә. Алар бу информацион дөньяда үзләре дә югалып кала. Ә баш миләре исә, "Тик-ток" ише социаль челтәрләр йогынтысында ансат кына кергән, бернинди анализ-синтез таләп итми, фикер тудырмый торган информацияне генә кабул итүгә күнегеп бара. Интернет ресурсларны файдалы куллана белүгә өйрәтү бурычы да кискен килеп басты. Дәресләребездә өстәмә материалны ссылкалар аша биреп, шул ссылкаларны кулланып эшләүне гамәлгә кертү нәтиҗәле икәнен үзебез дә аңладык. Коммьютер технологияләрен, интернет ресурсларны укучы эштә, эзләнүләрдә, теге яки бу мәсьәләне өйрәнүдә кулланырга күнексен. Эзләнү, үзлектән өйрәнү, анализ ясый белү тәҗрибәсе аз

булган саен укучы баланың бу катлаулы тормышка әзерлеге дә аксый. Нәтиҗәдә, тагын бер зур проблема туа. Хәзерге күзәтүләребездән чыгып, бу проблема үсә - зурая бара.

**Икенчесе:**

Узган гасыр, алдагы буыннан тәрбияләнгән чор тоташ бер әзер калып буенча формалашты. Бала мәктәпкә керә, укый, тәмамлый. Һөнәри уку йортына укырга керә, яисә, югары белем ала. Дипломы яклангач, эшкә урнаша, белгечлек буенча эшли башлый. Бар шартлар тудырылган, мөмкинлекләр булдырылган. Яңарыш чоры баласы өчен бу шома гына сукмак алдан ук салынмаячак. Башы – традицион: бала үсә, мәктәпкә керә, тәмамлый. Туры, шома юл инде югары сыйныф укучылары өчен шактый ук кытыршылана башлый. 9 нчы сыйныфлардан ук сайланылган предметлар буенча имтиханнар бирергә туры килә чыгарылыш сыйныф укучысына. Ныклы терәк һәм киләчәкнең таяну ноктасы булырга тиешле фәнне укучы әле аңы һәм психикасы өлгереп җитмәгән килеш, бала вакытта ук сайларга тиеш! Проблема шуннан ук башлана. Ноутбукта казынып утырырга күнеккән балага информатика кызык кебек булып, имтихан предметын 9 сыйныфтан ук “информатика” дип билгеләп, 9 нчыда имтиханнар бирелә. 10-11нчедә укыганда тарих, җәмгыять белеме, социология фәннәренең искиткеч кызык икәнен аңлап алган яшь кеше үзенең берничә ел элек ашыгып нәтиҗәләр ясаганын, ялгышканын аңлый. Әмма чыгарылыш имтиханнары якынлашкан, махсус курслар үтелмәгән, әзерлек вакыты башка юнәлештәге предметларга сарыф ителгән. Нәтиҗә: бала сайлап алу чорында үзенә ни кирәген ачыклау дәрәҗәсендә өлгергән акылга ия түгел. Укучы, ялгыш сайлаганын аңласа да, башын иеп, документларын башта сайлаган факультетына илтеп бирә. Нәтиҗәдә тагын бер үз һөнәрен сөеп бетермәгән “айтишник” барлыкка киләчәк, ә талантлы тарихчы тумый калачак. Еш кына, имтихан предметлары әти-әни, укытучы яки ситуация йогынтысында билгеләнеп тамгалана. 6-7 нче сыйныфлардан башлап, 8-9 нчы сыйныфларга җиткәндә укучы баланың һәрбер уку предметларын һөнәрләр, заманча итеп әйтсәк, һөнәри специалитетлар белән бәйләп тәкъдим итү мөһим. Бала күрсен, белсен, уйлансын, сайлансын. Чыгарылыштан 5-6 ел үткәч, медицина университетларын тәмамлаган укучыларның “ укуны бетердем, врач булып эшлисем килми. Дөрес сайламаганмын!” дигәннәрен еш ишетәбез. Сәбәпләрен ачыклый башласак, “әти-әни кертте”, “дуслар шунда бардылар, мин дә киттем”, “престижно иде” дигән аяныч сәбәпләр ачыклана. Анализ-синтез җитмәгән, баланың мөстәкыйль фикер йөртүе, сайлап алу өчен күзаллау һәм мәйдан киңлеге җитмәгән! Совет заманыннан ук мирас булып калган “профориентация” дигән бик файдалы юнәлеш бар. Һәр предмет укытучысы үз предметына яраклаштырып, һөнәр юнәлеш буенча укучыларга ярдәм оештырып эшләү ихтыяҗы зурайды. Бу заман таләбенә

әйләнергә тиеш! Мәктәпне бетергән, уку йортын тәмамлаган укучы югалып калмасын, эштә һәм тормышта үз урынын тапсын.

Хәзер татар теле укытучысы булып үз эшенә иң тугрылар гына эшләп калды. Барыгызга да сабырлык телим! Безнең эшләгәннәр, тырышканнар бушка китмәячәк, киләчәккә үз эзен салачак.

## Икенче бүлек. Укучылар эшләре.

*Абдульманов Демид, 6 сыйныф, Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районының» инглиз телен тирәнтен өйрәнү белән 33 нче урта гомуми белем бирү мәктәбе " муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесе*
*Җитәкчесе: Ахунова Гөлнур Габдулла кызы, туган*
*телләр һәм әдәбият укытучысы*

### Бөек Ватан сугышы – минем гаиләм хәтерендә

Кереш өлеш

Быел илебез Бөек Ватан сугышындагы Җиңүнең 77 еллыгын билгеләп үтте. Бу зур җиңүгә миллионлаган гап-гади кешеләрнең каһарманлыгы бәрабәренә ирешә алдык. Алар арасында безнең татар егет-кызлары иде: минем әбием, синең бабаң, аныкы... Сугыш афәте кагылмаган, сугыш капка-ишекләрен какмаган гаилә калдымы икән илдә - көндә? Минә шушы сорауга җавап табарга дип үземә максат куйдым һәм үзенең тамырларын истә тотып яшәүче гаилә турында эзләнеп, язарга булдым. Укытучы апам Гөлнур Габдулла кызыны мөрәҗәгать иттем. Миңа ул үзенең әбисе турында сөйләде. Мактау кәгазҗләрен һәм күп кенә медалҗ орденнарын күрсәтте. Мин сезне дә батыр, курку белмәс “Боевой” әби белән таныштырам.

Мин бу конференциядә бик теләп катнашам. Хөрмәтле укытучыбыз, Гөлнур Габдулла кызының әбисе турында сөйләве буенча”- язарга булдым. “Тамырларны истә тотып яшәү...”- исеме нәкъ менә шушы гаиләгә хас.

“Минем әтием Зиатдинов Габдулла Ширәмәт районы (бүген Түбән Кама) Кызыл Чапчак авылында туган, балачак гомеремнең күп вакыты шунда узгач, мин табигатьнең бу гүзәл почмагын үземнең туган җирем дип саныйм. Авылның нәкъ уртасында истәлек булып, сугыштан әйләнеп кайтмаганнарга, безнең бәхетебез өчен газиз башларын салганнарга, хәзер инде бу изге яуда катнашкан, сугыштан исән кайтып туган җирендә вафат булганнарга һәйкәл - обелиск торгызылды. Һәрдаим исәннәргә, бигрәк тә без - яшь буынга сугыш афәтен исебезгә төшереп тора кебек ул. “Әй син, Балам, оныгым минем.

Дөньяда без дә бар идек, син шуны онытмадыңмы? Дөньяның, җир шарының тыныч яшәешенең кадерен беләсеңме?” - дип искәртә кебек ул һәйкәл” – дип сөйли укытучыбыз.

“Әлеге һәйкәлнең “Сугышта катнашып, исән кайткан авылдашлар” исемлегендә бердәнбер хатын - кыз сугышчы - ветеран- минем газиз әбием Шәмсекамал Зиятдин кызының исем фамилиясе дә мәңгелеккә теркәлгән”- ди ул.

“Сугыш һәм хатын - кыз” мәңге тәңгәл килә алмый торган, берничек тә янәшә торырга тиеш булмаган төшенчәләр! Шулай булса да, сугыш афәтендә хатын - кызларга да катнашырга туры килгән. Хатын - кыз язмышлары, әбием язмышы... Уйландыра, тетрәндерә, җаннарны айкап күздән яшь китерә... Батырлыгың, түземлегең каршында баш иям, Әбием!”- дип дәвам итә ул.

Төп өлеш

...Әбием Шәмсекамал Зыятдин кызы Зыятдинова 1916 елның 7 октябрендә дөньяга килә. Ирләр сугышка китү сәбәпле, бөтен ир - ат эшләре хатын - кызлар җилкәсенә төшкән, әбиемә тракторчы һөнәрен үзләштерергә туры килгән. Бик тырыш, чырыш була әбием, көнне-төнгә ялгап җир сөрә, тырмалый, чәчә, ура. Ирләр өчен дә күтәргесез булган әлеге хезмәтнең хатын - кыз өчен никадәр авыр булганлыгын үз башыннан үткәннәр генә белә...Барысына күнеп, ил өчен, фронт өчен кирәк, дип, көнне-төнгә ялгап эшләп йөргәндә, әбием  үз теләге белән яу кырына китә. Бу ил язмышы хәл ителгән 1943 ел була. Әбием Волхов фронтының 44 укчы дивизиясендә сугышчан юлын башлый. Яу кырында да аңа ирләр эше башкару насыйп була: ул- машина (үзе полуторка дип атый иде) йөртүче булдым”- дигән.

“Әбием Бөек Ватан сугышының алгы сызыгында көн саен үлем белән очрашкан. Яңгыр явамы- кармы, бомбалар шартлыймы, кара төнме ул, шомлы урманмы - мөһим түгел,сугыш кирәк- яраклары кушылган җиргә, фронтның алгы сызыгына вакытында барып ирешергә тиеш. Баш очында, тирә - юньдә машинага тиеп диярлек бомбалар, миналар шартлый, ә әбием кеп-кечкенә кулларының сөякләре агарганчы чатырдап машина рулендә ябышкан, тиешле урынга барып җиткәч, сугышчылар әбиемнең кулларын көчкә аерып ала торган булалар...”- икән дип сөйли торган булган.

“Сугыш кырында күрсәткән батырлыклары өчен, сугышчан биремнәрне һәрчак җиренә җиткереп үтәгәне өчен ул “За боевые заслуги” медале, II дәрәҗә Бөек Ватан сугышы ордены белән, күп санлы медальләр, мактау кәгазьләре белән бүләкләнә. Әбием дошманны илебез җирләреннән куып чыгарып, Польша җирләрендә сугыша, Польшаның Млава, Дзялдев, Грудзянз, Тчев, Гнев шәһәрләрен азат итүдә катнаша. Әбиемнең сугышчан бүләкләре - гаиләбезнең иң кадерле ядкяре, һәм алар әбиемнең истәлеге булып, буыннан-буынга күчеп бара” – дип горурлана укытучыбыз.

“Ничек кенә авыр булмасын, тормыш дәвам иткән, узенең ошатып йөргән, ягъни минем бабам белән яшьлек хисләре, мәхәббәт хисләре кабынган һәм этиемне дөньяга китерү өчен әбием демобилизацияләнеп туган авылы Кызыл Чапчакка кайта. Дөньяга Зыятдиновлар нәсел җебен дәвам итеп, этием Габдулла килә, әбием аны бик кадерләп, яратып үстерә. Әтием,  үз авылы кызы, энием Рәзинә белән гаилә кора, һәм алар ике кызга гомер бирәләр.  Әбием соңгы көннәренә кадәр,  безнең гаиләдә гомер кичерде, без әбиемне тәрбияләп, соңгы юлга озаттык”- дип сөйләгәндә Гөлнур Габдулла кызының күзләренә яшь килә.

“ Әбием сугыш турында сөйләргә бер дә яратмый иде. “Сугыш турында сөйлә инде, әбекәй!” - дип бик аптыраткач, “И, балалар, сезгә аны күрергә язмасын!” - дип кенә әйтә иде” - ди укытучым. Әбиебез һәр яшәлгән көнне Ходайдан зур бүләк итеп кабул итте. Бары: “Фронт кырында, әллә үләм, әллә исән калам, дигән көннәр аз булмады” - дип кенә искә ала иде. Сәламәтлеге мөмкинлек биргән чорда, ул мәктәп укучылары белән очрашуларда еш була иде, туган илнең, туган җирнең кадерен белергә, сакларга, һәр тыныч көнгә сөенеп яши белергә өнди иде.

Йомгаклау

Һәр елны, горурлык  хисләре белән без әбиемнең зур фотосурэтен тотып “Үлемсез полк” акциясендә катнашабыз. Моның белән аның исемен мәңгеләштерү өлкәсендә үз өлешебезне кертәбез, дип саныйм.

Әбием 1998 елның 8 сентябрендә вафат булды. “Урының оҗмах түрләрендә булсын, Әбием, без синең белән чиксез горурланабыз!”

**Файдаланылган әдәбият:**

1. “Туган як” газетасы “Әбием-минем горурлыгым” №33 (4213) 8.05.2020

2. Гарипова Ф. “Авылларны сөям җаным тәнем белән”- Казан-1994.

*Абрарова Ильвина, Сафиуллина Адилә, 8 нче сыйныф, Түбән Кама районының “Аерым фәннәрне тирәнтен өйрәнүле 12нче гомуми урта белем бирү мәктәбе” муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесе*
*Җитәкчеләре: Аляшева Роза Абдулкадировна, география укытучысы, Галимуллина Зинфира Индусовна, татар теле һәм әдәбияты укытучысы*

## Бөек Ватан сугышы ветераны Демидова Екатерина Ивановнаның тормыш һәм сугышчан юлы

### Кереш

Рәхмәт сезгә ветераннар.
Буыннардан буыннарга...
Күчә барыр сезнең даннар...
Рәхмәт сезгә, ветераннар!
Берлингача барып җитеп.
Фашистларны тар-мар итеп
Илгә Җиңү китергәннәр,
Рәхмәт Сезгә!
Рәхмәт сезгә, ветераннар!
Х.Халиков.

78 ел элек безнең илебезгә тынычлык килде. Бөек Ватан сугышы тәмамлануга 78 ел үтте. Сугыш еллары артта кала, аның шаһитлары елдан-ел кими, яшәеш дәвам итә, әмма аның җирәнгеч йөзе беркайчан да халык хәтереннән җуелмас.

Сугыш... Бу куркыныч, шомлы сүзне ишетү белән, күз алдына янып каралган иген басулары,ятим калган сабыйлар,газиз ирләрен,сөекле балаларын югалткан аналар килеп баса. Ничә миллион кешенең гомерен өзгән, күпме баланы ятим иткән, аналарны тол калдырган ул. Меңләгән шәһәрләр җимерелгән, җир йөзеннән гөрләп торган авыллар юкка чыккан, шау чәчәккә күмелгән бакчалар янып көлгә әйләнгән. Әлеге афәт беркемне дә читләтеп үтмәгән.

Сугыш хатын-кызлар өчен түгел дисәләр дә, Бөек Ватан сугышы елларында алар да ир-егетләр белән беррәттән яу кырындагы авырлыкларны үз җилкәләрендә татыганнар

.Табигать тарафыннан йомшак табигатьле, нәфис,хисчән итеп яратылган һәм гаиләдәге иң җаваплы, иң четерекле вазифаны – бала тәрбияләүне үтәүче хатын-кызларыбыз да кулларына корал алырга мәҗбүр булган. Әле кичә генә парта артында утырган кызлар меңнәрчә яраланган солдатларны яу кырыннан алып чыкканнар, зениткалар белән дошман самолетларын бәреп төшергәннәр, дошманның ныгытмаларын һәм гаскәрләрен штурмлау өчен сугышчан очышлар ясаганннар. Ә күпме хатын - кыз фронтовиклар партизаннар, элемтәчеләр, шоферлар, снайперлар булып хезмәт иткәннәр?

Җиңү көнен якынайту өчен бар көчен куйганнарның берсе - безнең якташыбыз, Бөек Ватан сугышы ветераны Демидова Екатерина Ивановна. Безнең хезмәтебез бу искиткеч хатын-кызның тормыш һәм сугышчан юлы турында.

**Теманың актуальлеге:** Бөек Ватан сугышы ветераннары турында материалларны туплау һәм киләчәк буыннарга тапшыру, аларның батырлыгы турында хәтерне саклау.

**Хезмәтнең максаты:** Бөек Ватан сугышы ветераны Демидова Екатерина Ивановна һәм аның сугышчан батырлыгы турында мәгълүматны ачыклау, барлау, ситемалаштыру.

Максаттан чыгып, түбәндәге бурычлар куелды**:**

- Түбән Кама шәһәренең 12нче урта мәктәбе укучылары белән оештырылган очрашулар вакытындагы тормыш юлы һәм сугыш турындагы сөйләнгән истәлекләрне өйрәнү;
- сугыш ветераны истәлекләрен анализлау, алар нигезендә аның тормыш, сугышчан юлы тарихын язу;
- тупланган мәгълүматны киләчәк буыннар өчен саклау.

**Хезмәтнең гипотезасы:** хатын-кызлар ир-атлар белән беррәттән авыр сугыш елларының ачысын-төчесен татыганнар, җиңү сәгатен якынайту өчен тиндәшсез хезмәт батырлыклары күрсәткәннәр.

**Тикшерү объекты**: **Бөек Ватан сугышы ветераны Демидова Екатерина Ивановнаның тормышы һәм сугышчан юлы**.

**Тикшерү предметы:** Бөек Ватан сугышы ветераны Демидова Екатерина Ивановнаның тормышындагы вакыйгалар, аның дошманны җиңүгә керткән өлеше.

**Тикшеренү методлары:**

- гаилә архивындагы фото һәм документаль чыганакларны анализлау;
- ветеран сөйләгәннәрне гомумиләштерү һәм системалаштыру;
- Интернеттагы архив материалларыннан ветеран сугышкан хәрби частьнең сугышчан юлын өйрәнү;

**Бөек Ватан сугышы ветераны Демидова Екатерина Ивановнаның тормыш һәм сугышчан юлы**

***Соңгы тапкыр кичә көлде дөнья,***

***Соңгы тапкыр кояш балкыды.***

***Таң атмады бүген, таң атмады,-***

***Алды җирне сугыш ялкыны...***

***(Разил Вәлиев).***

Демидова (Дюсеева) Екатерина Ивановна 1923 елның 24 августында ТАССРның Кама Тамагы районы Антоновка авылында туа. Гаиләдә, аннан башка, абыйлары-Петр һәм Александр да була. Бөек Ватан сугышы башланганда алар, 1939 һәм 1940 елларда чакырылып, Кызыл Армия сафларында хезмәт иткән була.

Сугыш башланганда Еатерина Ивановнага 18 яшь була. Ул Кызыл Армия сафларында хезмәт иткән абыйлары өчен бик борчыла. Акрынлап Антоновка авылында яшәүче ир - атлар бер-бер артлы сугышка китә, ә колхоз эшенең авырлыгы хатын-кызлар һәм яшүсмерләр җилкәсенә төшә. Бу чорны искә төшереп, ул :«Дошман безнең җиребезгә килгәндә, миңа 18 яшь иде.40нчы елда 9нчы сыйныфны, ә 41нче ел башында хисапчылар курсын тәмамладым. Кама Тамагы районының Зур Кармалы авылы сельпосында эшләдем. Тиздән югарырак күтәрелдем, райпода бухгалтер булдым” дип сөйли иде.

Дошман җиребезгә аяк баса, шуңа күрә Украина, Белоруссия һәм Россиянең чик буе өлкәләренең эре оборона предприятиеләре җиһазлары сүтелә һәм Көнчыгышка җибәрелә. Казан СССРның Көнбатыш сәнәгать предприятиеләренең эвакуацияләнгән һәм сүтелгән җиһазлары белән эшелоннар кабул итүче шәһәрләрнең берсенә әверелә. Аларны торак , азык-төлек белән тәэмин итәргә, җиһазларны тизрәк монтажлауны оештырырга һәм хәрби продукция чыгара башларга кирәк була. Шуңа күрә республика авылларыннан күп кенә хатын-кызлар һәм яшүсмерләр, ашыгыч рәвештә төзелгән баракларда яшәп, торф әзерләүдә эшлиләр. Халыкның бер өлеше Идел буенда окоплар казый, чөнки дошман көннән-көн якынлаша…

Екатерина Ивановна да, көзен һәм кыш башында шунда хезмәт куя. Бу турыда ул: «Без немец танклары уза алмасын өчен бөтен дөнья белән окоплар казыдык. Ир-атлар юк диярлек, шуңа күрә бөтен авыр эшне хатын-кызлар, балалар эшләде. 41нче елның кышын онытмыйм, аеруча бер көнен. Зәмһәрир суык көн. Берәүләр одеялга, кемнәрдер берничә толыпка төренеп, басу буйлап барабыз. Шулкадәр суык, салкын тимер бияләй аша кулларны өтә. Битләребезне кар, бәс сарган. Менә без туң җирне вата башлыйбыз. Салкыннан туңган куллар тыңламый, җирне ватып булмый. Ирексездән күздән яшьләр атылып чыга, алар шул арада бозга әйләнеп битне чәнчиләр. Ни өчен, нинди гонаһларыбыз өчен бу безгә? Ә фронттагы солдатлар ничек чыдый икән? Елыйсым килә, әмма булдыра

алмыйм. Мин анда, алар белән бергә булырга тиеш. Һәм мин тагын да тырышыбрак җирне вата башлыйм”дип искә ала ул.
42нче елның августында, Еатеринага 19 яшь тулгач, аны фронтка алалар. Бу алтынчы тапкыр сугышка кызлар җыю була.Екатерина белән бергә 100гә якын 18 яше тулган һәм өлкәнрәк кызлар хезмәт итәргә алына. Башта аларны Идел буйлап зур баржада Чабаксарга озаталар. 4 ай дәвамында аларны элемтәче сыйфатында, төгәлрәге - радистлык хезмәтенә әзерлиләр. Соңрак аларны Ташкентка җибәрәләр.
Кызларны алып килгән Урта Азия хәрби округында, хәрби частьлар оештырыла. Екатерина Ивановна әлеге юлны яхшы хәтерли: «Алты көнгә сузылган әлеге сәяхәтне елмаеп искә алам. Өстебездә ир-ат киемнәре. Юлдагы станцияларда җиләк-җимешләр саталар. Беребезнең дә акчасы юк, шуңа күрә кыйммәтлерәк әйберләрбезне карбыз, кавынга алыштырып алабыз. Юл буе рәхәтләнеп сыйландык”.
Ташкентта кызлар 1943нче елның февраленә кадәр булалар. Биредә аларны сугышка әзерлиләр. Соңрак фронт башлана. Екатерина 22кыз белән 316 нчы элемтә батальонына эләгә . 43нең февралендә ул Орлов юнәлешендә, Сухиничи станциясен таба хәрәкәт итә.Бу вакытларны ветеран: “Алга таба юл юк. Немецлар станцияне Совет гаскәрләренә булмасын өчен юкка чыгарганнар. Без буш, җимерек, харәбәләрдән торган җирдә тукталдык. Монда канкойгыч сугышлар булган. Без килгәч, җирле халык качкан җирләреннән чыгып, землянкалар казый башлады.  Без барлык җиһазларны һәм киемнәрне зиратта бушаттык, ачык һавада, палаткаларда яшәдек. Безнең гаскәрләр немецларны Орлов дугасы буйлап куа иде инде. Без төньякка юл тоттык"дип искә ала.
Екатерина Ивановна фронтта радиотелеграфист була.Ул үзләрен тиз генә укытуларын, һәр нәрсәне тиз арада отып алырга кирәк булганлыгын искә ала. Морзе азбукасын, элемтә чараларын өйрәнергә бер - беребезгә булыштык.  Элемтәче өчен иң мөһиме-сигналны төгәл тапшыру, сугышчан операцияләрнең уңышлы узуы шуңа бәйле. "Элемтә — һәрвакыт изге эш, ә сугышта-тагын да мөһимрәк...", бу элемтәчеләрнең лозунгы була. Элемтә  Бөек Ватан сугышында зур роль уйный, бер генә җитди сугыш та аннан башка бармый. Ышанычлы элемтә чараларыннан башка гаскәрләр белән идарә итү— бүлекчәләрне оператив рәвештә удар йодрыкка җыю яки аларны сугыш кырында нәтиҗәле җитәкләү мөмкин булмый . Ышанычлы элемтә чараларыннан башка гаскәрләр белән идарә итү мөмкин булмый— [5].
Бөек Ватан сугышында элемтәчеләрнең роле турында вице-адмирал Г. Г. Толстолуцкий үзенең "Арктикадан эфирда"дип аталган истәлекләрендә болай дип сөйләде: "Элемтәчеләр, аларның сугыштагы батырлыклары турында күп язылмаган. Кайчакларда хәрби элемтәчеләрнең эшчәнлеге бертөсле, сугыш вакыйгаларыназур йогынты ясый алмый кебек тоела. Ә менә очучылар, разведчиклар, танкчылар, артиллеристлар... Аларның хәрби

хезмәте романтикага бай.

Сүз дә юк, очучылар да, танкчылар да башка хәрбиләр дә Бөек Ватан сугышы вакытында батырлык һәм каһарманлык могҗизалары күрсәтте. Әмма элемтәчеләр дә каты бәрелешләрдә катнашканнар. Дөрес, алар еш кына эфирда алып барылган.». [5]

Сугышта барысын күрергә туры килде, әмма иң авыры иптәшләренең, полкташларның үлемен кичерү булды, моңа күнегеп булмый. Сугышта иң тирән истәлекле вакыйгаларның берсен искә алганда Екатерина Ивановнаның күзләренә яшьләр тыгыла : «Бер тапкыр, бомбага тотканда, бер солдат мине радистлар кабинасыннан чыгарды һәм ашыгыч рәвештә яшеренергә кушты. Качардай урын юк иде. Берничә адым читтәрәк траншея күреп алдым. Анда һава атышлары вакытында кешеләр яшеренә иде. Ул бары 12 кеше сыйдырышлы, мин 13нче идем. Һәм мин башка җиргә яшеренергә булдым. Шинелемә төренеп, куаклар астына кереп яттым. Берничә секундтан ату тавышлары яңгырады. Фашист снаряды нәкъ менә шул траншеяга төште. Андагы кешеләрне ул кисәкләргә телгәләп атты. Ә минем бары аягым гына җиңелчә яраланды».

Әмма фронтта шатлыклы вакыйгалар да була, алар арасында хатлар аерым урын алып тора. Хатлар, гади өчпочмаклы солдат хатлары … Нәкъ менә алар кешеләрне үзара аралаштыра, табыштыра. Екатерина Ивановна да хатлар трында сөйли торган була. Әнисенең, сеңелкәшләренең авыл хәлләре турында язган хатларын искә ала. Әнисенең һәр хат саен аның өчен, абыйлары өчен алладан исәнлек соравын әйтә. Сугыш башыннан ук алынган абыйсы 1941нче елның декабрендә хәбәрсез югала. Туганнардан тыш хатлар дуслардан, хәтта бер таныш булмаган кешеләрдән дә килә торган була.

Күп кенә интервьюларында Екатерина Ивановна үзе өчен бик кадерле булган тагын бер кешене еш искә ала: «Уртанчы абыемның хезмәттәше Василий исемле очучы да яза иде миңа. Минем аны бер дә күргәнем булмады, шулай да хатларына җавап бирә идем. Аның хатларыннан ниндидер җылылык бөркелә иде. Ул мина, мин-аңа фотоларыбызны җибәрдек. Шулай итеп безнең арада хатлар аша роман башланды. Сугышчылар арасында татуировка ясарга оста кеше барлыгы беленгәч, теләк белдерүчеләр чират алды. Кемдер сөйгәненең исемен, кемдер бармагына йөзек, туганнарының исемен , туган җирләре атамаларын ясаттылар. Ә мин сул беләгемнең күренә торган җиренә “Вася” дип яздырдым.

Тиздән мин кайгылы хәбәр алдым. Хәрби очышларның берсе ваыкытында минем Васям каһарманнарча вафат булган. Минем аны бер тапкыр да күргәнем булмады, әмма гомерем буе аны хәтеремдә сакладым».

Бөек Ватан сугышы ветераны Демидова Екатерина Ивановна күп бүләкләргә ия була. Аның өчен иң кадерлесе - 1944нче елның 8нче мартында, сугыш кырында бомбежка вакытында палаткада тапшырылган медаль.

Бүләккә тәкъдим итү документында: “36 гвардия укчылар корпусы составында сугыш хәрәкәтләре вакытында иптәш Дюсеева ВТС телеграфисты булып эшли һәм оператив документларны корпус штабыннан дивизия штабына вакытында тапшыруны тәэмин итә.

Җәйге операцияләрдә безнең частьлар һөҗүм иткән көннәрдә экспедитор белгечлеген үзләштерә. Инициатива һәм үҗәтлеге ярдәмендә ул бер үк вакытта коммутаторны өйрәнә - телефончы белгечлеген үзләштерә. Мөстәкыйль рәвештә элемтә үзәгендә эшли.

1944 елның 3-5 февралендә Матрасы-Городище торак пунктларында дошман оборонасы өзелеп торган көннәрдә коммутатор янында өзлексез дежур тора һәм барлык элемтә линияләре буенча өзлексез элемтә тәэмин итә ала.

Шилово-Обитель районында 1944 елның 3-5 мартында КП корпусының элемтә узелында эшли һәм бу эшне тулысынча башкара.

Хөкүмәт бүләгенә лаек.

"Сугышчан казанышлары өчен" медален тапшыру өчен тәкъдим ителә” дип язылган [6]

Батыр элемтәче булган частьлар Карачев, Невель, Беркут һәм башка бик күп шәһәрләрне азат иткәннәр.

1945 елның язында Көнчыгыш Пруссиядә канкойгыч сугышлар бара. Икенче бөтендөнья сугышы тәмамлану вакытының төп вакыйгаларының берсе Кенигсбергны азат итү була.. Сугыш хәрәкәтләренең масштабы буенча Көнчыгыш Пруссия территориясендә искиткеч фронт башлана! Шул ук вакытта, Кенигсберг операциясе - шәхси составны бик аз күләмдә генә югалтып , яхшы ныгытылган шәһәрне яулап алуның иң яхшы мисалы. Совет армиясенең нәкъ менә бу җиңүе бөтен Көнчыгыш Пруссия операциясендә хәлиткеч роль уйный һәм Берлинга юл ача. Нәкъ менә биредә сугыш бетү, Җиңү турындагы хәбәр килә.

Дюсеевлар гаиләсеннән өч фронтовик өйләренә әйләнеп кайта:Петр, Александр һәм Екатерина. Екатерина Ивановна 1945 елның августында демобилизацияләнә һәм үзенең туган авылы Антоновкага кайта. Озакламый ул авылдашы, фронтовик Демидов Николай Андриановичка кияүгә чыга.

Сугыштан соңгы еллар авыр була, сугыш үткәндә калган булса да, кешеләр ачлыктан интегәләр. Екатерина Ивановна төрле эшләрдә эшли, берара башлангыч сыйныф укучыларын да укыта. Балалар мәктәпкә еш кына ярымач килеш киләләр. Ветеран : «Мин балаларны бик кызгана идем. Әнием колхозда икмәк пешерүче булып эшли иде. Мин класстагы балаларга икмәк алып килә һәм балалар аны рәхәтләнеп ашыйлар иде” дип искә ала.

Очрашуларда интервьюлар биргәндә, Екатерина Ивановна тормыш иптәше белән бик бәхетле гомер итүләре, ике ул, ике кыз үстерүләре турында горурланып сөйли. 1969нчы

елда тол кала һәм 1979нчы елда улы янына Түбән Кама шәһәренә күченеп килә. Биредә ул гомеренең соңгы көннәренә кадәр яши. Екатерина Ивановна 2018нче елда вафат була.

Безнең мәктәп укучылары микрорайоныбызда гомер итүче сугыш, тыл ветераннары белән аралашып яши. Екатерина Ивановна безнең мәктәптән ерак яшәмәгән. Шуңа күрә, еш кына мәктәбебезгә очрашуларга килә торган була.Ул бик теләп, сыйныф сәгатьләренә килә һәм сугыш еллары турындагы исәлекләре белән уртаклаша, укучыларга үзенең акыллы киңәшләрен бирә торган була. Ул аларны Туган илне яратырга, туганнарын кадерләргә чакыра.

Ул бик аралашучан, мөлаем кеше була. Укытучылар, укучылар белән очрашуларда ул: “Барысы да яхшы булыр, боларны да тәрбияләрбез, тормыш итәргә әзерләрбез”дия торган була. Ул бик кунакчыл кеше була. Укучылар еш кына аның янына баралар. Ул чәй өстәле янында алар белән истәлекләре белән уртаклаша. Соңгы көннәренә кадәр Екатерина Ивановна балалары, оныклары яратуын тоеп, кадер-хөрмәттә яши.

**Йомгаклау**

Бөек Ватан сугышы, кешелек дөньясына иң зур югалтулар, бәла-казалар алып килә..

Аяусыз бәрелешләр, киселгән гомерләр, ятимнәрнең ачы күз яшьләре. Күпме ватандашыбызның вакытсыз гомере өзелгән, күпмесе гариплэнеп кайткан, хәбәрсез югалган, ә күпме ир-егет фашист концлагерендә газапланган, үтерелгән. Шулар бәрабәренә Бөек Җиңү яуланган. Безнең ул көннәрне онытырга хакыбыз юк. Бездән соң киләчәк буыннап да бу хакта белергә тиеш.

Әлеге фәнни хезмәт өстендә эшләр алдыннан без үз алдыбызга түбәндәге максатны куйдык: Бөек Ватан сугышы ветераны Демидова Екатерина Ивановна һәм аның сугышчан батырлыгы турында мәгълүматны ачыклау, барлау, системалаштыру. Без үз максатыбызга ирештек, тикшеренү эшенең гипотезасы расланды: Екатерина Ивановна - Бөек Ватан сугышында Җиңү өчен үзеннән зур өлеш керткән шәхес.

Бөек Ватан сугышы ветераны Демидова Екатерина Ивановнаның тормыш юлын өйрәнеп, без ул чордагы вакыйгалар турында тагын да күбрәк белдек. Ветеран турындагы истәлекләр белән танышканда без бер үк вакытта курку да, горурлану хисләре дә кичердек. Тарих безнеңчә, вакыйгалардан, гади генә кешеләрнең язмышларыннан төзелә. Җиңү безнең халкыбызга җиңел генә бирелмәгән. Беркем дә, бернәрсә дә безнең хәтеребездән җуелмаска тиеш . Безнең тикшеренү эшебезне темасы актуаль, кызыклы гына түгел, практик әһәмияткә дә ия.

**Кулланылган чыганаклар, әдәбият**


1. Демидова Екатерина Ивановнаның гаилә архивы
2. podvignaroda.mil.ru сайты


3. 12нче мәктәптә оештырылган чаралардан фотолар җыелмасы
4. https://mybiblioteka.su/
5. https://pamyat-naroda.ru/
6. http://veteran-tatar.ru/


**Кушымта**






Рәс.1. Сугышчы Дюсеева Екатерина  Ташкентта (запас полкта) [7]







Рәс.2. Составында Демидова (Дюсеева) сугышкан 316нчы хәрби частьнеңсугышчан юлы [5,7]




Рис. 3. Бөек Ватан сыгышы ветераны Демидова Екатерина Ивановнаның бүләкләре[7]



НАГРАДНОЙ ЛИСТ

1. Фамилия, имя и отчество..... Дюсеева Екатерина Ивановна

2. Звание.. Мл. сержант ....3. Должность, часть.. Ст. телеграфист - морзист Штабной роты 316 Отдельного батальона связи 35 Гв.СК

Представляется к Медали "За боевые заслуги"

4. Год рождения 1923 .5. Национальность. Русская ....6. Партийность Член ВЛКСМ

7. Участие в гражданской войне и в послед. боевых действиях по защите СССР.
Отечественная война с июня 1943 года

8. Имеет ли ранения и контузии в Отечественной войне.. Не имеет

9. С какого времени в Красной Армии... С августа 1942 г.

10. Каким РВК призван...... Камско-Устьинским РВК Татарской АССР

11. Чем ранее награжден /за какие отличия/.... Наград не имеет

12. Постоянный домашний адрес /представляемого к награждению или его семьи/
[illegible]

I. Краткое, конкретное изложение личного боевого подвига или заслуг.

За время боевых действий в составе 35 Гв.СК тов. Дюсеева сумела работать телеграфистом на ВТС и всегда обеспечивала своевременную передачу оперативных документов от штаба корпуса к штабу дивизии.

В летних операциях в дни наступления наших частей овладела специальностью экспедитора.

Благодаря инициативе и настойчивости сумела одновременно с этим изучить коммутатор - овладеть специальности телефонистки. Самостоятельно работает на узле связи.

В дни прорыва обороны противника в районе нас. пунктов Матрасы - Городище 3 - 5 февраля 1944 года непрерывно дежурила у коммутатора и сумела обеспечить бесперебойную связь по всем линиям связи.

В районе Шилово - Обитель 3 - 5 марта 1944 года работает на узле связи НП командира корпуса и с этой работой вполне справляется.

Достойна Правительственной награды.

Представляется к медали "ЗА БОЕВЫЕ ЗАСЛУГИ".

Командир 316 ОБС
Майор [signature] /Олешкевич/

С представлением СОГЛАСЕН:

Начальник связи 35 Гв.СК
Гвардии инженер-подполковник [signature] /Махов/

Рис. 4. "Сугышчан казанышлары өчен" медален тапшыру өчен тәкъдим ителү документы [6,7]




Рис. 5. Демидова Екатерина Ивановнаның гаиләсе. 7]




Рис. 6. Демидова Е.И. укучылар белән очрашу вакытында (2016нчы ел) [2]



Рис. 7. 7а класс Демидова Екатерина Ивановнада кунакта ( 2017нче ел) [2]




Рис.8. Демидова  Е.И. Җиңү бәйрәме көнендә, ветераннар белән очрашуда 2018 нче ел[2]



Рис.9.БөекВатан сугышы ветераннары Костин С.Д., Демидова Е.И., 2018 нче ел [2]

**ДЮСЕЕВ Петр Иванович,** 1915 г.р., место рожд.: с.Антоновка. Моб. в 1939 г., ряд., демоб. в 1944 г. Место раб.: Камско-Устьинский гипсовый рудник, водитель. Умер в 1994 г., похоронен в п.Тенишево.


Камско-Устьинский
Лаишевский




Дюсеев Александр Иванович родился 20 июля 1921 года, в селе Антоновка Камско-Устинского района ТАССР. Русский. Беспартийный. 9 октября 1940 года был призван в ряды Советской Армии в батальон связи при 5-ом механизированном Сталинском корпусе в Забайкалье. Боевой путь Александра начался в июне 1941 года на Украине в городе Бердичев. Был ранен и после излечения в госпитале его направляют, для дальнейшего прохождения службы, в 10-ый полк 83-ой Краснознаменной дивизии Карельского фронта командиром 120-го мм. миномета. После присвоения звания младший лейтенант Александра Ивановича назначают командиром взвода управления разведки. В конце 1944 года в составе взвода минометов участвует в прорыве Мурманской обороны, освобождении Советского Заполярья. Демобилизовался в апреле 1946 года.

Награжден орденом Отечественной войны 2-степени (1985г.), медалями «За боевые заслуги» (1943г.), «За победу над Германией», «За оборону Советского Заполярья» (1944г.), Юбилейными медалями. В мирное время А.И.Дюсеев работал в сельском хозяйстве на различных должностях. Жил в с.Никольское.

| Фамилия Имя Отчество | г.р. | год выбытия | место рожд. | место выбытия | Цитата |
|---|---|---|---|---|---|
| ДЮСЕЕВ АЛЕКСЕЙ ИВАНОВИЧ | 1909 | 1941 | с.Антоновка | | **дюсеев** алексей иванович ... |
| ДЮСЕЕВ ВЛАДИМИР СТЕПАНОВИЧ | 1919 | 1942 | Камскоустьинский р-н,с.Антоновка | Губкинский р-н,с.Лукьяновка | **дюсеев** владимир степанович ... |
| ДЮСЕЕВ ПАВЕЛ ИВАНОВИЧ,1917 | 1911 | 1942 | Камскоустьинский р-н,с.Антоновка | | **дюсеев** павел иванович,1917 ... |
| ДЮСЕЕВ ПАВЕЛ ТИМОФЕЕВИЧ | 1924 | 1943 | Камскоустьинский р-н,с.Антоновка | | **дюсеев** павел тимофеевич ... |
| ДЮСЕЕВ ПЕТР АНДРЕЕВИЧ | 1905 | 1942 | с.Антоновка | | **дюсеев** петр андреевич ... |




*Арсланов Айдар, 9а сыйныф, Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районының «Аерым фәннәрне тирәнтен өйрәнүле 12 нче гомуми урта белем бирү мәктәбе» муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесе*
*Җитәкчесе: Галимуллина Зинфира Индус кызы, татар теле һәм әдәбияты укытучысы*

**Шигъри сәяхәт**

Дөнья мәшәкатьләреннән арганда
Кулыма китап алам,
Җәлил әсәрләре буйлап,
Шигъри сәяхәт кылам .
Җәлилнең иҗат дөньясы
Кызыклы, ымсындыргыч.
Кайчакларда бик көлкеле,

Ә кайчакта кызганыч .
Геройлар белән бергәләп
Шатланам, яшим,сөям,
Явыз дошманнарга каршы
Нәфрәт утында көям.
Кыска итәкле Хәдичә,
Томаулы егет гыйшкы...
Күпме генә укысам да,
Кимеми һич кызыгы,
"Бүреләр ", "Вәхшәт"не укысам,
Күңелемдә нәфрәт туа.
Ничек кешеләрдә шулкадәрле
Явызлык була ала?
"Җырларым ", "Катыйльгә"не укып
Горурланам, сокланам,
Кеше рухының чиксез көчле
Ныклыгына ышанам.
Җәлил әсәрләре үлемсез
Сихри бер көчкә ия,
Авырлыкка юлыкканга
Ышаныч, куәт бирә.
Шатлансам да, кайгырсам да,
Кулыма китап алам ,
Шигъри сәяхәт кылып
Юанам, илһамланам.

*Әсхадуллина Айзилә, 9 сыйныф, Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районының «35нче лицей» муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесе*
*Җитәкчесе: Яруллина Гөлүсә Сәетгәрәй кызы, татар теле һәм әдәбияты укытучысы*

## Сугышның да үз романтикасы...

## (Шагыйрь йөрәкле солдат - Гыйләҗев Фаекъ Гыйләҗетдин улы.)

**КЕРЕШ**

**Теманың актуальлеге**

Бөек Ватан сугышында Җиңүгә дә 75 ел тула. Кешелек дөньясын саклап калган каһарманнарыбызның, тыл ветераннарының батырлыгы әле дә булса хәтердә. Без аларның фидакарьлеген онытмаска, киләчәк буыннарга тапшырырга тиешбез. Сугыш турында бик күп әсәрләр язылган, эзләнү эшләре алып барыла, батырлар ачыкланган. Ә менә тирә ягыбыздагы гади солдатлар турында без ниләр беләбез, аларның нәсел-нәсәбәләре кемнәр? Бу фәнни эшем орденлы сугышчы Фаекъ Гыйләҗевка багышланган. Аның сугыштан язган хатлары бүгенге көндә дә саклана. Хатларның үзенчәлеге шунда, алар шигъри юллар белән язылган. Шигырьләр стиль, размер ягыннан таләпләргә туры килеп бетмәсә дә, хатлара аларның үз-үзләрен аямыйча, батырларча көрәшүе тасвирлана. Фашизмга булган нәфрәт хисеаның күңелендәге олы мәхәббәтне дә, матур хыялларын да кысрыклый алмаган.

**Теманың өйрәнелү дәрәҗәсе.**

Бу тема буенча эшне башкарганда, мәрхүм Гыйләҗев Фаек Гыйләҗетдин улының якын туганнарының истәлекләрен җыйдым, документларының ксерокопиясен ясадым, Фаек аганың әдәби ядкарьләрен тупладым, вакытлы матбугат архивын өйрәндем. Сайтлардан картографияне Файдаландым. Нәтиҗә ясап, барлык материалны иҗади эш рәвешенә китердем. Эшләү кызыклы булды, чөнки Фаек аганың кызы, эшемнең җитәкчесе Гарифзянова Нурзалия Фаековна, мәктәбебездә укытучы булып эшли.

**Фәнни эшнең максат һәм бурычлары:**

1. Укучыларның һәм әти-әниләрнең тирәбездә бетә барган сугыш һәм тыл ветераннарына игътибарын арттыру. Гади солдатның сугышчан юлын өйрәнү.
2. Документларның ксерокопиясен ясау, Фаек аганың әдәби ядкарьләрен җыйнау.
3. Язып алынганнарны туплау, эшкәртү, иҗади эш башкару.

4. Укучыларда үткәнебезгә горурлык хисе тәрбияләү, Бөек Ватан сугышы тарихына кызыксыну хисе тудыру.

**Өйрәнү объекты:** Фаек аганың сугыштан язган шигъри хатлары.

**Тикшерену методлары:** эшебездә эзләнү, чыганаклар анализы, синтез, күзәтү алымнары кулланылды.

**Эшнең гамәли әһәмияте:** әлеге хезмәтне әдәбият дәресләрендә, сыйныф сәгатьләрендә файдаланырга мөмкин.

**Эшнең структурасы:** хезмәт керештән, төп өлештән, йомгаклау бүлегеннән, файдаланылган әдәбият исемлегеннән тора.

**ТӨП ӨЛЕШ. Шагыйрь йөрәкле солдат - Гыйләҗев Фаекъ.**

Әдәбиятта “сугыш романтикасы” дигән каршылыклы ике сүздән торган төшенчә бар. “Сугыш” сүзен ишетүгә, күз алдына атыш, кан, үлем, курку һәм күз яшьләре килә... Ләкин сугыш еш кына башка сүзләр белән дә янәшә йөри: батырлык, намус, дан, яшьлек һәм мәхәббәт, Туган илне саклау һәм ярату – болар барысы да әлеге чорның романтик асылын тәшкил итә. Нинди генә дәһшәтле вакытны сурәтләсәләр дә, язучылар еш кына сугышның нәкъ менә шул “икенче” ягына игътибар итәләр. Миндә эзләнү эшемне шушы юнәлештә алып бардым.

Ветераннар илебездә Җиңү көнен бәйрәм иткән мизгелне үзләренә генә хас хис-кичерешләр белән сөйлиләр. Мәйданга җыелып, бар халыкның Бөек көнне туганнарча уртаклашуы, җырлап-биеп бәйрәм итүе, чыңлы гармун тавышлары – онытырлыкмы соң! Көттереп килгән, маңгай тире белән генә түгел, кан белән дә юланган, меңләгән гомерләр өзелү хисабына ирешелгән Җиңү яме һәр йортка, һәр гаиләгә үтеп керә. Сазлыклы урыннарда фашист илбасарларын тар-мар итүләр, җиңүне якынайту өчен җил-давыллы яңгырда, карлы буранда, чыдап булмаслык эсседә, көнне - төнгә ялгап, алга барулар - берсе дә эзсез узмый, һәр солдатның күңелен, тәнен камчылый, мәңге җуелмаслык булып йөрәкләргә уела.

**Балачак, үсмер еллар.**

Авылыбызның шагыйрь йөрәкле солдаты булган Фаек ага, 1922 елның 11 нче апрелендә Шеңшеңәр авылында туган. Ул сигез яшьтән төрле хуҗалык эшләрендә катнаша башлый. Ул заманда белемне туган авылында,җидееллык мәктәптә ала.Фәннәрне бик яхшы үзләштерә. Мәктәпне тәмамлагач та аны укытучы итеп билгелиләр. 1937-1942 елларда ул уку йортында эшли.

**Сугыштан язылган шигъри хатлар.**

20 яшьлек егет 1942 елның февралендә 73 нче номерлы укчы полк составында Мәскәү асты сугышларына җибәрелә. Аннан озын фронт юлы...Курск дугасы, Сталинград

сугышлары, Польша, Чехословакияне азат итү, Берлин. Бу авыр юлларны сыкранмыйча, өмет белән узарга тылда калган туганнар, сөйгән яры ярдәм иткән.

Исеңдәме, иркәм, мин киткәндә,
Синең белән соңгы очрашу.
Дошманнарны җиңеп, мин кайтырмын,
Килми калмас безнең күрешү.
Мин хәзергә синнән бик еракта,
Безне аерды тормыш дулкыны.
Синнән башка һичкем сүндерә алмас,
Кайнар йөрәк, сөю ялкынын.
Сине сагынып, синнән хатлар көтәм,
Кайнар сәлам язам мин сиңа.
Синнән алган һәрбер сәлам хаты
Көч һәм дәрт бирә миңа.
...Киләчәктә безнең тормыш тагы да
Матурланып чәчәк атачак,
Безгә каршы күтәрелгән ерткыч-Гитлер
Хәрәкәтсез җирдә ятачак.

Бу юллар Фаек аганың фронттан язган беренче хатларыннан өзек. Баштанаяк коралланган кансыз дошман илебез башкаласы Мәскәүгә якынлашкан иң авыр көннәрдә үк инде гап-гади авыл егете дә үзләренең барыбер җиңәсенә тирән ышана, меңнәрчә совет солдаты белән бер сафта якты киләчәк өчен батырларча көрәшә. Авылдашыбыз Бөек Җиңүне корал белән генә түгел, салкын окопларда каләм белән дә яулаша.

Йөзләрчә солдатлар белән бергә дошман атакаларын кире кайтаруда катнаша. Төрле якта мина тавышлары яңгырый… Югарыдан бертуктаусыз пуля яңгыры коя…1942 нче елның маенда әнә шундый бәрелешләрнең берсендә күрсәткән батырлыгы өчен рядовой Фаек Гыйләҗев та “Батырлык өчен ” медаленә лаек була, әмма медаль аңа 1949 елның 16 нчы маенда гына тапшырыла.

1942 нче елның августында аларның часте каты сугышлар алып бара. Әнә аларның ротасы атакага күтәрелә. Колак төбендә сызгырган пулялардан, үлемнән котылу өчен бердәнбер юл – мөмкин кадәр тизрәк дошманокопларына барып җитү. Калганын нәфрәт һәм үч уты белән янган солдат кулындагы рус штыгы хәл итә. Монда җитезлек, тәвәккәллек, куркып калмау мөһим. Шул мәшхәрдә пуля тиеп, авылдашыбызның аягы каты яралана. Ул көнбагыш басуында ятып кала. “Әле ярый чигенү булмады, әсирлектә кала

идек,”- дип сөенеп сөйли торган була Фаекъ ага. Аны санитарлар табып ала һәм 3666нчы номерлы эвакогоспитальгә озаталар.

Кара савыты эчләрендә
Әйләнә каләмнәрем.
Сөйгән ярым Галиябану,
Ялкынлы сәламнәрем.
Матур буяулап эшләнгән
Кулымдагы таягым.
Канлы фронт эчләрендә
Ранный булды аягым.
Яулыклар белән төрсәм дә,
Агып чыкты каннарым.
Явыз дошман утларында
Чыга язды җаннарым.
Койкама утырамын да
Карыймын як-ягыма.
Әти-әни, туганнарым,
Басалмыйм аягыма.

Үтәр еллар,үтәр авыр көннәр,
Ничек булыр инде киләчәк?
Сорау куям, җавап бирә алмыйм-
Тормыш үзе җавап бирәчәк.
Юк, бирешмим әле чит уйларга,
Матур тормыш безгә киләчәк.
Туган җиребез өчен көрәш бара,
Минем халкым барыбер җиңәчәк,-

дип, шул заман солдатына хас булганча, эчке ышаныч белән тәмамлый ул шигъри хатын.

Фаекъ Гыйләҗев госпитальдән чыккач, нестроевой частька җибәрелә. Әмма моның белән һич тә ризалашырга теләми ул. Көндә командирыннан үзен алгы сызыкка җибәрүләрен үтенә һәм теләгенә ирешә. 1943 елның январеннан 18 нче номерлы мотоукчы бригадага билгеләнә. 1943 елның августеннан 1381 нче номерлы артиллерия частенда хезмәт итә, зенит пушкасына төзәүче итеп билгеләнә. Данлыклы Курс дугасы сугышларында катнаша. Күп кенә дошман самолётларының башына җитәләр. Фаекъ

Гыйләҗев шушы частьта җиңү көненә кадәр сугыша. Кызыл Армия составында бик күп торак пунктларны азат итүдә катнашканнан соң, алар көнбатышка юнәлә.Шартлаулар тынып торган арада язылган хатларында мондый юллар бар:

Көнбатышка, озын ерак юлга,
Гөрләп уза безнең танкистлар.
Артиллерия залпом ут ача да,
Төтен булып оча фашистлар.
Туган илем өчен, газиз анам,
Безне үстерде хәләл сөтегез.
Көчегездән килгәнчә, фронт өчен,
Җиңү өчен ярдәм итегез.

Без еракта, без канлы көрәштә,
Безне көтә туган илебез.
Озакламый шатлыклы көн килер,
Без кайтырбыз, безне көтегез.

Ләкин аңа Берлинга барып җитәргә насыйп булмый. Бөек Җиңү хәбәрен Берлиннан 30 чакрым читтәге шәһәрдә ишетә. Бу сурәте Чехословакияне азат иткәннән соң җиңү сәгатьләрен көткәндә. Сугышта күрсәткән батырлыклары өчен күп кенә медальләр һәм Беренче дәрәҗә Ватан сугышы ордены белән бүләкләнә.

**Тыныч тормышта.**

1945 елның декабрендә Фаекъ Гыйләҗев туган авылы Шеңшеңәргә кайтып төпләнә.Совет органнарында эшли, колхозчылар белән бергә колхозны "күтәрә". Әмма авылдашлары аны сәнгатькә гашыйк кеше буларак, юксынып искә ала.

1946 нчы елның көзендә сөйгән кызы Галиябануга өйләнә. "Сугыштан синең көтүең мине исән-имин алып кайтты, сиңа булган ышанычым, яратуым ут-давылларны кичәргә ярдәм итте"- дип әйтә торган булган ул. Сугыштан соңгы чорлар бик авыр булса да, яшьләр яратышырга да, өйләнешергә дә, тормышларын көйләргә дә вакыт табалар. Дүрт ел буе ачлык-ялангачлык белән көрәшкән авылдашлар җыр-биюгә сусаганнар икән. Клубтагы бер генә чара да Фаекъ белән Галиябанудан башка узмый: икесе дә матур биючеләр; берсе телгә, икенчесе җырга оста кешеләр. Ул елларда һәр авыл сәхнәсендә Мирхәйдәр Фәйзинең "Галиябану"ы куела. Хәлил белән Галиябануны уйнаган парлар озакламый өйләнешәләр, бер-бер артлы алты кыз бала туа. Ул чагында да Фаекъ ага шигырьләр язуын дәвам итә. Колхозчылар җыелышының берсендә атларга булган начар караш турындагы шигъри юллар белән сөйләгән тәнкыйть чыгышын әле дә искә

алгалыйлар. Читтәге кызларына да хатларын шигырьләр белән яза. Тормыш җайланганга куанып кына гомер итә башлаган вакытта гаиләләренә зур хәсрәт килә.

Ачлык, ялангачлык эзсез узмый- әниләре ревматизм чиреннән 1968 елда алты баласын калдырып үлеп китә.

Язмышның явыз шаяруы Фаекъ аганы аяктан ега алмаган. Авылның ипле, эшчән хатыны Гөлсем апа балаларга әни булып килә.Үги әни дисәләр дә, бу таләпчән апаны балалар якын итәләр. Матур киенәләр, тәмле ашыйлар, аңа ярарга тырышып, эшкә өйрәнеп үсәләр. Шуңа күрә кызлар аңа бүген дә бик рәхмәтле.

Кызлар барысы да югары яки махсус белем алып, абруйлы урыннарда эшләп, лаеклы ялга чыгалар, оныклар тәрбиялиләр. Нурзалия апа мәктәптә балалар укыта. Бер-бер артлы 6 кыз туганда, әтиләре Фаекъ ага бик тә малай көткән. Нурзалия апага, төпчек кызына, туйда:

“Алты кызга алты кияү булды,
Ун оныкка бары бер малай.
Кызым, кияү, сездән көтәм малай,
Алып кайтыгыз, давай”- дип яза ул.

Аның теләге кабул була: Нурзалия апа ире Хәлил абый белән өч ул үстерәләр.

Үзенең 60 еллык юбилеена Фаекъ ага түбәндәге юлларны яза:

Яшьлегемә кире кайтыр идем,
Менәр идем тауның башына.
Озакламый инде язылыр шул,
Үлде диеп каберем ташына.

Оныкларга, үзе көткән малайларга сөенеп яшисе урында, Фаекъ Гыйләҗев 1987 елның 14 маенда йөрәк өянәгеннән кинәт вафат була.

**Йомгаклау.**

Бөек Ватан сугышы ветераны Фаекъ Гыйләҗевның түбәндәге дәүләт бүләкләре бар:

1. Медаль ”За взятие Берлина”, 2 май, 1945ел
2. “Медаль за освобождение Праги”, 9 май, 1945ел
3. Медаль “За Победу над Германией в Великой Отечественной войне 1941-1945 гг.”,13 июль, 1946 ел
4. Медаль “За отвагу ”, 16 май, 1949 ел
5. Орден Отечественной Войны 1 степени, 14 март, 1985 ел

Бөек Ватан сугышы... Бөек Җиңү... Бу вакыйгалар, андагы батырлыклар 75 еллык тарих катламы астында калды. Ләкин әнә шул катламнар астында югалмыйча, кешелек дөньясын юкка чыгудан саклап калган, бүгенге көннәргә кадәр халык күңелендә, ил

йөрәгендә онытылмаган каһарманнарыбызның батырлыклары әле исән, дөнья тарихында алтын хәрефләр белән язылган. Алар арасында Фаекъага Гыйләҗев кебек гап-гади солдатлар да бик күп. Шуңа күрә безгә аларны онытмаска, сугыш ветераннарын, тыл батырларын хөрмәт итәргә, зурларга, батырлыкларын киләчәк буыннарга тапшырырга тиешбез.

Фәнни-тикшеренү эшемне дә менә шушы күзлектән чыгып яздым. Бик күп сулар аккан, бик күп кышлар-җәйләр узган, чор белән чор алышынган, тик ничек кенә булмасын, без халкыбызның тарихын, үткәнен онытырга хаклы түгелбез.Без, яшьләр, сугыш афәтен, аның бөтен фаҗигасын язучыларыбыз, шагыйрьләребез язган әсәрләр аша, бабаларыбыз сөйләгәнне тыңлап кына күз алдына китерәбез. Әмма теләгебез бер: Бөек Ватан сугышы, Әфган, Чечня сугышлары кебек сугышлар кешелек дөньясындагы иң соңгы сугышлар булсын иде.

Дөньяда яшәүче барлык кешенең бер теләге бар – туган илдә тынычлык булсын! Аларга мәңгелек дан һәм мәңгелек хөрмәт! Ә безнең бурычыбыз – ул еллардагы халыкның батырлыгын үзебездә онытмыйча, бездән соң килгән буыннарга да тапшыру.

Күпме бәла – каза китергән, кеше гомерен өзгән, кайгылы хәбәрләр китергән бу афәтле, дәһшәтле, канкойгыч сугышны безгә мәңге онытырга ярамый, хакыбыз юк. Көннән –көн сугыш һәм тыл ветераннары арабызда кими бара. Без алар алдында бүгенге яхшы, тыныч, тату, бәхетле тормышта яшәвебез өчен бурычлы. Яшьтәшләремә "Хәтерләүдән курыкма син, үткәнеңне онытма син!" – дип дәшәсем килә.

**Кулланылган әдәбият.**


1. Гыйләҗев Фаекъ турында кызы Нурзалия Гарифҗанованың истәлекләре.

2.Интернет-сайтлар: http://www.hrono.ru/sobyt/1900sob/1945berlin.php, http://ru.wikipedia.org/wiki/

3. Йорт архивындагы документлар.

4. Мәктәп музеендагы стенд, альбомнар.

*Афанасьева Лиана, 7 класс, Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районының Муса Җәлил исемендәге “1 нче гимназия” муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесе*
*Җитәкчесе: Фалахиева Ильмира Ризатдин кызы биология, география укытучысы, Миннегалиева Гөлназ Сәләхетдин кызы татар теле һәм әдәбияты укытучысы*

## Көек-Ерыкса авылы микротопонимнары

### Кереш

1.1. Теманың актуальлеге, максаты, тикшерү методлары

Хәзер балаларда милли үзаң тәрбияләү, татар теленә, халкына, тарихына, туган ягына мәхәббәт уяту, рухи яктан бай ,физик яктан камил шәхес тәрбияләү аеруча игътибарга лаеклы проблемаларның берсе булып тора.

Үзенең үткәненә һәм тарихына хөрмәт һәм ышаныч белән караган халыкның гына киләчәге бар. Шуңа күрә без олы шәхесләребез, бөек халкыбыз, үткән олы тарихыбыз белән горурланырга, алар рухы белән яшәргә тиешбез.

**Теманың актуальлеге**: топонимик атамаларның аталу тарихын өйрәнеп, алынган нәтиҗәләрне авылның тарихын торгызуда файдалану.

**Эшнең максаты:** төрле чыганаклар аша Көек-Ерыкса һәм Яңа Комазан авылы микротопонимнарының аталу тарихларын тикшерү, материаллар җыю, өйрәнү, атамаларны төркемнәргә бүлү һәм нәтиҗә чыгару.

**Тикшерү объекты:** авылыбыздагы чишмәләр, күлләр, урман һәм болыннар.

**Бурычлар:** Көек-Ерыкса һәм Яңа Комазан авылы сулыклары, урман һәм болыннар топонимнарын өйрәнү.

**Тикшерү методлары:** эвристик ысул -- эзләнү, тикшеренү һәм нәтиҗә чыгару.

**Алымнар:** топонимика буенча булган фәнни әдәбият белән танышу, музейда, китапханәдә эшләргә өйрәнү; авылыбызның өлкән кешеләреннән атамалар тарихын сөйләтү, язмаларны редакцияләү; географик объектларны фотога төшерү.

Һәр авылның үз тарихы, үз атамалары бар. Халык авылның кое-чишмәсенә елга-күленә, чокыр-басуларына, урман-болыннарына бик матур исемнәр биргән.

Географик исемнәр белән без балачактан ук очрашабыз. Туган йортыбыз урнашкан авыл, урам исемнәре, авылыбызның тирә-ягындагы тау, чокыр, басу, болын, елга, күл, һәм башка географик объектларның атамалары кечкенәдән үк безне үзенә тартып тора.

1.2.Топонимнар тарихын өйрәнү кирәкме?

Географик атамаларның җыелмасын, аларның килеп чыгышын, ясалышын, кулланылыш һәм үсеш эволюциясен, мәгънәсен, таралышын **топонимика** фәне өйрәнә һәм тикшерә. **Микротопонимика** – топонимика фәненең аерым төбәк, шул тирәлек-урын кешеләре өчен генә билгеле булган географик атамалар (микротопонимнар) җыелмасын өйрәнә торган бер бүлеге.

Һәр авылның үз тарихы, үз атамалары бар. Халык авылның кое-чишмәсенә елга-күленә, чокыр-басуларына, урман-болыннарына бик матур исемнәр биргән.

Географик исемнәр белән без балачактан ук очрашабыз. Туган йортыбыз урнашкан авыл, урам исемнәре, авылыбызның тирә-ягындагы тау, чокыр, басу, болын, елга, күл, һәм башка географик объектларның атамалары кечкенәдән үк безне үзенә тартып тора.

Күренекле галимнәр, фән эшлеклеләре озак еллар дәвамында топонимиканы өйрәнү белән шөгыльләнәләр. Академик Гомәр Саттаровның “Туган җирем, туган авылым”, “Атамалар дөньясына сәяхәт”, профессор Фирдәүс Гарипованың “Авылларны сөям җаным-тәнем белән”, “Авыллар һәм калалар тарихыннан” дигән китапларында татар авылларының килеп чыгу тарихлары, ономастика турында бай һәм кызыклы мәгълүмат бирелгән.

Вак чишмәләрдән зур елгалар барлыкка килә, кечкенә авыллар тарихыннан олы тарихыбыз – туган илебез, Ватаныбыз тарихы туа. Кем булуыңны белү өчен туган ягыңны тарихи яктан гына өйрәнү җитми, ә географик яктан өйрәнү дә зур әһәмияткә ия. Шул максатны истә тотып, мин үз авылым тирәсендәге чишмә, күлләр һәм урман-каенлыкларның аталу тарихларын бик кызыксынып өйрәндем.

Безнең авыл табигате чишмәләргә бик бай: барлыгы 5 **чишмә** һәр иртәдә үзенең моңлы җырын суза. Әби-бабаларыбыз чишмәләргә элек-электән бик матур исемнәр биргәннәр: Солтан чишмәсе, Файзә чишмәсе, Баллы чишмә, Вакай чишмәсе, Комазан чишмәсе. Мин 5 чишмәнең аталу тарихын өйрәндем. Кайбер кешенең күңелендә мондый сорау туарга мөмкин: хәзерге вакытта, урамда су колонкалары тезелеп торганда, авылдагы кайбер өйләргә чишмә суы торбалар аша агып килгәндә, ул чишмәнең нинди исем белән аталуын белү безгә, яшьләргә, ни өчен кирәк соң? “Үткәнен белмәгәннең – киләчәге юк,”-- ди халык. Димәк, без авылның үткән тарихы белән кызыксынабыз икән, киләчәгебез дә мәгънәле булыр. Көек-Ерыкса һәм Комазан авыллары югалган авыллар

исемлегенә кермәсен дисәк, үзебез маңкорт булырга теләмәсәк, һичшиксез, авылның тарихын, топонимикасын белү кирәк.

**2.Төп өлеш**

2.1.Чишмәләрнең аталу тарихы безгәниләр сөйли?

**Солтан чишмәсе**

Авылның төньяк-көнбатышындагы таулыктан Солтан чишмәсе агып чыга. Авылның Ахметшин Солтан исемле кешесе таш чыгарган вакытта юлыккан бу чишмәгә. Яхшылап чистарткан, улак куйган. Чишмәне карап, чистартып торган. Суы бик көчле булганга, хатын-кызлар анда кер чайкаган.Аны “Изгеләр чишмәсе” дип тә атап йөртәләр.Борын-борыннан безнең әби-бабайларыбыз кыйблага таба ага торган барлык чишмәләрне “изге” дигәннәр. Бу чишмә Көек-Ерыкса аылында урнашкан. Моннан бик күп еллар элек ул чишмәгә кичен кояш баер алдыннан авыл кызлары су ташырга йөргәннәр. Матур киенгән, бизәкле көянтә- чиләк аскан кызлар арасыннан егетләр үзләренә тиң пар сайлап алып өйләнә торган булганнар. чишмә яны ул- гашыйклар очрашу урыны.



**Файзә чишмәсе**

Бу чишмә Көек-Ерыкса авылының төньяк-көнбатышындагы тау астыннан инешкә челтерәп ага. Гомер буе чишмәне Нургалиева Файзә апа карап-тәрбияләп торган: суга төшүчеләргә сукмак ясаган, улагын караган. Әби үзе исән түгел инде. Изге күңелле булганга, аның исеме халык телендә һаман яши.

**Вакай чишмәсе**

Әлеге чишмә Яңа Комазан авылында тау астыннан агып чыга. Аны Сафин Бакый исемле кеше казып чыгарып, карап торган. Башта уны Бакый абый хөрмәтенә “Бакый чишмәсе” дип атап йөрткәннәр. Ләкин ул соңыннан хәрефләре үзгәртелеп “Вакай”дип йөртелә башлый.

**Нәтиҗә: алда язылган 3 чишмәнең аталу тарихын тикшергәннән соң, мин аларның кеше исемнәренә нигезләнеп барлыкка килгәнен ачыкладым. Суларның**

**кадерен белгән, чишмә башын чистартып, карап торган изге күңелле, эшчән авылдашларын онытмый халкым. Димәк, исемеңне мәңгеләштерү өчен, үз халкыңа хезмәт итәргә кирәк.**

**Комазан чишмәсе**

Вакай чишмәсеннән ерак түгел агучы чишмә. Ул Яңа Комазан авылының иң зур чишмәсе. Исеме дә шуңа бәйле рәвештә кушылган.Һәр чишмәнең гасырлар буена җыйган үз сере, үз моңы, үз көе бар.



**Баллы чишмә**

Сап-салкын сулы чишмә авылның көньягындагы биек булмаган инеш таулыгыннан агып чыга. Бу таулыкны алмагачлар утыртып умарталык ясаганнар. Хәзерге көндә дә монда колхоз умартасы урнашкан. Чишмәгә дә аккан урынына бәйле рәвештә исем куйганнар. Суы тәмле, тирәсе чиста. Көндәлек тормышта эчү, ризык әзерләү һәм кер чайкау өчен файдаланыла.

Баллы чишмә-ерак чишмә
Шаһиты күп чорларның.
Бик борынгы аның моңы,
Чулпы чыңы җырлары.

*РәимГобәй*

**Нәтиҗә: чишмәләрнең атамасы аларның урнашкан урынына бәйле рәвештә бирелгән.**

2.2.Авылыбызның күлләре тарихы

Безнең авыл табигате үзенчәлекле, чөнки анда таулар да, урманнар да , болыннар да бар. Авылның көнчыгышындагы болыннарда бик күп күлләр бар.

**Кәрәкә күле**

Авылыбыз янында гына алтмыш гектар җирне биләгән Кәрәкә күле бар.*Күлнең исеме аның үзенчәлегенә бәйле рәвештә бирелгән. Бу күлдә элек-электән*

кәрәкә балыгы күп  була. Кыш көннәрендә алар боз астында һава җитмичә күпләп үлә торган да булганнар. Анда хәзер дә бала-чагалар балык тотарга төшәләр.

Бака күлләренең бакасы мин
Кәрәкәнең елгыр балыгы.
Мондый җирдә кем булсаң да ярый,
Бу салалар – оҗмах авылы.

Рафаил Газизов

**Урсай күле**

Кәрәкә күле янәшәсендә Олы Урсай һәм Кече Урсай күлләре урын алган. Әйе, күлләр күп безнең якта. Кайчандыр бу җирләрдән Нократ елгасы аккан. Йөзләгән күлләр - Нократның борынгы эзләре. Урсай сүзенең килеп чыгышы да кызыклы. Ул сүз “урыс  ай” дигән сүздән алынган диләр картлар. Русларның көчләп чукындыруларыннан качып, Урсай күлләре янындагы җирлектә айлар буе горур һәи иманлы бабаларыбыз качып яткан.

**Киндер күле**

Әлеге күлнең  икенче ягына чыгып киндер чәчә торган булганнар. Исеме дә шуңа бәйле рәвештә бирелгән.

**Саййөзек**

Бу кечкенә генә күл шулай ук болында урнашкан. Күлнең суы Арпач елгасына кушыла. Болынга төшкәндә шушы күл аркылы йөрилэр. Бу күл сай гына, ләкин баткак.

Яз җылынган  саен киерелә
Саййөзекнең  җәя кереше,
Дулкын суның
Рәхимулла байның атларыдай
Алга-артка чабып йөреше.

Рафаил Газизов

**Бака күле**

Әлеге күл Бакый исемле байның күле була. Мул сулы, балыклы матур күл иде, дип искә алдылар аның турында. Ләкин күл инде кипкән. Аның урынында сазлык кына калган. Бакалар бик күп бу урында. Халык Бакый исеменнән Бака исеменә күчкән. Монда хәзер бакалар хуҗа.

**Нәтиҗә: күлләрнең атамасы аларның урнашкан урыны, үзенчәлекләренә карап бирелгән . Аларны өйрәнеп без түбәндәге нәтиҗәләргә килдек: топонимик атамалар төбәкнең табигате, географик үзенчәлекләре турында мөһим мәгълүмат бирәләр.**

## 2.3.Елгалары һәм болыннары белән мактаулы безнең авыл

Бик борынгы заманнарда безнең басу-кырларда һәм урманнар тирәсендә елгалар , ә болыннарда төрле урыннар бар. Һәрбер елганың күңелгә ятыш үз атамасы бар. Ул атамалар буыннан- буынга күчә барган: Әбел елгасы, Шомыртлы елгасы, Бүре елгасы.

**Әбел елгасы**

Хәбибуллин Әбел-Хәсән исемле кеше кич белән Мамадышка барганда Шушы елгага төшеп үлә. Шушы вакыйгага бәйле рәвештә исем бирелгән.

**Шомыртлы елгасы**

Әлеге елга тирәсендә шомырт агачлары күп үсә. Шуңа бәйле рәвештә исем дә кушылган. Елгадан ерак түгел җиләкле аланнар күп.

**Бүре чокыры**

Шушы чокыр тирәсендә гел бүре оялый торган була. Берничә кешенең каршысына да очрый. “Миңа да Малмыжкага барганда ат каршына ике бүре чыкты”.- дип искә ала әлеге чокыр турында Шәйхетдинова Әминә апа. Исеме шуның белән бәйле.



**Яшь килен елгасы**

Бу елга Комазан авылыннан ерак түгел урнашкан. Элекке елларда язгы ташу сулары көчле килгәндә, елга су белән тула торган булган. Бер яшь килен ( исеме билгесез) Вахит базарына барган вакытта әлеге елгага төшә. Шушы очрактан соң исем бирелә.

**Кот чокыры**

Яңа Комазан авылының элеккеге урыны моннан ике чакрым ераклыктагы Кот чокыры дигән урында булган. 16 гасырда Явыз Иван яуларыннан качып, бире килеп чыккан бабаларыбыз, үлемнән котылып, бу урында үзләренең бәхетләрен тапканнар. Шуңа күрә яшәү урыннарын Кот чокыры( бәхет чокыры) дип исемләгәннәр.

Авылымның ерак тарихы син-

Кот чокыры- бәхет чокыры.

Онытмагыз үткәннәрне, диеп,

Әйтерсең лә, үзенә чакыра.

Рәим Гобәй

Безнең авылның болыннары бик зур. Шуңа күрә анда адашмас өчен кешеләр төрле урыннарга исемнәр кушканнар.

**Шамай болыны**

Шамил исемле кеше болынның бу өлешен таллардан чистарткан. Бу кешенең фамилиясе билгеле түгел.

**Гапсәләм әрчүе**

Болынның бер өлеше әлеге исем белән атап йөртелә. Муллагалиев Гапсәләм атлы кеше бу җирне таллыктан чистарткан.

**Вәрис куышы**

Болындагы печәнлек урыны шулай дип аталган. Галимов Вәрис исемле кеше болында сакчы булып торганда шушында үзенә куыш ясап яшәгән. Исеме шуннан калган.

**Мулла бае, Якты бай**

Болыннардагы әлеге урыннар авыл байларының җире булган. Исемнәре дә шуңа бәйле рәвештә куелган.

**Елга, чокыр һәм болыннарның аталу тарихын өйрәнеп, мин түбәндәге нәтиҗәгә килдем: топонимик атамалар безгә борынгы әби- бабаларыбызның тормыш-көнкүреше, һөнәрләре, гореф-гадәтләре, тарихы, теле, төбәкнең табигате, географик үзенчәлекләре, авыл халкының этник составы, кәсебе турында мөһим мәгълүмат бирәләр. Һәрбер җирле атама – үзенең килеп чыгышы, барлыкка килү мәгънәсе белән чал тарих хәбәрчесе икән.**

**3.Йомгаклау**

Тикшеренүләрдән күренгәнчә, микротопонимнарның барлыкка килүләре -- җәмгыятьнең һәр чорына хас күренеш. Аларның чыганаклары бик еракка, борынгы тарихка барып тоташа. Гасырлар үтү белән кайбер атамаларның баштагы исемнәре онытылган. Авыл халкы аларга яңа исемнәр кушкан, ә күбесе исә борынгы атамалары белән аталып йөри.

Мин өйрәнгән чишмә, күлләр, елга, болынлыкларның аталу тарихын төркемнәргә бүлү нәтиҗәсендә төрлечә аталган топонимнарның булуы ачыкланды.

**1. Иң күбе кеше исемнәренә нигезләнгән микротопонимнар**: Солтан чишмәсе, Файзә чишмәсе, Вакай чишмәсе, Әбел елгасы, Гапсәләм әрчүе, Вәрис куышы.

**2. Кушаматка нигезләнгән микротопонимнар**: Шамай болыны

**3. Катлам титулына нигезләнгән микротопоним**: Мулла бае, Якты бай.

**4. Үсемлекләр белән бәйле атама** : Киндер күле, Шомыртлы елгасы.

**5. Охшату – чагыштыру аша исемләнгәне:** Баллы чишмә, Сайөзек.

**6. Хайван исеме белән бәйле атамалар:** Бүре чокыры, Кәрәкә күле, Бака күле.

**7. Урнашкан урынына бәйле атамалар:** Комазан чишмәсе.

**8. Ниндидер вакыйгага бәйле атамалар:** Яшь килен елгасы, Урсай күле, Кот чокыры.

Тикшерү эшен йомгаклап, шундый нәтиҗәгә килдем: топонимик атамалар – халык иҗатының гасырлар буена җыелып килгән асыл җәүһәрләре, үзенчәлекле мирасы. Танылган язучы К. Паустовский бик дөрес бәя биргән: ”Урын-җир исемнәре -- халыкның үз илен шагыйранә бизәве ул. Аларда халыкның холкы, тарихы, һәвәскәрлеге һәм көнкүреш үзенчәлекләре чагылыш тапкан”.

Топонимик атамалар минем күңелемә балачагымның якты, кире кайтмас истәлеге булып кереп калдылар. Алга таба да үз авылымның, районымның топонимикасын өйрәнүне дәвам итәрмен дип уйлыйм, чөнки бу -- бик кызык, мавыктыргыч һәм шул ук вакытта файдалы шөгыль. Топонимик атамаларның аталу тарихын тикшерү – туган якның тарихын өйрәнү дигән сүз. Ә туган якны төрле яктан өйрәнеп, без үзебезнең тамырларыбызны беләбез.

Авылыбызга багышлап иҗат ителгән шигырьләрдә һәм җырларда да микротопонимнар киң чагылыш таба. Авылыбызның шагыйре, мәзәк остасы Рәим Гобәй авылыбызның табигатенә сокланып күп кенә шигырьләр иҗат иткән:

Бу якның чишмәсен, күлләрен
Кем күргән, сокланган иң элек?
Кем генә булса да авылымның
Урынын сайлаган бик белеп.

Урнашкан ул таулар кочагында,
Тирә-ягы болын, урманнар.
Мондый гүзәл авыл, йә өйтегез,
Җир йөзендә тагын кайда бар?!

Йомгаклап, шуны әйтәсе килә, без, яшь буын, туган ягыбызның киләчәге өчен җаваплы кешеләр. Туган төбәгебезнең тарихын җентекләп өйрәнеп, эш-гамәлләребезне

аның табигатенә зыян китермәслек итеп оештырырга тиешбез. Шулай булганда гына без сәламәт һәм бәхетле кешеләр булырбыз, бездән соң килгән буынга бай табигый мирас калдырырбыз.

**Файдаланылган әдәбият**


1. Гарипова Ф. Авылларны сөям җаным-тәнем белән. – Казан:Тат. кит. нәшр., 1994
2. Зарипов Р.С. Үткәннәр эзеннән.// Мәгариф.-- 1998.- №7.
3. Саттаров Г.Ф. Атамалар дөньясына сәяхәт. – Казан: Тат. кит. нәшр., 1992.
4. Саттаров Г.Ф. Туган җирем, туган авылым.// Мәгариф. –1996.--№11.
5. Гобәй Р. Борчулы җаным минем. (шигырьләр җыентыгы)- Чаллы, 2005





*Ахметзянова Ясмина, 5 сыйныф, Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районының Муса Җәлил исемендәге "1 нче гимназия" муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесе*

*Җитәкчесе: Фалахиева Ильмира Ризатдин кызы биология, география укытучысы*


## Туган ил

Сездә ничек, бездә шулай
Йөргәнем юк эзләнеп.

Чишмәләре янәшәмдә
Сулар эчәм тезләнеп.
Нигә мина эссе яклар,
Кирәк түгел чүлләре.
Исән булсын яшел болын,
Туган якнын күлләре.
Менәм дисәм, дәшеп тора
Тауга тартып үрләре
Юк болында чәчәкләрнең
Нинди генә төрләре.
Сездә ничек, бездә шулай
Мин-шушы җир баласы
Үсү белән туган җирне
Булыр җырга саласы.

*Буланова Диана, 9 нчы сыйныф, Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районының "19 нчы урта гомуми белем бирү мәктәбе" муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесе*
*Җитәкчесе: Ибраһимова Алсу Рәмзил кызы, татар теле һәм әдәбияты укытучысы*

## Үткәннәрдән калган ядкарь буйлап...

### Кереш

Бөек Ватан сугышы еллары еракта калса да, йөрәктәге яралар әле хаман төзәлми, кешеләрнең үлемсез хәтере аша безне михнәтле, шул ук вакытта бөтен халык батырлыгының онытылмас көннәренә алып кайта. Сугыш авырлыкларын үз иңнәрендә күтәргән батырларын, Ватанын, Туган илен саклаган геройларын хәзерге буын кешеләре онытырга тиеш түгел.

Кешелек дөньясына кайгы хәсрәт китергән Бөек Ватан сугышы тәмамлануга 78 елдан артык вакыт узса да, аның ачы кайтавазы әле бүген дә үзен сиздереп тора. Гомерендә бер мәртәбә дә авыз тутырып “эти” дип әйтә алмаган балалар, хәзер инде үзләре әби-бабай

яшендә, канлы ут эчендә йөргән чал ветераннарыбызның да саны инде санаулы гына булып тора. Бөек Җиңү көнендә аларның моңсу йөзләрендә һәрчак яшь тамчылары ялтырый.

Сугыш... Мин, сугышның ни икәнен белмәүче кыз, бу сүзне әйтү белән үк, бөтен тәнем чымырдап куя. Бу сүз – минем өчен иң куркыныч сүз... Сугыш... Безнең илнең тарихында күп сугышлар булган. Ләкин,иң куркыныч,иң дәһшәтле, иң рәхимсез сугыш – Бөек Ватан сугышы булгандыр...

Сугыш михнәтләре Яңа Ибрай авылын да читләтеп узмаган, әлбәттә. Аның беренче көненнән үк авыл халкы, баһадирдай ир - егетләрен, фронтка озата башлый.

Әйе,1941 елның июненнән башлап, бабаларын, әтиләрен, абыйларын, улларын, энеләрен, оныкларын зар елап сугыш кырына озата Яңа Ибрай халкы. Бары тик бер генә теләк: авылга исән - имин кайтыгыз! Тик киткәннәрнең барысы да туган авылына исән - имин әйләнеп кайта алмый шул...

Минем эзләнү - тикшерү эшемнең **максаты:** Бөек Ватан сугышы турында, бабамның әтисе - карт бабамның тормышын өйрәнү.

Шушы максаттан чыгып,мин үземә мондый **бурычлар** куйдым:

1. Бөек Ватан сугышы турында күбрәк өйрәнү.
2. Бабамнан әтисе Нуриәхмәт Ибраһим улы (карт бабам) турында сөйләтү.
3. Гаилә архивындагы документлардан карт бабам турында мәгълүмат туплау.

**Гипотеза:** Минем карт бабам сугыш вакытында ничек яшәгән?

Тикшерү **объекты:** минем бабамның әтисе Кубиев Нуриәхмәт Ибраһим улы.

Тикшерү- эзләү эше барышында мин әлеге **методларны** кулландым:

1. Бабамның әтисе Нуриәхмәт турында якын туганнарны сораштыру.
2. Гаилә архивын һәм авыл мәктәп музеендагы материалларны өйрәнү.
3. Җыелган мәгълүматны туплау.

Минем бу эзләнү эшенең практик үзенчәлеге бик зур. Бу материалны тарих, әдәбият, әйләнә –тирә дөнья дәресләрендә кулланырга була. Шулай ук бу эш буенча, башка укучылар үзләренең гаилә тарихын өйрәнә алалар.

Эшнең **структурасы.** Максат һәм бурычлардан чыгып, эзләнү эше кереш, төп, йомгаклау өлешләреннән тора.

**Төп өлеш**

**Мәскәүне саклау**

Утлар, сулар кичкән геройларның берсе минем бабамның әтисе – Кубиев Нуриәхмәт Ибраһим улы. Ул 1914 елның 25 нче июнендә Аксубай районы Яңа Ибрай авылында туган. Бала-чагы, яшь үсмер вакыты шушы авылда узган. Мәктәпне тәмамлаганнан соң, шул ук Яңа Ибрай авылының җиде еллык мәктәбендә башлангыч сыйныф укытучысы булып

эшләгән. Бөтен җанын, тәнен биреп тырыш хезмәт куеп эшләгән дәвердә 1941 нче елның 22 нче июнь көнне авылга дәхшәтле хәбәр килә. Фашистлар Германиясе Ватаныбызга хыянәтчел төстә хөҗүм ясый. Барлык авылдашлары белән Туган илен, Туган җирен сакларга, Ватан өчен көрәшкә чакырыла. Ул вакытта әле аңа бары 28 яшь кенә була. Яшлегенең шаулап чәчәк аткан вакыты, киләчәккә зур өметләр белән янып йөргән, гомеренең иң матур мизгелләрендә аңа кулына корал тотып сугышка китәргә туры килә. Сугышта ниләр күргәнен, ниләр кичергәнен мин аның үз кулы белән язып калдырган дәфтәреннән укып белдем.

Карт бабамның үзе язып калдырган истәлекләре буенча, аның батырлыгын мактап бирелгән медальләре, мактау грамоталары, рәхмәт хатларына таянып, аның батырлыгы турында язарга булдым.

1941 нче ел. Казан хәрби комиссириаты ерак бабам Нуриәхмәтне Саратовка эвокуацияләнгән 2 нче Киев артиллерия училищесына укырга юллама бирә. Уку көненә 12 сәгать дәвам итә. Яшь сугышчыларга артиллерия фәнен өйрәнүгә алты ай вакыт бирәләр. Соңыннан курсантлар сугыш тактикасының төрле формалары, артиллерия һәм политика буенча имтихан тапшыралар. Имтиханны бик яхшы тапшырган карт бабама кече лейтинант званиясе бирелә. Бу 1941 нче елның ноябрь аенда була. Шуннан аларны группа командирлары итеп Воронеж өлкәсенең Борисоглебск шәһәренә запастагы артполкка җибәрәләр. Яшь командирлар берничә ай солдатларны хәрби хезмәткә өйрәткәч, аларны Мәскәү оборона запасына озаталар.

1942 нче елның чатлама суык февраль ае. Карт бабамнар Мәскәүгә килгән вакытта немец гаскәрләре Мәскәү стенасыннан 400 – 450 километрга алып ташланган була. Шулай да башкалабызны дошманның яңа һөҗүменнән сакларга кирәк әле. Бабамның әтисе Нуриәхмәт монда авыр артиллерия взвод командиры була.

1942 нче елның март, апрель айларында ул үзенең девизиясе белән атаклы Бородино кырларына урнаша. Бу Мәскәүдән 140 километр, Можайск шәһәреннән 20 километр көнбатышта.

Мәскәүдән алып Можайскийга кадәр булган барлык авыллар да яндырылып беткән, андагы кешеләр күбесе немецлар тарафыннан үтерелеп, күбесе Германиягә куылган. Тимер юллар җимерек. Немецлар үзләренең солдатларының үле гәүдәләрен дә күмеп бетерә алмаганнар. Безнең армиянең һөҗүме шул кадәр көчле була ки, “җиңелми торган немец армиясе” Мәскәү яныннан көчкә үзенең табанын алып өлгерә.

1942 - 43 нче елгы сезонда карт бабам Нуриәхмәтләр часте Мәскәүне саклауда актив оборонада һәм аерым участокларда (Псков юнәлешендә) һәҗүм итүне дәвам иттерәләр.

**Ленинград блокадасын өзү**

1943 нче елның июнь аенда бабамның әтисе Нуриәхмәт хезмәт иткән частьне Ленинградка күчерәләр. Алар Мәскәү аркылы Волоховка, Волоховтан Ленинградка керергә тиеш булалар. Немецлар Волоховны бомбага тоталар, чөнки ул тимер юл станциясе. Моннан Ленинградка азык – төлек, сугыш кирәк – яраклары озатыла. Эшелон Волоховтан чыгып урман буена туктала. Караңгы төшмичә кузгалырга ярамый. Немец самолеты составның тукталган урынын күреп тә ала. Озак та үтми, биш дошман самолеты эшелонны бомбага тота башлый. Сазламыклы урын булу сәбәпле, поездга төбәп ташланган ике бомба шартламый кала, калган берничә бомба эшелонның ике ягында да шартлый, берничә солдат яралана. Бер иптәшләрен Волохов урманы буенда күмеп калдыралар.

Караңгы төшә башлый, эшелон кузгалып китә. “Тар коридор” га керәләр, немцлар эшелонга артиллериядән ата башлыйлар. Снарядлар бер-бер артлы эшелон тирәсендә шартлыйлар. Поезд һаман алга ыргыла. Акырынлап шартлау тавышлары да басыла. Эшелон дошманның бомбага тотуы һәм артиллерия уты астында, югалтулар белән булса да, 23 нче июньдә таң алдыннан Ленинград шәһәренә барып керү бәхетенә ирешә.

Шәһәрнең иң зур оборона пункты булып саналган Киров заводы территориясенә урнашалар. Ә Киров заводы үзе, сугышка авыр танклар – “КВ”лар җитештергән.

Шул көннән башлап Ленинград оборонасы башлана. Фашистлар тәүлекнең теләсә кайсы вакытында шәһәрне бомбага тоталар. Дошманның бомбага тоту һәм артиллерия уты шәһәрнең төп объектларына: завод-фабрикаларга, институтларга, вокзаллар, госпитальләргә , мәктәпләр, сәүдә үзәкләренә, хәрәкәт күп булган урамнарга төбәлгән. Шәһәрдә көн саен күпме кеше шул хәрәбәләр астында кала, күпме гомер өзелә. Карт бабамнар артиллеристлар буларак, шәһәргә авыр артиллериядән атучы немец артиллерия нокталарын утка тотарга тиешләр. Дошманның Ленинградка бер снаряды төшеп шартлау белән, аңа каршы ут ачарга кирәк. Артиллеристлар моның белән дошман атуларын туктаталар һәм йөзләрчә ленинградлының тормышын саклап калалар.

Блокада 1943 нче елның декаберенә кадәр дәвам итә. Ниһаять, 17 нче декабрьдә Ленин шәһәрен азат итү өчен һәҗүм башлана. Генерал фельдмаршал Фон Леебның “Җиңелмәс” армиясе тар-мар ителеп, дошман шәһәрдән 220 километрга алып ташлана. Ленинград блокададан тулысынча азат ителә.

Мәскәү Ленинградны саклаучылар хөрмәтенә салют бирә. Шул вакытта карт бабам Нуриәхмәт “Ленинград оборонасы өчен” медале белән бүләкләнә.

Дошманга каршы һөҗүм дәвам итә.

**Польшаны азат итү**

Карт бабам Нуриәхмәткә тагын да зур бурыч йөкләнә, аларны Польша җирләрен азат итәргә җибәрәләр. 1944 нче елның декабрь башында алар Полша җиренә аяк басалар.

Висланы кичү һәм Варшаваны алу кыска срокта хәл ителергә тиеш. Бер атна эчендә батареялар билгеләнгән урында һәм кирәкле санда сугыш кирәк-яраклары белән тәэмин ителергә тиеш. Бабамның этисе Нуриәхмәт полкның сугыш кирәк-яракларын кайгырту начальнигы буларак, кыска срокта полк батареяләрен снарядлар белән тәэмин итү, атна буена 28 автомашина белән ерак аралардан кирәк-ярак ташу йөкләнә.

Көнен төнен, ялсыз йокысыз килеш, ничек кенә авыр булса да билгеләнгән срокка полк боеприпас белән тәэмин ителә. Ниһаять, көтелгән сәгать килеп җитә. Польша башкаласын штурмалау башлана. Азатлык алып килүче Совет гаскәрләре белән поляк сугышчылары дошманның Висла оборонасын җимерәләр һәм Варшава азат ителә.

Польшаны азат итүдә күрсәткән батырлыклары өчен, карт бабам Нуриәхмәт, “Варшаваны азат иткән өчен” медале белән бүләкләнә.

**Берлинны алу**

Польша җирләре фашистлардан чистартылгач, фашизмны үз оясында юк итү бурычы килеп баса. Карт бабам полкташлары белән һөҗүмне дәвам иттереп, Германия җиренә аяк басалар. Сугыш хәрәкәтләре белән ул Одер ярлары буена барып җитә. Дошман һәр адым саен үзенең ерткычлыгын арттыра бара.

Бервакыт алар Одер буенда урнашкан батареяләрне снаряд белән тупландыру өчен автомашиналар белән шосседан баралар. Көтмәгәндә һавада немец самолеты күренә. Ул үзенең бомбасын колоннаның алдагы автомашинасына ташларга теләсә дә, бомба арттагы машинаның кабинасына төшеп шартлый. Снарядлар салынган ящикларга ут каба. Самолет тиз арада югала, чөнки безнең зенитчиклар үзен дә цельга алган булалар. Берничә шофер тиз генә утны сүндерәләр, зур фаҗига булмый кала. Боеприпас вакытында урынына җиткерелә. Машина шоферы, рус егете Фадеев, сугышчан заданияне үтәгәндә фаҗигале төстә һәлак була.

1945 нче елның 20 нче апреле. Кич. Кюстрин. Берлинга 70 км. 1 нче Белоруссия фронты командующие Г.К. Жуковның иртәнге сәгать икедә фашист өненә һөҗүм башланачагы. Дошманның әлегә кадәр сугышлар тарихында күренмәгән гадәттән тыш заман техникасы белән ныгытылган корылмаларның оборонасын пыр туздырып, беренче удар белән дошманның хушын алырлык һәҗүм оештырырга кирәк иде. Ул шулай булды да.

Май бәйрәмен Берлинда каршыларга карар бирүе турында берләшмә командирлары белдерү ясыйлар. Ул кичне берәү дә йоклый алмый. Сугышчылар барысы да иртәнге сәгать икене ниндидер бер ашкыну белән көтәләр.

Җир тетрәп киткәндәй була. Ике сәгать буена төрле орудие, минометлар, легендар “катюша” лар һавада меңнәрчә ут ачкач, дошман өстенә уннарча мең тонна металл, ут яугач, “Җиңелмәс” гитлер гаскәрләре кыямәт көнен үз күзләре белән күрделәр. Артиллерия

утыннан соң танк, җәяүле пехота һөҗүме башлана. Иртәнге сәгать алтыда инде дошман оборонасы җимерелә. Беренче көнне безнең гаскәрләр 12 км. алга китәләр. Артиллеристлар да танк һәм пехота артыннан калышмыйлар. Дошман үзенең соңгы сәгатьләре якынлашуын белә, каршылыгын ничек кенә арттырырга тырышса да, мөмкинчелеге кими бара.

Одер елгасы инде артта кала. Карт бабамнар һаман алга, фашист өненә ыргылалар. Совет сугышчыларын фашизмнан соңгы үчне алу хисләре белән сугарылган һөҗүмен туктатырга бер нинди дә көч юк кебек.

1942 нче ел, 2 нче май. Нуриәхмәтләр дошманның төп оясы – Берлинда. Берлинны алганнан соң, аларның артполкы Брондинборг капкасы янында тукталып торалар. Шул капка янында фашистларның кара козгын оясы – рейхстаг. Шул стена кирпечләренә карт бабам Нуриәхмәт тә иптәшләре белән бергә үзенең исемен язып калдыра.

9 нчы Май – Бөек Җиңү бәйрәмен ул Берлинда каршылый.

Берлин алуда күрсәткән батырлыклары өчен карт бабам “Берлинны алган өчен” медале һәм Кызыл йолдыз ордены белән бүләкләнә. 1945 нче елның 16 нчы гыйнварендә аңа 221 нче номерлы приказ белән Верховный Главнокомандующий рәхмәте белдерелә.

Бабамның әтисе Нуриәхмәт сугышның башыннан алып азагына чаклы йөреп, 1946 нчы елның апрелендә туган авылына кайта. Сугышка хәтле алган белемен, укытучы һөнәрен бик сагынып кайта. Кайтуының беренче көнендә үк яраткан эшенә керешә. 15 ел буена башлангыч классларда белем бирә. 10 ел буена сәүдә органнарында эшләп, пенсиягә чыга. Ерак әбием Гөлсем белән бергә 53 ел гомер кичереп 6 бала: 1 кыз, 5 малай тәрбияләп үстерәләр. Аларның һәрберсе югары белемле, илебезгә фидакарь хезмәтләрен башкарды. Ике улы шофер һөнәрен сайласалар, икесе әтиләре юлыннан укытучы һөнәрен дәвам иттеләр, бер уллары полиция һөнәрен сайлап, полковник дәрәҗәсенә җитеп эшләде. Элеге көндә алар хаклы ялда.

Кызганычка каршы, карт бабам 2000 нче елның 30 нчы октябрендә якты дөньядан киткән.

**Йомгаклау**

Бабам әтисе турындагы истәлекләрне сөйләгәндә, мин сугышның нинди рәхимсез икәнлеген аңладым. Мондый сугышлар кабатланмасын өчен без кулыбыздан килгәннең барын да эшләргә тиешбез. Сугыш белән бернинди мәсьәләләрне дә хәл итеп булмаячагын, ә бәлки меңнәрчә гомерләрне, хәтта кешелекне югалтырга мөмкин икәнлекне һәркем аңларга тиеш.

Сугыш ветераннары елдан – ел кимеп бару сәбәпле, безнең буынга Бөек Ватан сугышы турында мәгълүмат туплау авырлаша бара. Шуңа күрә, ветераннарның, аларның балалары, оныклары сөйләгән һәрбер сүзне без кәгазьгә теркәп барырга тиешбез.

Бөек Ватан сугышында һәлак булган авылдашларыбызның якты истәлегенә 1975 елның 9 маенда авылыбыз уртасында һәйкәл ачыла. Ел саен Җиңү бәйрәмендә мәктәп укучылары бирегә тантаналы линейкага җыелалар. Сугыш ветераннарын чакыралар. Һәлак булган авылдашларыбызны бер минутлык тынлык белән искә алалар

Сез барыгыз да ил өчен, кешеләрнең азатлыгы өчен көрәшкәнсез! Сез туган ил халкының, туганнарыгызның, исеменә тап төшермәдегез, яуда батырларча һәлак булдыгыз! Шушы изге эштә минем карт бабамның да өлеше керүе белән мин бик горурланам!

**Файдаланылган әдәбият:**


1.Ф.Имамов. “Исәннәр әйләнеп кайталар”. Нижнекамская городская типография. 2000

2. «Авыл таңнары» газетасы, 1984 ел, 28 нче гыйнвар.

3. Яңа Ибрай урта гомуми белем мәктәбе музеендагы мәгълүматлар.

4. Карт бабам язып калдырган истәлекләре.

5. Бабам – Кубиев Әүхәт белән әңгәмә.



*Валиева Камилла, 9 нчы сыйныф,*
*Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районының "аерым фәннәрне тирәнтен өйрәнүче 27 нче урта гомуми белем бирү мәктәбе" муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесе*
*Җитәкчесе: Сибгатуллина Гульчачак Гайнетдиновна, татар теле һәм әдәбияты укытучысы*


## Батыр солдат һәм шагыйрь Хәйретдин Мөҗәйнең Бөек Ватан сугышы чоры иҗатында солдат образы

### Кереш

Илебез тарихында иң караңгы сәхифәләрнең берсе ул - 1418 көнгә сузылган Бөек Ватан сугышы. Бик күп корбаннар, кайгы-хәсрәт китерде ул зур көрәш.Сугыш башлану бөтен кешенең тормышын кинәт кискен үзгәртеп ташлады. Бар халык, бердәм булып, Ватан азатлыгы өчен изге көрәшкә күтәрелде. Сугышның беренче көннәреннән үк татар язучылары да өсләренә солдат шинеле киделәр, кулларына корал алып, алгы сызыкларда сугыштылар һәм карлы-бозлы, ут-ялкынлы сугыш юлларын намус белән үттеләр.

Кайберләре язучы, шагыйрь, журналист буларак фронт газеталарында хезмәт иттеләр, сүзләре белән изге көрәшкә рухландырдылар, җиңүгә ярдәм иттеләр.

Күп шагыйрьләребез фронтта һәм дошман тоткынлыгында батырларча һәлак булдылар. Бу сугышта Татарстан 31 язучысын һәм 22 журналистын югалтты.

Менә аларның кайберләре: иҗат биографияләре яңа гына башланып килгән Хәбра Рахман, Мансур Гаяз, Рәхим Саттар, Әхмәт Әминов, Мифтах Вәдүт, Сөләйман Мөлеков һәм башкалар. Фатих Кәрим, Гадел Кутуй, Нур Баян һәм башка күпләгән талантлы язучыларыбыз, Туган илебезне яклап, яу кырында башларын салды. Фашист тоткынлыгында да яшерен көрәш алып барган Муса Җәлил, Абдулла Алиш, Хәйретдин Мөҗәйләр фашистлар тарафыннан ерткычларча җәзалап үтерелделәр. Һәр исем артында күпме моң, сагыш, тормышка ашмый калган хыяллар, язылып та илебезгә кайтып җитмәгән һәм язарга уйлаган бик күп җырлар ...Бу каһарманнар алдында без бүгенге матур, бәхетле тормышыбыз белән мәңгегә бурычлы. Без, яшь буын, ул батырларны белергә, аларның тормыш һәм сугышчан юлларын, иҗатларын өйрәнергә, киләчәк буыннарга тапшырырга , шундый каһарманнар үрнәгендә тәрбияләнеп, батыр булып үсәргә тиеш. Безнең аларны онытырга хакыбыз юк. Шуңа күрә бу эзләнү эшемдә күтәрелгән темам **актуаль** дип саныйм.

**Эзләнү-тикшеренү эшемнең темасы:** Батыр солдат һәм шагыйрь Хәйретдин Мөҗәйнең Бөек Ватан сугышы чоры иҗатында солдат образы.

**Эшемнең максаты:** Хәйретдин Мөҗәйнең тормыш һәм сугышчан юлын, Бөек Ватан сугышы чоры иҗатын өйрәнү, әсәрләрендә солдат образының бирелешен ачу.

Куелган максатка ирешү өчен түбәндәге бурычлар билгеләнде:

- Хәйретдин Мөҗәйнең тормыш һәм иҗат юлы турында фәнни хезмәтләрне барлау, туплау, укып- өйрәнеп системага салу;
- Бөек Ватан сугышы чорында иҗат иткән әсәрләрен уку, анализлау, солдат образының бирелешен ачыклау, нәтиҗә ясау.

**Өйрәнү-тикшерү объекты:** каһарман шагыйрьнең тормыш юлы, фронттагы һәм фашистлар әсирлегендәге эшчәнлеге.

**Предметы:** Хәйретдин Мөҗәйнең Бөек Ватан сугышы чорында язган әдәби әсәрләре.

**Кулланылган методлар:** эзләнү-тикшеренү, күзәтү, анализлау, нәтиҗә чыгару.

**Гипотеза**: Х.Мөҗәй үзе дә, аның иҗатындагы солдат образы да Ватанга бирелгәнлек, антка тугрылык, чын батырлык үрнәге, дип уйлыйк.

**Яңалыгы:** Хәйретдин Мөҗәйне халыкка таныту, исемен мәңгеләштерү өчен үзе дә фронтовик язучы Самат Шакир күп эш башкара. Дәфтәр- көндәлекне “Сугыш язмалары”

китабына туплап, үзе кереш сүз язып, берничә мәртәбә йөзәрләгән мең тиражлар белән дөньяга чыгара. 1978нче елда бу язмалар рус теленә тәрҗемә ителәләр. Дахау концлагере тоткыны Вәли Бикташевның “Мы старше своей смерти” дигән документаль повесте дөнья күрә. Самат Шакирның Х. Мөҗәйнең тиңдәшсез батырлыгын сурәтләгән, иҗатын яктырткан күп кенә язмалары, Г. Әпсәләмов, И.Гази, И.Юзеев, Марсель Гарипов мәкаләләре газета-журнал битләрендә төрле елларда басылып чыга. Ләкин мин алган тема буенча язылган хезмәтләр юк дәрәҗәсендә.

Бу эшкә алынуымның сәбәбе шул: Х.Мөҗәйнең дәресләрдә берничә әсәре генә өйрәнелә. Минем без яшь буынга аз таныш булган бу каһарман шагыйрьнең тормыш юлы һәм сугышчан эшчәнлеге, сугыш чоры иҗаты турында күбрәк беләсем, аның исемен халыкка танытуда кечкенә генә булса да өлешемне кертәсем килде.

**Эзләнү-тикшеренү эшенең практик әһәмияте:** эшем укытучыларга әдәбият дәресләре, сыйныф сәгатьләре үткәрү өчен, гомумән, әдәбият сөючеләр өчен файдалы кулланма булыр дип уйлыйм.

**Эшнең структурасы:** эш кереш,төп өлеш, 3 бүлектән, йомгаклау, кулланылган әдәбият һәм интернет-чыганаклар исемлегеннән тора.

**Төп өлеш.** Батыр солдат һәм шагыйрь Хәйретдин Мөҗәйнең Бөек Ватан сугышы чоры иҗатында солдат образы.

**Беренче бүлек.** Татар Самсоны Хәйретдин Мөҗәй.

Хәйретдин Мөҗәй 1901нче елның 26нчы мартында хәзерге Башкортстан Республикасының Туймазы районы Төрекмән авылында крестьян гаиләсендә туа.

Унсигез яшендә аны Кызыл Армиягә алалар, һәм шул вакыттан соң аның бөтен гомере хәрби хезмәткә бәйле рәвештә уза. Ул озак еллар чик буе гаскәрләрендә хезмәт итә, Урта Азиядә кулак һәм басмачыларга каршы көрәшә, 1938нче елда Хасан күле нында япон самурайларына каршы барган сугыш хәрәкәтләрендә катнаша. Бер үк вакытта Х.Мөҗәй актив рәвештә әдәби иҗат эше белән дә шөгыльләнә, шигырьләр, хикәяләр, очерклар язып бастыра.1932нче елны “Мылтыклылар” исемле җыентыгы дөнья күрә.

Ил, халык язмышы хәл ителгәндә тыныч кына кала алмый патриот Мөҗәй. Бөек Ватан сугышының беренче көннәреннән үк алгы сызыкка баса.Ул җитәкләгән полк башта Смоленск юнәлешендә, аннары Киев янында оборона тота. Тугры сугышчылары белән фашистларның корал складларын шартлата, тимер юлларын яндыра, корал төялгән поезд эшелоннарын түбәнгә тәгәрәтә.

1942нче елның июль урталарында Харьков янындагы сугышларда Х. Мөҗәй командалык иткән 789нчы полк дошман чолганышында кала. Сугышчылар дошман боҗрасында айдан артык искиткеч батырлыклар күрсәтеп көрәшәләр. Полк дошман

атакасын берничә мәртәбә кире кага. Окопларда, блиндажларда, землянкаларда кул сугышы башлана. Х.Мөҗәй янында гына дошман снаряды төшеп ярыла.Ул кинәт хәлсезләнеп аяктан егыла.Полктан исән калган авыр яралылар, шул исәптән полковник Х.Мөҗәй дә фашистлар кулына әсирлеккә төшә. Аны башка әсирләр белән бергә Германиягә озаталар. Лагерьдан- лагерьга күчерелә торгач, ул Мюнхенга килеп эләгә. Әсирлектә дә көрәшен туктатмый, командир булып кала. Мюнхенда, фашистлар оясында, БСВ(Братский союз военнопленных) дип аталган антифашистик яшерен оешма төзелә. Аның җитәкчеләре – 92 совет офицеры – немец антифашистлары белән бәйләнешкә керәләр. Җитәкчеләрнең берсе –борынгы яһүд мифы батыры “ Самсон” кушаматы белән йөргән Х.Мөҗәй. Төрле милләттән җыелган интернациональ оешма фашистларга каршы листовкалар тарата, коралллы восстание әзерли. Ләкин гестапога урнашып алган бер хыянәтче оешмага үтеп керә. Шул сатлык җан ярдәмендә яшерен оешманың эзенә төшәләр, җитәкчеләрен кулга алып, Дахау үлем лагерена ташлыйлар. Ике ай ярым сорау алып, ерткычларча җәзалыйлар. Дахау концлагере тоткыны, “Мы старше своей смерти”китабы авторы Вәли Бикташев Х.Мөҗәй белән соңгы очрашуын болай дип тасвирлый:”...мин аны чак эзләп таптым һәм чак-чак таныдым.Ул инде постельдән торырлык хәлдә түгел иде: аның авызында бер теше дә калмаган, колаклары кисеп алынган, балтыр мускуллары телгәләнгән, күкрәгенә свастика көйдереп басылган иде. Ул чактагы Мөҗәйнең хәле хәтта язып кына бетерерлек түгел... Мин аның сүзләреннән һәм күз карашыннан шуны аңладым: “Мин соңгы сулышыма кадәрТуган илемә тугры булып калам. Дошманга бернинди хәрби яки яшерен оешма серен чишмәдем.Исән кайта алсаң, безнең хакта шулай дип әйт туган илгә”.

Плетцензее төрмәсендә җәлилчеләрнең башларын кискәннән соң ун көн узгач, 1944нче елның 4нче сентябрендә фашистларДахау үлем лагеренда 92 совет офицерын – яшерен оешма җитәкчеләрен аталар һәм, тере килеш диярлек, дөрләп янган крематорий миченә ташлыйлар. Алар арасында шагыйрь-патриот Мөҗәһит Хәйретдинов та була. Каһарман шагыйрь, хәрби командир гомеренең соңгы минутына кадәр Туган иленә тугры булып калды, халкының ирекле тормышын яклаучы мифологик каһарманга әверелде. Шулай итеп үлеме белән үлемсезлек яулап алды.

**Икенче бүлек.** Х.Мөҗәйнең Бөек Ватан сугышы чорында язылган шигырьләр һәм хикәяләрендә солдат образы.

**“Ант” шигыре.** Хәйретдин Мөҗәй 1942нче елның 21нче апрелендә”Совет әдәбияты” журналына “Ант” шигырен җибәрә. Тирән хис белән язылган бу шигырьдә лирик герой “ мин” газиз Ватанны сакларга үзенең кайнар каны, бөтен йөрәге- җаны белән ант итә:

Йөрәктә ант янды ут кебек,

Ачу ташты, ташкын су кебек.

Үч алырга диеп дошманнан

Мин каршына чыктым юл бүлеп.

Безнең алдыбызда – явыз дошманга каршы “сөйгән анасы кебек иле, җирдә үскән һәрбер гөл, басып йөргән изге җир өчен кайнар тиргә батып” көрәшүче патриот солдат.

Мин йөрәктә антны сакладым,

Антым белән илне якладым!

Илем өчен булган көрәштән дә

Бөегрәк нәрсә тапмадым!- ди ул. Ватанын өзелеп сөюче бу солдатның биргән антына тугры калачагына һичбер шик юк.

**“Автоматчы”.** Шигырь “Сугыш язмалары”ның дүртенче дәфтәренә карандаш белән язылган. Исеменнән күренгәнчә, лирик герой – батыр, кыю, зирәк автоматчы, кирәк һәм тиешле вакытта дошман явы өстенә ыргылырга әзер торучы совет солдаты.

Хәнҗәр белән дошман йөрәген

Телгәләп, тартып ала.

әҗәлен тапкан кабахәткә –

кара көчкә ут сала, - дигән юллар сугышның дәһшәтле сулышын тоярга ярдәм итә.

**“Каның, җаның белән түләрсең”**шигырендә шагыйрь немец фашистларының чын йөзен фаш итә. Аларның аршын ярым сатин, мендәр тышы, йон юбкалар өчен комсызланып талап, каракланып, бар нәрсәне ватып-җимереп, яндырып бетерүләрен, урамнарда уйнап йөрүче бер гөнаһсыз үсмер балаларны атып үтерүләрен, карчыкларны аз гына да кызганмыйча, гәүдәләрен кисәкләргә турап утка ягуларын ачы нәфрәтләнү белән яза. Шагыйрь йөрәгендә ярсулы үч кайный. Ул фашистларның барлык кылган ерткычлыклары, вәхшилекләре өчен җавап бирер көннәре тиздән киләчәгенә тирән ышана:

...Түләү көне җитә,

Түләрсең син –

Каның, җаның белән, немчура!

Тетрәп, туфрак булган шәһәр үчен,

Янган авыл үчен күрерсең,

Хурланган кыз,

Асылган тол өче

Каның, җаның белән түләрсең!- ди арысландай батыр йөрәкле көрәшче.

**“Минем шатлыгым”.** Лирик геройның шатлыгы – бөдрә чәчле сөйгәне дә, ал галстуклы пионер да, яңаклары кипкән әби дә, көмеш чәчле бабай да, урман-суларга, кырларга бай матур Туган иле дә. Солдат- шагыйрьТуган илен, халкын өзелеп сөя. Шулар

өчен, шушы шатлыклары өчен канлы көрәшләрдә, күз алдында үлем күргәндә дә, ул көләргә үзендә көч таба.

**“Бүләк”.** Ил азатлыгы өчен көрәшеп йөрүче солдат кулында –уртасына кызыл җептән йөрәк чигелгән кульяулык. Аңа “Дошманнарны җиңеп тизрәк кайт!”- дигән сүзләр дә тезелгән. Бүләккә карап,батыр сугышчы хисләр дулкынына бирелә: күз алмасы кебек сөйгән егетен өзелеп сагынучы, төннәрен күз яшьләрен тамдырып яулык чигүче саф йөрәкле кыз күз алдына килә. Кульяулык аша кызның кул җылысын, күңелендәге изге хисләрен тойгандай була. Күпме солдатларны яңадан-яңа көрәшләргә рухландырган, җиңүгә ышанычын арттыргандыр тылдагылар җибәргән бу бүләкләр!

**“Разведчик Сысоев”.**Сысоев образында Х.Мөҗәй сугыш китергән ачы хәсрәт, солдатларның гомерләре хисабына яуланган җиңү, үлсәм дә, Туган ил өчен дип, алга омтылган, бик күп фашистларны кырган барлык батыр солдатларның язмышын чагылдырган.

- Дәшмәс инде ул мәңгегә...
- Үлде ул, үлде! – диләр, - дип өзгәләнеп язган бу юлларда якын дустын югалту кайгысын, үзен-үзе аямыйча сугышкан ут кебек үткен күзле батыр иптәшенең үлеме белән килешә алмавын, йөрәк әрнүен ачып сала. Фашистларны кырып, сугыш кырында үлеп калган нык ихтыярлы раззведчик Сысоев йөрәккә уелып, онытылмас образ булып кала.

**“Бер батырның кабере янында”.** Ялгыз кабер. Матур чәчәкләргә төрелгән. Ил чакыргач, кулына корал алып, Ватан азатлыгы, халык бәхете өчен дошманнарга каршы көрәшеп, батырларча һәлак булган Идел егете кабере ул.

Ватан өчен кызганмаган башын
Ватанымның батыр бер улы.

**“Шакир”** хикәясе. Хикәянең үзәгендә – сугышка яңа килеп кергән яшь солдат Шакир. Киткән чакта сөйгәне Зөһрә белән тиешенчә саубуллаша алмавына үкенеп, хис-тойгыларын белдереп, хат яза.Аннары, тынычланып, һөҗүмдә катнаша. Яшь солдат каушап калмый. Үз гомерендә беренче тапкыр, яндыргыч сыекча тутырылган шешәләр ташлап, ике немец танкын яндыра, өченчесен, граната ташлап , бара торган юлыннан туктата. Икенче бер бәрелештә ике немец солдатын әсир итеп алып кайта. Башка солдатларның батырлыклары белән чагыштырып карый да эшләгән батырлыкларын азсына, тагын да зуррак батырлыклар эшләү теләге белән яна. Батырлык эшләгән саен: “Командирга да күңелле, Зөһрә дә шатлана, миңа да шәп “,- дип кабатлый. Киң күкрәкле, һәрвакыт ачык, куркусыз һәм шаян күңелле бу 24 яшьлек кызылармеец, үзенең сугышта күрсәткән батырлыклары өчен бүләкләнүе турында газетадан укыгач та, күнегелгән сүзләрен кабатлау белән чикләнә.

Бу хикәядә Х.Мөҗәйнең Шакир шикелле батырларны тәрбияләп үстергән халкына тирән ихтирамы, аларның җиңүләре өчен эчкерсез шатлана белүе, һәр совет солдатының эшләгән кечкенә генә батырлыгы да дошманны җиңүгә илткән бер адым икәнен аңлап сөенүе чагыла.

**Өченче бүлек. Х. Мөҗәйнең “Сугыш язмалары” көндәлегендә солдат образы.**

Х.Мөҗәй ут эчендә төннәрен йокламыйча иҗат итә. Сугыш аз гына туктап торган вакытны да иҗат өчен файдалана: шигырьләр, очерклар, кыска хикәяләр, парчалар яза һәм аларны газета - журналларга җибәреп тора. Шулай ук сугыш көндәлеге дә алып бара. Харьков янында камалышта калгач, полк командиры үзенең “Сугыш язмалары” н махсус рәвештә кызылармеец Кожевников аркылы тылга җибәрә. Кожевников, фронт аркылы исән-имин чыгып, дәфтәрләрне Мөҗәйнең хатыны Мәрьям ханымга тапшыра. Мәрьям ханым исә аларны бик кадерләп саклый.

Ут эчендә язылган бу көндәлек 1941нче елның 22нче июленнән 1942 нче елның 3нче маена кадәрге вакытны үз эченә ала. 4 дәфтәр-көндәлектә Х.Мөҗәй сугышның беренче көннәреннән үк үз башларыннан кичкән хәлләрне аңлаешлы итеп сөйләп бирә. Бу язмаларда фронт юлларында автор кичергән сугыш картиналары, совет солдатлары һәм командирларының дошманга булган нәфрәте, фашизмны җиңүгә булган ышанычы чагылыш таба.Сугыш чын фронтовик күзлегеннән сурәтләнелә. Язмаларны укыгач, автор күз алдыбызга Туган илен җаны-тәне белән сөюче, талантлы оештыручы, ялкынлы агитатор, оптимист, яхшы әзерлекле, батыр, таләпчән командир булып килеп баса. Ул һәрбер кешенең йөрәгенә керә белә, аларның кайгыларын, шатлыкларын уртаклаша. Сугышларда чыныккан легендар командир иң кыен, иң куркыныч вакытларда да каушап төшми. Ул үзенең батырлыгы, кыюлыгы белән сугышчылар арасында хөрмәт казана.

Язучының һәр җөмләсеннән иптәшләре турында кайгырту, үзенә тапшырылган кешеләр өчен, бөтен полкның язмышы өчен борчылу, сугышчыларның батырлыкларын күрү, аларның батырлыгы турында тиешле органнарга җиткереп, бәя бирүне сорау, үз вакытында бүләкләнүләренә ирешү кебек изге гамәлләрне күрәбез.

Полк командиры буларак, Х.Мөҗәй фронтның иң алгы сызыгында солдатларын һөҗүмгә алып бара, иң авыр чигенү газапларын кичерә, фашистларның ерткычлыкларын күреп тетрәнә. Дүртенче дәфтәрдә фашистларның ерткычлыгы, вәхшиләрдән дә уздырып кешеләрне суюлары турында Х.Мөҗәй ачулы рәвештә нәфрәтләнеп яза: “ Урман арасында бер үлек гәүдәгә очрадым.Ул башы белән гарепкә(көнбатышка) таба ята. Куллары да шул якка, үргә сузылганнар. Немецларны куганда һәлак булган булса кирәк. Әйләндерәм. Уң күзе тирән итеп чокып алынган. Аяк киемнәрен салдырганнар...күкрәгендә – пычак эзләре. Аркасында – сөягенә кадәр теленгән “йолдыз”. Ниндидер “профессор” бер дә ашыкмыйча

гына “операция” ясаган...белмим, үлгәнчеме,яки үлгәчме – сугышчының өстендә өйрәнгәннәр. Бәлки, аның өчен берәр фашист тимер тәре белән бүләкләнергә уйлагандыр...билгесез сугышчы өстендә канлы эшләр эшләгән фашист та тимер тәрегә ирешә алмый шушы үлекләр арасында ятадыр. Ята, һичшиксез, ята! Шул, тик шул гына көтә ул фашистларны! Алар һичшиксез һәлакәткә хөкем ителгән кешеләр!

Билгесез кызылармеецның үле гәүдәсе. Моны күрәләр, бер гәүдә өчен унысын егалар. Һәркемдә үч, һич бетми торган үч кайный!”

Өченче дәфтәрдәге: “Немецлар плен төшкән кешеләр турында халыкара изге саналган кагыйдәләр белән исәпләшеп тә карамыйлар. Әсирләрне ату белән куркыталар. Аларны ачлык белән җәзалыйлар, аркаларына, күкрәкләренә йолдыз уялар. Аларның колакларын, борыннарын кисәләр, күзләрен чокып алалар. Тереләй утка ташлыйлар...”- дигән тетрәндергеч юлларны укыгач, Дахау үлем лагере әсире Вәли Бикташевның шагыйрь белән соңгы очрашуы турында сөйләве хәтеремдә яңарды. “Фашистлар кулына әсирлеккә төшәрмен дә мине дә нәкъ шулай ук җәзаларлар”, -дип Х.Мөҗәй уена да китермәгәндер.

“Сугыш язмалары”нда хикәяләүче автор да, аның сугышчылары да Туган илләрен өзелеп сөючеләр.”Безнең совет халкы арасында хикмәтле кешеләр бар. Аларның барысында да уртак бер сыйфат – батырлык, тирән ватанчылык хас. Бу ике төрле нәрсә белән барыбыз да коралланганбыз”, -дип яза Х.Мөҗәй һәм моны мисаллар белән дәлилли. Аның өчен “Ватан каннан да, җаннан да изгерәк, кыйммәтрәк”. Икенче бер урында : ”Ватан...Шул Ватан йөрәктә булмаса, сугышның беренче көненнән бирле көне-төне үлем арасында йөрмәс идем бит мин”, - дип тә өсти. Ил язмышын гомерләреннән дә кадерлерәк күрүче совет солдатлары турында: ” Без көчле. Без рух белән көчле, җиңүгә ышаныч белән көчле! Безнең халык куркуны белми! “- дип яза Мөҗәй, горурланып. Әсәрдә әнә шундый курку белмәс, батыр рухлы, ир йөрәкле солдатларның батырлыгына бик күп мисаллар китерелә. Менә “кызылармеец Андреев немецлар арасында калып 5 офицер, 6солдатны атып үтерә-үтерә үзенә юл ярып чыга. Байбеков – кул пулеметчысы гамьсез генә башларын иеп килә торган 7 немецны пулеметтан атып үтерә. Старшина Ярушин бүгенге утлы кыршау эченнән комбат Жуковны коткару өчен үзен кызганмыйча немецлар дулкынына каршы автоматтан ут ача”. Өченче дәфтәрдә командир үз полкының беренче тапкыр орден белән бүләкләнгән 8 сугышчысына характеристика биреп чыга, аларның күрсәткән батырлыкларын саный, “сугыш тәрбиясенең иң кирәген алган сугышчылар” дип атый. Дүртенче дәфтәрдә 28 батырның исемнәрен яза һәм: “Бу кешеләр өч атака белән дошманны җиңделәр”,- ди. Шул ук дүртенче дәфтәр башында Кусты хуторына һөҗүм вакытында батырлыклар күрсәткән сугышчыларны исемләп атый, батырлыкларын сурәтли. Менә автоматчы Коншев, Столбун. “Аларның икесе дә рус уллары, икесенең дә йөрәгендә

кадерле Ватанга мәхәббәт уты яна, Икесенең дә уенда бөек полководец Суворовның: "Руслар пруссакларны һәрвакыт тукмадылар" , -дигән сүзләре саклана",- ди автор һәм аларның батырлыклары белән танылулары турында яза.Ә рота командиры Ананьев инде " Батырлык өчен" медале белән бүләкләнергә дә өлгергән. Менә Ленинград егете сержант Николай Степанов, Казахстан егетләре сержант Клим Шатохин, Федор Вилков, өлкән сержант Тимофей Русанов." Бу кешеләр барысы да автоматчылар. Берсе өчен икенчесе үләргә торган сугышчан дуслар. Алар берсе өчен икенчесе үләргә торалар, шуның өчен аларның берсе дә үлми һәм үлем алар тирәсенә якын килергә курка", -дип яза Х.Мөҗәй, бу солдатлар арасындагы ерткыч дошманга каршы көрәшләрдә чыныккан керсез дуслыкка сокланып.

"Бу сугышларда әллә никадәр батырлыклар күрсәткән иптәшләр күп. Аларның исемнәре дә, саннары да көн саен арта... Бу кешеләр турында йөзәр битлек очерк, хикәя язарлык эшләр бар. Ләкин хәзергә бу зур эш белән шөгыльләнергә вакыт юк әле...", - дип яза автор. Башкалардан сәер характеры белән аерылып торган пулеметчы лейтенант Ананьевның батырлыгы турында язмыйча кала алмый ул. Аның турында укыгач, шагыйрьнең "Минем шатлыгым" шигыре искә төшә. Андагы лирик герой кебек үк Ананьев та, сугыш кырында алдында үлем торганын сизсә дә, көлә-көлә көрәшергә үзендә көч таба:

" Ул шулай шаркылдап көлә-көлә Конотоп шәһәре янындагы Загребелье авылы урамында 150 кешедән гыйбәрәт булган дошман колоннасын пулемет уты белән тураклады.

Ул шулай шаркылдап көлә-көлә Н.авылы янында дошманның атакага килә торган өч шеренгасын берсе артыннан берсен егып салды.

Ул шулай шаркылдап көлә-көлә, бер авылга инде кереп җиттем дигән дошманның штабын туздырып, ике машина документ алды.

Ул шулай шаркылдап көлә-көлә Сумы шәһәре күпере буенда берничә дистә дошман солдатларын суга батырды. Мин бүген аны орден белән бүләкләүне сорап язылган кәгазьгә ку куям",- дип яза аңа сокланып Х.Мөҗәй.

Сугыш корбаннарсыз булмый. Фронтта дусларының үлеме командирның йөрәген сыкрата. Аларны югалту аңа бик авыр. Бер сугышта аның күз алдында "бөтен тәне, җаны белән Совет ватанына бирелгән 24 яшьлек боевой командир" грек Дузь яралана. Аны ике кызылармеец мылтыкларыннан носилка ясап күтәрә генә башлыйлар...Снаряд төшеп ярыла. Дузьның ярты гәүдәсе киселә. Кызылармеецлар үзләре дә, мылтыклары да өзгәләнәләр...Аның белән бер сәгатьтә үк командирның адъютанты Цепляев һәлак була. Кече командир, "үткен, зирәк һәм һәрвакыт уяу разведчик Победа, Победа исеме белән дә, эше белән дә "Победа" разведкадан әйләнеп кайтмый, яшь булса да, ачык акыллы, үткен, куркуны белми торган Себер егете разведчик Астаховның гомерен дошман снаряды

кисә.”Ул үлде, ләкин ул җиңеп үлде! Аның турында истәлек миндә дә, Сумыда да мәңге калачак!”, - дип яза Х.Мөҗәй. Разведчик-лейтенант Сысоев та разведкада үтерелә.“ Безнең Сысоев сугыш белемнәренең разведка дигән тармагы буенча аерым талантлы, шул эшнең остасы, алыштыручысы булмаслык дәрәҗәгә җиткән бер разведчик иде. Менә бүген ул юк. Тик бүрекне салып: “Прощай, товарищ!”- дип әйтергә генә калды”, - ди шагыйрь. Бу батырга багышлап, ул “Разведчик Сысоев” шигырен яза.

Өченче дәфтәр азагында мондый юллар бар:” Бүгенге сугышта егермеләп яраланучы бар. 9 иптәш үлгән. Шулар арасында сержантлардан Сунленой һәм Кирсанов. Кызылармеец саперлардан Рогозин, Петровский, Романов, Платоновлар. Болар дошманның иләк кебек куе утына карамыйча, каннарын һәм үзләрен дә кызганмыйча, дошман оборонасына башлап ташланучы кешеләр. Аларның кулы белән дүрт ут ноктасы җимерелде. Алар сигез өйдәге гитлерчыларны гранаталар белән сөрделәр. Алар үлде, ләкин үзләре үлгәнче банда армиясенең берничә дистә солдатын һәм офицерын йомычка иттеләр. Аларны күмдек. Исемнәрен, эшләрен полк тарихына керттек” . Бу солдатлар барысы да, үзләренең сугышчан бурычларын намус белән үтәп, изге Ватан азатлыгы өчен батырларча һәлак булучы сугышчылар. Алар барысы да, үзләренең гомерләрен биреп, Җиңү көнен якынайтучылар. Аларның исемлеген тагын да дәвам итеп булыр иде әле. Исәпсез корбаннар хисабына яулап алынды шул ул бөек Җиңү! Мондый бөркет сугышчылары булган илне җиңү һич мөмкин түгел! Тарих моны раслады.

Кызганычка каршы, ил азатлыгы өчен гомерен дә аямыйча көрәшүче батыр солдатлар белән янәшә, куркаклык күрсәтеп, сугыш кырыннан качучы качкыннар да, сатлык җаннар да булган. Антларын саткан пычрак җаннар алар. Алар совет солдаты исемен йөртергә лаек түгелләр. Ләкин бу - берничек тә инкарь итеп булмый торган кырыс чынбарлык. Х.Мөҗәй дә моны яшереп кала алмый. Үзенең көндәлегендә, Дубна янында сугышта батырларча сугышып, 22 кызылармеец, 6 кече командирның һәлак булуы турында сөйли дә, шунда ук куркуларыннан сугыш урынын ташлап качкан ике урта командир Новиков һәм Кузьменко турында яза, алар “ киләчәк көннәрнең берсендә кулга төшәрләр һәм үз җәзаларын алырлар дип уйлыйм”, - дип ачы нәфрәтен белдерә. Икенче бер урында шундый куркак җанлы качкыннарга җирәнеп каравын белдереп: ” Синең иптәшең, бәлки атаң, бәлки энең фашистлар угы белән яраланып, кан эчендә ятканда, аңарга бер ярдәм дә бирмичә ташлап киткән оятсыз кеше түгелме син, качкын?! Сине чәнчеп үтергән кешеләр – мактаулы патриотлар. Сине кызгану юк!”- ди. Шушы ук фикерне “ Качкын” шигырендә дә үткәрә. Менә шундый куркак , сатлык җаннар булмаса, бәлки Җиңү көне тизрәк тә килгән булыр, 92 совет офицеры да исән калып, концлагерьда кораллы восстание күтәреп, бик күп әсирләрне азат иткән булырлар иде, дип уйлыйм мин.

**Йомгаклау**

Эшемне тәмамлап, шундый нәтиҗәгә килдем:

1. Хәйретдин Мөҗәй 18 яшеннән Совет Армиясендә. Шуннан алып гомеренең соңгы сулышына кадәр – солдат, офицер.Урта Азиядә басмачыларга каршы көрәшә. Хасан күлендә япон самурайларына каршы сугышта катнаша. Бөек Ватан сугышының беренче көннәреннән үк полк командиры буларак алгы сызыкта сугыша.Ул инде хәзер сугышларда чыныккан, иң кыен, иң куркыныч вакытларда да каушап калмый торган курку белмәс командир.Сугышта шәхси батырлыклар да күрсәтә, полковник дәрәҗәсенә кадәр күтәрелә. Каты сугышларның берсендә чолганышта калып, фашистлар тарафыннан әсир ителгәннән соң да көрәшен туктатмый. Дахау үлем лагеренда ерткычларча кыйналулар да батыр җанлы командирның рухи көчен сындыра алмыйлар.

Х.Мөҗәй фашист тоткынлыгында патриотик эшчәнлеге белән генә түгел, ә бөтен тормыш юлы һәм ялкынлы иҗаты белән дә көрәшче-әдип, патриот-шагыйрь дигән исемне тулысы белән аклады.Иҗаты да, командир буларак батырлыгы да, батырларча үлеме дә үлемсезлеккә әверелде. Хәйретдин Мөҗәйнең кабере юк. Ләкин аның исеме безнең йөрәкләрдә. Якташлары да аның белән горурланалар, батырлыгын Муса Җәлил батырлыгы белән тиңләп, Мөҗәйне "Башкортстан Җәлиле" дип йөртәләр.

2. Шагыйрьнең сугыш чорында иҗат ителгән һәр әсәрендә Туган илен ихлас сөюче, аның белән горурланучы, изге җирен пычрак итекләре белән таптаучы ерткыч фашистларга тирән нәфрәт уты белән янучы, җиңүгә бөтен күңеле белән ышанучы солдат образы тора. Ул солдатлар, үзләренең сугышчан бурычларын намус белән үтәп, сугышларда тиңдәшсез батырлыклар күрсәтеп, изге Ватан азатлыгы өчен батырларча сугышчылар. Алар, үзләренең гомерләрен биреп, Җиңү көнен якынайтучылар.

3.Шигырьләрендәге лирик герой да - Ватан азатлыгы өчен үзен аямыйча көрәшүче, биргән антына тугры калып, хәрби бурычын намус белән үтәүче курку белмәс батыр совет солдаты. Күп очракта ул шагыйрьнең үзенең уй-хисләрен, теләкләрен чагылдыра.

4. Барлык солдатларны бер максат берләштерә: Ватанны фашист илбасарларыннан саклау.

5."Сугыш язмалары"н укыгач, бик күпләр ул солдат образларында әтиләрен, абыйларын, энеләрен, улларын, туганнарын, таныганнардыр. Алар белән горурлану хисләре кичергәннәрдер.

Шулай итеп, Х.Мөҗәй үзе дә, аның иҗатындагы солдат образы да Ватанга бирелгәнлек, антка тугрылык, чын батырлык үрнәге, дип фаразлавыбыз расланды.

**Кулланылган әдәбият һәм Интернет-чыганаклар:**


1.Алар сафта. Төзүчесе С. Шакир. Казан, Татарстан китап нәшрияты, 1978

2.Әдипләребез.Т.2 Казан, Татарстан китап нәшрияты, 2009

3. Гарипов М. Мөҗәй батыр // Казан утлары.№5 2007.

4.Каһарман каләме. Казан, Татарстан китап нәшрияты, 2010. - 223б.

5. Татар поэзиясе антологиясе. Т.2 Казан, Татарстан китап нәшрияты, 1992

6. Талипова Э. Штыкны каләм итеп.// Мәгариф. №3 2001

7.Утлы еллар авазы. .Казан, Татарстан китап нәшрияты, 1972

8.Хәйретдин Мөҗәй.Тормыш юлы һәм иҗаты. Казан, Татарстан китап нәшрияты, 2010.-142б.

9. Хәйретдин Мөҗәй. Сугыш язмалары. Казан, Татарстан китап нәшрияты, 1991-301б.

10.Юзеев И.Йөрәгендә – җыр, кулында – мылтык.//Сабантуй. – 1996. -23март.

11. H.Mozhaj.izhatynda.sugysh.chynbarlygynyn.gaudalaneshe

12. shigriyat.ru›authors/hajretdin-mojaj/bio

13. tt.wikipedia.org

14. sptatar.com›m-y-h-yretdin/



*Валиева Лейла, 9 нчы сыйныф,*

*Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районының "инглиз телен тирәнтен өйрәнү белән 33 нче урта гомуми белем бирү мәктәбе" муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесе*

*Җитәкчесе: Нургатина Раиля Раифовна, татар теле һәм әдәбияты укытучысы*


## Шигъри тәлгәшләр

Мин җырларга яратам

Яратам мин җырларга,
Тыпыр-тыпыр биергә.
Килешле бизәнергә,
Матур күлмәк кияргә.

Яратам телефонда

Төрле уен уйнарга.

Тик яратмыйм, баш катырып,

Дәресләрне уйларга.

Яратам илһам килгәндә,

Хәтта шигырь язарга.

Ап-ак киндер тукымага

Төрле сурәт ясарга.

Яратам мин кояшны,

Яңгырны, ап-ак карны.

Елгаларны, күлләрне,

Кыяны, текә ярны.

Укуны да яратам мин,

Икеле куймасалар.

Өй эшен сорамасалар,

Бик күп эш кушмасалар.

Биремнәр эшләтмәсәләр,

Диктант яздырмасалар.

Саннар исәпләтмәсәләр,

Сорау яудырмасалар.

Әнигә зарланмасалар,

Сөйләшеп утырганны.

Җәзалап, партадашымнан

Аерып утырткanны

Яратмыйм мин, нишләтсәң дә,

Тып-тын дәрес тыңларга.

Миңа кирәк бу дөньяда

Җырларга да уйнарга.

Мин балыкны коткардым

Төшке ашка әнием

Кибеттән балык алды.

Суга салгач, талпынып,

Ул мине уйга салды.

Шундый матур балыкны

И жәлләдем, кызгандым.

Кире суга җибәргә

Җиңнәремне сызгандым.

Төне буе йокламыйча,
Балыкны саклап чыктым.
Үз иркендә яшәсен дип,
Балыкны суга тыктым.

Иртән әти уянгач,
“Киттек елгага!” – дидем.
Кама өсте боз диеп,
Йон итегемне кидем.

Әти аптырап торса да,
Мин үземнекен иттем.
Балыкны чиләккә салып,
Елга буена киттем.

Борау белән бозны тишеп,
Озаттык без балыкны.
Җибәрдек аны елгага,
Шаккатырып халыкны.

Балык, дус-ишләрен табып,
Әй сөенәдер инде.
Әти-әнисенә мине
Мактап сөйлидер инде.

Үз өемдә үз көем

Аулак өйгә дус кызым
Дәште мине кунакка.
Күптән уйланып йөрдек,
Хыялландык бу хакта.

Киемнәремне җыйдым,
Китапларымны алдым.
Теш щёткамны, таракны –
Барсын сумкага салдым.

Мендәремне кочакладым,
Юрганыма карадым.
Кунакка барам диеп,
Чәчләремне тарадым.

Йомшак куяным нигәдер
Боегып карап тора.
Иртәгә  кайтырмын дигәч,
Миннән башкаен бора.

Елмаеп торган гөлем дә
Моңсулангандай булды.
Барсына да карап торып,
Күземә яшьләр тулды.

“Үз өеңдә – үз көең”, – дип,
Дөрес әйтә әбием.
“Үз урыныңда йокла!” дип,
Өстәп куя әнием.

Уйладым да кабат-кабат,
Бармаска карар кылдым.
Йомшак куянымны кочып,
Татлы йокыга талдым.

Төрекчәгә өйрәнәм
Телләр өйрәнү кызык та,
Күңелле дә, кыен да.
Мин зур үскәч булырмын дим

Тәрҗемәче уемда.

Уйладым да, мин онлайн
Дәресләргә язылдым.
Татарчаның кардәш теле –
Төрекчәгә алындым.

Татарча белән охшашлар,
Бик күп уртак сүзләре.
Фонетика, грамматика –
Жиңел кебек үзләре.

Тик шулай да лексикада
Кызык хәлләргә тарам.
Тәрҗемәдә мин еш кына,

Баш ватам, уйга калам.

Галстукка “креват” диләр,
Ә тукталышка “дурак”.
“Баба” була икән эти,
Ә стакан була “бардак”.

Төркиядә без “эт” дисәк,
“Ит” дип аңлаячаклар.
Паста дисәк, токмач түгел,
Алга торт куячаклар.

“Учак” – очкыч була икән,
Ә кошны “куш” дияләр.
“Ун” төрекчә сан түгел ул,
Онга шулай дияләр.

Баштан төтен чыга кайчак,
Төрек сүзләрен ятлап.
Телләр туган булса, өйрән
Бутамый, мәгънә саклап.

Эт чаба дип, бет чапмасын!
Әнием язга чыкканда,
Марафонга кушылды.
Дөрес туклану һәм фитнес –

Программаның асылы.

Әнигә кушылып, бер көн
Мин аңа булдым терәк.
Ябыгу марафонында
Дөрес туклану кирәк.

Дөрес туклануга керә
Парда пешкән ризыклар.
Яшелчә, җиләк-җимешләр,
Шикәрсез, тозсыз ашлар.

Бер көн фәкать әфлисун,
Мандарин көне булды.
Эчебезгә зур күләмдә
С витамины тулды.

Кич җиткәч, бөтен тәнемә
Кызыл тимгелләр чыкты.
Кычыткан чаккан диярсең,
Бүртте – аяктан екты.

Кычыта да, әчетә дә,
Тимгелләр арта гына.
Бу газапка түзәр хәл юк,
Ут кебек янам гына.

Әни дә куркуга төште:
Тизрәк табиб чакырды.
Ул арада ни булганын
Уйлап борчу кабынды.

Табиб мине күрүгә үк:
“Ни ашадың син? – диде. –
Аллергия чыккан сиңа,
Нидер килешми,” – диде.

Әни белән икебезгә
Бу хәл булды зур сабак.
Әфлисунымны ташладым,
Тулы иде бер табак.

Табиб белән киңәшләшү

Кирәк кайбер вакытта.
Эт чаба дип, бет чапмасын,
Чама белик кайчакта!

Догалы булыйк

Көненә нәкъ биш мәртәбә
Намаз укый әбием.
Шул вакытта теләк теле
Кул күтәреп әнием.

Әби намаз укыганда,
Һәммәбез тып-тын кала.
Песи дә, намазлыкка
Килеп, башкаен сала.

Догалы изге келәмдә
Күрә песи фәрештә.
Уң була икән юллар да
Дога булса һәр эштә.

Дога белән, намаз белән
Башлансын безнең иртә.
Очрамасын безнең юлда
Җиңә алмаслык киртә.

Азанлы булсын йортыбыз,
Тыныч булсын җаныбыз.
Атсын әле бик күп еллар,
Аяз булып, таңыбыз.

Рөхсәт бирдем
Сеңел, энекәш кирәкми.
Сөйләмәгез, китегез.
Кечкенә песи баласы
Миңа бүләк итегез.

Уйнар идем, сыйлар идем,
Бик тә яратыр идем.
Шул песием аркылы
Сагыш таратыр идем.

Йомышларын йомышласа,
Җыештырырмын үзем.
Ярамаган хәл кылса да,
Бары булырмын түзем.

“Биш”кә генә укырмын
Миңа песи алсагыз,
Бар эшне дә эшләрмен,
Әгәр дә сез талсагыз.

Бу кадәр ялваруга
Түзмәде бит әнием.
Кечкенә уенчыктай
Песи алды әтием.

Минем хәзер песием бар.
Бигрәкләр мин бәхетле.

Әйтерсең лә, булдым үзем
Алтын-көмеш тәхетле.
Песиемне яраттым,
Йоклаттым да, ашаттым.
Хәтта эч серләремне дә
Мин аңарга бушаттым.
Әни белән әтием
Хәйран булдылар миңа:
“Мондый җаваплы булгач,
Энекәш кирәк сиңа.”
Ярый инде, булсын әйдә,
Алып кайтыгыз малай.
Карашырмын бәбине дә,
Бик теләсәгез алай.
Шулай итеп, әниләргә
Миннән рөхсәт тә булды.
Берничә ай үтүгә
Нәни энекәш туды.

Инстаграм

Максатым бар көндәлдә:
Кирәкнең дә кирәге.
Төнлә дә йокы бирми
Блогер булу теләге.
Блогер булырга телим,
Файдалы да, данлы да.
Видеолар төшерәм
Монтажлы да, җанлы да.
Инстаграмыма куям,
Подписчиклар күрсеннәр.
Лайк, комментлар белән
Танылу китерсеннәр.
Фотоларга төшерәм
Табигатьне, үземне,
Дусларны, әниемне,

Өемдәге песине.

Инстаграмда танылып,
Акча эшли башлармын.
Миллионга ия булсам,
Мәктәпне дә ташлармын.

Диңгез ярында кояшта
Статуслар куелыр.
Минем блог һәркем өчен
Шатлык булып тоелыр.

Соңгы версия айфонда
Сыйфатлы кадр булыр.
Күңеле һәр кешенең
Ак бәхет белән тулыр.

Кибетләрдән кибетләргә,
Кафелардан кафега,
Салоннардан салоннарга
Йөрермен реклама алырга.

Шул хыяллар белән янып
Йөргән мәлдә бервакыт.
Инстаграмга чик керттеләр,
Яптылар  сәбәп табып.

Хыялларым, теләкләрем-
Барсы да юкка чыкты.
Укырга алынырга дип,
Башыма бер уй сукты.

Эшсезлектән интегеп,
Дәресләргә тотындым.
Темаларны өйрәнеп,
“Биш”ле ала башладым.

Инстаграмда булмагач,
Булыйм дидем мәктәптә
Иң алдынгы шәп бала
Һәм мактаулы әлбәттә.

Тырышкан һәрчак табар,
Ташка да кадак кагар.

Акча эшләү юлын да
Белем аркылы табар.

Авылым

Зәйнең бер почмагында
Имәнле авылы бар.
Гүзәллеккә күмелә ул
Яуган чакта ап-ак кар.

Имәнледә матур була
Язгы алсу таңнар да.
Ашкынам авылыма
Җәйге озын ялларда.

Авылымда урманнарда
Шаулап үсә имәннәр.
Шуңа күрә исемен дә
Имәнле бит дгәннәр.

Көзен алтынсу вакытта
Чикләвекләр өлгерә.
Авылга кайткач әбием
Кызык сөйләп көлдерә.

Бик яратам авылымны,
Халкы да эшкә булган.
Бар да монда тырышлар,
Ул-кызлары бик уңган.

Яшәсен әле авылым
Бик күп еллар гөрләтеп.
Яксын яшьләр су буенда
Учакларны дөрләтеп.

Исән булсын якыннарым,
Мәңге яшәсен авыл.
Булмасын сугыш, кан-кою!
Тимәсен безгә давыл!

Яран гөле

Тәрәз төбендә әбинең
Үсә яран гөлләре.
Аллы-гөлле чәчкәләре
Матур да соң үзләре.

Авылга кайткан саен мин
Шул гөлләргә сокланам.
Ничек шулай гүзәл алар
Диеп, һәрчак уйланам.

Бу яран гөле шәһәрдә
Болай ук булмас иде.
Фатирны бизәп, матурлап,
Ут янып тормас иде.

Гөл авыл кояшы белән
Чәчәк ата, нурлана.
Балкыта әби өен,
Ә кайвакыт моңлана.

Яран гөл авыл өеннән,
Тәрәздән аерылмас.
Бисмиллалы шифа сусыз
Тылсымлы була алмас.

Әби сипкән чишмә суы
Аңа көч биреп тора.
Табигатьнең дәрте-яме
Тамырга сеңеп тора.

Әбинең дога, теләген
Яран бик тә ошата.
Нурга күмеп өебезне,
Ак чәчкә булып шыта.

Бисмиллалы һәм әбиле
Йортыбыз балкып торсын.
Каникулга кайткан саен
Яран чәчкәдә булсын!

*Вәлиуллина Гүзәл , 11 сыйныф,*
*Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районының "Каенлы урта гомуми белем бирү мәктәбе" муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесе*
*Җитәкчесе: Хайруллина Лилия Аркадий кызы, татар теле һәм әдәбияты укытучысы*

## Театр тарихы һәм театр сәхнәсендә балкыган йолдызлар

### Кереш өлеш

### Театрның сәнгатебездә тоткан урыны.

Яңа заман тарихыбызның рухи күгендә гел янып торган берничә иң якты йолдыз бар. Аларның кайберләре - әллә ничә гасырдан бирле күңелләргә яктылык биреп килгән булса, икенчеләре – XIX йөз белән XX гасыр башында кабынган, шуннан бирле нур сибеп торган олы йолдызлар. Якты йолдыз сыйфатында икеләнмичә милли театрыбызны атарга кирәк.XIX гасырда ук идеясы тернәкләнә башлап, 1906 елда реаль җимешләре – спектакльләр рәвешендә киң мәйданга чыккан театр сәнгатебез.

Сәхнә сәнгатенең әһәмияте турында сүз чыкканда, сәхнә осталарыбызның халыкка күрсәткән олы, игелекле хезмәтенең моңарчы тиешле дәрәҗәдә яктыртылып җитмәгән бер сыйфатына төртеп дигәндәй күрсәтүне кирәк дип табам.Сүз, гомумән, сәхнә сәнгатенең- театр спектакльләре булсын, эстрада концертлары булсын, тоталитар тәртипле совет шартларында гамәлдә булган, дөресрәге тормышка ашырыла килгән үзенчәлекле бер хосусияте хакында. Ул-сәхнәгә чыккан тамашаларның цензор чикләүләреннән чагыштырмача ирекләрәк булу сыйфаты.

Сәхнә сәнгатебезнең икенче объектив өстенлеге дә булган. Ул – милли мәктәпләр ябылып, татарча китаплар елдан-елга азрак таралган, халкыбызның күпчелеге үз ана телендәге матбугатны иркенләп уку мөмкинлегеннән мәхрүм ителгән елларда барлыкка килгән бушлыкны тутырырга омтылудан туган өстенлектән гыйбарәт. Чөнки ул шартларда СССР буйлап сибелгән, үзара мәдәни-рухи бәйләнешләре зәгыйфьләнгән халкыбызның милли бердәмлек хисе саклануга хезмәт иткән бердәнбер дип әйтерлек чарабыз беренче нәүбәттә сәхнә сәнгате- театр һәм эстрада булды.
Бу хөкемнең коры дәгъва гына булмавын аңлар өчен сәхнә -эстрада, күчмә һәм академик театр хезмәткәрләренең бихисап гастрольләрен искә төшерик. Ерак өлкә - республикалардагы чыгышларыннан тыш, ярымкараңгы авылларыбызда алар кабызган

“клуб утларын” истән чыгармыйк. Ягъни төрле яклап таланган, кыерсытылган авыл халкына артистлар күрсәтә килгән игелекле, сирәк булса да тирән тәэсирле хезмәтнең әһәмиятен онытмыйк.  Артист хезмәте дигәч, шуны да истә тотарга кирәк:совет җәмгыяте матди яктан кыерсытылган (түбән эш хакына көн кичергән ) халыкның беренче зур төркемен колхозчылар тәшкил иткән булса, икенчесе, артистлардан һәм гомумән, сәхнә хезмәткәрләреннән гыйбәрәт иде.Шуны һәрвакытта исәптә тотсак,алар күрсәткән чын фидакярлекне беркадәр дөрес бәяләргә мөмкин.Шул ук вакытта сүзне, фикерне авызлыклау “осталыгын” югары камиллеккә җиткерә алган совет цензурасы артист осталыгын,аның омтылышларын тулысынча чикли һәм богаулый алмаган иде.

Дөрес, күп кенә артистларның, ”җор телле” конферансьеларның эштән куылулары, ”себер китүләре”, режиссерларның махсус үтерелүләре мәгълүм. Монда сәхнә дигән хикмәтнең өстәмә мөмкинлеге күз уңында тотыла.Ул- башкаручы артист белән тамашычы арасындагы турыдан-туры мөнәсәбәт, нәкъ шул вакытта цензурага урын калдырмый торган тыгыз якынлык. Язучы әсәрләре әле дөньяга чыгып җиткәнче, цензура узган вакытта ук эзәрлекләнә башласа, артистлар нигездә үз эшләрен башкаргач кына төрле җәзага тартылалар иде.

Ниһаять, татарча китапларның саннары, тиражлары елдан-ел азая,вакытлы матбугат эчтәлеге дә гел саега барган елларда театр һәм сәхнә сәнгатебезнең гөрләп эшләвен, тамаша залларының һәрчак тулып торган булуын да онытмыйк.Татарстаннан читтәге шәһәрләрдә гастрольләр вакытында никадәр халыкның театр ишекләренә ябырылуын хәтергә төшерик.

Кыскасы,сәхнә сәнгатебез, артистларыбыз адресына ихлас күңелдән рәхмәт әйтәбез.Әйе, безнең төрле яклап милли-рухи җәһәттән эзәрлекләнгән,таланган, бүлгәләнгән халкыбызда бүген бердәмлек, рухи һәм тарихи уртаклык хисе азмы-күпме дәрәҗәдә сакланып калган булса, без моның өчен сәхнә сәнгатебез, милли театрыбыз,фидакяр артистларыбыз, режиссерларыбыз алдында бик зур бурычлыбыз.

Шуңа күрә үземнең фәнни - эзләнү эшемне театр темасы белән бәйләргә уйладым. Чөнки киләчәктә үземнең һөнәремне сәхнә белән бәйләргә телим. Кечкенә сыйныфлардан ук иҗади бәйгеләрдә катнашам, республика күләм тел остасы, шигырь бәйгеләрендә катнашып,җиңүләргә ирештем. Җырларга, шигырь язарга,сәхнәдә рольләргә кереп уйнарга яратам. Бу тема миңа якын булганлыктан театр тарихы һәм артистлар тормышы белән кызыксындым. Укытучыбыз белән тема буенча фәнни эшкә алындык.

**Максат:**

Туган төбәгебездән чыккан һәм анда хезмәт итүче артистларның театр сәнгатенә керткән өлешен билгеләү.

Куелган максатлардан чыгып түбәндәге бурычлар билгеләдек.

**Бурычлар:**

1. Театр тарихында театрының беренче юбилеены билгеләп үтүне өйрәнү.
2. Түбән Кама җирлегеннән чыккан һәм туган төбәгебездә хезмәт итүче сәнгать әһелләрен барлау.
3. Фатхуллиннар династиясенең театр сәнгатенә керткән өлешен өйрәнү
4. Театр үсешенең заманча тенденцияләре.

**Актуальлеге:**Театр — кеше күңеленә турыдан-туры юл салучы сәнгать, һәм ул халык тормышыннан башка яши алмый.Шуңа күрә фәнни эшебез аша укучыларны илебезнең үткәнен, бүгенгесен һәм киләчәген белергә;геройларның сыйфатлары аша әхлак тәрбиясенә әдәбият дәресләрендә, класстан тыш чараларда, олимпиада һәм бәйгеләргә әзерләнгәндә,әдәби түгәрәкләрдә кулланырга була.

**Эзләнү предметы:**

Театр артистларының театр үсешенә керткән өлеше.

**Эзләнү объекты:**

Татар театры артистлары һәм аларның иҗаты.

Куелган максатларга ирешү өчен **төрле методлар** кулланылды.

1) Татар театр тарихына теоретик анализ ясау;
2) Сорау методы:әңгәмә, интервью алу, хат алышу, экскурсия-эзләнүгә бару.

**Эшнең структурасы:** керештән, өч бүлектән, йомгактан һәм кулланган библиографиядән гыйбарәт.

## I БҮЛЕК

### 1.1.Татар театрының килеп чыгышы һәм үсеше

*“Милли театрыбызның мәдәни шәкелгә керүен, театр сәнгате гражданлык алып, уйнаучыларның да, театрга язучыларның да күбәюен һәм камилләшүен телим”.Г.Камал, 1913 ел*

*“Театр — кеше күңеленә турыдан-туры юл салучы сәнгать, һәм ул халык тормышыннан башка яши алмый.Милли театр бигрәк тә”.*

*М.Сәлимҗанов, 1996 ел*

Татар театрына 100 ел. Халыкның талантын, рухи дөньясын, дәрәҗәсен билгели торган театр сәнгате – милләтебезнең казанышы һәм чиксез горурлыгы. Рус драматургы А.Н.Островский фикере белән әйткәндә, театр оешу – милләтнең камиллеген, өлгереп җиткәнлеген раслаучы зур тарихи вакыйга ул. Россиядә театр сәнгатенең XVIII гасыр урталарында мәйданга чыгуын искә алсак, империя биләмәләрендә туган милли театр өчен 100 ел аз тарих түгел. Гәрчә үткәнебезне барлаганда, без, халкыбызның бай мирасы,

әдәбиятлы булуы белән бергә, асылда бик борынгыдан җор, тапкыр, үткен һәм шук телле, җыр-моңга, уен-тамашага һәвәслеген дә күрербез. Аулак өйләр, сабантуйлар — моның ачык мисалы. Шуңа да кешенең бар осталыгын, сәләтен күрсәтүгә корылган сабантуй бәйрәме үзенең миллилеген югалтмыйча, бүген дөнья мәйданына чыгып бара. Татар театры турында да нәкъ шуны әйтергә мөмкин. Россия чикләрен каплаган "тимер пәрдә"ләр ачылу белән, милли театр үзенең бер гасырлык мирасын чит ил тамашачыларына да җиткерә башлады. Германия, Финляндия, Төркия, Бөекбританиядә узган уңышлы гастрольләр — бүгенге татар театрының дөньядагы иң мәшһүр, зур тарихлы театрлардан калышмый гына түгел, ә бәлки алар дәрәҗәсендә иҗат итүен исбатлады. Димәк, милли театрыбыз 100 еллык зур юбилеена мактауга, данга лаек булып килеп ирешге.

Ил тарихы, халык язмышы белән бергә үрелеп барган театр биографиясендә XX гасырдагы иң әһәмиятле вакыйгалар урын алган — җиңүләр һәм фаҗигаләр дә, казанышлар, табышлар һәм югалтулар да җитәрлек анда. Бу иҗади эшчәнлектә дистәләгән, йөзләгән фидакарь, талантлы режиссер, драматург, артист, рәссам, музыкант һәм театр сәнгатен тудыручы башка һөнәр ияләре катнашкан. Бу кереш мәкаләдә кыскача театрның оешу, аякка басу, үсү, җитлегү чорларына кагылышлы кайбер әһәмиятле адымнар һәм баскычларны телгә алыйк.

**1.2. Татар театры барлыкка килүдә тәүге адымнар**

XIX гасырның икенче яртысында татар дөньясында рус театры үрнәгендә милли драматургия һәм театр белән чын мәгънәсендә кызыксыну башлана, шуны кайгыртучы алдынгы фикерле әдәбият эшлеклеләре мәйданга килә. 1887 елда Габдрахман Ильяси тарафыннан "Бичара кыз" исемле беренче пьеса языла һәм өй шартларында куела да. Бер елдан соң Фатих Халиди "Рәдде бичара кыз" драмасы белән бу өлкәдә икенче адым ясый. 1899 елда булачак мәшһүр драматург Галиәсгар Камалның беренче әсәре булган "Бәхетсез егет" драмасы нәшер ителә, бер үк вакытта Гаяз Исхакыйның "Өч хатын белән тормыш" пьесасы да укучыларга барып ирешә. Мөгаллим, шәкерт, приказчик, гимназист яшьләр катнашында мәдрәсәләрдә, укымышлы гаиләләрдә өй шартларында спектакль-тамашалар уйнала башлый.

1905 елгы Беренче рус революциясе мәгърифәткә, мәдәнияткә, рухи иреккә омтылган зыялыларыбыз өчен, димәк, гомумән татар халкы өчен дә, Тукай сүзләре белән әйтсәк, күңелләрдә йоклаган дәртне уятучы, яктылыкка, нурга илтүче зур этәргеч була. Милли матбугатка юл ачыла, татарча әдәби-музыкаль кичәләр ешая. Мәдәният үсешен чагылдырган мондый күренешләр халкыбыз яшәгән бик күп төбәкләрдә — Уфада, Оренбургта, Әстерхан, Орск, Уральск һ.б. шәһәрләрдә күзәтелә. Казандагы "Шәрекъ клубы"на (Татарстан урамы, 8 нче йорт) шимбә саен татарның укымышлы, зыялы яшьләре

җыела. Шушы мәдәният учагына җыелган тамашачылар өчен тәүге һәвәскәр спектакльләрне оештыручылар да, катнашучылар да тарихта “шимбәчеләр” исеме белән танылган алдынгы яшьләрдән гыйбарәт. Татар театры туугa, аның дөрес юнәлеш алуына Галиәсгар Камал, Габдулла Тукай, Гаяз Исхакый, Фатих Әмирхан, Гафур Коләхмәтов кебек талантлы яшь әдипләрнең тәэсире һәм ярдәме гаять зур була.

1906 елның 22 декабрендә Казанда Яңа клубта (Горький урамы, 3 нче йорт) беренче тапкыр киң катлау тамашачылар өчен губернатор рөхсәте белән ярлы студентлар файдасына татарча ачык спектакль күрсәтелә, бу кечтә сәхнәдә “Кызганыч бала” драмасы һәм “Гыйшык бәласе” комедиясе уйнала. Казанны шаулаткан бу данлыклы вакыйга татар театрының туган көне булып тарихка керә.

**1.3. “Сәйяр” труппасы оешу**

1907 елның язында Оренбургта әле 1905 елда 226н уйналырга тиеш булып та реакцион көчләр каршылыгы аркасында тыелган “Галимлек вә наданлык” (А.Островский буенча) һәм “Морад Сәлимов” (Ф.Халиди) спектакльләре уйнала. Казанда Татар укытучылар мәктәбен тәмамлаган күренекле шәхес, талантлы музыкант һәм җырчы Ильяс Кудашев-Ашказарский тарафыннан оештырылган алдынгы фикерле татар егетләреннән торган әлеге төркем шул 226 елны Идел буйлап беренче гастрольгә чыга. Бу — профессиональ татар театр труппасының яши башлавы.

Соңрак Түбән Новгородта труппага “беренче татар артисткасы” булып танылачак Сәхибҗамал Гыйззәтуллина-Волжская һәм үзе исән чагында 226н “татар театрының атасы” дип йөртеләчәк, тарихка артист, режиссер, “Сәйяр” труппасының җитәкчесе Габдулла Кариев булып керәчәк 21 яшьлек Миңлебай Хәйруллин кабул ителә. “Сәйяр” — 1908 елда труппага Г.Тукай кушкан исем (күчеп йөрүче йолдыз мәгънәсендә). Татар театры үзенең беренче исеменә гасыр буе тугрылыклы калып ил гизә; ул халкыбыз яшәгән һәр төбәктә — Мәскәү, Санкт-Петербург, Баку, Уфа, Идел буе, Урал, Себер, Казахстан, Урта Азия шәһәрләре һәм Балтик буе республикаларында, ерак чит илләрдә гастрольләрдә булып, үзенең 226нны-мәдәни вазифасын зур фидакарьлек белән башкарып килә. 1918 ел ахырына кадәр “Сәйяр” исемен йөрткән татар театр труппасы артистлары, барлык авырлыкларны җиңеп, чор каршылыклары һәм фәкыйрьлек белән көрәшә-көрәшә нибары 10–12 ел эчендә тормышчан, халыкчан, рухи тәрбия чыганагы булып җитешкән 226нны театр барлыкка китерәләр һәм 226нны чын сәнгать югарылыгына күтәрәләр. Драматурглар Г.Камал, Г.Исхакый, Ш.Камал, М.Фәйзи, Ф.Бурнаш, К.Тинчурин, Мольер, Ф.Шиллер, У.Шекспир, Н.Гоголь, А.Чехов, М.Горький, А.Островский әсәрләрендә Г.Кариев, С.Гыйззәтуллина-Волжская, Н.Сакаев, В.Мортазин-Иманский, Г.Болгарская, Ф.Сәмитова, Б.Болгарский, Ф.Ильская, К.Шамил, З.Солтанов, Н.Таждарова, Н.Арапова,

Ә.Кулалаев, Г.Мангушев, Камал I, Камал II, С.Байкина, Ш.Шамильский, Ә.Синяева, С.Айдаров кебек яшьләр, күбесенең махсус театр белемнәре булмаса да, талантлы җитәкчеләр һәм рус театрының тормышчан мәктәбе үрнәгендә (монда “Сәйяр” труппасының эшчәнлегендә катнашкан Н.Зимовой, А.Михайленко, А.Загорский, М.Громов һ.б. рус режиссерлары, артистларының да өлеше бар) иҗади яктан үсәләр, профессиональ зур артистлар булып өлгерәләр.

### 1.4. Татар театрының ил күләмендә танылуы

1912 елда С.Гыйззәтуллина-Волжская “Сәйяр” төркеменнән китеп, Уфада “Нур” исемле — икенче татар театры труппасы оештыра. Оренбург шәһәрендә 1915 елда В.Мортазин-Иманский җитәкчелегендә татарча өченче театр — “Ширкәт” труппасы эшли башлый. Шулай итеп, 1917 елгы Октябрь революциясенә кадәр татар театры ил күләмендә танылып өлгерә һәм аның белән кызыксынучылар арта.

1917 елгы революциягә Г.Кариев җитәкчелегендәге “Сәйяр” артистлары Россия күләмендә даны таралган, театр белгечләре, тәнкыйтьчеләр күзлегеннән дә иҗади җитлеккән, иң мөһиме, тамашачыларның мәхәббәтен казанып, матди яктан да иркен сулыш алган труппа булып килеп керә. Бу вакытта театрга махсус бина булдыру чаралары да күрелә башлый. Октябрь революциясе театр тормышына яңа борылыш, яңа сынаулар алып килә. Кыска гына арада берничә исем алыштырып, театр үзгәрешләр чорында үзенең актив эшчәнлеген дәвам итә.

### 1.5. Беренче дәүләт театры төзелү

Гражданнар сугышы елларында артистлар төрле фронт бригадаларында кырыс, күчмә шартларда хезмәт күрсәтәләр; Урта Азиядәге тугандаш республикаларның милли театрларына беренче юл күрсәтүчеләр дә, бөтен ил буйлап дистәләгән татар театрлары туугa сәбәпче һәм аларга ярдәм итүчеләр дә татар артистлары була. 1922 елда асылда “Сәйяр” труппасы нигезендә һәм аңа төрле яклардан, төрле труппалардан артистлар, драматурглар, музыкантлар җыелу нәтиҗәсендә дәүләт театры төзелә. Ул “Кызыл Октябрь исемендәге беренче татар дәүләт үрнәк драма театры” дип атала, аның җитәкчесе итеп Г.Кариевның шәкерте — артист, режиссер, драматург К.Тинчурин билгеләнә. 1926 елда театр Академия исеменә лаек була, ә 1939 елда Галиәсгар Камалның 60 еллык юбилее уңае белән театрга аның исеме бирелә.

1920–1930 еллар театр эшчәнлегендә төрле эзләнүләр, тәҗрибәләр чоры. Драматург Ф.Сәйфи-Казанлы сүзләре белән әйткәндә: “Безнең театрда ... романтизм да, футуризм да бар, ләкин театрның 99 проценты — реалистик”. Халык тормышыннан алып язылган мелодрамалар, чит ил классикасыннан У.Шекспир әсәрләре, чор кадагына кагылышлы милли һәм тәрҗемә пьесалар репертуарның тотрыклы булуына ярдәм итә.

1923 елда Казанда театр техникумы ачыла һәм татар театрына артистлар хәзерләүне башлап җибәрә. 1926 елда труппа техникум тәмамлаган беренче артистлар Галия Булатова, Галия Нигъмәтуллина, Галия Кайбицкая, Хәким Сәлимҗанов кебек яшь талантлар белән тулылана. 1930 елда театрыбыз Мәскәүдә СССР халыклары театрлары Олимпиадасында катнаша. Шуның нәтиҗәсе буларак, режиссурага яңа таләпләр куела һәм махсус югары белемле режиссерлар әзерләү өчен талантлы яшьләр Мәскәүгә укырга җибәрелә. 1928 елда татар театры махсус җиһазландырылган, уңайлыклары булган бинага күчә (Горький урамы, 13 нче йорт).

**1.6.Музыкаль драма үсеше һәм яңа театрлар ачылу**

1920 еллардагы татар театрының иң әһәмиятле үзенчәлеге — музыкаль әсәрләр куюга йөз тоту. Татар театр сәхнәсендә беренче профессиональ композитор Солтан Габәши башлап җибәргән эш — спектакльләрне музыкаль яктан бизәү — тагын да көчәйтелә. К.Тинчурин татар тамашачысының җырны әсәрләргә мәхәббәтен яхшы тоеп, драматургиядәге иҗаты белән дә, режиссер һәм җырчы артист сыйфатында да музыкаль драма жанрын үстерүгә зур өлеш кертә. 1922 елда музыка бүлегенә җитәкче итеп талантлы композитор Салих Сәйдәшев чакырыла. Музыкасын ул язган “Зәңгәр шәл”, “Казан сөлгесе”, “Сүнгән йолдызлар”, “Наемщик”, “Кандыр буе”, “Талир тәңкә” спектакльләрендә С.Айдаров, Г.Кайбицкая, Р.Кушловская, С.Садыйкова кебек артистларның җыр таланты тагын да ачыла. Академия театрында туган музыкаль драма жанры татар опера театры оешуга турыдан-туры этәргеч була. 1925 елда театрда куелган “Сания” исемле беренче татар операсында күп кенә драма артистлары катнаша. 1934–1938 елларда Мәскәү консерваториясе каршындагы татар опера студиясен тәмамлап кайткан яшь көчләр нигезендә (алар арасында драма артистлары да була) 1939 елда Казанда опера театры оеша. Бу ике театр 1956 елга кадәр бер бинада иҗат итәләр.

1933 елда Академия театрының филиалы — Татар дәүләт күчмә театры (хәзерге К.Тинчурин исемендәге Татар дәүләт драма һәм комедия театры) оештырыла. Шулай ук, 1936 елда Минзәләдә, 1944 елда Әлмәттә татар дәүләт драма театрлары эшли башлый.

**1.7. Театрның Бөек Ватан сугышы елларындагы эшчәнлеге**

Театрның Бөек Ватан сугышы елларындагы эшчәнлеге күпкырлы. Артистларның күбесе фронтка алына. Яшь артистлар Г.Газизов, Ә.Йосыпов, Х.Кәтиев, Ф.Камал яу кырында ятып кала. Сугыш чорының авыр шартларында кабатланмас талантлар Ш.Шамильскийның, Н.Арапованың гомерләре вакытсыз өзелә. Р.Җиһаншина, И.Гафуров, Р.Тәминдарова, Р.Ибраһимова, Ш.Сарымсаков, С.Вәлиев-Сульва, К.Тумашева концерт бригадалары составында төрле фронтларда сугышчыларга хезмәт күрсәтәләр. Госпитальләрдә дежур тору, авыл хуҗалыгына булышу, фронт файдасына планнан тыш

концерт-спектакльләр кую белән бергә, кыенлыкларга бирешмичә, театр коллективы, иң мөһиме, киеренке иҗат эше дә алып бара. 1941–1945 елларда театрда барлыгы 23 премьера күрсәтелә. Классика җәүһәрләре “Король Лир”, “Яшенле яңгыр”, “Печән өстендәге эт”, “Хуҗа Насретдин”, шулай ук сугыш темасына язылган, халыкның фидакарь хезмәтенә, батырлыгына багышланган “Мәрьям”, “Миңлекамал” кебек спектакльләр халыкка рухи көч бирүче иҗат казанышлары була. Бу изге тема театр репертуарыннан беркайчан да төшеп тормый. “Тормыш җыры”, “Муса Җәлил”, “Моңлы бер җыр”, “Бер төн”, “Тол хатыннар, тол кызлар”, “Йә кайтырбыз, йә кайтмабыз”, “Ике сәгать, бер гомер”, “Яра”, “Телсез күке” спектакльләре шуның күренекле үрнәкләре.

1944 ел. Сугыш дәвам итүгә карамастан, татар театры өчен югары белемле артистлар әзерләү максаты белән Мәскәүдә А.В.Луначарский исемендәге дәүләт театр сәнгате институтында (ГИТИС) татар студиясе ачыла.

## II.БҮЛЕК. Тикшеренү нәтиҗәләре:

### 2.1.Районыбызда танылган театр артистлары һәм аларның Галиаскар Камал исемендәге Академия театры белән бәйләнеше.

Әйе, театр – тамашачыларның ял урыны. Ә артисларыбызның эш урыны. Шаккатырлык. Татарстаныбызның Казан шәһәрендә хәзер күпме театр бар! М. Җәлил исемендәге опера һәм балет театры, Г. Камал исемендәге татар дәүләт академия театры, Качалов исемендәге Зур рус драма тетры, Кәрим Тинчурин исемендәге дәүләт һәм комедия театры.., саный китсәк бик күп алар... Без эзләнүне ул шәһәребезнең Түбән Кама Татар драма театрына туктатыйк.

**Туфан Миңнуллин исемендәге Түбән Кама татар дәүләт драма театры.**

- 1989 нчы елда театр-студия буларак оештырыла.
- 1994 – татар яшьләр театры итеп үзгәртелә.
- 1997 – татар драма театры статусын ала.
- 2007 – дәүләт театры статусы бирелә.
- 2012 – театр күренекле драматург Туфан Миңнуллин исеменә лаек була.

**Театрга нигез салучылар:** Татарстанның халык артисты, Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе, Марсель Сәлимҗанов исемендәге республика премиясе, Дамир Сиражиев исемендәге премия лауреаты, театрның беренче баш режиссеры Рөстәм Вәлиәхмәт улы Галиев, «Нефтехим» берләшмәсенең генераль директоры Гаяз Җәмикъ улы Сәхапов, Халык иҗаты йорты директоры Татарстан Республикасының атказанган артисты Анатолий Степан улы Богатырев (хәзер мәрхүм).

Театр үзенең **беренче сезонын** Туфан Миңнуллинның «Ак тәүбә, кара тәүбә» пьесасы буенча куелган «Кызлар кызык итәләр» музыкаль комедиясе белән ача. Режиссер Рөстәм Галиев, композитор Фасил Әхмәтов, рәссам Рафаэль Шакиров (хәзер мәрхүм).

**Театрның беренче артистлары:** Гөлгенә Зәйнуллина, Гөлнур Галиева, Олег Фазылҗанов, Илшат Мостафин, Илдар Закиров, Фарил Вафиев, Разил Сибгатуллин, Илдус Әхмәтҗанов, Гөлчәчәк Габдрахманова.

**Беренче спектакльләр:** Т.Миңнуллин "Яшьлек белән очрашу", "Ай булмаса йолдыз бар" (режиссер – Р.Галиев), Г.Каюмов "Адашкан чәчәкләр", "Бәхетеңне кәҗә сөзсә" (режиссер – Р.Галиев), Р.Галиев "Карурман аша" (режиссер – Р.Галиев), Аманулла "Итәкле кияү" (режиссер – Р.Галиев).

**Театр үсешенә үзләренең зур өлешләрен керткән иҗат көчләре:** режиссерлар Рөстәм Фатыйхов (хәзер мәрхүм), Байрас Ибраһимов, Гафур Каюмов, Фаил Ибраһимов, директорлар Е.Н.Мурлатов, Татарстан Республикасының атказанган мәдәният хезмәткәре Фәнис Чабатов, әдәби бүлек мөдире, тамашачы буенча директор урынбасары Розалия Чабатова, рәссамнар Әхәт Закиров (хәзер мәрхүм), Ленар Гыйльметдинов, Михаил Греньков, театрның баш рәссамы Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе Булат Насихов, костюмнар буенча рәссам Фәридә Мөхәммәтшина, композиторлар Азат Нәҗмиев, Юрий Чаплин, Мохтар Минһаҗев, артистлар Айдар Каримов (хәзер мәрхүм), Татарстан Республикасының халык артисты Ания Фәттахова (хәзер мәрхүмә), Татарстан Республикасының атказанган артисты Мәүҗит Фәттахов.

**Бүгенге көндә театрда эшләүче артистлар**: Татарстанның атказанган артистлары – Фәхразиева Г.А., Вафиев Ф.Ф., Зәйнуллина Г.Г., Галиев Р.А., Карпова Д.К., Гыйниятуллина Ф.Ф., Ибраһимов А.Х., артистлар – Әгъләмова А.Р., Әсәтов Р.Р., Галиева Г.Ш., Гафиуллин С. Р., Зәйнуллин Р.Ш., Зарипова Р.Р., Куянова А.П., Манойлова А.С., Павлов Ю.В., Сәйфетдинов Н.Ш., Фәттахова Э. Р., Харисов Д.Ф., Хөсәенов А.М., Хөсәенова Н.И., Чупашева Л.Р., Шәмәрданова Г.Ф.

**Театрның директоры һәм сәнгать җитәкчесе** Татарстанның халык артисты, Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе, Марсель Сәлимҗанов исемендәге республика премиясе, Дамир Сираҗиев исемендәге премия лауреаты Рөстәм Вәлиәхмәт улы Галиев.

Театр коллективы 70 тән артык әсәр сәхнәләштерде. Репертуарда татар, рус, чит ил драматургларының әсәрләре урын алды: М.Кәрим " Кыз урлау", "Ай тотылган төндә", Һ. Такташ " Җир уллары трагедиясе", Г. Исхакый "Өч хатын белән тормыш", К. Тинчурин " Ил", И.Юзеев "Соңгы төн", Н. Гыйматдинова "Бүре каны", М.Гыйләҗев "Яра", О.Хайям "Үзем белән үзем", А.Иванов "Гөнаһлы мәхәббәт өрәге", Т.Миңнуллин

“Яшьлек белән очрашу”, “Нәзер”, Р.Галиев “Кадер кичәсе”, Ч.Айтматов “Анам кыры” һәм башка спектакльләр.

Районыбыздагы артистлар арасында 2 артист Г.Камал исемендәге Академия театры белән тыгыз бәйләнгән. Олег Фазылҗанов үзенең карьерасын Түбән Кама драма театрында башлый. 2004 елны Академия театрына Казанга күчә.

Ә Васильева Аграфена тумышы белән Түбән Кама районы Келәтле авылыннан чыгып,театр техникумын тәмамлап Академия театрында эшли. Шуңа күрә аның эшчәнлегенә, театр сәнгатенә керткән өлешен киләсе бүлекләрдә өйрәндек.

**Артист Олег Фазылҗанов**. Татарстанның Балык бистәсе районы Казак Чаллысы авылында туа. 1987 елда Казан театр училищесын тәмамлый һәм Әлмәт татар театрында эшли башлый. Шул ук елны армиягә алына. 1990 елдан ТүбәнКама шәһәренең Нефтехим берләшмәсе каршындагы театр студиясендә, 1996 елдан Халык иҗат йортында артист-вокалист булып эшли. 2003 елдан ТүбәнКама драма театрында, 2004 елның августыннан Татар академия театрында артист. Татарстанның атказанган артисты — 2010

Камал театры сәхнәсендә уйнаган беренче рольләре:

Мирсәет — «Талак, талак» Х.Вахит

Карт Убырлы — Кечтүкле уен — Илгиз Зәйниев

Әмир — Мулла — Туфан Миңнуллин

Амур — Диләфрүз — Remake — Туфан Миңнуллин

Сәйфулла — Яшь йөрәкләр — Фәтхи Бурнаш

3 кнәз — Ханума — Авксентий Цагарели

Әбелкарип — Кыю кызлар — Таҗи Гыйззәт

Пәтрәй — Зәңгәр шәл — Кәрим Тинчурин

Зариф яшь чакта — Телсез күке — Зөлфәт Хәким

2 хезмәтче — Тәкъдир — Педро Кальдерон (Ркаил Зәйдулла тәрҗемәсе)

III кода — Казан сөлгесе — Кәрим Тинчурин

Әкми — Гөлҗамал — Нәкый Исәнбәт

**2.2. Артист Фәтхуллиннар династиясенең театр сәнгатенә керкән өлеше.**

**Фәтхуллин Габдулла Нигъмәтҗан улы.** (1915–1996) **Фәтхуллин Габдулла Нигъмәтҗан улы** Казан шәһәрендә туа.Мәктәпне яхшы гына тәмамлагач,яңа ачылган Татар театр техникумына укырга керә.1939 елда Татар театр техникумын тәмамлагач, Татар академия театрында эшли башлый. Бөек Ватан сугышы башлангач,1941 елны Ватан сугышына китә.Бары 1949 елны гына илне азат итеп Туган якларына әйләнеп кайта.1949–1951 елларда Фәтхуллин — Республика күчмә театрында режиссер булып эшли. 1951 елдан Татар академия театрына артист булып кайта. Ул төрле

үзенчәлектәге кечкенә рольләрне истә калырлык, тормышчан итеп башкару остасы буларак аерылып тора.Үзенең театр сәнгатенә керткән өлеше, онытылмаслык рольләре өчен, 1976 нчы елны **Фәтхуллин Габдулла Нигъмәтҗан улына** ТАССРның халык артисты исеме бирелә. 2015 нче елның 27декабрендә Г.Камал исемендәге Татар дәүләт Академия театрында ТАССРның халык артисты Габдулла Фәтхуллинны искә алу кичәсе булды. Әлеге чара артистның 100 ел тулу уңаеннан үткәрелде.Искә алу кичәсен Татарстанның халык артисты Луара Шакирҗан ачып җибәрде. Кичәдә шулай ук Россиянең һәм Татарстанның халык артистлары Ринат Таҗетдинов, Әзһәр Шакиров һәм Татарстанның халык артисты Хәлим Җәләлов, Габдулла Фәтхуллин хакындагы истәлекләре белән бүлеште

**Аның уйнаган рольләре:** Шәйхулла — «Миңлекамал» (М.Әмир),

Редозубов — «Варварлар» (М.Горький)

Бики — «Хуҗа Насретдин» (Н.Исәнбәт),

Суфый — «Шәмсекамәр» (М.Әблиев),

Клобуков — «Диңгездәгеләр өчен» (Б.Лавренев),

Комиссар — «Көннәр һәм төннәр» (К.Симонов),

Антонио — «Фигароның өйләнүе» (П.Бомарше),

Шаһвәли — «Татар хатыны ниләр күрми» (Г.Ибраһимов),

Салай Салтанович — «Соңгы корбан» (А.Островский),

Вәгыйз — «Назлы кияү» (К.Тинчурин),

Исидор — «Борчылма, әнием» (Н.Думбадзе),

Бом — «Канлы күләгәләр» (Г.Боровик),

Ризван — «Кыю кызлар»,

Әхтәри — «Ташкыннар» (Т.Гыйззәт),

Ишморза би — «Нәркәс» (И.Йомагулов),

Аблай — «Качаклар» («Һижрәт») (Н.Исәнбәт),

Аждар — «Шәһәрдә җәй көннәре» (Анар) һ.б.

Без эзләнүләр барышында укытучым белән театр архивыннан Габдулла Фәтхуллинның спектакль уйнаганда төшерелгән фоторәсемнәрен тупладык.Кайсы спектакльдә нинди роль уйнаганын белдек.( Кушымта) Мәтбугат битләрендә басылып чыккан статьяларда без Фатхулла Габдуллинның үз рольләрен җиренә җиткереп уйнавы, образларын бөтен йөрәгенә салып, йөрәге аша кичереп, рольләрнең эченә кереп уйный дип язылган.1971 нче елның 17 ноябрь санында тәнгыйтьче Гази Кашшафның"Акчарлаклар" тәнкыйть мәкаләсендә дә "Сафа образындагы Габдулла Фәтхуллин спектакльнең жаны булды дисәк тә хаталанмабыз.Үзләренең авыр тормышын уен-көлке белән бизи

белүче,шаян табигатьле,үткен сүзле бу эшче, Фәтхуллинның стихиясе иде”дип яза.Эзләнүләр барышында артистның сәхнә тормышында булган кызыклы вакыйгаларын таптык.

( “Шәһри Казан”газетасы30 сентябрь,2010 нчы ел).Эзләнүләр вакытындаФәтхуллин Габдулла абыйның килене театр артисты Аграфена Васильева белән очраштык.Ул безгә театрның70 еллыгы уңаеннан Фәтхуллин Г.Н. театр директоры һәм баш режиссерның артистны яңа сезон ачылу белән котлавын,эшендә яңа уңышлар, сәламәтлек теләгән котлау хатын бирде. Шулай ук артистның соңгы юлга озатканда әйтелгән сүзләре белән таныштырды.Татарстан мәдәнияте министрлыгы,Татарстан театр әһелләре берлеге, Г.Камал исемендәге Татар дәүләт Академия театры коллективы исеменнән әйтелгән сүзләрдә “Зур талантларга бай Академия театрында Г.Фәтхуллинның үзенә генә хас йөзе бар иде.Татар театры тарихын бизәп торучы дистәләрчә комик рольләр белән бергә,искиткеч тирән кичерешле драматик образлар да иҗат иткән артистыбыз дип искә алалар”.Талантлы артистыбыз,яхшы күңелле,ягымлы кеше Габдулла Нигъмәтҗан улы Фәтхуллин турындагы якты истәлек ул уйнаган образлар йөрәкләребездә һәрвакыт сакланыр.

**Фәтхуллин Фатин Габдулла улы** Фәтхуллин Фатин Габдулла улы 1949 елның 5 июнендә Казан шәһәрендә туа.1973 елда Ленинградта театр институтын тәмамлый (ЛГИТМИК) һәм Татар академия театрына кабул ителә. Бер сезон эшләгәч, Республика күчмә театрына китә.1977 елдан Татар дәүләт драма һәм комедия театрында эшли.Театрда эшләү чорында түбәндәге рольләрне башкарган:

Нәҗип –Т.Миңнуллин “Ак тәүбә,кара тәүбә”;

Фирдүс- Ю.Сафиуллин “ Әллә өйләнергә инде?”;

Дим – Т.Миңнуллин”Кайтмый калсам көтәрсеңме?”

Альфред- Т.Миңнуллин “Кырларым,тугайларым”

Нәгыйм- М.Гафури” Кара йөзләр”,

Дәрвиш, Вәзир – Н.Исәнбәт “ Хуҗа Насретдин”,

Петр- А.Саплынский “Зарыгып көткәнем”,

Хакимзадә- Г.Ахунов”Кошның да үз оясы була”,

Иркен – Исфандияр” Атасының кызы”.

Фатин Фәтхуллин берничә спектакльдә режиссер,режиссер ассистенты булды.Мәсәлән “Богауланган мәхәббәт” спектаклендә режиссер- постановщик була,үзе Питер ролен башкара. Шулай ук Фатин Фатхуллин

2 кинофильм төшергән, шул фильмнарда эпизодик рольләр уйный. **«Солёный пёс**” нәфис фильмы1973 елда кыска метражлы совет фильмы “ Ленфильм” киностудиясендә

куела. Фильмның премьерасы1974 елда чыга. Каты авырудан соң Фатин Фәтхуллин вафат була.

**АграфенаВАСИЛЬЕВА:**

Аграфена Васильева. Театр һәм эстрада артистының паспортта исем-фамилиясе әнә шулай язылган. Әмма халык телендә ул йә Груша, йә Груня дип йөртелә. Белүчеләр аның тагын башка исемнәре дә бар, диләр. Үзе күп исемнәрен кушамат булып тагылып китә дип аңлата һәм моңа һич тә үпкәләми. Аграфена-Груша-Гөрпинә тормышының кайбер сәхифәләренә генә тукталдык. Авылдагы бөтен титуллар белән әйтсәк, Бүре Бәчелие кызы Марҗук белән Җабалак Симонының Унтун кызы Гөрпинә мин. Тугач та шулай атап куйганнар, силсәвиттә исә матур булса да, мондый исемне язмыйча, Аграфена дип теркәп куйганнар. Бәләкәй вакытта, үртәп, Гөрпинә Гөберле Бака дип тә әйтәләр иде. Артистка Аграфена Васильева 1956 елны Түбән Кама районы Келәтле авылында 6 балалы гаиләдә дөньяга килә. 9 сыйныфны тәмамлагач, Казан Театр училищесын тәмамлый.Юллама буенча Күчмә театрда эшли башлый. Соңрак 1981 нче елны М.Сәлимҗанов Г.Камал исемендәге театрга чакыртып ала.Анда1992нче елга кадәр эшли. Түбәндәге рольләрне башкара.

Аниска — «Нашествие» Л.Леонова,

Кыз — «Күктәге йолдызлар кебек» М.Горькому,

Ишморза — «В ночь лунного затмения» М.Карима,

Гөлли — «Зифа» Н.Исәнбәт,

Чарли — «Авыл эте Акбай» Т.Миннуллин,

Сажидә — «Казанское сөлгесе» К.Тинчурин.

**Аграфена Васильева белән интервьюда алынган җаваплар.**

***Артистлык юлын сайлау***

– Мин кечкенәдән бер генә үнәр (һөнәр) турында хыялланмадым шул. Космонавт та, табиб та, укытучы да, сатучы да буласы килде. Уйларымда кемнәр генә булып бетмәдем мин. Шушы ике һөнәрнең берсен сайлаганда булыр идем,әгәр авылыбызга Г.Камал театры артистлары килеп төшмәсә.Ул вакытта Ш.Әсфәндияровның яшь чагы,сәхнәдә ул тудырган образга исем китте.Үземнеңдә сәхнәгә менәсем,бөтен гомеремне театр сәнгатенә багышлыйсым килде.Әзак та үтмәде авыл яшьләре белән “ Өти балак” спектаклен куйдык.Авылдашларымның мактавы җиде кат күкләргә менгерде.Мин үземнең алдагы тормышымны сәхнәдән башка күз алдына да китерми идем инде.Ходай бу бала сәхнәдә бөтен һөнәрләрне үзләштереп карасын дигәндер. Мәктәпне тәмамлап, өйдәгеләргә

артистлыкка укырга барам дигәч, берсе дә ризалык бирмәде. Шуннан соң хәйләләргә туры килде. Авылдан йә педагогика, йә медицина юлын сайлыйм дип чыгып киттем. Документларны исә туп-туры театр училищесына илтеп бирдем. Кайткач, серне чишәргә туры килде. Укып кара соң, тора-бара фикерләрең үзгәрер, диделәр. Шулай итеп хыял тормышка ашты. Укып бетергәч тә юллама буенча Күчмә театрда эшли башладым.

### *Гашыйклык чоры*

– Театрга килүгә башлар әйләнде. Фатин Фәтхуллинга гашыйк булып чат ябыштым инде менә. Юкса һай кыз бала, нигә ул өйләнгән, бала атасына күз саласың, дип үгетләүчеләр дә шактый иде. Күңелемә хуш килде, нишләтәсең бит инде. Җаны теләгән җылан ите ашаган, шулай итеп бергә яшәп киттек. Фатинның хатыны Ленинградта калган. Күпме генә чакырса да, провинциаль шәһәргә кайтасы килмәгән. Ә безнең тормыш көйләнеп китте. Улыбыз Диас туды. Ни өчен Диас дип куштык дисеңме? Чөнки Г. Камал театры артисты Зөлфирә Зарипованың да малае Диас исемле иде. Ул, үзе театрга киткәндә, бала белән утырып тор әле дип, үтенә иде. Минем кебек студент өчен артист баласын карау – дәрәҗә, риза булам. Ә Диас – көйсезрәк бала, елак. Әтисе Сәет Раенбәков, чыгып киткәндә, имиеңне каптыр, шуннан тынычлана ул дия торган иде. Мин аңа ышанып, буш ими каптырам, бала чыннан да тынычлана. Менә шулай җанга якын булып кереп калды ул. Балам тугач та телгә килгән беренче исем Диас булды.

### *Сәхнә артындагы кырыс тормыш*

– Камал театрына чакырып алдылар. Бала тапкач суырылып, зифаланып калган идем. Хастаханәдән чыкканда авырлыгым 38 килога калган. Чөнки бәби тапкач та бер-бер артлы 4 операция кичерергә туры килде. Мин тернәкләнгәнче баланы каенанам, рәхмәт яусын инде аңа, карады. 42 килоны җыйгач, Марсель Сәлимҗанов шәйләп алды. Дебют эшем «Казан сөлгесе»ндә апа роле булды. Алсу Гайнуллина – сеңел, мин Саҗидә ролен уйнадым. “Кәкре аяклы, бот арасыннан биш фәрештә үтеп чыга алган апа” – бик кызыклы роль иде. Шуннан бүтән характерлы рольләр дә булды. Ләкин күбесенчә малайларны, кызларны уйнадым. Аннан килеп, Камал сәхнәсендә мин уйнамаган хайван калмады. Эт тә, тәкә дә булдым, башка киек җанвар да. Сәхнә – могҗизалы җир, әмма театрның эчке дөньясы бик кырыс. Анда бөтен мөмкинлекләреңнән файдаланып иҗат итәр өчен административ составның да сиңа карата җылы мөнәсәбәттә булуы кирәк. Хәзерге акылым булса, мин катгый сүзләр әйтмәгән дә булыр идем. Кыскасы, театрдан үзем теләп китмәдем. Киткәндә фатирны калдыру мәсьәләсе дә күтәрелде. Бала белән урамда калмавым Әсхәт Хисмәтнең яклап чыгуы аркасында гына булды. Ярый әле миһербанлы кешеләр бар димен. Үзем дә

катгый булмаска, кеше ниндидер авыр сүз әйтә, ниндидер читен хәлдә кала икән, аның сәбәбе булган дип уйлый башладым. Мине сөймәгән кешеләр тормыш укытучыларым булдылар. Аларга рәхмәттән башка сүзем юк.

### *Тормыш сынавы*

Хезмәт биржасына бастым. Аннан да рәт чыкмады. Ә баланы үстерергә кирәк. Чыгам да чүп савытыннан шешә җыям. Аны илтеп тапшыргач, ипи, сөт алып кайтам. Авылдан бәрәңгесе, ите килә. Менә шулай яшәп ятыш. Ярый әле егылып ятканда кул сузучылар, кыйнап киткәндә яраны төзәтүчеләр булды. Яшермим, мин – йомшак холыклы кеше.. Шөкер, вакытында туктап кала алдым. Ирем кино-видео режиссерлыкка укырга китте. Соңыннан аның белән ике фильм әзерләдек. Аның берсе И. Сәлаховның “Ана тавышы” әсәре буенча кыска метражлы фильм, икенчесе курчак театры әкияте булды. Тормыш тагын көйләнде кебек. Ләкин тагын бер бәла килеп чыкты. Ирем авырый башлады. Шул вакытта Вилдамир Баһау шалтыратып, сәхнәгә чыгасың киләме дип сорый. Каян килгәндер миңа андый тавыш, андый көч: “Килә!”,– дип кычкырдым моңа. Трубканың теге башында азрак тынлык торганнан соң, ник кычкырасың шул кадәр, диләр. Аның белән, эшсез калган бөтен артистны җыеп, авылларга чыгып киттек. Татарстанны аркылыга-буйга гиздек.

### *Эстрада дөньясы*

Бу төркем белән мин эстрадага кереп киттем. Мәсгут Имашев белән дә шактый гына эшләдек, башка артистлар да алып баручы сыйфатында чакырып торалар. Берзаман туй алып барырга чакырдылар. Бөтен шартын китереп алып бардым да “сарафан радиосы” буенча минем тамадалык осталыгым турында сүз таралды. Хәзер бер аягым эстрада сәхнәсендә булса, икенчесе – туйларда. Тамадалык эше бик кызыклы. Тик менә яшьләрнең ата-бабадан килгән йолаларны онытып, европача мәҗлес оештырулары пошаманга сала. Безнең бит шулкадәр бай рухи мирасыбыз югалып бара. Кара-каршы җыр әйтешләр, теләк теләшләр, ике кодагыйның кара-каршы җырлаулары, бирнә малы әзерләү, аны күрсәтү йолалары юкка чыккан инде. Эшләп күрсәтсәң, шаккаталар. Шушы җәүһәрләр югалмасын дип, материал туплый башладым. Берзаман бер калын китаплык булды бу. Китап чыгару артыннан йөри башлаган идем, заманадан артта калуым сәбәпле, хәзер китап чыгаруның машина алу белән бер икәнен белми калганмын. Шулай итеп бу эш әлегә читтә калып торды. Әмма әзер проектлар тынгы бирми, аларны дөньяга чыгарасы килә. Шулай итеп керәшен җәмгыятенә тәкъдимнәремне ирештерә башладым. Сәхнәгә керәшен бәйрәмнәре

менде. Казанда Питрау бәйрәмен уздыруны Керәшен җәмгыяте рәисе Мария Семенова белән бергәләп без башлап җибәрдек. “Бәрмәнчек” ансамбленең башында да торырга туры килде. Геннадий Максимов – директоры, фольклор ягыннан ярдәм итүче – Лена Бичарина, Галина Казанцева, мин постановкалар өчен җаваплы белгеч булдым. Бу да үзенә күрә бер тәҗрибә туплау иде.

Аграфена Васильева-күпкырлы талантка ия шәхес.Ул Кәрим Тинчурин һәм Г.Камал театры сәхнәләрендә шактый кызыклы образлар тудырган артист. Ибраһим Сәләхов әсәре буенча куелган “ Ана тавышы”нәфис фильмында, “ Җен кызы”әкият-фильмында директор,күп сериалы “ Кияү” телефильмында режиссер ярдәмчесе, берничә ел “Саумысез, карендәшләр”тапшыруын эшләүче, алып баручы була.Концерт группаларында конферансье, юмор кичәләрендә чыгышлар ясый. Театр сәхнәсеннән китергә туры килсәдә, Аграфена Васильевнаның сәхнәдән төшкәне юк.

IV. **Йомгаклау өлеше**

**Нәтиҗә:**

**1.** Халыкның талантын, рухи дөньясын, дәрәҗәсен билгели торган театр сәнгате – милләтебезнең казанышы һәм чиксез горурлыгы.Быел Татар театрына 110 ел.Театр тарихын өйрәнеп,без театрның беренче юбилей датасы бары 20 ел үткәч кенә билгеләнеп үтелүен белдек.Татар театрының беренче 20 еллыгы чын мәгънәсендә 20 еллык көрәш бәйрәме була һәм без бу бәйрәм -20 еллык юбилейның үтү тантанасын Г. Камал театры архивындагы материаллар аша өйрәндек.

**2.** Түбән Кама җирлегендә яшәп ,театрга фидакарь хезмәт итүче артистларны барлап,артист Олег Фазылҗанов Г.Камал исемендәге Академия театры белән бәйле икәнен, хәзерге вакытта әлеге театрда хезмәт итүен белдек. Ә якташыбыз Түбән Кама районы Келәтле авылында туып үскән Аграфена Васильева театр техникумын тәмамлап, Академия театрында күп еллар театр үсешенә үзенең көчен куйганын эзләнүләр нәтиҗәсендә билгеләдек.

**3.** Аграфена Васильева иҗатын һәм тормыш юлын күзәтеп, театраль династиягә килеп тоташтык һәм әлеге Фәтхуллинар династиясенең театр сәнгатенә керткән өлешләрен билгеләдек. Фәтхуллин Габдулла Нигъмәтҗан улының ,аның улы Фатин Фатхуллинның һәм килене Аграфена Васильеваның Г.Камал исемендәге Академия театры сәхнәсендәуйнаган онытылмаслык рольләрен өйрәндек. Бу шәхесләрнең театр сәнгатенә керткән өлешен билгели алдык.

Җир йөзендә ничә төрле халык яшәсә, мөгаен, шулкадәр үк төрле күңел ачу чарасы бардыр. Әйтик, Бразилиядә – карнаваллар, Испания, Португалия илләрендә коррида милли күңел ачу чарасы дип саналса, безнең татар күңеленә җырлы-биюле тамашалар якын.

Шуңа күрә театрның милли тамаша булып әверелүе безне һич тә гаҗәпләндерми. Чөнки ул халыкның үзеннән – аулак өйләрдән, кичке уеннардан, Сабан туйларыннан үсеп чыккан. “Театр халыкныкы, бары тик халыкныкы гына. Әгәр тамашачы үз театрыбыз бар дип белә һәм анда барырга атлыгып тора икән, бу — зур бәхет. Әгәр театр халыкка кирәкми икән, бу — зур фаҗига. Театр үз милләтенә кирәк булырга тиеш. Ул үз халкының культурасын күтәрергә, аның гореф-гадәтләрен, телен сакларга бурычлы.” Танылган режиссер Марсель Сәлимҗанов әнә шулай әйтә килде. Театр бүген дә кеше рухының, кеше җанының пакьлеге өчен көрәшне дәвам итә, һәм ул көрәш һәр заман өчен актуаль.1926 елда аңа “Татар дәүләт академия театры”, 1939 елда Г.Камал исеме бирелә. Беренче профессиональ труппаның варисы саналган Г.Камалның исемен йөрткән Татар дәүләт академия театры үзен татар театрының гасыр буена ныгыган үзәге дип таныта.Узган гасыр башында күңелләрдә “Сәйяр” труппасы кабызган рухи учакның очкыннары халкыбыз яшәгән төрле төбәкләрдә үрләп китә һәм, нәтиҗәдә, яңа коллективлар оеша. Шуңа күрә татар театры шәҗәрә агачының кәүсәсен “Сәйяр” тәшкил итә. Ябалдашлары тармакланып киткән алмагачтай, бер-бер артлы Әстерхан, Сембер, Троицк, Урал, Уфа, Туймазы, Самара, Оренбург, Чиләбе, Акмулла, Петропавловск, Мәскәү, Ленинград, Баку, Алма-Ата, Төркестандагы Бохара, Хорезм өлкәсендәге Хива, Ташкент калаларында татар, Симферопольда кырымтатар, Кытайның Голҗа шәһәрендә башта уйгур, аннары татар театрлары үсеп чыга. Стәрлетамакта башкорт, Ташкентта үзбәк-татар (хәзер исә — үзбәк), Ашхабадта төркмән труппасы һәм театрлары оешуга да татар сәхнәсе сәбәпче була. Болардан тыш, Татарстанның үзендә дә татар театрлары ачыла: Буа, Мамадыш, Әлмәт, Чаллы, Түбән Камада; Казанда исә Татар дәүләт академия театрының колхоз-совхоз филиалы (хәзерге К.Тинчурин театры), Татар дәүләт театры каршындагы балалар труппасы (хәзерге Яшь тамашачы театры). Ләкин, ни кызганыч, шул татар театрларының бүген нибары 11е генә исән калган. Театр труппалары таралуның сәбәпләре төрле: эзәрлекләүләр, сугышлар, репрессияләр, дәүләт сәясәте, башка халыклар арасында ассимиляцияләнү нәтиҗәсендә тамашачысын югалту һ.б.

Театр – милләт язмышының һич тутыкмас көзгесе ул. Бик күп еллар дәвамында татар милләтенең рухын, милли үзенчәлеген, телен, әхлагын саклап һәм үстереп, безне бербөтен халык итеп тотучы татар театры һичшиксез, олы ихтирамга, чиксез мәхәббәткә лаек. Безнең халык китаплы һәм театрлы халык бит ул. Һәр кешенең җанында театрга карата булган мәхәббәт яши. Шуңа күрә халкыбызның йөзе булып яшәп килгән театрыбыз киләчәктә дә чәчәк атар, дип өметләнеп калабыз. Шәһәребезнең театр артистларына бик зур рәхмәтебезне белдереп, аларны яратып, хөрмәт итеп кабул итүче тамашачы, иҗади уңышлар телибез....

**V. Файдаланган әдәбият**

1.Абдуллин Ф.А. Туган як әдәбияты. Түбән Кама, 2006.

2. Хәбибуллина Х.И. Могҗизалар тудыручылар. Түбән Кама, 2007.

3. Гимадиева Ф.Ә. Сүнмәс алар хәтәр җилләрдә. Казан, 2003.

4.Хөснияр З. Театр зарланганны яратмый. Казан: Сәхнә.-2005-№2

5.Галиев Р. Үз театрыбыз бар.Түбән Кама: Хезмәттәш авазы.- 2005- №3.

6.Кадырова А.М. Театрга Булатлар кирәк. Казан: Ватаным Татарстан.-2005-№3

7.Галимуллин Ф.И. Төп эш – иҗади мөхитна җанландыру. Казан: Татарстан .- 2008-№11.

8. Гыйльманов Г.Г. Сәхнә - каһарманнар мәйданы. Казан: Мәгърифәт.- 2009-№12.

9. Илялова И.М. Театр. Казан:Сәхнә.-2005-№3

10. Хәбибуллина Л.Н. Сәнгать дөньясында. Казан:Шәһри казан.- 2010-№11

11. Даутова Д.В. Г.Камал истәлекләре. Казан: Сөембикә.-2011-№1

12.Татар театры.1906-1926ел.Казан” Мәгариф”нәшриты,2003.

13.Марсель Сәлимҗанов альбомы. Казан” Мәгариф”нәшриты,2004.

14.Г.Камал театры артистлары . Казан китап нәшрияты ,2005

*Газетдиов Раяз, 4 нче сыйныф, Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районының «35нче лицей» муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесе*
*Фәнни җитәкчеләре: Садыкова Сиринә Илсур кызы, татар теле укытучысы,*
*Газизова Фәйрүзә Габделахат кызы, башлангыч сыйныф укытучысы*

**Муса абыйга**

-Муса абый,ничек хәлләрегез?-диеп
Сезгә дәшәсем килә.
Сезнең кебек минем дә
Шигырь язасым килә.

Шигырьләрне ничек итеп
Матур итеп язасыз?
Авыр чакларыгызда да,
Сез бит жаен тапкансыз.

Инде менә хәзер без дә,

Шигырьләрегезне укыйбыз

Укыган саен укыйсы килә

Укып хич тә туймыйбыз.

Рәхмәт Сезгә,Муса абый Батырлыгыгыз өчен.

Тойсын иде һәрбер кеше

Сезнең йөрәкнең көчен.


*Галактионова Регина, 8 нче сыйныф,*
*Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районының "Аерым фәннәрне тирәнтен өйрәнүче 16нчы урта гомуми белем бирү мәктәбе" муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесе*
*Җитәкчеләре: Фәрхетдинова Фәнирә Гарәф кызы, татар теле һәм әдәбияты укытучысы,*
*Сәлимова Гүзәлия Рәшит кызы ,*
*татар теле һәм әдәбияты укытучысы*


## Исеме җырларда җырлана

### Кереш

Туган җир, туган як, туган авыл... Һәркем өчен изге, газиз, кадерле ул. Безнең һәрберебезнең газиз туган йорты, туган авылы бар.

Кеше үз туган җирендә беренче адымнарын ясый, әйләнә-тирә дөньяны танып белергә өйрәнә, туган җире аны гүзәл табигате белән иркәли. Туган җирендә кеше укып, белем ала,хезмәткә өйрәнә. Туган авылның бормаланып аккан көмеш сулы елгалары, дулкын кебек тирбәлеп утыручы иген басулары, киң болыннары урманнары җанга якын,үзенә тартып тора.

Һәр кеше үзенең туган авылын аерым бер хис белән үзенчә ярата. Кайда гына торса да, кеше үзенең туган ягын сагынып яши.

Авылда туып-үсеп, читтә яшәгән кеше һәрвакыт туган җирен искә төшерә. Кушучлап тәмле суын эчкән,балачактан ук күңеленә моңлы җыры белән кереп урнашкан таныш чишмәсен күз алдына китерә.Аны туган җиренә челтерәп аккан шул чишмәләр тарта.

Миңа да туган ягым бик кадерле. Каникуллар җитү белән мин туган авылма ашыгам. Анда мине сагынып көтеп яшәүче әбием, бабам, туганнарым, дусларым бар.

Һәр авылның, һәр төбәкнең атамасының килеп чыгышы хакында төрле риваятьләр бар. Безнең авылны ни өчен Каенлы дип атадылар икән соң?

Туган авылымны ярату хисе,мине туган ягымның тарихын өйрәнүгә этәрде.

**Актуальлеге**: Бу эшем укучылар, укытучылар, авыл халкы өчен Каенлы авылы тарихын өйрәнүгә зур булышлык, этәргеч булачак. Укучыларга туган якка багышланган иншалар язганда ярдәмлек чыганагы булыр.

**Максат:** Туган авылның үткәне, хәзергесе, тарихы белән танышу; табигатьне, туган авылны ярату хисе,аның матурлыгын тоя Һәм саклый белү омтылышы тәрбияләү.

**Бурычлар:** Туган якның табигатен күзәтү, шәхесләрен барлау, авылның үткән тарихын тирәнтенрәк өйрәнү.

**Тикшерү методы:** кирәкле материаллар туплау, укытучылар, өлкән кешеләр, җитәкчеләр белән әңгәмә.

Тономика: кешеләр күчеп килгәнче монда куе урманнар булган.

## 1 нче бүлек. Каенлы каеннары

### 1.1 Авыл исеме каян алынган?

Исеме җырларга әйләнгән, борма-борма юллар ясап тыныч кына агып ятучы Зәй елгасының бер куенына урнашкан, урманнарының тигезлеге, йортларның төзеклеге, халкының тырышлыгы белән сокландыра торган бер авыл бар. Каенлы авылы ул!

Бигрәк матур исемең лә

Туган авылым Каенлы.

Каенлы гына түгел ул,

Таш мәчетле һәм айлы.

Кара еллар, кара төннәр

Җиңә алмаган аемны.

Горур атлый киләчәккә

Авылкаем Каенлы, -дип

яза авыл шагыйрәсе Саимә апа Сөләйманова.

... Түбән Кама районындагы Каенлы дип йөртелгән авылның Бөек Октябрь социалистик революциясенә кадәр ике исеме була: Җирекле (яки Татар Җиреклесе) һәм Каенлы. Бу авылдан ике километр гына ераклыкта икенче бер авыл да шул ук Җирекле исеме белән аталганлыктан, авылларның исемнәре алдында сыйфат куеп, берсен- хәзерге Каенлыны – Татар Җиреклесе дип, ә икенчесе Керәшен Җиреклесе дип атап йөрткәннәр.

Авылның Җирекле дип аталуының чынбарлыкка туры килә торган сәбәбе бар. Кешеләр әле монда күчеп утырганга кадәр, бу тирәләр тоташ катнаш урманнан торган. Катнаш булса да, урманның күпчелеген каен агачы хасил иткән. Биредә сазлык һәм күлләр дә күп булган. Алар тирәсендә зирек агачлары үскән. Шуңа күрә, авылга Зирекле исеме бирелгән. Руслар авылны Каенлы дип йөрткәннәр һәм читтән килгән хатларның адресларында, югары органнардан килә торган эш кәгазьләрендә дә элек – электән үк Зирекле дип түгел, Каенлы дип язылa торган булган. Авылның Каенлы дип исемләнүе дә табигый, чөнки, монда каеннар күп үскән.

Бу урынга килеп утырган беренче кешеләр арасында авылга нинди исем бирү турында бәхәс чыккан булырга кирәк, аларның берәүләре "Зирекле" дип, ә икенчеләре "Каенлы" дип тәкъдим иткән.

Элек Зирекле, Каенлы, ә хәзер бары тик Каенлы гына дип йөртелгән бу авыл кайдан һәм кайчан барлыкка килгән соң?

Хәзерге көндә Каенлы авылы Татарстан Республикасына керсә дә, Бөек Октябрь социалистик революциясенә кадәр ул административ бүленеш буенча Уфа губернасына кергән. Уфа губернасы, Минзәлә өязе, Сухрау волосте, Каенлы авылы- авылының тулы һәм төгәл адресы шундый булган.

### 1.2 Беренче күчеп килүчеләр.

Каенлы кешеләре Мамадыш районының Кече авылыннан күчеп килгән. Каенлы – Зиреклегә беренче булып төпләнүчеләр Сәмикол, Рәхимкол, Миңлебай, Бикбау, Сиражетдиннәр белән бергә, бер чирмеш тә (мари) була. Соңрак күчүчеләр арасында да була алар. Чирмешләрне өлҗәдән килделәр, дип сөйләгәннәр. Беренче булып урнашкан чирмешнең җиде кызы булган. Авыл зираты ике өлешкә бүленгән була, аның авыл ягына (Зәй елгасына) караган өлешенә – татарлар, ә көньяк – көнбатышка караган өлешенә чирмешләр күмелгән. Хәзерге вакытта бу милләт кешеләрен чирмешләр, дип түгел, ә марилар, дип кенә йөртәләр. Бер үк авылда татарлар да, марилар да тату яшәгәннәр. Бу инде ике милләт кешесенең ныклап аралашуына, гаилә коруга кадәр китереп җиткергән. Тора – бара чирмешләр ислам динен кабул итәләр, тик аңа кадәр чирмеш буларак ничә буын яшәгәнлеге генә билгесез.

Авылга башта берничә генә хуҗалык килеп урнашкан булса, килүчеләр саны арта бара. Чирмеш нәселеннән булган Зөбәер улы Гыймади бай бик усал, кире беткән сәүдәгәр була. Ул сәүдә белән ерак – ерак авылларга, чит өязләргә чыккан. Берничә айлар йөреп кайткан. Берсендә ул гаҗәеп бер әйбер – ялтырап торган җиз самавыр алып кайта. Бу самавырны күрү өчен авылның аягында йөри алучы һәр кеше килгән. Авылдашлары кунак

килгәндә, туйлар уздырганда бу самавырны сорап ала торган булалар. Самавыр бар, ләкин чәйнеге юк. Беркадәр вакыттан соң Гыймади бай чәйнек тә алып кайта.

Авылга беренче тимер сабанны Юлдаш нәселеннән килүче Исхак улы Хәмидулла 1894 елда Зәйдән 26 сум 15 тиенгә алып кайткан. Сабан “Зингер” маркалы була. Ләкин ул вакытта сабаннар ике ат тартышлы, ике калаклы итеп эшләнгән була. XX нче гасырга чыккач, бу тирәдә Ширәмәт тимерчеләре бертуган Смышляевлар бер ат тартышлы берле сабаннар эшләүне үзләштерәләр һәм, бу як крестьяннары махсус заказ биреп,алардан берле сабаннар эшләтеп ала башлыйлар. Соңга таба мондый сабаннарны заводларда җитештерәләр.

## 2 нче бүлек. Җир бүлү

### 2.1 Ревизия.

1850 елда, халык теле белән әйткәндә, рәбиз була, ягъни ревизия – ир җенесеннән булганнарның санын алу үткәрелә. Җир бары тик ирләргә генә бирелгәнлектән, халык санын алу да ирләр белән чикләнгән. Ревизия күрсәткәнчә, Каенлыда ирләр саны 242 була. Шул елда булган барлык чәчүлек җирләрен һәм болыннарны 242 гә тигезләп бүлгәннәр. Шуннан соң озак еллар буена җир бүленми торган. Ул 12 елга бер мәртәбә бүленергә тиеш. Үлгән ирләрне сызып, 12 ел эчендә туган ир балаларны кертеп, җирне бүлик, диючеләргә каршы үзләрен “рибизни”, дип йөртүче халык, җир хуҗалары, ирләр: “Без имананы түләп бетердек, бүлмибез- дип приговорга тамга салмыйлар һәм шунлыктан озак еллар буе җир бүленми торган.Җир өләшенгәннән соң, кешеләрнең аерылып чыккан улларына кырдан йорт салу өчен җир мәйданы бирү булмаган. Чөнки басу капкасын чыгуга ук җир инде кемгә дә булса бирелгән, ул берәүнең билгеле бер вакытка кадәр шәхси милеккә әверелгән. Шуңа күрә аерылып чыгучы кеше йорт урыны бөтен булган башка берәү белән сөйләшеп,аның ярты пуҗымына гына урнаша ала. Шуның аркасында күпләрнең йорт урыннары бик тар.

### 2.2 Янгыннар.

Каенлы авылында еш кына янгыннар була. 1898 елда бик көчле янгын чыга, бик күп йорт һәм каралты-кураны юкка чыгара. 1910 елда Аксак Ульданнан янгын чыгып, ярты авыл янып беткән. Саксызлык аркасында да вак янгыннар булгалап торган. 1931 елда – 9 йорт, 1963 елда – 2 йорт янган. Авылны төзегән вакытта 5-6 йорт саен тыкрыклар калдыру гадәткә кергән. Бу, һичшиксез, янгыннан саклану чарасы буларак эшләнгән. Безнең авыл да шулай кварталларга бүленеп салынган. Бу тыкрыклар йорт салу өчен бирелмәгән.

## 3 нче бүлек. Ачы еллар

### 3.1. 1914 нче ел.

Озак та үтмәгән, ачлык елы килгән. 1914 елдан башлап, җиде ел буена сузылган империалистик һәм гражданнар сугышы вакытында авыл хуҗалыгын алып барырдай ирләр булмаганлыктан, күп җирләр чәчелмичә калган. Продразверстка чоры булганга, крестьянда запас икмәк булмаган. Ә бу елда Россиянең ундүрт губернасында корылык хөкем сөргән. Кешеләр яздан ук ачыга башлаган. Чәчкән икмәк кашык буе үскән дә көйгән. Бәрәңге булмаган. Сыерлары булган кешеләр беркадәр тернәкләнә алсалар да, күпчелек ачлыктан интеккән. Кайберәүләр читкә, Себер ягына, Урта Азиягә, Кавказга чыгып, китеп, үзләрен саклап кала алган. Авыл халкы эт- мәчегә кадәр ашаса да, күпләп кырылган.

1914 елның ташуы шулкадәр көчле булган, хәтта картлар да мондый галәмәтне хәтерләмәгән. Ул елны 9 йорт агып киткән. Шунысы гаҗәп, йортлар таралмаган. Өй түбәләрендә әтәчләр кычкырып барган. Бу хәл авылның төзелешен бик нык үзгәрткән. Авыл инешнең төньяк - көнбатыш өлешенә утырган кадәргесе төп өлеш булган, ә инешнең икенче ягында 58 хуҗалыклы өлеше булган. Ташу нәкъ менә шул якка зыян салган. Халык мондый казаның яңадан кабатлануыннан куркып, икенче урынга күчкән.

Ташу вакытында йортлары акмаган гаиләләр дә су кермәгән кешеләргә вакытлыча күченеп торганнар. Ул чакта кирпечне кулдан сукканнар, шунлыктан, мичләрнең кирпечләре җебеп беткән.

Алда әйтелгән 58 хуҗалыкның 25е үз нигезләрендә калып, елгага каршы яклап утырганнар.Ә 33 хуҗалыкка күчү өчен урын кирәк.Озак еллар буена бүленми килгән җирне өләшүдән башка чара калмый. Шулай итеп, 1914 елда үлгәннәрне исәптән чыгарып, яңа туганнар өстәлеп җир бүленә.

1939-1940 еллар. Фин сугышы бара.Элек Шәнгәлче волостена караган авылларның яшьләре Каенлыга җыелган. Алар үзләре квартирларга урнаштырылган, ә көндезләрен клубта җыелалар, солдат уенын тышта күрсәтсәләр дә, теоретик белем клуб эчендә үткәрелгән. Ә клуб салкын.

Шул вакытта Каенлы халкы берничә йөз еллар буе үсеп утырган өянкесеннән колак кага. Бу өянкенең кайчан, кем тарафыннан утыртылуын 1840 елда туган кешеләр дә белмәгән. Бәлки, авылга беренче килеп, җир төпләүчеләр ук сокланып, аны кисми калдыргандыр. Уенга өйрәнергә килгән яшьләр аны турап, утын итеп әзерлиләр, клубны җылыталар.

1941 елның 22 июнендә Бөек Ватан сугышы башланып китә. Колхозда төп эшче көч булып хатын-кызлар, яшүсмерләр, балалар, картлар кала.

Каенлы авылыннан Советлар Союзы Герое исеме алган кеше булмаса да, Бөек Ватан сугышында зур батырлыклар күрсәтеп, Ватаныбызның зур бүләкләренә лаек булучылар байтак.

Безнең буын Яңа авылны тудырырга тиеш. Хәзер иң мөһим, иң катлаулы һәм иң авыр эш авылда. Авылның язмышын яңартырга кирәк. Төп бурыч хәзер шул!

## 4. Каенлы халкы шөгыле

Бу тирәне каплап алган кара урманнар юкка чыга, алар урынына чәчү җирләре барлыкка килә.

Халык ярлы яшәгән, шулай да Каенлыда җан башына тия торган җир мәйданы башка авылларга караганда күбрәк була. Бу хәл авылда һөнәрчелекнең җәелүенә тоткарлык ясаган. Күпме авыллар Каенлыларны "көртлек", дип йөрткәннәр. Көртлек- ялкаулык символы. Чөнки тегүчеләр, итек басучылар, бүрек тегүчеләр, ювелирлар, калайчылар, чиләк төпләүчеләр, самавыр төзәтүчеләр, пычкы тешәүчеләр, тәрәзә пыяласы куючылар - барысы да Мамадыш, Саба якларыннан килеп, кемгә булса да фатирга кереп, атналар буе халыкка хезмәт күрсәткәннәр. Әнә шулай яши Каенлы халкы. Иген игә, мал асрый.

Әле урманнар төпләнеп беткәнче, халык аучылык белән дә, Зәй елгасыннан балык тоту белән дә шөгыльләнгән. XX гасырга, кергәч, балыкчылык белән, чынлап торып, ягъни профессиональ рәвештә шөгыльләнүче бер генә кеше- Мөхәммәтша Бикбов кына калган. Бу абыйның бөтен авылга бердәнбер саналган көймәсе, сөкә, морда кебек балык тоту кирәк-яраклары булган.

Әйе, кызыклы, мәртәбәле шәхесләргә бай Каенлы төбәге! Әлеге җирлектә туып-үскән Һәм хәзер Түбән Камада "Россиянең иң яхшы предприятиесе"исемен йөртүче шәһәр электр транспорты берләшмәсе директоры - "Ел җитәкчесе" Рафаил Хәбибуллин, "Нижнекамскшина"җәмгыятенең генераль директоры урынбасары Рәшит Маликов, Чаллыда-"КамАЗ" берләшмәсенең двигательләр заводында профсоюзлар комитетын җитәкләүче Дамир Ахунов, "Нижнекамскнефтехим" җәмгыятендә цех начальнигы булып эшләүче Равил Хәйруллин, 42 елын балаларга туган телне өйрәтүгә багышлаган, авыл шагыйрәсе Саимә Сабир кызы Сөләйманова.

### 4.1 Сугыш ачысы

Ул каһәр суккан сугыш елларын онытырга мөмкинме соң? Әле генә дөньяга аваз салганнарның да, инде тәпи атлап киткәннәрнең дә, урамнарда уйнап йөрүче бала-чагаларның да, сөякләре дә ныгып җитмәгән килеш колхозның авыр эшләренә җигелгән яшүсмерләрнең дә, буй җиткән кызларның да, килен булып килгән, әмма ана булу бәхетенә ирешә алмаганнарның да, ир белән яшәү бәхетен татып та бетермәгән хатыннарның да, балаларын кочаклап тол калганнарның да иң ачы күз яшьләре аккан еллар бу! 1941-1945 еллар! Күпме балалар әтиләрен соңгы тапкыр күреп калгандыр. Әтиләрен бөтенләй күрми калган сабыйлар... Боларны тарихтан сызып ташлау мөмкинме соң?

Гадәттәгечә җәйге аяз, бик матур бер көн . Кояшның гаме юк, кыздыра да кыздыра, ара-тирә болытлар арасына да кереп яшеренә. Авыл халкы җәйге эш- мәшәкатьләре белән яши. Тик бу матурлык, тынычлыкка бер мизгелдә нокта куела. Сугыш! Илне дә, авылларны да кара сөрем томалый. Халык көндә нинди хәбәр булыр икән дип, Левитан тавышын тыңлый....Үлем, кырылыш, авыллар, шәһәрләр юк ителә. Елап калды авыллар да, балалар да, игеннәр дә... Бишектәге сабыйлар бу сүзне аңламады, әтиләренең аларны ни өчен болай каты кысып сөюләрен дә абайламыйлар. Сугышның ни икәнен аңлап бетермәсәләр дә, бала-чагалар әниләре күзләреннән агып төшкән яшьләрне күреп, сагая калалар. Икенче көнне үк сугышка чакырып повесткалар килә башлый. Башта фронтка яшьрәкләрне алалар. Аларның күбесе 1941-1942 елларда билгесез югала да. һәр көнне диярлек сугышка чыгып киттә Каенлы авылының ир-егетләре. Авыл халкы әрнеп, елашып, яулыкларын болгап, басу капкасына кадәр озата баралар. Күпме Каенлы авылының баһадир ирләрен сугышка озатып калды икән авыл капкасы? Ул капка хәзер юк инде. Аның аша автобус тукталышына илтә торган юл үтә. Солдатлардан өч почмаклы хатлар килә башлый. Беркем берни яшерми, күбесе бергәләп укыла. Хатларның эчтәлеге дә бертөрлерәк: башта озын-озын сагынычлы сәламнәр, өй, балалар хәлен сораштыру, аннары «Көтегез, исән булсак, бер кайтырбыз, кайта алмасак, бәхил булыгыз» кебегрәк җөмләләр. Күбесендә бер-ике җыр да язылган була. Сыгылып елый хатыннар. «Госпитальдә ятам», - дип язылган хатлар килсә, шатланалар, чөнки монысы инде исән калган дигән сүз. Авыл советы каршындагы баганага табак формасындагы радио эленгән. Левитан соңгы хәбәрне җиткереп тора. Тик сөенечле хәбәрләр генә бер дә ишетелми. Дошманнар әле бер, әле икенче шәһәрне алып торалар. Авылда хәлләр мөшкелләнгәннән мөшкелләнә бара: маллар ачыга, балалар ач, ягарга утыны юк. Ярый әле ул елларны Ташлык әрәмәсе була. Чаналар тартып, Зәй бозы өстеннән чыгалар да, юанрак әрәмә эзләп, балта белән чабып эшкәртәләр. Ботак, чыбык-чабыгын кисеп ташлыйлар югыйсә кул чанасына төяү читенләшә! Әрәмә урларга халык күбрәк төнлә йөри - ул чакта каравылчылар кайтып киткән була. Әгәр алар эләктерсәләр, балтаңны алып калалар, бауларыңны чабып ташлыйлар.

Мәктәптә дә укулар хөртиләнә: укырга китап, язарга дәфтәр, язу каралары юк. Дәфтәр урынына иске китапларның буш битләренә язалар. Китапларны инде я берничә партага берне генә бирәләр, я бөтенләй юк. Кара ясау ысулын да табалар: казан астына утырган корымны кырып алалар да сөт белән кайнаталар. Ясаган караларны бәләкәйрәк шешәләрдә йөртәләр. Укытучылар һәр көнне сугыш хәлләрен аңлатып торалар. Кайчакта класс тәрәзә пәрдәләрен, кич белән өй тәрәзәләрен капларга кушалар, немец самолетлары күрмәсен, янәсе. Шундый куркыныч булып китә: менә-менә фашист самолеты очып килер дә бомбасын ташлар кебек тоела.

Шундый авыр чакларда авыр шартларда укысалар да, укытучылар бик таләпчән була. Яз көне унар фәннән имтихан алалар.

Күп гаиләләргә инде кара кәгазьләр килә. Каты яраланып кайтучыларда була. Болары инде «бәхетле кешеләр», алар исән калуларына сөенәләр. Бакчаларны эшкәртү тагын да кыенлаша. Көрәк белән казып чыгу озак та, авыр да. Аның да җаен таба халык. Чиратка куелган бер япьле сөрәнгә үзләре җигелеп сукалыйлар. Аларга балалар да булыша. Орлыгы җитсә, бәрәңге утырту бер ни түгел икән ул. Кайчакта заемын вакытында түли алмаган кешеләрнең утыртырга дигән бәрәңгесен дә алып чыгып китәләр. Бер сүз әйтмиләр, чөнки барысы да «Ил өчен!», «Җиңү өчен!». Җәйләрне көтеп алалар, чөнки туйганчы юа, кычыткан ашы ашыйлар. Сугыш еллары авырлыгы барысына да тия. Авыр булса да балалар үсә тора. Яшүсмерләр дип атый башлыйлар үзләрен.. Олылардан калышмаска тырышып эшлиләр. Кинолар карарга да, аулак өйләр уздырырга да вакыт тапкан булалар. Аяк-ларындагы чабатага да гарьләнмиләр, әниләрен борчымаска тырышалар. Ләкин бу матур яшьлек түгел инде.

Яшьлегемне сагынмыйм
Кояшка карап торамда,
Нурларына табынмыйм.
Сугыш елларында үткән,
Яшьлегемне сагынмыйм.
Яшьлек, яшьлек диеп сөйләп
Өзәләр үзәгемне.
Ә мин уйлыйм, ул елларда
Ничекләр түзгәнемне?!
Бер туйганчы ипи ашау
Керә иде төшләргә,
Булмады шул, ул чагында.
Ипиләре тешләргә!
Юа,чирәм... Төрле үлән
Кырыктык ничә тапкыр...
Кемдер яшьлеген сагына
Ә мин куркам, ул – кайтыр.
Кайтыр да, ул урап алыр,
Кара сөреме белән...
Үткән яшьлегемне, дуслар,
Куркып төлләрдә күрәм....

Яшьлекне сагыну шулай,

Була икән төрлечә.

Бәхетле яшьлек булсын ул, - дип  яза Саимә апа.

Әйе, армиягә озата торалар-кара язулар  килә тора. Каенлы авылыннан

гына да 150 гә якын кеше озатылган.Яртысы диярлек әйләнеп кайтмаган. Күбесенең әле дә кайда җирләнгәне билгеле түгел. Бер гаиләдән бишәр кеше үлгән.

**4.2. Авыл шагыйрәсе.**

2010 нчы ел "Укытучы елы" булганга күрә, Саимә апа Сөләйманова турында язып үтәсем килә.

Сүзем зур хөрмәткә лаек авыл укытучысы, гомеренең 42 елын балаларга туган телне өйрәнүгә, аларны  рухи-әхлакый тәрбияләүгә  багышлаган Саимә Сабир  кызы Сөләйманова турында. Боргалана-боргалана салмак кына агучы Зәй  елгасына, мәһабәт тауларына якын гына  урнашкан гүзәл табигатьле  Каенлы авылында дөньяга килгән ул. Аның балачагы, гомер йомгагы  сугыш елларында сүтелә башлый. Авыл өйләрен сугышның хәсрәт сөреме урап алганда, әтиләрне  яшь түгеп, фронтка озатканда, аңа бары 11яшь була. Ул чакта әнисенең  дүрт баласын кочаклап, гомерлеккә тол,үзләренең ятим каласын каян уйласын ул. Дүрт ел фронтның гел алдынгы сызыгында булган әтиләре, сугыш беткәндә, Кенигсберег шәһәрен алганда, 1945 елның 23 мартында һәлак була. Мәңгелек истәлек булып, әнисенең учында йомарланган кара язу гына кала.

Ата тәрбиясеннән кечкенәдән мәхрүм калып, олылар белән беррәттән, өй һәм колхоз эшләренә яшьтән тартыла, ни кушсалар шуны эшли. Ә эш арасында кулына нинди китап төшсә, сукыр лампа, ай яктысында укып чыга торган була ул.

Гомер елга кебек бит ул. Ага да ага. Балачак елларын артта калдырып, 1950 елда яулыкка берничә дәреслек, бер пар галош төйнәп, аягына чабата бәйләп, Алабуга шәһәренә юл тота.

Педагогия институтын тәмамлаганнан соң хезмәт юлын Яңа Чишмә районындагы Ленино авылында башлап җибәрә. Аннары районыбызның Колмакчы авылында дәвам итә.Сокландыргыч тавы, авыл уртасындагы  кышын туңмыйча агучы саф чишмәсе белән хәтерендә уелып кала игелекле Колмакчы.

Аннан соңгы хезмәт еллары туган авылы Каенлыда үтә. Балаларга аң-белем бирү өлкәсендә эшләп, ул укучыларда туган ягыбызга, ана телебезгә, әдәбиятыбызга мәхәббәт уята алды.

Балаларда иҗат уты кабызу өчен "Энҗе бөртекләре" дигән әдәби түгәрәк ача. Аларның сәләтен күрә белә.

Саимә апа хәзер лаеклы ялда. Тик исеме генә ялда. Күңеле, хисләре, тойгы - фикерләре гел эштә аның ,чөнки ул җаны белән иҗат кешесе. Аның уй-кичерешләре, шигырь булып, дәфтәр битләренә тезелә. Күңел җылысы салынган, йөрәгенең иң түреннән ургылып чыккан шигырьләре аңа яшәргә көч бирә. Авылына кагылышлы һәм тормыш фәлсәфәсен эченә алган шигырьләре самимилеге, эчкерсезлеге,якты уйлар уятуы белән әсир итә.

Сөйлим дисәм, сүзләрем бар,
Җырланасы җырларым.
Тормышыма ямь бирәләр
Оныкларым,улларым.
Кайгыларым бүлешергә
Дусларым бар янымда.
Алар миңа куәт бирә,
Ризыгым мул табында, -дип яза җир җылысын тоеп яшәүче, чәчәкләрне, табигатьне яратучы, буш вакытларында чигеп, бәйләп, борынгы китаплар укып, кешеләргә изгелекләр кылып яшәүче Саимә апа.Әйе, игелекле эшләрдән әле дә туктамый, һәркемгә ярдәм кулы сузарга әзер ул.

Хәзерге укытучыларга әйтер сүзләре дә бар аның: “Тормышның матди ягына нык игътибар бирмәсеннәр иде алар, балалар күңелендә дөрес, матур тойгылар калдырырга тырышсыннар иде”, -ди.

**Йомгаклау**

... Сүз башы Каенлы каеннары турында иде бит. Үзенең бер әсәрендә Татарстанның халык язучысы Аяз абый Гыйләҗев: “Каенлының каеннарын күрәсе иде!” – дип язган иде. Исән булып, үзе килеп күрсә, ихластан шатланыр иде әдибебез. Мәктәп тирәли дә, Сабантуйлар үтә торган урыннарга да, Каенлы авылына борылган юл буйларына да каеннар утыртылган.

Хәзер исә алар, язын- яшел, көзен – сары күлмәкләрен киеп нур чәчәләр. Әйтерсең лә, ул каенкайлар: “Сезгә бик рәхмәтле без, эшләрегез һәрвакыт уң булсын!” – дигәндәй, бөдрә толымнарын җилләр кочагында сүтеп, җыр сузып олы юлга озата баралар...

Каршы ала, озатып кала
Каенлы каеннары,
Матурлыгы белән мәшҺүр
Безнең як авыллары.

Бик якын миңа авылым, аның үткән тарихын күбрәк беләсем килә; тарихи, әдәби китаплар укыйм-эзләнәм. Матур ул минем авылым-Каенлы. Йортлары, урамнары гына түгел, кешеләре дә матур: тыйнак, эшлеклеләр.

Кемнәрнеңдер яңа җирләргә килеп урнашуы, урман төпләп, җир эзерләүләре, иген игүләре, малчылык, аучылык белән шөгыльләнүләре; агач эш коралларының, киемнәрнең, савыт- сабаларның бик гади итеп кулдан эзерләнгән булуы, чукындыру чоры, сәнәкчеләр,төрле сугышлар, 1921 елгы ачлык китергән фаҗигаләр,колхозлашу еллары – болар барысы да Каенлы авылы тарихына кереп калган.

Бу истәлек- хәтирәләр, һәр нигез, һәр нәсел үзе бер тарих икән бит.

Килер бер көн, үтәр бер гасыр, агар Зәй сулары, үзгәреп бетәр бу тормышлар, ә Каенлы авылы тарихы дәвам итәр.

**Кулланылган әдәбият:**

1.“Әй,Каенлым,Каенлым” Саимә Сөләйманова Казан “Милли китап”нәшрияты 2009.

2.Каенлы авылы тарихы Фәхри Шәрәфиев Казан “Сүз” 2009.

3. “Зәй сулары ага тора ...” .Саимә Сөләйманова . Татарстан Республикасы, Түбән Кама .”Гүзәл” НПҮ ААҖ. 2013 ел.

*Галиуллина Алинә, 4 нче сыйныф,*
*7 нче мәктәп, Татарстан Республикасы Түбән*
*Кама муниципаль районының "7 нче урта*
*гомуми белем бирү мәктәбе" муниципаль*
*бюджет гомуми белем бирү учреждениесе*
*Җитәкчеләре: Хәмизова Вафия Тимершәех*
*кызы, Камалова Гөлназ Радик кызы*
*татар теле һәм татар әдәбияты*
*укытучылары*

## Әби-бабаларыбыздан калган уеннар

**Кереш**

“Уен - хезмәт баласы”

В.Г. Плеханов

Күңелле, мавыктыргыч уеннар - балачакның онытылмаслык мизгелләре... Әлеге шөгыльдән башка, балаларны күз алдына китерептә булмый. Чөнки уеннар аша балада фикер йөртү, киң күңеллелек, бер - береңне яклау,ягымлылык, ихласлылык дигән төшенчәләр арта, үсә. Уеннар аша балалар коллективка ияләшәләр, аларда җаваплылык хисләре арта. Без дә төрле уеннар уйныйбыз. Урамда футбол, качышлы, куышлы уйнарга яратсак, өйдә күбрәк компьютер уеннарына өстенлек бирәбез. Нindиләре генә юк аның! “Три в ряд”,”Птичий городок”, “Аватария”, “Нано Ферма”, “Сокровища пиратов” һәм башкалар. Аларны санап та бетерерлек түгел хәтта!

Әти - әниләр, әбиләребез күп вакыт безгә кисәтү ясыйлар. - “Җитте сиңа, кызым! Күзеңне бетереп утырма! Урамда уйнар идең ичмаса!”- диләр алар. Белсәләр икән алар, бу уеннарның шундый мавыктыргыч икәнен. Белмиләр шул!

Тукта... Аларның да балачагы булгандыр бит! Менә шушыннан башланды да инде минем проектның башы.

А**ктуальлеге**:

Әлеге тема бик актуаль диеп уйлыйм, чөнки, укытучыбыз Гөлназ Радик кызы безгә “Әби - бабаларыбыз мирасы”, “Күзләрне саклыйк”, “Хәрәкәттә - бәрәкәт”дип аталган сәламәтлене саклауга юнәлткән темалар турында бик еш сөйли. Мәктәптә үткәрелгән чаралар да шуны раслый. Хәзер бит без - балалар, ни өчендер, күбрәк саф һавада хәрәкәтчән уеннар уйныйсы урынына, күбрәк компьютер уеннарына өстенлек бирәбез.Үзебез - үзебезгә белә торып зыян салабыз түгелме соң?

**Гипотезасы**:

Безнең әбиләребез уйнаган уеннар, безнең хәзерге уеннардан аерыла.

Әлеге уйланулардан соң, миндә шундый сораулар туды:

Компьютер,планшетлары булмагач, әби - бабамнар нинди уеннар уйнадылар икән?

Уйнасалар үзләре генә уйнаганнармы, әллә күмәкләшепме?

Аларның уеннары кызыкмы икән? Безнекеннән нәрсәсе белән аерылып тора?

Әлеге сорауларга җаваплар табу өчен, алдыма шундый **максатлар** куйдым:

1. Халкыбызның мәдәниятын өйрәнү һәм аны үстерү;

2..Әби - бабаларыбызның уеннарын, тарихын өйрәнү, чагыштыру;

3.Әбиләр һәм укучыларның фикерләрен белү өчен сораштырулар үткәрү;

4. Күзәтүләрне йомгаклап, нәтиҗә ясау.

**Методлары:**

- Өстәмә әдәбият өйрәнү, интернет челтәрендә эш;
- Күзәтү;
- Чагыштырмача анализ ясау;

- Йомгаклау.

**Эшнең планы:**

1. Уеннар турында мәгълүмат туплау;
2. Әби - бабайлар арасында һәм укучы балалар арасында сораштыру;
3. Уеннар уйнау;
4. Нәтиҗә ясау.

**Объекты**: әби - бабаларыбыздан калган татар халык уеннары.

**Предметы**: әбиләр һәм бабайлар.

**Бүлек I. Эзләнүне теоретик яктан анализлау**

**1.1. Халык уеннарының барлыкка килү тарихы**

Уеннар да - халык иҗаты җимеше икән ул. Аларны да халык уйлап чыгарган. Борын - борын заманнарда кешеләр бер түгәрәккә тезелеп: “Нинди уен уйлап чыгарыйк икән?” - дип баш ватып утырдылар микән? Юк, һич тә алай түгел икән.

Нинди генә уенны алсаң да, аның эчтәлегендә кешеләрнең әүвәлге чорлардагы шөгыльләре, тормыш - көнкүреше чагылыш таба. Гади генә бер мисалга тукталыйк, малайлар ук - җәяләр ясап уйнарга ярата. Белгәнебезчә, ук һәм җәяләр борынгы кешеләрнең ау һәм сугыш коралы булган. Заманалар узган, тора - бара ауга ук - җәя белән йөрүнең кирәге калмаган, алар халыкның көнкүрешеннән төшеп калганнар. Ләкин бөтенләй үк онытылмаганнар, балалар арасында уйнала торган бер уен буларак хәзерге көнгә кадәр килеп җиткәннәр. Кыскасы, вакыт үткән саен, кешеләрнең тормыш - көнкүреше уеннарга әверелеп барган. Халык уеннары гасырлар дәвамында шул рәвешчә барлыкка килгән.

Әмма уеннар тормыш вакыйгаларын гына кабатлый икән дип уйларга ярамый. Алар буыннан буынга күчә - күчә шомарганнар, аларга яңа кызыклы вакыйгалар, сүзләр, хәрәкәтләр өстәлгән.

“Уен - чын шөгыльгә, тормыш көрәшенә һәм хезмәткә әзерләнү ул”, - дип язган Н. Исәнбәт.

Уен - баланың тормышка әзерләү күнекмәсе ул. Уеннар балага зур файда китерәләр, алар ярдәмендә ул үзенең характерына нигез ташы булып урнашып кала торган гадәтләргә, күнекмәләргә өйрәнә, моның өстенә бу уеннар балада, гадәттә, зур канәгатьләнү хисе уяталар, - бу профессор П.Ф. Лесгафт сүзләре.

Халык уеннары бик борынгы заманнардан барлыкка килгән. Хәрәкәтчән уеннарны инде борынгы кешеләр яшәгән чорларда ук (6-8 гасырлар) уйнаганнар. Бу аларның физик көчләрен һәм сугышчан сәләтләрен үстерүгә корылган уеннар булган.”Таяклар сугышы”,” “Буй”, “Кем ераграк” уеннары әнә шундыйлардан. Алар ташлар, сөңгеләрне тиешле урынга оста тидерү өчен күнегүләр максатында уйнаганнар.

Борынгы рус елъязмалары, 12 гасырда , урманнарда яшәүче борынгы славян кабиләләре мәҗүси бәйрәмнәр вакытында кешеләрнең төрле уеннарга җыелулары турында язалар.

10-13 г.гдагы Новгород шәһәрен археологик казулар вакытында галимнәр формалары буенча тупка, курчакка, кечкенә җәя һәм укларга, шахмат фигураларына охшаган күп кенә әйберләр табалар. Табылдыклар борынгы Новгородның уенга зур әһәмият бирүләре турында сөйли. Рәсем 1.

19 гасырда танылган халык уеннарын өйрәнүче Е.А Покровский төрле халык уеннарында аерма барлыгын әйтә. Борынгы грекларда "уен" сүзе балаларга гына хас сүз булып саналса, римлыларда бу сүз шатлык, күңеллелек дигәнне аңлаткан. Ә немецларда "уен" сүзе - күңелгә рәхәтлек китерүче җиңел хәрәкәтләрне аңлата.

Бик озак вакытлар буена уеннарны телдән өйрәнү традициягә әйләнә. Россия халыклары уен фольклорын буыннан - буынга тапшырып, әлеге буыннар арасындагы якынлыкны саклап кала алган. Борынгы заманнарда Русьта якынча 3меңгә якын уеннар булган.

Безнең әби - бабаларыбызны уен уйнарга беркем дә өйрәтмәгән икән. Аларга үзләренә генә урамга чыгарга рөхсәт бирелгәч, үзләреннән зуррак башка балаларның уйнауларын күзәткәннәр,шуннан акрын гына коллективка кереп киткәннәр. Үзләре дә сизмәстән уенда катнашучыга әйләнгәннәр. Ул вакытта балалар бик күп булган.Зурраклары кечрәкләрен уенга тартканнар. Менә шулай әлеге уеннар буыннан - буынга тапшырылган.

**1.2. Татар халык уеннары**

Күңел ачу йолаларын элек ел фасыллары белән, авыл җиредәге хуҗалык эшләре барышы белән турыдан - туры бәйләнгән булуын исбатлап торасы юк шикелле. Әйтик, язгы кыр эшләре беткәч үткәрелә торган "Сабан туй" бәйрәме күп кенә уеннарның барлыкка килүенә һәм таралуына җирлек булган. Этнографлар борынгы ыруглар булып яшәүче кабиләләрнең мөнәсәбәтләренә бәйләнештә туган "җыен" үткәрү йолалары вакытында да уен, җыр, биюләр күп булуын әйтәләр. Җыеннарны бигрәк тә яшьләр көтеп алган. Чөнки атна буеа җыелган бәйрәм көннәрендә егетләр, кызлар бер берсе белән танышып, аралаша алганнар, күмәк уеннар оештырып ял иткәннәр. Фото 1.

Казан тирәсендәге авылларда җәй башында кызлар җыелышып "Чәчәк бәйләме", "Җуа атнасы" үткәргәннәр. Шомырт чәчәк аткан яисә җиләк пешкән вакытта, җуа өлгергәч, урманда, тугайларда һәм тау буйларында төрле уеннар уйнап күңел ачканнар.

Беренче салкыннар төшкәч, татар авылларында каз өмәләре, тула өмәләре үткәрелүе һәркемгә билгеле. Ә өмә беткәч, яшьләр арасында таралган уен – бию җырларының һәм

җырсыз уеннарның бер өлешен “аулак өйләр”, “урлаш өйләр”үткәрү, кич утырулар, “утырмага йөрүләр”гадәтенә бәйләп карарга кирәк.

**1.3. Эзләнүнең төп төшенчәләре**

Болгар чорында уеннар чагыштырмача иркен шартларда, күмәк рәвештә уйнаганнар булса кирәк. Шул чорга караган риваятьләрнең берсендә Кама буенда кызлар уйный торган махсус урын булуы турында әйтелә. Кызлар уеннын карар өчен анда Болгар ханы да килгән. Тарих битләрендә яшьләр җыелып ял итә торган урыннарның “Кызтау”, “Кыз каласы” дип аталу турында мәгълуматлар бар. Фото 2.

Казан ханлыгы чорына караган тарихи чыганакларның берсендә татарларның ял иткән вакытларында төрле көйләргә кул чабып җырлаулары, биюләре турында языла.

Әмма акрынлап татар халкы тормышында иҗтимагый бәйрәмнәр биләгән урын тарая барган, иркенләп күңел ачу, күмәк уйнау гадәтләре дә кысылган. Моның төп сәбәпләре, бер яктан,изү - кысуга корылган политикасына кайтып калса, икенче яктан, ислам диненә, аның суфыйчылык белән сугарылган кануннарына барып тоташа.

XVII - XIX гасырларда халык көнкүрешен, рухи культурасын яктырткан тарихи чыганакларда без инде иркенлектә узган бәйрәмнәр, күңел ачулар, уеннар турында мәгълуматлар таба алмыйбыз.

Ләкин халык бәйрәмнәрен, җырлы - биюле уеннарын бернинди кысрыклаулар да, тыюлар да, куркытулар да юкка чыгара алмаган. Моны раслаган мисаллар тарихта аз түгел.

**II.Бүлек. Эзләнүнең прктик өлеше**

**2.1. Әби - бабамнар уйнаган уеннар**

Безнең әби - бабаларыбыз яшь вакытта нинди уеннар уйнавын белү өчен, мин алар арасында анкета үткәрдем. Сорау алуда 10 әби - бабай катнашты. Анкета нәтиҗәләре буенча, безнең авылда , әби - бабаларыбыз бик күп төрле уеннар уйнаганнар икән. “Чүлмәк сатыш” , “Йөзек салыш”, “Кулъяулык салыш”, “Ак калач”, “Татумы, сатумы”, “Аллия, Гөллия”, “Наза”, “Челтәр элдем читәнгә”, “Күрсәт әле үскәнем”, “Капкалы”, “Кәрия - Зәкәрия”, “Чума үрдәк, чума каз”, “ Кап та коп”, “Казлар аккошлар” уеннарын бик теләп, яратып һәм сагынып искә алдылар. Һәрбер уенның уйнау тәртибен сөйләделәр.

Нәтиҗә: Безнең әби - бабаларыбызның күбесенчә саф һавада уйнала торган һәм җырлы - биюле хәрәкәтчән уеннар уйнаганнар. Күбесенчә уен ахырында “җәза” биреп балаларның сәләтләре ачылган. Таблица 1.

“Чүлмәк сатыш” - 7,

“Йөзек салыш” - 8,

“Кулъяулык салыш” -10,

“Ак калач” - 10,

“Татумы, сатумы” - 4,

“Аллия, Гөллия” - 5,

“Наза” - 7,

“Челтәр элдем читәнгә” - 9,

“Күрсәт әле үскәнем” - 7,

“Капкалы” - 8,


“Кәрия - Зәкәрия” - 10,

“Чума үрдәк, чума каз” - 10,

“ Кап та коп” - 8,

“Казлар аккошлар” – 10.

Таблица 1.




## 2.2. Безнең уеннар белән элеккеге уеннар арасында охшашлык һәм аерымлыклар

Күбесенчә хәзер балалар нинди уеннар уйнарга яратуын ачыклау максатыннан, шулай ук сораштырулар үткәрдем. Сорашуларда 10 бала катнашты. Мин аларның яратып уйный торган уеннарын ачыкладым. Таблица 2.

6 бала - “Куышлы”

3 бала - “Шахмат”

5 бала - “Атыш”

4 бала -“Футбол”

9 бала - “Лего” (конструктор)


7 бала - “Лото”

5 бала - “Твистер”

5 бала - “Шашка”

10 бала - Компьютер уеннары  уйнарга яраталар икәнен ачыкладым. Фото 3.

Таблица 2.




**Нәтиҗә**: диаграммадан күренгәнчә,балаларның күбесе, компьютер һәм утырып уйный торган уеннарга өстенлек бирәләр. Безнең хәзерге уеннарыбыз әбиләребез уйнаган уеннар белән бер дә туры килми. Кайбер уеннар эчтәлеге буенча да, уенның тәртибе белән дә бик нык аерылып тора. Ә файдасын карасак: элекке вакытта уйнаган уеннарның күбесе саф һавада үткән, хәрәкәтчән булган һәм татар халкының җырларын,такмакларын үз эченә алган. Ә хәзер балалар бик яратып уйный торган уеннар, уйлау - фикерләү сәләтләрен үстерсә дә, хәрәкәт аз булганга күрә, физик яктан сәламәтлеккә зур зыян сала. Бигрәк тә күзләргә тискәре яктан нык йогынты ясый. Виртуаль “тормыш” белән яшәп игътибарлылык югала, хәтер начарая.  Кызганычка каршы, мондый тискәре күренешләр белән без бик еш очрашабыз. Әле өй эше эшләргә,  эле китап - дәфтәр алып килергә, барасы җиргә вакытында барырга оныту, монын ачык мисалы.

**Йомгаклау**

Әлеге проект эшен, мин зур кызыксыну белән башкардым. Яңа уеннар белән танышканнан соң, миндә бу уеннарга карата зур кызыксыну уянды. Ә нишләп әле без, үзебезнең әби - бабаларыбыз уйнап үскән уеннардан баш тартырга тиеш? Без бит - киләчәк

буын, әби - бабаларыбызның дәвамчылары. Киресенчә без бу уеннарны өйрәнергә,аларны белергә дигән теләкне тормышка ашыру максатыннан, бу фикеркемне үземнең сыйныфташларыма җиткердем. Алар мине хупладылар. Шулай итеп, без әбиләребез белән бергәләшеп, авылыбызның "Буыннар мирасы" музеена, элеккеге уеннарны өйрәнергә җыелдык. Безгә бик күңелле булды! Әбиләребезгә дә безнең бу гамәлебез бик охшады, алар үзләренең бала чакларына кайткандай булдылар. Берсен - берсе бүлдерә - бүдерә, безгә уен тәртипләрен аңлаттылар, аяклары сызлавын да онытып, безнең белән бергә рәхәтләнеп уйнадылар. Минем Рәхимә әбиемнең дә шатлыгы йөзенә чыккан иде. Мин аның, безгә карап, җиңел сулап куюын сиздем. Аңа ияреп мин дә , үзем дә сизмәстән ,җиңел сулыш алдым. Чөнки, проект барышында куйган барлык сорауларыма җавап таптым. Алай гына да түгел әле, без әбиләребездән, "Чүлмәк сатыш" , "Йөзек салыш", "Кулъяулык салыш", "Ак калач", "Татумы, сатумы", "Аллия, Гөллия", "Наза", "Челтәр элдем читәнгә", "Күрсәт әле үскәнем", "Капкалы", "Кәрия - Зәкәрия", "Чума үрдәк, чума каз", " Кап та коп", "Казлар аккошлар" дигән уеннарны тулысынча, барлык кагыйдәләренә туры китереп уйнарга өйрәндек. Фото 4.

Шушы уен эчедә җырлана торган җырларны ятладык! Галимҗан бабайның шушы көйләрне гармунда уйнавына сокландык та, кызыктык та. Безнең дә аның кебек моңлы, матур итеп гармунда уйнап карыйсыбыз килде.Кем белгән, бәлки өйрәнеп тә куярбыз әле!

Гипотезам тулысынча ачылды. Чыннан да, әби - бабаларыбыз уеннары безнең хәзерге уеннардан нык аерылып тора. Аларның сәламәтлеккә йогынтысы да бик зур. Юкка гына "Хәрәкәттә - бәрәкәт!" димәгәннәр бит. Йомгаклап шуны әйтәсем килә, без киләчәктә дә әлеге уеннарны дәвам итәрбез, үзебездән соң килүче кечкенәләргә дә өйрәтебез дип ышанам. Әлеге уеннар безнең күңелләребезне генә түгел, кул - аякларыбызны, башыбызны, күзләребезне дә ял иттерде. Тиздән без көтеп алган, җәйге каникуллар җитә. Иң сөендергәне шул: мәктап яны сәламәтләндерү лагерьенда, бергә укыган дусларыбыз белән дә, сәламәтлекне ныгытучы, ә иң мөһиме татар милли йолаларын саклаучы, җыр, такмак, такмазаларга бай уеннарыбыз җитәрлек хәзер бездә! Ә әлегә, без бу уеннарны тәнәфесләрдә уйный торабыз. Минем бу темам бик актуаль дип, уйлым. Чөнки үткәнен белгән халыкның, киләчәге бар. Без үзебезнең милли уеннарыбызны беркайчан да онытмабыз!

**Кулланылган әдәбият**

1. Баязитова Ф. Татар халкының бәйрәмнәре һәм көнкүреш йолалары. – Казан: Татар кит.нәшр., 2005.

2. Уразман Р. Татар халкының йолалары һәм бәйрәмнәре. – Казан: Татар кит.нәшр., 2002.

3. Татар халкының йолалары һәм бәйрәмнәре / Татарстан Милли китапханәсе; Төз. З.Ә. Җамалиева. Казан: милли китап, 2010.

4. Р. Сибгатуллин. татар милли педагогикасы. – Казан: Матбугат йорты нәшр., 2004.

5. Татар халык иҗаты. Йола һәм уен җырлары. - Казан:татар кит.нәшр., 2010.

6. Татар халкының җырлы - биюле уеннары / Төз. Х. Гатина, сүз башы язучы И.Надиров. - Казан: Татар кит.нѐшр., 1968.

7. Р. Ягъфәров. Уен - күңел бәйрәме .- Казан: Мәгариф,2009.

*Гарипов Габделкәрим, 8 нче сыйныф,*
*Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районының "Каенлы урта гомуми белем бирү мәктәбе" муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесе*
*Җитәкчеләре: Гарипова Лилия Рәүф кызы, татар теле һәм әдәбияты укытучысы,*
*Гарипов Расим Фаиз улы, тарих һәм җәмгыять белеме укытучысы*

## Авыл күрке- мәчет

### I КЕРЕШ

Татар милләтенен язмышы ислам дине белән турыдан-туры бәйле. Дин безнең күп гасырлар дәвамында дәүләтле халык булып яшәвебездә зур роль уйнады, җәмгыятьтә әхлакый нормалар тәрбияләде, гомумән, татарны татар итеп саклап калуга үзенең зур өлешен кертте. Авылларның Аллаһы йорты-мәчетләр, мәчетләр турында язылган китаплар, төшерелгән фильмнар, архив материаллары күп. Ләкин туган төбәгем Түбән Кама районы Каенлы авылының бер гасырлык мәчете тарихын туплаган материаллар бик аз. Шуңа күрә мин фәнни-тикшерү эшемнең **темасын** “Авыл күрке – мәчет” дип алдым.

Мин бу теманы бик **актуаль** дип саныйм. Хәзер динебез, телебез, гореф-гадәтләребегә карата игътибар арта бара, дини уку йортлары ачыла, мәчеткә халык елдан ел күбрәк тартыла. Шулай ук 2022 нче елда Идел буе Болгар дәүләтендә ислам динен кабул итүгә 1100 еллыкны билгеләп үтү дә бу эшкә алынуга этәргеч булды. Авылыбызның мәчет тарихын белү – безнең бурычыбыз. Мин, киләчәк буынга авылның мәчет тарихын белер өчен, сакланып калган материалларны туплап, моңарчы ачыкланмаган мәгълүматларны тикшереп нәтиҗәләр чыгаруны эшемнең **проблемасы** итеп куйдым. Кызганычка каршы

авылыбызның мәчете һәм имамнары турында күп мәгълүмат тупланып калмаган. Өлкән буын вәкилләренең дә күбесе инде бакыйлыкка күчкән. Шуңа да булган бар көчемне җыеп бу эшкә үземнән кулымнан килгән кадәр өлеш кертәсем килә. Бу проект эше моның белән генә чикләнеп калмыйча, киләчәктә тагын да тулыланыр һәм дәвам ителеп барыр дип ышанам.

**Фәнни тикшерү эшемнең объекты:** Каенлы авылы мәчете.

**Фәнни тикшерү эшемнең предметы:** авылнын муллалары, абыстайлары, мәчетнең төрле еллардагы хәле.

**Максат:**

Түбән Кама районы Каенлы авылының мәчет тарихын өйрәнү.

**Бурычлар:**

- бүгенге көндә безнең арада булган өлкән буын кешеләре белән аралашып мәчетнең тормышы турында материал туплау;

- мәчет тарихын , имамнар язмышын архив материалларыннан һәм төрле чыганаклардан өйрәнү;

- район газеталарында басылып чыккан мәкаләләрне файдалану, мәктәп музеендагы булган язмалар белән танышу;

- фотоматериаллар туплау;

- туган илгә, авылга булган мәхәббәт, ватанпәрвәрлек хисләре тәрбияләү өчен, эшне мәктәп музеена тапшыру.

**Гипотеза:**

Авылым мәчете елдан ел янарыр, үсәр, матурланыр.

Максатка ирешү өчен:

- өлкән буын кешеләреннән сорашып мәгълүмат тупладым;

- архив материаллары тупладым;

- туган як тарихы өйрәнү буенча китаплардан, альбомнардан, массакүләм информация чараларын файдаландым;

- фотоматериаллар җыйдым.

Фәнни-тикшерү эшем : кереш өлештән, төп бүлектән, йомгаклаудан, библиографик исемлектән тора . Бу эш киләчәктә практик кулланыш табар дип уйлыйм.

Һәр авылның тарихы аерылгысыз рәвештә андагы мәчетләр Һәм дин тарихы белән бәйләнгән. Кызганыч ки, узган дәвердәге динне юк итү, милләтне җәберләү сәясәте барган вакытта мәчетләр җимерелгән, иң асыл затлар, укымышлы кешеләр Һәм имамнар төрмәләргә ябылганнар, сөргенгә озатылганнар. Күп кенә җимерелгән мәчетләрнең тарихы югалган диярлек. Анда эшләгән имамнарның фаҗигале язмышы турында да мәгълүматлар

бик аз һәм таркау хәлдә. Проект эшебезне башкару өчен үз алдыбызга шундый бурыч куйдык: Каенлы авылындагы дин Һәм мәчетләр тарихын, дин әҺелләре эшчәнлеген җентекләбрәк өйрәнеп, тулырак яктырту. Үзебездән соң килгән буыннарга тулырак мәгълүмат туплап калдыру. Проект эше һәм тупланган хезмәт моның белән генә чикләнмәс, тагын да ныграк тулыланып һәм баетылып югалмыйча, киләчәктә дә дәвам ителер.

## II ТӨП ӨЛЕШ

Мәчет ( гарәпчә “мәсҗид”) сүзе гади генә әйткәндә “сәҗдә кылу урыны” дигәнне аңлата. Сүзнең төп мәгънәсе исә Аллаһы Тәгаләне олылап берүзең яки җәмәгать белән бергәләп гыйбадәт кылу урынын , йортын аңлата.

Коръән Кәримдә Раббыбыз, Зате Җәләл хәзрәтләре: “ Хакыйкаттә, җир йөзендә беренче буларак салынган мәчет - Мәккәдә. Ул – мөбәрактер вә галәмнәрдәгеләргә туры юл күрсәтүчедер!”, дигән ( Әәл Гыймран сүрәсе, 96 аят). Аятнең эчтәлегеннән күренгәнчә, аннан берничә мөһим мәгълүмат килеп чыга.

Беренчесе: мәчет әдәм баласына Аллаһы Тәгаләне олыларга билгеләнгән махсус урын була.

Икенчесе: мәчет җир йөзендә Аллаһы Тәгаләнең бар, бер булуына һәм аның диненең шул җирдә таралган булуына күрсәткечтер.

Өченчесе: җир йөзендә беренче буларак Мәккә-и Мөкәррәмәдәге Кәгъбәтүллаһ мәчете төзелгән.

Дүртенчесе: җир йөзендәге кайбер урыннарның Ходай каршында шул җиргә генә хас булган дәрәҗәсе бар икән.

Әлбәттә, иң әүвәл, мәчет гыйбадәт кылу урыны. Әмма моннан тыш, элек-электән мәчетләребез шулай ук уку-укыту урыны булып торган.

Мәчетләребез һәм татар халыкы язмышы шома гына бармаган. Бик җитди сынаулар аша үтәргә туры килә. Бигрәк тә XVI нчы гасыр татар халкы өчен авыр, газаплы чор була.

**1**552 нче елның июнь аенда, яңа төзелгән стрелецлар полклары белән тулыландырылган, 150 хәрби туп белән баетылган урыс армиясе Явыз Иван җитәкчелегендә Казанга юнәлә. Свияжскига тоткарлыксыз килеп җитеп, шунда ярты ай чамасы ял итеп сугышка хәзерлек үтеп, урыслар 23 август көнне Казанны камап ала. Бер айдан артыкка сузылган аяусыз сугыштан соң, 2 октябрь көнне Казан шәһәре кара канга батырылып яулап алына. Дәүләт һәм хөкүмәт оешмалары, илдәге бөтен хакимият юкка чыгарыла, гаскәр тар-мар ителә, бөтен Казан ханлыгы яулап алына, яшәүдән туктый. Дәүләт юкка чыкканнан соң, татарның сәяси тарихы Россия империясе эчендә дәвам итә һәм бөтенләй икенче төсмер ала. Халык буларак сакланып калу, туган телен, күп гасырлык

мәдәниятен вә динен югалтмау, ниһаять, элекке дәүләтчелеген һәм мөстәкыйльлеген торгызу өчен милли азатлык хәрәкәтенә әверелә.

Казан алынганнан соң Урта Иделдә чәчәк аткан ислам мәдәниятенең үсеше кинәт өзелеп-туктап кала. Яңа хуҗалар алып барган христианлаштыру сәясәте ислам архитектурасының үсешен бик авыр хәлдә калдыру белән беррәттән, гомумән, бу төбәктә мөселман диненең яшәвен шик астына куя. XVI йөзнең II яртысы һәм XVII йөз тулысы белән милли һәм социаль изүгә каршы көрәштә уза. Казан алынуга ук татарлар, кулларына корал тотып, дәүләтне торгызу өчен көрәшкә күтәреләләр: татарларга чирмешләр, башкортлар, кайбер башка халыклар да кушыла. Урыс дәүләте мондый күтәрелешләрне рәхимсез бастырып бара. Татарларны көчләп чукындыру башлана, мәчетләрне җимереп, алар урынына чиркәүләр салырга тотыналар. Татарларның зур сулар буендагы иң яхшы җирләре тартып алына, урыс алпавытларына һәм Рәсәйнең үзеннән килгән качкын крестьяннарга бирелә.

Рухи эзләнүләр, мөселман мәдәнияте үсүдән туктаган, гаять түбән төшкән шартларда да ерак авылларда Казан татарларының шәһәр мәдәнияте, теле, аң-белемгә омтылу, дин әле сакланып килә. М.Худяков язганча, атаклы мөгаллимнәр, дин белгечләре ерак салаларда ачкан байтак мәдрәсәләр чәчәк ата. Шәрекъ илләре белән элекке элемтәләр торгызыла, сәүдә юллары белән аннан төрле китаплар килә. Тырыш авыл муллалары аларны күчереп яза, шулай борынгы традиция өзелмичә дәвам итә.

1744 елда Казан епархиясендә исәпләнгән 536 мәчетнең 418 е инде җимертелгән була. Җимерүнең сәбәбен мәчет санының билгеләнгән нормага туры килмәве белән аңлаталар: норма буенча 200-300 мөселманга 1 мәчет тиеш икән.

1756 елда татарлар дәүләтнең ислам диненең законлаштырылуына ирешәләр.

Шушындый авыр сынау, изүләрне дә үз башыннан кичергән татар халкы. Иң мөһиме сынмаган, сыгылмаган, татарлыгын, динен югалтмаган, көчле баш имәс, горур булып калган. Каенлы авылы халкы да шушы авыр сынаулы чорларда да исән-имин, диненә тугърылык саклый алган.

Бөек Октябрь революциясенә кадәр авыл мәчетләре дини белем генә бирмәгәннәр, укырга, язарга өйрәтә торган бердәнбер уку йортлары булып торганнар.

Минем туган авылым булган Каенлыда бер мәчет авыл уртасындагы иске зиратның бер почмагына салынган, манарасыз бина булган. Беренче булып килгән Госаметдин мулла авылда озак тормый, китеп бара. Аннары Бохарада белем алган кеше мулла булып килә, аны халык Бохари хәзрәт дип йөрткәннәр, чөнки аның исемен берәү дә белмәгән. Хәзрәт мәрхүм булгач, Мөхәммәтсадыйк исемле мулла килә. Искерә башлаган агач мәчет кенә авыл кешесенә җитмәү сәбәпле, авыл картлары икенче мәхәлләгә дә мәчет

кирәклеген белдерәләр. Авылның хәзерге өч катлы йортлар урынында нараттан мәчет төзиләр. Ә 1898 нче елда Каенлыга Ибнеямин Шамбазов мулла булып килә. Ул иске мәчеттә хезмәт итә башлый. Ул Каенлыда мәктәп-мәдрәсә ачуга да ирешә.Ибнеямин мулла –указлы мулла, белеме дә бар,дәрәҗәсе дә, аны күрше авылларга да чакырып торганнар.

Мәчет бинасының иске, хәтта җимерелә башлавы Ибнеямин мулланы борчый. Ул халыктан иганә җыеп, яңа мәчет салдыру турында хыяллана. Күрше – тирә авыл байлары да аңа булышырга ризалык бирәләр. Бүгенгә кадәр сакланып калган таш мәчетебезнең нигез ташларын салдырган, шундый мәһабәт мәчет итеп ул төзеткән. Мәчетне төзетү өчен Ибнеямин мулла күпме борчулар кичергән, оештыру эшләре,төзелеш материалларын табу-барысы да аның өстендә булган.Төзелеш өчен ташны Тоба тавыннан чыгарганнар, атлар белән ташыганнар. Мәчетне бары тик мөселманнар гына, күтәргеч краннар да булмау сәбәпле, кул көче белән салганнар. 1913 елда мәчет төзелеп беткәч, аны Таш мәчет дип атый башлыйлар. Таш мәчеттән ерак түгел, инеш буена Ибнеямин хәзрәт мәдрәсә- мәктәп җиткерттергән. Аны “Ибнеямин мулла мәктәбе” дип йөрткәннәр. Үзе яши торган йорт янына Кызлар мәктәбе дә ачкан. Бу мәктәптә кызларны Ибнеямин мулланың хатыны Хәдичә абыстай укыткан. Ибнеямин хәзрәт мәктәпләренә балалар бик теләп йөргәннәр. Чөнки монда көнгә бер мәртәбә кайнар аш белән сыйлаганнар, бушка язарга өйрәтү дәфтәре-“мәшык дәфтәре” өләшкәннәр. Бу мәктәптә дини дәресләрдән тыш дөньяви фәннәр: арифметика, география дә укытканнар. Шушы яңалыклар өчен Ибнеямин Шамбазов мәктәбенә күрше авыллардан да шәкертләр китергәннәр.

Революциядән соң авылның ике мәчете дә 1928-1930 елларга кадәр яхшы гына эшләп килә. 30 нчы еллар башында авылның ике мулласын да кулга алалар, гаиләләрен авылдан сөрәләр. Мәчетләр колхозга бирелә. Агач мәчет медпункт вазыйфасын үти, аннары мәчет бинасында сүтеп икенче урында авыл клубы ясыйлар. Шулай итеп агач мәчет тарихы тәмам була. Таш мәчет буш тора. 1941 нче елның гыйнварында Каенлы тулы булмаган урта мәктәбе яна. Мәктәп җитәкчелеге, авыл картларын җыеп, мәчетләрне мәктәп кулына тапшыру турында сөйләшәләр. Аксакаллар риза булалар. Таш мәчеттә - башлангыч сыйныфлар, ә агач мәчеттә зурлар укытыла. Авыл тарихы турында истәлекләр туплаучы, мәгариф ветераны, “Каенлы авылы тарихы” китабы авторы Фәхри Шәрәфиев мәчет белән бәйле түбәндәге вакыйганы искә ала: “Мин мәктәп директоры булып эшләгәндә Байданкино руслары минем янга килеп, мәчет манарасын кисәргә теләүләрен әйттеләр, тик мин бу эшкә риза булмадым. 1952 нче елда Бороктан өч урыс килеп, арзан бәягә генә манара кисәргә риза булуларын белдерделәр, мин тагын каршы килдем. Мәчет манарасының авуы, җимерелүе, гомеремнең чикләнүе белән бер иде.”[3-32б] XX

гасырның 60нчы елларында мәчет бинасында колхозның икмәк амбары, аннары химик ашламалар склады була.

Соңрак бина җимерелә. Мәгариф ветераны Саимә апа Сабирова бу мәчет бинасы турында болай дип искә ала: “Мәчет бала-чаганың уйнап йөри торган урыны иде. Алар биек баскычлары буйлап курка-курка күгәрченнәр куарга дип үрмәлиләр. Балалар өйләренә кайтып мәчеттә китапларның күп булуын әйтәләр. Кирәксә кочагың белән ал! 1-45 б]

Илдә үзгәртеп корулар башлангач, мәчетне ремонтларга рөхсәт бирелә. Мәчетне ремонтлаганда материаль ярдәм күрсәтүдә “Кызыл Зәй” совхозы директоры Әхмәтшин Габделбәр, авылның өлкәннәреннән Фәхретдинов Бәдертдин, Хәсәнов Әнвәр, Хөсәинов Исмәгыйль, Хайруллин Нурулла, Ибраһимов Назыйм, Сибгатуллин Исхакны искә алмыйча мөмкин түгел. 1990 нчы елда яңартылган мәчеттә беренче азан яңгырый.

Җомга һәм гает намазларын, ишегалларында, тыкрыкларда,зиратка да барып укып йөргән Каенлы авылы кешеләре шул көннән мәчеткә юл ала. Авыл аксакалы Бәдертдин Фәхретдинов бу турыда күңелендә булган хисләрен шигырь юлларына салган.

... Моңлы азан тавышларын
Бик озак көтте халык.
Тыңлый аны яше- карты-
Һәрбарчасы тын калып.
Яңгырый азан тавышы,
Һәр яхшылыкны хуплап.
Тыңлый аны сабыйлар да,
Уеннарыннан туктап.[1-46б]

Яңартылган мәчетнең мулласы итеп Хәбибуллин Исмәгыйль куела. Исмәгыйль бабай мулла булып 1998 нче елга кадәр хезмәт итә. Ул вафат булгач, Бәдертдин Фәхретдиновка имам вазыйфасы йөкләнә.

2004 нче елда Түбән Кама районы имам - мөхтәсибе Рамил хәзрәт Юнысов тәкъдиме белән Бәдертдин хәзрәткә ярдәмгә Каенлы авылына икенче имам итеп, Яр Чаллы шәһәрендә дини һәм дөньяви югары белем алып кайткан минем әти- Гарипов Нияз билгеләнә. 2006нчы елда Бәдертдин хәзрәт үз урынында Нияз хәзрәтне калдыра. Нияз хәзрәткә указлы мулла булуга шәһадәтнамә тапшырыла. Шул вакыттан бирле әтием авылыбызның хөрмәтле кешесе-хәзрәте булып тора. Бу урында әтием турында “Туган як” газетасында язылган юлларны китерәсе килә: “Нияз хәзрәтне авыл халкы хөрмәт итә. Имамның абруе бик зур, намазга килгән һәр кеше, хәзрәт турында мактау сүзләрен әйтеп калырга ашыга. Имам үзе дә мәхәллә халкын бик хөрмәт итә. “Алар булмаса, мин берүзем берни дә эшли алмыйм бит”,- ди тыйнак кына.”[2 ]

2012нче елда авыл картлары тырышлыгы белән бер гасырлык мәчетне яңарту эшләре башлана. Халыктан җыелган 250 мең сум һәм эшмәкәрләрдән кергән хәйрия акчасына ремонт ясала. Мәчетнең эченә һәм тышына яңа сулыш өрелә.

2013 нче елның сентябрендә мәчетнең 100 еллыгы уңаеннан оештырылган тантанада "Шәһәр электр транспорты" предприятиесе генераль директоры Рафаил Хәбибуллин компьютер тапшыра, Бөтендөнья татар конгрессының Түбән Кама бүлеге җитәкчесе Рөстәм Ганиев вәгазь укулар урамнарга ишетелеп торсын, мәчет алды мәйданында да зур экраннарда трансляцияләнсен өчен техник аппаратура бүләк итә. Бәйрәмдә Татарстан баш мөфтие Камил Сәмигуллин исеменнән аның беренче урынбасары Рөстәм Батров мөселманнарны әлеге бәйрәм белән котлый.

Каенлы халкы авыл мәчетен бер гасыр саклый алуы белән горурлана.

Шулай итеп, иман йорты рухи көчкә һәм тарихи әһәмияткә ия булуын дәвам итә.

## III. ЙОМГАК

Эш барышында алдыма куйган **максат** һәм барлык **бурычлар** да чишелде. Мин фәнни - тикшерү эшем буенча әдәбият кулландым; өлкән буын кешеләреннән сорашып мәгълүмат тупладым; мәктәп музеена мөрәҗәгать иттем; массакүләм информация чараларын файдаландым; фотоматериаллар җыйдым һәм үземә шундый **нәтиҗә** ясадым. Авылымнын дини учагы булган бер гасырлык мәчетебез бүгенге көнгә кадәр хезмәт итә. Хезмәт итеп кенә калмый елдан ел яңара , үсә, матурлана. Бүгенге көндә авылыбыз имамы, абыстайлары иң абруйлы, ихтирамлы санала.

Эшемнең башында куйган **гипотеза** тулысы белән расланды. Мәчетебез елдан ел яңара, үсә, авылыбыз дини авыл булып кала бирә. Авылым халкының рухи мәдәнияты, анын купгасырлы тарихы ислам диненнән аерылгысыз. Авыл халкының тормыш тәртибен, дөньяга карашын һәм рухи кыйммәтләрен формалаштыруда мәчет һәрвакытта хәлиткеч роль уйнаган һәм уйнаячак та.

Тарихи эзләнүләр нәтиҗәсендә тупланган хезмәтемне тарих дәресләрендә, туган якны өйрәнгәндә һәм тәрбия эшендә материал буларак кулланырга мөмкин.

**КУЛЛАНЫЛГАН ӘДӘБИЯТ**

1.Саимә Сөләйманова "Зәй сулары ага тора" Түбән Кама, 2013,45- 46б

2. "Туган як" газетасы, 2013ел, сентябрь

3.Ф.Шәрәфиев "Каенлы авылы тарихы", Казан, "Сүз",2009,32б

**Сөйләгәннәр, кулъязмалар**

Аксакаллар сөйләгән мәгълүматлар , кулъязмалар

Бәдертдин Фәхретдинов "Авылым мәчетләре" кулъязма альбом

**Интернет чыганаклары**

https://tatar-congress.org/yanalyklar/kaenly-avylynda-mechetnen-100-ellygy-bilgelep-ytelde/
https://nsportal.ru/shkola/kraevedenie/library/2015/11/24/mchetlr-tozelu-tarihy

*Гарипова Эльвина, 9 сыйныф,*
*Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районының «Аерым фәннәрне тирәнтен өйрәнүле 31 нче гомуми урта белем бирү мәктәбе» муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесе*
*Җитәкчеләре: Фокеева Елизавета Павел кызы, Шамбазова Эльмира Гомәр кызы, туган тел һәм әдәбияты укытучылары*

## Укытучы һөнәре : кичә, бүген, иртәгә

### Кереш

2023 ел Россиядә Укытучы һәм остаз елы дип игълан ителде.

Укытучы һөнәре һәрвакыт иң хөрмәтле һәм җаваплы саналды. Укытучы балаларны укытып кына калмый, ул бөек илнең киләчәк буынын тәрбияли. Укучылар үсеп җитәчәкләр, галимнәр, инженерлар, сәясәтчеләр, үз илләрен, туган якларын, туган шәһәрләрен данлаучы эшкуарлар булачаклар. Кеше яратучанлык, рухилык, патриотизм – укытучы үз укучыларына белем белән бергә бирә торган сыйфатлар. Укытучы үз иленең киләчәген булдыра.

Әлеге тикшеренүнең актуальлеге, барыннан да элек, Россия Федерациясе территориясендә белем бирү эшчәнлегенең әһәмиятлелеге белән билгеләнә. Superjob тикшеренү үзәге үткәргән сораштыру нәтиҗәләре, аның барышында укытучы һөнәренең абруйлылыгы һәм идеаль укытучы нинди сыйфатларга ия булырга тиешлеге ачыкланган: сораштырылган гражданнарның 21% ы укытучы һөнәрен Россиядә түгел, ә чит илдә генә абруйлы дип таный. Россиялеләрнең күпчелеге – сораштырылучыларның 64 проценты укытучы һөнәрен абруйсыз дип саный. Бу фикерне барыннан да ешрак 45 яшьтән өлкәнрәкләр әйткән, алар барлык сораштыруда катнашкан кешеләрнең 69% с тәшкил иткән. Моннан тыш, РФ гражданнарының яртысы – 51% соңгы 10 елда Россиядә укытучы статусы кимегән, 21% педагог статусы үзгәрмәгән, ә 17% ул артты дип саный.

Бүгенге укучыларның үзләрен педагогик һөнәргә багышларга теләмәве, шәһәр мәктәпләрендә укытучыларның җитмәве укытучы һөнәренең абруе кимүен күрсәтә. Абруй (Франциянең " prestige» - йогынтысы, абруе) – бу, беренчедән, әлеге һөнәр ияләренең җәмгыятьтәге йогынтысы. Икенчедән, лаеклы хезмәт хакы. Педагог һөнәренең абруен күтәрү - бөтенроссия, төбәк һәм муниципаль дәрәҗәдә хәл ителә торган бурыч.

Әмма укучылар арасында укытучының абруен күтәрү, шулай ук яшь белгечләрне мәктәпкә җәлеп итү проблемасы ахыргача хәл ителми.

Мәктәптә кадрлар җитмәү фонында педагогика өлкәсендә яшь белгечләр җитмәүдә кискен каршылык сизелә. Әлеге каршылыкны гомумиләштерү нигезендә без «Укытучы» һөнәре абруен кискен киметүдән гыйбарәт проблеманы формалаштырдык, аның нәтиҗәсе – педагогик кадрлар кытлыгы.

Билгеләнгән актуальлек, каршылыклар һәм проблема безгә тикшеренү эше темасын билгеләргә мөмкинлек бирде: «Укытучы һөнәре: кичә, бүген, иртәгә».

**Эшнең максаты:** «укытучы» һөнәренең дәрәҗәсен төшерүгә алшарт булган факторларны ачыклап, аларны гамәлгә ашыру «укытучы» һөнәренең абруен төшерү һәм педагогик кадрлар җитмәү проблемасын хәл итәргә мөмкинлек бирүче чаралар комплексын билгеләү.

**Бурычлар:**

* педагогик һөнәрнең асылын һәм формалашуын билгеләү;

* турыдан-туры герой булган сәнгать, кинематография әсәрләренә проблемалы-юнәлешле анализ ясап, педагог, укытучы образын төрле вакыт чикләре күзлегеннән күз алдына китерү;

* проблемаларны ачыклау һәм чишелешләр табу өчен алшартларны ачыклау;

**Тикшеренү объекты: "укытучы" һөнәре.**

**Тикшеренү предметы:** "укытучы" һөнәренең абруен күтәрү ысуллары.

**Тикшеренү ысуллары:**

- Системалы караш һәм анализ ысулы.
- Социаль тикшерү ысулы.
- Җыелган мәгълүматларны системалаштыру һәм гомумиләштерү.

**Эшнең практик һәм теоретик әһәмияте.**

Хәзерге тикшеренү укыту эшчәнлеге белән кызыксынган мәгариф учреждениеләре җитәкчеләре һәм укытучылары, студентлар һәм мәктәп укучылары өчен кыйммәт бирә ала. Тикшеренү эше материалларын сыйныф сәгатьләре, профориентация буенча әңгәмәләр уздырганда, газетага мәкаләләр язу, презентацияләр ясау өчен кулланырга мөмкин.

## Төп өлеш

### 1 нче бүлек. Укытучы – дөньяда төп һөнәр.

#### 1.1 «Укытучы» һөнәренең асылы.

С. И. Ожеговның аңлатмалы сүзлегеннән без «1.Укытучы-берәр нәрсә өйрәтүче кеше, укытучы. Атказанган укытучы (мактаулы исем). 2. Тәгълиматның башы, берәр нәрсә өйрәтә (өйрәткән) кеше» дигән аңлатманы беләбез. Аның башка һөнәрләрдән төп аермасы шунда ки, ул бер үк вакытта үзгәртеп кору классына да, идарәче һөнәрләр классына да керә. Педагогның төп максаты – укучының шәхесен формалаштыруда ярдәм итү, аның белемнәрен баету, интеллектуаль һәм физик сәләтләрен үстерү, рухи дөньясын формалаштыру. Педагог һөнәрендә төп бурыч - иҗтимагый максатларны аңлау һәм башка кешеләрнең тырышлыгын аларга ирешүгә юнәлтү. Педагог, башка җитәкчеләр кебек, үзе җитәкчелек иткән укучылар эшчәнлеген яхшы белергә һәм тәкъдим итәргә тиеш.

#### 1.2 Педагогик һөнәрнең барлыкка килүе.

Тарихи җәмгыятьтә, примитив җәмгыять төзелеше вакытында, кеше әле язу уйлап тапмаган һәм эчке хисләр аша дөньяны танып белмәгән вакытта, укытучы төшенчәсе символик булган. Хезмәт коралларының катлаулана һәм камилләшә барган саен, хезмәт күнекмәләрен һәм осталыкларын тапшыру зарурлыгы барлыкка килгән. Нәсел өлкәннәре беренче тәрбиячеләр булып киткән, алар балаларны ут ягарга, ауга, кием тегәргә, хезмәт кораллары әзерләргә, яңа буынны киләчәк тормышка әзерләргә өйрәткәннәр

Тәрбия кеше эшчәнлегенең кирәкле өлкәсенә әйләнгән. Нәкъ менә шуңа күрә җәмгыять үсешен дәвам итә, чөнки өлкән буын үз тәҗрибәсен һәм белемнәрен яшь буынга тапшыра.

Унынчы гасыр елъязмаларында беренче мәктәпләр турында искә алына. «Повесть временных лет» әсәрендә :”Ул (кенәз Владимир) иң яхшы кешеләрдән балалар җыярга һәм аларны укытырга утыртырга җибәрде, " – диелә.

Шулай итеп, педагогик һөнәр барлыкка килгәннән бирле укытучы остаз һәм тәрбияче ролен берләштерә, яшь буынны тәрбияләүдә әйдәп баручы роль уйный.

#### 1.3 Кеше тормышында укытучының роле.

Укытучы һөнәре башка һөнәрләр арасында мөһим роль уйный, аның әһәмиятен инкарь итеп булмый. Чөнки нәкъ менә укытучылар укучының әхлакый, рухи һәм физик сәламәтлеге нигезләрен формалаштыралар, белемнәрен киләчәк буынга тапшыралар. Һәр кешенең шәхесен формалаштыруда укытучы остаз була, ул баланың интеллектуаль потенциалын үстерергә ярдәм итә, баланы дөнья турында белем алырга һәм баетырга дәртләндерә, патриотизм рухын тәрбияли, югары әхлакый ориентирлар бирә. Рухи-әхлакый

тәрбия Россия мәгариф системасында гамәлгә ашырыла торган укыту-тәрбия процессының аерылгысыз өлеше булып тора. Укытучы – ул, гаилә институты белән беррәттән, үз укучыларына, Россия Федерациясенең булачак гражданнарына рухи-әхлакый тәрбияне сеңдерергә тиеш, чөнки киләчәктә нәкъ менә алар хәзерге буынны алыштырачак һәм илнең таянычы булачак.

Россия империясенең бөек укытучысы Константин Дмитриевич Ушинский иде, ул Россиядә фәнни педагогикага нигез салучы булды. К.Ушинский исеме дөнья педагогикасында мөһим урын алып тора. Тәрбия, укыту процессларының асылын тирәнәйтү, әхлакый ышанулар формалаштыру һәм педагогик фикернең алдагы үсешенә йогынтысы буенча, фәнни нигезлелек дәрәҗәсе буенча аның концепциясенә тиңнәр юк.

Унынчы гасырның беренче яртысында яшәгән мәшһүр гарәп галиме Ибн Рустә үзенең бер язмасында: “Болгарларның күпчелеге ислам динен тота; шуңа да алар яши торган шәһәрләрдә, авылларда мәчетләр каршында башлангыч уку йортлары бар,” – дип билгеләп үтә. Дәверләр үткән саен халыкның аң-белемгә омтылышы үсә барган. Мәктәп ачу, мәдрәсә тоту традицияләре гасырлар аша килгән.

Тарихчыларның эзләнүләреннән күренгәнчә, Болгар дәүләтендә йөзләгән мәктәп мәдрәсә булган. «Галия», «Хөсәения», «Иж-Бубый», «Мөхәммәдия» һәм башка тарихка кереп калган мәдрәсәләребез – татар халкы мәгарифе нигезе булып тора. Аларда, дингә кагылышлы фәннәр белән беррәттән, дөньяви фәннәр дә укытылган.

## 2 нче бүлек. Укытучы: кичә, бүген, иртәгә.

### 2.1 Укытучы образының әдәби әсәрләрдә, кинематографиядә һәм массакүләм мәгълүмат чараларында чагылышы.

Укытучының җәмгыять тормышындагы роле турында сөйләүче үзебезнең сәнгать әсәрләрен өйрәнеп, аның эчке сыйфатлары тасвирлануын күреп, 20 нче гасырның 30-80 нче еллары чорында укытучының җыелма образын төзергә була.

Виктор Астафьев «Мин булмаган фотография» хикәясендә 20 нче гасыр уртасында укытучының образын, аның укучылар белән мөнәсәбәтен, педагогның үз һөнәренә мөнәсәбәтен, укытучы шәхесе алдында хөрмәтен һәм курку-хөрмәт хисен тасвирлый.

Валентин Распутинның «Француз дәресләре» повестендә укытучы образы автобиографик булып тора. Әсәрнең төп герое Лидия Михайловна француз теле укытучысы гына түгел, ул үз укучылары өчен әхлакый характердагы үрнәк булып тора.

Юрий Поляковның «Хаталар өстендә эшләү» повестендә 20-нче гасыр азагындагы авыр вакытта, Совет идеологиясе җимерелә башлагач, яңа тормыш идеалларына бирешеп, буыннарның бер-берсен аңлауда туган аерма тасвирлана.

Муса Җәлилнең “Беренче дәрес”, Ләлә Гыймадиеваның “Ике әни һәм бер математика”, Чыңгыз Айтматовның “Беренче мөгаллим”, Николай Носовның “Витя Малеев в школе и дома”, Илшат Сәйфуллинның “Җиденче дәрес” һәм башка әсәрләрдә дә укытучы образы яктыртылган.

Югарыда китерелгән авторларның каралган әсәрләрен анализлау нигезендә түбәндәге нәтиҗәләрне ясарга мөмкин:

• конкрет әсәрдә укытучының образы укытучы образын һәм аның бу чор җәмгыяте тормышындагы ролен чагылдыра;

• укытучы һөнәре һәрвакыт актуаль һәм кирәкле булды;

• укытучы-әхлак үрнәге, тормышта юнәлеш бирүче остаз;

• укытучыга аерым хөрмәт күрсәттеләр;

• чын укытучы җаваплылык, игелек, толерантлык кебек сыйфатларга ия;

• укытучы белән студент арасындагы махсус мөнәсәбәтләр һәм бәйләнеш үзара аңлашу өчен мөһим.

Мәгариф өлкәсендәге проблемалар тынып тормады, ә укытучы образы хәзерге Россия кинематографында идеальләштерелүдән туктады, кайчагында тулы, рөхсәт ителмәгән түбәнсетүгә кадәр барып җитте.

Мәктәп, укытучылар һәм укучылар тормышын күрсәтүче «Школа», «Барвиха», «Ябык мәктәп», «Классная Катя» кебек сериаллар федераль каналларда трансляцияләнде.

Безнеңчә, укытучы эшчәнлеге белән бәйле мондый кинокартиналар, әлеге һөнәр ияләренә тискәре караш формалаштырырга омтыла.

Ә "Кайда син?"дип аталган татар сериалы өч укытучы дус кызның язмышы турында хикәяли. Алар яшь, акыллы, белемле, яраткан һөнәрләре бар һәм бер мәктәптә эшлиләр. Аларны гомуми борчу берләштерә – шәхси бәхетләре булмау. Яшь кызлар тормышларын үзгәртергә телиләр...

### 2.2 Укытучы образын формалаштыруга тәэсир итүче факторлар.

Алдагы бүлектә әйтелгән заманча кинокартиналарны, телетапшыруларны анализласак, укытучы образы кимсетелә, педагог һөнәренең әһәмияте һәм җәмгыятьтә укытучының торышы ясалма рәвештә түбәнәя, димәк, яшь буын арасында һөнәрнең актуальлеге һәм абруе төшә дигән нәтиҗә ясарга мөмкинлек бирә.

Бу тенденциягә алшартлар булып, берничә төп фактор булырга мөмкин, ягъни:

- Масскакүләм мәгълүмат чараларында, кинематографиядә, әдәбиятта укытучы һөнәренең дәрәҗәсе түбәнәю;
- укытучы һөнәренең аз хезмәт хакы;

- белгечлек спектрын үзгәртү, һөнәрләрнең структурасын һәм эчтәлеген үзгәртү;
- мәгариф өлкәсендә квалификацияле педагоглар җитмәү;
- гаиләдә укытучыга хөрмәт күрсәтмәү, димәк, баланың хөрмәте булмау.

Нәкъ менә бу факторлар укытучы образын һәм аның җәмгыять тормышындагы ролен туплауга турыдан-туры йогынты ясыйлар.

**3 нче бүлек. «Туган телебезгә хөрмәт тәрбияләүчеләр "**

**3.1 Минем беренче укытучым**

“Хезмәте барның – хөрмәте бар”, дип юкка гына әйтмәгән бит халык. Авырлыклардан курыкмыйча эш яраткан, кулыннан эш килгән кешене бар да хөрмәт итә. Андый кешенең җирдә һәрвакыт үз урыны, үз юлы була. Хөрмәткә лаек кешеләр безнең мәктәптә дә бик күп. Шундыйларга мин укытучыларымны кертер идем. Чөнки аларның эшләре хөрмәткә лаек.

Минем беренче укытучым – Мингазова Резеда Галяуетдин кызы 1967 елның 31 гыйнварында туган. 1982 елда Түбән Кама педагогия училищесына укырга кергән. 1986 елда тәмамлый. 1986 елдан ул башлангыч сыйныфларда эшли. Педагогик стажы 36 ел. 31 нче мәктәптә 1998 елдан бирле эшли. Озакламый бу мәктәптә эшләвенә 25 ел була. 2003 елда Алабуга педагогия университетына укырга керә, 2008 елда тәмамлый. 2 улы һәм 5 оныгы бар, үз эшен һәм балаларны ярата, шуңа күрә ул пенсиядә булса да эшләвен дәвам итә. Бүгенгә кадәр күп укучыларының аналары белән элемтәдә тора һәм котлауларны шатлык белән кабул итә. Күп тапкыр мәктәп грамоталары белән бүләкләнгән. 2015 елда намуслы хезмәте өчен мәгариф идарәсенең Мактау грамотасы бар. 2020 елда «Мәгариф өлкәсендә күпьеллык уңышлы хезмәте өчен» Түбән Кама муниципаль районының Мактау грамотасы белән бүләкләнгән.

**3.2 Мәктәбебезнең туган тел укытучылары – безнең таянычыбыз**

*Бадгиева Эльза Даниязовна.* Ул Түбән Кама педагогик училищесында һәм Яр Чаллы дәүләт педагогик институтында укыган. Педагогик стажы 29 ел. Безнең мәктәптә 27 ел эшли. Төрле бүләкләргә ия: Россиянең иң яхшы укытучысың гранты җиңүчесе, «Мәгарифтәге казанышлары өчен» күкрәк билгесе.

*Садыкова Лидия Хамдегалиевна.* Ул 1994-1999 елларда Яр Чаллы педагогик институтында укыган. Педагогик стажы 30 ел. Безнең мәктәптә 27 ел эшли. Бүләкләре: РТ һәм РФ грамоталары. РТ “Мәгарифтәге казанышлар өчен” күкрәк билгесе.

*Фокеева Елизавета Павловна* 1985 нче елда Алабуга дәүләт педагогия институтын тәмамлаган. Рус теле һәм әдәбияты укытучысы булып, Түбән Каманың 10 нчы урта мәктәбендә эшен башлаган. Педагогик стажы 37 ел. 29 елын татар теле һәм әдәбияты

укытучысы булып эшли. 13 ел 31 мәктәптә балаларга белем һәм тәрбия бирә. Хезмәтен хөрмәтләп бирелгән бүләкләре: «Казанның 1000 еллагы» медале. ТР «Мәгарифтәге казанышлары» өчен күкрәк билгесе бар.

*Шәйхетдинова Рәфидә Әслаховна*. Ул Володя-Ульянов исемендәге Казан дәүләт университетында укыган. Педагогик стажы 41 ел. Безнең мәктәптә 13 ел эшли. Бүләкләре дә бар: 2009 елда «Мәгарифтәге казанашлары өчен» күкрәк билгесе, «Квалификация белгечләре гамәли эзерләүгә өлеш керткән өчен» 2013 ел мәгариф министрлыгы һәм Россия Федерациясе мактау грамотасы. 2021 елда «РФ мактаулы тәрбия һәм мәгариф хезмәткәре » күкрәк билгесе бар.

*Нәбиуллина Резеда Хәйдәровна*. Ул НПУда (1996-1999 ел) һәм НМИда (2009-2010 ел) туган тел һәм әдәбият укытучысы буларак белем алган. НГПУда (2017-2018 ел) рус теле һәм әдәбияты укытучы буларак белем алган. Педагогик стажы 23 ел. Безнең мәктәптә 9 ел эшли. Анын бик күп мактау грамоталары бар. “Ел укытучысы-2020” муниципаль конкурсның “Иң яхшы татар теле укытучысы номинициясендә лауреат .

*Һадиева Сиринә Әсхәтовна*. Ул Алабуга Дәүләт педагогика институтында укыган. Педагогик стажы 21 ел. Безнең мәктәптә 21 ел эшли. Бүләкләре бар: мәктәп грамоталары, РТ Түбән Кама муниципаль районы Башкарма комитеты мәгариф идәресе һәм мәгариф хезмәткәрләрнең мактау грамотасы (2017 ел). Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы башкарма комитетының Мәгариф идарәсенең мактау грамотасына (2022) лаек булган.

*Шамбазова Эльмира Гомәровна.* Ул 2005-2010 елларда Алабуга дәүләт педагогия университетында укыган. Педагогик стажы 12 ел. Безнең мәктәптә 12 ел эшли. Аның бүләкләре дә бар: Түбән Кама муниципаль районы башкарма комитетының Мәгариф идарәсенең мактау грамотасы (2017), «Укытучы-мастер» укытучыларның һөнәри үсеш гранты жиңүчесе ( 2011, 2012, 2014, 2015,2016 елларда) 31 нче мәктәпнең мактау грамоталары, 2022 елда «2023 ел укытучысы» Бөтенроссия һөнәри осталык конкурсынын мәктәп этабыгында 1 урын өчен мактау грамотасы беләң бүләкләнә.

## Йомгаклау

Укытучы һөнәре – дөньядагы төп һөнәр, чөнки нәкъ менә укытучылар илнең киләчәген формалаштыралар, яшь буынны өйрәтәләр һәм тәрбиялиләр. Нәкъ менә педагоглар укучының әхлакый, рухи һәм физик сәламәтлеге нигезләрен формалаштыралар, белемнәрен киләчәк буынга тапшыралар. Һәр кешенең шәхесен формалаштыруда Укытучы остаз була, ул баланың интеллектуаль потенциалын үстерергә ярдәм итә, баланы дөнья турында белем алырга һәм баетырга дәртләндерә, патриотизм рухын тәрбияли, югары әхлакый ориентирлар бирә.

Тикшеренү эше темасына материалны анализлау нәтиҗәсендә хәзерге этапта педагог һөнәренең әһәмияте һәм җәмгыятьтә укытучының позициясе ясалма рәвештә түбәнәюе ачыкланды, димәк, яшь буын арасында һөнәрнең актуальлеге һәм абруе төшә.

Без бу тенденциягә алшартларның түбәндәге факторлар булуын ачыкладык:

• Масскүләм мәгълүмат чараларында, кинематографиядә, әдәбиятта укытучы һөнәренең дәрәҗәсе түбәнәю;

• укытучы һөнәренең хезмәт хакы аз;

• белгечлек спектрын үзгәртү, һөнәрләрнең структурасын һәм эчтәлеген үзгәртү;

• мәгариф өлкәсендә квалификацияле педагоглар җитмәү;

• гаиләдә укытучыга хөрмәт күрсәтмәү, димәк, баланың хөрмәте булмау.

Мәгариф өлкәсендәге заманча вәзгыятьне анализлау нәтиҗәсендә без педагогик һөнәрнең абруе төшү һәм педагогик белем алырга теләмәү сәбәпләре булып торуын билгеләдек:

1. Материаль якның түбән дәрәҗәсе.

2. Укытучының социаль статусы түбән.

3. Конкуренция булмау.

4. Авыр эш шартлары.

Нәтиҗә ясап, шуны әйтәсе килә: нинди генә чорда яшәсәк тә, без намуслы хезмәт кешеләре булып көн итәргә тиешбез, шул чакта гына безнең барыр юлыбыз тигез булыр.

**Файдаланылган әдәбият:**


1. Антология педагогической мысли Древней Руси и Русского государства XIV-XVII вв. / Сост. С. Д. Бабишин, Б. Н. Митюров. - М., 1985. - С. 167.

2. Астафьев В. П. Сборник «Далекая и близкая сказка»: Рассказ "Фотография, на которой меня нет"- Иркутск, издатель Сапронов, 2008. - С. 274 - 302.

3. *Доклад Мусаткиной Елены: «Девальвация образа учителя в современном российском кино на примере сериала «Школа»*. **– 2010.**

4. Леонтьев А. Н. Общее понятие о деятельности // Хрестоматия по возрастной психологии. Под ред. Д. И. Фельдштейна.—М.: Междунар.педагогич. академия, 1994. — С. 112—121.

5. Макаренко А. С. Сочинения: В 7 т. - М., 1958. - Т. V. - С. 178.

6. Ожегов С. И. Словарь Русского языка - М., 1970.- С. 900.

7. Поляков Ю. М. Книга «Работа над ошибками»: Повесть «Работа над ошибками» - Издательство «Современник» 1989. – С. 256.

8. Распутин В. Г. Уроки французского. Повести: Рассказ «Уроки французского» - Издательство «Эксмо» 2004 - С. 607 - 638.

*Гилемханова Язилә, 9 сыйныф,*
*Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районының «Аерым фәннәрне тирәнтен өйрәнүле 31 нче гомуми урта белем бирү мәктәбе» муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесе*
*Җитәкчеләре: Фокеева Елизавета Павловна, Һадиева Сирена Асхатовна, туган тел һәм әдәбияты укытучылары*

# Табиб һөнәре (хирург белгечлеге мисалында)

## Кереш

Һәр кеше үзенең табигый сәләтләренә һәм омтылышларына туры килгән һөнәрне сайларга тиеш, ул чакта ул куркып түгел, ә намус белән эшләячәк. Яраткан эшенә кеше бөтен көчен, бөтен белемен бирсә, бу эш яхшырак үтәләчәк, нәтиҗә күбрәк булачак.

Әлбәттә, барлык һөнәрләр дә кирәк, алар җәмгыятьтә бертөрле һәм максатчан бүленергә тиеш. Ләкин һәр табиб, һәр укытучы, токарь, балта остасының киң күзаллауга ия булуы мөһим.

Табиб - иң асыл һөнәрләрнең берсе. Ул - яшәү рәвеше. А. П. Чехов әйткәнчә, табиб һөнәре - батырлык. "Ул җан һәм акыл чисталыгын таләп итә. Психик яктан саф, әхлакый яктан чиста һәм физик яктан пөхтә булырга кирәк". Табиб һәрвакыт игелекле һәм шәфкатьле булырга тиеш, чөнки ул эшләгән эш авыруның газапларын җиңеләйтә һәм аны үлемнән коткара. Табибларга кешеләр һәрвакыт аеруча ихтирам белән карыйлар, аларны кадерлиләр һәм хөрмәт итәләр. Табиб кулында - кеше тормышы, шуңа күрә табиб һөнәре һәрвакыт **актуаль.**

Табиб профессионал гына түгел, ул - иҗатчы.

**Эшнең максаты:** Хирург һөнәре формалашу үзенчәлекләрен өйрәнү.

**Бурычлар:**

1.Сайланган тема буенча фәнни әдәбиятны өйрәнү.

2.Медицина тарихы белән танышу.

3.Хирургия үсешенең үзенчәлекләрен карау.

4.Танылган хирургларның эшчәнлегенөйрәнү.

5. Медицина хезмәткәре һөнәренә ия булуның төп юлларын ачыклау.

Тикшеренү объекты: медицина, аның үзенчәлекләре һәм хәзерге вакытта кеше өчен әһәмияте.

**Тикшеренү предметы**: хирургия белгечлеге.

**Гипотеза:** һөнәрне дөрес сайлаганда һәм чын күңелдән өйрәнгәндә генә үз эшеңнең яхшы белгече булырга мөмкин.

## Төп өлеш

### 1.Табиб һөнәре тарихы

Табиб һөнәре күптән барлыкка килгән. Аны кешелекнең яшьтәше дип атарга мөмкин, чөнки кешеләр һәрвакыт авыруларның нәтиҗәсе булган уңайсызлыклардан яки кыенлыклардан арынырга тырышканнар. Соңрак, дин барлыкка килү белән, табиб функцияләре дәвалаучылар кулында туплана башлаган. Фәкать Аллаһы ярдәме белән генә авырудан арынырга ярдәм итү мөмкинлеге бар дип саналган (сүз уңаенда, "табиб" сүзе славян теленнән тәрҗемә иткәндә "сөйләшүче" яки "тылсымчы"дигәнне аңлата). Ләкин еллар узгач, уңышлы дәвалау процессы өчен кайбер белемнәр һәм күнекмәләр кирәклеге ачыкланган. Бүгенге көндә, хәтта медицина белән бәйле булмаган кешеләр, Гиппократ, Асклепиад, Цельс, Авиценна һәм башкалар кебек күренекле табибларның исемнәрен беләләр.

Табиб - беренче чиратта, яхшы хәтерле акыллы кеше, һәрвакыт камиллеккә омтыла һәм яңа белем ала. Медицина бер урында тормый бит. Табибның стресска каршы торуы мөһим, бигрәк тә сез хирургияне сайлаганда. Табиб намуслы булырга һәм критик ситуацияләрдә тиз карар кабул итә белергә тиеш. Кичектерелү авыру тормышын өзәргә мөмкин. Табиб шулай ук пациентка проблеманың асылын аңлатырга, тынычландырырга, дәвалауның мөһимлеген аңлатырга тиеш.

Табиб һөнәре тамырлары белән тарихи чорга – борынгы кешеләргә китә. Үткәрелгән казу эшләре кешеләрнең сынган урыннарны дәвалый алуларын раслый. Ул вакытта табиб дәвалап кына калмаган, рухлар белән дә аралашкан, тыйган һәм корбаннар китергән. Кыскасы, рухани ролендә чыгыш ясаган.

Кешелек тарихындагы һәр этап белән медицина да тиз алга китә. Төрле авыруларны дәвалау һәм диагностикалау өчен яңа белемнәр, техника барлыкка килә.

Борынгы бөек грек табибы Гиппократ барлык белемнәрне берләштереп, табиб һөнәренә нигез салучы булып тора. Нәкъ менә ул авыруларны чикләп алып кына түгел, ә сәбәпләренә нигезләнеп классификацияли башлаган. Галим төрле процессларны аера алган һәм һәркемгә билгеле Гиппократ анты кабул ителгән.

"Медицина" сүзе латин medicari сүзеннән килеп чыккан-дәвалау чарасын билгеләү. Ләкин медицина какшаган сәламәтлекне торгызу турында гына түгел, какшауларны кисәтү турында да кайгырта. Хәзерге көн күзлегеннән тулы билгеләмә буенча: “Медицина-фән өлкәсе һәм кешеләрнең сәламәтлеген саклау һәм ныгыту, авыруларны кисәтү һәм дәвалауга юнәлтелгән практик эшчәнлек”. Күп гасырлар дәвамында тәҗрибәле юл белән дәвалау чаралары һәм алымнар тупланган, алар шул исәптән халык медицинасында сакланган һәм (соңрак) өлешчә фәнни медицинага кергән. Вакыт узу белән медицина фәнни булып киткән.

Борынгы дөньяда табиб һөнәренең иң югары ноктасы- Гиппократ эшчәнлеге. Фәнгә тугрылыклы иң танылган борынгы дәвалаучы Гиппократ б.э. к. 460 елда Грек Коса утравында туган, аны еш кына "медицина атасы"дип йөртәләр. Гиппократ медицинада рациональ караш өчен нигез салган. Ул авыру аллалар җибәргән җәза дигән төшенчәне кире каккан, аның табигый сәбәпләр аркасында килеп чыгуын аңлаткан.

Мәсәлән, эпилепсия озак вакыт "изге авыру" дип аталган, чөнки аны илаһилар гына дәвалый ала дип уйлаганнар. Ләкин Гиппократ аның изге авыру түгеллеген, табигый сәбәпләрен аңлаткан. Гиппократ шулай ук төрле авыруларның үзенчәлекле билгеләрен күрүче һәм тасвирлаучы беренче билгеле дәвалаучы булган.

Гиппократ бер китапка медицина белемен җыйган - “Гиппократ коллекцияләре”. Ул фәнни медицинага башлангыч салган, чөнки диагноз куйганчы, авыруны тикшерү кирәклегенә нигезләнгән.

Аның китабында симптомнар һәм авырулар торышы тасвирланган. Беренче тапкыр тылсымга таяну урынына, дәвалау авыруны тикшергәч һәм өйрәнгәнгәч, шулай ук алдагы тәҗрибәләр нигезендә башкарылган. Заманча медицина шул ук принципларга нигезләнгән. Б.э. 2 гасырында антик медицинаның тәкъдимнәре грек Гален тарафыннан системалаштырылган; аны гарәп Ибн Сина тулыландырган. Бу система медицинада яңарыш чорына кадәр өстенлек иткән.

**2."Хирург"белгечлеге тарихы**

Хирург-авыруларны һәм җәрәхәтләрне диагностикалау һәм хирургик дәвалау ысуллары буенча әзерлек алган белгеч (табиб).

Хирургия безнең эрага кадәр үк барлыкка килгән. Ул вакытта баш сөяген трепанацияләү (алардан соң пациентлар еш исән калган), бөер ташларын чыгару, имгәнүләрне һәм башка җәрәхәтләрне дәвалау буенча операцияләр ясаганнары билгеле. Оператив катнашу турындагы беренче язмалар безнең эрага кадәр мең ярым ел элек Борынгы Һиндстанда барлыкка килгән. Ул вакытта анда беренче хирургия коралларының 100 дән артык исеме билгеле булган.

Урта гасырлардагы хирургия, гомумән алганда, медицина кебек үк, көчсезләнгән һәм начарланган. Кеше төзелеше турында белем алу омтылышы үлемгә китерергә мөмкин булган, кара тылсымга һәм иблиснең хәйләләренә тиңләшкән. Яңа үсеш Яңарыш чорында башлана. Бу чорда дәвалауга юнәлдерелгән иң кулай концепцияне эшләү максатыннан торышны күзәтү методикасы беренче тапкыр барлыкка килә. Бу чорның иң күренекле хирурглары Паре, Парацельс, Гарвей булып санала. Нәкъ менә Яңарыш чорында беренче тапкыр 1667 нче елда Франциядә танылган медицина галиме Жан Дени кан җибәрү процедурасын үткәрә. 19-20 гасырларда хирургия тиз үсә башлый. Анатомия турында төгәл белемнәр барлыкка килә. Шулай ук инфекцияләр, инфекцияләр таралу юллары һәм аларны булдырмау ысуллары ачыла.

Хирургия тар белгечлекләргә бүленә башлый, операцияләр үткәрүнең яңа эффектив ысуллары кертелә. Белем тиз үсә, бу көннәрдә яңартыла һәм тулыландырыла.

Табиблар бик белемле булырга тиеш.囊Эштә һәм белгечлек буенча нишләргә кирәк соң? Һәрбер хирург көн саен барлык белгечлекләр өчен уртак бурычлар спектры белән очраша: хирургия, медицина, дәвалау.

- Килгән авыруларны кабул итү һәм карау.
- Планлаштырган, планлаштырмаган оператив катнашулар уздыру.
- Операциядән соң тикшерү һәм өзлегүләрне булдырмау.
- Авыруларны тулысынча савыктырганчы күзәтү.
- Теккән урыннарны тикшерү, дәвалау сайлау, пациентларны җибәрү.

Бу кызыклы һәм җаваплы эш кенә түгел, ул организмдагы сыеклыклар, исләр һәм югары төгәллек, җаваплылык белән бәйле.21 гасыр-робот механизмнары ярдәмендә технологияләр, минималь инвазив хирургия һәм операцияләр үсеше чоры. Бу көннәрдә хирург - алыштыргысыз белгеч, ул көн саен кеше гомерен саклый. Хирургия - медицина белеменең иң күпкырлы һәм катлаулы тармакларының берсе, ул төрле юнәлешләрне үз эченә ала:

Проктология хирургиясе. Бу ректаль авыруларны оператив дәвалау. Бик төгәллек таләп итә торган шактый катлаулы һәм киң операцияләр. Еш кына тире катламына зур зыян китермичә ясала.

- Тире хирургиясе. Тумыштан булган таплар, полипларның үсешен бетерү. Пластика хирургиясе белән бик тыгыз бәйләнгән.
- Балалар хирургиясе
- Протезлау - иң зур һәм катлаулы тармакларның берсе.
- Кул чуклары хирургиясе.

- Гомуми хирургия-органнар һәм системалар буенча үз классификациясе булган киң тармак: йөрәк-кантамырлары (торакаль), эндокрин - эчке секреция бизләренә операцияләр. Хатын-кыз авырулары хирургиясе аналык проблемалары өчен җаваплы.
- Трансплантация - иң югары, төгәл тармакларның берсе, максималь белем һәм концентрация таләп итә.
- Нейрохирургия – бик төгәллек таләп итә, чөнки сүз баш мие һәм умыртка баганасы, нервлар белән эшләү турында бара.
- Авыз хирургиясе. Операция ясап, тумыштан да, җәрәхәтләр алганда да авыздагы кимчелекләрне төзәтү.
- Отоларингологик хирургия яки ЛОР-хирургия - өч орган зонасында операция: колаклар, тамак һәм борын.
- Акушерлык һәм гинекология. Шактый киң өлкә. Бу бала тудыру эшчәнлеген генә түгел, гинекологик операцияләрнең бик киң тармагын да үз эченә ала.
- Ортопедия. Бу бөтен гәүдәне һәм сөякнең дөрес формасын торгызу өчен хирургик интервенцияләр.
- Офтальмологик хирургия – күрү органнарында анны төзәтү яки җәрәхәт нәтиҗәләрен бетерү өчен операцияләр.
- Пластика хирургиясе. Бу косметик кимчелекләрне бетерү яки организмга камил формалар бирү өчен эшләнгән дәвалау.
- Онкология хирургиясе – яман шеш авыруларын дәвалау.
- Урология һәм андрология – җенес системасы белән эшләү. Соңгысы ир-ат проблемаларына гына махсуслашкан.
- Травматология. Бу өлкәдә универсаль хирурглар эшли, җәрәхәтләр китергән зыянны тиз арада дәвалау өчен карарлар кабул итә белү мөһим.
- Ветеринария- хайваннарга операцияләр ясау.

**3.Россиянең танылган хирурглары**

Совет һәм Россия медицинасында бик күп танылган медицина хезмәткәрләре бар. Россия медицинасы дөньяга бик күп танылган табиблар биргән:

Николай Иванович Пирогов (1810-1881)-хирургһәм анатомия белгече,

Владимир Петрович Филатов (1875-1956) -советофтальмологы,

Гавриил Абрамович Илизаров (1921-1992)-ортопед хирург,

Склифасовский һәм Боткин, Лео Бокерия һәм Рошаль, һәм башкалар.

Россиянең танылган кардиохирургы Ренат Акчурин. Ярты гасырдан артык ул кешеләргә хезмәт итә. Татар табибы, барыннан да элек, президент Ельцинга операция ясаган кеше буларак дан казана. Ул Казанда бик еш кунак. Татарстанның беренче затлары белән шәхсән таныш. 2006 елда Казанда Төбәкара клиник-диагностикалау үзәгенең яңа бинасы ачыла, яңа җиһазлар кайтарыла. Җирле хирургларны өйрәтергә Акчурин һәм тагын ике хирург килә. Аның эшен дәвам итүчеләр Р.К.Джорджикия, Г.И. Харитонов, А.Р. Садыков, И.И. Вагизов, М.Н. Мухарямов, Н.М. Гильфанов, И.В. Абдульянов- бүгенге көннең танылган кардиохирурглары.

**4. Бөек Ватан сугышы елларында хирурглар**

Гаскәрләрне дәвалау-эвакуация белән тәэмин итү системасындагы төп звено һәрвакыт хәрби кыр хирургиясе була, чөнки сугышларның иң массалы корбаннары — яралылар, шуңа күрә, элекке сугыш елларындагы кебек, Бөек Ватан сугышы елларында да, медицинада әйдәп баручы тармак буларак, хирургия ярдәмен оештыручылар була.

Яралыларга хирургия ярдәмен һәм дәвалауны оештыру принципларын эшләүдә хирургия хезмәтенең «югары эшелоны» — Кызыл армиянең баш хирургы академик Н.Н. Бурденко, аның урынбасарлары — профессорлар С. С. Гирголава, Б. С. Левит, В. Н. Шамовның өлеше зур.

Сугыш чорында Н.Н. Бурденко, берничә тапкыр инсульт кичерсә дә, хәтта каты авырудан тулысынча савыкмыйча, армияләрдә һәм фронтларда хирургия ярдәмен оештыру эшенә актив кушылган.

Фронтларның баш хирурглары арасында аеруча совет хәрби-кыр хирургиясенең күренекле оештыручыларын: М. Н.Ахутин, С. И.Банайтис, Н.Н. Еланский һәм П. А. Куприянов искә алырга кирәк.

Илебезнең медицина хезмәткәрләре, шул исәптән зур хирурглар отряды, сугышны Армия һәм флот солдатлары һәм офицерлары белән бер сафта үтеп, Ватан алдындагы бурычларын ахыргача үтәгәннәр.

**5. Ничек хирург булырга?**

Гомереңне багышларлык һөнәр сайлау җиңел түгел. Бүген яшьләр алдында һөнәр сайлаугаюллар бик күп. Авыруларга булышырга омтылучылар медицина хезмәткәре һөнәрен сайлый. Хирург һөнәре күптән билгеле һәм безнең илдә генә түгел, бөтен дөньяда танылган табиблар күп. Илнең медицина югары уку йортларына керүчеләр һәм аларга керергә теләүчеләр өчен таләпләр:

1. уку йортын (мәктәп яки гимназия) яхшы яки бик яхшы тәмамларга;
2. медицина хезмәткәре һөнәрләрен өйрәтә торган махсус уку йортына керергә;
3. медицина учреждениеләрендә практика узарга;

4. бөтен материалны намус белән өйрәнергә һәм практика үтәргә;

5. 6 елдан 8 елга кадәр укырга.

Әлеге һөнәр хәтере яхшы үсеш алган кешеләргә туры килә. Бу аеруча мөһим, чөнки алар көн саен кешенең эчке органнары белән эшлиләр һәм төрле хирургия манипуляцияләрен үткәрүнең үзенчәлекләрен истә тотарга тиешләр. Хирург төрле исләргә, авырлыкларга бирешми торган кеше булырга тиеш. Стресска каршы торуның иң югары дәрәҗәсе - хирургның мәҗбүри сыйфатларының берсе. Барлык операцияләр дә уңышлы тәмамлана алмый бит. Әлеге белгеч психологияне дә белергә тиеш: бу пациентлар белән аралашканда мөһим.

**6. Хирург булу өчен кайда һәм ничек белем алырга?**

Хирург белгечлеген һәм интернатура узу хокукын алу өчен, бу белгечлек булган медицина югары уку йортын сайларга кирәк. Россия Федерациясендә хирурглар әзерләү буенча барлыгы 15 иң дәрәҗәле медицина вузы исәпләнә. Түбәндәгеюгарыукуйортларыиндәрәҗәлесанала:

• Н.И. Пирогов исемендәге Рәсәй медицина университеты(Российский медицинский университет им. Н.И. Пирогова).

• И.И. Мечников исемендәге Төньяк-Көнбатыш медицина университеты(Северо-Западный государственный медицинский университет им. И.И. Мечникова).

• Академик И.П. Павлов исемендәге Санкт-Петербург дәүләт медицина университеты(Санкт-Петербургский государственный медицинский университет им. акад. И.П. Павлова).

• И.М. Сеченов исемендәге ПМГМУ (ПМГМУ им. И.М. Сеченова).

• Себер дәүләт медицина университеты(Сибирский государственный медицинский университет).

Хирурглар барлык медицина учреждениеләрендә (дәүләт һәм шәхси) кирәк. Гадәттә, карьера шифаханәдә эшләүдән башлана, анда белгеч интернатура һәм ординатура уза.

Эшкә урнашу җиңелме: югары уку йортын тәмамлагач, белгечне интернатура һәм ординатура узарга җибәрәләр. Аннан соң белгеч үзе практик күнекмәләр алган җиргә эшкә билгеләнә. Һәр белгеч үз көчен югары хезмәт хакы тәкъдим ителүче клиникаларда сынап карый ала.

Карьера гадәттә ничек төзелә? Хирург - абруйлы һөнәр. Күп белгечләр практиканы тәмамларга һәм карьера баскычына күтәрелергә тели. Тәҗрибәле хирург хирургия бүлеге мөдире яки соңрак баш табиб була ала. Тәҗрибәле белгечләргә шәхси клиника ачу мөмкинлеге дә бар.

**7.Хирургларның хезмәт хакы**

Россиядә хирургларга айлык хезмәт хакы 25000 сумнан 40 000 сумга кадәр, уртача сәгатьлек хезмәт хакы 150 сумнан 300 сумга кадәр.

| Хирургларның безнең илдә уртача хезмәт хакы | | |
|---|---|---|
| | айлык хезмәт хакы | сәгатьлек хезмәт хакы |
| Гомумән | 36 984 сум | 220 сум |
| Ирләр | 43 238 сум | 257 сум |
| Хатын-кызлар | 29 426 сум | 175 сум |

**Йомгаклау**

Хирург - абруйлы һөнәр. Хирурглар барлык медицина оешмаларында кирәк. Хирург төрле исләргә, авырлыкларга бирешми торган кеше булырга тиеш. Стресска каршы тора алу – һәр хирургның мәҗбүри сыйфатларыннан берсе. Барлык операцияләр дә уңышлы тәмамлана алмый, шуңа күрә әлеге белгеч психологияне дә белергә тиеш - бу пациентлар белән аралашканда мөһим. Дөньяда бик күп кызыклы, мөһим, файдалы һөнәрләр булуын исәпкә алсак, һөнәр сайлау җиңел түгел.Аларның кайсысы сиңа туры килә икәнен ничек аңларга? Шагыйрьләр язганча, барлык эшләр дә яхшы – җаның теләгәнен сайла. Ләкин, дөрес сайлау бик мөһим. Балачактан һөнәрләр турында күбрәк белергә, үз сәләтләреңне, омтылышларыңны, белемнәреңне бәяли белергә кирәк. Булачак һөнәрне иртәрәк сайлаган саен, аңа күбрәк әзерләнергә мөмкин.

Минем иң зур теләгем – хирург булу. Әлегә максатым - хирург һөнәре турында тулырак мәгүлүмат җыю. Һөнәрне дөрес сайлаганда һәм чын күңелдән өйрәнгәндә генә үз эшеңнең яхшы белгече булырга мөмкин. Шул вакытта гына ул кешегә шатлык китерәчәк.

**Кулланылган әдәбият**

1.Абакумов М.М. "Ранение сердца"; М. "Здравоохранение"; 2004г,112с.

2.Бусыгина И.К., "Ваш выбор. Сборник профессий…"; Н-Тагил 2001г;25с

3.Вишневский И.К., "Релапаротомия в хирургии желудка и двенадцатиперстной кишки"., 2005г., 400с

4.http://edunews.ru/professii/obzor/Medicinskie/hirurg.html

5. https://www.google.ru

6. www. edunews.ru/professii/obzor/Medicinskie/hirurg.html

7. www.kto-kem.ru/professiya/hirurg/

8. www. moeobrazovanie.ru/professions_hirurg.htm

9. https://ru.wikipedia.org/wiki/Хирургия

*Гилязова Нурзиля, 7 нче сыйныф,*
*Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районының "29нчы урта гомуми белем бирү мәктәбе" муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесе*
*Җитәкчесе: Чевачина Розалия Вакифовна, туган тел һәм әдәбияты укытучысы*

**Сезгә әйтер сүзем бар!**

(бу шигыремне мин армия хезмәтеннән качып йөрүче егетләрне күз алдында тотып яздым, ләкин бүгенгесе көндә илебезнең киләчәге өчен битараф булмаган ир-егетләребез шактый икәнлегенә инандым. Мин чын ир-егетләребез белән горурланам, аларның исән-сау туган йортларына әйләнеп кайтуларын телим!)

Муса абый, сезгә генә
Әйтер сүзем күбәйде.
Кайсысыннан башлыйм икән,
Кайсысы иң кирәге?
Нигә икән бу егетләр
Армиягә китмиләр?
Хезмәт итәргә кирәген
Әллә алар белмиләр?
“Ир-егетләр-ил тоткасы”-
Дигән сүзләр хак микән?
Акыллы, кыю егетләр
Кай җирдә яши икән?
Сыра белән томаланган
Күбесенең акылы,
“Компьтер”дип җенләнә
Егетләрнең “асылы”.
Йөрәк әрни, Муса абый,
Кем безне яклар икән?
Алай-болай сугыш булса,
Безне кем саклар микән?
“Алла үзе сакласын”,-дип
Теләргә генә кала,

Сезнең кебек егетләр юк,
Кем безне яклый ала?
Муса абый, кайда соң ул
Сезнең кебек егетләр?
Кыю, батыр һәм намуслы
Ныклы корыч кебекләр.
Заманадан артта калган
Тиле кыздыр мин, бәлкем,
Шагыйрь абый, соравыма
Җавап бирер икән кем?

**Заман хикмәтләре**

Көндәгечә иртә белән
Кабинетка керәбез.
Дәресләрне тагын бер кат
Хәтердән үткәрәбез.
Бүген иртән килеп керсәк,
Үзгәргән бит бүлмәбез.
Әллә нинди такта тора,
Аптырашта калдык без.
Интерактив такта бу, дип,
Аңлатты безгә апа.
Көне буе уйларыбыз
Булды гел шул хакта.
Менә дәрескә дә кердек,
Бу чынлап та могҗиза:
Бигрәк кызык такта икән,
Әйтерсең үзе яза.
Хаталарны да төзәтсә,
Шәп булыр иде дә соң.
“5”ләләр генә алыр идек,
Уйламаганнар шунысын.
Ә шулай да бу яңалык,
Дәресләр дә тиз үтә,
Презентацияләр карыйбыз-
Вакыт та җитми хәтта.

Әле менә уйлап куйдым,
Техника камилләшә.
“Бигрәк кызык укыйсыз”,-дип
Әниләр дә көнләшә.
Төрле фильмнар төзибез
Сыйныфыбыз турында.
Мондый кызыклы чаралар
Дуслаштыра тагын да.
Әле болай дәвам итсә,
“2”леләр дә булмас,
Алла бирсә, 3-4 елдан
Ялкаулар бер дә калмас.

**Үзгәрде бит Азамат**

Тәмле ашап, озак йоклап
Яши безнең Азамат.
“Уку качмас”,-дип җибәрә
Уйламыйча ул кайчак.
Укытучылар да әрлиләр,
Әнисе дә тузына.
Әллә аңа әйтәләр ди,
Әллә футбол тубына.
Уйлап та бирми Азамат,
Интернетта язынша.
Бертуктаусыз кино карый,
Кызлар белән таныша.
Көннәрдән бер көнне шулай
Айгөлгә күзе төшә,
Сырлый  ул гыйшык хатларын
Йөрәге  ешрак тибә.
Тик Айгөл генә нигәдер
Җавабын һич җибәрми.
Шундый матур Азаматның
Хатларын гүя күрми.
Хат артыннан хат сырлый ул
Мәхәббәтен аңлата.

Төшләрендә кызны күреп
Төннәр буе саташа.
Егеткә тик бер җөмлә
Ниһаять яза Айгөл:
“Мондый надан егет белән
Аралашасым юк гел.”
Әй гарьләнә соң Азамат,
Үпкәли ул, тузына.
Ләкин шушы секундтан ук
Укуга кереп чума.
Шушы бер җөмлә егетне
Әйтерсең алмаштыра.
Мәңге бирмәстәй тоелган
Зачетын да тапшыра.
Кайбер чакта бер сүз җитә
Тормышны үзгәртергә.
Айгөл кебек кызларга мин
Телим  рәхмәт әйтергә.

**Китап укы син, энем!**

Минем энемнең бөтенләй
Китап укыйсы килми.
Хәтта барлык туганнар да
“Заманасы шул бит”,-ди.
Булмагае, замана дип,
Надан калсынмени ул?
Интернет кына кирәкле
Мәгълүматны бирми шул.
Китап укыганда кеше
Хыяллана, хисләнә.
Үзең яшәгән дөньяга
Кайтып булмый тиз генә.
Китапларда тәрбия дә
Нечкә генә бирелә.
Шулай булса да, яхшылык
Күңелгә сеңдерелә.

Китап укыган кешеләр
Гел елмаеп яшиләр.
Тормыш авырлыкларына да
Алар һич бирешмиләр.
Китап укысаң син әгәр,
Аң – белемле булырсың.
Нинди генә хәлләрдә дә,
Кеше булып калырсың.
Энем, укы син китаплар,
Тыңла әле үземне.
Бервакытта сынатмассың,
Булырсың син гыйлемле!

**Булышыйк без кошларга!**

Кар-бураннарын туздырып,
Тагын кыш килеп җитте.
Ачы,салкын җиле белән
Күңелләрне өшетте.
Без анысы шаккатмыйбыз
Җылы туннар киябез.
Бияләй, бүрек, итекләр-
Җәйдән үк әзерлибез.
Ә канатлы дусларыбыз
Ничекләр соң түзәрләр?
Язгы көннәргә кергәнче
Тагын күпме кимерләр?
Азык табуы да авыр
Бу нәни кошкайларга.
Әйдәгез, әле бергәләп
Булышыйкчы аларга!
Һәрберебез берәр җимлек
Ясыйк әле, әйдәгез!
Ә үзегез җимлек элгәч,
Башкаларны өндәгез!
Җиңеләйтикчи хәлләрен,
Ясыйк матур җимлекләр!

Алар язын үзләренчә

Безгә рәхмәт әйтерләр.

Сөендерерләр сайрашып,

Күтәрерләр күңелне.

Кошлар сайравын ишетү

Булыр бик тә күңелле!

*Гыйрфанов Сөләйман, 6 сыйныф,*

*Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районының "7 нче урта гомуми белем бирү мәктәбе" муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесе*

*Җитәкчесе: Абдукаликова Ләйсән Тәлгать кызы, татар теле һәм әдәбияты укытучысы*

**Җәлил һәйкәле**

Муса Җәлил герой-шагыйрь,

Татарның бөек улы!

Күп авырлыклар күрсә дә,

Калды халкына тугъры.

Халкыбызның батыр улын,

Укып без соклanабыз.

Шәһәребездәге һәйкәлгә

Карап горурланабыз.

Шәһәрнең үзәгендә,

Кыю басып тора ул.

Ватанны яратыгыз!

Дигән кебек миңа ул.

*Домолазова Анастасия, 9 нчы сыйныф,*
*Фәйзуллина Динара ,7 нче сыйныф,*
*Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районының "аерым фәннәрне тирәнтен өйрәнүче 11 нче урта гомуми белем бирү мәктәбе" муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесе*
*Җитәкчеләре: Вагыйзов Фәрит Яхъя улы,*
*Фәйзуллина Гөлгенә Фәнис кызы,*
*татар теле һәм әдәбияты укытучылары*

## Такталачык авылы топонимик атамаларының килеп чыгышы

### Кереш

Безнең тормышыбызның беренче елларыннан ук географик атамалар көндәлек һәм даими рәвештә безнең аңыбызга керә, шәһәр, авыл, урамнар исемнәреннән башлап, туган йортыбыз урнашкан урамнардан башлап. Ә алар борынгы заманнарда ук барлыкка килгәннәр; аларның чыганаклары борынгы җәмгыятьтә барлыкка килгән. Меңнәрчә еллар буе алар җыелды, аларның саны артты. Язучы К. Паустовский әйткәнчә: «Исемнәре халыкның характеры, аның тарихы, һәвәслеге һәм көнкүреш үзенчәлекләре турында сөйли». Географик атамалар һәм исемнәр, аларны биргән халык турындагы истәлекләрен саклап, озак яшиләр. Географик атамаларның килеп чыгышын ачыклау, аларның формасы, мәгънәви озату белән шөгыльләнүче фән «топонимика» дигән грек сүзе белән күрсәтелә, аның нигезендә балта - «урын, урын» һәм оним - «исем».

Татарстанда 2023 ел Милли мәдәният һәм традицияләр елы дип игълан ителде. Бу хакта ТР Дәүләт Советына еллык юлламасында республика Президенты Рөстәм Миңнеханов белдерде.Мәдәни традицияләрне төбәкне өйрәнү мөмкин түгел, аның юнәлешләренең берсе - топонимика. Туган ил тарихын өйрәнү һәрвакыт актуаль булды, һәм ул бүген дөньяда сәяси тотрыксызлык хөкем сөргәндә аеруча мөһим.

Минем тикшеренү эше Актаныш районының Такталачык авылының топонимикасына багышланган. Минем уйлавымча, бу зур булмаган тикшеренү кече Ватаным тарихына кечкенә өлеш булачак.

Минем эшнең тикшерү объекты булып топонимика һәм микротопонимика тора. Такталачык авылының топонимнары һәм микротопонимнары тикшеренү предметы булып тора. Эшнең максаты: авыл топонимнарын һәм микротопонимнарын географик

объектларның, тарихның, тел мәдәниятенең үзенчәлекләрен һәм анда яшәүчеләрнең традицияләрен чагылдыру буларак тикшерү. Тикшерү максаты, объект һәм тикшерү предметы нигезендә түбәндәге бурычларны хәл итәргә кирәк: - Такталачук авылының һәм аның тирәсендәге топонимнарын һәм микротопонимнарын җыярга һәм классификацияләргә; - топонимнарның һәм микротопонимнарның исемнәре килеп чыгышын ачыкларга.

Такталачык авылының тарихи-этнографик характеристикасы.

Такталачык авылы Актаныштан 9 чакрым көнбатышта Шәбез елгасы бассейнында урнашкан. Авыл тирәләре бронза гасыр һәм урта гасыр чорларында яшәгән, археология һәйкәле шул хакта сөйли: бура, чиркәс, чиялек культураларына карый торган «Такталачык» комплексы. Гәрәй башкортлар, башка мәгълүматлар буенча, типтәрләр тарафыннан нигез салынган. Инкыйлабка кадәрге чыганакларда 1702 елдан Югары Такталачык, Иске Такталачык кебек тә телгә алына. XVIII-XIX гасырларда халык кан тамырлары ягыннан башкорт-вотчиннарга һәм типтәрларга бүленә. Игенчелек, терлек асрау, он җитештерү белән шөгыльләнгәннәр. 1773-75 елгы крестьян сугышы чорында Е.И. Пугачёв ягында актив чыгыш ясыйлар. XX гасыр башында авылда волость идарәсе, полиция урядникгы фатиры урнашкан; 2 мәчет, мәдрәсә, земство хастаханәсе, 8 җил тегермәне, бакалея кибете, икмәк запасы кибете эшләгән. 1920 елга кадәр Уфа губернасы Минзәлә өязенең Шәрип (Такталачык) волостеның үзәге була. 1920 елдан ТАССРның Минзәлә кантоны составында. 10.08.1930 елдан Актаныштa, 01.02.1963 елдан Минзәләдә, 12.01.1965 елдан яңадан Актаныш районында. 1929 елда авылда «Таң» колхозы оеша. 1994-2003 елларда авыл колхозы «Таң» кооперативларын берләштерүгә үзгәртеп корыла, соңрак - «Таң» ҖЧҖ. 1930 елда авылның хастаханәсе үзәк район хастаханәсенә үзгәртелә, үзгәртеп кору елларында «Аккош» шифаханәсенә үзгәртеп корыла. Гасыр башында халык саны ике меңгә җиткән, хәзер якынча 850 кеше яши. 2022 елгы халык санын алу нәтиҗәләре буенча, авыл халкының милли структурасында татарлар 100% тәшкил иткән. Авылда тарихи-мәдәни мирас һәйкәлләре сакланган: земство хастаханәсе бинасы (1914 ел), классик юнәлештәге эклектика стилендәге гражданлык архитектурасы һәйкәле. 1919 елның ноябрь-декабрендә крестьян чыгышы (сәнәкчеләр восстаниесе) вакытында җәзалап үтерелгән Такталачык башлангыч мәктәбе укытучысы С. И. Фәйзуллин кабере участок хастаханәсе территориясендә урнашкан (1984 елда обелиск куелган). Авылның күренекле кешеләре - Гамил Афзал (1921-2003) - Татарстанның халык шагыйре, ТАССРның Г.Тукай исемендәге Дәүләт премиясе лауреаты, Мохтар Мутин (1885-1941) - драматик актер, ТАССРның атказанган артисты; Н. С. Нургалиев - Татарстанның атказанган химигы; А. Б. Фәйрушин (1943 ел) -ТРның атказанган мәдәният хезмәткәре; Ф. Г. Фәррахов (1944 нче рәсем) -

педагог, Татарстанның атказанган укытучысы; Ленар Шаех (1982 нче рәсем) - шагыйрь, филология фәннәре кандидаты һәм башкалар.

Топонимик тикшеренүләр сүзнең килеп чыгышын яки конкрет географик объектны билгеләү һәм урам, елгалар, таулар исемнәренең мәгънәви әһәмиятен ачыклау өчен кулланыла торган сүзләрне берләштерүне күздә тота. Топонимика географик атаманың башлангыч дөрес язылышын һәм әйтелешен торгызганда, шулай ук агымдагы яки үткән (борынгы географик атамалар өчен) конкрет урынның халәтен тасвирлау өчен кулланыла.

Борын заманнарда Актаныш районы урнашкан җирләрдә кара урманнар булган. Аю (аю), Бурсык (барсук), Кабан, Куян (куян), Еланово (җылан - елан), Әтәс (әтәч), Түке (күке-күке курчагы) авылларында бүгенге көнгә кадәр сакланып калган атамалар моны раслый. Такталачык авылы бүген дә булган урында тиз генә барлыкка килмәде. Авылның барлыкка килүе турында түбәндәге риваять сакланган. Башта күчмә башкортлар кечкенә елга янындагы зур аланлы урманга килеп урнашалар. Бу хәл XVII гасыр ахыры - XVIII гасыр башында була. Җирлеләр урманны кисү белән шөгыльләнгәннәр һәм башта үзләре өчен кечерәк кенә корылма: алачык яки шалашлар төзегәннәр. Алар такталардан - берничә өлешкә ярылган бүрәнәләрдән була. Бу урынны "Такта алачык" дип атый башлыйлар. Татар теленнән тәрҗемә иткәндә «алачык» икенче - «тимерче алачыгы» дигән мәгънәгә ия. Урманны кискәннән соң, кешеләр ул тирәне сөреп игенчелек белән шөгылләнә башлыйлар, бал кортлары үрчетәләр, балык тоталар.

Хәзерге вакытта авылда төп сигез урам бар. Үзәк - авылның күренекле шагыйре, Тукай премиясе лауреаты Гамил Афзал урамы. Авылның көнбатыш өлешендә Пролетарская һәм Медицина урамнары урнашкан (анда хастаханә урнашкан). Иң озыны - Кооператив, анда әле инкыйлабка кадәр үк сәүдә кибетләре булган, параллель рәвештә Пионерская урамы сузыла. Яшьләр, Мәктәп һәм Нарат урамнары заманчарак булып тора. Авылның көнчыгыш читендә Мохтар Мутин урамы урнашкан. Ул авылда туып үскән, узган гасырда Татарстанның күренекле трагик актеры хөрмәтенә аталган. Авыл тыкрыкларының борынгы исемнәре дә кызыклы: Кәҗә сукмагы, Аръяк мәчете тыкрыгы. Бүген авыл тыкрыкларын йортлары янәшә урнашкан кешеләр исеме белән атыйлар. Мисал өчен, Фоатлар тыкрыгы, Нәсимнәр тыкрыгы, Рафаэль тыкрыгы һәм башкалар.

Такталачык авылының топонимнар, микротопонимнар сүзлеге һәм аларның килеп чыгышы.

Агыйдел елгасы

Ары киртә урамы

Аръяк урамы

Бурсык тавы

Бүләк урманы

Гәрәй урманы

Зариф бакены

Зират юлы

Каракай чокыры

Медицина урамы

Наратлыкүл чишмәсе

Нүрек тавы

Ташлыкай  чокыры

Түбән очка урамы

Түмерҗә авылы

Чалманарат урманы

Убырлы чокыры

Унынчы квартал урманы

Усаклы куак

Уразай болыны

Уразай күпере

Уразай таллыгы

Урта урам

Урыс базы

Урта урам көтүлеге

Үләт базы

Шәбез елгасы

Чөгәнә болыны

Чәбе болыны

Әҗмәт болыны

Өлкәр  тавы

Әҗмәт авылы

Югары оч урамы

Яңа урам

Яшьләр урамы

Галимнәр топонимнарны төрле типларга бүләләр:

оронимнар - тау атамалары (б.-греч.ὄρ□;ς «возвышенность», «тау), хоро́нимнар - чикләнгән җирлек исемнәре (грек ур.όρος;ς.«межевой знак», «чик», «рубеж»), табигый хоронимнар - теләсә нинди табигый ландшафт өлкәсе атамасы, административ хороним -

рәсми документларда кабул ителгән административ-территориаль берәмлек һәм урбаномика объектлары (торак мәйданнары, авыл-шәһәр урамнары исемнәре), гелóнима - сазлык атамалары (грекча τέμα α α;α «стоячая вода», «болото»), агроонимнар - җир кишәрлеге, (грекча ур.ἀγρόςς «поле», «пашня») һәм микротопонимнар - кечерәк объектларның исемнәре (грекчадан?μμ`╼`μ``╼»).

Бу типологиядә су объектларының атамалары зур урын алып тора (грек. ὕδωρ «су») Алар төп 3 төргә бүленәләр: потамоним - елгаларның атамалары (грек. ποτἄμό`ς «елга») , лимномнар - күлләр, буалар һәм башка йомык сулыклар атамалары; океанонимнар - теләсә кайсы океан һәм аның диңгез өлешләре атамалары.

Агыйдел (потамоним). Такталачык авылы Агыйдел ярыннан 4 чакрым биеклектә урнашкан. Бу елганың исеме ике киң таралган - Ак һәм Агыйдел. Башкортлар аны Агыйдел дип атыйлар («ак елга», «ак Идел»). Бер версия буенча елга көньяктан, кояштан аккан атаманы алган, шуңа күрә "якты", "ак". Башка версия буенча аны шулай дип атадылар. Икенче версия буенча аны эретелгән известь күп булу сәбәпле аксыл төстәге су дип атадылар. Елга башы башкортлар борынгы бабаларыбыз санаган Иремель тавыннан көнчыгышка таба урнашкан.

Шәбез - Агыйдел елгасының сулъяк кушылдыгы. Озынлыгы 35 километр. Бассейнның мәйданы 335,5 кв. км. Актаныш районы территориясе буйлап ага. Апас авылыннан көньяк-көнчыгыштарак урнашкан чишмәдән башлана, Агыйдел елгасына Такталачык авылыннан 3 км көньяк-көнчыгышта килеп кушыла. Топоним "Шәбез" гидронимыннан һәм "баш" гидрографик терминыннан (чишмә, башлангыч) булган.

Ыштанчык елгасы (потаномим). Шәбез елгасының култыгы, елга тамагыннан 1,5 километр ераклыкта. “Ыштанчык” гидронимының килеп чыгышы халык риваятенә нигезләнгән. Авылдашлар сөйләве буенча, бик күптән инде, су буенда коенганда, җирле крестьян чалбарын югалткан һәм яр буенда озак кына “ыштан, чык!” дип кычкырып йөргән.

Күпер колагы гидроним да Шәбез елгасы белән бәйле. Исеме «күпернең колагы» дип тәрҗемә ителә. Элек аулак урында урнашкан, печәнлек вакытында гына кулланылган зур булмаган агач күпер су басу зонасына эләккән һәм хәзер су астына яшерелгән.

Шәбез тамагы гидронимы конкрет географик урынны - Шәбез елгасы тамагын аңлата. Ягъни Агыйдел белән кушылу урыны.

Иске Идел (гидроним) дип Агыйделнең зур утрау белән аерылып торучы елга култыгы атала.

Шарлама - Шәбез елгасы тугаендагы ермак, «шарлама» төркичә «шарлама», ул «шарпад, агым» дигәнне аңлата.

Такталачык авылының тирә-ягында күлләр бик күп. Моннан берничә гасыр элек Агыйдел елгасы, авылдан ерак түгел генә үтеп, үзәнлектә зур борылыш ясап аккан. Ләкин тора-бара зур елга үзенең үзәнен турайта, күп кенә елга култыклары күлгә әверелә. Менә бу топонимнарга берничә мисал:

Кәрге күле (лимноним). Бу күл Агыйдел елгасыннан 500 метр ераклыкта, Бурсык авылыннан ерак түгел сазлыклы урында урнашкан. Төрки теленнән «карга» сүзе 1.карга (кош); 2. Урман, күл, топь; фин –угор телләреннән “сазлык”, “сазлык арасындагы калкулык” дип тәрҗемә ителә.

Киндер күле (лимноним): куптәнге заманда киндер тукыма (татар телендә киндер) әзерләгәндә, чималны сулыкларда чылатып эшкәрткәннәр. Картларның сөйләүләре буенча, бу күл бик тирән, урыны-урыны белән 7-8 дилбегә (15-20 метрга) җиткән.

Бәкелде күле (лимноним): күленең исеме “бакылдый” фигыль сүздән килеп чыккан. Борынгы заманнардан бирле бу күлдә бик күп кыргый үрдәкләр яшәгән.

Чәйлекүл (лимноним) исеменең килеп чыгуыда бик гади. Тирә-юньдә камышлар күп булганлыктан, мондагы сулыкның төсе һәрчак коңгырт төстә. Шунысы кызыклы, күл тирәсендә җирле халык чәйгә өстәргә яраткан хуш исле үләннәр(зәңгәр һәм сары мәтрүшкәләр) бик күп үсә.

Мүкле күл (лимноним): бу күлдә элек агач буралар төзегәндә кулланыла торган мүк табалар иде.

Камышлы күл (лимноним) - Камышлы күл.

Авыл җирлегендә җир кишәрлекләренең исемнәрен - сөрүлекләрне, кырларны һәм башка авыл хуҗалыгы җирләрен билгеләү өчен топонимнар төре булган агроонимнар бик күп. Термин Н. В. Подольскаяның 1988 елда рус ономастик терминологиясе сүзлегендә эшләнгән һәм тәкъдим ителгән. Такталачык авылы тирәсендә печән әзерли торган болыннар күп, һәм инкыйлабка кадәр крестьяннар бу җирләрне хәтта башка авылларда яшәүчеләргә арендага да биргәннәр. Аларның кайберләренең исемнәре:

Чәбе болыны (агрооним) . Исеме татар телендәге «чабу» фигыленнән килеп чыккан, бу – печән чабу дигән сүз. Түбән Кама районында да шуңа ошаш топоним бар. Әмма галимнәр “Чабья” сүзенең удмурт телендәге «чабей» - бодай сүзенә катнашы бар дип фаразлыйлар, шулай ук бу сүз удмуртларның нәсел шәҗәрәсенә барып тоташа.

Әҗмәт болыны (агрооним) - Әҗмәт болыны, күрше авыл исеме белән. Уразай болыны шул җирләрнең элеккеге хуҗасы исеме белән аталган.

Чатлыкай болыны (агрооним) - «чат» сүзе татарча икегә аерылучы юл чаты дигәнне аңлата.

Бишенче басу - бишенче кыр (ераграк), элек күрше авыл җире булган.

Уразай таллыгы - авылга нигез салучыларның берсенең исеме буенча.

Актаныш районында ороним терминологиясе нигезендә төзелгән бик күп топонимнар бар. Такталачук авылы тирәсендә түбәндәге атамалар оронимнар белән бәйле: Кашлак тавы - зур булмаган калкулык, җиләк урыннар; Бурсык тавы – бурсыклар күп яшәгән урын , анда элек аучылык җирләре булган.

Нүрек тавы - алтмышынчы елларда Актаныш юлында барлыкка килгән зур булмаган калкулык. Ул елларда СССРда Нурек ГЭС ы төзелде, бәлки, җирле атама бу вакыйга хөрмәтенә барлыкка килгәндер (Россиянең барлык шәһәрләрендә дә, шул исәптән Түбән Камада да, ерак торак районнарны "БАМ", "Тында" дип атый башлаганнар).

Ташлыкай калкулыгы - Кашлак тавы янындагы урын, анда ташлы комлык бар, төзү материалы итеп кулланыла.

Гайшә күпере. Бу урын узган гасырның егерменче елларында булган Такталачук авылы тарихында булган фаҗигале вакыйгаларның берсе белән бәйле. 1920 елда Совет хакимиятенә каршы сәнәк күтәреп күтәрелгән крестьяннар бу җирдә авыл активистларын, шул исәптән авыл мөгаллимнәрен дә үтергәннәр.

Әбугали баткаклыгы. Бу топоним шулай ук тарихи вакыйгага нигезләнгән. 1910 нчы елны авылда земство больницасы төзелә башлагач, Агыйдел буенча баржалар белән кызыл кирпеч алып киләләр. Ярга бушатылган кирпечләрне ат арбаларына төяп ташыйлар. Ул елны ташу көчле була, Әбугали исемле бер кеше аты белән адашып сазлыклы урында батып үлә.

## Йомгак

Шулай итеп, без бу эштә топонимнарның никадәр киң тикшерелүен, аларны өйрәнү һәм системага салу алымнарының төрлелеген, шулай ук Актаныш районы Такталачык авылы топонимиясен төрле яктан анализларга тырышып карадык. Башкарылган эшкә йомгак ясап, куелган бурычлар үтәлде дип әйтергә мөмкин: 1.Билгеләп үтелгәнчә, авыл һәм аның тирә-ягындагы атамалар очраклы рәвештә генә сайлап алынмаган, алар бу урыннарның географик һәм башка үзенчәлекләрен тәфсилләп аңлаталар.

2. Топонимик атамалар авылыбызның барлык халкы өчен бик зур әһәмияткә ия, чөнки аларда якын һәм бөек кешеләр турында, күңелгә якын җирләр, кече Ватаныбызның бөеклеге турында истәлекләр яшәвен дәвам итә.

Авылдагы топонимнарга һәм микротопонимнарга лингвистик анализ ясаганда, тарихи документларны, шулай ук кайбер географик объектларны өйрәнгәч, исемдә халыкның якты һәм үзенчәлекле тарихы чагылган дигән нәтиҗәгә килдем. Киләчәктә туган якның микротопонимнарын өйрәнү эшен дәвам итәргә планлаштырам, чөнки барлык мәсьәләләрне дә хәл итеп булмады, күп кенә исемнәрне аңлату үз чишелешен көтәләр. Алга

таба «Такталачык авылының һәм аның тирәлегенең топонимик сүзлеген» төзүне дәвам итәргә, шулай ук топонимнар һәм микротопонимнар мәгълүматлары буенча табигать объектларының фотоальбомын төзергә планлаштырам.

Авылның топонимик характеристикасын төзү кече Ватан тарихы буенча белешмәләр өстәргә, кыйммәтле материалны язып алырга һәм сакларга мөмкинлек бирде. Топонимнар – туган якны комплексы өйрәнергә мөмкинлек бирә торган төп юнәлешләрнең берсе. Хәзер үткәрелгән тикшеренүләр нәтиҗәсендә нинди дә булса географик атамалар, Такталачык авылы топонимнары югалган дип курыкмаска мөмкин. Россия картасыннан югалган күп кенә торак пунктлар белән булган кебек, безнең Такталачык авылы да юкка чыга ала. Минем тикшеренү эшендә җыелган материалларны тарих, география һәм туган якны өйрәнү дәресләрендә кулланылырга мөмкин.

Кулланылган әдәбият исемлеге:

1.Татарстан Республикасының административ-территориаль бүленеше (белешмәлек) / Татарстан Республикасы Премьер-министры Р.Н. Миңнеханов редакциясендә. Казан: Инновацион технологияләр үзәге, 2005. 456 б.

2.Әсфәндияров А. З. Минзәлә башкортлары. - Уфа: Китап, 2009. - 410-421. - 600 с. - ISBN 978-5-295-04952 -

3. Башкорт ыруының тарихы. Гирей. / С. И. Хәмидуллин, Ю. М. Йосыпов, Р. Р. Асылгужин, Р. Р. Шәйхиев, Р. М. Рыскулов, А. Я. Гомәрова, Г. Ю. Галиева, Г. Д. Солтанова. - Уфа: Уфа полиграфкомбинаты, 2014. Т. 2.

4.Гарипова Ф.Г. Татарстан гидронимиясе буенча тикшеренүләр. М.: Фән, 1991

5. Суперан А. В. Нәрсә ул топонимика? М.: Наука, 1985. 182 б.

6.Такталачук © 2021. Tatarica. Татар энциклопедиясе - 528 с

7. Уфа өязе татарлары (1722-1782 елгы халык санын алу материаллары). / Р.Р. Исхаков. - Казан: ТР Фәннәр академиясенең Ш.Мәрҗани исемендәге тарих институты, 2020. С. 64. 192 б.

Электрон чыганаклар:

1. https://tatarica.org/ru/razdely/municipalnye-obrazovaniya/

2. https://tatarica.org/ru/razdely/priroda/gidrograficheskaya-set/reki/shabiz

*Еремеева Ильвина, 8 нче сыйныф,*
*Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районының "28 нче урта гомуми белем бирү мәктәбе" муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесе*
*Җитәкчеләр: Мингәрәева Гөлсара Минрәхим кызы, Гыйлфанова Гөлназ Рәшит кызы*
*татар теле һәм әдәбияты укытучылары*

## Иске Рәҗәп авылы топонимикасы

### Кереш

Хәтерләүдән курыкма син!
Үткәнеңне онытма син!
Бел син ерак бабайларның
Ничек итеп көн иткәнен,
Нинди уйлар, нинди моңнар
Безгә калдырып киткәнен...

Равил Фәйзуллин.

Мин Иске Рәҗәп авылының тарихы белән кызыксына башладым һәм бу мине фәнни эшкә этәрде. Эзләнү эшләре алып барганда, мин өлкән буын кешеләре белән элемтәгә кердем, алар миңа авылдагы атамаларның мәгънәләрен тирәнрәк аңларга ярдәм иттеләр. Авылның тарихын, аның килеп чыгышын, андагы атамаларны белү бик кирәк. Без дә бит үзебездән соң килгән буынга белгәннәребезне тапшырырга тиешбез.

Фәнни-эзләнү эшемдә күтәрелгән темам актуаль дип саныйм, чөнки туган телеңне белү, халкыңның гүзәл йолаларын, гореф-гадәтләрен, нәселеңнең килеп чыгышын, үз туган ягыңның тарихын өйрәнү - һәр кешенең изге бурычы. Борынгы бабаларыбыз бик белеп әйткәннәр: үзебезнең үткәнебезне, килеп чыгышыбызны, тарихыбызны яхшылап белми, өйрәнми торып, без тыныч кына киләчәгебезгә атлап керә алмыйбыз.

Топонимик атамаларның аталу тарихын тикшерү - туган як тарихын өйрәнү дигән сүз. Нәрсә соң ул топонимика? **Топонимика** - географик атамаларның (топонимнарның) җыелмасын, аларның килеп чыгышын, ясалышын, кулланылыш һәм үсеш эволюциясен, мәгънәсен, таралышын өйрәнә һәм тикшерә торган фән.

**Тикшеренү эшенең максаты**: төрле чыганаклар аша Иске Рәҗәп авылы микротопонимнарының аталу тарихларын өйрәнү, аларны төркемнәргә бүлү һәм нәтиҗә чыгару.

Максатка ирешү өчен түбәндәге **бурычлар** билгеләнде:

- фәнни әдәбият белән танышу;
- авылның өлкән кешеләреннән микротопонимнар тарихын сөйләтеп язып алу, материал туплау, язмаларны редакцияләү;
- географик объектларны фотога төшерү.

Эшнең төп **объекты:** Иске Рәҗәп авылы, аның су чыганаклары, калкулыклары, урман-аланнары, урамнары.

Эзләнү эшенең **предметы:** Иске Рәҗәп авылының географик атамалары тарихы.

**Гипотеза:** һәрбер җирле атама нигезендә авылның тарихи үткәне турында мәгълүмат ята, дип уйлыйм.

Кулланылган **методлар:** эзләнү, тикшеренү, күзәтү, анализлау, гомумиләштерү, нәтиҗә чыгару.

Эшнең **яңалыгы** шунда: мин сайлаган тема моңа кадәр районда һәм мәктәп тарихында махсус тирәнтен өйрәнелмәгән.

Тикшеренү эшенең **практик әһәмияте:** эш укучыларда туган як тарихына кызыксыну уятыр, татар теле, география, тарих укытучылары, топонимика белән кызыксынучылар өчен файдалы кулланма булыр, дип уйлыйм.

## Төп өлеш

## Иске Рәҗәп авылы микротопонимнары тарихын өйрәнү

### 2.1.Торак пункт һәм аерым урын атамалары.

### Иске Рәҗәп атамасының килеп чыгышы.

Авылыбыз Шәһри Болгар территориясендә урнашкангадырмы, тарихи мәгълүматлар бик күп һәм кызыклы. Борынгы заманнардан ук безнең Иске Рәҗәп авылы бик зур һәм танылган авылларның берсе булган. Монда төрле чорда, төрле сәбәп белән әледән-әле зыялы кешеләр килеп йөргән һәм авылыбыз тарихында якты эз калдырганнар. Мәсәлән, Шиһабетдин Мәрҗәнинең 1872 елда безнең авылга сәяхәт кылуы турында язган язмалары шуны дәлилли.

Авылыбызга кайчан нигез салынуы турында төгәл мәгълүматлар юк. Легендалар, авылыбызга Рәҗәп атлы Шәһри Болгарның зур кешесе килеп, 1680 елда нигез салган дип сөйли. Әлеге бабай килгән вакытта, бу урында кап-кара урманнан башка берни булмый. Шуннан соң әлеге территориядә Иске Рәҗәп авылы әкренләп торгызыла башлый. Авылыбызның хәзерге исеме Иске Рәҗәп дип йөртелсә дә, 1958 елга кадәр Старый Баран

атамалы була. Нишләп Старый Баранмы? Риваятьләргә караганда, Патша Россиясе вакытында халык санын исәпкә алу үткәрелә. Екатерина 2 нче патшалык иткән вакытта, халык санын алучы рус чиновнигы көзге пычрак көннәрнең берсендә авылыбызга халык санын алырга дип килә. Аяк киемен пычратып, каретадан төшеп тормас өчен, авыл халкыннан кычкырып кына бу нинди авыл икәне белән кызыксына. Русча белмәгән авылдашларыбыз, юл сорый дип, "бара-бара"- дип җавап бирәләр. Бу хәл күрше авылда да кабатлана. Чиновник узенең ведомостена безнең авылны "Старый Баран" дип, күрше Чәчәкле авылын "Новый Баран" дип язып куя. Чынлап та шулай булганмы, юкмы икәнен беркем дә әйтә алмый. Ләкин 1695 елның 3нче декабрендә Петр 1нче патшаның Иске Рәҗәп авылы халкына җир бүлеп бирү турындагы приказында авылыбызның исеме Старый Баран дип атала. Ничәмә еллар буе авыл исемен алыштырыр өчен көч куела. Ләкин туган җиребезнең чын исемен законлаштыруга омтылышлар Сталин үлгәннән соң гына тормышка аша.

**Изге җир "Ташбилге".** Авылыбызның изге җирләреннән саналган "Ташбилге" зиратында сакланып калган өч ташның берсендәге язу 1344 елга карый. Димәк, авылыбыз территориясендә 14нче гасырга кадәр үк кешеләр яшәгән дип фикер йөртергә була. Әлеге каберлектәге ташлардагы язуларны күп галимнәр, укымышлы кешеләр тикшерә. Әлеге таш астындагы каберлектә яткан кешеләрнең кем булулары һәм кайсы чорга караулары да ачыкланган.

**Изге җир "Калалар өсте".** Авыл халкы өчен изге урын саналган "Калалар өсте" дә күп тапкырлар тикшерелә. Әлеге урында борынгы заманда зур шәһәрчек була. 1987 елда Казанда чыккан "Археологические памятники татар" дигән китапта болай язылган: Иске Рәҗәптән өч чакрым ераклыкта көньяк көнчыгышта тау киртләчегендә Калалар өсте (город Гора) Кала тау дигән урын бар. Шәһәрчек мәйданчык дүртпочмак сыман, 8100 квадрат метр мәйданны били. Төньяк көнчыгыштан көньякка таба туфрак өеме һәм чокырлар белән ныгытылган. Көньяк ягында ныгытмалар юк. Калалар өсте 1764 елда капитан Речков тарафыннан тикшерелә. 1964 елнын июнь аенда археолог Равил Фәтхетдинов җитәкчелегендәге экспедиция тарих укытучысы Гыйззәтуллин Зиннән Гыйззәтулла улы белән берлектә Калалар өсте һәм Ташбилге зиратын тикшерде. Риваять кенәдерме, әллә инде чыннан да әлеге урын изге саналадырмы, төгәл әйтеп булмый, ләкин әлеге урында теләгән теләкләр кабул була дип сөйләгәнне күп тапкыр ишетергә туры килә.

**Изге җир "Комиссар каберлеге".** Ирек урманы башындагы (икенче төрле аны Чәчәкле авызы дип тә атыйлар) әлеге каберлек бүгенге көнгә кадәр сакланып калган. Менә шушы бик матур урынга комиссар Соловьев күмелгән. Әлеге кеше турындагы тарих бик еракларга барып тоташа. Бу вакытта чех гаскәрләре безнең авыл аша уза. Әхмәтвәлиев

Мөһәммәтвәли Спаска Соловьевны алып бара. Бу вакытта Спастан чехлар китеп өлгермәгән була, алар Мөһәммәтвәли агайның яхшы атын үзләренә алалар, ә комиссар атны кире хуҗасына кайтарырга булыша. Соловьев тумышы белән Түбән Колчурино авылыннан була. Шушы вакыйгадан соң комиссар бер ел гына безнең авылда яшәп кала. 1913 елның җәендә урманда качып яткан дезиртирлар тарафыннан атып үтерелә. Авыл халкы әлеге каберлекне чистартып, чардуганын буяп тора. Әлеге каберлекне нигә изге дип санаганнарын төгәл аңлатып булмый, ләкин халык теленә шундый мәгълүмат кереп калган.

**2.2. Иске Рәҗәпнең су чыганаклары исемнәре.**

Безнең борынгы бабаларыбыз табигать белән тыгыз бәйләнештә яшәгәннәр. Елга, инеш, күл, чишмә кебек су чыганаклары халык тормышында алыштыргысыз кыйммәткә ия булганнар. Аларның тормыш-көнкүреш өчен әһәмиятле яклары һәм физик-географик үзенчәлекләре, кешеләр тарафыннан бәяләнеп һәм кабул ителеп, атамалар туу өчен хезмәт иткән.

**Чишмәләр.**

Без чишмәләребез белән чыннан да горурлана алабыз. Һәрберсенең үз тарихы, үз исеме, үз моңы, үз тәме. Иштуган, Әбҗәлил, Шәкүр, Рәҗәп чишмәләре үзләренең чиста һәм мул сулары белән авыл халкын шатландырып тора. Чишмәләр, кайда гына юк та, кайда гына очрамыйлар. Һәр йортка күптәннән су кертелгән булуга карамастан, авыл халкы чишмәләрне онытмый, даими рәвештә чистартып тора. Авылыбызның бизәге булган, күп гасырлар аша килеп, безнең көннәргә кадәр сакланып калган берничә чишмә турындагы риваятьне тәкъдим итеп китмичә булдыра алмыйм.

**Иштуган чишмәсе.** Алда сөйләнәчәк чишмәнең дә тарихы бик кызыклы. Бер гаиләдә ике бәләкәй малай дөньяга килә. Алар үсеп аякка да басарга өлгермиләр, әти-әниләре үлеп китә. Тормыш авырлыгын бик иртә татыган ятим егетләр кичләрен чишмә буена киләләр һәм суга вак ташлар атып, гел хыялларга чумып утыралар икән. Берсе аның үсеп җиткәч, мул тормышта яшәргә, матур кызга өйләнергә хыяллана. Ә икенчесе исә байлыкка кызыкмый, ул Аллаһтан алтын-көмеш түгел, сәламәтлек сорый икән. Еллар үтә, егетләр буйга җитәләр һәм үз теләкләренә ирешәләр. Берсе бай хатынына өйләнә, тик бәхете генә булмый. Ә икенчесе байлыкта йөзмәсә дә, дөньядан ямь табып яши. Шуңа күрә алар үлгәч, авылыбыз халкы бу чишмәгә Иштуган исеме биргән. Хәзерге вакытта да ул шушы исемне йөртә.

**Пәриле куак чишмәсе.** Ни өчен аңа шундый исем кушканнар? Олы кешеләрнең сүзләренә караганда, Пәриле куак чишмәсе каен агачы төбеннән бәреп чыккан. Бу каен агачы башка каеннарга охшамаган. Ул бик күп ботаклы, бик зур һәм ниндидер куркыныч төсмерләр алган. Олы кешеләрнең сөйләве буенча, бу урында кич белән барган атлар туктап

калганнар, азан әйтмичә, ул атлар кузгалып китмәгәннәр. Артка борылып караганда, шушы Пәриле куак чишмәсе буенда ялт-йолт утлар ялтыраган, пәриләр биегәне кешеләрнең күзләренә күренгән. Шуна күрә аны Пәриле куак дип атаганнар. Ләкин аның суының чисталыгы, сафлыгы, аның челтерәп агуы бөтен дөньяга танылган. Нишләптер кешеләр бу чишмәдән су алырга курыкканнар, эчәргә теләмәгәннәр, чөнки аның атамасы куркыткан. Билгеле инде, кешеләр һәрвакытта да бу чишмәне әйләнеп үтәргә тырышканнар. Хәзерге вакытта да бу чишмәнең су бик күп, мул ага һәм инешкә барып кушыла.

**Рәҗәп бабай чишмәсе.** Бу чишмә турында шушындый легенда - риваять бар. Бабай Аллага ялварып, шул җирдә чишмә чыгаруын сораган, ди. Аллаһ, аның теләген кабул итеп, чишмә чыгарган. Чишмә суы, көмеш кебек ялтырап, кыйбла ягына таба ага башлаган. Рәҗәп бабай беренче мәртәбә тәһарәт алып, намаз укыган. Менә шуннан соң бу чишмә Рәҗәп бабай чишмәсе дип, чишмәдән барлыкка килгән елга да Рәҗәп елгасы дип атала икән.

**Елгалар.**

**Рәҗәп елгасы**. Уратып, зур борылышлар ясап агуыннан чыгып, бу елгага халык Рәҗәп дип исем биргән. Елганың озынлыгы 10 км чамасы. Рәҗәп елгасы Майна елгасына кушыла. Элек елга буйлап шомырт агачлары тезелеп киткән булган. Бала-чагалар шунда шомырт җыярга йөргән. Ләкин, көтү йөри башлагач, әкренләп ул агачлар корыган. Хәзерге вакытта шомырт агачлары санаулы гына калган.

**Инеш һәм Байтирмән елгалары**. Авыл аркылы Инеш һәм Байтирмән елгалары ага. Авылдан ерак түгел Майна суы Иделгә тоташа. Аны Майна башы дип атыйлар. Иске Рәҗәп авылы Олы һәм Кече Майна елгаларының башланган урынына утырган була. Элек Инеш һәм Байтирмән елгалары бик тирән, киң һәм матур булганнар. Елгалар тирәсендә куаклар үскән, су тегермәннәре көне-төне эшләгән. Бу тегермәннәрдә авыл халкы гына түгел, ә күршедәге урыс авылларыннан да килеп он тарттырганнар. Рәҗәп тегермәннәренең даны күп еллар буена сакланган. Суларында балык күп үрчегән. Елгаларда, халык сөйләве буенча, кечерәк пароходлар да йөзгән. Шулай бер пароход, ни сәбәпледер, елгада баткан. Ул алтын-көмеш тәңкәләр төяп барган. Моннан йөз еллар элек авыл уртасыннан аккан Инеш елгасы ярларында көмеш тәңкәләр табылган. Бу тәңкәләр Шәмсуар шәһәрендә сугылган акчалар була.

**2.3.Калкулыклар.** Авылның тирә-ягында таулар юк, зур булмаган калкулыклар урнашкан. Аның көнбатыш өлешендә ике калкулык бар. **Аларны халык Алып чабата каккан урыннар исеме белән йөртә.** Аның берсе Майна суын чыккач, икенчесе – Пан юлы өстендә. Авылның көнбатыш һәм көнчыгыш өлеше урман белән өйләндереп алынган. Урманнарда усак, имән, өрәңге, каен, чикләвек агачлары үсә. Урман кырыйлары җиләкләргә, гөмбәләргә бай. Җәнлекләрдән поши, кабан дуңгызы, төлке, бүреләр очрый.

Моннан күп еллар элек авылның көньяк-көнбатыш өлеше зур әрәмәләр белән капланган була. Хәзер алар беткән, бары сазда үсә торганнары гына сакланып калган. Көньяк ачыклык өлешендәге “ Чиялек” дип аталган урын турында мин дәү әниемнән сораштым. Бу урында бик күп чияләр үсә торган булган. Хәзер анда чияләр юк инде, ә карлыганнар очрый.

**2.4. Авылым урамнары тарихы.**

Туган авылыбыз урамнарга бай. Шулардан: Байтирмән, Муса Җәлил, Ленин, Яшьләр, Абдулла Алиш, Чурай, Тау башы, Сәмигулла Хәйретдинов урамнарын атап үтәргә була.

**Байтирмән урамы.** Авылыбызда бүгенге көндә дә Байтирмән дигән урам бар. Тарихи мәгълүматларга караганда, авылыбыз тегермәннәргә бай булган. Җиде җил һәм бер су тегермәне булганы билгеле. Бер уйласаң, әлеге урам нәкъ шул тегермәннәр урнашкан якта сузылып ята, шуңа да исеме бшулай аталадыр Ләкин легенда-риваятьләргә караганда, әлеге урам исеменең килеп чыгышы бик кызыклы. Дөрестерме, юктырмы, әлеге урамның аргы ягында агучы елгада кораблар, пароходлар йөзгән дип фаразлыйлар. Шулай бервакыт, алтын төяп баручы бер кораб ни сәбәпледер су астына китә. Корабның баткан урыны Капраннан ерак булмаган. Әлеге хәлне исбатлаган сыман, моннан йөз еллар элек авылыбыз уртасыннан аккан инеш буенннан көмеш тәңкәләр дә табылган.

**Яшьләр урамы.** Яшьләрнең олылардан башка аерым тормыш алып барасылары килгән һәм аерылып башка чыкканнар. Шуңа күрә бу урам Яшьләр урамына әйләнгән.

**Абдулла Алиш урамы.** Бөек язучыбыз Спас районы Көек авылында дөньяга килгәнлектән, аның исемен мәңгеләштереп, урам исеме аталган.

**Сәмигулла Хәйретдинов урамы.** Талантлы каләм иясе, озак еллар “Ватаным Татарстан” газетасының хатлар бүлеге мөдире һәм баш редактор урынбасары, Татарстанның атказанган мәдәният хезмәткәре, тарих фәннәре кандидаты, республика журналистларының Хөсәен Ямашев исемендәге мәртәбәле бүләк иясе  Сәмигулла Хәйретдиновның арабыздан китүенә дә 23 ел вакыт узып киткән. Киңкырлы шәхеснең исемен мәңгеләштереп, бер урам аның исемен йөртә.

**2.5.Күперләр.** Авылда берничә күпер исеме бар: Алтылы күпер, Сары саз, Майна, Нәлет һәм Буалы елга.  Алтылы күпер дип, урман янындагы тарихи урынны атыйлар. Элек, бәлки, анда күпер булгандыр, хәзер күпер юк, елга яисә инеш тә акмый. Халык сөйләве буенча, күпер янында ниндидер зур сугышлар барган һәм бу сугышта алты туган вафат булган. Анда берничә кабер урыны бар, алар чардуган белән тотып алынган. Халык бу каберләрнең чардуганнарын төзәтеп карап тора.

Татарстан архивы материалларына караганда, авылыбызда заманында 5000гә якын кеше яшәгән.  Спастан кеше саны буенча бик азга гына калышкан. Әби-бабаем сөйләве

буенча, авылыбызда 8 мәчет, 8 мәдрәсә, кирпеч заводы булган, 10га якын тегермән гөрләп торган.

Берсе артыннан берсе килеп торган сугышларның рәхимсез җилләре авылыма кагылмыйча узмаган. Өлкән буын сөйләве буенча, ачлык вакытында җирдә калып кышлаган черек бәрәңге, икмәк, иртә язда күренгән үлән белән тукланырга туры килгән. Агуланган икмәк ашап авыручылар да күп булган. Сугыш кырында күп кенә авылдашларыбыз башын салып кала, кайтучыларның исә күбесенең исәнлеге какшаган, тәннәре яраланган була. Якты киләчәгебез өчен ятып калган солдатларның исемнәре күп еллардан соң да җуелмас өчен, авылыбыз уртасында 2010 елның 7 нче маенда мемориал ачылды. Әлеге ташта 356 батырның исеме уеп язылган.

Кызганычка каршы, авыл елдан ел кечерәя, халык кимегәннән кими бара. 3-4 дистә елдан соң авыл нинди хәлдә булыр дигән сорау йөрәкне әрнетеп куя...

## Йомгаклау

Тормышны топонимик атамалардан башка күз алдына китерергә дә мөмкин түгел. Алар - халык иҗатының гасырлар буена җыелып килгән асыл җәүһәрләре, үзенчәлекле мирасы.

Мин шундый нәтиҗәгә килдем:

1. Халык гомер-гомергә исем-атамалар белән бергә яшәгән, аларны телендә кулланып килгән. Һәр җирле атама тарихының төбендә авылның үткәнен күрәбез, шуңа күрә микротопонимнар халыкның үткән тормышын тикшерү өчен ышанычлы чыганак булып торалар. Алар безгә борынгы бабаларыбызның тормыш-көнкүреше, һөнәр-кәсепләре, гореф-гадәтләре, шул төбәктә булып узган вакыйгалар, төбәкнең табигате һ.б. турында мөһим мәгълүмат бирә.

2. Атамаларның һәрберсенең үз исеме, үз тарихы, яшәеш үзенчәлеге бар. Алар кинәт, сәбәпсез генә тумаганнар. Географик берәмлекләргә исем-атама биргәндә, күзәтүчән борынгы бабаларыбыз аларның күзгә ташланып торган физик-географик үзенчәлекләренә зур игътибар иткәннәр яисә тормыш-көнкүреш өчен әһәмиятле ягын исәпкә алганнар.

3. Су чыганаклары, бигрәк тә чишмә атамалары, кеше исемнәренә яки яратып кушылган кушаматларга нигезләнеп барлыкка килгәннәр, һәм алар күпчелекне тәшкил итәләр. Халык суларның кадерен белгән, чишмә башларын карап, чистартып торган эшчән, изге күңелле авылдашларын онытмый, аларның исемнәрен чишмәләргә биреп мәңгеләштерә.

4. Авыл урамнарын халык хәзер дә үзенчә, үз күңеленә якын элеккеге атамалары белән йөртә.

Авылым микротопонимнары тарихын тикшерү минем өчен кызыклы да, мавыктыргыч та, файдалы да булды, туган төбәк белән кызыксынуым артты. Иске Рәҗәп үзенең кабатланмас тарихи һәм матур үзенчәлекләре белән тагын да тирәнрәк ачылды.

Кызганычка каршы, микротопонимнарны әйбәт белә торган олы буын - зирәк зиһенле авыл картлары, хәтерле әбиләр соңгы юлга китә бара. Шуңа күрә, алар исән чакта сорашып, сөйләгәннәрен язып алып, онытылып бара торган атамаларны җыеп туплап калу бик мөһим. Бу эш безнең һәрберебезнең кулыннан килә. Тарихыбызның әһәмиятле бу өлеше югалмасын, саклансын, киләчәк буыннарга да тапшырылсын иде. Авылыбыз, халкыбыз тарихын алар да белергә тиеш.

Киләчәктә мин туган як топонимнарын өйрәнүне дәвам итәргә уйлыйм, чөнки кайбер атамаларның исемнәре минем өчен сер булып калды. Тупланган мәгълүматлардан альбом төзергә һәм авылның “Туган як” музеена тапшырырга телим.

**Кулланылган әдәбият.**


1.Мәрҗани Ш. Мөстәфәдел - Әхбар фи әхвәли Казан вә Болгар. – Казан: таткнигоиздат, 1989. 415 бит.

2.Дибаева М. Җирдә эзең. – Казан: таткнигоиздат, 1967.-185 бит.

3.Батырлар китабы.- Казан: таткнигоиздат,1945.- 170 бит.

4.Хәйретдинов С.К. Туган җир...(документаль хикәя).- Иске Рәҗәп,1974.-270 бит.

5.Альбом. Иске Рәҗәп авылы тарихы.- Иске Рәҗәп, 1969.



*Закиров Рөстәм, 6 нчы сыйныф,*
*Муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесе Мөслим урта гомуми белем бирү мәктәбе им. Г. Тукай " Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районы*
*Җитәкчесе: Закирова Илиза Илфир кызы башлангыч сыйныфлар укытучысы*


## Үткәнен оныткан халыкның киләчәге юк

(минем бабам, сугыш ветераны

Миннегалиев Хуҗагали Миңнегали улы мисалында)

### Кереш

**Үткәнен белмәгән халыкның киләчәге юк.**

Ел саен 9 Май – Җиңү бәйрәмендә без “Үлемсез полк” парадында катнашабыз. Бу парадта мин әниемнең бабасы Хуҗагали бабайның фотосүрәтен зур горурлык хисләре белән йөртәм. Чөнки бабам сугышның соңгы көннәренә кадәр катнашып, Берлинга барып җиткән.

Еллар үткән саен вакыйгалар, шул вакыйгаларда катнашучылар тарих битләрендә урын ала бара. Хәер алай дип әйтү дөрес тә түгелдер.Тарих битләрендә калып,буыннан – буынга күчсен өчен аларны язырга кирәк – хәзергә әле кешеләр тарафыннан бүтән юл уйлап табылмаган.

Кеше туган иленең, туган төбәгенең, туган йортының үткәнен, үз халкының чыгышын белергә тиеш.

Кызганычка каршы, хәзер күп кеше гаиләсенең тарихын, шәҗәрәсен, килеп чыгышын белми. Үз нәселеңне өйрәнер өчен бөтен мөмкинчелекләр дә тудырылган, югыйсә. Архивлар, эзләнү методлары, махсус әдәбият....

Минемчә, гаиләңнең тарихын өйрәнү кызыклы һәм файдалы. Минем әби – бабам кем булган, ничек яшәгән һәм шөгыльләнгән, кешеләр өчен файдалы эшләр башкарганнармы, әллә киресенчәме? Минем уйлавымча, безнең бабаларның яшәү рәвеше безнең тормышта да уз урынын алган, үз нәселеңне белергә һәм хәтерләргә тиешбез.

Бүгенге көндә буыннар арасында тарихи бәйләнеш юк дисәң дә була. Балалар өлкән буын кешеләреннән үрнәк алу мөмкинлегеннән мәхрүм. Шуңа күрә һәр кеше үз гаиләсендә буыннан буынга килгән истәлекләрне белеп, аларны саклап, киләчәк буынга тапшырырга тиеш.

Бүгенге көндә гаиләнең тарихын өйрәнү проблемасы иң мөһим проблемаларның берсе булып тора.

Меңләгән, миллионлаган кеше ачы газаплар күрсәләр дә, алар нык торган, җиңгән. Без бу баһадир солдатларны , батырларны онытырга тиеш түгел. Сугыш безнең гаиләне дә читләп үтми. Шуңа минем тема бик кирәкле дип саныйм.

**Гипотеза:** Әгәр без тыныч тормышның кадерен белергә теләсәк, моннан 77 ел элек тәмамланган,илебезгә күз яше, ачлык, үлемнәр һәм кайгы китергән, салкын тын өргән сугыш турында онытмаска, аның батырлары белән горурланып яшәргә тиеш.

**Проектның максаты:** Гаиләбез архивындагы истәлекләргә таянып, Бөек Ватан сугышының безнең гаиләдә нинди эз калдыруын ачыклау. Киләчәк буынга сугышта катнашкан бабам турында истәлекләрне китапларда, язмаларда мәңгеләштерү.

Проектның объекты:гаилә истәлекләре.

Проектнын предметы:Бөек Ватан сугышында катнашучы- минем карт бабам.

**Проектның бурычы:**

1. Бөек Ватан сугышы елларында туганнарыбыз язмышы турында мәгълүмат җыю.

2.Батыр бабамның сугыш юллары белән танышу.

3. Бабам турында истәлекләрне китапларда, язмаларда мәңгеләштерү.

Еллар уза, дөньяга яңа буыннар килә. Кешелек дөньясына кайгы-хәсрәт китергән Бөек Ватан сугышы тәмамлануга жиде дистә елдан артык вакыт узса да, сугыш дип әйтүгә, күз алдына җимерелгән йортлар, актарылып беткән болыннар, ятим балалар килеп баса. Әйе, рәхимсез сугыш илебез халкына әйтеп бетергесез кайгы-хәсрәт китерә. Япь-яшь егетләр, кызлар туган җирләрен саклау өчен фронтка китәләр. Тылда калганнар да солдатлар өчен җылы оекбашлар, бияләйләр бәйлиләр. Җиңү өчен дип, бар тырышлыкларын куялар. Сугыш бик күп гаиләләргә кайгы, ачы күз яшьләре китерә. Я ире, я уллары, я әтиләре Ватан өчен яу кырларында мәңгегә ятып кала. Бер кайтмасак, бер кайтырбыз  дип китсәләр дә, күпме ватандашларыбыз туган туфрагын күрү бәхетенә ирешә алмады. Алар еракта мәңгелек йокыга талдылар. Туган җирләре өчен башларын салган бу батырларны онытырга безнең хакыбыз юк. Алар безнең белән, безнең арада. Ил азатлыгы өчен изге сугышта һәлак булучыларның исемнәрен мәңгеләштерү эше бүген дә дәвам итә. Бу эштә һәркем үзеннән өлешен кертергә бурычлы. Бүгенге тыныч тормышта яшәвебез өчен без аларга бурычлы. Өлкән буынның сугыш һәм сугыштан соңгы героик тормышы безнең өчен һәрчак үрнәк.

**Төп өлеш**

**Бөек Ватан сугышы – ил, гаилә фаҗигасы.**

1941 нче елнын 22 нче июнь иртәсе искиткеч матур,  күк йөзе ап-аяз. Менә шундый матур күк йөзе кинәт самолётлар гөрелтесе, шартлаулар, янгын төтене  каплап кала. Бу көнне, фашистлар Германиясе хыянәтчел төстә хөҗүм итеп, илдә Бөек Ватан сугышы башлана. Сугыш! Никадәр кайгы-хәсрәт, югалту, бәхетсезлек китердең син тыныч халыкка. Син аның бәхетен урлап, рухын сындырырга, юк итәргә, колга әйләндерергә, кешеләрне тезләндереп, алар өстеннән явызларча хакимлек итәргә теләгәнсеңдер. Безнең илнең көчсез, әле ныгып җитмәгән булуыннан файдаланырга теләгәнсеңдер. Ләкин бер хакыйкатьне син аңламагансың. Безнең илебез яшь, көчсез булса да, аның горурланып сөйләрлек, курку белмәс, җиңелмәс батыр уллары һәм кызлары, шундый батыр йөрәкле балалар үстергән бөек аналары бар. Аларга бәхет төшенчәсе туганда ук ана сөте белән керә, әнә шуны чын мәгънәсендә аңлау аларга бетмәс-төкәнмәс көч, туган илгә кайнар саф мәхәббәт бирә, әнә шул көч җиңүгә алып килә. Безнең илебез зур сынаулар, авыр юллар, чиксез күп югалтулар белән җиңү таңын каршылады. Без бәхетле яшәсен өчен егерме миллион кеше яу кырында ятып калды. Аларның чиксез батырлыгы турында без кинолардан карап, тарих дәреслекләреннән укып, язучыларыбыз сугыш темасына иҗат иткән әдәби әсәрләр белән танышып беләбез. Миллионнарча гаиләләр сугышта һәлак булган, хәбәрсез югалганнарның язмышын белә алмады.

Быел Бөек Ватан сугышында Җиңү яулаганга - 78 ел. Сугыш хатирәләрен, җиңелмәс батырларыбызны искә төшереп торучы тере һәйкәлләр – ветераннарыбыз бар. Шунысы кызганыч, аларның сафы елдан-ел сирәгәя. Бүгенге көндә, күкрәк тутырып көмеш медальләрен чыңлатып, Җиңү көнен каршылаучы авылдаш ветераннарыбыз да юк.

Бөек Ватан сугышының беренче көннәреннән үк менләгән егетләр, кызлар үз теләкләре белән Ватанны сакларга китәлар. Безнең Үрәзмәт авыл Советы территориясенә кергән 5 авылдан 628 кеше сугышка китә, 367 яу кырында ятып кала, кайтканнарының да күбесе фронтта алган яраларыннан озак тормый вафат була.

Җиңү яулауга уз өлешен керткән авылдашларыбыз арасында минем әтиемнең дә, әниемнең дә бабалары булган. Менә шуларның берсе әниемнең бабасы Хуҗагали Миңнегали улы Миңнегалиев турында язарга булдым. Анын турында истәлекләрне миңа әнием сөйләде.

**Трофей солдаты**

Хужагали бабамның әтисе Миннегали 1914 елда башланган Беренче Бөтендөнья сугышында катнаша, аннан яраланып кайта. Озак та тормый алган яраларын- нан терелә алмыйча денья куя. Хуҗагали һәм сенлесе Миннур ярты ятим калалар. Әниләре Гыйлмежиһанга балаларын ялгызы тәрбияләргә туры килә. 1929 елда башланган колхоз оештыруда ул башлап йөрүчеләрнен берсе була. 1931 елның октябрендә Үрәзмәт авылы кулаклары икмәк әзерләү эшендә зур тырышлык куеп эшләүче колхоз әгъзасы, фәкыйрь Гыйлмеҗиһанны мылтыктан атып яралыйлар. Шул ук елны сеңлесе Миңнур белән Хуҗагалине Донбасска җибәрәләр.

Сугыш Хужагалине дә үзенә суыра. Кечкенә чакта салкын тиеп анын бер колагы начар ишеткән. Шуңа карамастан ул 1941 елның 1 сентябрендә берсеннән-берсе 4 сабыен калдырып, үз теләге белән сугышка китә. 1942 елның июненә кадәр 2043 укчы полкта, 1942 елнын июненнән 1943 елның гыйнварына кадәр 127 укчы полкта хезмәт итә. Сугышның берсендә сул кул бармаклары өзелеп 2 ай буена госпитальдә дәвалана. Аннан чыккач Хужагали солдатны трофей батальонында хезмәт итәргә куялар. Трофей батальоны дигәч тә... Анда бомба, снарядлар шартламый, туктаусыз пулялар да сызгырып үтми, шул бармаксыз кулы, башка чирләре, тән җәрәхәтләре белән фронтка ярамаган кешеләр хезмәт куя. Дошман калдырып киткән техниканы, башка кирәк-ярак әйберләрне учетка алырга кирәк. Кайсын өстерәп чыгарасы, тәртипкә китереп тезәсе, өясе. Арада миңа кыстырылганнары да очрый. Ипләберәк кыланмасан, теге деньяга очуын да бар. Тимер юлда вагоннарга таяп ул трофейны каядыр озатасы. Күтәрү краннары сирәк, эш кулдан, җинел түгел, әлбәттә. Һәммәсен тиз, бик тиз эшләргә кирәк. Күп генә чакта бу эшләрне башкарганчы фронтка китүең мең елеш артык дигән уй башка килә иде, дип искә ала торган була трофей командасы солдаты.

Хуҗагали бабай 1945 елның ноябрендә генә туган төбәгенә кайта. Кайта да иркенләп иркәләнеп ятмый, баш аягы белән колхоз эшенә чума. Ул яхшы балта остасы була. Кирәкле хезмәт Ул чакта таштан, кирпичтән өй житкерү юк, башка тезелешләр дә шулай, барысы да агачтан. Агачтан булгач балтасыз булмый инде. Хуҗагалигә чират. Авылда ул житкергән өйләрнең саны бихисап. Кулын белсә, карусыз булсаң, эш табыла. Шул ук вакытта ул авыл тегермәнендә дә хезмәт куя. Колхоз хезмәт көненә, өеп булмаса да, бертекле ашлык бирә тора. Он кирәк. Шулай булгач, Хуҗагали дә бик кирәк. Тагын чират.

Авылда танылган умартачы буларак, ул лаеклы ялга чыккач та эшсез тормый. Шул эш белән кызыксынучылар еш кына аннан кинәш сорарга киләләр. Ул үзенең бакчасында унлап семья умарта тота. Бабайнын гаиләсе ишле була. Алар әбием Әминә белән 7 бала тәрбияләп үстерәләр. Картлык көннәрендә ул минем бабам Илфир тәрбиясендә яши.

Җиңүнең 50 еллыгын билгеләп үткәндә, 1906 елда дөньяга килгән Хужагали бабай 89 яшендә вафат булды. Безнен бугенге якты көннәребез өчен яу кырында ятып калган, сугышта катнашкан батыр якташларыбызны, Фронтны икмәк, азык-төлек, кием-салым белән тәэмин иткән тыл хезмәтчәннәрен онытмыйк.

Бөтен Россия, Европа буйлап Берлинга кадәр күпме юллар, күпме ил чикләре узган! Хуҗагали бабай бу еллар турында искә алырга яратмый иде. Үз гомеренең бу дәһшәтле, сугыш еллары турында ул авырлык белән генә искә аса да. Аның әйтүенчә, пулеметларның куркыныч гүләвенә, пуляларның сызгырып очуына, елга кебек аккан канга берничек тә ияләнеп булмый. “Телевизордан онытылмас сугыш елларында кешеләрнең газаплануларын, үлемен күрсәтсәләр бабамның сугыш хәтирәләре яңара иде. Сөйләп бетергәч бер – ара тавыш тынсыз кала да, күзләреннән кайнар яшь тамчылары тәгәрәп төшә иде дә, и балалар, берук сезне андый афәтләр урап үтсен диеп куя иде” – дип сөйли әнием, бабай турында.

“...Неман елгасын кичү, Кенигсберг, Вильнюс шәһәрләрен азат итүдә катнашу, Берлинга кадәр барып җитү бәхетенә ирешергә насыйп булды миңа. Бик күп күрдем: үлем дәһшәтен, дусларымны югалтуны, яралы да булдым.. “Катюша” снарядлары тавышы килә башлагач, колак чыңлаганына түзеп булмый башлый, куркудан я чүгәләп куясың, я тәгәрәп җиргә сеңәсең. Һәрбер пуля, снаряд сиңа гына төбәп килгән сыман. Ә сугышта син боерыкны үтәргә тиеш. Яңадан күтәреләсең дә, яңадан – алга... Бу курку хисе, “Катюша” снарядларының тавышы сугыштан соң да төшләремә кереп йөдәтте...”

Бөек Ватан сугышында күрсәткән хезмәтләре өчен Миңнегалиев Хуҗагали Миңнегали улы түбәндәге орденнар һәм медальләр белән бүләкләнгән: «Сугышта хезмәтләре өчен»; 1969 нче ел; 1 нче дәрәҗә Бөек Ватан сугышы ордены» 1985 нче ел һәм башка истәлекле юбилей медальләре һәм башкалар.

Еллар үтә, сулар ага.. Балаларына тиешле тәрбия биреп, олы тормышка аяк бастырдылар. Ә тәрбияне алар үз үрнәкләре аша бирделәр. Алар үзләренең балаларында хезмәт сөючәнлек, фидакарьлек, олыларга карата хөрмәт һәм тормышны ярату кебек сыйфатлар тәрбияләгәннәр..

Бабам үз хезмәтенә бик җаваплы караган. Аның мактау хатлары һәм Почет грамоталары да бар. Кеше арасында ул үзенең хезмәт сөючәнлеге, кешелеклеге, игелеклеге белән аерылып торган. Ир кеше үз гомерендә малай үстерергә, агач утыртырга, йорт төзергә тиеш дип әйтәләр.. Ул 1995 нче елда 89 яшендә вафат булды.

Хуҗагали бабай гаиләсенең якты хәтирәсе безнең күңелләрдә мәңге калыр! Җир йөзендә анын балалары, оныклары, онықчыклары - аның дәвамы. Башкаларга терәк һәм үрнәк булып, тормыш сикәлтәләрендә егылып калмыйча яшәгәннәр алар. Үзеннән соң игелекле балалар, матур эшләр калдырганнар. Кеше турында башкалар күңелендә матур хатирәләр саклана, аның исеме яши.

**Йомгаклау**

Тиздән - Бөек Җиңү көне. Аның быел 78 еллыгын бәйрәм итәбез.Совет солдаты бирешмәде! Туган ил хакына, аның бердәм халкы, туганнары, дуслары, сабый чаклары куркыныч сугыш елларына туры килгән газиз балалар хакына алар барлык авырлыкларга да түзде һәм җиңде! Аларга дан һәм чын күңелдән рәхмәтебез! Безнең буынны саклап калган кешеләрнең батырлыгы беркайчан да онытылмас! Күкрәкләренә орден, медальләр таккан чал чәчле ветераннарны күргәч, безгә тыныч тормыш бүләк иткән өчен — рәхмәт хисе уяна. Чал чәчләреннән сыйпыйсы, дөньядагы иң матур сүзләр белән юатасы, мең рәхмәт әйтәсе килә аларга! Дөньяда яшәүче барлык кешенең бер теләге бар – туган илдә тынычлык булсын! Аларга мәңгелек дан һәм мәңгелек хөрмәт! Ә безнең бурычыбыз – ул еллардагы халыкның батырлыгын үзебездә онытмыйча, бездән соң килгән буыннарга да тапшыру. Без дә, Хуҗагали бабам турында киләчәк буынга калдырырлык истәлекләрне сакларбыз, безнең тынычлыгыбыз өчен гомерләрен кызганмаган батыр йөрәкле бабайларыбыз белән горурланып яшәрбез.

Уткәнне белү, синең киләчәген
Хәтерләүдән курыкма син!
Уткәненне онытма син!
Бел син ерак бабайларның
Ничек итеп көн иткәнен,
Ни иккәнен, ни чиккәнен,
Нинди уйлар, нинди моңнар
Безгә калдырып киткәнен.

Бөек Ватан сугышының дәһшәтле һәм фаҗигале көннәре елдан-ел ераклаша бара. Ләкин халкыбыз кичергән ул кайгы-хәсрәтләр һичкайчан онытылмас... Бөек Ватан сугышы тәмамланганга, никадәр вакыт үтсә дә, аның хәтирәләре күңелләргә тирән сеңеп калган. Язлар җитү белән Җиңү бәйрәмен билгеләп үткәндә бу вакыйгалар кабат искә төшә.

**Кулланылган әдәбият исемлеге:**


1. Гаилә архивындагы фотосурәтләр.
2. Хуҗагали бабайның хәрби билеты.
3. Медальләр таныклыклары.
4. Мемориал Великой Отечественной войны – obd-memorial.ru
5. Шарипов А.А. – Утлы еллар аша – Яр Чаллы шәһәре: «Диамант» ҖЧҖ нәшрияты,2014г.
6. Автор төзүче Әлфинур Ногманова “Үрләр яулар Үрәзмәт” – Казан, “Халкыбыз мирасы” нәшрияты, 2022
7. Данилов А.А. Отечественная история: Учебник для вузов. М., 2003г. С 99-112.
8. Зуев М.Н. История России. Учебник. М, 2004г. С 68-73.
9. Татарстан в годы Великой Отечественной Войны 1941-1945гг. Татарстан Бөек Ватан сугышы елларында (1941-1945) – Казань: издательство «Книга Памяти», 2000.



*Зиганшин Билал, 8 нче сыйныф,*
*Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районының «24 нче лицей-интернат» муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесе*
*Җитәкчесе: Егорова Рәсимә Хәмит кызы, Әхмәдиева Динара Хамиз кызы, татар теле укытучылары*


## Татар телендә сленглар

### Кереш

Хәзерге тормышыбызда сленгларны белмәгән, аларны сөйләмендә беркайчан да кулланмаган берәр кешене таба алырбызмы икән?! Ләкин сөйләмебездә аларны еш һәм яратып куллансак та, аның кайчан һәм ничек барлыкка килүе, кулланылу сәбәпләре, нинди үзенчәлекләргә ия булуы, телебезгә ничек тәэсир итүе турында уйлап та карамыйбыз. Сленглар сөйләмебездә актив кулланылулары өстенә, тормышыбызның төрле

катламнарына да тирән үтеп керәләр. Мәсәлән, кинофильмнарда, радиотапшыруларда, газета-журналларда, китапларда да еш очратабыз без аларны. Сленглар, гадәттә, гадәти сүзләр урынында әйтелеп, сөйләмгә эмоциональлек өстиләр. Аларны уйлап чыгару өчен ана телебезнең күп кенә фонетик, лексик-семантик, грамматик чаралары активлаштырыла, эшкә җигелә.

Уртак мәнфәгатьләрне кайгырткан, билгеле бер төркем кешеләр сөйләмендә барлыкка килгән бу үзенчәлекле сүзләр, тора-бара, аларга бернинди катнашы булмаганнарга да тарала. Шулай итеп, сленглар сөйләмебезгә тамыр җибәрәләр, берегеп калалар. Аларны яше дә, карты да, барлык һөнәр ияләре дә, галимнәр дә кулланалар. Ләкин соңгы елларда, яшьләр арасында бу юнәлеш аеруча активлашып китте. Фәнни-тикшеренү хезмәтемә мондый тема алуым да очраклы түгел. Сәбәбе-соңгы елларда туган телебезгә булган карашның үзгәрүе. Аны өйрәнергә теләмәүчеләр дә күренгәли башлады. Русларда “Для достижения цели все средства хороши” (максатка ирешү өчен бөтен чаралар да яхшы) дигән бик акыллы бер гыйбарә яши. Минемчә, бик дөрес сүзләр. Инглизләр әнә, интернет челтәрләрендә ингиз телен сленглар ярдәмендә өйрәтүгә корылган видеокурслар ачканнар ич! Туган телебезгә карата кызыксындыру уятырга татарча сленглар да бик зур ярдәм күрсәтәләр, дип уйлыйм мин.

Фәнни-тикшеренү эшемнең темасы -“Татар телендә сленглар”. Минем уйлавымча, бу тема хәзерге вакытта бик актуаль. Тел үсәргә, камилләшергә тиеш. Ләкин шул телдә сөйләшүчеләр артмаса, тел төзелеше ягыннан камилләшмәсә, аның функцияләре үсмәсә, ул юкка чыгар иде. Әдәби тел дә, сөйләм теленнән аерым гына яши алмый. Ә аның коммуникацион үсешендә төп рольне балалар, яшьләр уйный. Телебезнең киләчәге дә алар кулында.

**Тикшеренү эшемнең актуальлеге**: сленглар-хәзерге заман лингвистикасының актуаль булган һәм иң бәхәсле темасы. Бу хезмәтем сленгларның да тел үсешен тәшкил итүдә зур роль уйнавын һәм аларны куллану яшьләргә тел өйрәнүдә өстәмә кызыксыну тудыруын аңларга ярдәм итәр.

**Эшемнең максаты**: сленгларны анализлау һәм аларның тел өйрәнүдә ярдәм итүче фактор икәнен раслау.

**Бурычлар**: татарча сленглар ничек барлыкка килүен, тел өйрәнүгә ничек тәэсир итүен аңлату.

**Гипотеза**: сленглар сүзлек составын баета.

**Эксперимент**: анкеталаштыру, күзәтү, әңгәмә, уеннар.

**Тикшеренү методлары**: тема буенча өстәмә әдәбият уку. Укучылар, укытучылар белән әңгәмә, уен үткәрү.

**Тикшеренү объекты**: яшьләр сөйләме**.**

**Тикшеренү предметы:** татарча сленглар.

**Хезмәтнең гамәли әһәмияте**-материалның татар теле дәресләрендә, класстан тыш чараларда, класс сәгатьләрендә кулланыла алуында.

**Төп өлеш**

**1.1. Сленг атамасы, килеп чыгышы, аның функцияләре, кулланылу сәбәпләре.**

Лингвистика өлкәсендә иң бәхәсле темаларның берсе булып сленгларның килеп чыгу тарихы торадыр, мөгаен. Аңа аңлатманы да төрлечә бирәләр. **"Сленг** — бердәй һөнәр, көнкүреш шартларында, уртак кызыксынулар белән бергә вакыт үткәрүче бер төркем кешеләр сөйләмендәге үзенчәлекләр.

Икенче төрле "жаргон" дип атау да очрый". Жаргоннар, минемчә, тупас, ямьсез, колакка ятышсыз сүләр. Аларны төрмәчеләр уйлап чыгарган "авыр" сүзләр дип тә атап булыр иде.[6; с.2]

Гомумхалык теленнән сленг үзенчәлекле сүзлек составы, фразеологиясе һәм сүз ясалышы белән аерыла. Аларның килеп чыгышы да бик кызыклы. "Күп еллар элек, Рәсәйнең Мәскәү тирәсендәге шәһәрләрендә вак әйберләр белән сәүдә итүче алып-сатарлар телендә беренче сленглар барлыкка килгән. Чөнки алар, төннәрен дә, көннәрен дә үзләренә талау оештырган зимагурлардан, караклардан сакланыр өчен, үзләре генә белгән сүзләр, сүзтезмәләр, гыйбарәләр системасын барлыкка китергәннәр". Югарыда китерелгән язмадан аңлашылганча, сленглар - сәүдәгәрләр тарафыннан уйлап табылган сөйләм үзенчәлеге. Сәүдәгәрлек - безнең ата-бабаларыбыз канында. Новгородның Мәкәрҗә ярминкәсенә безнең бабаларыбыз атлар белән йөри торган булган. Новгородка барып җиткән татар, географик яктан, Новгород белән генә тукталып калырмы?! Мәскәү тирәсендәге шәһәрләрдә, ниһаять, Мәскәүнең үзендә дә татар сәүдә итмәс дип кем әйтмәс?! Кем белә? Сленгларны да безнең татар бабаларыбыз уйлап чыгармадымы икән?! Чөнки элек заманнардан ук татар халкы телендә сленглар яшәгән. Димәк, без аны татар халкында борын заманнарда ук килеп чыккан дип исәпли алабыз. Мәсәлән, *"тәңкә", "сәмән"* (сум), *"әвен базары"(*йокы), *"түнде"(*йоклады), *"бәчте", "чәлде"* (урлады), *"чашты"* (тәрипсезләнде), *"апай"* (кечкенә кеше), *"ычкынды", "катты"* (үлде, качты), *"әзмәвер"* (көчле кеше), *"мокыт"(*аңгыра), *"әбрәкәй"(*бәдрәф), *"типчү"(*тегү), *"бир бишне"(*исәнләш), *"салмыш" (*исерткеч эчкән кеше), *"салырга" (*исерткеч эчемлекләр эчәргә), *"теге ни", "ни бит"* (онытканда, сүзне ялгап җибәрү), "*манчы" (*сук), "*тәпәлә" (*кыйна), *"менә сиңа кирәк булса!", "менә сиңа мә!", "бәррәч"* (шаккатканда әйтелә) , *"төртергә" (*ришвәт), *кәҗә тоягы* (кукиш), *сәмәй* (алкоголь), *сырланма* (ялындырма), *агач*

(тупас кеше), *аяк* (тәртә), *“хуш иттек”* (сабуллаштык), “*шылдымы”* (аңлашылдымы), *“сиптерәбез генә”* (җырлыйбыз), “*арба”*-машина,*“аякланган”*, *“аяклар ускән”* (урлаганнар), *дундук* (миңгерәү), “егылып китмәле” (отпад) һ.б. Характерлары ягыннан сленг сүзләр шаярту-ирониядән алып, тупас - вульгар төсмерләргә кадәр ия булырга мөмкиннәр. [7; с.23]

Сленг лексика, нинди иҗтимагый катламда кулланучга карап, ике төргә аерыла:

- киң катлам кешеләр телендә кулланыла торган (укучы балалар, яшьләр, студентлар телендә: «*телик*» - телевизор, «*картлар*» - әрмедә приказ көтүче солдат, “*башкан*” –староста, «текә» - үзен әллә кемгә куючы, «*шпора*», «*бомба*» - шпаргалка һ.б.);
- тар, ябык коллективларда башкаларга аңлашылмаслык итеп, конспирация максатыннан кулланыла торган- арго. Мәсәлән, балалар арасында кулланылганы, сүзнең һәр иҗегенә “пи” кушып сөйләшү (Пи-мин пи-бү пи-ген пи-мәк пи-тәп пи-кә пи-бар пи-дым).

Җәмгыять үзгәргән саен, сленг - лексика составы да үзгәреш кичерә.

Сленглар телебездә ничек берегеп калалар соң?

1. Көнкүрешне белдерүче берәр сүзнең синонимы булалар.
2. Бу сүзләргә экспрессив-стилистик бизәк хас булганга еш кулланыла башлыйлар.
3. Кулланучылар күбәю сәбәпле, бик җиңел генә гади сөйләмгә дә күчеп китәләр.

Татар теленең яшәеше, аның киләчәге турында сүз алып барганда, беренче чиратта, телебезнең көндәлек аралашудагы үзенчәлекләренә игътибар итү сорала. Бу – бик әһәмиятле һәм шактый үзенчәлекле яссылык, чөнки нәкъ сөйләм теле, аның яшәеш формалары киләчәктә телебезнең үсеш юнәлешләрен, халыкның милли менталитетында, психологиясендә барган кайбер үзгәрешләрне күрсәтә торган билге булып тора.

1.2. **Татарча сленглар файдалымы, зыянлымы?**

Хәзерге вакытта, минем уйлавымча, сленглар - телебездә тулы тормыш белән яшәүче сүзләр, телнең үзенчәлекле бер төре. Сөйләм теленә якын булганга күрә, һәрвакыт үзгәрештә, үсештә. Ләкин алар әдәби тел нормаларына туры килмәү сәбәпле, әдәби сүзләр белән бергә кулланыла алмыйлар. Тел галимнәребез һәм олы яшьтәге кешеләр бу юнәлешкә каршы дип уйлыйм. Чөнки, алар фикеренчә, сленглар әдәби телебезне чүпләүгә хезмәт итәләр. Әдәби телгә сленглар сөйләм теле аша, матур әдәбият аша үтеп керәләр, әмма аларның телдә кулланылуы, әзме-күпме дәрәҗәдә, әдәби нормалардан читләшүгә этәрә, телнең сафлыгына зыян китерә. Ләкин бу юнәлешкә кискен каршы чыгарга да ярамый.

Замана яшьләренә бу кызык икән, нигә каршы килергә?! Бу бит әле өлкән буын кешеләреннән яшерен сөйләм дә.

Русча сленглар белән беррәттән татарча сленглар да татар яшьләре арасында киң таралган. Татарча сленгларның кайсылары инглиз, рус телендәгеләрдән турыдан туры тәрҗемә белән ясалган. Ә кайсылары үз телебез эчендә туган сленглар. Мин бары тик үзебезнең лицейда һәм дусларым арасында киң таралган сленглар белән генә эш иттем. Бу хезмәтемдә миңа классташларым һәм әниемнең туган авылындагы татар мәктәбендә укучы авылдаш дусларым, “Сәләт” легеренда танышкан иптәшләрем ярдәм итте. Шулай ук интернет челтәреннән дә күп ярдәм алдым. Мәсәлән, “Әллүки”, “Татар-медиа”, “Азатлык”, “Татар яшьләре төркеме”, “Кызык-мызык” төркемнәре. Бу төркемнәрдә татарча сленглар киң кулланыла.

Телнең бу өйрәнелмәгән бүлегенә кереп китәргә миңа нәрсә этәргеч булды соң? Бу сорауга мин түбәндәгечә җавап бирер идем. Интернет челтәрләрендә ингиз теленә өйрәтүнең нинди генә юллары юк! Хәтта сленглар ярдәмендә укытуга корылган видеокурслар да бар икән ич! Инглиз сленглары инглиз теленә кызыксындыру тудырган икән, татарча сленглар белән моны эшләп булмыймени?! Милли телебез авырлык кичергән заманнарда, руслар әйтмешли, телгә кызыксыну уятыр өчен “все способы хороши”. Ә болай, кызыксынып китеп, күпме яңа сүз өйрәнергә була.

Мин хәзергә мәктәптә укыйм. Минем тикшерү объектым булып та мәктәптә кулланылучы сленглар тора. Тикшеренү күрсәткәнчә, алар, 12 яшьтән алып 25 яшькә кадәр булган кешеләр арасында аралашу чарасы булып тора. Яшьләр, шушы сүзләрне кулланып, олы буын вәкилләреннән, официаль системадан яшеренәләр. Тар, ябык коллективларда башкаларга аңлашылмаслык итеп, конспирация максатыннан кулланыла торган сленглар актив кулланыла. Моңа каршы төшү-файдасыз.

Татар яшьләре арасында көнкүреш сленгы актив. Ул киң катлам яшьләр теленә генә түгел, татар телендә сөйләшүчеләрнең шактыена таныш. Яшьләр белән даими аралашкан өлкән буын вәкилләре дә әлеге сүзләрнең мәгънәләрен аңлый, хәтта ситуациягә бәйле үз сөйләмендә куллана да. Гомер буе балалар арасында эшләгәнлектән, минем әнием дә өйдә бик күп татарча сленглар кушып сөйләшә.

Гадәттә, әлеге сүзләрнең барлыкка килүен уртак кызыксынулары булган кешеләрнең башкаларга аңлашылмый торган итеп сөйләшергә омтылуы нәтиҗәсендә барлыкка килгән дигән караш яши. Яшьләр телендә исә бу төр лексика яңалык, модага иярү төсмере бирү, кабул ителгән тел өлгеләреннән читләшергә, заманча булырга омтылу, аерым бер кәеф, атмосфера тудыру өчен кулланыла.

Татар яшьләре сленгының зур күпчелек өлеше башка телләрдән кергән берәмлекләрдән тора. Хәзерге вакытта кесә телефоннары, SMS аралашулар, электрон почта, ICQ һәм интернет-чатларның актив кулланылуы яшьләр сөйләменә зур йогынты ясый. Белгәнебезчә, билегеле бер дәрәҗәдәге бу ясалма тел әдәби тел нормаларын бозуга, шуның өстенә яшьләр сленгы, башка төр жаргоннардан аермалы буларак, киң катлам вәкиләре теленә тиз арада үтеп керә һәм шул рәвешле телебездә чит элементлар таралуга, телебезнең табигыйлегенә зыян килүгә китерә. Күңелне борчыган бер нәрсәгә игътибарны юнәлтәсем килә: яшьләр сленгының активлашуы иҗтимагый-публицистик стильгә дә тәэсир итте. Хәзер яшьләр өчен язылган, я булмаса яшьләр тарафыннан иҗат ителгән язмаларда бу төр лексиканы иркен күзәтергә мөмкин. Мисал өчен, яшьләр һәм балалар газета-журналларыннан берничә мисалга тукталыйк: *Мондагы тормышның бер кызыгы юк: шул «общага», «универ», «универ» – «общага»* («Татарстан яшьләре» газетасы). *Синең кебек шәпский егетләрне ташлап киткәненә үзе үкенсен!* («Шәһри Казан» газетасы). *Программада күңелле җырлар, үтерически мәзәкләр, шәпский пародияләр.* («Балтач таңнары» газетасы). *Минемчә, «фэйс»не үткәндә, берничә гади кагыйдәне истә тотарга кирәк* («Кәеф ничек?» газетасы). *Заманага туры китереп, яшьләр смайликлар да төшерде* («Ялкын» журналы). “Аңлашылдымы? Шылды, шылды. Шылмаса, шылдырабыз аны”; “Татарча җырларны сибәбез генә,” диләр кызлар”; “Без монда чәчләрне йолкып-йолкып яңа идеяләр уйлап чыгарып утырдык-утырдык та...”

**1.3. Татарча сленгларның ясалу ысуллары**

Татар яшьләре сленгына күз салсак, аның составы шактый үзенчәлекле һәм төрле. Бәхәс уяткан мәсьәләләрнең берсе – татар теленең үз җирлегендә сленг ясалу мөмкинлеге. Чыннан да, беренче карашка, сленг лексикасы алынма сүзләрдән яки варваризмнардан гына тора шикелле. Сүз дә юк, алар зур күпчелекне тәшкил итә, әмма соңгы елларда телебезнең үз чаралары ярдәмендә дә сленг ясау шактый активлашты. Ясалышлары ягыннан да аларны төрле ысулар белән барлыкка килгәннәр дип әйтә алабыз. Гомумхалык сүзләре сленг рәтенә күчкәндә семантик яктан үзгәреш кичерәләр, мәсәлән, *“якынрак утырту”* - тегүчеләр телендә ваграк атлатып тегүне, *“батырып алу”, “кушучлап чуму”*-үзеңә тиешле өлештән күбрәк алуны, *“тәртә каеру”* –качарга тырышу, *“киптереп элү”*-ябыктыру, тәрбияләмәү, карамауны белдерә. Сленг лексика телнең үз сүзләре һәм алынмалар исәбенә дә тулылана (*ычкыну, сызу* - качу, *арба* - машина һ.б.).

**1.4. Татар теленең үз фондыннан ясалган сленглар.**

Беренче чиратта, татар теленең үз лексик фондындагы гомумкулланылыш сүзләрен күчерелмә мәгънәдә куллану һәм шул рәвешле кинаяле, эмоциональ эчтәлеккә ия булган мәгънә барлыкка китерү киң таралыш тапкан, мәсәлән, *кисәк* – мең сум акча, *сәдәф* –

таблетка, *шыттырма*-алдама, *чәпәш*-иркә, *чәк*-әз, пышкырт-ачулан, *лыгырдык*-күп сөйләүче, *сызу* – качу, *чеби* – кыз, *чәйнек*-тәҗрибәсез, *койрык* – «икеле» билгесе, югары уку йортларында укытучыга булган бурыч, *тәгәрмәч* – машина, *арба*-автомобиль, *кәттә*-киенгән ясанган, *татар малае*-башлы, тәртипле егет, *укыткыч*-укытучы, *беткәнский*-кердык(төрки сүз "кердек")-хана, һ.б.

Шулай ук гади сөйләм сүзләрен куллану еш очрый: *каефләнергә* – вакытны әйбәт үткәрү, *бөке* – юлдагы пробка, *мөгезле* – троллейбус, *акырафон* – микрофон.

**1.5. Русча сленгларны турыдан-туры тәрҗемә итүдән ясалаган сленглар.**

Урыс телендә кулланылган сленгларны турыдан-туры тәрҗемә итү юлы белән дә сленг ясалышын еш очратабыз: *текә* / *кәттә* – крутой, *чәйнек* – чайник (башлап өйрәнүче), *түбә* – акча түләтүче җинаятьче яки җинаятьчел төркем, *шәпчек*-топчик, һ.б.

Яшьләр теле, гомумән, кыскалыкка омтылу белән аерылып тора. Бу үзенчәлекне татар телендә ясалган, я булмаса башка телләрдән алынган сленгларда да күзәтәбез: *комп* – компьютер, *стипа* – стипендия, *физра* – физкультура, *лаба* – лаборатор эш, *фан* – фанат, *комбай* – көнбагыш, *шпора*– шпаргалка, *сәлкеш* – сәләтле кеше һ.б.

**1.6. Инглиз теленнән күчкән сленглар.**

Әлбәттә, болары инде телебезне өйрәнүгә тамчы да ярдәм итмиләр. Ләкин татар яшьләре сөйләмендә урыс яки инглиз телендәге сленгларны куллану киң таралган. Яшьләребезне рус-инглиз сүзләреннән аралый алмыйбыз. Бусы-факт! Заман таләбе! Мәсәлән, *киндер* (kinder) – кечкенә бала, *данслау* (to dance) – бию, *задрот* – зур хезмәт куеп, максатына ирешүче, күп укучы яки эшләүче, *респект* (respect) – хөрмәт, *ДУ* – универсиада авылы, *дискәтук* – дискотека, *сорри* (sorry) – гафу, *ОК* – барысы да әйбәт.

**1.7. Лицеебыз җирлегендә актив кулланылган заманча сленглар.**

Мин укый торган 24 нче номерлы лицей башка мәктәпләрдән үзенә генә хас булган үзенчәлекләре белән аерылып тора. Үзенең кечкенәлеге, бала санының аз булуы, төп белем алучы контингетның күбрәк татарлардан торуы туган телдә булган яңалыкларның тиз таралуына сәбәпчедер дә. Мин үзем бу исемдәге проектны 7 нче сыйныфта башлап җибәргән идем. Сыйныфташларым арасында да сайлаган темам тиз таралыш тапты. Шушы ике ел эчендә, сыйныфташларым, дусларым ярдәме белән әлбәттә, гади проект лицейда үзгә әйләнде. Мин шушы гади генә ысул ярдәмендә рус телле булган лицей малайларының сүзлек составын татарча сүзләргә баеттым. Мин аларны заманча яңгыраган рус, инглиз сленглары белән янәшә тупладым. Бездә актив кулланылучы татарча сленглар:

*малайка*-поцык, *хәчтерүш*-лошара, *корсакханә*-столовка, *әкәмәт*-кипиш, *бәбкәч*-няша, *исрафханә*-магаз, *үземчек*-себяшка, *чекрәймә*-не зырь, *бөкеләргә*-забанить, *чәлергә*-стырить, *мәмчек*-мемчик, *картлач*-старшак, *әстәгъфирулла*-о май, *шәәәп*-круто, *текә,*

*шалкан*-крутой, *коймак*-диск, *маңка*-салага, *лайкла*-лайкай, *манарасыз*-безбашенный, *мокыт*-тормоз, *бәләкәч*-малявка, *тай*-смойся, *көтмәүчелек*-нежданчик, *тукран*-стукач, *туңбаш*-отморозок, *кызган таба*-дискач, *кешнәмә*-не гоготай, *рисвай*-рофлить, *элдерт*-тикай с огорода, *куертма*-не гони, *колга*-дрыщ, башкан, *чын*-рил, *шәп*-найс, *ялган*-фейк, *көлчек*-смайлик,*тизкүчергеч*-шпоры, *юк-б&к*-трэш, *хәл-әхвәл*-статус, *кәеф-сафа кору*-чилить, *ат чыгару*-на хайпе, *җусаң җу, җумасаң җума*- французча сөйләшү, акыллы булып күренү, комп сүгенә(уррыр) –error, *шпәрә*- шпора һ.б. Алай гына да түгел, чит тел элементларын кулланып, ике яки берничә теленең сүз ясалыш чараларыннан яңа берәмлекләр дә ясадык: *шәпский,беткәнский, бетте, тайганский,шылганский, матурчик, лайклау* һ.б. Соңгы дәрестән китүче сыйныфташымның: "*Учителю скажете, мин шылганский*"-дигән сүзләре бер дә сәер яңгырамый.


### 1.8. Төрек теленнән татар теленә күчкән сленглар.

Лицеебызда төрек теле укытылу сәбәпле һәм шулай ук төрек иптәшләрнең дә еш килеп торуы ярдәмендә төрекчәдән күчкән сүзләр, соңгы вакытта сленгларга әйләнгән сүзләр дә еш очрый. Мәсәлән, *башкан*-баш кеше, *аптал*-тинтәк, *гулә-гулә*-кит әле моннан, *аркадашым*-иң якын дустым, *брум-брум*-тиз-тиз, *көчек, күчүк*- кечкенә бала һ.б. Боларның күбесе төрек теле сүзләре булса да, бездә сленг формасын алды. Чөнки аны бүтән мәктәп укучылары аңламый.

### 1.9. Татарча сленгларны мин ничек иптәшләрем, классташларым арасында таратам?


Хәзерге шартларда татарча сленглар таралуын төрле юллар белән тәэмин итәргә була. Без сыйныфтан тыш чараларда, дәресләрдә компьютер чараларыннан да, интернет мөмкинлекләреннән дә киң файдаланабыз. Менә, мәсәлән, **"Kahoot"** программасын гына алыйк. Татар теле һәм татар әдәбияты дәресләрендә сленглар кергән биремнәр эшләтеп куйсаң, кызыклы да, файдалы да.

Хәтта интернет челтәрендә эшләп килүче татар төркемнәре, сообществлар игътибарны җәлеп итәр өчен дә сленглар кергән шундый интерактив тестлар, уеннар куялар. Радиотапшыруларда шул темага багышланган сораулар бирәләр. Мәсәлән, түбәндәге скриншот шуңа дәлил.




Үзебез утыра торган төркемнәрдә, сообществоларда да без сленглар кулланып язышабыз.

(Үзебезнең Ватсаап челтәрендә сөйләшү скриншоты)↓




Сыйныф сәгатьләрендә, тәнәфесләрдә, ачык ишекләр көнендә үзем ясаган карточкалардан пазл төзеп уйнату да бике кызыклы шөгыль. Русчасын һәм татарчасын тиешле тәртиптә куярга гына кирәк (Үзебез төзегән 50 сүздән торган тулы уен комплекты бар).




## 1.10. Тикшеренүнең гамәли өлеше.

Хезмәтем өстендә эшләгәндә, лицей укучылары арасында төрле гамәли тикшерүләр дә уздырдым. Бу эштә миңа сыйныфташларым һәм фәнни җитәкчеләрем ярдәм итте. Анкета да 6-9 нчы сыйныфлар арасында 45 укучы катнашты.

“Татарча яшьләр сленгларын беләсеңме?”- дигән сорауга 91% белгәне турында әйтте. “Үз сөйләмеңдә кулланасыңмы?”- дигән сорауга 62% укучы уңай җавап бирде. “Татарча сленгларны нигә кулланасың?”-дигән сорауга “татарча сөйләшү –кызык” дип 63% укучы җавап бирде. “Татарча яшьләр сленгларын куллану мәгънәлелекне арттырамы?”-дигән сорауга “юк”-12%, “әйе”-56%, “бу модно”-15%, “текәлекне күрсәтә”-17%. **“**Татарча яшьләр сленгларын куллану татар телен өйрәнүгә ярдәм итәме?”-дигән сорауга “әйе”-70 %, “юк”-15%, “уйлаганым юк”-15%. **“** Сленглар кулланылырга тиешме?”-дигән сорауга “әйе”-85%, “юк”-15%. Нәтиҗә: укучылар арасында татарча сленглар белән кызыксынучылар күп. Аларны өйрәнү эше алып барылырга тиеш! “Татарча сленглар татар телен өйрәнүгә ярдәм итәләрме соң?”-дигән сорауга 17% “юк” дип, 83 % “әйе”-дип җавап бирде.

**Йомгак**

Үземнең фәнни-тикшеренү эшемне тәмамлаганда түбәндәге нәтиҗәләр ясадым. Сленгларны без функциональ аспектта гына тикшердек. Мондый төр лексика белән чиктән тыш мавыгу телнең аһәңлегенә, самими яңгырашына, табигый агышына гаять тәэсир итә. Шунлыктан матур әдәбиятка, публицистикада аларны куллануга саклык белән карарга кирәк. Гомумән, хәзерге вакытта яшьләр арасында рус телендә сөйләшкән вакытта да татарча сүзләр кушып җибәрү, яисә татарча сленг куллану-текәлек. Фәнни-тикшеренү эшләре алып барганда, сыйныфташ рус телле малайлар татарча сленглар әйтеп сөйләшә башладылар. Кызык өчен урынлы әйтеп җибәрелә торган сүзләр телгә, сөйләмгә эмоциональлек өсти, бизәкләп җибәрә. Татарча әйтелгәннәре телне белеп бетермәүчеләр арасында кызыксыну уята. Рус телле укучыларда да “Нишләп әле Билал белә, ә мин белмим”- дигән уй туа. Кабатлап торгач, истә кала. Тәнкыйтьчеләр күзлегеннән чыгып караганда, сөйләм кагыйдәләренең үтәлеше ягыннан алар бик урынлы булмасалар да, татарча сүзләрнең таралышына булышлык итәләр. Димәк, алар тел өйрәнүгә дә ярдәм итәләр булып чыга. Тел белән кызыксынуны арттыралар. Сөйләм теле мондый беркатлы “хилафлык”ны кичерергә тиеш!

Ләкин яшьләр арасында татарча сленглар куллану татар теленең таралуына да ярдәм итә. Чөнки җәмгыятьнең бу катламы һәр яңалыкны отып ала. Шулай ук, татар милләтеннән, татарча яхшы белгән яшьләргә мөрәҗәгать итеп, шуны әйтәсем килә: яшьләр сөйләме бу төр лексикадан азат була алмый, әмма телебезнең матур үрнәкләре, үз чаралары ярдәмендә яңа берәмлекләр ясарга, аларны актив кулланырга кирәк, заманча яңгырый дип, чит тел берәмлекләрен куллану белән мавыкмаска гына.

**Кулланылган әдәбият**

1. Береговая З. М. Молодежный сленг: формирование и функционирование // Вопросы языкознания.- М.: 2006, № 3.

2. Большая советская энциклопедия.- М.: Советская энциклопедия. 1969—1978.

3. Вальтов Х., Мокиенко В. М., Никитина Т. Г. Толковый словарь русского школьного и студенческого жаргона. – М.: АСТ, 2005.

4. Грачёв М. А. Словарь современного молодёжного жаргона. М.: Эксмо, 2006.

5. Горбачевич К.С. Особенности молодёжного жаргона. //РЯШ. 2001г.

6. Мардиева Л. А. Жаргонная лексика в публицистическом стиле татарского языка как результата лингвострановедческой интерференции // Сопоставительная филология и полилингвизм. - Казань, 2002, 180-182 с.;

7. «Проба пера» Гуманитарные науки»: материалы IX школьной международной заочной научно-исследовательской конференции. (26 сентября 2013 г.) — Новосибирск: Изд. «СибАК», 2013. — 198 с. 62 стр

8. Интернет-ресурслар:

vk.com›topic-2002448_21774710?post=1011

uslide.ru›russkiy-yazik/16520-molodezhniy-sleng-v…

http://rus.1september.ru/article.php?ID=200102304

http://history-kazan.ru/

https://matbugat.ru/news/?id=21225

**1 нче кушымта**

**Анкета «Яшьнең заманча сөйләме»**

**1.** Татарча яшьләр сленгларын беләсенме?

а) юк;

б) әйе;

**2.** Татарча яшьләр сленгларын үз сөйләмеңдә кулланасынмы?

а) юк;

б) әйе;

**3.** Татарча яшьләр сленгларын нигә кулланасың ?

а) бөтен кеше кулланганга;

б) татарча сөйләшү-кызык;

**4.** Татарча яшьләр сленгларын куллану мәгънәлелекне арттырамы?

а) юк;

б) әйе;

в) бу-модно;

г) текәлекне күрсәтә

**5.** Татарча яшьләр сленгларын куллану татар телен өйрәнүгә ярдәм итәме?

а) Әйе.

б) Юк.

в) Уйлаганым юк.

**6**. Сленглар кулланылырга тиешме?

а) Әйе.


б) Юк.

**2 нче кушымта**

**Үз сөйләмегездә татарча сленглар кулланасызмы?**

6 сыйныфлар, 17 кеше катнашты.  7 сыйныфлар, 9 кеше катнашты.

8 сыйныфлар, 10 кеше катнашты.  9 сыйныфлар, 12 кеше катнашты.




**3 нче кушымта**

**Татарча сленглар куллану татар телен өйрәнүгә ярдәм итәме?**



*Кадырова Камилә, 6 сыйныф,*
*Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районының «Адымнар - Түбән Кама "полилингваль белем бирү комплексы" муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесе*
*Җитәкчесе: Булатова Лилиә Шәмил кызы, тарих укытучысы*

**Минем гаиләм авыллары исемнәренең мәгънәсе**

«Үз илем үземә кадерле…»
*татар халык мәкале*

**Кереш**

**Топони́мика** - географик исемнәрне өйрәнүче һәм аның мәгънәсе фән.

Авыл һәм шәһәр исемнәре кайвакыт бик кызыклы була. Минем гаиләмдә әби-бабайлар төрле урыннарда тудылар. Мин аларның туган авыллары исемнәре нәрсә аңлатканы белән кызыксындым

Бу эшемдә мина әти әнием ярдәм итте, чөнки алар кечкенә вакытта авылда күп вакыт үткәрделәр.

*Максат:* Ата-бабаларымның ватан җирлекләре исемнерәнең килеп чыгышын өйрәнү.

*Вазифалар:*

1. Туганнарымның тормышын өйрәнү,туган авылда чәйнәу белән бәйле фактлар.
2. Авыл исемнәренең килеп чыгышы турында мәгълүмат булган тарихи чыганакларны барлау.

**Сөлек авылының әһәмияте.**

Сөлек авылы минем әбиемнең туган авылы. Минем әбиемнең исеме Ахунова Налиә Наил кызы. Бу авыл Сарман районында урнашкан.Сөлек авылы турында бер кызык риваять бар.

Бик куптәннән елларда өч бер туган Сөлек, Мөлек , Йөзек исемле бер туган Минзәлә елгасы янына килеп урнашкан.Бу тирәдә бернинди дә авыл булмаган. Алар шушы елганың сул як ярында урнашырга уйлаганнар. Шушында йорт җиткереп яшәп калганнар.Өлкән

абыйлары Сөлек исемле булган шуның хөрмәтенә бу төзеләчәк авылны Сөлек дип атаганнар.Алар өйләнешеп гаилә корганнар,авыл зурагайган, үскән.

**Чаллы Башы авылының әһәмияте.**

Чаллы Башы авылы минем бабаемның, Ахунов Тагирҗан Сабирзян улы туган авылы. Бу авыл Яңа чишмә районында урнашкан. Чаллы Башы авылы турында бер кызык риваять бар.

Югары Чаллы авылы чыгышы ревяятләргә караганга бу урында урман булган .Шушы урманга Чаллы исемле бер бабай гаиләсе белән килеп урнашкан. Аларның өч улы булган .Өлкән улларын урманны кисеп шушы урынга урнаштырганнар. Ә уртанчы улларына аз гына түбәнрәк урынга йорт салганнар. Кече улларын аннан бик ерак булмаган җирдә яши башлаган .Шушы малайларның әтисе хөрмәтенә авылларның урнаушына карап, исемнәр бирделәр: Югары Чаллы,Урта Чаллы,Түбән Чаллы. Ә Югары Чаллы авылын халык телендә Чаллы Башы дип тә йөртәләр.

**Шәнгәлчи авылының әһәмияте.**

Шәнгәлчи авылы минем әтиемнең әтисенең туган авылы. Аның исеме Кадыров Таһир Шамил улы. Ул анда ускәң, өләнгәң һәм вафат булган.

Шәнгәлчи авылы мавыктыргыч хикәя бар.

1902 елда Казанда басылып чыккан Х.Шәрәфетдин Рисалан Болгария китабында Шәңгәлчегә Барыс хан Субай һәм Шәнгәльчи уллары нигез салган дип әйтелә. Соңгы торак пункт хөрмәтенә исеме дә мөмкин.1006 елда Шәнгәлчи Зәй елгасы буйлап Идел буе Болгар ханына тугрылыкка ант итәргә барган. Авыл кешеләре сөйләвенчә, куршедә урнашкан Антле авылы янында басуда болгар кабер ташы бар. Ул известьташ башыннан 40-50 сантиметр. Калынлыгы 15 сантиметр чыгарылган. Янәсе, анда нигез салучы хан кызы кумелгән. Кабер ташы тирәсендә металл койма бар. Аңа динни бәйрәмнәр вакытында сөлгеләр яулыклар кулмәкләр һәм башка бәйләп куялар. Моннан тыш ташка тәнкәләр салалар. һәйкәлне авыл халкы карый алар анда бәйрәмнәргә йөри.

**Урмай авылының әһәмияте.**

Урмай авылы минем әбиемнең Кадырова Сания Мингалим кызы туган авылы. Бу авыл Чуваш якларында урнашкан. Минем әби укытучы булып эшләгән дә, аны Татарияга эшкә билгеләделәр. Анда ул минем бабай белән танышып, кияугә чыккан.

Дүрт йөз ел элек, риваят буенча, Олы Яушыдан хәзерге Вырнар районы хәзер мишәр авылы Урмай Комсомолск районы Хундырма елгасында урнашкан урында күчкәннәр.

Өч абыйның берсен Урмай дип атаганнар ,ул зирәк иде,хәм ул переска иректле җирләргә күченергә тәкъдим итте,ләкин алар абыйсы белән бергә яшәргә теләмәделәр. Авылны аның исеме белән атадылар.

**Йомгаклау.**

Тикшеренү проекты туган авыл тарихына мәхәббәт, аның үткәненә хөрмәт үстерүгә юнәлдерелгән.

*Нәтиҗәләр:*

*Әби -бабаларымның туган авыллары исеме турында бик күп кызыклы фактлар белдем.*

**Кулланылган әдәбият исемлеге:**


1. Академия наук Республики Татарстан. Институт татарской энциклопедии. URL: http://www.ite.antat.ru/articles/punkt_p/p_101.shtml
2. «Большой сборник пословиц» URL: https://www.poslovic.ru/blog/poslovicy-o-rodine-na-tatarskom-yazyke
3. Бурханов А.А. «Некоторые итоги изучения объектов историко-культурного наследия исторических сел Сармановского района», статья (с.16-40).
4. Википедия. URL: https://ru.wikipedia.org/wiki/Топонимика
5. Павлов, П. В. Шингальчи: вчера, сегодня, завтра / П. Павлов // Ленинская правда. – 2005. – 12 авг.
6. «Татарские села Чувашии» URL: https://nailtimler.com/tatars_in_russia/chuvashiya/tatar_villages_of_chuvashiya.html
7. Х. Шарафетдин «Рисалан Болгария», 1902 г. г.Казань
8. Яңа Чишмә хәбәрләре, “Татар авыллары тарихы: Чаллы Башы авылы”, 11.06.2018 URL: http://novoshishminsk.ru/news/yana-chishme/tatar-avyllary-tarikhy-chally-bashy-avyly

*Кәримуллна Әдилә, 9 сыйныф,*
*Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районының «37 нче күп профильле лицей» муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесе*
*Җитәкчеләре: Усманова Рузилә Рәшит кызы, Хәнәфиева Ләйсән Фәйзехан кызы, туган тел һәм әдәбият укытучылары*

## “Түбән Кама”, “Хатлар язам” шигырьләре

### Түбән Кама

Түбән Кама - туган калам,
Синдә тудым, синдә калам.
Кая барсам, кайда йөрсәм,
Йөрәгемдә мәңге сине йөртәм.

Шәһәр уртасында мәшһүр мәчет
Ямь өсти ул матур калага.
Туган җире әнкәй кебек якын
Һәр кешегә, һәрбер балага.

Шәһәребез күрке - Тукай паркы,
Әкияти дөньяга тиң.
Җиһанда синдәйләр юктыр,
Иң гүзәл шәһәр бит син!

Тормышымның һәр мизгеле
Синдә үткән, нурлы калам!
Тәнем белән, җаным белән
Монда тудым, монда калам!

### Хатлар язам

Ерактагы туганнарга
Әнием яза хатлар.
Сәламнәрне җиткерер, ди,
Күңел җылысын саклап.
Дусларыма хатларны
Бик еш язамын мин дә.

Телефоннан SMSлар
Җибәреп торам көн дә.
Сагынуымны белдереп,
Смайликлар да куям.
Дусларым да сагынганнар,
Күңелем белән тоям.
Әнием әйтә: “Чын хатлар
Саклый саф йөрәк хисен.
Аларда күреп була
Сагынуларның төсен”.
Ерактагы дусларыма
Кич утырып хатлар язам.
Күңелемдәге хисләрне
Кәгазь битенә салам.

*Низамов Ранил, 4 нче сыйныф,*
*Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районының «32 нче гимназия» муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесе*
*Җитәкчеләр: Мөбарәкшина Рузилә Рәшит кызы, туган тел һәм әдәбияты укытучысы,*
*Авдошина Нина Александровна, башлангыч сыйныфлар укытучысы*

## Карга боткасы – язны каршы алу тарихы һәм традицияләре

### Кереш

Карга боткасы – татарларның туклану өстенлеге ягыннан иң мөһим бәйрәмнәренең берсе. Бу бәйрәмнең бик күп вариантлары бар. Бу аны үткәрү урыны белән бәйле. Бүгенге көндә әби-бабаларыбыздан килгән күп кенә бәйрәм һәм йола күренешләре югалып бара . Менә шуны истә тотып, без туган ягыбызда онытылып бара торган милли йолаларның берсе - “Карга боткасын” өйрәнергә уйладык.

Тикшерену объекты: “Карга боткасы” татар халкының милли йоласы.

Тикшерену предметы: Татарстан Республикасы Мамадыш районы Иске Комазан авылында «Карга боткасы» милли йоласы.

Гипотеза: татар халкының милли йолаларын һәм бәйрәмнәрен өйрәнеп, без үз халкыбызның тарихы һәм мәдәнияте турында тулырак беләчәкбез.

Максат: татар халкының борынгы милли йоласын өйрәнү.

Бурычлар:

1. “Карга боткасы” милли йоласының тарихын белү һәм Иске Комазан авылы үрнәгендә тасвирлау.

2. Яшьләрдә милли йолалар һәм бәйрәмнәргә карата кызыксыну уяту.

3. Йолаларның һәм бәйрәмнәрнең тәрбияви әһәмиятен билгеләү, укучыларда башка халыкларга мәхәббәт һәм хөрмәт хисләре тәрбияләү.

4. Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы 32 нче гимназиясенең 4 нче сыйныф укучылары арасында анкета үткәрү.

Практик әһәмияте. Әлеге тикшерену эшен туган якны өйрәнү музейларында, туган тел, тарих дәресләрендә уку әсбабы буларак кулланылырга мөмкин. Өйрәнүнең теоретик базасын татар милли фольклорын үстерү мәсьәләләре буенча фәнни хезмәтләр тәшкил итә: Бакирова М. Х., Уразманова Р. К., Фазлыева Л. Р. Тикшерену ысуллары: эмпирик (өйрәнү, чагыштыру, туры килү); анкета.

**I “Карга боткасы” йоласының тарихы, традицияләре**

**1.1. “Карга боткасы” йоласының килеп чыгу тарихы**

Борын-борын заманда кешеләр нилектән яз булганын белмәгәннәр. Алар ямьле язны җылы яктан кара каргалар алып килә икән, дип уйлаганнар. Шуның өчен карлар эреп сулар ага башлагач, гөрләвекләргә таба, яңаруга-яшәрүгә йөз боргач, каргалар килү хөрмәтенә бәйрәм ясый торган булганнар. Аны “Карга боткасы” дип атаганнар.

Бу көнне балалар матур итеп киенгәннәр, йомырка җыйганнар. Хуҗаларга рәхмәт әйтеп, изге теләкләр теләгәннәр. Халыкны бәйрәмгә чакырганнар. Шулай авылны урап үткәннән соң, ярма, май, сөт алып, табигатьнең иң күркәм җиренә-кардан ачыла башлаган су буйларына, ялан-кырларга яки тау битләренә җыелганнар. Учак тергезеп, казан асканнар, ботка пешергәннәр. Ботка пешкәнче, төрле уеннар уйнаганнар, җырлар җырлаганнар, такмаклар әйтешкәннәр. Аннан соң, бергәләп, ботка ашаганнар.

Ботканы балалар үзләре генә ашап бетермәгән, аның күп өлешен, каргаларга дип ялан өстенә сибеп калдырганнар. Чишмә суына корбан иткәннәр.

Кырда учак ягу, ботка пешерү белән мәш килү балаларга әйтеп бетергесез рәхәтлек биргән. Соңыннан читкә китеп, каргаларның көтүе белән төшеп, ничек итеп карр-карр килеп ботка белән сыйлануларын карап куанганнар.

Балалар бу көнне бәйрәмгә хас булган келәү-теләүләр әйткәннәр, җирдән муллык, күктән яңгыр, кояштан җылылык, табигатьтән бәрәкәт, илгә туклык. Гаиләгә иминлек теләгәннәр. Җаннары-тәннәре белән кояшлы җылы көннәрнең тизрәк килүен, язгы ташуларның тизрәк агып китүен көткәннәр.

## 1.2. "Карга боткасы" йоласының борынгы ышанулар белән бәйләнеше

Карга боткасы – татарларның традицион бәйрәмнәренең берсе. Борынгы заманда кеше һәм табигать мөнәсәбәтләре йолаларбелән бәйле булган. Алар ярдәмендә кешеләр үз тормышларын җайга салу, аны тәртипкә китерү һәм фатиха алу өчен югары көчләргә мөрәҗәгать иткәннәр. "Карга боткасы" бәйрәме җир һәм игенчелек белән тыгыз бәйләнгән. Бу бәйрәмнең төп максаты – мул уңыш белән тәэмин итү. Хронологик яктан бу елның беренче календарь бәйрәме. Аны яз башында, каргалар килгәч үткәрәләр.

Күпчелек сакланган кычкыруларда йомырка Карга боткасы йоласының мәҗбүри элементы буларак искә алына. Йомырка традицион рәвештә Галәм символы булып санала; бөтен дөнья космосын үз эченә алган тема.

Йола карга культы белән бәйле. Каргаларны изгеләштерү, алар кайтуын бәйрәм итү йоласы бик борынгы заманнардан каргаларның җиргә җан алып кайтуы белән бәйле булган. Татарларда каргалар канат очында яз китерә дигән ышану бар. Мул уңыш алыр өчен аларны ашатырга кирәк, дип ышанганнар.

Татар халкында кара карганы изге кош дип санаганнар. Бу күренешнең эзләре бүгенге көндә дә сакланган: каргалар үтерергә, аларның ояларына кагылырга ярамый. Карга оясына кагылган кеше беркайчан да бәхет тапмас дип санала. Татарлар каргалар үз канатларында язны алып килә, дип ышана: Кошлар белән бәйле күп кенә кешеләр: «Карга килсә, кар китәр»;  «Кара карга килгәч, бер айдан яз килер» һәм башкалар. Шунысын да билгеләп үтәргә кирәк, карганы каршы алу бәйрәме – угор халыкларының йолалары системасында иң мөһимнәрнең берсе.

Мәсьәләнең визуаль ягы да мөһим: күрәсең, яз көне кара җирнең кардан арынуы элекке кешеләрнең аңында кара каргалар очып килүе белән бәйле булган. Төсләр һәм кошлар бәйләнеше такмакларда да сакланган. Мәсәлән, «Каргага кара кирәк, ә безгә ак май кирәк». Бәйрәмдә кычкырулар һәм кульязмалар балалар фольклоры системасында сакланып калган.

«Карга боткасы» - уеннар, такмаклар, «тылсымлы» әйтелмәләр ярдәмендә җирдән муллык, күктән яңгыр, кояштан җылылык, табигатьтән бәрәкәт, илгә туклык, гаиләгә иминлек,

язның, кояшлы җылы коннәрнең тизрәк килүен теләп, табигать көчләренә эндәшү, кырда пешерелгән ботканы җиргә, суга сибеп, җир-ананы хөрмәтләү, явыз рухларны куалау йоласы булган.

"Карга боткасы" күп гасырлар дәвамында төрле культларның синкретик бердәмлеге элементларын саклап калган: каргалар, су, Җир, шулай ук йола ризыклары, күңел ачулар. Тора-бара бу йолалар үзенең борынгы сыйфатларын югалтып, язгы бәйрәмгә әверелеп калган.

**II Хәзерге вакытта “Карга боткасы” йоласын үткәрү традицияләре**

2.1. Татарстан Республикасы Мамадыш районының Түбән Козгынчы авылында “Карга боткасы” йоласын үткәрү традицияләре

Мамадыш районы Түбән Козгынчы авылында Карга боткасы бәйрәме май аеның беренче көннәрендә үткәрелә. (Кушымта 1) Иртәгә ботка пешерәсе дигән көнне, һәр йортта хуҗабикәләр төрле-төрле ярмалар, май, тоз, йомырка, ит, борчак, бәрәңге әзерләп куялар. Иртән таң атуга 7-13 яшьлек малайлар, янчык, чиләк, сумкалар тотып өйдән-өйгә кереп боткага азык-төлек җыялар. Балалар капкадан керүгә, хор белән:

«Карга әйтә: кар, кар,
Туем җитте, барр, барр,
Ярма, күкәй алып бар,
Сый, маеңны салып бар».
«Карга әйтә: туем җитте
Ярма, күкәй алып бар,
Сөт -маеңны алып бар,
Ипи-чәең алып бар.
Өйдәме түтәй,
Тизрәк бир күкәй.
Бирсәң безгә өч күкәй
Тавыгың салыр йөз күкәй[1]”, - дип кычкыралар.

Хуҗабикә әзерләп куйган әйберләрен балаларның савытларына бушата. Һәр төр азык аерым савытка салына. Әйберләрне алып бетергәч, балалар тагын хор белән “Бал-бал күкәй, рәхмәт түтәй”- дип кычкыралар.

Азык-төлекне җыйгач, балалар кашык-савыт алып болынга җыела.

Ботка пешүгә дуслар, танышлар җир өстенә өстәл көйләп ботка белән сыйланалар. Ашап туйгач балалар төрле уеннар уйныйлар.

[1] Ягъфәров Р. Ф. Татар халкының уен фольклоры. Казан: Иман, 2002. – Б. – 118.

Бала - чаганың йорттан - йортка кереп йомырка, төрле тәм - томнар җыеп йөрүе бик зур тәрбияви әһәмияткә ия булган. Алар үзләренең туганнары һәм якын кешеләре белән очрашканнар, сөйләшкәннәр, аралашканнар. Бу вакытта өлкәннәр балаларны игътибар белән күзәткән: исәнләшә беләме, кыюмы, тапкырмы яки оялчанмы - гомумән, баланың үз-үзен тотышына бәя биргәннәр. Икенче яктан исә, балалар да өлкәннәрнең ачыклыгын, кунакчыллыгын, юмартлыгын, түземлелеген сынаган.

2.2. Социаль сораштыру

Әлеге теманы өйрәнү барышында мин сыйныфташларымның “Карга боткасы” йоласы буенча белемнәре белән дә кызыксындым. Түбән Кама шәһәре 32 нче гимназиянең 4 нче сыйныф укучылары арасында социаль сораштыру үткәрдем. (Кушымта 2) Сораштыруда 57 укучы катнашты.

- 90 % укучы бүгенге көндә борынгы йолаларны белү һәм аларны дәвам итү кирәк дип саныйлар
- 85 % укучы милли бәйрәмнәр халыкны берләштерә дип уйлый;
- 45 % укучының туганнары яшәгән районнарда, авылларда Карга боткасы йоласы уздырыла;
- 70% укучының Карга боткасыбәйрәмендә катнашканы бар;
- 95 % укучы бу бәйрәмне каргалар хөрмәтенә үткәрәләр дип саный;
- 50 % укучы “Өйдәме түтәй,

Тизрәк бир күкәй.

Бирсәң безгә өч күкәй

Тавыгың салыр йөз күкәй”, - такмагын белә;

- 50% укучы бәйрәмне елга буенда, 1 нче майда; 30 % укучы – мәдәният йортында; 20 % укучы – Сабантуй мәйданында үткәрәләр дип уйлый;
- 90 % укучы калган ботканы каргаларга ашаталар дип уйлый;
- 100 % укучының Карга боткасы бәйрәмендә катнашасы килә.

Сораштыру нәтиҗәләреннән күренгәнчә, безнең мәктәп укучылары милли бәйрәмнәрне беләләр һәм бик теләп катнашалар.

Без “Карга боткасы” йоласы темасына сценарий төзедек һәм аны сыйныфыбызда үткәрдек. Барлык укучылар да бик актив катнаштылар.

Шулай итеп, Карга боткаса бәйрәме зур тәрбияви әһәмияткә ия. Әлеге йоланы социаль-мәдәни мохиткә интеграцияләү традицияләрне яңартып кына калмый, шәһәрлеләрне һәм авылдашларны берләштерүгә дә ярдәм итә һәм буыннар дәвамчанлыгын күрсәтә.

## Йомгаклау

XX гасыр ахыры - күп халыкларда, шулай ук татар халкында да милли бәйрәмнәрнең яңару чоры. Һәрбер халык горурлык белән милли традицияләрне яңарта һәм яңа буын ата-бабалар мирасын дәвам итәр дип өметләнә. Халык бәйрәмнәре һәм йолалары үсеп килүче буынны тәрбияләүдә зур роль уйный. Башка халыкларга карата хөрмәт тәрбияләү дә мөһим, чөнки Мамадыш районында күп милләтләр яши.

Мин хезмәтемдә куелган максатка ирештем, бурычлар үтәлде, гипотеза расланды дип уйлыйм.

“Карга боткасы” календарь йоласы Түбән Козгынчы авылы балаларының һәм безнең мәктәп укучыларының популяр һәм яраткан бәйрәме булып тора. Яшьләр үз халкы белән горурланып үсә, милли гореф-гадәтләр, бәйрәмнәрдә теләп катнаша. Киләчәктә дә балалар үз мәдәниятләрен, диннәрен белерләр, үз халкын гына түгел, башка халыкларны да яратырлар һәм хөрмәт итәрләр дип ышанам.

**Кулланылган әдәбият исемлеге**


1. Бакиров М. Татарский фольклор. Казань: Ихлас, 2012. – 400 с.
2. Бакиров М.Х. Обрядово-мифологический синкретизм – колыбель древнейшей поэзии // Филология и культура. 2013. №3 (33). – с. 168-171.
3. Гамирзан Давлетшин. Понятие Родины у древних тюрков. https://www.tatarmir.com/stati/1065
4. Гыйльманов Г. Татар мифлары. Икенче китап. Казан: Тат. китап. нәшр., 1999. – 432 б.
5. Закирова И. Г. Мәңгелеккә аккан сулар бар // Милли-мәдәни мирасыбыз: Омск өлкәсе татарлары. Казан: ИЯЛИ, 2015. – Б. 240-266.
6. Мәхмүтов Х. Ш. Язылмаган кануннар. Казан: Тат. Китап. нәшр., 1995. – 173 б.
7. Уразманова Р.К. Обряды и праздники татар Поволжья и Урала (Годовой цикл. XIX – нач. XX вв.) Историко-этнографический атлас татарского народа. Казань: ПИК «Дом печати», 2001. – 198 с.

Ягъфәров Р. Ф. Татар халкының уен фольклоры. Казан: Иман, 2002. – 278 б.

*Мөбарәкшин Илгиз, 4 нче сыйныф,*
*Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районының «32 нче гимназия» муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесе*
*Җитәкчеләр: Мөбарәкшина Рузилә Рәшит кызы, туган тел һәм әдәбияты укытучысы, Авдошина Нина Александровна, башлангыч сыйныфлар укытучысы*

**Туган ягым**

Мин – Мөбарәкшин Илгиз. 32 нче гимназиянең 4 нче сыйныф укучысы.

Мин Татарстан Республикасының иң гүзәл урынында урнашкан Мамадыш районы Иске Комазан авылында туганмын. Мин туган ягымны бик яратам! Шигырьләремне дә туган ягыма, гаиләмә багышладым.

**Чишмәләр җыры**

Туган авылым салкын сулы
Чишмәләргә бай минем.
Җырлый-җырлый үзенә дәшә
Чишмәле туган җирем.

Сагынып кайтамын һәрчак
Шул моңнарны тыңларга.
Бик бәхетле, шат бала мин
Туган җирем булганга.

Әбием-бабаем янында үткән балачагымны мин гел сагынып искә алам.

Туган яктан янә ишетелә
Талгын гына җыр-моң көйләре.
Сез әле дә шундый ягымлымы
Мин яраткан авыл өйләре?

Кайтуымны өзелеп көтәсезме
Туганнарым, әби, бабаем?
Юк шул...
Сез юк инде...
Тик мин сезне
Онытмадым,

Оныта алмамын.

Синең төсең булып калды, бабам,
Кулларымда яшел гармуның.
Синең эзләреңнән мин дә барлыйм
Бизәкләрен татар моңының.

Туган якка миннән сәлам булып
Ишетелсен җыр-моң көйләре.
Онытмадым сезне, онытмамын
Тынып калган авыл өйләре.

**Минем бабай**

Минем бабай бик акыллы,
Минем бабаем зирәк.
Барыбыз өчен дә ул
Зур таяныч, нык терәк.

Кадак, чүкеч тотарга
Өйрәтә мине бабай.
Тәртипне дә онытмый:
“Артык шаярма, малай!

Беркайчан да чыкма, ди,
Әниең әйткән сүздән.
Минем өчен зур шатлык
Бәхетле булып үссәң”.

Бакчада да гел бергә без,
Балыкка да йөрибез.
Ишегалдын ялт иттереп
Кышын карлар көрибез.

Бабамны бик яратам мин
Тыңлыйм аның һәр сүзен.
Бабам булу бу дөньяда
Зур бәхет минем өчен!

**Энемә**

Бик бәхетле ел булды бу
Шатлык тулды күңелгә!
Әни энекәш алып кайтты
Минем туган көнемә!

Шушы көннән безнең тормыш
Матурайды, үзгәрде.
Энемнең шат авазы
Бизи безнең көннәрне.

Үзе кечкенә генә ул
Түп-түгәрәк йөзләре.
Төймә кебек уйнап тора
Аның зәңгәр күзләре.

Көннән-көн минем энемнең
Һөнәрләре күбәя.
Кечкенә генә булса да
Тәпиләргә өйрәнә.

Физзарядка ясыйбыз без
Иртән иртүк торгач та.
Энем туган хөрмәткә
Утырттык без агач та!

Энем булгач бездә хәзер
Көн дә бәйрәм шикелле.
Мине абый иткән өчен
Яратам мин энемне!

*Нуретдинова Рәзилә, 10 нчы сыйныф,*
*Муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесе Мөслим урта гомуми белем бирү мәктәбе им. Г. Тукай " Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районы*
*Фәнни җитәкче: Әсәдуллина Йолдыз Рәис кызы, тарих һәм җәмгыять белеме укытучысы*

## Муса Җәлил эзләреннән

### Кереш

**Теманың актуальлеге.**

Муса Җәлил бөек фронтовик шагыйрь. Аның үлемсез иҗатын мин бик яратам, дошманга нәфрәт белән сугарылган ялкынлы шигырьләрен кат-кат укыйм, яттан өйрәнәм,

сәхнәләрдән сөйлим. Курку белмәс татар егетенең фронттагы тиңдәшсез батырлыгына сокланам, аның белән чиксез горурланам. Муса Җәлилнең үткән сугышчан юлының кечкенә генә булса да бер өлеше минем туган ягым – Мөслим, тагын да төгәлрәк әйткәндә, мин укыган икенче санлы Мөслим урта мәктәбе белән бәйле булуы аңа карата булган җылы хисләремне тагын да яңартып шушы фәнни – тикшеренү эшен башларга этәрде. Вакыйгаларның шаһитләре әкренләп бакыйлыкkка күчә, ә истәлекләре язма рәвештә тупланып барылмый. Шуңа күрә мин бу эшемне нәкъ шушы темага багышларга булдым.

**Чыганакларга күзәтү.** Эзләнү-тикшеренү эше өчен Мөслим район үзәк китапханәсе туплаган “Авыл утлары” газетасы материаллары, авылдашларымның истәлекләре, Татарстанның атказанган мәдәният хезмәткәре Әхмәдулла Әхмәтгалиевнең “Мөслим төбәге: тарихи сәхифәләр” исемле китабы, Мөҗәһит Әхмәтҗановның “Кыңгыраулы мәктәп еллары” исемле китабы, Тамара Хановaның язмалары нигез итеп алынды.

**Фәнни-тикшеренү эшенең максаты** - Мөслим районы Мөслим урта мәктәбендә Муса Җәлил калдырган истәлекләрне барлау, музей экспозициясенең тарихын өйрәнү.

**Бурычлар:**

1) Муса Җәлилнең Мөслимдә төн кунуы тарихына караган материалларны өйрәнү;

2) истәлекләргә нигезләнеп, 1970 нче елларда Мөслим урта мәктәбендә өлкән пионервожатый эшен башкарган Ханова Тамара апаның тормыш сәхифәләрен теркәү;

3) 2005нче елда Мөслим урта мәктәбендә куелган музей экспозициясенең экспонатларын өйрәнү;

**Фәнни-тикшеренү алымнары:** тарихи документлар, истәлекләр һәм фәнни чыганакларны анализлау, системалаштыру.

## Төп өлеш

### Муса Җәлилнең Мөслимдә төн кунуы.

1941 елның үзәккә үтә торган салкын ноябре.Фашистлар армиясе Курск янына ук килеп җитә. Мусалар отряды Щигры шәһәренә күчәргә мәҗбүр була. Бераздан соң алар эшелонга төялеп Татарстанга – Минзәлә шәһәренә юл тоталар. Бу хакта шагыйрьнең сугышчан дусты И.Г.Степанов язып калдыра. Аның истәлекләреннән күренгәнчә, эшелон бик акрын бара. Тимер юллар ул чакта хәрби товарлар, гаскәри частьләр ташый. Шуның өстенә эвакуацияләнүче совет кешеләре белән тулы була. 24 көндә алар Бөгелмә станциясенә килеп җитәләр. Юлда да хәрби мәктәп (курс) үзенең эшен туктатмый, укулар дәвам итә. Курсантлар сугыш коралларының материаль частьләре буенча да, башка дисциплиналар буенча да зачетлар тапшыралар, аттестациягә әзерләнәләр.

Бөгелмә станциясеннән Минзәләгә кадәр йөзләрчә километрдан артык юлны алар стройга басып, җәяүләп узалар, бик күп татар авылларын үтәләр.  Ә бер төнгә каршы алар безнең Мөслим авылында тукталалар. Хәрби комиссариат аларны урта мәктәпнең спорт залына урнаштыра. Кунакчыл Мөслим халкы солдатларга бик теләп хөрмәт күрсәтә. Ашарларына китерәләр, җылы йон оекбашлар, бияләй, бүрекләр бирәләр.

И.Г.Степанов үзенең истәлегендә Муса белән гел янәшә атлавын горурланып искә ала: *"Бервакытта да Мусадан ару, талчыгу турында, походның авырлыгы турында сүз ишетмәдем. Ул һәрвакыт  көр күңелле, иптәшләренә игътибарлы һәм ярдәмгә әзер иде. Буш вакытларында шигырь язды,  совет халкының бәйсезлеген һәм бәхетен яклап, көннең кадагына суга торан әсәрләр генә иҗат итте"*, - дип язып калдыра.

1942 елның январендә алар курсларны тәмамлыйлар, аттестат алып, маршевый роталар белән фронтка китәләр...

*"Татарстан әдәбият җәмәгатьчелеге үзенең улын, шагыйрь һәм гражданинын тантана белән, Җәлилнең халык ышанычын намус белән аклаячагын, җиңү өчен тормышын һәм көчен кызганмаячагын әйтеп, озатып калды"*, - ди Степанов.

Муса Җәлил Мөслимдә кунып киткән чорда, аның  туганнан туган энесе Таһир Корбанов (соңрак ул Казан дәүләт педагогика институты доценты) безнең мәктәптә математикадан укыткан була. Тик, ни кызганыч, алар монда очраша алмыйлар. Еллар узгач, мәктәбебезнең крайны өйрәнү музее җитәкчесе Суфия Зәйнуллина Таһирның адресын табып, абыйсы Муса турында мәгълүмәтлар җибәрүен сорап яза. Җавап озак көттерми.

Таһир Корбановның хаты үзгәртүсез бирелә:

*"...Сезнең хатыгызны алдым. Мөслим мәктәбеннән хат алу минем өчен зур шатлык, чөнки 1941-1942 нче уку елында ярты ел чамасы мин ул мәктәптә укыттым. 1942 нче елның мартында шул авылдан армияга киттем.*

*Сез кызыксынган сорауга түбәндәгечә җавап бирергә мөмкин. Моннан ун ел чамасы элек сезнең мәктәптә булып, укучылар  алдында мин Муса Җәлил турында истәлек сөйләдем. Шунда Муса Җәлилнең Мөслимдә булуын әйттем. Ул менә болай булды.*

*1941 нче елның ноябре. Бик каты салкын бер көн иде. Мәктәптә миңа военкомат янына бер взвод чамасы солдатлар килеп туктаганлыгын әйттеләр. Мин алар янына бара алмадым. Икенче көнне мәктәпнең зур залында идәнгә бик күп салам түшәлгәнен күрдем. Салам арасында берничә пилотка ята иде. Минем сорауга каршы: "Монда кичә Мөслимгә килгән солдатлар кундылар, алар, бик иртә торып, җәяү Минзәлә ягына киттеләр", - диделәр. Кичен авыл халкы кайберләренә җылы оек, бияләй һәм бүрекләр биргәннәр. Шунлыктан берничәсе, салкын пилоткаларын ташлап, җылы бүрекләрдән киткәннәр. Бу команда Бөгелмә шәһәреннән Минзәләгә үтеп бара икән. Шушы командада  Муса Җәлил дә*

*булган. Мин аларны күрмәдем. Әгәр Мусаның шул мәктәп залында кунганлыгын белгән булсам, мин төне буе аның янынннын китмәгән булыр идем. Муса Җәлил – минем якын туганым. Безнең әниләр бертуган. Бәхетсезлеккә каршы, бу тарихи төндә без аның белән күрешә алмадык. Ләкин Мусаның шул залда кунуы хак. Соңыннан бу турыда миңа Минзәлә педучилище укытучысы Дәүләтьяров һәм башка берничә кеше сөйләде. Минзәләдәге хәрби-политик курсларны тәмамлаганнан соң, Муса Җәлил , политрук буларак, фронтка китә. Менә бу вакыйганың дөресе шул. Сезгә ихтирам белән, Таһир Корбанов. 19 нчы февраль, 1983 нче ел. Казан.”*

**Муса Җәлилгә багышланган экспонат.**

“Таш кисүнең авыр икәненә

Карарсыңмы, янып җилкенсәң?

Мин шат,

Әгәр дуслар һәйкәленә

Җилкәм белән бер таш китерсәм” (Шәйхи Маннур)

Дөньякүләм танылган күренекле шәхеснең исемен шушы мәктәптә мәңгеләштерү йөзеннән, 60 елларда Мөслим урта мәктәбенең пионер дружинасысына Герой-шагыйрь Муса Җәлил исеме бирелә. Мәктәп каршына аның бюсты урнаштырыла, 1983 елда мәктәп коридорына мемориал такта эленә. Герой-шагыйрьнең туган көнендә мәктәпнең беренче каттагы коридорында Герой-шагыйрьгә багышланган стенд-почмак эшләнеп, анда Мусаның энесе Таһир Корбановның хаты, шагыйрьнең кайбер фотолары, шигырьләре урнаштырыла. Соңгы елларда элеге экспонат яңартылды һәм тулыландырылды. Аны ачу тантанасында элеккеге район башлыгы Р.Р.Хәбипов та катнаша.

**Муса Җәлил исемендәге пионер дружинасы.**

1960 елларда Мөслим урта мәктәбенең пионер дружинасысына Герой-шагыйрь Муса Җәлил исеме бирелә. Яшь җәлилчеләрнең ничек эшләүләрен тирәнерәк белү максатыннан шул елларда дружина советы председателе булып эшләгән Тамара Мөхәммәт кызы Ханова белән очрашып, җанлы әңгәмә оештырдым. Ул моңа бик шат булды, пионерлар белән мәктәптә һәм мәктәптән тыш нинди чаралар үткәрелүе турында тәфсилләп сөйләде. Чыннан да, бу олы, мактаулы исемне югару тоту, аңа лаелы булу максатыннан мәктәп күләмендә киң кырлы эшләр, зур тәрбияви чаралар үткәрелә. Пионер сборлары, комсомол җыелышлары, учком (укучылар комитеты) утырышлары укучыларның зур активлыгы шартларында уза.. Аларда үткән эшләрне барлау белән рәттән алга планнар да куела, аларны үтәүгә җаваплы кешеләр билгеләнә. Ул елларда шулай ук укучылар үзидарәсе дә бик көчле эшли. Мәктәптән тыш чаралар үткәрү дә бик күркәм төс алган. Дружина Герой-шагыйрь Муса Җәлил исемен йорткәнлектән, ел саен февраль ае хәрби

патриотик тәрбия айлыгы дип игълан ителгән. Мәктәп каршындагы Муса Җәлил бюстына тантаналы төстә венок салына, дружина сборы үткәрелә. Калинин исемендәге бакчадагы обелискка сбордан соң ук венок куела.

Укучыларның белемнәрне нигезле үзләштерүенә ирешү, җәмгыятькә файдалы хезмәт итүенә ирешү – дружинаның иң мөһим бурычларыннан санала. Ул вакытта “Тимурчылык” хәрәкәтләре киң җәелдерелә. Металл ватыклары, макулатура җыеп тапшыру буенча да дружина алдынгылардан була. “Кар десанты”, “Аҗаган”, “Бөркеткәй” кебек хәрби-патриотик уеннар үткәрү матур традициягә әйләнә. “Бөркеткәй” уенының финалы Җиңү бәйрәме көнендә Мөслим урамнары һәм Бөек Ватан сугышында һәлак булганнар истәлегенә төзелгән обелиск яныннан парад үтү белән тәмамлана. Әлеге уеннар белән Бөек Ватан сугышы ветераны, “Батырлык өчен” медаленә һәм күп сугышчан бүләкләр иясе, хәрби хәзерлек һәм тарих укытучысы Мидхәт Фәтхуллин җитәкчелек итә. Аның “Азимут” исемле яшь эзтабарлар экспедициясе озак еллар буе илебезнең төрле почмакларыннан сугыш ветераннары, архив-музейлар белән тыгыз элемтәдә тора, хәбәрсез югалган фронтовикларны, тарих битләрендәге ак тапларны ачыклауда зур эш башкарды.

**Йомгаклау**

15 февральдә хакыбыз зурлап Советлар Союзы Герое, илебезнең легендар улы Муса Җәлилнең зур юбилеен - 117 еллыгын билгеләп үтә. Муса Мостафа улы Җәлилов 1906 елда Оренбург өлкәсенең Мостафа авылыда туа. 1944 елның 25 августында Германиянең Плетензее төрмәсендә үтерелә. Муса тормышының соңгы минутына кадәр изге туфрагына, иленә, намусына тугры булып калган, гильотинага башын куйганда да хыянәт итмәгән.

“Үлгәндә дә йөрәк тугры калыр

Шигыремдәге изге антыма”, - дип язган ватанпәрвәр. Шагыйрьнең исеме кешелек тарихы сәхифәләренә алтын хәрефләр белән язылган. Бөек Ватан сугышы чорында күрсәткән тиңдәшсез батырлыклары өчен шагыйрьгә 1956 елның 2 февралендә Советлар Союзы Герое исеме бирелә, әсирлектә иҗат иткән “Моабит дәфтәрләре” өчен 1957 елда Ленин орденына лаек була. Геройның иҗаты үлемсез. Күренекле таҗик шагыйре Мирза-Турсун Задә татар халкының горурлыгы булган Муса турында: “*Аның “Моабит дәфтәрләре” Памирның иң ерак кышлакларына хәтле җитте. Кем җиңеп үлә – ул үлемсез. Муса Җәлил венгр шагыйре Петефи һәм Чехославакия улы Юлиус Фучик белән бер рәттә. Җәлил шигыйрьләре халыкларны якты киләчәк өчен көрәшкә чакыра, ул гасырлар буе балкып торыр”*, - дип язган.

Белорус шагыйре Петрусь Бровка исә: *“Палач балтасы астында шундый зирәк, Ватанга чиксез мәхәббәт, ә фашистларга карата җимергеч нәфрәт тулы ялкынлы юллар*

*язу өчен тимер, сыгылмас ихтыярлы, якты акыллы, зур һәм кайнар йөрәкле булырга кирәк"*, - дип язып калдырган.

...Фашизма тоткынлыгында йөрәген ялкынлы факел итеп күтәреп, ярты Европаны түшендә шуышып үтеп Берлинга барып җиткән, үзенең фаҗигалы үлемеме белән МӘҢГЕЛЕК ҮЛЕМСЕЗЛЕК яулаган батыр сугышчы, дөнья күләм танылган легендар шагыйрь Муса Җәлил бүген дә безнең мәктәп укытучылар һәм укучылар коллективының, бөтен мөслимлеләрнең йөрәк түрендә яши.

**Кулланылган әдәбият исемлеге:**


- С.З.Сибгатуллина мөхәррирлегендәге "Муса турында истәлекләр" китабы, Казан, 1964.
- М.З.Әхмәтҗанов "Кыңгыраулы мәктәп еллары", Казан, 2006.
- "Безнең мәктәп мәтбугат битләрендә" дигән альбом.



*Раимова Самира,7 нче сыйныф,*
*Татарстан Республикасы Агерҗе муниципаль районы Кучуков урта гомуми белем бирү мәктәбе муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесе*
*Җитәкчесе: Лотфуллина Илгиза Зуфаровна , педагог-китапханәче*


## Һәйкәл булып баса ветераннар

### I. Кереш

Онытырга безнең хакыбыз юк
Узган Бөек Ватан сугышын.
Әле һаман тоеп яшибез күк
Ул дәһшәтле еллар сулышын.
Д.Абдуллин

Сугыш! Әлеге сүзне ишеткән саен, җаннар тетрәнә, күңелгә курку катыш хәсрәт хисе тула. Әйе, күп корбаннар таләп итә әлеге фаҗига: яшьли өзелгән чәчәк кебек гомерләр, тулысынча ятим калган балалар, йөрәк парәләрен үзләреннән алдан җирләгән ата-аналар, утка тотылган шәһәр-авыллар, бомбалар шартлаудан тишкәләнеп беткән иген кырлары... Боларны бернинди үлчәүләргә салып та үлчәп булмый, җан яралары, тән сызлаулары да еллар узган саен арта гына бара. Авылларны тергезеп, шәһәрләрне яңадан аякка

бастырсалар да, сугыш үткән урыннарда әле бүген дә яралыларның авыр ыңгырашканы, бомба, снаряд тавышлары ишетеләдер кебек.

Бөек Ватан сугышының дәһшәтле һәм фаҗигале көннәре елдан-ел ераклаша бара. Әмма халкыбыз 1418 көн буена дәвам иткән ул коточкыч вакыйгаларны һич тә онытa алмас. Онытырга хакыбыз да юк! Чөнки 27 миллионнан артык совет кешесе илебезнең якты киләчәге өчен, Ходайдан бер генә бирелгән гомерләрен кызганмыйча, яу кырларында ятып калды. Ватандашларыбыз күрсәткән батырлыклар күпләргә үрнәк, сынып-сыгылып калмаска терәк, җиңүгә этәргеч булган дип әйтсәк тә, ялгышмабыз. Түбәндәге юллар – моның ачык дәлиле.

Татарстан сугышчыларының 300 нә Советлар Союзы Герое дигән исем бирелә. Республикада туып-үскән 50 каһарман – өченче дәрәҗәдәге Дан ордены, йөзләрчә батырыбыз төрле дәрәҗәдәге орден һәм медальләр белән бүләкләнә. Унөч якташыбыз Бөек Ватан сугышында үз гәүдәләре белән дошман амбразурасын каплый. Александр Матросов (Мөхәммәтҗан Шакирҗанов) үрнәген кабатлаучылар арасында Г.Гафиятуллин, Б.Шәвәлиев, Х.Зарипов, А.Исаев, Н.Идрисов һәм башкалар була.

Егет һәм кызларыбызның әлеге батырлыклары күп кенә әдәби әсәрләрдә, шигырь-җырларда яктыртылган. Бу урында Габдрахман Әпсәләмовның “Газинур” романын искә алып үтәсе килә. “Ажгырып торган амбразурага берничә адым калгач, Газинур бик азга гына туктады... Фашист пулеметы котыруының соңгы чигенә җитеп үкерә. Кара амбразурада пулемет авызыннан чыккан ялкын утлы хәнҗәр төсле айкала. Кышкы зәһәр җил кебек пулялар чиелдап сызгыра. Артык бер генә минут та көтәргә ярамый, һәр секунд безнең җиңүебезне тоткарлый, уннарча сугышчыларның гомерләрен алып китә.

Газинурның карары нык. Аның күңелендә курку да, тетрәү дә, икеләнү дә юк.

– Туган ил өчен! – дип кычкырды ул һәм, яшәү белән үлемсезлек арасындагы ике адым җирне йөгереп үтеп, үкереп торган фашист пулеметы авызына күкрәге белән капланды...”

Мондый батырлыкны туган иленең чын каһарманы гына башкара ала, әлбәттә.

Әйе, зур кыенлыклар, коточкыч югалтулар кичерергә туры килсә дә, республикабыз хәрби вакыттагы бурычларны намус белән үти һәм дошманны тар-мар итүгә лаеклы өлеш кертә.

Ә бу миллионланган җаннарны тетрәткән көн туган авылымда ничек башланган соң?

Сугыш башлану турындагы хәбәр туган авылым Көчеккә 1941 елның 22 июнь көнендә сәгать икеләрдә килеп җиткән. Бик матур кояшлы көн була. Авыл халкы үз эше белән мәшгуль: кемдер печән әзерли, кемдер колхоз басуын утый. Авыл Советы бу хәбәрне алу белән бөтен халыкны Мәдәният йорты каршына митингка җыя. Шул көнне үк Көчек авылыннан 40 кешене 4 олау белән сугышка озаталар. Сугышка киткәннәрнең күбесенә туган авылына кире әйләнеп кайту бәхете насыйп булмый.

Бүгенге көндә авылыбызда бары тик ике ветеранлыбыз гына исән: Зиннәтуллин Гыйният, Шәехов Хәмәт.
Күршебездә яшәгән Кави бабай Садыков мәрхүм булды. Ә аның сугыш еллары турында сөйләгән хатирәләре көннән-көн минем хәтергә ныграк сеңә бара. Сугыш һәм хезмәт ветераны Кави бабайның исән чагында күкрәген бизәп торган орден-медальләре, бер өем рәхмәт хатлары балаларына, оныкларына әле бүген дә бабайның якты истәлеге, дәһшәтле көннәрнең онытылмас хатирәсе булып тора.

## II. ТӨП ӨЛЕШ

1. Татарстан Бөек Ватан сугышы чорында

Бөек Ватан сугышының дәһшәтле һәм фаҗигале көннәре елдан-ел ераклаша бара. Әмма халкыбыз 1418 көн буена дәвам иткән ул коточкыч вакыйгаларны һич тә оныта алмас. Сугышта 27 миллионнан артык совет кешесе һәлак булды, дистәләрчә миллион хатын-кыз – тол, бик күп балалар ятим калды, инвалидлар биниһая булды. Илебез ярым җимерек хәлгә килде, халкыбыз күпме кайгы-хәсрәт кичерде!
Шуларны уйлыйсың да, “Бу сугыш котылгысыз идеме соң?“ – дигән сорау алга килеп баса. Әйе, аңа 30 нчы еллар уртасында һәм хәтта әле соңрак та киртә куярга, сугышны булдырмый калырга мөмкин иде. Германиянең СССР га каршы һөҗүм итәргә әзерләнүе турындагы хәбәрләр уйдырма төсендә бәяләнде. Нәтиҗәдә, илебез сугышка әзерлексез килеп керде. Әмма, моңа карамастан, халкыбызның сабырлыгы, тырышлыгы, үҗәтлеге, батырлыгы аркасында без, барлык авырлыкларны узып, Җиңүгә ирешә алдык. Әлеге җиңүдә татарстанлыларның өлеше дә бәяләп бетергесез.
Бәйсезлегебезне саклап калу өчен республикабызда берничә укчы дивизия оештырыла. Сугышка озатылыр алдыннан аларга Татарстан Югары Советының шефлык байраклары тапшырыла. Татарстанда оештырылган 334, 352 нче һәм 146 нчы укчы дивизияләр – Мәскәү, ә 147, 120 нче укчы дивизияләр, 91 нче аерым танк бригадасы Сталинград фронтларына җибәрелә. Республикабызның 700 меңгә якын улы һәм кызы илне сакларга китә, аларның 340 меңнән артыгы сугыш кырында ятып кала.
Татарстан хезмәт ияләре дә дошманны җиңүгә лаеклы өлеш кертә. Зур икътисади куәткә ия булган, әһәмиятле су һәм тимер юллар чатына урнашкан республика сугыш елларында илнең тыл базасына әверелә. Анда 70 тән артык предприятие күчереп урнаштырыла. Алар арасында Горбунов исемендәге Мәскәү авиация заводы, Гомель аяк киемнәре фабрикасы, Ленинград металл заводы, Мәскәү сәгать заводы бар.
Заводлар белән бергә республикага эшчеләр, инженерлар, аларның гаиләләре дә килә. Татарстан үз “куенына” фашистлар басып алган шәһәр, авыллардан күчеп килгән бик күп балаларны да сыендыра.

Сугыш елларында фронтка ярдәм хәрәкәте киң колач ала. Республика хезмәт ияләре фронтка 10 миллион данә җылы кием, танк колонналары һәм авиаэскадрильялар төзелешенә 262 миллион сум акча җыеп җибәрәләр. Татарстан дәүләткә 131 миллион пот ашлык, 39 миллион пот бәрәңге, 56 миллион пот ит бирә. Дүрт елда армиябез Казаннан 21 меңнән артык самолёт ала. Бу – илдә җитештерелгән һәр җиде самолётның берсе дигән сүз. Татарстан, башка республикалар кебек үк, хәрби вакыттагы бурычларны намус белән үти һәм дошманны тар-мар итүгә лаеклы өлеш кертә.

2. Исәннәрнең кадерен бел,үлгәннәрнең каберен бел

Әйе, кеше гомере, тормышы – бернинди акчалар, байлыклар белән дә бәяләнми торган хәзинә ул. Шушы Ходайдан бер генә бирелә торган хәзинәне вакытсыз тартып алырга беркемнең дә хакы юк! Илебезне таң белән бомбага тотар алдыннан, тыныч кына яшәп яткан халыкны кырмыска оясын таяк тыгып туздыргандай пыран-заран китергәнче Гитлер моны уйлады микән, бу сугышның күпме җаннарны “йотасын” күз алдына китерде микән? Мөгаен, юктыр.

Бөек Ватан сугышында һәлак булган авылдашларым истәлегенә куелган һәйкәл яныннан узган саен, минем күңелгә шушындый уйлар тула. Җиңү көнен якынайту өчен, авылыбызның күпме кешесе яу кырларында ятып калган бит.

...Сугыш башлану турындагы хәбәр туган авылым Көчеккә 1941 елның 22 июнь көнендә сәгать икеләрдә килеп җиткән. Җәйге кояшлы матур көн. Чип-чиста зәңгәр күк йөзендә талгын гына карлыгачлар оча. Җәйге җылы җил исә. Кошлар сайрый. Авыл халкы бар да үз эше белән мәшгуль: кемдер печән әзерли, кемдер колхоз басуын утый. Җырлый-җырлый, көлешә-көлешә эшлиләр. Һәм шушы гүзәллекне бозып хәбәр килә: Сугыш!

Авыл советы тиз арада бөтен халыкны мәдәният йорты каршына митингка җыя. “Бүген таң белән герман солдатлары безнең илебезгә басып кергәннәр. Дошман самолётлары шәһәрләребезне, авылларыбызны бомбага тоталар икән“, - дигән сүзләрдән авыл ах итә, бер мәлгә тирән тынлык урнаша. Әйтерсең, җай гына яшәп яткан авылның кендек каны тамыры шартлап өзелә.

Күп тә үтми, урам чатларында, капка төпләрендә төркем-төркем булып ирләр җыелыша. Кемгә кайчанга чакыру килгән – шул турыда сорашу, сөйләшү китә. Күпләренә хәрби комиссариатка чакыру килеп өлгергән була инде.

Авыл кырмыска оясы кебек мәш килә. Туган-тумача бер-берсенең хәлен белергә ашыга. Яңарак өйләнешкәннәр, сөйгәннәрен кочып, өлкәннәргә күрсәтмичә генә мышык-мышык елашалар. Итәкләре бала тулы хатыннар, ирләренең муеннарына асылынып: ”Бәгырькәем! Ятим калдырып китәсең бит? Бу сабыйларым белән синсез нишләрмен?“ – дия-дия, яулык очы белән күз яшьләрен сөртәләр.

22 нче июнь көнне үк Көчек авылыннан 40 кешене 4 олау белән сугышка озаталар. Беренче олауда гармунчы, өздереп, йөрәк яргыч көйләр уйный. Аңа кушылып кемдер җыр суза:

Атландым атның биленә,

Киттем Герман иленә.

Герман иле – кара урман,

Әллә кайтам, әллә үләм.

Ир-атларны озатырга авылның олысы да, кечесе дә җыела. Күбесе, елый-елый, күрше Рус Шаршадысы авылына хәтле җигелгән атлар артыннан бара, ә кайберәүләр хәтта район үзәге Әгерҗегә кадәр озата.

Көчек авыл советы территориясенә кергән авыллардан сугышка барысы 486 кеше китә. Шуларның 184 е, Җиңү яулап, туган якларга исән-сау әйләнеп кайталар. Ә 302 кеше яу кырында ятып кала. Көчек авылыннан – 36, В.Бодья авылыннан 63 каһарманга туган якларын күрү бәхете насыйп булмый.

Ирләр фронтка киткәч, авылдагы эш нигездә хатын-кызлар җилкәсенә күчә. Алар тракторчылар, комбайнчылар, бригадирлар булып та эшлиләр. Аның өстенә әле урман кисүләр, зәмһәрир салкыннарда окоп казулар да өстәлә. Өй арасындагы тавык та чүпләп бетерә алмаслык эшләрне әйтеп торасы да юк. Барлык эшләр беткәч, төннәрен фронтка бияләй-оекбаш бәйләү, кием-салым юнәтү, сохарилар киптерү кебек шөгыльләрдән дә читтә калмый тылдагылар.

Үзләренең тамаклары такы-токы булуга карамастан, авыл халкы Мәскәүдән эвакуацияләнгән 8 гаиләне дә, туганнарыдай кабул итеп, яннарына сыендыра. “Алар арасында булган Мартынова фамилияле кызның (исеме төгәл билгеле түгел) “Катюша” җырын бик оста башкаруын тыл афәтен күрүчеләр бүген дә яхшы хәтерли торгандыр“, – дип искә ала авыл музее җитәкчесе Фатхулова Маһира апа.

Тылдагылар өчен иң авыры өйләргә кара мөһерле хат килү була. Ә андый хат һәрбер йортның капкасын шакый диярлек. Тыныч киләчәгебез өчен күп авылдашым яу кырында башын сала.

Исән кайткаННарының да тән сызлаулары һәм җан яралары, еллар узган саен, санын киметә бара. Бүгенге көндә авылыбызда бары тик ике ветеранибыз гына исән: Зиннәтуллин Гыйният, Шәехов Хәмәт.

...Ә һәйкәлләрнең теле юк. Алар сүзсез генә безгә: “Туган ил өчен, тынычлык, бәйсезлек, матур киләчәк өчен гомерләрен дә кызганмаган батырларны онытырга хакыгыз юк! Алар – мәңгелек! Без – мәңгелек!!!” – дип искәртеп тора сыман. Тыныч йоклагыз, авылдашлар, чит җирләрнең авыр туфрагы сезгә йомшак мендәр булсын! Сез кан коеп яулаган тынычлыкны бозарга башка беркемнең дә кулы күтәрелмәсен!

3. Язылмаган язмыш

Җиңү... Бу сүзнең ни дәрәҗәдә кадерле, күңелгә якын икәнлеген безгә караганда бабаларыбыз яхшырак аңлыйдыр. Хәзерге буын кешеләре җиңүнең ни бәрабәренә бирелүен кинофильмнар карап, китаплар укып кына белә алабыз. Әби-бабаларбыз исә бәйсезлегебезне гомерләрен аямыйча, кан-тир түгеп, зур тырышлыклар белән яулап алганнар. Күршебез Кави Габденур улы Садыков та моңа лаеклы көчен керткән.

Кави Садыков 1927 елның 15 гыйнварында Көчек авылында дөньяга килә. 14 яшендә олылар белән беррәттән сука сукалый, тырмалый. Киләчәктә туган авылында эшләп, гаилә корып, матур тормыш кичерергә хыяллана.

Үсеп килүче буынның бөтен хыялларын челпәрәмә китереп, 1941 елда сугыш башлана. Кави бабай 17 яшендә гаиләсеннән, туган йортыннан аерылып, сугышка китә. Пенза өлкәсендә укулар узганнан соң, 1944 елның 14 маенда бабай дивизиясен Ерак Көнчыгышка алып китәләр. Ул көннәрне ветеран күз яшьләрсез искә ала алмый иде: “Җәй. Чамасыз кызу. Безнең алда Монголиянең иң куркыныч Гоби чүле. Бер атна кичтек шуны. Күбесенчә төнлә бардык, чөнки көндез кояш кызуында чыдарлык түгел. Безгә машиналарны калдырып, җәяү барырга туры килде. Бер атна сусыз тилмердек. Чикне кичеп Маньчжуриягә чыктык. Һәм менә безнең алда бөек Кытай стенасы. Биеклеге – искиткеч. Карасаң, башыңнан бүрегең төшеп китәрлек. Киңлеге, ныклыгы турында әйтәсе дә юк. Ләкин без аны узарга үзебездә көч таба алдык. Ул минутларда безнең җиңү теләгебезгә бернинди Бөек Кытай стеналары да киртә була алмый иде.

Японнар чигенде. Иң элек Порт- Дальнийны алдык”, – дип сөйли иде ул. 1945 елда Порт-Артур өчен барган дәһшәтле сугышта бабайның аягы каты яралана һәм ул госпитальгә эләгә. 20 тәүлектән соң кире алгы сызыкка чыкканда, Японияенең иң көчле армиясе капитуляцияләнгән була.

Сугыштан соң совет солдатлары Кытайны аякка бастырырга ярдәм итәләр. Шушы бурычны үтәп, күршебез бары тик 1952 елда гына туган йортына кайта ала. Авылыбызда тракторчы, аннан ревкомиссия рәисе булып эшли. Гаилә корып, тормыш иптәше белән дүрт бала тәрбияләп үстерәләр.

Пенсиягә чыккач та тынгысыз җанлы күрше бабай тик утырмый, авылыбызның Ветераннар советы рәисе вазифасын башкара. Кече җанлы, ярдәмчел, намуслы булганга күрә Кави бабай авылыбыз аксакаллары арасында хөрмәткә лаеклылардан берсе була.

Бүген дә күрше бабайны авылның олысы-кечесе сагынып искә ала, күңелендә аңа карата рәхмәт хисләре йөртүчеләр дә аз түгел.

Мине Кави бабай үз оныгы кебек күрә  иде. Һәрвакыт киңәшләр биреп, өй арасындагы эшләргә өйрәтеп, янында ияртеп йөртте. Мин аннан бик еш кына сугышта күргәннәрен

сөйләтә идем. Инде бабай мәрхүм булса да, аның сугыш еллары турында сөйләгән хатирәләре көннән-көн минем хәтергә ныграк сеңә бара. Сугыш һәм хезмәт ветераны Кави бабайның исән чагында күкрәген бизәп торган орден-медальләре, бер өем рәхмәт хатлары балаларына, оныкларына әле бүген дә бабайның якты истәлеге, дәһшәтле көннәрнең онытылмас хатирәсе булып тора.

## III. ЙОМГАКЛАУ

Кешелек тарихына кайгы битләре белән кереп калган сугыш вакыйгаларыннан вакыт безне торган саен ераклаштыра бара. Аның шаһитлары – ветераннарыбыз да кимегәннән- кими. Алар сугыш елларының ачы газабын ничә еллар инде үз йөрәкләрендә, хәтерләрендә саклыйлар, дәшмиләр, зарланмыйлар. Ветераннарның теләге бер: Башка сугышлар кабатланмасын!

Безгә, яшьләргә, узган вакыйгаларны белү аеруча мөһим. Үткәнен белмәгәннең киләчәге юк, диләр. Чыннан да, тарихны өйрәнү, белү безгә киләчәгебезне төзегәндә ярдәм итәчәк. Булган ялгышларны табып, башка андыйларны кабатламаска, дөрес карарлар кабул итәргә нигез булачак.

...Мин – гади бер укучы. Кешелек тарихында иң коточкыч сәхифәләрнең берсе булган Бөек Ватан сугышының гаепләләрен эзләп таба да, сәбәпләренә тирәнтен төшенә дә алмам, бәлки. Ләкин шушы эшемне әзерләгәндә авыл музеенда эзләнүләрем, сугыш турында укыган әсәрләрем, күрше бабайның күңел хатирәләре, аның күргәннәре миңа бер нәрсәне аңларга ярдәм итте: тарих бары тик хакыйкать теле белән генә язылырга тиеш. Хакыйкать һәм башкалар бәхете өчен кан койган, михнәт-газаплар кичергән ватандашларыбызны, туганнарыбызны онытырга хакыбыз юк безнең!

## IV. ӘДӘБИЯТ ИСЕМЛЕГЕ:

1. Б.Ф.Султанбеков “Татарстан тарихы”Казан.”Тарих”2001.
2. Р.К.Бәширов,Ф.Г.Галиуллин “Татар әдәбияты тарихы” Казан” “Раннур”2001.
3. Д.Абдуллин “Иртәнге чык тамчылары”Ижау 2000.
4. Мәгариф №2,3 2000.
5. Мәгариф №4 1991.
6. Мәгариф №5 1996.

*Рәхмәтуллин Кәрим, 4нче сыйныф,*
*Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районының "38 нче Лицей" муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесе*
*Җитәкчеләре: Шәмсетдинова Лейсан Асфановна,*
*Хөснетдинова Лейсан Аслахетдиновна, татар теле һәм әдәбияты укытучылары*

## Исемемнең мәгънәсе – тормышымның билгесе

***Теманың актуаллеге:***

Минем исемем Кәрим. Мин 38 нче лицейның 4 нче сыйныфында укыйм. Фәнни эшем үземнең исемем белән бәйле. Бер көнне дәрестә укытучы апам исемнәр турында сөйләде. Өй эше итеп үзебезнең исемнәребезнең мәгънәләрен белеп килергә кушты.

Минем исемем нинди мәгънәне аңлата, нәрсә белдерә икән? Мондый сорауны күпләр биреп караганнардыр үзләренә. Мине дә үземнең исемем, аның килеп чыгышы, нинди мәгънә белдерүе бик кызыксындырды. Шуңа күрә фәнни-эзләнү эшемә мин «Исемемнең мәгънәсе – тормышымның билгесе» дигән теманы сайладым.

***Эзләнү гипотизасы:***

Исемнәр очраклы рәвештә генә килеп чыкмыйлардыр дип уйларга мөмкин. Кешенең исеме аның язмышына һәм характерына тәэсир итә дигән фикер кызыксындырды.

***Эзләнүнең максаты:***

- Үземнең исемемнең нинди мәгънә белдерүен ачыклау;

- Лицеебызда укучы 1-4 нче сыйныф укучылары арасыннан Кәрим исемле ничә укучы малай укыганлыгын барлау,санау;

- Дөньяда күпме Кәрим исемле танылган бөек шәхесләр барлыгын ачыклау.

***Эзләнү бурычлары:***

- Исемем кайдан килеп чыккан, нинди мәгънә белдерә;
- Исемнәр кеше тормышында нинди роль уйныйлар;
- Лицейда 1-4 нче сыйныф укучылары арасында ничә Кәрим исемле малай укый.

***Эзләнү объекты :***

- ***КӘРИМ исеме.***

***Эзләнү ысуллары:***

***- интернет челтәрләрендә информация эзләү;***

***- социологик сораштыру;***

***- китап һәм журналлардан мәгълүматлар табу.***

### *ТӨП ӨЛЕШЕ*

***Исемнәрнең барлыкка килү тарихы***

Кешенең исеме - ул аның тормышында иң еш ишеткән сүзе. Кешеләрнең исемнәре - халыклар тарихының бер өлеше. Җир йөзендә барлык кешеләрнең дә исемнәре бар. Бала дөньяга килү белән аңа исем кушалар. Бу исем аңа бер тапкыр гына бирелә һәм гомерлек юлдашына әверелә. Кытай халкында: «Начар исем начар язмыштан да яманрак», дигән мәкаль бар. Халыкта «кешенең исеме аның характерын, язмышын һәм һөнәрен билгели» дигән ышаныч та яши. Шуңа да өлкән буын вәкилләре исемне бүгенге мода буенча түгел, ә мәгънәсенә карап сайларга куша. Һиндлар да: «Исемнең мәгънәсе кешенең тормышын билгели» - дип уйлыйлар икән. Аларның уйлавынча, әгәр яңа туган малайга Ахиго дип кушсаң, ул үскәч батыр көрәшче булачак (чөнки "ахиго"ның тәрҗемәи аңлатмасы шул) .

Һәр халыкның үзенә генә хас исем кушу йолалары бар. Татар исемнәре - күбесенчә татар милләте вәкилләре арасында таралган шәхси исемнәр. Аларның тарихи яктан килеп чыгышы гарәп, мөселман, төрки телләрдән һәм күрше халыкларның телләреннән алынмаларга бәйле. Борынгы заманнардан ук кешенең сыйфатларын ача торган исемнәр өстенлек иткән: Матуркай, Янбарс, Гүзәлбәк һ.б. Ислам дине кабул ителгәч , өстенлекне Мөхәммәт, Ибраһим, Якуб, Гайшә, Фатыйма, Зәйнәп дигән исемнәр ала.

***Кәрим исеменең килеп чыгышы һәм мәгънәсе***

Миңа бу эш бик мавыктыргыч булып китте. Минем исемем турында тагын күбрәк информация табасым килде. Мин эзләнә башладым һәм менә нинди мәгълүматлар таптым:

1. Кәрим исеме Борынгы Фарсы теленнән барлыкка килгән. Бу исем ике мәгънәне белдерә. Беренчесе – «шәфкатьле», «юмарт», «намуслы», «киң җан иясе». Икенче версия буенча Кәрим исемен «хөрмәтле», «кадерле»дип тәрҗемә итәргә мөмкин.

2. Кәрим исеме, нигездә, мөселманнарда кулланыла. Аны шулай ук татар һәм башкорт халыклары да киң куллана.

3. Кәримнең ир-ат исеме хатын-кыз формаларына ия. Бу Кәримә исеме.

4. Мөселманнар Кәрим исемле малай юмарт һәм намуслы, шулай ук җәмгыятьтә хөрмәткә лаек булыр дип саныйлар. Кәрим исеме хуҗасына игелек һәм юмартлык бирә.

5. Инглиз телендә Кәрим исеме Карим дип язылa. Кәрим исеме Кирим белән синоним.

6. Арча районы интернациональ исемнәр кушу буенча лидер булып тора һәм биредә иң күп **Кәрим**нәр яши икән.

7. Республикабызда малайлар арасында **Тимур**, **Әмир** һәм **Кәрим** исемнәре инде соңгы дистә ел эчендә үз позицияләрен бирми – һаман да иң еш кушылалар.

Эзләнә торгач, интернет челтәрләреннән мин исемем турында менә шундый белешмәләр таптым.

***ПРАКТИК ӨЛЕШЕ***

Миңа бу эзләнү эше шундый кызыклы булып китте, минем башыма уй килде. Ә безнең лицейда башлангыч сыйныфларда ничә Кәрим исемле малай укый икән?

Үземнең блокнотымны алдым да сыйныфлар буйлап Кәримнәрне эзләп киттем. Нәтиҗәдә, 11 Кәрим укыганлыгын ачыкладым.

| № | СЫЙНЫФ | УКУЧЫЛАР ИСЕМЛЕГЕ |
|---|---|---|
| 1 | 1Б | Гәлләмов Кәрим |
| 2 | 1В | Гатауллин Кәрим |
| 3 | 1Г | Вәлиев Кәрим |
| 4 | 1Д | Хисамов Кәрим |
| 5 | 2Г | Хашимов Кәрим |
| 6 | 2Г | Зиһаншин Кәрим |
| 7 | 3Е | Илалов Кәрим |
| 8 | 3Ж | Иргалиев Кәрим |
| 9 | 4Е | Рәхмәтуллин Карим |
| 10 | 4В | Гәрәев Кәрим |
| 11 | 4Ж | Зарипов Кәрим |
| | БАРЛЫГЫ | 11 УКУЧЫ |

Минем бу эш белән кызыксынуым арткannан-арта барды. Хәзер инде минем Кәрим исемен йөртүче Татарстаныбызның һәм башка илләрнең күренекле, бөек шәхесләрен беләсем, барлыйсым килде.

Киттем кереп интернет челтәрләренә. Эзләнә торгач менә кемнәрне таптым мин.

1. Кәрим Тинчурин - бөек татар режиссеры һәм драмматургы. Казанда Татар дәүләт драма һәм комедия театры аның исемен йөртә. Мин үзем дә театрларга йөрергә һәм сәхнә әсәрләрендә катнашырга яратам.

2. Кәрим Мостафа Бензема – атаклы француз футболисты, «Реал Мадрид» дип аталган испан клубының капитаны. Ул үзенең чиксез күп голлары белән данлыклы һәм

мөхтәрәм спортмен. Ул минем дә кумирым. Чөнки мин үзем дә футбол уйнарга яратам, 5 яшемнән бирле футбол секциясенә йөрим.

3. Кәрим Давид Адейеми шулай ук танылган немец футболисты, яшь булуына карамастан спортсмен бик күп җиңүләр яуларга җитешкән.

4. Кәрим Халили - рәсәй биатлонисты. Олимпия уеннарының бронза призёры, Европа күләмендә һәм ил буенча яшьләр  чемпионатында күп такырлар җиңүче булган спортсмен.

5. Мостай Кәрим - танылган башкорт шагыйре, язучы һәм драмматург. Шулай ук Бөек Ватан сугышы ветераны, сугыш кырларында булганда да ул язуын ташламаган.

6. Фатих Кәрим –язучы, шагыйрь, совет чоры татар поэзиясенең күренекле вәкиле.

7.Карим Абдуллин – Дәүләт Академия театры биючесе.

8. Кәрим Варис Оламилека – 12 яшьлек нигерия рәссамы. Ул үзенең рәсемнәрен гиперреализм жанрында ясый. Аның ясаган картиналарын фотографияләрдән аерып булмый диярлек.

9. Гарипов Кәрим Альберт улы – Казанда яшәп эшләүче табиб.

***Йомгаклау:***

Эзләнә торгач үзем өчен менә шундый шәхесләрне ачтым. Аңлавыгызча, бу  атаклы кешеләрнең барысының да исемнәре КӘРИМ. Ә КӘРИМ исемле кешеләр ,  әйтеп киткәнемчә, « җәмгыяттә  хөрмәткә лаек » булырлар диелгән. Дөрестән дә, алар барысы да хөрмәткә лаеклы шәхесләр. Минем дә исемем КӘРИМ бит. Димәк мин дә киләчәктә җәмгыяттә хөрмәткә лаеклы кеше була алам, әгәр теләсәм һәм тырышсам. Минем инде үземнең кечкенә генә казанышларым да бар. Бәлки , киләчәктә мин дә шушы Кәримнәр төсле, үземнең исемемне күтәрермен, сезгә күрсәтермен. Моның өчен бик күп тырышырга , иренмәскә, бирешмәскә кирәк! Шулай эшләгәндә генә «Исемемнең мәгънәсе – тормышымның билгесе » булачак.

Игътибарыгыз өчен рәхмәт.

**Кулланылган әдәбият исемлеге:**

1. Хигир А. «Энциклопедия имен» Москва «Эксмо. Яуза» 2006

2. Г.Саттаров. Исемең матур, кемнәр куйган? Казан, ТКН. 1989

3. http:// www.imena.org

4. http://www.kakzovut.ru

5. https://ru.wikipedia.org/wiki/Имя;

6.  http://1000names.ru/bashkir_names;

7.  http://lib.a-grande.ru/imena.php;

8. http://bashkirica.ru/books/etnografiya-i-kultura-bashkirskogo-naroda/bashkirskie-imena.

*Салимов Ильгам, 5 нче сыйныф,*
*Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районының "аерым фәннәрне тирәнтен өйрәнүче 27 нче урта гомуми белем бирү мәктәбе" муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесе*
*Җитәкчесе:Гимранова Ильсеяр Гарафутдиновна*

## Дөньяны бары тик Тынычлык яшәтә, яшәртә

### КЕРЕШ

Татар милләтенең йөзек кашы булган, бөек шагыйребез, безгә тыныч тормыш бүләк иткән батырыбыз, Муса Җәлил турында бөтен кеше дә белергә тиеш. М. Җәлил үзенең шигырьләре белән күп еллар кечкенә буынны тәрбияләүгә зур өлеш кертте. М. Җәлил кебек батыр язучылар һәм сугышта катнашкан ветераннарыбыз бармак белән генә санарлык калды, шуларны барлау максатыннан чыгып эшләнелде.Украинада барган сугышлар беркемне дә битараф калдырмый. Тынычлык бүгенге көндә иң кадерле әйберләрнең берсе булып тора. Шуңа күрә мин фәнни тикшеренү эшемнең **темасы** итеп : **“Дөньяны бары тик Тынычлык яшәтә, яшәртә!”-** дип алдым. Мин бу теманы **актуаль** дип саныйм. Беренчедән быел Бөек җиңүнең 74 еллыгы билгеләп үтәргә җыенабыз, икенчедән бүгенге тыныч тормышта да кайбер илләрдә канкойгыч сугышлар бара, өченчедән безгә бу матур тормышны бүләк итүче ветераннарыбызның батырлыкларын яшь буыга җиткерү, өлкән буын кешеләренә хөрмәт тәрбияләү. Балаларда Туган илгә мәхәббәт тәрбияләү, сугыш ветераннарыбызны онытмауларын күздә тотып эшләнде. Мин киләчәк буынга тарихыбызны, сугыш ветераннарын онытмаска, бүгенге тыныч тормышның нинди зур югалтулар барәбәренә булуын, киләчәктә мондый афәтләр кабатланмасын дигән максаттан чыгып эшләдем. Кинотеатрның яшьләр күңелендә “ кинотеатр Джалиль” булып, буш сүзләр булып кына калмавын, шәһәребездә һәйкәлләр барлыгын белеп үсүләрен эшемнең зур **проблемасы** итеп алдым.

**Фәнни тикшеренү эшемнең объекты:** Түбән Кама шәһәренең истәлекле урыннары, Ватан Сугышы ветераны, “Нефтехимик” эзтабарларының хезмәте.

**Фәнни тикшеренү эшемнең предметы:** шәһәрнең һәйкәле, кинотеатры, ветераннары.

**Максат:**

Туган якка, халыкына сугыш китергән зыянны ачыклау.

**Бурычлар:**

- Һәйкәл, кинотеатрлар турында материал туплау.
- Бүгенге көндә безнең арада булган өлкән буын кешеләре яки сугыш ветераннары белән аралашып, сугыш турында чыганаклар җыю.
- Төрле китап, газетларда басылып чыкка мәкаләләрдән файдалану.
- Фотоматериаллар туплау.
- Туган илгә, туган җиргә мәхәббәт, патриотик хисләр тәрбияләү.

## 2.1. ШӘҺӘРЕБЕЗДӘ М.ҖӘЛИЛ БЕЛӘН БӘЙЛЕ БУЛГАНИСТӘЛЕКЛЕ УРЫННАР

Мин Татарстанның иң гүзәл төбәгеннән - Түбән Кама шәһәреннән. Минем өчен туган җирем, гүзәл каламнан да кадерле, аннан да матур җир юктыр шикелле дөньяда. Шәһәрем буйлап ясаган экскурсияләрдә иң беренче булып 1нче номерлы гади генә бер мәктәп, ягъни гимназия булды. Килеп керү белән башка мәктәпләрдән әлләни аерылмый да кебек, укытучым сөйли башлагач төшендем, бу гади мәктәп кенә түгел, ул герой-шагыйрь Муса Җәлил исемен йөртә икән (кушымта №1, 1 нче рәсем). Мәктәп җыйнак кына, укучылар тәрбияле, әйтерсең, Җәлил “оныклары”.

Алдагы “танышыбыз” әле күптән түгел генә шәһәребездә калкып чыккан мәһабәт Муса Җәлил һәйкәле (кушымта №1, 2 нче рәсем). Күтәрелеп карау белән бу сында ниндидер моңсулык, йөзендә әйтерсең: “Эшләнеп бетмәгән эшләрем кала...”,- дигән, үкенүне күреп була. Ә менә башкалабыз Казан шәһәрендәге һәйкәл башкачарак (кушымта №1, 3 нче рәсем).

Анда ул, югарыга очар очен канатларын җайлап куйган бөркетне хәтерләтә. Ике кулы артка каерып бәйләнгән... Менә-менә җилкәләрен киереп, чылбырларны өзәр дә һавага күтәрелеп китәр кебек.

Ә алдагы сәяхәтебез шәһәребездә күптән эшләп килүче, Муса Җәлил исемен йөртүче “Җәлил” кинотеатры турында (кушымта №1, 4 нче рәсем). Анда күпләрнең, яше-картының рәхәтләнеп ял итү урыны.

Сугыш дип әйтүгә бөек шагыйребез, “чәчәк телле”, патриот-шагыйрь - Муса Җәлил күз алдына килеп баса. Кем генә булуына карамастан зур кешеме, кечкенә генә баламы бу изге, милләтебезнең йөзек кашы булган Җәлилебез, кыю сугышчыбызны белмәгән кеше юк. Һәр татар баласы аның шигырьләрен, җырларын, экиятләрен тыңлап үсә.

М.Җәлил, шундый вәхшәт эчендә үлемсез җырларын иҗат итеп, бер

батырлык күрсәтсә, шул җырларны төрмәнең калын стеналары аша иреккә чыгара алуы белән икенче батырлык эшли. Бу үлемсез җырлар безгә Җәлилнең авазы булып кына түгел, фашистлар җәзалаган миллионнарча корбаннарның, миллионнарча көрәшчеләрнең васиятләре булып килеп җитте.

Тирәнтен уйландыра, авыр уйларга чумдыра торган фаҗига бу. Күпме кешенең чәчәктәй гомерен өзде ул. Күпме гөнаһсыз кешенең каны дәрья урынына акты. Әле хәзер дә, ул еллардан соң 74 елга якын вакыт үтсә дә, фашизмга ләгънәт укыйлар. Ватан өчен барган изге көрәштә татар халкының күпме бөек улы башын салды. Күпме әсәрләр, шигырьләр, күңелләрдә туып та ак кәгазь битенә төшмичә, яралгы хәлендә югалды. Муса Җәлилнең дә нибары 94 шигыре генә бик бормалы юллар аша туган илгә кайтып җитә алды.

Үлем карары чыгарылгач та, шагыйрь күңелен төшерми, рухын сындырмый. Төрмәнең кысан, караңгы камерасында да аның өчен иҗат йолдызы балкый. Тоткынлыкта тимер чыбыклар белән уратып алынган төрмә камерасында да ул, җырчы сабан тургаедай, һаман биеккә тартыла.

**2.2. ВЕТЕРАН БЕЛӘН ОЧРАШУ**

Минем кечкенә генә булган шәһәремдә **ЗУР** батырлар яши икән бит. Үзе җыйнак кына, чәчләре инде күптән агарган шәһәрдәшем, безгә шушы матур көннәрне бүләк итүче, Гайфуллин Харис Гали улы белән күрешергә насыйп булды. Бабайны күрүгә “Әлдермештән Әлмәндәр”дәге чиста, саф күңелле, эчкерсез, батыр, нурлы йөзле кеше килеп басты алдыбызга. Ул - Ватан солдаты. Сугыш турында сөйләгәндә бабайның җиңелчә генә калтырануын, күзләрендә яшь бөртекләре җемелдәшүен һәм кечкенә бала башыдай йодрыкларының, нечкә иреннәренең тагын кысылганын күрдем. Күпме балаларның ятим, хатыннарны тол иткән “йөзе кара” сугышка чиксез нәфрәт билгесе итеп кабул иттем мин бу халәтне.

Сугыш башланган көннәрдә табигать ниндидер котылгысыз бәла килүен көткәндәй үлгән кебек тынып калды... Шәһәр, авыл урамнарында тәрбиячесез калган балалар төркемләп тә, ялгызлап та йөриләр. Алар үтеп

баручыларга ябык кулларын сузып икмәк сорыйлар. Сугыш белән корылык китергән афәтнең иң куркынычы шушы иде, сезгә шуларны күрергә язмасын, - ди ул. (Кушымта №1, 5нче, 6 нчы рәсемнәр)

Авылдамы, шәһәрдәме, туган республикабыздамы, ватаныбызның башка төбәкләрендәме, чәчләренә чал кунган, маңгайларна тирән җыерчыклар сызылган могтәбәр ветераннар, икенче бөтендөнья сугышында җиңү яулаган каһарманнар белән очрашканда,

күңелдә еш кына бер сорау туа. Шул сорау белән мин тагын Харис бабайга мөрәҗәгать иттем:

- Шундый югалтулар һәм батырлыклар бәрабәренә ирешкән җиңү көннәрендә җир йөзендә кайчан да булса тагын сугыш, кан кою булыр дип күз алдына китерә ала идегезме?, –дигән сорау бирдем.

-Юк! Кеше акылына килер, сугышлар турында уйлау түгел, ул сүзне бөтенләй онытыр кебек тоела иде, дип җавап бирде ветеран бабай. Әйе, кызганычка каршы кешелекнең сугыш дигән афәттән әлегәчә арына алганы юк. Гомер-гомергә аның бәгырен эзәрлекләп һәм телгәләп килгән сугыш шәүләсе әле булса Җир шары өстендә эленеп тора. Дөньяның әле бер, әле икенче почмагында шартлау авазлары гөрселди. Алай гына да түгел, кешелек һәм зәңгәр бишегебез алдында яшәргәме, әллә... юкка чыгарыргамы дигән

сорау куелган. Американың котырынып кораллануы, яшәү, Бәхет һәм Гүзәллек дигән мәңгелек изге төшенчәләр белән хисаплашмыйча, коточкыч финалга ашкынуы бөтен прогрессив дөньяны сагаерга мәҗбүр итә. Бүгенге көндә дә Украина җире кан һәм күз яшьләре белән сугарылган. Ерткычларча

җәзалаланган, меңнәрчә картларны, балаларны һәм ата-аналарны күргәч, Украинаның гүзәл шәһәрләре һәм авыллары урынына таш һәм күмер өемнәре генә калганын күргән саен, минем җаным тетрәп, йөрәкләрем боздай булып китә. Бүгенге көндә дә шушылар өчен кайгырып, кабат җир йөзендә сугышлар булмасын,- дигән сүзләрне һәрдаим безгә кабатлап торды.

Юк шул, сугыш аяусыз, сугыш – рәхимсез, шәфкатьсез! Күпме асыл ир-

атларны үзенең комсыз тегермәненә салып тарттырган, күпме тол-ятимнәрне

арттырган ул! Күпме карт-карчыкларны улларыннан, егетләрне сөекле кызларыннан аерган ул!

Ир туган илен онытмас,- ди халык.

Безнең татар халкы уллары да кабахәт дошманга каршы шулай ук батырларча һәм оста сугышканнар.

Шундый күренешләр белән очрашкан саен мин кабат дәхшәтле сугыш кырларын, анда ятып калган яшь-яшь ир-егетләрне күз алдына китерәм. Бүген менә шундый бәхетле, имин тормыш өчен, күгебез һәрвакыт аяз булсын өчен корбан булдылар бит алар. Яшь буын белеп торсын: бүгенге якты көннәрнең һәр иртәсе күп миллионлаган гомерләр хакына яулап алынды. Яу кырында һәлак булганнарга. Шул мәһшәрдән исән кайтканнарга, тылдагы "шинельсез солдатлар"га – тол хатыннарга, сугыш чоры балаларына карата битараф булуны, гаделсезлекне күтәрә алмыйм! - ди бабабыз.

Сугыш еллары һаман ераклаша бара. Җиңү бәйрәме көнне мәңгелек ут янына килүче ветераннар сафы да һаман сирәгәя. Алар белән бергә халкыбызның сугышчан батырлыгы да акрынлап тоныкланырмы. Юк, моңа юл куярга ярамый. Музейларга, һәйкәлләргә сукмак өзелмәсен. Һәйкәлләр, мәңгелек утлар янында чәчәкләр бетеп тормасын. Бу бүгенге яшьләргә өлкән буыннардан амәнәт!

СУГЫШ... Әмма... Сугыш сугыш инде ул! Берни белән дә хисаплашып тормый ул орыш, кан-яшь коеш...

Әйе...

Үлгәч кайтулар юк... Үлгәч, кеше, хәтерсезлек баткаклыгына суырылып, акрын гына онытылу томаннары арасында кала бара...

## 2.3 . СУГЫШ КАЙТАВАЗЫ...

Күп корбаннар китергән канкойгыч сугыш инде күптән тәмам. Еллар узган саен аның кайтавазы да ерагая кебек. Хәзер инде сугыштан кайтмый калган “хәбәрсез югалган”нарны көтүдә өмет тә юк. Сугыштан исән–имин әйләнеп кайтканнары да бик өлкән яшьтә һәм алары да язын сызып кына эрегән кар кебек, арабыздан китә баралар. Ә менә исемнәре билгеле булмыйча сөякләре төрле җирләрдә чәчелеп ятучы солдатлар әле һаман да бик күп. Энтузиастлардан төзелгән дистәләрчә эзтабарлар отрядлары аларны ачыклау белән шөгыльләнә. Шәһәребезнең “Нефтехимик” эзтабарлар отряды да (командиры Ольга Ланцова (Кушымта № 1, 7нче рәсем) бу изге эшкә зур өлеш кертә. Бөек Ватан сугышында һәлак булучы солдатларның һәм офицерларның сөякләрен һәм шәхси әйберләрен эзлиләр. Эзтабарлар отряды күп еллар рәттән һәлак булган сугышчыларның калдыкларын табу буенча Бөтенроссия төбәкара эзләү чараларында катнаша. Аларның даими бара торган урыннары — Ленинград һәм Смоленск өлкәләре.(Кушымта №1, 8 нче рәсем). Сугыш чорында, һәлак булган очракта исемнәрен ачыклау мөмкин булсын өчен, солдатлар үзләре турында кыскача мәгълүматлар язылган махсус капсулалар (солдат медальоннары) йөрткәннәр. Казу эшләрендә эзтабарлар әнә шундый медальоннарга тап булсалар, бик яхшы инде. Чөнки һәлак булган сугышчының исеме мәгълүм була. Шулар буенча аның туган-тумачасын да табарга мөмкин икән.

“Нефтехимик” эзтабарлар отряды 21нче мәктәп, политехника колледжы, шәһәр музее һәм үзләренең “НКНХ” акционерлык җәмгыяте музейларын экспонатлар белән даими баетып торалар. Шул ук вакытта яшьләр арасында патриотик тәрбиягә зур әһәмият бирәләр, очрашуларда катнашалар.

«Сугышта үлгән бер генә солдатның булса да гәүдәсе җиргә иңдерелмәгән икән, сугыш беткән булып исәпләми», дип әйткән берәү. Әйе, сөякләре төрле җирләрдә чәчелеп ятучы, исемнәре билгесез солдатлар әлегә бик күп. Аларның каберләрен генә күреп булса

да, күңелләрен юатырга теләүче туганнары, балалары, оныклары яши тирә-ягыбызда. Шуларның хәер–догаларын ишетмәгән килеш, илебез азатлыгын яклап гомерләрен биргән каһарманнарның рухлары тынычланырмы икән?...

## ЙОМГАКЛАУ

Эш барышында алдыма куйган **максат** һәм барлык **бурычлар** да чишелде. Мин фәнни-тикшерү эшем буенча әдәбият кулландым, ветераннар белән очраштым, М.Җәлил белән бәйле истәлекле урыннарда булдым, архив материаллар тупладым; массакүләм информация чараларын файдаландым; фотоматериаллар җыйдым һәм үземә шундый нәтиҗә ясадым. Бүгенге көндә дә ветераннарның сугышчан батырлыклары яшь буынны тәрбияләүдә зур роль уйный, уйнаган һәм уйнаячак.

Эшемнең барышында **гипотеза** тулысы белән расланды. Шәһәребез яңарышлары белән яшь буынны таныштырып, тарихыбызны балаларга җиткерә алуыбызга бик шат.

Эшемне төгәлләп шуны әйтергә кирәк: бүген без яшь буынга ветераннарыбызга, өлкән буын кешеләренә иътибарлырак, итәгатьлерәк булырга тиеш. Шуңа күрә без үзебездән шундый **тәкъдим** кертәбез: Эзләнүләр нәтиҗәсендә тупланган хезмәтемне туган якны өйрәнүдә һәм әдәбият дәресләрендә тәрбия эшендә материал буларак кулланырга мөмкин.

**Библиография**


1. М.Җәлил. Шигырьләр. 1918-1941. Казан, Тат. кит. нәшр.: 1975ел.
2. Р. Мостафин. “Җәлилчеләр”, Казан, тат.кит.нәшр.: 1988 ел.
3. Ш. Мостафин. “Хәтер яктысы”, Казан, Тат. кит. нәшр.: 2004 ел
4. “XX гасырның беренче яртысында дөнья.” 1918-1945. Профессор О. С. Сороко-Цюпа редакциясендә. Казан, Тат. кит. нәшр.: 1996 ел.
5. “Каһарман каләме”. Бөек Ватан сугышында һәлак булган татар язучыларын иҗатыннан үрнәкләр. Казан, Тат. кит. нәшр.: 2010 ел.
6. Шаһинур Мостафин. “Вәсият”. Казан – 1994ел.
7. Эзләнүләр, уйланулар, табышлар. Казан , Тат. кит. нәшр.: 1989 ел.
8. Ә.Ә. Юнысов. “Солдат хәтере”. Казан, Тат. кит.нәшр.: 1990 ел.
9. З.Зәйнуллин. “Ник ямансу бу көзләр?” Казан, Тат. кит.нәшр.: 1998 ел.
10. Ш.Рәкыйпов. “Кызлар йолдызлар”. Казан, Тат.кит.нәшр.: 2000 ел.
11. Ф. Имамов. “Югалган эзләр”. Казан, “Ихлас”: 2012 ел.

*Туктамышев Әмир, 10 нчы сыйныф,*
*Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районының "29нчы урта гомуми белем бирү мәктәбе" муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесе*
*Җитәкчеләр: Якупова Венера Бәдертдин кызы, татар теле һәм әдәбияты укытучысы*
*Фаттахова Римма Артур кызы, информатика укытучысы*

# Инфокоммуникацион мохиттә татарча терминнар

## Кереш

Дөньяда көннән-көн мәдәният, икътисад, фән һәм башка өлкәләрдә аралашу ихтыяҗы арта бара. Без фән һәм техниканың зур үсеш кичергән чорында яшибез. Бу өлкәдәге яңалыкларны, үзгәрешләрне барлык халыкка җиткерүдә тәрҗемә мөһим роль уйный[1:67]. Татар теленә чит телдән сүзләр рус теле аша керә. Информацион технологияләр белән бәйле терминнар чит һәм рус телле калыпта. Алар үзенчәлекле лексик-семантик табигатькә ия. Информатика дәреслеген предмет буларак өйрәнүдән тыш, татар телендә булуын бәяләү өчен кулга алгач, бу өлкәдәге татарча терминнарның шактый күп булуы гаҗәпләндерә. Гаҗәпләнү кызыксынуга әйләнеп, дәреслектәге терминнарны өйрәндек. Нәтиҗәләр “Инфокоммуникацион мохиттә татарча терминнар” дип исемләнгән фәнни эшкә тупланды.

Фәнни эшнең максаты: информацион технологияләр өлкәсендәге татарча терминологияне өйрәнү, татар теленә тәрҗемә итүнең лексик-семантик үзенчәлекләрен тикшерү.

Бурычлар:

1) фәнни-техник әдәбиятта алынмаларны туплау;
2) уңышсыз ясалган һәм ялгыш кулланылган сүзләрне күзәтү;
3) калькалаштыру ярдәмендә ясалган терминнарны өйрәнү;
4) терминнарны тәрҗемә итүдә тәңгәллекләрне ачыклау;
5) кыскартылмаларның тәрҗемә ителешен күзәтү;
6) лексик сурәтләү чаралары тәрҗемәләрен анализлау.

Эшенең практик әһәмияте. Фәнни эш информатика белән кызыксынучыларга, укытучыларга, укучыларга, бу өлкәдә эзләнүләр алып баручыларга ярдәмлек була ала.

Эшнең яңалыгы һәм фәнни кыйммәте. Татар терминологиясенә кагылышлы хезмәтләр бик күп. Информацион технологияләр өлкәсендә татар терминнары махсус сүзлекләргә тупланган. Фәнни эшнең яңалыгы һәм кыйммәте татар телен информатика өлкәсе белән бәйләп, шул бәйләнешкә кагылышлы махсус әдәбиятны чыганак итеп өйрәнүдә. Татар телен укытуга үзгәрешләр кертелгәнгә кадәрге чорда милләтебез, берничә буын галимнәр, укытучылар тарафыннан изге һәм гаять зур эшләр эшләнгән. Нинди генә кануннар чыкса да, без – татар телле буын әлеге хәзинәләрдән файдаланып, аны тагын да өйрәнеп, үз балаларыбызның чорына җиткерергә тиешбез. Тиңсез хәзинәбез булган туган телебез бетәргә тиеш түгел. Соңгы вакытта татар теленә кагылышлы сәяси карашлар эшебезнең актуальлеген көчәйтә.

“Инфокоммуникацион мохиттә татарча терминнар” дип исемләнгән фәнни эш эзләнү, туплау, чагыштыру, анализ-синтез алымнарына нигезләнеп башкарылды. Шулай ук, сайлап алу, чагыштыру, тасвирлама, стилистик методларны кулландык.

Эшнең структурасы. Фәнни эш кереш, төп өлеш, йомгактан тора. Төп өлешнең беренче бүлеге информатикада татарча терминнарның лексик-семантик үзенчәлекләренә багышланды. Икенче бүлектә калькалаштыру ярдәмендә ясалган терминнар, терминнардагы тәңгәллекләр, кыскартмалар кулланышы һәм лексик сурәтләү чараларын тәрҗемә итү үзенчәлекләре өйрәнелде. Эшкә нәтиҗәләр йомгакта урын алды. Мисалларның чыганагы итеп И.Г. Семакинның 7- 9 нчы сыйныфлар өчен тәкъдим ителгән информатика дәреслеген файдаландык.

## Беренче бүлек

## Информатикада татарча терминнарның лексик-семантик үзенчәлекләре

### 1.1. Информатика фәнендә алынма терминнар

Фәнни-техник әдәбият тәрҗемәсе – төрле телләрдә сөйләшүче кешеләр арасында махсус фәнни-техник мәгълүмат алышыну өчен куллана торган тәрҗемә. Фәнни-техник тәрҗемә фән һәм техника өлкәсендә мәгълүмат алмашу чарасы булганга, әлеге төр тәрҗемә икенче телдә шул ук техник мәгълүматны тәкъдим итү максатына хезмәт итә [2:357].

Терминнар фән өлкәсенә карыйлар һәм бер өлкәдә эшләүче кешеләр тарафыннан кулланалар. Терминнар бер мәгънәгә ия, нейтраль, кыска һәм систематик характерда булалар. Тәрҗемәче шуны истә тотарга тиеш: термин икенче телдәге тәңгәл килгән термин белән тәрҗемә ителә. Шуңа күрә аналогын табу, синонимы белән алыштыру һәм аңлатма аша тәрҗемә итү, чыганак телдәге терминның тәрҗемә телендә тәңгәл килә торган термины булмаганда гына кулланыла. Шулай ук тәрҗемә ителгән фәнни-техник текстлар фикерне төгәл тапшыру һәм кабул ителгән терминологиядән файдалану белән генә чикләнмичә, аңлаешлы, кыска булулары белән аерылып торырга тиеш [2:357].

Башка фәннәр белән чагыштырганда информатика фәне шактый соң барлыкка килгән. Шуңа күрә аның барлык терминнары да Көнбатыш Европа телләреннә карый. Фән – интернациональ күренеш, ул нинди телдә тудырылса, аның атамалары да шул телдә эшләнеп, башка телләргә таратыла, тәрҗемә ителә.

Терминнарны тәрҗемә итүнең берничә ысулы билгеле: 1) термин чыганак телдән турыдан-туры алына; 2) калькалаштырыша; 3) аңлатмалар ярдәмендә бирелә; 4) турыдан-туры тәрҗемә ителә.

Информатика фәне интернациональ фән булганлыктан, андагы төшенчәләрне белдерә торган терминнар арасында да алынмаларның актив булуы күренә. Билгеле булганча, терминны икенче телгә алынма буларак алу аны турыдан-туры тәрҗемә итү мөмкинлеге булмаганда һәм тәрҗемә ителә торган телдә эквиваленты табылмаганда күзәтелә.

Алынмаларның күпчелек өлеше Көнбатыш Европа телләренә карый, **ә** татар теленең лексик составын баетуда зур роль уйнаган рус теле хәзерге вакытта Европа телләреннән керә торган сүзләр өчен арадашчы тел булып тора. Чит тел лексикасы рус теленең фонетикасы һәм графикасына туры китерелеп алына. Татар теленә әлеге сүзләр рус телендә кичергән үзгәрешләр белән килеп керәләр һәм рус телендәгечә кулланылалар. Мисал өчен:

*Чаще всего это **графики,** круговые и столбчатые **диаграммы.** – Башлыча бу **графиклар*** - *түгәрәк һәм баганалы **диаграммалар.** (88 б.)*

*Почтовый ящик – это раздел внешней памяти **почтового сервера,** отведенный для абонента. – Почта тартмасы – **почта серверындагы** тышкы хәтеренең абонент өчен аерып куелган бүлемтеге. (109 б.)*

Мисаллардан күренгәнчә, аерым бер сүзләр латин графикасында кулланылалар. Бу үзен аклый, чөнки әлеге сүзләр Паскаль телендә билгеле бер мәсьәләне чишү алгоритмын төзү өчен кулланылалар. Ә менә компьютерның ***«enter»*** дигән төймәсен рус телендә ***«ввод»*** дип бирү бик үк уңышлы түгел, чөнки әлеге атама бөтен кеше өчен таныш һәм аны тәрҗемә итү ихтыяҗы юк.

*С этой целъю создавались различные **машины** и **механизмы.** – Шул максаттан төрле **машиналар** һәм **механизмнар** иҗат иткәннәр. (72 б.)* Җөмләнең татарча вариантында стилистик хата бар. *Создавались* сүзен ***иҗат иткәннәр*** дип тәрҗемә итү, беренчедән, стильгә туры килми, икенчедән, техниканы иҗат итмиләр, ә төзиләр, уйлап табалар.

*Такая **таблица** называется трассировочной таблицей, а процесс ее заполнения называется **трассировкой алгоритма.** – Мондый **таблица** –трассировкалы таблица, ә аны тутыру процессы **алгоритм трассировкасы** дип атала. (184 б.)*

Алынма терминнар график принципка нигезләнеп языла һәм бу әдәби сөйләмгә дә тәэсир итә. Терминнарга карата бу нәкъ шулай булырга тиеш тә. Шулай да күпчелек телләрдә алынма терминның тамыр өлеше график принцип белән, сүз азаклары исә һәр телнең үз табигатенчә языла, ягъни тел тарафыннан үзләштерелә. Мондый терминнарны түбәндәгечә төркемләп була:

1. -лы/-ле сыйфат ясагыч кушымчасын алган терминнар:

*Дисплеи, работающие описанным способом, называются* ***растровыми дисплеями.*** *– Югарыда тасвирланган ысул белән эшләүче дисплейлар* ***растрлы дисплейлар*** *була. (93 б.)* *Интерфейс современных системных и прикладных программ носит название* ***объектно - ориентированного интерфейса.*** *– Хәзерге системалы һәм гамәли программалар интерфейсы* ***объектлы – ориентлашкан интерфейс*** *дигән исем белән йөртелә. (65 б.)*

*В* ***трассировочной таблице*** *выводимые значения выделены жирным шрифтом. –* ***Трассировкалы таблицада*** *чыгарыла торган кыйммәтләр куе шрифт белән күрсәтелгәннәр. (68 б.)*

*Существуют три основных вида величин, с которыми работает компьютер:* ***числовой, символъный и логический.*** *– Компьютер өч типтагы зурлыклар* ***санлы, символлы, логик*** *зурлыклар белән эшли. (23 б.)*

2. Төрләндергеч кушымчалары, ягъни окончаниеләре кыскартылып алынган терминнар:

*Графика в САПР исполъзуется для подготовки* ***технических чертежей*** *проектируемых устройств. – САПРда графика профиланучы җайланмаларның* ***техник сызымнарын*** *әзерләү өчен кулланыла. (180 б.)*

*В резулыпате появилась логарифмическая* ***линейка.*** *– Нәтиҗәдә,* ***логарифмик линейка*** *барлыкка килә. (30 б.)*

***Битовая структура*** *определяет первое сеойство енутренней памяти компъютера - дискретностъ. –* ***Бит структурасы*** *компьютерның эчке хәтеренең беренче үзлеген - дискретлыкны билгели. (45 б.)* Җөмләдәге ***битовая структура*** **сүзтезмэсен** ***бит структурасы*** дип **икенче** төр **изафә** белән тәрҗемә итү бик уңышлы түгел, чөнки сүзтезмәнең мәгънәсе үзгәрә. Аны ***битлы структура*** дип тәрҗемә итсәк, уңышлырак булыр иде.

***Знания*** *второй группы, начинающиеся со слов "я знаю, как...", называются* ***процедурными.*** *– Икенче төркемгә кергән белемнәр "мин... ничек... беләм... " формасында бирелә. Болары* ***процедур белемнәр*** *дип атала. (11 б.)*

*Режим диалога часто называют* ***интерактивным режимом.*** *– Диалог режимын еш кына* ***интерактив режим*** *дип тә йөртәләр. (57 б.)*

3. Сүз ясагыч кушымчалар ялганып үзләштерелгән терминнар:

*Все символы такого алфавита можно* ***закодировать*** *всевозможными комбинациями из двух двоичных цифр. – Мондый алфавитның барлык символларын да икешәрле ике цифрның мөмкин булган барлык комбинацияләре белән* ***кодлаштырырга*** *мөмкин. (30 б.)*

*Битовая структура определяет первое свойство внутренней памяти компьютера –* ***дискретность.*** *– Бит структурасы компьютерның эчке хәтеренең беренче үзлеген –* ***дискретлыкны*** *билгели. (45 б.)*

*Команду алгоритма, записанную на языке* ***программирования,*** *принято называть оператором. –* ***Программалау*** *телендә язылган алгоритм командасын оператор дип әйтү кабул ителгән. (233 б.)*

Гомумән алганда, информатика фәне терминнары чит телләрдән кергәнгә күрә, алар тәрҗемә ителмиләр, бары тик беркадәр үзгәрешләр кичереп телгә үтеп керәләр. Мисаллар да моңа дәлил булып тора. Терминнарның бер өлеше *-лы/-ле, -ик, -аль* сыйфат ясагыч һәм ***-чы/-че, -лык/-лек*** исем ясагыч кушымчалары алып яраклашканнар, бер өлешенең кушымчалары төшеп калган, кыскарган.

**1.2. Уңышсыз ясалган һәм ялгыш кулланылган сүзләр**

һәр тел теге яки бу халык тарафыннан ачылган фәнни яңалыкны үз тел материалында чагылдырырга, тәрҗемә эшчәнлегендә телнең үз байлыгыннан мөмкин дәрәҗәдә файдаланырга омтыла. Соңгы вакытта татар телендә дә күп еллар дәвамында яшәп килгән интернациональ сүзләр урынына яңа сүзләр ясау белән бик мавыгып киттеләр. Яңа сүзләр, шул исәптән фәнни терминнар, яки татар теленең үз җирлегендә, ягъни булган сүзлек хәзинәсенә таянып ясала, яки чит тел лексик берәмлеге өлгесендә төзелә. Мәсәлән, *автомат* - *үзэшкәрткеч; автоматический* - *үзэшчән; дисплей* - *күрек; компьютер* - *санак; кабель* - *каплы тимер чыбык; клавиатура -төймәсар, төймәләр җыймасы; микро ЭВМ* - *микрокалькулятор -сансанар; мини ЭВМ* - *минисанак; принтер* - *язык, бастыргыч; таблица-табын; меню – сайлак.* (Это выводимый на экран список, из которого пользователь может выбирать нужные ему элементы. - Экранга чыгарылган исемлек сайлак дип атала. Кирәкле элемент шул исемлектән сайлап алына). Әлбәттә әлеге терминнарның татарча вариантларын булдыру – мөһим эш, ул татар теленең кулланылыш даирәсен киңәйтү максатыннан чыгып эшләнә, әмма телдә бу төшенчәләрне белдерә торган чит ил һәм рус терминнары актив кулланылганда, яңа сүзләр ясау кирәкме икән? ***Клавиатураны*** *– төймәләр җыймасы* һәм *принтерны – бастыргыч* дип атау уңышлы булса да, алар кулланылышка кереп китә алмады, чөнки аларны куллану ихтыяҗы юк. Ә *компьютерны – санак, таблицаны – табын, принтерны – язык,* ***мониторны*** *–* ***күрек*** дип атау уңышсыз,

чөнки әлеге сүзләр мәгънәне ачып бетерә алмыйлар, буталчык кына китереп чыгаралар. Ә терминны тәрҗемә итү өчен сайланган сүзнең төгәл мәгънәсе белән бу терминның асыл мәгънәсе арасында каршылык тумаска тиеш. Әгәр дә каршылык туа икән, термин дөрес тәрҗемә ителгән булса да, уңышсыз була һәм телдә урнашып китми. Мондый типтагы терминнарны кулланганчы, телдә киң таралыш алган һәм һәркемгә аңлаешлы булган интернациональ терминны куллану күпкә яхшырак булыр иде, дип уйлыйбыз.

## Икенче бүлек
## Информатикада кулланылган терминнарның лексик-семантик төрләре

### 2.1. Калькалаштыру ярдәмендә ясалган терминнар

Информатика фәненә караган терминнарның күп өлешен калькалар һәм ярымкалькалар алып тора. Сүзен-сүзгә тәрҗемә итеп термин ясау иң җиңел, ләкин тайгак ысулларның берсе булып тора. Шуңа күрә, беренче чиратта телнең үзендә яшәүче, аңа ят булмаган, табигый сүзләргә, формаларга нигезләнеп термин ясарга тырышырга кирәк, тулы калька тибындагы телебезгә ятышсыз тәрҗемә терминнар телне дә баетмый, шул ук вакытта фәнни текстны кабул итүгә дә киртә булып тора [2:358].

Калька - француз телендә “үтә күренмәле” дигәнне аңлата һәм чит тел сүзен яки сүзтезмәсен башка телгә турыдан-туры, кисәкләп тәрҗемә итү була [1:72]. Мондый очракта чит телнең морфологик төзелеше кабул ителә.

***Числитель** первой дроби умножить на **знаменатель** второй. – Беренче вакланманың **санаучысын** икенче вакланманың **ваклаучысына** тапкырларга. (40 б.)*

*Арифметическое выражение может содержать числовые константы и **переменные,** знаки арифметических операций, круглые скобки. – Арифметик аңлатма саннар һәм **үзгәрешлеләрдән,** арифметик гамәл тамгаларыннан, түгәрәк җәяләрдән тора. (355 б.)*

*Есть **алфавит,** который можно назвать **достаточным.** – **Җитәрлек дәрәҗәдәге алфавит** дип санарга мөмкин булган алфавит бар. (26 б.)* Бу җөмләнең рус телендәге төзелеше үк дөрес түгел, шуңа күрә татар теленә тәрҗемәсе дә бигрәк ямьсез яңгырый.

***Домашняя страница:** - **Өй бите.** (122 б.)*

*В системном блоке помещается **блок питания.** – Системалы блокта **туклану блогы** да урнашкан. (42 б.)*

Күргәнебезчә, калькалаштыру ярдәмендә тәрҗемә ителгән терминнар арасында уңышсыз булганнары да бар, мәсәлән: ***домашняя страница – өй бите, блок питания – туклану блогы.*** **Әлеге сүзтезмәләр** татар **телендә** кытыршы яңгырый, чөнки алар чит телдән башта рус теленә, аннан соң татар теленә механик рәвештә тәрҗемә ителгәннәр.

Тәрҗемә иткәндә, тәрҗемәче терминнарның мәгънәсенә төшенеп тормаган, сүзгә-сүз тәрҗемә иткән, шуңа күрә тәрҗемәсе дә бик ямьсез, хәтта көлке дә тудыра. Безнең фикеребезчә, ***домашняя страницаны шәхси сайт, блок питанияны көчәнеш формалаштыручы блок яки җайланма*** дип бирү уңышлырак булыр иде.

Калькалар кебек үк ярымкалькалар да фәнни-техник әдәбият тәрҗемәсендә шактый урын алып торалар. Алар шулай ук татар теленең сүзлек составын үстерүдә һәм баетуда зур роль уйныйлар.

Ярымкалькалар ясалганда чит телдәге кушма сүзнең бер өлеше генә калькалаштырыла, икенчесе тәрҗемә ителмичә кала. Мәсәлән:

*Процессор через* ***многопроводную линию,*** *которая называется магистралъю, связывается с другими устройствами. – Эшкәрткеч магистраль дип аталган* ***күп үткәргечле линия*** *аша башка җайланмалар белән тоташа. (50 б.)*

*Там же помещается:* ***блок электропитания,*** *дисководы, контроллеры внешних устройств. –* ***Электр белән туену блогы,*** *дисководлар, тышкы җайланмаларның контроллерлары да шунда кертелгән. (55 б.)* Сүзтезмәнең тәрҗемәсе шулай ук уңышсыз, электр белән тәэмин итү җайланмасы дисәк, татарчарак булыр иде дип уйлыйбыз.

*Переход на* ***полупроводниковые*** *элементы улучшил качество ЭВМ по всем параметрам. –* ***Ярымүткәргечле*** *элементларга күчү, ЭХМның сыйфатын бөтен параметрлары буенча арттыра. (248 б.)*

*Так один символ из* ***четырехсимвольного*** *алфавита «весит» 2 бита.* ***-Дүрт символлы*** *алфавитның бер символы 2 бит тора. (22 б.)*

*Затем появились специальные устройства для графического вывода на бумагу -* ***графопостроители.*** *– Бераздан соң графиканы кәгазьгә чыгару өчен махсус җайланмалар -* ***график төзүчеләр*** *уйлап табылган. (87 б.)*

Күргәнебезчә, тәрҗемә итү тезмә терминнарны активлаштыра. Алар арасында бер компонентлары татар, ә икенче компонентлары рус яки чит ил сүзе белән бирелгән гибрид калькалар еш очрый.

***Програмное обеспечение,*** *предназначенное для работы с базамы данных, называется СУБД. - Бирелмәләр базасы белән эшләү өчен билгеләнгән* ***программалар белән тәэмин ителеш*** *(ББИИС) дип атала. (1406.)*

*Режим, при котором управляющая система работает синхронно с объектом управления, называется* ***режимом*** *реального* ***времени.*** *- Идарә итүче система идарә итү объекты белән бер вакытта эшләгән режим* ***агымдагы вакыт режимы*** *дип атала. (191 б.)*

*Количество используемых цифр называется **основанием позиционной системы счисления.** – Файдаланудагы цифрлар саны **позицион санау системасының нигезе** дип атала. (35 б.)*

*Данные и программы в **памяти компьютера** имеют вид двоичного кода. - **Компьютер хәтерендәге** бирелмәләр һәм программалар икеле код рәвешенә ия. (32 б.)*

***Графическое изображение** результатов расчета распространения волн на поверхности жидкости после падения капли. – Тамчы тамганнан соң сыеклык өстендәге дулкыннар таралышының хисапланган **график сурәтләнеше.** (88 б.)*

*Чаще всего это графики, **круговые** и **столбчатые диаграммы.** – Башлыча бу графикалар – **түгәрәк һәм баганалы диаграммалар.** (88 б.)*

*Получение **растрового изображения** в электронно-лучевой трубке. –Электрон - нурлы трубкада **растрлы сурәт** алу. (93 б.)*

*Аналогично действует устройство внешней памяти компъютера — **накопитель на магнитной ленте. – Магнитлы тасмадагы туплагыч** та шулай ук эшли. (45 б.)*

*Весъ системный блок помещен в металлический корпус; на поверхности которого имеются: **клавиша включения электропитания, щели для установки дискет в дисковые устройства,** разъемы для подключения внешних устройств. - Системалы блок металл корпуска урнашкан. Корпусның тышында **электрны кабызу төймәсе, дискетны дисклар җайланмаларына кую ярыгы,** тышкы җайланмаларны тоташтыру урыннары бар. (48 б.)*

***Раздел операторов** - основная часть программы. – **Операторлар бүлекчәсе** программаның төп кисәге булып тора. (91 б.)*

*В середине XV века немецкий типограф Иоганн Гутенберг изобрел первый **печатный станок.** – XV гасырның уртасында немец типографы Иоганн Гутенберг беренче **басу станогы** уйлап таба. (28 б.)*

*Естъ еще третъя часть магистрали – **шина управления;** по ней передаются управляющие сигналы. – Магистральнең өченче кисәге – **идарә итү шины** буенча идарә итүче сигналлар тапшырыла. (51 б.)*

Мисалдан күренгәнчә, тәрҗемә вакытында ***шина*** терминына өченче зат тартым кушымчасының *-ы* варианты ялганган. Билгеле булганча, әлеге кушымча тартыкка беткән сүзләргә генә ялгана, ә әлеге сүз сузыкка тәмамлана, шуңа күрә *-сы/-се* кушымчасы ялганырга тиеш. ***Шины*** урынына ***шинасы*** дип әйтү дөресрәк булыр иде.

Сүзләрне калькалаштырган очракта төп шарт булып оригинал сүзенең мәгънәсен төгәл, дөрес һәм телдә сүзләрнең бәйләнешен истә тотып бирү тора. Әмма еш кына бу сакланмый.

*Полученный алгоритм имеет* ***линейную структуру.*** *– Алынган алгоритм* ***сызыкча структурага*** *ия. (63 б.)* дигән җөмләдә калькалаштырып тәрҗемә ителгән *сызыкча структура* сүзтезмәсендә иярүче сүз ияртүче сүзгә -*ча* кушымчасы ярдәмендә ялганган. Сүз ясалышы кагыйдәсе буенча татар телендә -*ча* кушымчасы, исемнәргә ялганып, рәвеш барлыкка китерә. Мисалдан күренгәнчә, әлеге кушымча предметның билгесен белдерүче сүзгә ялгана. Шулай итеп, сүзтезмәнең компонентлары бер-берсенә сыйфат ясагыч кушымча яки изафә ярдәмендә бәйләнешкә керергә тиеш: *сызыклы* ***структура.***

Фәнни-техник әдәбиятта бер мәгънәгә генә ия терминнар белән беррәттән күпмәгънәле терминнар да яшәп килә. Күпмәгънәлелек, хәтта бер компонентлы гына булса да, терминны дөрес аңлауны һәм тәрҗемә итүне кыенлаштыра.

*Переменные* ***величины*** *получают конкретные* ***значения*** *в результате выполнения команды присваивания или команды ввода. – Үзгәрешле* ***зурлыклар*** *конкрет* ***кыйммәтләрен*** *үзләштерү һәм кертү командаларын башкару нәтиҗәсендә алалар. (78 б.)*

*Информационный вес символа двоичного алфавита принят за* ***единицу*** *информации и называется один бит. – Икешәрле алфавит символының мәгълүмати авырлыгы магълүмат берәмлеге буларак кабул ителгән. (21 б.)*

*Количество используемых цифр называется* ***основанием*** *позиционной системы счисления. – Файдаланудагы цифрлар саны позицион санау системасының* ***нигезе*** *дип атала. (35 б.)*

*Графическое изображение результатов расчета распространения волн на поверхности* ***жидкости*** *после падения капли. – Тамчы тамганнан соң* ***сыеклык*** *өстендәге дулкыннар таралышының хисапланган график сурәтләнеше. (76 б.)*

*Все, что мы с вами знаем, мы когда – то узнали от родителей, учителеи, из книг, из личного практического* ***опыта*** *и сохранили в своей памяти. –Без белгән мәгълүматлар кайчандыр әти-әниләребездән, укытучыларыбыздан, укыган китапларыбыздан, шәхси гамәли* ***тәҗрибәбездән*** *алынганнар һәм алар безнең хәтеребездә сакланып калганнар. (15 б.)*

***Объем*** *внутренней памяти, тактовая частота, разрядность процессора. –Эчке хәтернең* ***күләме,*** *такт ешлыгы һәм процессорның разрядлылыгы. (46 б.)*

*Битовая структура определяет первое* ***свойство*** *внутренней памяти компьютера - дискретность. - Бит структурасы компьютерның эчке хәтеренең беренче* ***үзлеген*** *- дискретлыкны билгели. (46 б.)*

*Арифметическое* ***выражение*** *может содержать числовые константы и переменные, знаки арифметических операций, круглые скобки.- Арифметик* ***аңлатма***

*саннар һәм үзгәрешлеләрдән, арифметик гамәл тамгаларыннан, түгәрәк җәяләрдән тора. (355 б.)*

Шулай итеп, мисаллардан күренгәнчә, күпмәгънәле терминнарны тәрҗемә иткәндә, текстта мәгънә төгәлсезлекләре барлыкка килмәсен өчен, терминның контексттагы реаль мәгънәсен исәпкә алу бик мөһим. Әмма еш кына тәрҗемә барышында моңа игътибар ителми, шуңа күрә хаталар барлыкка килә. Мисал өчен:

*В трассировочной таблице выводимые значения выделены* ***жирным шрифтом.*** *– Трассировкалы таблицада чыгарыла торган кыйммәтләр* ***куе шрифт*** *белән күрсәтелгәннәр. (36 б.)*

*Полное* ***количество информации*** *заключенное в тексте, записанное с помощью двоичного алфавита, равно числу нулей и единичек в этом тексте.- Икешәрле алфавит ярдәмендә язылган тексттагы* ***мәгълүматның тулы микъдары*** *әлеге тексттагы нольләрнең һәм берәмлекләрнең санына тигез. (26 б.)*

Бу сүзләрне тәрҗемә иткәндә чыганак тел сүзләренең мәгънәләре текстны исәпкә алмыйча билгеләнгән. Шуның аркасында әлеге сүзләр татар теленә аеруча күп кулланыла торган, гадәттә ике телле сүзлекләрдә теркәлгән, төп мәгънәсе буенча оригиналга туры килә торган сүзләр белән бирелгән. Алар ярдәмендә ясалган сүзтезмәләрне *калын хәрефләр* һәм *мәгълүматның тулы күләме* дип тәрҗемә итү уңышлырак булыр иде.

Нәтиҗә ясап, шуны әйтергә мөмкин: калькалар телебезне беркадәр ямьсезләсә дә, бүгенге көндә калькалаштыру тәрҗемә процессында иң киң кулланыла торган ысулларның берсе булып тора һәм телебезнең лексик составын баетуда зур роль уйный.

Телебезнең сүзлек составы, лексик-семантик нормалары еш кына кирәксезгә рус теле сүзләре кулланылу аркасында да бозыла. Сөйләм телендә һәм хәтта әдәби телдә дә татар теленең тиешле төшенчәне белдерерлек үз сүзләре яки телдә алар кебек үк үзләштерелгән гарәп һәм фарсы алынмалары була торып та, рус сүзләрен кушып сөйләү һәм язу очраклары шактый күп. Без дә эшебездә мондый үзенчәлекләргә тап булдык. Мисал өчен:

*Последовательность выполнения* ***операций*** *определяется по их приоритетам.* - ***Операцияләрне*** *башкару эзлеклелеге аларның өстенлекләре буенча билгеләнә.(355 б.)*

*Естественные языки имеют устную и письменную* ***форму.*** *– Табигый телләрнең сөйләм һәм язма* ***формалары*** *яши. (12 б.)*

*Счетно-перфорационные машины осуществляли перфорацию,* ***суммирование,*** *вывод на печать числовых таблиц. – Исәпләүче-перфорацион машиналар перфорация,* ***суммалау,*** *санлы таблицаларны бастыру кебек операцияләр башкарганнар. (245 б.)*

Монда алынма сүзләр куллануның төп принцибы бозыла. Әлеге принцип түбәндәгедән гыйбарәт: туган телнең тиешле төшенчәне белдерә алырлык үз сүзлек хәзинәсе булганда яки үз лексик байлыгыннан яңа сүз ясау мөмкинлеге булганда, чит тел сүзләре кулланылырга тиеш түгел [5:14]. Югарыда китерелгән мисаллардагы ***операцияләр, формалар һәм суммалау*** дигән сүзләрнең татар телендә үз сүзләре бар. Аларны *гамәлләр, төрләр һәм кушу* дип бирү уңышлырак булыр иде дигән фикердә торабыз.

**2.2. Терминнарны тәрҗемә итүдә тәңгәллекләр**

Тәңгәллек төшенчәсе тәрҗемәнең гомумән алганда оригиналга туры килүенә карата кулланыла, һәм тәрҗемә эшенең иң төп принцибы шунда чагыла. Тәрҗемәче, оригиналның мәгънәсен һәм үзенчәлекләрен икенче телгә җөмләләп күчергәндә, һәрвакыт аерым сүзләр белән эш итә. Ул, контекстка карап, оригиналдагы теге яки бу сүзнең матди, экспрессив һәм стилистик мәгънәләрен билгели һәм тәрҗемә телендә шул мәгънәләрне белдерерлек сүз эзли. Мисал өчен:

*В ходе работы компъютера информация через **устройства ввода** попадает в **память.** – Компьютерның эш барышында мәгълүмат **кертү җайланмасы** аша **хәтергә** эләгә. (34 б.)*

*Занесение значения в **ячейку памяти** называется **присваиванием.** – **Хәтер күзәнәгенә** кыйммәтләр кертү **үзләштерү** дип атала. (25 б.)*

*Самым распространенным устройством **внешней памяти** на современных компъютерах стали **накопители** на магнитных дисках, или дисководы. – Хәзерге компьютерларда иң киң таралган **тышкы хәтер** җайланмасы булып магнитлы дисклы **туплагычлар,** яки дисководлар тора. (46 б.)*

*Информационный вес символа двоичного алфавита принят за **единииу информации** и называется один бит. – Икешәрле алфавит символының мәгълүмати авырлыгы **мәгълүмат** берәмлеге буларак кабул ителгән. (21 б.)*

*К магнитной **поверхности диска** подводится **записывающая головка. –Дискның** магнитлы йөзлегенә **язучы** магнитлы **очлык** якын килә. (46 б.)*

*Он вам непонятен, а поэтому – **неинформативен.** – Билгеләмә сезгә аңлашылмады һәм шуңа күрә ул **мәгълүмати булалмый.** (14 б.)*

Мисаллардан күренгәнчә, ике телдә лексик элементларның бер сүзлектә дә бирелмәгән һәм беренче карашка эквивалент була алмаган тәңгәллекләре дә еш очрый. Шулай да, алар хата булып түгел, ә контексттан чыгып, ике тел арасындагы лексик-семантик тәңгәллекләр табу нәтиҗәсе буларак каралалар, әмма кайчак тәрҗемәче сүзнең мәгънәсен контексттан чыгып билгеләми һәм контекстка туры килми торган тәңгәллек белән тәрҗемә итә. Мисал өчен:

***Назначение*** *програмирования – разработка программ управления компъютером с целъю решения различных информационных задач. –Программалауның* ***йөкләмәсе*** *– төрле мәгълүмати мәсьәләләрне чишү максатында компьютер белән идарә итү программаларын эшләү. (67 б.)*

Безнең фикеребезчә, *назначениены йөкләмә* дип бирү бик үк уңышлы түгел. Аны ***вазыйфа*** сүзе белән бирсәк, төгәлрәк булыр иде.

**2.3. Кыскартылмаларның тәрҗемә ителеше**

Фәнни-техник текстлардагы лексик элементларның бер өлешен кыскартылмалар алып тора. Ясалыш принцибы буенча кыскартылмалар синтаксик яки сүз кушу ысулына карый. Чөнки алар сүтезмәләрне яки тезмә сүзләрне төрлечә кыскарту юлы белән ясалалар. Әлеге сүзләрне ачыклаганда яки тәрҗемә иткәндә аларның төзелешләре, сүз тәртибе үзгәрә; я тулысынча, я кайбер компонентлары тәрҗемә ителә.

Компонентларның беренче хәрефләреннән ясалган терминнар:

*В нашеи стране первая* ***ЭВМ*** *была изобретена е 1951 году. – Безнең илебездә беренче* ***ЭХМ*** *1951 елда иҗат ителә. (240 б.)*

*Програмное обеспечение, предназначенное для работы с базами данных, называется* ***СУБД:*** *система упраеления базами данных. – Бирелмәләр базасы белән эшләү өчен билгеләнгән программалар белән тәэмин ителеш бирелмәләр базасы белән идарә итү системасы* ***(ББИИС)*** *дип атала. (140 б.)*

***ГРИС*** *может шагать или прыгать по линиям сетки, а также поворачиватъся. –* ***ГРИС*** *сызыклар буенча атларга, сикерергә, шулай ук борылырга мөмкин. (201 б.)*

*Когда степенъ интеграции приблизиласъ к тысяче, их стали называть* ***болъшими интегралъными схемами – БИС;*** *затем появилисъ* ***сверхболъшие интегралъные схемы – СБИС*** *– Интеграция дәрәҗәсе меңгә якынлашкач, аларны* ***зур интеграль схемалар (БИС)*** *дип атый башлыйлар, соңрак* ***бик зур интеграль схемалар (СБИС)*** *барлыкка килә. (249 б.)*

Мисаллардан күренгәнчә, кыскартылмаларның бер өлеше татар теленә сүзләрнең тулы формаларын тәрҗемә итү һәм алар нигезендә кыскартылма ясау аша тәрҗемә ителгән. Билгеле булганча, аббревиатуралар, гадәттә, тәрҗемә ителми, чөнки алар билгеле бер формада кабул ителгәннәр. Соңгы елларда исә, тәрҗемәчеләр фәнгә игътибар итмичә, механик тәрҗемә белән мавыгалар һәм шуның нәтиҗәсендә беркемгә дә аңлашылмый торган сүзләр, терминнар барлыкка китерәләр.

Беренче компонент кыскартылып, икенчесе тулысынча алынган сүзләр:

*Например, может получитъся вот такой перечень: – я знаю, как собратъ* ***радиоприемник;*** *– я знаю, как перемножить две простые дроби. – Мисал өчен, түбәндәге*

*белемнәргә мөрәҗәгать итик: – мин беләм: – мин **радиоалгычны** ничек җыярга кирәклеген беләм; – мин ике гади вакланманы ничек тапкырларга икәнен беләм. (11 б.)*

*Носители **видеоинформации** стали **фотопленка** и **фотобумага.** – **Видеомәгълүмат фототасмада** һәм **фотокәгазьдә** саклана башлый. (24 б.)*

Шулай итеп, татар телендә мондый төр кыскартылма терминнарны тәрҗемә итүнең бер ысулы күзәтелә: тәрҗемә итеп булмый торган термин ясагын элемент татар теленең үз сүзе белән бәйләнештә бирелә.

### 2.4. Фәнни-техник текстларда лексик сурәтләү чаралары

Фәнни-техник текстларда терминологиядан тыш күчерелмә мәгънәләрен югалткан метафоралар да очрый.

*При алфавитном подходе считается, что каждый символ текста имеет определенный «**информационный вес».** – Алфавитлы алымда текстның һәр символы билгеле бер **«мәгълүмати авырлыкка»** ия дип санала. (35 б.)*

*Знакомство с **языком Паскаль.** – **Паскаль теле** белән танышу. (225 б.)*

*Совокупностъ правил записи программ управления компъютером с использованием машинных команд называется **машинным языком.** – Машина командаларыннан файдаланып, компьютер белән идарә итү программаларын язу кагыйдәләренең җыелмасы **машина теле** дип атала. (236 б.)*

***“Песчинками»*** *компъютерной **памяти** являются биты. – Битлар компьютер **хәтеренең «ком бөртекләре»** булып санала. (45 б.)*

*Числовая константа в форме с **плавающей точкой** рактуется как мантисса, умноженная на 10 в степени, равной порядку. – **Йөзмә нокталы** формадагы санлы константа – тәртибенә тигез булган дәрәҗәдәге Юга тапкырланган мантисса буларак укыла. (168 б.)*

*Каталог самого верхнего уровня, который не вложен ни в какие другие, называется **корневым каталогом.** – Иң югары дәрәҗәдәге каталог (башка каталог эченә кермәгәне) **тамыр каталог** дип атала. (62 б.)*

*Графическое изображение иерархической файловой стуктуры называется **деревом.** – Иерархик фатлар структурасының график сурәтләнеше **агач** дип атала. (62 б.)*

*Оставшаяся часть экрана представляет собой пустой **холст,** на который наносится рисунок. – Экранның калган өлеше рәсем ясала торган **"киндер"**ролен үти. (102 б.)*

*Интернет и **«всемирная паутина»** – интернет һәм **«бөтендөнья пәрәвезе» (119 б.)***

***Родной язык компьютера** – это язык машинных команд и двоичных чисел.* - ***Компьютерның туган теле** – компьютер командаларының һәм икешәрле саннарның теле ул. (244 б.)*

Әлеге метафоралар, нигездә, турыдан-туры тәрҗемә ителгәннәр, чөнки татар телендә аларның күчерелмә мәгънәле эквивалентлары юк. Турыдан-туры тәрҗемә ителгән булсалар да, бу гыйбарәләрнең мәгънәләре, коммуникатив вазыйфалары җиткерелгән.

Бүлеккә нәтиҗә: информатика фәне яңа фән булганга күрә, аның лексик составында терминнарның киң кулланылышы күзәтелә, һәм мондый текстны тәрҗемә иткәндә төп авырлык терминнарны тәрҗемә итүгә бәйле килеп туа. Терминны тәрҗемә итә башлаганчы, аның составына кергән сүзләрнең мәгънәсен, төзелешен анализларга, термин элементларга таркатырга кирәк.

## Йомгак

Эш барышында информатика фәне терминнарының чит телдән сүз алу, калькалаштыру, ярымкалькалаштыру һәм эквивалент табу юллары белән, ә кыскартылма терминнарның, нигездә, тулы форманы тәрҗемә итү, транскрипция, транслитерация ярдәмендә тәрҗемә ителүен ачыкладык.

1. Информатика фәне яңа фән булганга күрә, аның лексик составында терминнарның киң кулланылышы күзәтелә, һәм мондый текстны тәрҗемә иткәндә төп авырлык терминнарны тәрҗемә итүгә бәйле килеп туа. Терминнар, нигездә, чит телдән сүз алу, калькалаштыру, ярымкалькалаштыру һәм эквивалент табу юллары белән тәрҗемә ителәләр.Эшебездә күп урынны алынма терминнар алып тора. Алар арасында үзгәрешсез кулланылганнары да, телебезнең грамматик закончалыкларына яраклаштырылганнары да бар, мәсәлән: *дисплей, видеоконтроллер, дисковод, программа, оператор; кодлаштыру, программачы, дискретлык* һ.б.һәр тел теге яки бу халык тарафыннан ачылган фәнни яңалыкны үз тел материалында чагылдырырга, тәрҗемә эшчәнлегендә телнең үз байлыгыннан мөмкин дәрәҗәдә файдаланырга омтыла. Соңгы вакытта татар телендә дә күп еллар дәвамында яшәп килгән интернациональ сүзләр урынына яңа сүзләр ясау белән мавыгу күзәтелә. Мәсәлән, *автомат – үзэшкәрткеч; дисплей – күрек; компьютер – санак; клавиатура – төймәсар, төймәләр җыймасы; принтер – язык, бастыргыч; таблица – табын; меню – сайлак.*

2. Калькаларга килгәндә, эшебездә тулы һәм ярымкалькаларны аерып чыгардык: *числитель – санаучы, знаменатель – ваклаучы, переменные – үзгәрешлеләр, достаточный алфавит – җитәрлек дәрәҗәдәге алфавит; основание позиционной системы счисления – позицион санау системасының нигезе, память компьютера –*

*компьютер хәтере, графическое изображение – график сурәтләнеш, оперативная информация – оператив мәгълүмат.* Калькалар арасында уңышсыз булганнары да бар. Мисал өчен: *домашняя страница – өй бите, блок* ***электропитания – электр белән туену блогы.*** Аларны ***электр белән*** *тәэмин итү блогы, шәхси сайт* итеп бирү уңышлырак булыр иде.

3. Телебезнең сүзлек составы, лексик-семантик нормалары еш кына кирәксезгә рус теле сүзләре кулланылу аркасында да бозыла; күп очракта телдә тиешле төшенчәне белдерерлек сүзләр була торып та, рус сүзләрен кушып сөйләү һәм язу күзәтелә. Без дә эшебездә мондый үзенчәлекләргә тап булдык. Мисал өчен: *Последователъностъ выполнения* ***операций*** *определяется по их приоритетам. –* ***Операцияләрне*** *башкару эзлеклелеге аларның өстенлекләре буенча билгеләнә. (355 б.) Естественные языш имеют устную и письменную* ***форму.*** *– Табигый телләрнең сөйләм һәм язма* ***формалары*** *яши. (12 б.) Счетно-перфорационные машины осуществляли* ***суммирование,*** *вывод на печать числовых таблиц. – Исәпләүче-перфорацион машиналар* ***суммалау,*** *санлы таблицаларны бастыру кебек операцияләр башкарганнар. (245 б.)* Бу сүзләрне *гамәлләр, төрләр һәм кушу* дип тәрҗемә итү уңышлырак булыр иде.

4. Билгеле булганча, фәнни-техник әдәбиятта кыскартылма терминнар да бик күп. Алар күбрәк тулы форманы тәрҗемә итү, транскрипция, транслитерация ярдәмендә тәрҗемә ителәләр. Мәсәлән: *ЭВМ – ЭХМ, СУБД –* ***ББИИС, ГРИС – ГРИС, большие интегральные схемы – зур интеграль схемалар, видеоинформация – видеомәгълүмат, фотопленка – фототасма, фотобумага – фотокәгазь.***

Гомумиләштереп әйткәндә, тәрҗемә иткәндә тел нормаларын бозуны булдырмауда, телне чит ил сүзләре белән чуарламыйча, грамматик һәм стилистик яктан камилләштерүдә тәрҗемәләрнең лексик-семантик үзенчәлекләрен тикшерү мөһим роль уйный.

**Әдәбият:**

*Чыганаклар*

1. Семакин И.Г., Залогова Л.А., Русаков С.В. Информатика. Базовый курс. 7-9 классы / И.Г. Семакин, Л.А. Залогова, С.В. Русаков, Л.В. Шестакова. -М.: БИНОМ. Лаборатория знаний, 2014. - 390 с.

2. Семакин И.Г., Залогова Л.А., Русаков С.В. Информатика. Нигез курсы. 7-9 сыйныфлар/ И.Г. Семакин, Л.А. Залогова, С.В. Русаков, Л.В. Шестакова. Русчадан В.Р. Камалиева тәрж. - Казан: "Дом печати" нәшрияты, 2014. -3906.

*Кулланылган әдәбият*

1.Бәширова И.Б. Хәзерге татар әдәби телендә фәнни әдәбият стиле: гомуми мәгълүмат / И.Б. Бәширова // Фән һәм тел. - 2000. - № 3. - Б. 12-15.

**2.** Шәмсетдинова Р.Р. Фәнни-техник әдәбиятны тәрҗемә итүгә кагылышлы кайбер мәсьәләләр / Р.Р. Шәмсетдинова // Фәнни язмалар 2007. -Казан: КДУ, 2008.-398 б.

**3.** Юсупов Р.А. Мәгълүмат чаралары теле һәм сөйләм культурасы / Р.А. Юсупов. - Казан: ТДГПУ, 2007. - 193 б.

***4.*** *Сүзлекләр*

**5.** Ершов А.П., Шанский Н.М. Терминологический словарь по основам информатики и вычислительной техники / А.П. Ершов, Н.М. Шанский, А.П. Окунева. -М.: Просвещение, 1991. - 159 с.

**6.** Закиров В.З., Муртазин З.Г. Русча-татарча математик терминнар сүзлеге/В.З. Закиров, З.Г. Муртазин. -Казан: Татар. кит. нэшр., 1970. -2046.

**7.** Русско-татарский словарь технических терминов / А.К. Юлдашев. -Казань: Магариф, 2000. - 254 с.

**8.** Русча-татарча техника терминнары сүзлеге / А.К. Тимергалин, М.С. Галеев. -Казан, 1963 .-2166.

*Фәзуллина Илина, 6 нчы сыйныф,*
*Татарстан Республикасы Түбән Кама*
*муниципаль районының «Адымнар - Түбән*
*Кама "полилингваль белем бирү комплексы"*
*муниципаль бюджет гомуми белем бирү*
*учреждениесе*
*Җитәкчесе: Ялалова Зөлфия Фаел кызы,*
*туган тел һәм әдәбияты укытучысы*

## Ач, шигърият, серләреңне!

### Кереш

**“Шигырьне язалармыни? Шигырь белән яшиләр... дөресрәге, ул үзе җанында бер изге зат булып яши. Аңа бернинди аерым вакыт та, махсус шартлар да кирәкми “ –дип язган Хәсән Туфан.**

Аның белән килешмичә мөмкин түгел.Мин шигырьләр укырга бик яратам. Шигырьләргә карата булган мәхәббәтем балачактан килә. Кечкенә чактан ук матур шигырьләр тыңларга ярата идем. Үсә төшкәч аларны үзем укырга, ятларга өйрәндем.Сонрак, күңелемә якын шигырьләрне өйрәнеп, бик күп шигырь конкурсларында катнашып, призлы урыннарга лаек булдым.

Гадәттә, шигырьләр хикәяләрдән кыскарак була. Шушы кыска гына шигырьләрдән дә авторның уйларын, сөйләгәннен һәрвакыт ачык күз алдына китерергә мөмкин. Шигырьләр кешеләрне елаталар да, юаталар да, тәрбиялиләр дә. Шигырьләрне прозага караганда өйрәнү җиңелрәк. Беркөнне күңелемдә шундый уй туды.Кызык, шигырьләр язарга өйрәнеп буламы икән? Шигырьләрне нәрсә үзенчәлекле итә? Мин, шигырьләрнең уртак яклары бармы-юкмы, дип, тикшеренүне үткәреп, шигырь язарга өйрәндем.

**Тикшеренү эшенең максаты**: шигырьләрнең ничек тууын белергә, аларның нинди кагыйдәләр буенча язылуын ачыкларга.

**Тикшеренү эшенең бурычлары:**

1. Шигырьләрнең нәрсә икәнен, нинди шигырьләр булуын ачыкларга;
2. Шигырь төзелешен өйрәнергә;
3. Шигырь иҗат итеп карарга.

**Тикшеренү эше барышында башкарылган эшләр**:

- энциклопедия, фәнни белешмә, төрле авторларның шигырьләрен тикшерү, тема буенча әдәбиятны укыдым; үзем шигырьләр иҗат иттем.

**Фәнни эшнең структурасы**: Фәнни эш керештән, төп өлешнең ике бүлегеннән, йомгаклау һәм кулланган әдәбият исемлегеннән тора.

## I БҮЛЕК. Төп өлеш

### 1.1 Нәрсә ул шигырь, нинди шигырьләр була?

Нәрсә ул шигырь? Шигырь ничек туа? Кем соң ул шагыйрь? Үземнең тикшерү эшемне әлеге сорауга җавап эзләүдән башладым. Әлбәттә, әлеге сорауга җавап табар өчен фәнни китаплар,энциклопедияләр укыдым.

Шигърият-сүзләрнең гади сөйләмгә хас булмаган рәвештә ритмы, яңгырашы буенча билгеле бер тәртипкә китерелгән хәле. Сүзләрне шундый хәлгә китерүгә нигезләнгән нәфис әдәбиятның бер тармагы.Шигърият үз эченә лирика һәм лиро-эпик әдәби төрләрне берләштерә. Шигырь - тезмә формага салынган, сүзләр, иҗекләр ритм таләбенә ярашлы итеп урнаштырылган әдәби әсәр.

Шагыйрь - шигырь язучы, шигърият белән шөгыльләнүче кеше. Ул хис- тойгыга бай кеше. Шигырь язу өчен хис- тойгы кирәк. Хис- тойгылар нинди булырга мөмкин? Патриотизм, соклану, ярату, горурлану, бәхет, сагыш, шатлану, югалту, мәхәббәт, нәфрәт - болар

кешеләрдә була торган хис-тойгылар. Нәкъ менә әлеге тойгылар гүзәл шигырьләр иҗат итәргә мөмкинлек бирә дә инде.

Шигырьләр нинди булалар соң? Алар күләменә карап кечкенә һәм зур булырга мөмкин. Шулай ук шигырьләр темалары, язылу стильләре белән дә бер-берсеннән аерылып торалар.Шагыйрьләр шигырь язганда кулланыла торган, иң еш очрый торган темалар алар: «Туган ил", "Мәхәббәт һәм нәфрәт", " Сугыш һәм тынычлык", "Ел фасыллары", "Табигать", "Ярату". Тагын шигырьләрдәге кайбер кагыйдәләрне белү бик мөһим:

**1.2 Шигырь төзелеше.**

Шигырь төзелеше- ритмик яктан оешкан һәм үлчәмгә салынган, шигъри сөйләм системасы. Шигырь – строфа,рифма, ритм, үлчәмнән тора.

Нәрсә ул строфа? Строфа - ритм ярдәмендә оешкан тезмәләр бәйләме. Татар шигыре, нигездә, 2, 4, тезмәле строфалардан тора. Сирәк кенә 5, 6, 7, 8 тезмәле строфалар да очрый.

Рифма нәрсә ул? Ритмик төзелеше бердәй тезмәләр ахырында аваздаш кабатлаулар яки охшаш яңгырашлы сүзләр. Рифма 2, 3, 4, 5 тезмәне070бербөтенгә әйләндерә.

Нинди рифма төрләре бар?

Татар сүзләренең нечкә һәм калын әйтелешенә карап, рифма:

- Нечкә әйтелешле, калын әйтелешеле
- Рәдифле
- Катлаулы (вакыт белән – йакут берлән, һәр ягы – тау ягы),
- Гади (тамчысы – илһамчысы, театр – император)
- Төгәл (мәйдан – кайдан, уйнатадыр- уйлатадыр)
- Ябык
- Ачык
- Омонимик

Ритм – нәрсә ул? Ритм - сөйләм берәмлегенең тигез вакыт аралыгында кабатланып, чиратлашып торуы.

Шулай ук, сүрәтләү чаралары, троплар һәм стилистик фигуралардан башка да матур әдәи әсәрләр тудыруы мөмкин түгел. Тагын шуны билгеләп үтәргә мөмкин: шигырьдә текст җөйләре рифма белән чикләнгән, сүзләр ирекле түгел, бәлки ритм тудырырлык итеп урнаштырыла һәм сайлана, ритм бәрмә һәм басымсыз иҗекләрнең чиратлашып барлыкка килә, авторның тормышы, тәэсирләре, уйланулары шигырьләр язуга сәбәп булып тора, автор укучының хыялында образлар тудыра, рәсем-тәэсирле чаралар ярдәмендә кәефне тапшыра, һәр шигырьнең дә шигъри сөйләм билгеләре юк, шигырь кагыйдәләрен аерып күрсәтергә һәм белергә мөмкин, ләкин бу белемнәр чын шагыйрьләр кебек шигырь иҗат итәргә мөмкинлек бирми, бары тик ярдәм генә итәләр.Димәк, шигырь язу өчен мәгънәгә

дә,эчтәлеккә дә,үлчәмгә дә, сүрәтләү чараларына да игътибар итәргә кирәк.Минемчә шигырь язу түбәндәге таләпләргә туры килергә тиеш: шигырьләр шигырь төзелешенә туры китерелеп язылырга тиеш. Ритм, рифма структураларын һәр язылган шигырьдә саклануы мөһим. Әмма рифма төзибез дип шигырь мәгнәсенә туры килмәгән һәрбер сүзне кулланып язу бик урынсыз. Рифма куллану бик зур осталык таләп итә, шуның өчен күбрәк шигырьләр укырга, даими язышып торырга кирәк. Ләкин ритм, рифма гына шигырь ясамый әле, һәрбер шигырьдә автор үз хисләрен, фикерен әйтеп бирергә тиеш, шул ук вакытта һәрбер шигырь укучыга ниндидер яңалык әйтеп бирергә тиеш. Чын йөрәктән чыккан шигырь генә башка йөрәкләрне тетрәндерә ала һәм уйланырга мәҗбүр итә ала. Шушы таләпләргә туры килгәндә генә шигырь укучылар күңеленә хуш килер.

## II БҮЛЕК ПРАКТИК ӨЛЕШ

### Туган тел

Төн утырып шагыйрь шигырь язды.
Чираттагы булды «Туган тел»
Күңеленнән генә әйтеп куйды,
Әй, син, кеше, аның кадрен бел.
Күңеленнән генә шундый сүзләр,
Кат- кат түгелде дә, түгелде.
Ә каләме һаман яза бирде.
Бүлмә эче нурга күмелде.
Иң зур теләк, иң зур ышанычы
Туган теле атсын гел чәчәк.
Татар теле мәңге бетмәячәк,
Аннан тора алгы киләчәк!
Шулай уйланыла- уйланыла,
Соңгы сүзләр төште кәгазьгә.
Чын күңелдән ышанды яшь шагыйрь
Татар теле яшәячәгенә.
И туган тел, и матур тел диеп,
Күпләр әле сөйләп йөрерләр.
Шундый телне башка халыклар да,
Үз итәрләр, якын күрерләр.
Төн утырып шагыйрь шигырь язды.
Чираттагы булды «Туган тел»
Күңеленнән генә әйтеп куйды.

Әй, син, кеше, телнең кадрен бел!

**Туган телем**

Сорасалар, кем ул укытучың,
Күрсәтүчең җирне, илләрне?
Зур горурлык белән туган телем
Кабатлармын синең исемне.
Сорасалар, кем ул тәрбиячең
Үстерүчең назлы гөлләрне?
Татар телем булды гомер буе
Уятучым язгы бөрене.
Сорасалар, зур шатлыгың нидә,
Дөнья күрү, илләр гизүме?
Башым иеп тыныч кабатлармын:
“Саклый алсам туган телемне!”
Ялкынланып шулчак әйтермен мин
Татар телем-моңлы бишегем.
Син укыттың, бирдең тәрбияне,
Ачтың миңа дөнья ишеген.

## Табигать бүләге

“Табигатьне сакларга, аның кадерен белеп яшәргә кирәк!”- дип әйтәләр, шулай эшләсәң генә табигать тә сиңа ярдәм кулы сузачак. Бу чыннан да хак, гаҗәеп сүзләр, ышанмаска мөмкин дә түгел, чөнки ул һәрдаим кеше баласын, шаккаттыруын дәвам итә, үзенең шифасы белән дәвалый.

Мин кечкенә чакта, күрше кызы бик нык авырып китте. Ул минем якын дустым, без аның белән гел белән бер- беребездән аерылмый идек. Болыннарда чәчәк җыярга, урманга барып серле җирләр юлларга ярата идек, тик нишләптер аның аяклары авыртып, ул тәмам аякларына баса алмый торган булды, күпме генә йөреп тә, файдасы тимәгәч, шифаханә ягына да кул гына селтәделәр. Шулай итеп, әбисе аны үләннәр белән дәваларга тотынды, мин аңа бу эштә бик теләп ярдәм иттем.

Безнең авыл матур якта урнашкан, анда чишмәләр, адаштыргыч урманнар да, искиткеч җирләр дә күп, авылда оҗмах почмагы яшеренгән сыман иде! Мондагы горур таулар араларына алып, җәннәт бакчасына алып керә һәм, иң гаҗәбе шул, бу таулардан челтерәп- челтерәп шифалы чишмә ага... Язиләне дә без шул чишмәгә алып барырга булдык. Ни әйтсәң дә, карт- корылар тәҗрибәлерәк бит, алар яхшыны яманнан аера беләләр, дарулар белән дәваланганчы, үләннәр белән дәваланалар иде.

Бу чишмәләр иленә аяк баскач та, әллә нинди сихри бер хис биләп алган, саф Һавасыннан баш әйләнгән, бөтен борчуларың юкка чыккан, ә агып торган чишмәсеннән бер йотым су эчсәң, үзеңә чиксез дәва алган сыман буласың... Элек- электән үк бу чишмәләрне файдалы дип уйлаганнар, тик шифаханәләрдә дәвалану шартлары үзгәргәч, халык хәтерендә табигатьтән алып була торган дәвалар онытыла барган. Аларның да үзенең бер кагыйдәләре бар шул, Язиләнең әбисе бу табигать серләрен бик яхшы белә, кайсысы нидән файдалы икәнлеген яхшы аңлый иде, ул Язиләне тау арасыннан чыккан чишмә белән дәваларга тотынды, бу чишмәнең суы аеруча да салкын иде, аның суы белән юынгач аягыңны сөлгегә сөртергә ярамый икән, чишмә суы шулай аякны куырып алып, кайнарландырып дәвалый, ләкин шул салкын чишмәдә күпме генә юынсаң да, ни гаҗәптер салкын тими. Язиләгә дә күпме юынып та салкын тимәде һәм иң гаҗәбе шул ул атна- ун көн дигәндә аякларына басты, әллә нинди дарулар дәваламаган Язиләнең аякларын чишмә суы дәвалады! Шул көннән башлап без ул җирлекне “Шифа чишмәсе” дип атый башладык.

Хәзер ул безнең өчен изге урын булып санала, халыкның яратып ял итә торган җире. Без анда ел саен килеп чәчәкләр утыртабыз, һәрдаим чистартып торабыз. Табигатьнең кадерен белеп яшибез!

## Йомгаклау

Тикшеренү барышында мин әдәби чыганаклар, белешмә әдәбияты белән таныштым, гамәли эш башкардым һәм түбәндәге нәтиҗәләргә килдем: шигырьләр шигырь төзелешенә туры килеп язылырга тиеш. Ритм, рифма структураларын һәр язылган шигырьдә саклануы мөһим. Әмма рифма төзибез дип шигырь мәгнәсенә туры килмәгән һәрбер сүзне кулланып язу бик урынсыз. Рифма куллану бик зур осталык таләп итә, шуның өчен күбрәк шигырьләр укырга, даими язышып торырга кирәк. Ләкин ритм, рифма гына шигырь ясамый әле, һәрбер шигырьдә автор үз хисләрен, фикерен әйтеп бирергә тиеш, шул ук вакытта һәрбер шигырь укучыга ниндидер яңалык әйтеп бирергә тиеш. Чын йөрәктән чыккан шигырь генә башка йөрәкләрне тетрәндерә ала һәм уйланырга мәҗбүр итә ала. Шушы таләпләргә туры килгәндә генә шигырь укучылар күңеленә хуш килер дип уйлыйм.

Тикшернү эше барышында алган белемнәр миңа шигырьләрне яхшырак аңларга, туган телемнең матурлыгын һәм байлыгын тоярга ярдәм итәчәк.

Шигырьләр язу теләгем сүрелмәде, гәрчә мин моның җиңел түгеллеген аңласам да.

Киләчәктә дә талантлы шагыйрьләрнең шигырьләрен укырмын һәм янәшәмдә булган матур күренешләр, кызыклы вакыйгалар яңа иҗат җимешләре тудырырга ярдәм итәр дип уйлыйм.

**Кулланылган әдәбият**

1. Әдәбият белеме: Терминнар һәм төшенчәләр сүзлеге. – Казан: ―Мәгариф, 2007.

2. Әдәбият белеме сүзлеге. Төзүчесе: А.Г.Ахмадуллин.—Казан: Тат. китап нәшр., 1990.

3. Бариева Э. Әдәбият белеме һәм тәнкыйть. // Татар әдәбияты тарихы: 6 томда.− Казан: Тат. китап нәшр., 1989.− Т.4.

4. Галиуллин Т. Хәзерге шигърият // Мирас. – 1996. – № 7-8.

*Фаттахова Айлина, 2 нче сыйныф,*
*Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районының «26нчы урта гомуми белем бирү мәктәбе» муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесе*
*Җитәкчесе: Хайруллина Лилия Миннефаязовна, туган тел һәм әдәбияты укытучысы*

**Алтын бөртекләр**

Ак каеннар, тирәкләр
Яшел күлмәк кигәннәр.
Җил искәндә башларын
Алар түбән ияләр.

Тузан туздыра комбайн-
Шундый ул урак өсте.
Тавышы күңелгә якын,
Ишетелә җыр төсле.

Әкрен генә йөзеп бара
Комбайн гүя кораб.
Аяз һава телимен мин
Зәңгәр күкләргә карап.

Илкәемнең амбарлары
Алтын бөртеккә тулсын.
Өстәлләребездә һәрчак
Ипи-күмәчләр торсын.

*Федорова Карина, 11 нче сыйныф,*
*Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районының "Аерым фәннәрне тирәнтен өйрәнүле 15 нче урта гомуми белем бирү мәктәбе" муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесе*
*Җитәкчеләр: Гыйзәтуллина Гульнара Хамисовна, Әхмәтҗанова Таскиря Фатыховна, туган тел һәм әдәбият укытучылары*

**Укытучым - тәрбиячем минем**

(хикәя)

Сигезенче сыйныф укучысы Лилия мәктәпне гел яхшы билгеләргә генә тәмамлар мөгаен, чөнки ул классташлары арасында иң үрнәк, алдынгы укучы. Әнә, ишектән килеп керүе генә булды, иптәшләре үзен әйләндереп үк алдылар. Яудыралар гына сорауларын... “Синең алгебрадан икенче эшең ничек килеп чыкты,”, “Татар теленнән барлык сүзләрне дә кулланып яза алдыңмы иншаны,” һәм башкалар, фәлән-фәсмәтән... Җавап кына биреп өлгер!

Җиткән, гел миңа гына баш эшләтергә димәгән, бүген дәресләрдә ял итәчәкмен, бер көн укытучыны тыңламый утырганнан әллә ни булмас, дигән карарга килде Лилия. Аңламаса, кайткач, үзлектән укып, асылына төшенер әле. Янәсе, укытучы да китаптагы кагыйдәләргә таянып кына аңлата ич инде аларга дәресне!.. Әйе, Лилия бик нык ялгыша иде...

Дәресләр Лилия өчен бик күңелле үтте бүген, җаны ни теләде – шуны эшләде, әллә ниләр турында хыялланып утырды. Дөресен генә әйткәндә, үзенә үзе ял оештырды ул бүген. Беренче дәрес алгебра иде. Ул 9 нчы класс кызы Алсу биргән “Истәлек дәфтәре”н тутырып утырды. Укытучы апа берни сизмәде дә ахры, дәрес буе яңа тема аңлатуы белән мәшгуль булды.  Рус телендә әллә ни ял итеп булмады – диктант яздылар. Хезмәт, физик культура дәресләрендә баш эшләтергә туры килмәде. Шулай да укып була икән бит, дигән фикергә килде кыз һәм үзенең әлеге “ачыш”ына сокланып, горур атлап өенә кайтып китте. Өйдәгеләр Лилиянең кәефе әйбәт булуын чираттагы “5”ле билгесе алу белән бәйләделәр, кызларының шундый ялгышлык кылуын белмәделәр.

Лилия бер көнне өйгә кәефсез кайтты. Беркем белән дә исәнләшмәде, гадәттәгечә елмаюы да йөзеннән качкан иде. Әнисе ашарга чакырды – чыкмады. Әлфия апа кызының бу хәлтен

ишектән кереп, бер күтәрелеп карауга ук сизгән иде инде. "Кызым, ни булды сиңа, – дип эндәште Әлфия ханым. "Юк, әнием, берни дә булмады, аппетитым качкан бүген каядыр", - дип җавап кайтарды кыз. Әнисе:"Аппетит болай гына качмый ул, сөйлә әниеңә барысын да, бәлки, булыша алырмын," – дигәч, Лилия сөйләми булдыра алмады. Ул бүген алгебрадан "2"ле билгесе алып кайткан иде. Аның ни өчендер үзенә түгел, ә укытучысына ачуы килә иде. "Әни, ничек инде гел яхшы билгеләргә генә укучыга начар билге куеп була! Мин Гөлия Айратовнага үпкәләдем, башка укучыларга караганда өстенрәк күрергә тиешләр инде ул мине, бүтән берниндә олимпиадаларга да бармыйм! Мәктәп данын яклап йөргән булам бит әле тагын", - дип ярсынды кыз.

Әлфия апа кызының ялгышуын аңлады һәм тиз арада газиз баласын әлеге хаталы фикерләрдән арындырырга тырышты. "Кызым, нишләвең бу, алай ярыймы инде, синең начар билге алуыңда укытучының гаебе бармы икән? Бәлки, син ул аңлатканда тыңламыйча утыргансыңдыр, исеңә төшер әле. Бигрәк яратып өйрәнә идең бит ул фәнне, укытучысын да ярата идең." Лилия үзенең ярсуы басылуын сизә башлады, чыннан да, үзенә "лаеклы ял" үткәргән көнне Гөлия Айратовна аларга нәкъ шул теманы аңлаткан иде бит. Ә ул, кайткач укып, бу темага үзе төшенергә уйлаган иде. Тик өйдә берничә кабат укыса да, нечкәлекләренә төшенеп бетә алмады. Ярар, кирәге чыкмас та, бәлки, дип, бу турыда онытты. Ә Гөлия Айратовна бүген шушы темага үзлектән эш эшләтте. Лилия әнисенә боларның барысын да сөйләп бирде.

Ана кеше баласын бүлдермичә тыңлады һәм үзенең киңәшләрен бирергә булды. "Кызым, син хәзер үзеңнең ялгышыңны аңладың булса кирәк. Укытучыга үпкәләү – зур хата булыр, ул сиңа начар билге куеп бик дөрес эшләгән. Әгәр сине өстен күреп, билгеңне тиешлесеннән арттырып куйган булса, син хатаңны аңламый да калыр идең. Чын укытучы барлык укучыларга да бертигез карый, кемнең кайсы өлкәне аңлап бетермәвен дә сизә. Ул бары тик сине шул рәвешле сынап кына караган. Иртәгә үк укытучыңнан гафу үтен һәм әлеге теманы яңадан аңлатуын сора, кызым. Укытучылар – иң галим кешеләр, дип юкка гына җырлар да язмаганнар!"

Лилия әнисе белән тулысынча килешеп, иртән, Гөлия Айратовнадан ничегрәк гафу үтенергә икәнлеген уйлый-уйлый, мәктәбенә ашкынды. Дәрес башланырга тагын 20 минутлап вакыт калган иде әле. Менә коридорда һәрвакыттагыча тыйнак һәм пөхтә итеп киенгән, уйчан йөзле Гөлия Айратовна күренде. Ул, әйтерсең лә, һәр адымын үлчәп, уйлап атлый. Шундый салмак кына, барысы белән дә ихлас күңелдән елмаеп исәнләшеп килә... Лилиянең йөзенә кызыллык йөгерде, аңа үзе өчен бик оят иде. Ничек ул шундый кешенең дәресен тыңламыйча утыра алган да, ничек итеп шундый кешегә үпкә белдерә алган!

Менә Гөлия Айратовна Лилия янына килеп җитте. Кызның үзен көтүен күзләреннән укып өлгергән иде инде ул. “Лилия, син мине көтәсең, бугай, “ – диде ул йомшак кына. Лилия каушап калды һәм: “Ә, әйе, сезне көтәм, вакытыгыз бармы,” – диде. Гөлия Айратовна ризалыгын белдереп баш какты һәм укучысын үз кабинетына өндәде.

“Йә, ни йомыш, Садыйкова,” – диде ул кырысрак булырга тырышкандай. “Гөлия Айратовна, зинһар өчен, мине гафу итегез! Мин сезнең фәннән “2”ле алырга тиеш түгел идем. Бер көнне сезнең ни аңлатканыгызны тыңламыйча утырдым, шуның бәласе бу!” – диде Лилия көч-хәл белән.

Укытучы:” Эх Лилия, әлбәттә гафу итәм. Мин синең ул дәрестә бөтенләй икенче нәрсә белән шөгыльләнеп утыруыңны бик тиз сиздем. Күзләрең тактада булса да, уйларың белән син еракта идең. Ләкин минем фәнемне беркемгә дә көчләп укытасым килми. Укучылар белем алырга теләп укыганда гына рәхәт бит укытуы. Шуңа күрә, мин бернинди кисәтү дә ясамадым. Үз хатагызны үзегез аңлагансыз икән, мин бик шат! Теләсәң, дәресләрдән соң калып, бу теманың нечкәлекләрен аңлатып бирә алам.”

Лилия шатланып риза булды. Югыйсә, бу тема әллә ни кыен да түгел икән! Китаптан да шуны ук укыды, ләкин аңламады бит Лилия! Күрәсең, укытучы булып туарга кирәктер! Аңлата белү сәләте теләсә кемгә бирелми икән шул! Бик зур рәхмәт сезгә, укытучым!

Бу вакыйгаларга инде берничә дистә еллар үтте. Ә хәтердә әле һаман бүгенгедәй сакланган икән... Лилиянең дә кызы бүген яраткан фәненнән “койрык” алып кайткан. Үзе зирәк бала да кебек! Ләкин ул кызына ничек ярдәм итәргә кирәк икәнен белә иде! Рәхмәт, рәхмәт сезгә, укытучым! Мине генә түгел, баламны да тәрбияләргә ярдәм итәсез бит!!!

*Федорова Милена, 9 нчы сыйныф,*
*Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районының "Аерым фәннәрне тирәнтен өйрәнүче 16нчы урта гомуми белем бирү мәктәбе" муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесе*
*Җитәкчеләр: Гайнетдинова Зәлфирә Рәшид кызы, татар теле һәм әдәбияты укытучысы, Шәрифуллина Алсу Илнур кызы, тарих һәм җәгыять белеме укытучысы.*

## Бишек җырларының яшь буынны тәрбияләүдәге роле

### Кереш

**Эшнең актуальлеге:** хәзерге көндә бишек җырлары онытылып бара. Тормыш шартларының үзгәрүе, фәннең алга китүе, үзгәртеп корулар аркасында яшь буын бишек җырларсыз үсте. Кайбер заманча яшәүче ата-аналар балалар үстергәндә бу җырларны кирәк санамыйлар. Мондый ата-аналар халыкның гореф-гадәтләрен, йолаларын оныта баралар. Без күтәргән сораулар бүген дә актуаль. Бишек җырларын барламасак, сакламасак, киләчәк буыннарга нәрсә әйтербез? Без, гореф-гадәтләребезне саклау өстендә армый-талмый эшләргә тиешбез.

Салмак көйнең кеше күңеленә тынычландыргыч тәэсир итүен медицина галимнәре, психологлар да таный. Музыканың мондый сыйфатын борынгы әби-бабаларыбыз да белгәннәр һәм баланы тынычландыру, йокыга талдыру чарасы итеп кулланганнар. Бу җырларны борынгы заманнарда ук инде халыкның тәрбияви-гамәли тәҗрибәсе тудырган. Ә сүзләре исә шул көйләр нигезендә аналарның, бала багучыларның импровизацияләре төсендә барлыкка килгән.

**Эзләнү эшебезнең максаты:**

Бишек җырлары турында күбрәк белү, хәзерге чор әниләре балаларын йоклатканда нинди бишек җырларын куллануын ачыклау.

**Максатка ирешү өчен түбәндәге бурычлар куелды:**

1. Бишек җырлары турында язылган әдәбият белән танышу.
2. Сабый тормышында бишек җырларының ролен билгеләү.
3. Анкета үткәрү һәм нәтиҗәләр ясау.
4. “Бишек” җырлары тупланган брошюра ясау .

**Кулланылган чыганаклар:**

**Теоретик чыганаклар:** “Азат хатын”, “Мәгариф” журналлары,“Балалар фольклоры” китабы, К. М. Миннулин, Ф. И. Урманченың “ Татар халык иҗаты” китабы, “Милли тәрбия – милләт яшәешенең нигезе” китабы, М. Гайнуллин, М. Мәһдиевнең “Татар әдәбияты” дәреслеге, К.М.Миңнуллин, Ф. И. Урманче, Җ. Х. Кәлимуллинның “Татархалыкҗырлары”китабы, М. Х. Бакировның “Татар фольклоры” китабы.

**Практик чыганаклар:** Татар халык иҗаты.Балалар фольклоры. Бишек җырлары, “Татар халык иҗаты” хрестоматиясе.

**Эзләнү эшебезнең практик өлеше:**

Түбән Кама шәһәренең укучылары һәм укытучылары арасында анкета үткәреп, бишек җырлары турында материал туплау.

**Тикшеренү методлары.** Эшемдә эзләнү, тикшерү, чагыштыру, сораштыру методлары кулланылды.

**Фаразлау:**

Хәзерге яшь әниләр бишек җырларын һәм аның сабый тормышына ни дәрәҗәдә йогынты ясавын беләләрме?

**Эшнең гамәли әһәмияте.** Без - туган телне яратучы, буыннар тарихын һәр кешегә җиткерергә омтылучылар. “Бишек” җырларының тарихы һәм аларны саклау проблемасы белән танышырбыз.“Бишек” җырларын укып чыккач, күңелебездә туган сораулар һәм шуларга җавап табу теләге безгә эзләнү эшебезне башларга этәргеч бирде. Без белем бирә торган мәктәп укучылары да шушы кызыклы вакыйгалар, истәлекләр белән танышсыннар иде дигән максатны алга куеп эшләдек.

**Эшнең структурасы.** Хезмәт керештән, төп өлештән, йомгаклаудан һәм файдаланылган әдәбият исемлегеннән, кушымтадан тора.

Нью-Йорк шәһәренең неврология институты докторы Консетта Томани әйтүенчә, кайбер җырлар кешегә яхшы тәэсир итәләр, мине төрле химик матдәләр, серотонин һәм допамин, белән тәэмин итәләр. Кешеләр күбрәк кечкенә чакларында булган хәтирәләрне искә төшерәләр. Әти-әниләренең, әби-бабайлары җырлаган бишек җырлары шуның мисалы булып тора. Җирдә популяр поп-,рок-, электрон музыка яңгыраган көндә бишек җырларын саклау авыррак була. Бу проблеманы укытучылар белән тәрбиячеләр генә түгел, бәлки мәдәни министрлык, фән һәм мәктәп системасының идарә бүлекләрендә эшләүчеләр, журналистлар, радио-телевидение хезмәткәрләре, газета-журнал редакцияләре дә чишәргә тиеш [7, б. 71].

## Төп өлеш

### 1. Бишек җырларының эволюциясе

Җырларның туу тарихы ерак үткәннәргә барып тоташа. Күп гасырлар элек, әле дөньяда беренче китаплар гына түгел, ә беренче язу ысуллары барлыкка килгәнче үк, кешеләр җырны да, шул җыр ритмына башкарыла торган биюләрне дә белгәннәр. Җыр – ике сәнгать чишмәсе: шигърият һәм музыка кушылудан туа. Халык җырларының иҗат итүчеләре күптән онытылган, ә җырлары телдән-телгә күчеп, үзгәреп, шомарып, матурланып әле дә булса яши. Аларга бишек җырлары да керә. Җырларның иң беренче чаткылары мең еллар элек яшәгән хатын-кызларның “ә-ә,!ә-ә,ә!” дип бала юату, бала иркәләү авазларында ук яңгыраган. Ана теле сабый күңеленә җыр булып иңә; бишек тибрәткәндә дә, аны елавыннан юатканда да ана үзенең газизенә әйтәсе сүзләрен җыр-моңга төреп җиткерә һәм, ни гаҗәп, сабый аларны тыңлый, ишетеп юана, кайвакыт хәтта елавыннан да туктый!.. [9, б. 3]. Бишек җырлары турында “Балалар фольклоры” дигән китапта язылган.

Бала багу иҗаты сабыйның бишектән алып үз күңелен үзе күрә һәм үзлегеннән иҗат итә башлауга кадәрге чорын эченә ала. Баланың физик үсеше, теле, дөньяга күзе ачылуга багышланган иң тәүге фольклор үрнәкләре һәм иң беренче уен күнекмәләре әлеге иҗатның иҗтимагый-педагогик асылын, төп эчтәлеген тәшкил итә. Бала багу фольклорына карый торган иң тәүге һәм иң популяр жанр, әлбәттә, бишек җырлары. Аларның төп вазифасы-баланы йокыга талдыру, йоклату. Әлеге жанрның борынгырак үрнәкләрендә тирә-яктагы явыз мифик көчләрнең сабыйга бәла-каза китерүеннән яки йокысына комачаулавыннан качарга тырышу эзләре дә сизелә сыман.

Әлли-бәлли бәй итә,  
Балам йокыга китә,  
Балам йокыга китмәсә,  
Бүкәйләр алып китә.

Мәхмүд Кашгарый сүзлегендә күрсәтелгәнчә (XI йөз), борынгы төрки телдә “бүкә” зур елан дигән мәгънәне белдергән. Димәк, әлеге елан исемен телгә алу яки баланы шуның зыян китерүе ихтималы белән куркыту, һичшиксез, бабаларыбызның борынгы ышануларына барып тоташа. Соңрак чорларда иҗат ителгән яки импровизация белән чыгарылган бишек җырларында исә куян, кәҗә, песи, әтәч, тавык кебек тыныч табигатьле хайваннар һәм кош-кортлар телгә алына. Һәм иң характерлысы: ата-ананың үз баласының сау-сәламәт үсүенә һәм киләчәгенә бәйләнешле теләкләре, өмет-хыяллары шактый киң чагыла.

Әлли-бәлли итәр бу,

Йокыларга китәр бу.

Бәү-бәү итеп,күз йомып,

Изрәп кенә китәр бу

Алма кебек тәгәрәп,

Үсеп буйга җитәр бу,

Абыйлары артыннан

Казаннарга китәр бу,

Казаннарда укыгач,

Галим булып җитәр бу [4, б. 3].

Бала багу поэзиясенә янә кендек әби такмаклары, юаткычлар һәм мавыктыргычлар дип йөртелә торган тагын өч жанр керә. Кендек әбисе такмаклары баланы, seберке белән җиңелчә генә чаба, беренче тапкыр мунча керткәндә, яисә беренче башлап коендырганда әйтелә торган булган.

Атаң кискән утын түгел,

Анаң яккан мунча түгел,

Аюдай ага бул,

Бүредәй бөгә бул.

...Тәмле-татлы телле бул!

....Кәбестәгә су салдым,

Суы сарыксын,

Үзе калыксын,

Ят та йокла,

Тор да уйна.

Бишек җырлары ана белән бала икәүдән-икәү калган вакытта башкарыла. Ана ул мәлдә күңеле белән баланың рухи дөньясына якынаерга, уй-фикерләрен нәниләр кабул итәрлек гади, самими итеп әйтергә омтыла. Шуның өчен бишек җырларында катлаулы стилистик һәм лексик сурәтләү чаралары очрамый. Аның каравы, җырның яңгырашына караган чаралар – аллитерацияләр, ассонанслар күп. “Әлли-бәлли”, “алла-һу”, “чү-чү” кебек аваз ияртемнәре, ымлык сүзләр бишек җырларына салмаклык, тынычлык төсмере бирәләр, еш кабатлана торган “карлыгачым”, “былбылым”, “багалмам”, “гөлием”, “сачәгем” кебек эндәш сүзләр дә аларга үзенчә бер назлылык, ягымлылык, йөрәк җылысы өстиләр [10, б. 8].

Юаткычларның эчтәлеге – баланың физик яктан үсүен теләү, акыл-аң ягыннан үсә башлавына теләктәшлек итү рухында. Бәбәйне йокыдан уятуга, “үчти-үчти” сикертүгә, “чәбәкәй-чәбәкәй” иттерүгә, күкрәгеннән аяк очларына кадәр сыпырып “үс-үс” итүгә

хезмәт итә торган күнекмәләр һәм шулар вакытында әйтелүче текстлар моңа мисал була ала. Юаткычларның эчтәлекләре гади. Бу әсәрләрдә нәниләрнең таза-сау, итагатьле булып үсүләре турында теләк теләнә, баланың холкы-фигыле, кыланышлары юмористик планда тасвир ителә.

Тор, тор, тургай,
Таң-таң ата бугай,
Тургай, кил, чыпчык,чык,
Чырык-чырык-чырык.
Үчти-үчти сикерсен,
Каймак ашап кикерсен,
Әткәсе магазиннан
Бер шалтырмак китерсен.

Мавыктыргыч жанры баланың зиһенен, әйләнә-тирәгә игътибарын арттыруга, төрле объектларны белә һәм таный башлавына хезмәт итә торган текстларны берләштерә. Аларның берише сюжетлылыкка да тартымрак. Вакыйга сыманрак хәлне тасвирлыйлар. Мавыктыргычлар күптөрле әсәрләрне берләштерә. Алар арасында нәниләрне әйләнә-тирәлек, гаилә әгъзалары, хуҗалыктагы эшләр белән таныштыру максатыннан; санарга өйрәтү, логик фикерләвен, зиһенен ачтыруны күз алдында тотып башкарыла. Мавыктыргычлар аша бала әхлак кагыйдәләре белән таныша. Күпчелек бармак уеннарының сүзләре шундый характерда. Аларның кайберләрендә һәр бармак гаиләнең бер әгъзасына тиңләнә, йә булмаса һәркайсына нәрсәдер йөкләнә.

Баш бармак. Бал ашыйсы килә.
Имән бармак. Чиләктән алып ашыйк.
Урта бармак. Сорамыйчамы? Тотылырбыз.
Атсыз бармак. Юк, котылырбыз.
Чәнчә бармак. Сез котылсагыз да,
Мин котыла алмам,
Мин кечкенә. Чаба алмам [11, б. 337].

Халкыбызның язма мирасы аның элеккеге рухи мирасын чагылдыра. Кулъязма рәвешендә саклнган китапларда бишек җырлары да очрый. Текстлар 1868 нче елда төзелгән язмада теркәлгән. Китапны Казан дәүләт университетының гыйльми китапханәсенә 50 нче елларда татар теле һәм әдәбияты бүлегендә укытучы булып эшләгән галимебез мәрхүм Җәвад Алмаз тапшырган. Хәзер китапханәдә Т.1901 номеры белән саклана. Җырларның кайчан, кайларда, кем тарафыннан иҗаи ителүе турында белешмә юк. Беренче җыр:

Улым,улым.улым, шул,

Улым матур булган шул;

Улыбыз йитеп беткән икән-

Бер кыз кирәк булган шул.һ.б.

Икенче җыр:

Әлли-бәлли итәдер,

Бәләкәй матур бәпкәсе;

Еламаса,йокласа,

Рәхмәт укыр әнкәсе.һ.б. [11, б. 337].

Бишек җырлары, юаткычлар, мавыктыргычлар халыкның поэтик җәүһәрләре булу белән бергә, нәниләрне эстетик, физик, интеллектуаль яктан тәрбия итүнең отышлы чаралары да булып хезмәт итәләр. Аны “Күңел ачу фольклоры” дип атарга да була, чөнки анда уен төсмере көчле [11, б. 337].

**2. Г.Тукай җырлары**

Әдәбият тарихында бик зур фаҗига кичергән, зур бәхетсезлекләргә дучар булган шагыйрьләр бар. Әмма бала вакытында, Габдулла Тукай кебек ана җылысын эзләп, асрамага бирелеп, кагылып-сугылып йөргән һәм җиде гаиләгә бала булган бүтән шагыйрь юк. Шәхси тормышының гадәттән тыш авыр булуы аның лирикасына зур йогынты ясады, ул нечкә күңелле, дөньяның гаделсезлегнә дә, кешеләрнең яхшылыгына да искиткеч сизгер шагыйрь буларак танылды.

Бишек җырларын бөек шагыйребез Г.Тукай да үз җҗатында тирән яктырткан. Габдулла кечкенәдән җыр ярата. “Кайда ишетсәм дә, җырлау тавышын салкын кан белән тыңлый алмый идем: мәдрәсәдә хәлфәләр, кече атна кичләрдә, бер кадак симәнкә, ярты кадак чикләвек алып ясаган мәҗлесләрендә мине дә онытмыйлар иде. Мин, самовар артына гына утырып, алар кушкан көйләрне җырлап бирә идем, шул җырлавым барабәренә хәлфәләрдән берәр уч симәнкә һәдия (бүләк) кылына иде. Мин, кулымдагы симәнкәне беткәнче яргач, тагын җырлый идем”. ”Ул, кулы язу белә башлаганнан бирле, халык җырларын куен дәфтәренә терки бара. “Халык җырлары чын үзебезнеке генә булганга, анда читләрдән гарәп, төрек, сарт (утрак тормышта яшәүче үзбәкләрне революциягә кадәр шулай атаганнар) кебиләрнең тәэсире булмаганга, мин аларга әһәмият бирәм һәм мәхәббәт итәм”, дип язды ул” [8, б. 191].

”Габдулла өенә кайтып кергәндә түр башына кабык бишек эленгән, җырлый торган җырлары да бар” [8, б. 192]. Габдулла Тукай Кырлайдагы Сәгъди абзыйларда торганда бишек җырлары ишетә. Бу җырларны Сәгъди абзыйның хатыны улына, ә Саҗидә апасы энесенә багышлап җырлый торган була. Тукайның күңелендә дә бишек җыры туа.

Әлли-бәлли итәр бу,
Мәдрәсәгә китәр бу,
Тырышып сабак укыгач,
Галим булып җитәр бу.
Йокла, углым, йом күзең,
Йом, йом күзең, йолдызым,
Кичтән йокың кала да,
Еглап үтә көндезең.
Әлли-бәлли көйләрем,
Хикәятләр сөйләрем,
Сиңа теләк теләрем,
Бәхетле бул, диярем.
Гыйззәтем син, кадрем син,
Минем йөрәк бәгърем син,
Куанычым, шатлыгым
Тик син минем, синсең, син!

(татар халык көе) [3, б. 9]

Тукай күңеле белән әнисе булуын, әнисеннән матур, ягымлы сүзләр ишетергә теләгәндер... Ләкин тормыш син теләгәнчә генә бармый шул. “Халык җырлары халкыбыз күңелендә һич тә тутыкмас вә күгәрмәс, саф вә раушанкөзгеседер” дигән тапкыр билгеләмәсен бирде һәм җырларның “җәүһәр вә якутлардан” да кыйммәтле бернәрсә булганы өчен, аларга әһәмият бирергә... аларны югалтмаска, иҗтиһат итәргә чакырды (1) [ 8, б. 192].

1.Г.Тукай. “Халык әдәбияты”,1946,Казан.29 б.

**3. Халык җырлары нигезендә иҗат ителгән “Бишек” җырлары**

Җыр - татар халкының иң таралган, иң хөрмәтле иҗат җимеше. Җыр сөйләр сөйләр өчен түгел, көйләр өчен чыгарыла. Әгәр халыкның моңлы, аһәңле, матур көйләре аның тиңдәшсез һәм оста композитор булуы турында сөйләсәләр, шул көйләрнең нәфис сүзләре аның акыллы һәм талантлы шагыйрь булуын раслый.

Татар халкының җыр хәзинәсе үзенә күрә бер тарих ул. Анда без ерак гасырлар тавышын да, бүгенге көннәр аһәңен дә ишетәбез. Г. Тукай сүзләре белән әйткәндә, җыр халыкның бай “халәте рухиясе”, “бертөрле сихерле көзгесе кебек күз алдына килеп баса [9, б. 4]. Бишек җырлары бик күп. Без аларның кайберләрен мисал итеп китерәбез.

Әлли-бәлли итәр бу,
Йокыларга китәр бу,

Бәү-бәү итеп, күз йомып,
Израп кенә китәр бу.
Алма кебек тәгәрәп,
Үсеп буйга җитәр бу,
Абыйлары артыннан
Казаннарга китәр бу.
Казаннарда укыгач,
Галим булып җитәр бу.
Әлли-бәлли итәргә
Ал бишеге бар аның;
Алдына алып йоклатырга
Үз әбкәсе бар аның.
Ал бишеге бар аның,
Гөл бишеге бар аның,
Тәрбияләп үстерергә
Үз әнкәсе бар аның.

(Татар халык җыры, татар халык көе) [ 2, б. 3]

Борынгы бишек җыры
Әлли-бәлли итәдер,
Бәләкәй матур бәбкәсе;
Еламаса, йокласа,
Рәхмәт укыр әнкәсе.
Гомере булса, зуррак үссә
Сабак укыр бәбкәсе;
Сабагыны матур белсә,
Бик яратыр әткәсе.
Әткәсенең, әнкәсенең
Бер генә шул бәбкәсе.
Бу бәләкәй бәбкәбезне
Күрсә яратыр әбкәсе.
Бәбкәбезне күрергә килми
Ничек түзә әбкәсе?
Килсә килсен бүләк берлән,
Буш килмәсен әбкәсе! [2, б. 19]

Халык чыгарган бишек җырларына композиторлар: Шамил Шәрифуллин, Фәрид Шәрифуллин көй чыгарганнар.

**4. Бүгенге көндә дә яңгырый торган “Бишек” җырлары**

Көнчыгыш халыкларының усал хан турындагы әсәре бар. Усал ханның бишек җырын ишетүе була, ул кешелекле, яхшы күңелле кешегә әйләнә. Ул канкойгыч сугышларны туктата, кечкенә балаларга бишекләр ясарга, аларга бишек җырлары җырларга куша. Заманча әти-әниләрне авторлар язган бишек җырлары битараф калдырмый [7, б. 72]. Мәсәлән, Г. Афзалның “Әлли-бәлли, былбылым” җыры.

Җилләр дә тынган инде,
Күлләрдә томан инде,
Син дә йокла, күз нурым,
Әлли-бәлли, былбылым.
Әлли-бәлли, Әлли-бәлли,
Әлли-бәлли, былбылым!
Күк тулы йолдыз гына,
Ай йөри ялгыз гына,
Син дә йокла, йолдызым,
Әлли-бәлли, былбылым.
Әлли-бәлли, Әлли-бәлли,
Әлли-бәлли, былбылым! [3, б. 28]

Бишек җырларын күп кенә шагыйрьләр иҗат иткән. Бу җырларга композиторлар тарафыннан матур көйләр чыгарылган.

Кыйгач кашым, асыл ташым,
Йоклаек икәү!
Йокла, иркә,йокла,бәбкә,
Бәүкәй,бәлли-бәү!

(Дәрдемәнд сүзләре, Резеда Ахиярова көе)

Шаян кызым син минем,
Таң йолдызым син минем,
Йөрәгемдә кабынган
Шатлык җырым син минем.

(Муса Җәлил сүзләре, Җәүдәт Фәйзи көе)

Кичке шәфәкъ сүнде күптән,
Кояшны каплый таулар.
Тиздән инде, сине эзләп,

Тәрәзәгә ай карар.
Йокла, йокла, улым,
Без бергә икәү
Каршыларбыз таңны,
Әлли-бәлли-бәү,
Әлли-бәлли-бәү.

(Ләбиб Айтуганов сүзләре, Алмаз Монасыйпов көе)

Бәлли-бәү, кызым,
Күктә ай калка.
Йокла, йом күзең,
Шаярып ятма.
Бәлли-бәү, бәлли-бәү,
Йокла, йом күзең,
Шаярып ятма.

(Мәхмүт Хөсәен сүзләре, Алмаз Монасыйпов көе)

Сине көткән тыныч таң да,
Уятасы матур чаң да
Әлли-бәлли-бәү итә –
Дөнья йокыга талган!

(Ренат Харис сүзләре, Ренат Еникеев көе)

Бакчада кошлар тынган,
Гөлләр керфеген йомган.
Син дә, балам, йом күзең,
Йокла нәни йолдызым!
Йолдызым!..

(Гөлшат Зәйнашева сүзләре, Ренат Еникеев көе)

Алтыным ла син,диеп,
Ялкыным ла син,диеп,
Үстерәм бәбкәемне
Иркәләп-сөеп,
Улыкаем син минем,
Колынкаем син минем;
Юлыма нур сибүче
Бәхетем минем.
Бәлли-бәлли-бәү.

(Фирая Зыятдинова сүзләре,Луиза Батыр-Болгари көе)

Әлли-бәлли,йом син күзең,
Әлли-бәлли – татлы сүзем.
Йоклый инде бөтен бәбиләр дә,
Йоклый инде хәтта әбиләр дә,
Әлли-бәлли,йом син күзең,
Әлли-бәлли – татлы сүзем.

(Разил Вәлиев сүзләре,Шамил Тимербулатов көе)

Син минем нәнием,
Табигать җимеше.
Син минем җирдәге
Йөрәгем җимеше.

(Эльмира Шәрифуллина сүзләре, Риф Гатауллин көе)

Кояш ятты бишегенә,
Күзләрен йомды.
Кошлар да сайрамый инде,
Чишмәләр тынды.

(Резеда Вәлиева сүзләре, Ренат Салихов көе)

Йолдызлар да йоклыйдыр зәңгәр күктә,
Кондызлар да йоклыйдыр зәңгәр күлдә.
Чәчәкле гөлбишектер  бар табигать,
Йокла, балам, син дә ак мендәреңдә.
Йокла, бәбкәем!
Күгәрченкәем.

(Гөлшат Зөйнашева сүзләре,Мәсгут Имашев көе)

Болыт, болыт таралды,
Җирдә,җирдә таң алды.
Аваз салдың, син балам,
Бар шатлыгым яңарды.

Бүләк итәм мин туган телемне,
Күңлемә тулган олы хисләрне:
Челтер чишмәле аяз иртәне,
Әкият тулы айлы кичләрне.

(Сәйдә Зыятдинова сүзләре, Зиннур Гыйбадуллин көе)

Кояш инде тәгәрәп
Төште таулар артына;
Әлли-бәллли-бәү, диеп
Әнә Чулман яктыра-
Әлли-бәллли-бәү, диеп...

(Мөдәррис Әгъләмов сүзләре,Рамил Курамшин көе)

Син минем нәнием
Табигать җимеше.
Синдә Җир шарының
Йөрәге тибеше.

(Эльмира Шәрифуллина сүзләре, Фәрид Шәрифуллин көе)

Күтә йолдыз елмая,
Йолдызлар яна,
Матур елгаларда
Сикереп су ага.
Син тауларда йөрдең,
Диңгездә йөздең,
Парашютчы булдың-
Күктән сикердең.
Йокла, балам, йокла,
Йом тизрәк күзең,
Бик зур эштә үтте
Синең көндезең.

(Әхмәт Ерикәй сүзләре,Гөлчәһрә Байкина көе)

Гөлдер,гөлдер,гөлдергү...
Күк күгәрчен көе бу.
Әнкәең дә,эткәең дә
Сөя сине, бәбкәем.

(Нәкыйп Каштан сүзләре,Ильяс Гыйләҗетдин көе)

Йолдызлар яна җемелдәп,
Йокыга талган дөнья.
Безнең тәрәзә каршында
Көмеш ай балкып тора.
Мин җырлыйм синең яныңда,
Тыныч төн телим сиңа.

Безнең тәрәзә каршында
Көмеш ай балкып тора.

(Нәби Дәүли сүзләре,Рөстәм Яхин көе)

Уйнаганда гөр килеп,
Дәү әнием туктата.
Яткыра да янына,
Мине җырлап йоклата:
- Йокламыйм,дип еламый,
Менә бит ул нинди дәү!
Әлли-бәлли, әлли-бәлли,
Әлли-бәлли, әлли-бәлли-бәү.

(Хәкимҗан Халиков сүзләре,Разыя Еникеева көе) [3, б. 4-84]

Т. Миңнуллиннны үзенчәлекле әдип иткән сыйфат иң элек аның дөньяга карашыннан, тормыш күренешләрен заман үзгәрешләрен аңлау дәрәҗәсеннән башлана.Кеше язмышын җәмгыять һәм милләт язмышы белән бәйләнештә карап, халкыбызның милли йөзен, гореф-гадәтләрен тасвирлау аша һәр кешенең үз алдындагы бурычларын онытмаска тиешлеге аның **“**Әниләр һәм бәбиләр**”** (1984) драмасында ачык күрсәтелә. Драмада әдәбиятның мәңгелек темаларыннан берсе ана булу бәхете чагыла, һәм бу бәхетнең матурлыгы милли-әхлакый кануннарга барып тоташа. Драмадагы төрле дәрәҗәдәге хатын-кызлар- аналарның сөйләшүләре, гади авыл хатыны, унике бала анасы Гөлфинәнең акыллы, борчулы, миһербанлы, кирәк икән кисәтүле дә сүз-киңәшләре җәмгыятьтәге әхлак кануннарының бозыла башлавында хатын-кызның роле зур икәнлеген аңларга ярдәм итә. Тамашачы күңелендә аптыраулы гаҗизлек катыш кызганулы нәфрәт уяткан образ- Дилемма. Баш табибның “иманыгыз бармы сезнең?”, “бишек җырын беләсезме?” дигән сорауларына яңа гына баладан котылган яшь хатынның “мин ул сүзне аңламыйм”, безгә аны өйрәтмәделәр” [13, б. 115] дип җавап бирүе Дилемма кебекләрнең бу тормышта очраклы күренеш түгеллеген, аларның барлыкка килүләренең сәбәпләре бик тирәндә икәнлеген күрсәтә. Тәрбия ана сөте, бишек җырлары, балага булган мәхәббәт, иреңә карата ихтирам, ата-анага хөрмәт кебек гүзәл сыйфатлар белән күчә. Әйе, ул вакытларда тапкан баласын алырга һәм тәрбияләргә теләмәүләр, ташлап калдырулар күренә башлаган була инде. Бу күренешнең ни дәрәҗәдә куркыныч булуын, кешелекнең алга үсешенә ничек янавын әйтеп, драматург чаң суга.

Татар язучылары, шагыйрьләре үз балалары тугач, илһамланып бишек җырлары язганнар. Алар халык педагогикасына таянып эш иткәннәр. Ә бит халык педагогикасы-зур акыл, сәламәт әхлак чишмәсе. Аның нигезендә кешелеклелек, шәфкатьлелек,

мәрхәмәтлелек, гаделлек, тыйнаклык кебек матур сыйфатлар тәрбияләү ята. Шул ук вакытта, буыннардан буыннарга күчеп килә торган тәрбия чаралары искиткеч күптөрле шул [6, б. 8].

## Йомгак

Бишек җырларының әһәмияте зур. Кеше тормышында бишек җырларының урыны дәрәҗәле. Һәркем аны, сабый чакның якты истәлеге итеп, гомеренең соңгы көннәренә кадәр күңел түрендә саклый. Ул җырлар газиз ана, туган ил, туган тел кебек изге төшенчәләр белән бергә йөри. Бу табигый да, чөнки бала шигъри матурлык, аналарның йөрәк җылысы, үз халкының рухы белән тәүге кат шушы бишек җырларында очраша.

Бу җырлар әбиләрнең "өшкерүләре" кебек, бик зур файда китерәләр. Ана бала йоклатканда җырлаган җыр тормыштагы авырлыкларны җиңәргә көч бирә, заманча кешеләргә җитмәгән уңай кешелек сыйфатлары булдырырга ярдәм итә. Россия медицина фәннәре академиясе галимнәре бишек җыры җырлаган ананың сөте күбрәк төшә, бала белән элемтәсе якынрак була, диләр. [7, б. 72]. "Тыныч йокы, нәниләр" тапшыруы да бишек җыры белән тәмамлана.

Түбән Кама шәһәрендә "Ак калфак" җәмгыяте эшләп килә. Бу җәмгыять Халыклар дуслыгы йортында урнашкан. Анда булачак яшь әниләргә бишек җырлары өйрәтәләр. Хәтеремдә әле дә яңгыраган бу сүзләрне мин үз кызыма да җырлармын, алла бирса.

Әлли-бәлли бәү итә,
Милена йокыга китә.
Милена йокыга киткәч,
Бар да тынычлап китә.
Әлли-бәлли бәү итә,
Милена йокыга китә.
Милена йокыга киткәч,
Әннә кибеткә китә.
Әлли-бәлли бәү итә,
Милена йокыга китә.
Милена йокыга киткәч,
Апасы урамга китә.
Әлли-бәлли бәү итә,
Милена йокыга китә.
Милена йокыга киткәч,
Әттә йоклап та китә.

16 нчы мәктәпнең өлкән сыйныф укучылары һәм укытучылары арасында анкета үткәрдек.Анкетада 243 кеше катнашты: 31 укытучы, 212 укучы.Анкета сораулары һәм нәтиҗәләре:

1. Синең бишек җырларын ишеткәнең бармы?

Әйе: 217

Юк: 26

2. Сиңа әниең бишек җырлары җырладымы?

Әйе: 225

Юк: 18 (мин йокласын дип, телевизорны кабызалар, магнитофон язмасындагы төрле җырлар тыңлаталар иде; кулга ияләнмәсен дип, бишеккә салып, йоклаганны көткәннәр; әби караган, елый-елый йокыга киткәнмен һ.б.)

Белмим:

3. Балага бишек җырлары җырларга кирәкме?

Әйе: 232

Юк: 11 (укучыларга бишек җырларын тыңлатып карагач, аларга бик ошады һәм алар үз балаларына да җырларбыз дип сүз бирделәр)

4. Нинди бишек җырлары беләсең?

Рус балалары рус җырларын, татар балалары татарча бишек җырларын җырлап күрсәттеләр. Бу җырлар дүртюллыклар иде.

Халык иҗатын, бишек җырларын онытмау өчен төрле юллар кулланырга була:

1. Гаиләдә һәм җәмгыятьтә буыннар алмашын ныгытырга, сакларга кирәк.

2. Балалар иҗаты әсәрләрен мәктәптә, балалар бакчасында, музыка мәктәпләрендә өйрәтергә, бишек җырларын аерым бүлек буларак хәзерге яшьләргә өйрәтүне татар әдәбияты дәресләрендә максат итеп куярга кирәк.

Нәтиҗә: 1) Сораштырулардан күренгәнчә, хәзерге заманда телевизорлар, төрле дисклар, интернет булуга карамастан, әниләр сабыйларына бишек җырларын барыбер җырларга тиешләр, дип уйлыйбыз.

2) Хәзерге заманда бишек җырларын саклап калу өчен тырышырга кирәк. Шуңа күрә мин үзем өчен бишек җырларыннан торган брошюра эшләдем. Әйдәгез, бишек җырларына югалтырга ирек куймыйк, үзебез өйрәник һәм балаларыбызга җырлыйк.

**Файдаланылган әдәбият**

1. “Азат хатын” журналы. №10.1990. – 20 б.

2. Бишек җырлары. – Казан: “Мәгариф” нәшрияты, 1993. – 3 – 45б.

3. Бишек җырлары. – Казан: Татарстан китап нәшрияты, 2000. – 5 – 101б.

4. Балалар фольклоры.- Казан: Татарстан китап нәшрияты,1984. – 3б.

5. К. М. Миннулин, Ф. И. Урманче. Татар халык иҗаты. – Казан: Мәгариф, 2001. – 183 б.

6. Милли тәрбия – милләт яшәешенең нигезе. - Түбән Кама: 2010. – 8б.

7. “Мәгариф” журналы. №3 ,2013. – 71б.

8. М.Гайнуллин, М. Мәһдиев. Татар әдәбияты. – Казан: Татарстан китап нәшрияты,1975. – 191 – 192б.

9. Татар халык җырлары. К.М. Миңнуллин, Җ. Х. Кәлимуллин, Ф. И. Урманче – Казан:“Мәгариф” нәшрияты, 2001. – 3 – 4б.

10. Татар халык иҗаты.Балалар фольклоры. –Казан,Татарстан китап нәшрияты,1993. – 8 – 9б.

11. Татар фольклоры. М.Х.Бакиров.- Казан: “Мәгариф” нәшрияты,2008. – 337 – 339б.

12. Хрестоматия. Татар халык иҗаты. –Казан: Мәгариф, 2004. – 479 б.

13. Туфан Миңнуллин.Әниләр һәм бәбиләр. – Казан: Татарстан китап нәшрияты,1985. – 115б.

*Хәбибуллин Давид, 9 сыйныф,*
*Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районының Муса Җәлил исемендәге “1 нче гимназия” муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесе*
*Җитәкчесе: Солтанов Радик Ибраһим улы, тарих һәм җәмгыять белеме укытучысы*

## Казан кремленың саклану системасы

### I. Кереш өлеше. Казан шәһәренең саклану системасы.

Дәресләрдә Рәсәй һәм Татарстан тарихын өйрәнгән вакытта, XVI гасырда Казан ханлыгы белән бәйле чор, Иван Грозныйның аны яулап алганы, татар халкында зур үзгәрешләр вакыты бик зур кызыксыну тудыра. Мең еллык Казан Европа һәм Азия уртасында урнашкан, җәмгыяви-икътисадый һәм территориаль-этник үсеше белән аерылып тора. Борынгы заманнардан ук татар халкы өчен, Казан- милли горурлык булып тора. Шулай ук билгеләп үтәсе килә,шәһәрнең тарихы Урта Идел буенда яшәүче халыклар тормышы белән аерылгысыз .

Казан турында бихисап мәгълүмат тупланган, әмма дә ләкин тарихи-географик яктан аз өйрәнелгән. Казан шәһәре  Көнчыгыш Европаның ике зур елгасы Идел белән Чулман кушылган урында урнашкан. Әкренләп Казан тирәсендә авыллар, бистәләр барлыкка килә.

Урта гасырларда Казан шәһәре бик яхшы ныгытылган була. Ләкин, кызганычка каршы, шәһәрнең саклану  системасына багышлынган мәгълүмат бик аз. Мин үземә, Казан шәһәренең, Кремльнең саклану системасын  өйрәнергә максат итеп куйдым.Бу максатка ирешер өчен миңа тарихи һәм географик чыганакларга таянып, объектларның урынын, мөхимлеген күрсәтү зарур.Тикшерү эшемнең төп алымы, язмаларны һәм археологик чыганакларны анализлау.

Казан ханлыгы идарә системасының югары катламында дәүләт идарәсендәге бәкләр һәм дини катлам белән беррәттән хәрбиләр торган. Ханның шәхси гаскәре дәүләттәге башка хәрби көчләрнең үзәге буларак саналган. Бу гаскәр даими хезмәттә булучы гаскәриләрдән: эчке, тышкы һәм сарай казакларыннан торган. Эчке һәм сарай казакларлары ханның шәхси гаскәре(гвардия), ә тышкы казаклар исә ханлыктагы аерым феодал биләмәләр белән бәйле бәк-морзалар кул астындагы гаскәриләр буларак карала[1]. Алар белән бәк-кенәзләр (кенәзләр – ханлыкка кергән башка халыкларның җитәкчеләре), морза, огланнар (уланнар), җитәкчелек иткән*)* [2]. Хәрбиләр эшчәнлеге күп чыганакларда искә алына. Мәсәлән, Сафа-Гәрәй хан тарафыннан 1530-1544 еллар арасында Польша короле һәм бөек Литва кенәзе Сигизмунд I гә җибәрелгән хатлардан Казан ханлыгы гаскәренең өске катлам төзелеше шәрехләнә: “Минем барлык морза һәм уланнарым... Бөтен Казан җиренең кенәз, морза һәм уланнары... Козучак улан җитәкчелегендә 40 меңле гаскәр җибәрдем... Ямурч аталык җитәкчелегендә 70 мең гаскәр җибәрдем... Ахмагма улан җитәкчелегендә 40 меңлек гаскәр җибәрдем... Минем кул астындагы Казанның кенәз, морза һәм уланнары... Кенәз, морза һәм уланнарга... Кенәз, морза һәм уланнар...” [3].  Хаттан күренгәнчә, гаскәрдә хезмәт итүчеләргә акча яисә җир түләме бирү каралган.

## II. Төп өлеш.

### 1. Казан кремле ханлык чорына кадәр.

Кремльнең тарихы шулкадәр бай һәм гыйбрәтле ки, аның үзе турында гына да, мөгаен, бөтен бер китап язарга мөмкиндер. Шулай булмыйча, ул бит Казанның моннан мең ел чамасы элек ташы салынган урыны, сәнгатьчәрәк итеп әйтсәк, аның йөзек кашы, гамәли кендеге. Хәзер исә — шәһәрнең генә түгел, бөтен республиканың дәүләти үзәген тәшкил иткән, чал тарих рухы белән эретелгән бөтен бер мәһабәт һәйкәл-корылмалар җыелмасы. Белгечләр фаразынча, “кремль” татарча “кирмән” сүзеннән ясалган, ханлык дәверендә башлыча “кальга” (ныгытма, замок мәгънәсендә), патша Россиясе чорында “крепость” дип

йөртелгән. Казан шәһәренең һәр җәһәттән үзәге буларак, ул, һичшиксез, аерым, тәфсилле хикәяләүгә лаек.

Кремльнең оешу һәм үсү тарихын шартлы рәвештә биш дәвергә бүлеп карау дөресрәк булыр. Аның беренчесе — нигезләнгән вакытыннан алып ханлык башкаласына әйләнгән, икенчесе — ханлык хөкем сөргән, өченчесе — Россия составына кергән, дүртенчесе — совет, бишенчесе — без шаһитлары булган хәзерге чорларны үз эченә ала. Беренче дәвер турында мәгълүматыбыз бик чикле. Ул хакта без асылда археологик табылдыклар нигезендә генә хөкем йөртә алабыз. Соңгы елларда кремль территориясендә үткәрелгән казу эшләре вакытында төгәл даталары билгеле булган Салтово-Маяк (элгәре болгарлар чоры) культурасына караган балчык савыт-саба, сердолик, гәрәбә һәм пыяладан эшләнгән муенса төймәләре, бакыр беләзекләр, каеш прәшкәсе, ат йөгәне бизәге, тимер ук очлары һ. б. әйберләр килеп чыкты. Ә менә кенәз Вацлав тарафыннан 929-930 елда сугылган чех көмеш дирһәме (денарий) чын мәгънәсендәге могҗизага әйләнде. Галимнәрнең бердәм фикере буенча, Казан кремлендә табылган әлеге һәм башка төр борынгы әйберләр безнең ерак бабаларыбызның бирегә X гасыр башларында килеп, кальга салып утыруларын раслый.

Әйтергә кирәк ки, хәзерге кремль урыны (ягъни шәһәрнең маясы) бабаларыбыз тарафыннан даһиларча дип әйтерлек зирәклек белән сайлап алынган. Бу төбәк яшәү һәм дошманнардан саклану өчен менә дигән табигый крепость вазифасын үтәгән. Чөнки кальганы берничә яктан текә кыялар, төньяктан ул вакытларда тирән һәм киң сулы Казансу елгасы, көнбатыштан сазлыкларны кисеп аккан Болак, көньяктан һәм көнчыгыштан үтеп чыккысыз урманлы чокыр-чакырлар, күлләр бoҗрасы, куе кара урманнар һ. б. күпсанлы киртәләр саклаган.

**2. Кремль Казан ханлыгы чорында.**

Казан ханлыгы чорында (1439—1552) кремльдә инде эчке һәм тышкы кальгалар барлыкка килә, аларга таза агач диварлары һәм биек күзәтү-саклану манаралары булган калачык (посад) килеп сыена, боларга исә берничә яктан бистәләр килеп терәлә. Шәһәр һәм аның кремле турында XVI гасырда яшәгән билгесез автор үзенең "Казан тарихы" дигән хезмәтендә болай дип язган: "Казан шәһәре чамадан тыш нык, таш кыяга охшаш, аның стенасы тулы имән бүрәнәләрдән буралган, ә арасына ләм белән эре ком тутырылган". Кремльдә үз дәрәҗәсен белеп, мәгърур кыяфәт белән басып торган купшы сарайларны, биек манараларын күккә чөйгән таш мәчетләрне, сырлап-бизәкләп төзелгән, төсле керамика белән зиннәтләнгән биналарны үзән ягыннан күзәткән шәһәр кунаклары исләре китеп тамаша кылган. Хәтта каланы алырга, җимерергә дип, яу белән килгән Мәдһиш Иван белән воевода Андрей Курбский да Казанның гүзәл манзарасына соклануларын яшерә алмаган.

Галимнәрнең фараз кылуынча, кремльдә “Зур”, “Нургали”, “Аталык”, “Төмән” һ. б. исемдәге капка манаралары күтәрелеп торган. Казанның XVI гасыр теркәү кенәгәсендә хәзерге Благовещение соборы каршындарак известьле таш һәм кирпечтән салынган берничә бина һәм пулатны үз эченә алган хан сарае искә алына. Сарай белән янәшәдә күпсанлы манаралары белән берничә зур мәчет калыккан. Алар арасында үзенең зурлыгы, мәһабәтлеге һәм зәвыклы эшләнеше белән биш (кайбер мәгълүматлар буенча: сигез) манарасын күккә төбәгән Кол Шәриф җәмигъ — шәһәрнең баш мәчете аерылып торган. Аңа берьюлы меңнән артык кеше сыйган. Мәчет каршында бөтен Казан ханлыгында гына түгел, башка илләрдә дә мәшһүр сәед (дин башлыгы) һәм мөдәррис (дәрес бирүче) Кол Шәрифнең атаклы мәдрәсәсе урнашкан. Кремльнең иң шөһрәтле һәм серле биналарыннан берсе — Хан мәсҗеденә (күбрәк Сөембикә манарасы буларак мәгълүм) киңрәк тукталу гадел булыр. Инде легендага әйләнгән, бихисап давыллы вакыйгаларның үзәгендә кайнап, аларның телсез шаһиты булган бу гаҗәеп монументның Казан ханлыгы чорында төзелүе (1500—1535 елларга ишарәләр бар) миндә бернинди шик уятмый. Моның шулай икәненә Н. Г. Ханзафаровның “Символы Татарстана (мифы и реальность)” [4] һәм Габбас Мөхәммәдшинның “Семь ступеней минарета “Сююмбики” [5] дигән китапларын укыгач, тәмам инанасың.

Бу уңайдан өч-дүрт кенә дәлил китерәм. Әгәр, кайбер россиячел чыганакларда күрсәтелгәнчә, бу манара XVIII гасырның беренче яртысында төзелгән икән, нигә бу хакта сыңар документ та сакланмаган?

Аның “чордашлары”, хәтта аларны төзүчеләре турында мәгълүматлар бар бит. Россия дәверендә руслар тарафыннан корылган икән, бу төзелешне Казан татарлары да күзәткән булырга тиеш. Шунлыктан руслар салган бина төбенә тәкъва мөселман татары дога кылырга берничек тә килә алмый. Хәлбуки, ул моны, мәчеткә хисаплап, гасырлар буена эшли. Өченчедән, “үзләре” бина кылган шундый мәһабәт корылмага татарның шанлы-шәүкәтле заманнарын хәтерләткән “Сөембикә” исеме бирергә рус хакимиятенең башына тай типмәгән лә! Шунысы мөһим: 1894 елда Санкт-Петербургта басылган Ф. А. Брокгауз һәм И. А. Ефрон энциклопедиясендә Сөембикә манарасы — татар ханлыгы чорыннан сакланып калган бердәнбер бина дип күрсәтелгән. Менә шуларны яхшы аңлап, Ленин хөкүмәте 1918 елның 30 гыйнварында Сөембикә манарасын үз хуҗаларына, ягъни татарларга “кайтарып бирү турында” карар чыгарган да инде.



1880-1900 – Тайницкая башня Казанского Кремля.




Казан ханлыгында хәрби хезмәт һәм кораллану Алтын Урда хәрби хезмәте һәм гаскәр туплавы үрнәгенә нигезләнеп корылган. Казан гаскәренең структурасы, аны тәртипкә салу һәм тәэмин итү шул ук системада алып барылган.

Шул ук вакытта Казан ханлыгы үзендә Идел Болгары хәрби сәнгатенең шактый гына элементларын туплаган. Күпчелек очракта алар сакланыр өчен эшләнгән вал, чокыр, ныгытма диварларына охшаганнар. Казан хәрбиенең якын арадагы сугыш өчен кирәкле коралларына шул вакыттагы сугыш кирәк-яракларының һәммәсе дә кергән: кылыч, сөңге, сугыш балталары, булава һ.б. Сакланыр өчен шлем, калкан, көбә кулланылган. Тарихи чыганаклар казанлыларда утлы кораллар һәм хәрби флот булуы турында хәбәр итәләр.

**3. Россия составына кергәч Казан кремле.**

1552 елның азагыннан кремль язмышында өченче дәвер башлана. Кала Мөдһиш Иван гаскәрләре тарафыннан алына һәм нигезенәчә диярлек җимерелә. Җимерү-шартлатулар, ут төртеп яндырулар нәтиҗәсендә иске Казан, шул исәптән кремльнең таш һәм агач корылмаларыннан бик аз нәрсә генә имин кала яисә хәрабә хәленә килә. Әмма Казанның стратегик әһәмиятен яхшы аңлаган Грозный хөкүмәте тиз арада аны (инде христиан шәһәре буларак) аякка бастыру эшенә керешә. XVI гасырның азагында ук инде кремль бүгенге кыяфәтенә тартым төс ала башлый. Башта барлык корылмалар да агачтан ашык-пошык кына төзелә. Мәсәлән, кремльдәге Благовещение соборы өч, Спас чиркәве бер көн эчендә өеп куела.

Тарихи чыганакларга караганда, 1556 елда Казанга Постник Яковлев (Барма) һәм аның ярдәмчесе Иван Ширяй җитәкчелегендәге Псков ташчылары артеле килә. Алар зур күләмле төзү эшләре башлап җибәрәләр. Тиз арада таштан кремльнең көньяк стеналары, үтеп йөрмәле Спас, Преображенский, Тайницкий манаралары, Воскресенск капкасы, шулай ук яңа Благовещение соборы һәм Спас “капка өсте” (“надвратная”) чиркәве салына. Бүгенге көндә кремльнең төньяк-көнчыгыш өлешендә зур мәйдан биләп торган Благовещение соборы җимерелгән Кол Шәриф җәмигъ мәчете нигезендә утыра дигән мәгълүматлар бар. Соборның нигезенә мөселман кабер ташлары салынуы бу версияне куәтли генә.

XVII гасыр башында агач стеналар тулысынча таш диварлар белән алмашына, 13 манара (бишесе үтеп йөрмәле) корыла. Хәзер аларның сигезе сакланып калган. Шул ук вакытта ханлык чорыннан калган бина-хәрабәләр дә өлешчә сафка баса. Мәсәлән, һөҗүмнән соң шактый төзек калган Нургали мәчетен һәм ярым җимерек хан сараен хәрби склад итеп җайлаштыралар. Инде әйткәнебезчә, беркадәр соңрак әлеге мәчетне Сарай чиркәве (Дворцовая церковь) итеп үзгәртеп коралар.
Кремль чын мәгънәсендәге крепостька әйләнә. Авыр капкалар шалтырап бикләнә, күтәрелмә күпер чылбырга асыла, төнлә факеллар яндырыла, стена өсләрендә коралланган укчылар (“стрельцы”) кизүлек итә. Шуңа күрә 1774 елның июлендә Е. И. Пугачевның кремльне ала алмавы бер дә гаҗәп түгел. Тагын шунысы бар, XVII гасырның урталарында

татарларга шәһәрдә инде күренергә яраса да, крепостька (ягъни, кремльгә) үтеп керү үлем куркынычы астында катгый тыелган булган.

Кремльнең төп мигъмарият һәйкәлләреннән берсе — ак таштан салынган үтеп йөрмәле Спас башнясы. XX гасыр башынача ул сыңар гөмбәзле “капка өсте” чиркәве белән бер комплекс тәшкил иткән. Кремльгә керү чиркәү аша гына мөмкин булган. XIX гасыр башларынача башня алдында күтәрелмә агач күпер торган. Ул кремльнең көньяк стеналары буйлап үткән тирән чокыр өстенә салынып, “кирәк вакытта” крепостьне шәһәрдән аерган. Спас башнясы, нигездә, XVI гасырда ук төзелеп бетсә дә, бүгенге кыяфәтенә XVIII гасыр башларында гына керә һәм әле XIX йөздә дә камилләште-релүен дәвам итә. XVIII йөзнең икенче яртысында манарага музыка уйнаучы сәгать куела. Сәгатьнең үзенчәлеге шунда: ук циферблат тирәсендә түгел, ә циферблат хәрәкәтсез торган ук тирәсендә әйләнә торган була. Шул ук гасырның азагында бу сәгать урынына бик зур механизмлы гадәти сәгать урнаштырыла. 1963 елда аны электр сәгате алмаштыра. Революциягәчә чорда манараның “баш түбәсе”ндә Россия империясенең дәүләт символы — ике башлы каракош “оя кора”. 1917 елгы Февраль революциясе вакытында ул алып ташлана. 1930 елда шпильгә урак белән чүкеч урнаштырыла. 1963 елдан алар урынын диаметры 2,7 метрлы һәм авырлыгы 1,3 тонналы алтынга манчылган йолдыз ала.

Бүгенге көндә Спас башнясының биеклеге 47 метр чамасы тәшкил итә. 1845-1849 елларда Мәскәү архитекторы К. А. Тон проекты буенча кремльдә губернатор сарае төзелә. Ул, нигездә, элекке хан сарае урыны белән тәңгәл килә. Архитектура ягыннан күркәм һәм мәһабәт бу бинада 1917 елгы Февраль революциясеннән соң эшче, солдат һәм крестьян депутатларының Казан Советы эшли. 1990 елларга кадәр биредә ТАССР Югары Советы Президиумы һәм ТАССР Министрлар Советы урнашкан иде. Хәзер исә ул — Татарстан Республикасы Президенты резиденциясе.


Өстән караганда, кремль диварлары сызыгы төгәл булмаган “күппочмак”ны хәтерләтә. Бу төгәлсезлек кремль урнашкан калкулык конфигурациясе белән бәйле. Кремльнең төньяктан көньякка таба озынлыгы 575 метр чамасы. Көнбатыштан көнчыгышка сузылган иң зур киңлеге — 257, көньяк дивар буендагы иң тар урыны — 170 метр. Диварларның тышкы периметры 1,8 километрга, кремльнең мәйданы 12,4 гектарга җитә. Әлеге саннарны китерүнең хикмәте шунда, мондый зур, мәһабәт кремле булган шәһәрләр Россия Федерациясендә бармак белән генә санарлык. Совет чоры кремльдәге биналар сакланышына, алардагы символларның торышына зур үзгәрешләр алып килә. Әле 1917 елның 16 сентябрендә үк (ягъни Вакытлы хөкүмәт заманында) Мөселман хәрби шурасы карары нигезендә Сөембикә манарасы шпиленнән ике

башлы каракош алып ташлана. Аның урынына шунда ук ай кую планлаштырылган булса да, каршы көчләр моңа ирек бирми. Совет власте карары нигезендә манара татар “хезмәт ияләре”нә кайтарылып бирелгәч (1918 ел, 30 гыйнвар), шул ук елның 8 мартыннан аның түбәсен ай бизи башлый. Димәк, корылмага мәгълүм дәрәҗәдә Хан мәсҗеде статусы бирелә. 1930 елларда дингә, гыйбадәт йортларына аяусыз һөҗүм башлангач, Сөембикә манарасындагы ай да юкка чыга. Бу хәвефле чорда кремль эчендәге чиркәүләр дә зур зыян күрә, шактые сүтелә, иң мәһабәт Благовещение соборы байтак корпус һәм янкормаларыннан “колак кага”. Ләкин совет власте елларында да бу соборның төп рухи-идеологик мәгънәсенә хилафлык килми: аның гөмбәзендәге алтынланган зур тәреләре сакланып кына калмый, бәлки әле исламны гәүдәләндергән айларны басып-сытып та тора.

Совет власте елларында Спас башнясына мөнәсәбәтле үзгәрешләрне инде өлешчә күрсәтеп узган идек. Бу чорларда ул кремльнең генә түгел, бөтен Казан шәһәренең “визит кар-точкасы”на әйләндерелгән иде. Алтынга манчылган йолдызы Мәскәү кремле рубин йолдызларының нурын чагылдыручы символ буларак тәкъдир ителде. Манарага электр сәгате, вакытны суга торган чаң куелуы зур тантанага әйләнде. Бу хакта матбугат, радио күп шаулады. Кичләрен һәм төннәрен чаң сугуы кызыл балкыш фонында яңгырап килде. СССР таркалганнан соңгы чорда кремль ансамбленең “чырае”на яңа төсмерләр кунды. Бу процесска Татарстанның дәүләт суверенлыгы игълан ителүе дә үз тамгасын салды. 1990 еллардан соң үткәрелгән төзекләндерү эшләре вакытында Благовещение соборының тәреләр имгәткән айлары алынып, православиенең үз символикасы гына калдырылды. 1990 елның 24 августында Сөембикә манарасына ай кую турында ТАССР Министрлар Советының махсус карарына кул куелды. Шул карар нигезендә Татарстан дәүләтчелегенең үзенә күрә бер билгесенә, хәтта символына әйләнгән манара 1990 елның 26 сентябрендә алтын төсендәге ай урагы белән бизәлде. Бу гамәл 1930 еллардан бирле хөкем сөргән гаделсезлеккә, ниһаять, чик куйды, манараны үзенең табигый халәтенә кайтарды. Тарихи гаделлекне торгызу бу акт белән генә чикләнмәде.

Бераздан чират Казанның иң гүзәл мигъмарият корылмаларыннан һәм гыйбадәт йортларыннан булган Кол Шәриф җәмигъ мәчетенә дә килеп җитте. Татарстан Республикасы Президенты 1995 елның 13 ноябрендә 1552 елда юкка чыгарылган гайбадәтханәнең варисын төзү турындагы карарга кул куйды. Кол Шәриф мәчетен төзү эшләре 1996 елның ахырында башланып китте һәм хәзер инде төгәлләнеп килә. Берничә купшы, шәмдәй төз манарасын күкләргә чөйгән бу мәһабәт мәчет кремльнең генә түгел, бөтен Казан шәһәренең дә күрке булып ераклардан балкып тора һәм гүяки әче тарих сабакларыннан гыйбрәт алырга чакырып тынсыз гына вәгазь укый. Кремль диварлары эчендә тагын Татарстанның төрле вазифалар башкаручы югары дәүләт

учреждениеләре, министрлыклар, музейлар, җәмгыяте хәйрия фондлары урнашкан күркәм биналар бар. Алар чорлар “кисеше”нең чатында торган корылмалар буларак, үзләре билгән төбәкнең аерылгысыз өлешен тәшкил итә, гомуми мәһабәтлек манзарасына өстәмә камиллек бирә.



**III. Йомгаклау. Казан шәһәре һәм Казан кремленың әһәмияте.**

Минем өчен Казан тарихы зур кызыксыну тудыра.Бер яктан Казан рус шәһәрләре белән охшаш, шул ук вакытта ул үз эченә күп гасырлар дәверендә килгән болгар-татар гореф-гадәтләрен мирас итеп алган.Монда аның тамыры, нигезе сакланган. Шуңа күрә

Казан искитмәле бай тарихлы, көнбатыш Европа шәһәрләренә охшамаган, татар һәм рус мәдәнияты белән бәйләнешен чагылдырган ,үзенчәлекле шәһәр.

Кыскасы, безнең хикәяләвебезнең максаты булган Казан кремле замандашларыбыз күз алдына гаҗәеп истәлекле, бердәм архитектура һәм культура ансамбле булып килеп баса.

**Әдәбият исемлеге:**

1. Ф.Г. Галләмов, Гаяз Исхаки и национальное возрождение татар в начале XX века: Материалы Международной научно-практической конференции. – 2000 - 171 стр.

2. ПСРЛ, XIX, История о Казанском Ханстве, 1903 - 392 стр.

3.Татарстан һәм татар халкы тарихы, 7 сыйныф, Казан татар балалар нәшрияты, 2017.

4. Н. Г. Ханзафаров “Символы Татарстана (мифы и реальность)” Казан, 2001.

5. Габбас Мөхәммәдшинның “Семь ступеней минарета Сююмбики”, Казан, 2003.

6.История Татарстана.Учебное пособие. Казань: ТаРИХ, 2001 – 309 стр.

*Хайруллина Ясмина, 10 нчы сыйныф,*
*Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районының "22 нче Гимназия" муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесе*
*Җитәкчесе: Аменова Эльмира Зуфаровна, туган тел һәм әдәбият укытучылары*

## Кушаматлар аша нәсел тарихы

### Кереш

Минем әтием Мөслим районы Нарат Асты авылыннан, ә әнием шул ук районнан Түбән Табын авылыннан. Без авылга еш кайтабыз, чөнки анда әбиләрем яши. Беркөнне әбиемнең “керпеләр” дип сөйләшүен ишеттем. Һәм мин нинди керпе турында сүз барганын белергә теләдем. Чынлыкта исә “керпе” дигәне кушамат булып чыкты. Мине бу бик кызыксындырды. Моңа кадәр мин кушаматларны үртәү йөзеннән генә бирелә дип уйлый идем. Эзләнү эшемнең барышында кайбер кушаматларны горурланып та йөртүләрен аңладым.

Тикшерү эшебезнең темасы**:**Кушаматлар аша нәсел тарихы.

Тикшерү эшебезнең максаты: авылда һәм тирә-якта булган кушаматларны табу, аларның ни өчен тагылуын ачыклау, нәсел кушаматларын барлау.

Әлеге максатка ирешү өчен, түбәндәге бурычлар куелды:

- кушамат төшенчәсен ачыклау
- авылдагы һәм тирә-яктагы кушаматларны җыю
- материалларны системага салу

Фәнни эзләнү эшенең объекты булып Мөслим районы Түбән Табын,Тугаш, Нарат Асты, Мәллә авылларында булган кушаматлар.

Тикшерү методы: кушаматлар (татар антропонимикасы) буенча фәнни әдәбиятны уку, авылдагы кушаматларны табу, анализлау, системалаштыру.

## Төп өлеш

### 2.1. Кушаматлар турында төшенчә.

Кушамат- кешегә аның үзенчәлекле сыйфатларын яки җәмгыятьтәге урынын ачу максатында җәмгыять яки кешкләр тарафыннан бирелгән официаль булмаган исем. Кушаматны  кешегә кушылган икенче исем дип тә йөртәләр. Ул туу турында таныклыкка да язылмый, аның юридик көче дә юк. Әмма шуңа карамастан, кушаматның кеше тормышына тәэсире турында белмәгән кеше сирәктер.

Исемнән аермалы буларак кушамат аны йөртүченең теләгән сыйфатларын түгел, ә чын сыйфатларын чагылдыра. Шулай ук мыскыл итү булып та тора ала. Кушамат теләсә кайчан, теләсә кайда тагыла ала һәм еш кына бөтен кешегә дә билгеле булмыйча, аерым бер төркем тарафыннан гына кулланыла ала.

Кушамат терминының икенче өлеше борынгы төрки «ат» сүзеннән гыйбарәт булуы да, аның тамырлары тирәндә икәнлекне һәм төп исемгә өстәмә рәвештә элек-электән кулланылуны раслый. Билгеле булганча, иске татар телендә «ат» сүзе «исем» мәгънәсендә йөргән. Борынгы заманнарда кушаматлар фамилия функциясен башкарган, ягъни кеше исеменә өстәлеп, шәхесне тагын да конкретлаштырган.

Кайвакыт кушаматлар рәсми төс алып, исем, фамилия, ата исеме белән бергә дә килергә мөмкин: Пётр Беренче, Бөек Патшабикә һ.б. Кушаматларның шәхси яки группага хас төрләрен аерып карыйлар [ЭССЛТП, 2008: с.146]. Татар теленең аңлатмалы сүзлегендә кушаматка конспирация өчен яки кешеләрдән көлеп, мәзәк өчен бирелгән исем дип аңлатма бирелә [ТТАС, 2005: с.299].

Кушаматлар – кешенең нинди дә булса бер билгесен, характер үзенчәлеген, эш-шөгылен исәпкә алып бирелгән икенче исем. Алар аралашуны, аңлашуны җиңеләйтү, кем турында сүз алып баруны төгәл, ачык әйтү өчен ярдәм итә торган бер антропономик чара.

Кушаматларны өч зур төркемгә бүлеп карыйлар:

1.Нәсел –ыру.

2.Шәхси.

3.Коллектив – территориаль.

Кушаматлар кайчан барлыкка килгәндер, анысы билгесез. Авыл җирендә һәр кешенең диярлек кушаматы бар. Бу бик үк әдәпле булмаса да, кайчакта файдасы да тия. Бигрәк тә авылда бер үк исемдәге кешеләр күп булганда. Аларның күбесе кош-хайван атамасы, кайберләре кеше исемнәрен бозып әйтүдән, кыяфәтенә карап, беришләре ерак бабалардан калгандыр. Кушамат нәселдән нәселгә «койрык» кебек ябышып йөри, ә балалар яңаларын уйлап чыгарып тора. Мәктәп укучылары арасында да кушамат белән эндәшүләр таралган.

Күргәнебезчә, татар телендә кушаматлар күбесенчә күмәклек сүзләрдән ясалалар. Кушамат булып китеп, индивидуаль тамгага әверелгәч, яңа мәгънә алалар һәм үзгә функция башкаралар. Икенче төрле әйткәндә, ялгызлык исемнәргә әвереләләр. Ялгызлык исемнәр һәрвакыт баш хәреф белән язылалар. Димәк, без кушаматларны да баш хәреф белән язарга тиеш булабыз.

Хәзерге вакытта кешегә кушамат белән эндәшү искелек калдыгы булып санала. Бүгенге көндә күп кенә авылларда кешегә кушамат белән бөтенләй эндәшмиләр. Безнең авылда әле кушамат белән эндәшү олылар, яшьләр, мәктәп балалары телендә дә күргәнегезчә чагылыш таба. Кайвакыт исемен бөтенләй әйтмичә, кешегә кушамат белән генә эндәшәләр.

## 2.2. Авыл кушаматлары.

Без кайта торган авыллар бер-берләренә бик якын урнашканнар. Бу Тугаш,Түбән Табын, Югары Табын, Тегермәнлек, Тамьян, Мәллә, Нарат Асты авыллары. Кешеләр берсен-берсе бик яхшы беләләр. Кайбер авылларның үз кушаматлары да бар икән. Мәсәлән Югары Табыннарны - Көртлекләр дип йөртәләр. Чөнки ул авыл урманга якын урнашкан. Тамьян авылын - Китек бадыян, Табын – Исле сабын, бу кушаматлар авыл исемнәре белән рифмалаша. Нарат Асты - Ком чебене ,чөнки бу авылда кара балчык түгел, ә ком. Тугашны – Тугаш буры диләр. Элек Минзәлә өязендә базар булган. Кешеләр шул базарга Тугаш авылы аша барганнар. Бу авыл кешеләре базарга баручыларны, аннан кайтучыларны талый торган булганнар. Куркыныч авыллардан саналган. Мәллә авылын өч өлешкә бүлеп йөртәләр: башкортлар,типтәрләр, казанчылар. Аңа XVI йөз ахыры XVII йөз башында Миас елгасы буеннан (хәзер Чиләбе өлкәсе) башкортларның кара-табын нәселеннән чыгучылар тарафыннан нигез салына. XIX йөзнең 1 нче яртысында типтәрләр, башлыча, Башкортстанның төньяк һәм көнбатыш районнарына башкорт-вотчинниклар арасына килеп урнашалар.Ә казанчылар Иван Грозный вакытында Казаннан куылып килеп урнашкан-нар.Хәзерге көндә алар кушылып бетсә дә авылның бер өлешендә яшәүчеләрне – Типтәрләр, бер өлешендәгеләрне – Башкортлар һәм бер өлешендәгеләрен - Казанчылар

дип йөртәләр. Һәр кайсының аерым зыяратлары да бар. Әйтеп үтәсем килә бу авыл бик үк зур булмаса да анда 4 зыярат.

### 2.3. Шәхси кушаматлар.

Әйткәнемчә авылларда һәр кешенең кушаматы бар. Кайбер кушаматлар шәхси кушаматлар, ә кайберләре нәселдән килгән кушаматлар. Шәхси кушаматларның күбесе кешенең теге яки бу сыйфатын, рухи яки физик билгеләрен турыдан-туры атау юлы белән ясала. Кешенең рухи яки физик сыйфатларын теге яки бу предметка, күренешкә, кош-корт яки хайванга охшату нигезендә барлыкка килгән кушаматлар байтак. Шәхси кушаматлар кешенең һөнәренә, эшләү яки яшәү урынына, милләтенә, титулына, социаль чыгышына, берәр сүзне еш кабатлау яки үзенчә әйтүенә, рәсми исемен бозып әйтүгә мөнәсәбәтле рәвештә дә барлыкка килә. Этнонимнарга нисбәтле кушаматлар кешенең теге яки бу милләт вәкиле булуына яисә әлеге милләт вәкиленә физик яктан охшашлыгына ишарәли.

Бүгенге көндә кулланыла торган шәхси кушаматлар:

Нарат Асты авылында: Шаман, Артист, Чыкый, Апра, Ләпи, Бәлеш.

Түбән Табын авылында: Төлке, Бүре, Куян, Тавык, Кәҗә, Кыргыз.

Тугаш авылында: Шакал, Кырлай, Куян, Күпәш, Скорпион, Әтәч, Чапай, Шүмпел, Шипай, Обман шапка, Бурсык, Кумак, Мәхүп, Кашап, Бүтәк, Башкисәр, Ярпач, Дошман. Тугаш авылында яшьләр күбрәк яши, шунлыктан кушаматлар күбрәк.

Мәллә авылында: Аю, Җомга, Чәли кушаматлары бар. Мәсәлән Чәли кушаматы Рөстәм абыйга бирелгән. Ул кечкенә вакытта әтисенең исемен Чәли дигән Сәел урынына. Мәлләдә яшәүче Рузалия апаның әтисе Рафаэль абыйны Чубр дип йөрткәннә. Чөнки аның эре сипкелләре булган.

### 2.4. Нәселдән килүче кушаматлар.

Борынгы чорларда кушамат нәсел тамгасы, нәсел-ыруг атамасы яки шәхеснең рәсми исеменә өстәмә исем булып йөргән.

Нәселдән килгән кушаматлар арасында өч, дүрт буынга кадәр килүчеләре дә бар. Мин нәселдән килүче кушаматлар белән кызыксындым. Мондый кушаматлар бик күп түгел, ләкин алар бар.

Дүрт буын килә торган кушаматларның берсе Тугаш авылында Бурзайлар нәселе. Мин бу нәсел вәкиле белән очрашып, ни өчен шундый кушамат бирелүен ачыкларга теләдем. Авзалов Хәниф абыйның әтисе Таҗетдин бабай авылда берүзе яшелчә бакчасы тоткан. Һәм бу бакчаны саклау өчен ике бурзай токымлы эт тоткан. Кушамат шул эт токымы белән бәйләнгән. Таҗетдин бабай тирә-якны яшелчә белән тәэмин итеп торган. “Авырсак та сезгә киләбез”, - дип авыл халкы үзенең рәхмәтләрен укыган. Бу кушамат нәселдәге ир балаларга гына тагылып килә икән. Бүгенге көнгә кадәр бу нәсел бакчачылык сәләтен

югалтмаган. Бакчаларында нинди генә яшелчә-җимеш үстермиләр алар! Кушаматны горурланып йөртәләр.

Дүрт буын килүче Югары Табында  Күркә нәселе. Элек авылда өч Нуриәхмәт исемле кеше яшәгән. Аларны узара бутамас өчен кушамат биргәннәр. Юсупова Флүрә апа, хәзерге көндә Нарат Асты авылында яши: “Безнең бабайлар күркә тотканнар, шуннан киләдер” - дип җавап бирде. Флүрә апаның тормыш иптәше Вәзир абыйны Чабак дип йөрткәннәр. Чөнки ул балык тотарга бик яраткан. Чабак ул балыкларның бер төре. Бу кушамат ике буын дәвам итә.

Нарат Асты авылында өч буын дәвам итүче тагын бер кушамат ул- Тимер тырнак кушаматы. Фахрануров Айдар абыйның бабасы Фахранурга бирелгән булган. Шук һәм көчле булганга шулай әйтелгән.

Шулай ук Нарат Астында ике буын дәвам итүче кушамат – Шүкә (щука). Гарипҗан абыйның әтисе Галимҗан бабайга бирелгән булган. Алар да балык тотарга бик ятатканнар. Галимҗан бабай чуртан балыгы тота торган булган. Шуннан бу кушамат калган. Бүгенге көндә Гарипҗан абый да балык тотарга бик яратып йөри.

Тугаш авылында яшәүче Зимфира апаның нәселен Әрләннәр дип йөрткәннәр. Элек Зимфира апаның бабасы көлтә җыйганда коелган башакны авызына тутырып барган. Бәйләгәндә кушып бәйләгән. Шуннан Әрлән кушаматы калган. Кушамат өч буын сакланган.

Түбән Табын авылында Буран Хөппи нәселе булган. Хәзерге көндә бу нәселнең бер кешесе дә авылда тормый, читкә чыгып киткәннәр. Хөппениса апа усаллыгы белән дан тоткан. Урамнан үткәндә бар кешене ачуланып, бураннар уйната торган булган. Кечкенә бала-чагаларны: “Буран Хөппи алып китә”,- дип куркытканнар. Бу кушамат ике буын дәвам иткән.

Түбән Табын авылында ике буын дәвам итүче тагын бер кушамат - Керпе кушаматы Вәҗиев Фәүзәт абыйга бирелгән. Яшь вакытта аның чәче кабарып тора торган булган. Бер көнне эшкә килгәч колхоз рәисе Шайхрамов абый аңа : “Керпе кебек йөрмә, чәчеңне алдыр”, – дигән. Шуннан киткән бу кушамат. Фәүзәт абыйның кызы Гөлназ апаның да улының чәчләре шулай кабарып тора икән. “Шуңа чәчтарашханәгә бик еш йөрибез”, - дип көлде Гөлназ апа.

Мәллә авылында өч буын килүче Кәпкәй кушаматы Вагыйзов Зәкәрия абыйга, аның улы Фирдәвескә һәм Фирдәвес абыйның улы Алмазга бирелгән. Алар кыланып, арттырып сөйләшәләр икән.

Ике буын килүче Пушкин кушаматы хезмәт укытучысы Мәхмүт абыйга һәм аның малайлары Нияз белән Илназ абыйларга бирелгән. Аларны төс-кыяфәте белән А.С.Пушкинга охшатканнар.

Ике буын килүче Гипноз кушаматы Нуретдинов Рамис һәм аның улы Ранис абыйга бирелгән. Чөнки аларның кая барсалар да сүзләре үтә, югалып калмый торган кешеләр.

**III. Йомгаклау**

Мәктәбебезнең 10 нчы сыйныф укучылары кушамат йөртүгә ничек карауларын һәм кемнәрнең кушаматлары булуын ачыклау максатыннан анкета сорауларын тараттым.Алтмыш өч укучы катнашты. Кушамат йөртүгә кырык ике укучы каршы. Унике укучы икеләнеп карый, ә инде тугыз укучыга бу күренеш кызыклы. Утыз укучының кушаматы юк. Утыз өч укучының кушаматы бар, шуларның егерме дүрте исемен үзгәртеп эндәшү.

Әлеге санап киткән кушамат ияләренең кайберләре горурлансалар, кайберләре бик үк шат булмадылар.

Балаларга кеше исемнәрен бозмыйча, әдәби телдә кабул ителгәнчә дөрес әйтергә һәм язарга кирәклекне төшендерергә, кешегә кушамат белән эндәшүнең шәхесне кимсетү икәнлеген яхшылап аңлатырга кирәктер дип уйлыйм.

**IV. Кулланылган әдәбият:**


1. Саттаров Г. Ф. Исемең матур, кемнәр куйган?/ Г. Ф. Саттаров. – Казан: Тат. кит.нәшр., 1989. – 256 б.
2. Саттаров Г.Ф. Татар антропонимикасы / Г.Ф.Саттаров. – Казан: КДУ нәшр., 1990. – 278б.

3. Ә. Әхмәтгалиев. Мөслим төбәге. Тарихи сәхифәләр. “Яр Чаллы типографиясе” дәүләт унитар предприятиесе. 2003 ел.

4. Түбән Табын урта гомуми белем бирү мәктәбенең “Туган якны өйрәнү” музее материаллары.

5. Ганиев Ф. Ә. Татар теленең аңлатмалы сүзлеге / Ф. Ә. Ганиев ред. – Казан: Матбугат йорты., 2005.

6. Энциклопедический словарь-справочник лингвистических терминов и понятий. Русский язык: в 2-х т. / Под общ. ред. Тихонова А.Н., Хашимова Р.И. М.: Флинта: Наука, 2008. 1654 с.

*Хәмидуллина Гөлшат, 9 сыйныф укучысы,*
*Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районының «37 нче күп профильле лицей» муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесе*
*Җитәкчеләре: Усманова Рузилә Рәшит кызы, Хәнәфиева Ләйсән Фәйзехан кызы, туган тел һәм әдәбият укытучылары*

# Бишек җырларының кеше тормышында тоткан урыны

## Кереш

Татар әдәбияты дәресләрендә халык иҗаты әсәрләрен өйрәнгәндә бишек җырлары белән таныштык. Бишек җырларының бик күптән барлыкка килгәнен белдек. Бишек җыры безнең иң беренче ишеткән җырыбыз. Ул баланы өлкәннәр дөньясы белән бәйләүче бик кадерле җеп.

Шуңа да тикшеренү эшемне татар халык авыз иҗатының бик матур жанры – бишек җырлары белән бәйләдем. Бишек җырлары бөтенебез өчен дә кадерле мирас. Гаиләгә шатлык, өмет һәм куанычлар өстәп, бала дөньяга килә. Әлбәттә, куаныч белән бергә, мәшәкатьләр дә өстәлә. Бәбине гел карап, тәрбияләп үстерәсе була. Ул борчыла да, елап та ала. Менә шул чакта әниләребез бишек җырларын көйләп, җырлап йоклаталар, юаталар. Балалар сөйләшә белмәсә дә, шул авазларны тыңлап ята, шулай рәхәтләнеп йоклап китә. Бала сүзләрне отып алып, үзенең дә сүзләрен өстәп көйләп йөргән. Вакытлар үтеп, үзе әти яки әни булгач, таныш көй, таныш сүзләрне искә төшереп, үзенең баласына җырлый. Шуңа да бишек җырлары һәрвакыт **актуаль** булып кала.

Эзләнү эшемнең **максаты:** бишек җырларының үзенчәлекләре турында белергә. Максатыма ирешү өчен берничә бурычны үтәргә кирәк:

1. Бишек җырларын тыңлау, сүзләренең эчтәлеген өйрәнерү.
2. Бишек җырларының кешегә йогынтысын күзәтү.
3. Сүзлекләрдән мәгънәләрен карау.
4. Сораштыру нәтиҗәсендә алынган мәгълүматларны анализлау.

**Эзләнү эшенең предметы**: бишек җырлары.

Эзләнү эшенең **материаллары** булып бишек җырлары, сүзлекләр, интернет-ресурслар, музей экспонатлары тора.

**Эзләнү методлары:** күзәтү, анализлау, сораштыру.

## 1 нче бүлек

### 1.1 Бишек җырлары турында

Татар халык аваз иҗаты әдәби тарихи мирасыбызның гүзәл бер өлешеп тәшкил итә. Анда без ерак гасырлар тавышын ишетәбез. Халык авыз иҗатының барлык төрләре дә кешеләрнең тормыш турындагы уйлануларын, тәҗрибәсен һәм хыял - омтылышларын чагылдыра. Халык авыз иҗатының бер зур рухи йорт дип күз алдына китерсәк, әлеге йортның нигез ташларын бишек җырлары ташкил итә.

Габдулла Тукай: “Җырлар халык күңеленең мәңге тутыкмас көзгесе”, дип әйткән. Иссез, төссез, күзгә күренмәс, кулга тотып булмас булса да, тормышыбызда җырлар бик зур урын алып торалар. Җыр - шигърият һәм музыка чишмәләренең кушылуыннан туа.

Җырларның иң беренче чаткылары меңнәрчә еллар элек яшәгән хатын-кызларның “ә-ә, ә! ә-ә, ә!” дип бала юату, бала иркәләү авазларында ук яңгыраган. Ана теле сабый күңеленә җыр булып иңә; бишек тибрәткәндә дә, аны елавыннан юатканда да ана үзенең сабыена әйтәсе сүзләрен җыр-моңга төреп җиткерә һәм, ни гаҗәп, сабый аларны тыңлый, ишетеп юана, кайвакыт хәтта елавыннан да туктый!.. “Әни” дип теле ачылганчы ук, һәркем әнисенең бишек җырларын ишетә, шулай итеп баланың күңел күзләре ачыла, матурлыкны, моңны таный башлый.

Бишек җыры - яңа туган баланы йоклатканда тирбәтеп җырлана торган җыр. Шуңа да аларның һәркайсыбыз сабый чакның якты истәлеге итеп гомер буе күңел түрендә саклый. Ул җырлар газиз ана, туган ил, туган тел кебек изге төшенчәләр белән бергә йөри. Бишек җырлары ана белән бала икәүдән-икәү генә калган вакытта башкарыла. Ана ул мәлдә күңеле белән баланың рухи дөньясына якынаерга, уй-фикерләрен нәниләр кабул итәрлек гади, самими итеп җиткерергә омтыла.

Һәр халыкның бишек җырларының үз «серләре» бар. Татар, казакъ халыкларының борынгы гореф-гадәтләре буенча һәр сабыйның үзенә багышланган бишек җыры булган, һәм бу җыр гомер буе сабыйны күз тиюдән, проблемалардан, бәла-казалардан, авырулардан саклау хезмәтен үтәгән. Себер халыкларының бишек җырлары аша гаиләнең әхлакый идеаллары бер буыннан икенчесенә тапшырылган. Ненец халкында малайлар һәм кызлар өчен аерым бишек җырлары барлыкка килгән. Кызларга җырланганында «Син минем ярдәмчем» дигән сүзләр булса, малайларга «Киләчәккә син хуҗа һәм болан үрчетүче» дип җырлаганнар. Бөтен халыкларның бишек җырларының төп эчтәлеге - әнинең үз баласына булган мәхәббәте, аның бәхетле киләчәге турында хыяллары.

### 1.2. Бишек җырларын тикшерәбез

Бишек җырларын өйрәнгәндә мин китапларга, интернет-ресурсларга мөрәҗәгать иттем, сыйныфташларым да кызыксынып китеп, миңа бишек җырлары эзләшергә

булышты. Алар бер яки берничә бишек җырлары табып алып килде. Сыйныфташларым алып килгән җырлар арасында халык язган гына түгел, авторлар язган бишек җырлары да очрады.

Мин бишек җырларын тыңладым. Аларның барысында да бер үк охшашлык: тирбәтү ритмы һәм бертөрлерәк тыныч көй бар. “Әлли – бәлли”,”алла-һу”, “чү-чү” кебек аваз ияртемнәре, ымлык сүзләр бишек җырларына салмаклык, тынычлык төсмере бирәләр, еш кабатлана торган “карлыгачым”,”былбылым”, “багалмам” кебек эндәш сүзләр дә аларга үзенчә бер назлылык, ягымлылык, йөрәк җылысы өстиләр. Бишек җырларында чагыштырулар аерым бер үзлеккә ияләр. Аларда бала еш кына халык поэзиясенең традицион образлары – алма, гөл; ә күзләре бөрлегән, карлыган белән чагыштырыла:

Минем кызым дәү кебек,
Бакчадагы гөл кебек.
Ике күзе янып тора,
Кара бөрлегән кебек.
Бигрәк матур, күз тимәсен,
Кемгә охшаган, кем төсле?
Утырадыр бишегендә
Ал чәчкә аткан гөл төсле.

Күпчелек бишек җырларына кош–корт, хайван образлары да килеп керә.

Әлли –бәлли, бәү итәр,
Улым йокыга китәр.
Улым йокыга китмәсә,
Маэмай күтәреп китәр.
Әлли–бәлли, Бәхтияр,
Ызба артында бүре бар ...
... Илнур йокыга китмәсә,
Аюлар алып китәр.

Татар бишек җырларында кош–корт образлары күп очраса да, алар пассив: рус халык иҗатындагы кебек, балага күмәч алырга йөгерүче мәчеләр, баланы юатырга керүче этләр юк. Һәр халык бишек җырларында үзенә генә хас булган җәнлекне сурәтли. Мәсәлән: Һиндстанда сыер изге санала, аны кадерлиләр һәм шуның өчен үзләренең сабыйларына да әлеге исем белән эндәшәләр, русларда – куянкай диләр, чөнки ул йомшак, чукчаларда – минем боланым, французлар – чебешем, ә татарлар былбылым, сандугачым дип сабыйларын йоклата.

Җырдагы теләкләр, аның эчтәлеге төрле–төрле. Татар халкы бишек җырларында ананың баласының киләчәгенә якты өметләре, бәхетле булачагына ышанычлары, сабыеның рухи һәм физик яктан матур, сәламәт, акыллы итеп күрү теләге ята:

Әлли-бәлли итәр бу,
Йокыларга китәр бу,
...
Алма кебек тәгәрәп,
Үсеп буйга җитәр бу,
...
Мәдрәсәгә китәр бу,
...
Галим булып җитәр бу.

### 1.3. Бишек җырларының кешегә йогынтысы турында галимнәр тикшеренүләре

Борынгы бабаларыбыз кеше тәрбиясе бишек җырларыннан башлана дип уйлаганнар. Яңа туган балага олылар дөньясында ялгыз һәм уңайсыз дип ышанганнар.

Безнең көннәрдә бишек җыры җырлаучы әнине еш очратмыйсың. Хәзерге әниләрнең вакыты сәгатьләп язылган, һәм бала катгый расписание буенча яши. Хәзер әниләр баласына бишек җырлары җырласа да бары аны йоклатыр өчен генә башкара. Ә кайчагында бишек җырлары урынына я тынлы музыка куялар, я бала телевизор тавышы астында йоклый. Бүген әниләрнең бик азлары гына үз баласына бишек җырын җырлап йоклата. Аналар бу җырларның бала үсеше өчен әһәмиятен һәм сабые белән аралашу чарасы булуын аңлап бетермиләр.

Белгечләр раславынча, балачакта бишек җыры тыңлап үсмәгән балалар тормышта азрак уңышка ирешәләр һәм еш кына психик авырулардан интегәләр. Психологлар тикшерү үткәргәннәр, алар ике төркем балаларны күзәткәннәр. Беренче төркем балаларына әниләр бишек җырлары җырлаганнар, икенче төркем балаларына тыныч музыка гына кабызганнар. Нәтиҗәсе гаҗәп булган. Беренче төркем балаларының тыныч, тыңлаучан булуы, интеллектуаль яктан тиз үсеш алуы күзәтелгән. Психологлар бу нәтиҗәләрне берничә сәбәп белән аңлаталар. Иң мөһим сәбәп - ана белән бала арасында махсус эмоциональ мөнәсәбәтләр урнашу. Ана бишек җыры аша көне буе тупланган барлык борчылуларны һәм дулкынлануларны юып төшерә, сабыйга игътибарын, назын һәм җылысын бирә. Бала әнисенең интонациясен, тавышының тембрын сизә, бик кадерле һәм яраткан тавыш аңа җылылык һәм куркынычсызлык хисе бирә. Бу тыныч йокы өчен бик мөһим.

Галимнәр фикеренчә, бала өчен халык җырларын җырлау иң яхшысы. Алар халык көйләренең балага иң яхшы йогынты ясавын исбатлаганнар. Галимнәр көнгә 2-3 тапкыр баланы ашатканнан соң бишек җырлары җырларга киңәш итәләр, һәр җырның дәвамлыгы 10 минут тирәсе булырга тиеш.

Моннан тыш, соңгы тикшеренүләр күрсәткәнчә, бишек җырын тыңлап үскән балада телнең фонетик картасы тизрәк формалаша, ул эмоциональ сүзләрне һәм сүзтезмәләрне яхшырак аңлый һәм хәтерендә калдыра, димәк, ул иртәрәк сөйләшә башлый.

Бишек җырларын телевизор тавышлары, компьютер уеннары, поп яки рок-төркем аудиоязмалары белән алыштыру балада игътибар җитмәү синдромы (Синдром дефицита внимания (СДВ) китереп чыгарырга мөмкин. Бу ата-аналар ягыннан балага игътибар җитмәүне күз алдында тота. Илебез психологлары һәм психиатрларының исәпләүләре буенча, әлеге психопатология Россия балаларының 20-25% ында очрый. Игътибар җитмәү синдромы (СДВ) белән авыручы балалар, кагыйдә буларак, нормаль укый алмый. Яшьтәшләре белән аралашуда кыенлыклар туа.

Чыннан да, балага белем һәм тәрбия бирүдә бишек җырлары бик зур роль уйный. Алар сабыйның тыныч халыклы булып үсүенә ярдәм итә. Әнисенең җырлары аша ул туган телендә сүзләр әйтергә, тирә-якны танып белергә, фикерләү сәләтен, сөйләмен үстерергә өйрәнә.

## 2 нче бүлек

### 2.1. “Бишек”сүзенең мәгънәсе

Укучылар арасында сорашулар үткәрдек. Алар арасында *бишек* сүзенең мәгънәсен беркем дә аңлата алмады. Без төрле чыганаклардан карарга булдык. Татар аңлатмалы сүзлегенннән бишек сүзенең аңлатмасын таптык. Бу аңлатма безнең тарихыбызга барып тоташа. Борынгы бабаларыбыз яңа туган сабыйны тирбәтеп йоклату өчен махсус җайланма уйлап тапканнар. Ул “бишек” дип аталган. Нинди генә төрләре булмаган ул бишекнең! Нечкә тал чыбыгыннан үрелгәннәре дә, агачны уеп ясаганнары да, тактада сырлап эшләгәннәре дә. Бишек түшәмгә эленгән. Җылы һава, билгеле булганча, өскә таба күтәрелә һәм сабый бишектә җилдән, төрле салкын һава агымыннан сакланган. Бишеккә җиңелчә тукыма капланган, ул баланы чебен-черкиләрдән генә түгел, борынгы ышанулар буенча, явыз рухлардан да яклаган. Бишекләрдә төрле орнаментлар сурәтләнгән, болар баланы авырулардан һәм күзләр тиюдән саклый дип ышанганнар.

Шушы бишекне тирбәтеп әниләребез, әбиләребез җырлар җырланганнар. Бишекне тирбәткәндә килеп чыккан әлеге җырларны бишек җырлары дип йөртә башланганнар.

### 2.2. Бишекләр кайда саклана?

Сыйныфташларымның бик азы гына бишек күргәне бар икән, чөнки хәзерге вакытта балаларны бишектә тирбәтеп йоклатмыйлар. Бишекләр инде өйләрдә юк диярлек, аларны заманча бишек–колляскалар алыштырды. Хәзер бишекләрне ясамыйлар диярлек, аларны музейларда гына күрергә була. Элекеге бишекләрне күрәсе килү теләге мине музейларга алып килде. Монда тарихны сөйли торган экспонатлар бик күп икән. Музей җитәкчесе безгә бишекне күрсәтте. Бу дүртпочмаклы бишек нәни бала сыярлык кына итеп тал чыбыгыннан ясалган. Дүрт почмагыннан баулар белән эләктереп уртадагы пружинага беркетелгән.





Туганымның баласы тугач, балта остасы булган абыебыз бишек ясап бирде. Аны караватъ янына, өйнең түшәменә калын пружина белән беркеттеләр. Бишек, тирбәтү вакытында, уңга-сулга, аска-өскә, алга-артка салмак, ритмик хәрәкәт ясый. Кечкенә сеңлем шунда изрәп, әнисенең бишек җырын тыңлап, тынычлап йоклый.





**Йомгаклау**

Галимнәр инде күптән ачыклаганнар: балага белем һәм тәрбия бирүдә бишек җырлары бик зур роль уйный. Алар сабыйның тыныч холыклы булып үсүенә ярдәм итә. Әнисенең җырлары аша ул туган телендә сөйләшергә, тирә-якны танып белергә, фикерләү сәләтен, сөйләмен үстерергә өйрәнә.

Безнең халкыбызда бишек җырлары бик борынгыдан барлыкка килгән. Аны әбиләребез, әниләребез, апа - сеңелләребез үзләре уйлап чыгарган. Шул җырлар безгә дә

буыннан буынга күчеп килеп җиткән. Бишек җырлары халык җырлары белән бер үк вакытта барлыкка килгән дип карала. Бу җырлар - бала тормышындагы иң беренче җырлар. Безнең буын балалары бишек җырларын ишеткән бар, ә бишекнең үзен күргән юк, шуның өчен бишек җырлары дип аталуын без белми идек.

Элек-электән борынгы бабаларыбыз яңа туган сабыйны тирбәтеп йоклату өчен махсус җайланма уйлап тапканнар. Ул “бишек” дип аталган. Нинди генә төрләре булмаган ул бишекнең! Нечкә тал чыбыгыннан үрелгәннәре дә, агачны уеп ясаганнары да, тактада сырлап эшләгәннәре дә.

Шушы бишекне тирбәтеп әниләребез, әбиләребез җырлар җырланганнар. Бишекне тирбәткәндә килеп чыккан әлеге җырларны бишек җырлары дип йөртә башланганнар.

Минем бу эзләнү эшем безнең белемебезне арттырды, тарихыбызны күбрәк өйрәнергә булышты. Хәзер без бишек җырларының каян килеп чыкканын беләбез, бүтән сыйныф укучыларына да сөйлибез.

Бишек җырларының текстлары бик матур. Кайберләре бик гади сүзләрдән генә тора, кайберләре әкият, такмак кебек. Бала бишек җырларын тыңлаганда тирә-юньдәге беренче күзаллауларны ала: кошлар, җәнлекләр белән таныша. Иң мөһиме: туган телен ишетә. Бишек җыры тыңлап, тирбәлеп йоклап киткән баланың йокысы тыныч була. Ә тыныч йоклаган бала яхшы кәефле, сәламәт булып үсә.

**Әдәбият исемлеге**


1. Бишек җырлары. “Мәгариф” 1993
2. Татарский детский фольклор / Сост. Р.Ягфаров Казань: “Раннур” нәшр., 1999.-352 с.
3. Татар теленең аңлатмалы сүзлеге \ Ф.Ф. Гаффарова, К.К. Миннибаев, Ф.Ә Ганиев, Г.Г. Саберова. – Казан: “Матбугат йорты” нәшрияты, 2005. – 848 б.
4. Татар теленең мәктәпләр өчен аңлатмалы сүзлеге \ Ф.Ф. Гаффарова, Ф.Ә Ганиев, Г.Г. Саберова. – Казан: Татар. Кит. Нәшр., 2013. – 510 б.
5. Спойте ребенку на ночь: русские народные колыбельные песни // Берегиня. – 2007. - № 1. – С. 64-65

*Ханова Нурзилә, 7 нче сыйныф,*
*Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесе "Сарман гимназиясе"*
*Җитәкчесе: Ханова Нурания Вәзир кызы, татар теле һәм әдәбияты укытучысы*

## «Дару», «Бәхет» ( хикәя)

### Дару

Яз. Язның ни салкын, ни җылы булмаган бер мәле. Кояш көндезләрен җылы нурларын җир өстенә мул итеп сибә дә кичкә таба офык артына кереп югала. Көндезге җылыны кышның салкын карлары үзләренә ала. Кичкә суыта. Апрельнең соңгы көннәре.

Укып ятабыз әле өйдән генә, укып кына түгел, укытып та яталар әле бездә. Таҗлы вирус аркасында инде. Шул бөтенебезне мәктәпләрдән өйләребезгә күчерде, ялан чаклы өйгә көчкә сыешабыз. Мин дүртенче сыйныфта укыйм, ике апам – институтта, әни- әти – укыта. Иртән йокыдан тору, ашау-эчү тәмамлангач, бүлмә ишекләре ябыла, һәрберебез үз почмагында эшкә керешә.

Май бәйрәмнәрендә 11 көн ял бирделәр. 11 көн! Әмма ул көннәр башланганчы бер көнне үткәреп җибәрергә кирәк.

Укытучы биргән шигырьне ятлап, сөйләп,яздырып җибәрергә кирәк бит әле.

Вакыты да билгеле – бик тиз кирәк. Бәйрәм ялларына кадәр сөйләргә! Алайса ял – ял булмаячак. Бер-бер артлы дәресләр бетте, ә шигырьне ятлап кына булмый бит. Укыйм, укыйм – ни башка керми, ни истә калмый. Көндезге ашны ашап, дәресләрне әзерләп бетергәч, елап, китабымны күтәреп әни янына килдем. «Ятлый алмыйм, дим», –күздән энҗе бөртекләре тәгәри, үзем мышкылдыйм. Әни:

– Ятлар өчен нишләдең, кызым? – ди.

– Укыдым инде, тагын нишләп була? – дип тел озынайтам.

– Нишләсәң дә ятлыйсың, кызым! Ятлый алмасаң да!

Бераз мышкылдап басып тордым. Минем хәлгә кечкенә апам керде. Бергә ятларга дип, бүлмәсенә алып кереп китте. Ятлыйбыз, инде өйрәнеп беттем дигәндә генә онытам да җибәрәм. Апамның сабырлыгы бетте, мине җитәкләп, китабымны күтәреп, әни янына чыгарып бастырды.

– Бу бала ярты сүзен дә аңламый бит! – дип әйтте дә бүлмәсенә кереп югалды. Әни:

– Бүген һава суламадың , өйдә ятлап булмаса, ишегалдында ятлап кара әле,  – диде. Киендем дә китабымны күтәреп ишегалдына чыктым. Салкын, әмма туңарга вакыт юк. Ятлыйм. Әни дә минем тирәдә һава сулап йөри. Әнинең кырына барып, сырпаланып, ятлап бетерүемне әйттем дә өйгә кереп киттем. Ятладым. Хәзер сөйләтеп караячаклар. Киенеп куйдым, апам видеога яздырачак. Әнинең эше җитәрлек. Тавык та чүпләп бетерерлек түгел.

Менә башланды хәлләр! Апам мине тагын әни янына китереп куйды.Үзе мине җәлли, мин дә үземне кызганам. Бик әйбәт кенә сөйләгән җирдән, сүзләр онытыла. Хәзер шигырьне әни, әти, апам, мин ятлыйбыз. И сәнгатьле итеп, күңел биреп сөйлим… тагын ялгышам! «Сугылып-сугылып тибә йөрәге…»

– Сулыгып-сулыгып! –ди әни.

Тагын бер сүз онытыла. Аннан тагын берәү…

–Гаҗиз? Зарыктырды? Савыгуын?

Гаилә белән аңлаталар. Инде «авыру» сүзен «чирли» дидем. Тагын яңадан сөйлим. Ятлый-ятлый гаҗиз булдым. Иртәгә бу шигырьне бик яхшы сөйләячәкмен, ә бүген, бүген сөйли алмыйм. Әни башын тотып утыра, әти сүзләрне аңлата, апам хаталарымны төзәтә, олы апам гына: «И-и-и аны», –дип мине ярата, әби генә бер сүз дә дәшми. Ул бит 86 яшендә дә мәктәптә ятлаган шигырьләрен яттан сөйли. Русча да, татарча да, немесчә дә. Мин дә сөйләячәкмен, әмма бүген түгел. Иртәгә мин аны менә дигән беләчәкмен… Аптырагач, әни 5 строфалы шигырьне аерым-аерым ятлатып яздырырга дигән фикергә килде.

Строфалап ятлыйбыз, яздырабыз. Безгә бит «2» ле кирәкми, укытучы да куймый аны. Әйткәнне эшләргә кирәк! Тырышабыз. Яздырдык, җибәрдек. «5» лене алдык.

– Эшләр болай барса, уку шушылай өйдән генә булса, барыбызга да дару кирәк булачак,  – диде әни.

Иртән йокыдан торгач, бернинди хатасыз Муса Җәлилнең «Дару» шигырен яттан сөйләдем. Хәер, аны апам да, әнием дә, әтием дә сөйли белә иде инде. Күңелле булды, ә кичә бер дә күңелле түгел иде.

Калган эшкә кар ява, диләр. Әле ярый кичә ятлап сөйләдек. Бик матур шигырь бит. Күпме яңа сүз өйрәндем?! Кызның сугыш бетеп, әтисе кайткач терелүенә сөендем. Тиздән Бөек Җиңү бәйрәме җитәчәк, шул уңайдан шигырь дә ятлап куйдым. Тырыштым инде. Тырышкан табар,ташка кадак кагар, диләр бит. Тыныч тормышта шигырь генә ятлау әллә түгел!

**Бәхет**

Бик яратам мин җәйне, бик яратам. Җәй җитүгә, каникуллар башлануга, авылга әбигә кунакка кайтам. Кунак дип әйтү бик үк дөрес тә булмас. Кунак 3 көн генә була ул, ди, әбием, ә мин өч айга кайтам бит. Авылда мина бик рәхәт. Башта чишмәләрне йөреп

чыгабыз, челтерәп аккан салкын суны авыз итүгә, көч кереп китә, сусын басыла, җәйге челлә дә онытыла. Тау итәгеннән агып чыккан Урман чишмәсенең суы бигрәк тәмле, Әче чишмәсенең суы баш авытуыннан файдалы, ди, әбекәй.

– Их, бигрәк рәхәт авылда! Мин авылда яшәр идем, авылда бу кадәр рәхәт икәнен әти-әни генә белми! Әллә нишләп шәһәрдә яшәп ятабыз. Мин авылда яшәр идем, – дим әбигә. Минем сүзләр әбиемнең йөрәгенә сары май булып ята, сизәм бит, әби сиздермәскә тырышса да, сизәм. Мин бит әбием кызы, аңа ошаталар, Сорур апа оныгы дип маңгаема язылган бугай.

–Балакаем, берүк әти-әниең янында яшә, минем янымда кунак булуың да бик җитә, ди, үзе, елмаеп, башымнан сыйпый. Әбиемнең бердәнбер кыз оныгы бит мин. Бик ярата ул мине, мин дә аны яратам.

Эт-мәче халкын бик яратсам да әллә нишләп куркам мин алардан. Куркам дисәм дә бик ук дөрес түгел инде. Минем яныма килмәсәләр исем китми. Күз белән яратам, әмма якынрак килсәләр – котым оча. Ә менә күрше кызы Ләлә бик ярата, бик нык ярата, чынлыклап ярата, куркуның нәрсә икәнен дә белми. Ул янымда булганда, бер песи дә, эт тә миңа куркыныч түгел. Бүген дә минем кайтканны ишетеп, иртән иртүк кереп тә җиткән. Безнең очның кызлары җыелып бергә уйныйбыз. Күршебез Зәйнәп апаның песие балалаган икән, шуны карарга кердек. Нәни, йомшак песи балаларын күрүгә, Ләлә нишләргә белми. Ә песи балалары – бишәү. Узләре матур, төрле төстә. Берсе – ап-ак, маңгаенда кара тап бар. Монысы – Аква, берсе куе сарыга буй-буй кара сызыклысы – Юлбарыс, сарысы – Алтын, чем карасы – Бәрхет, ә өч төслесе – Бәхет. Исемнәр табылды, хуҗалар табыласы гына калды. Бу песи балалары Зәйнәп апага кирәк түгел икән.

– Болай да ишегалды тулы мәче, шушылар гына җитми безгә! Кемгә кирәк, алыгыз, – диде дә сарайга кереп китте. Нишләргә?! Мин әбиемдә кунак кына, песи күтәреп кайта алмыйм бит инде. Күтәрү түгел, кулыма да ала алмыйм. Миннән песи карау булмый, кызыгам да үзем, әмма куркам бит мин аннан. Галиянең өендә өч песи, Әминәләрдә – икәү, Алсуларда – берәү, ә Ләләнеке – бишәү. Бөтенебезгә дә песи балалары ошый, әмма ошаган бөтен әйберне өйгә алып кайтмыйлар бит. Торабыз шулай песи балаларына сокланып. Шундый матурлар, кечкенә йомгаклар, бигрәк нәниләр, ә шулай да безгә кирәкмиләр. Ләлә түзмәде, барлык песи балаларын кочагына алды.

– Нишлисең син, Ләлә? Сездә болай да песиләр җитәрлек бит. Әниең, әбиең нәрсә дияр?

– Нәрсә дигәннәрен әйтермен,яме, - диде. Без Ләләләргә юнәлдек.

Бәхетебездән эти-әнисе эштә иде. Безне Камал әби каршы алды, Ләләнең кулындагы песи балаларын күрүгә,  таягы төшеп тә китте. Мин тиз генә әбигә таягын бирдем, егылып китмәсен өчен, аны тотып тора башладым.

– Шушылар гына җитми иде. Тагын берәр песи балаламадымы икән, барыгыз, бөтен авылны әйләнеп чыгыгыз, - диде. – Анаң кайткач була икән әле монда Сафура бураннары. Чарасызлыктан кул селтәде дә алмагач төбендәге эскәмиягә барып утырды. Без өйгә кереп, песи балаларын җылы, йомшак урынга урнаштырдык та авыл буйлап сәяхәткә чыгарга булдык. Исәп – тагын берничә песи баласына ярдәм итү.

– Әбекәй, безне югалтма,яме. Без песи балалары эзләргә киттек,  –дидек тә ашыгып , югары очка юнәлдек. Рәхәт, тагын нинди песи балалары очрар икән? Авылны аркылыга-буйга йөреп чыктык, бер карамаган җир, сорамаган кеше калмады. Тапмадык. Инде буш кул белән Ләләләргә кайттык. Песи балалары белән минем дә уйныйсы килә башлады. Камал әби бакчада нидер эшләп йөри, безне күрми калды. Өйгә керсәк – песи балаларыннан җилләр искән. Күрсәгез Ләләне, ул бик кызганыч хәлдә, ни еламый, ни көлми. Сөйләшә дә алмый. Песи баласы өчен кайгырган кешене беренче тапкыр күргән шәһәр баласы бит мин. Ләлә атылып бакчага чыкты, күзләреннән тамчылар тама, көчкә сөйләшә.

– Әби, әби дим, песи балалары кая? – ди Ләлә.

– Кызым, әниең төшке ашка кайткан иде. «Песи балаларын эзләп тә тормасын, таба да алмый тапса ала да алмый», – дип әйтергә кушты.

– Кайда булырга мөмкин икән песи балалары? – дип сорады Ләлә. – Төшке аш вакыты – бер генә сәгать  бит, димәк, әнисе аларны әллә кая куя алмый. Ихатадан эзләргә кирәклекне бик тиз аңладылар.Менә бөтен җирне бетереп, песи балаларын эзлибез. Ардык, талдык – песи балаларын тапмадык. Ындыр артына чыгып, инешкә юнәлдек. Кайдандыр песи тавышы килде, ул шундый матур итеп, йомшак итеп, тәмле итеп мияулый. Тавыш килгән якка юнәлдек. Бакча артында бик куе кычытканлык бар. Тавыш шул яктан килә иде. Песи балалары, ара- тирә ярдәм сорагандай тавыш бирәләр. Бу кычытканлык бик куркыныч иде. Анда алар бик-биек булып үскәннәр.Ләлә, озак уйлап тормады, мүкәләп, кычытканлыкка кереп тә китте. Үзе елый. Күз яшьләренең шатлыктанмы, кайгыданмы икәнен белерлек тә түгел. Әллә песи балалары табылудан, әллә бичараларның кычыткан арасында адашуларыннан? Песи балаларын берәмләп табып алдык. Кычыткан арасына үрмәләп кергәнебезне сизми дә калдык. Мин өч төслесен абып алып чыктым. Бер дә куркыныч түгел икән ул. Җып-җылы, йоп-йомшак Бәхет. Инде аларны өйгә алып керергә ярамаганлыгы барыбызга да көн кебек ачык иде. Сарай эчендә менә дигән итеп урын ясап, песи балаларын урнаштырдык. Кычыткан чагудан чабырып чыккан кулларыбызны, аякларыбызны кашый –кашый, бик бәхетле гөрләшәбез. Рәхәт, бик рәхәт авылда!.

– Таптым, кычытканнан курыкмыйча кереп алдык. Үскәч мин песиләр өчен яшәү урыны төзетәчәкмен, авылда яшәячәкмен. Песи балалары ташландык булмаслар, караулы булырлар, – диде ул. Аңа карап без сөендек. Ашау да онытылган. Һаман кайтмагач, әбекәем мине эзләп, Ләләләргә кергәндә, без инде Өйле уйнап ята идек. Бәхет кушаматлысын кулымда тотып торганымны күргәч, әбекәй аптырады.

–Менә бәхет – син дә песидән курыкмыйсың икән бит. Авылда яшәсәң, эт-мәчедән куркып торып булмый ул, – ди әбекәй. Минем әбигә баштан үткәннәрне сөйләп ятканда, кете-кете көлеп, Камал әби дә килеп җитте. Безне күзәтеп торган икән ул.

– Балакайлар, эт-мәче халкы шулай тугач ук тормышка яраклаша башлый. Җәнлекләр, хайваннар дөньясының үз кануннары бар. Әнә, карлыган куагы янында керпе йөри. Керпеләрне әниләре бер ай гына карый, аннан үз көннәрен үзләре күрәләр. Куяннар балаларын тугач та ташлап калдыра. Әле үсә төшегез, күбрәк укыгыз, тәҗрибә туплагыз, Җир- Анабызга ярдәмчеләр бик кирәк. Мәрхәмәтле булыгыз, – дип барыбызны да коймак белән чәй эчәргә чакырды.

Рәхәт авылда, бик рәхәт!

*Хәсәнҗанов Шамил, 8 нче сыйныф,*
*Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районның “14нче лицей” муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесе*
*Җитәкчесе: Мифтахова Эльмира Флүр кызы,*
*Насыйрова Миләүшә Сәлмән кызы,*
*туган тел һәм әдәбияты укытучылары*

## Вакыт елгасы

### I. Кереш

Календарь, календарь,
Ел буе син патшабыз,
Көннәрне син саныйсың,
Бәйрәмнәр китерәсең.
Без һич тә яши алмабыз

Синнән башка, календарь,
Шуңадыр син иң кирәкле,
Алыштыргысыз бүләктер.

Моннан күп гасырлар элек үк календарь кешеләр өчен бик мөһим предмет булган. Календарьлар укучыларны аерым елларда билгеләнеп үтүче бик мөһим вакыйгалар һәм даталар белән таныштыралар. Һәрдаим басылып чыккан календарьлар цифрлы белешмәләр, данлыклы һәм истәлекле даталарга кагылышлы олы тарихи вакыйгалар, үткәндәге һәм хәзерге танылган шәхесләрнең биографияләре белән бәйле башка күп кенә мәгълүматларны үз эченә ала. Календарь – ул вакытны санау ысулы. Латинча «калере» сүзе игълан итүне белдерә.

Димәк, календарь - елның барлык көннәре исемлеге һәм белешмә мәгълүматләр туплаган вакытлы матбугат басмасы. Календарь көндәлек, атналык, айлык, еллык итеп төзелә. Календарьлар күп төрле: стена календаре, татарча битле календарьлар, мөселман календаре, балалар календаре, бакча календаре һ.б.

Мин, яшь, матур, яшеллеккә төрелгән шәһәрдә, Түбән Камада яшим. Шәһәрем көннән-көн матурлана, яңа парклар, ял итү почмаклары, музей һәм китапханәләр ачыла. Бүген Түбән Кама - матур, яшел, уңайлы шәһәр булу белән бергә дөньякүләм танылган эре сәнәгать үзәге дә. Һәр предприятие елда үзенең өстәл календарен бастырып чыгара. Бу реклама максатыннан эшләнәдер, бәлки.

Ә нишләп соң шәһәремнең истәлекле, яңа урыннары турында мәгълүмат биреп торырлык өстәл календарьлары юк. Бу бит Түбән Кама шәһәре турында мәгълүмат тарату өчен яхшы ысул да булып торыр иде. Шунлыктан, эшем **актуаль** булыр дип уйлыйм.

Эшнең башлар өчен календарьлар турында, Түбән Кама турында мәгълүмат туплау, булдыру максаты белән, Х.Ш.Мәхмүтовның “Ел тәүлеге – 12 ай”, шәһәребезнең 50 еллыгы уңаеннан чыгырылган “Нижнекамск. История в 50 лет” китапларына мөрәҗагать иттем.

**Эшемнең максаты**: Түбән Кама шәһәренең истәлекле, төзекләндерелгән, яңа ачылган урыннары турында мәгълүмати өстәл календаре булдыру.

Эшемнең максатына ирешү өчен, түбәндәге **бурыч**ларны билгеләдем:

- Календарьларның килеп чыгыш тарихын өйрәнү;
- Түбән Кама шәһәренең истәлекле урыннары буенча мәгълүмат туплау;
- бу урыннар буенча матур фотолар барлау;
- өстәл календаре булдыру.

**Өйрәнү объекты**: өстәл календарьлары, **предметы:** Түбән Кама шәһәренең истәлекле урыннары.

Фәнни эшемнең **фәнни методлары**. Фәнни эш тасвирлау, анализлау, күзәтү **алымнары**на нигезләнеп башкарылды. Тасвирлау методы анкета сорауларының, аларның функциясен күрсәтүгә юнәлтелгән. Анализлау методы исә төрле фикерләрне тикшергәндә кирәк. Күзәтү методы газета-журналларда басылып чыккан мәгълүматләрне карап чыгу, шәһәребез урамнарына күзәтү ясау, бәя бирүгә юнәлгән.

## II. Төп өлеш

### 1. Календарьларның килеп чыгыш тарихы

"Һәр нәрсәнең вакыты бар", "Вакытлы эш вакытында яхшы", "Бүгенге эшне иртәгә калдырма", "Вакытның кыйммәте алтыннан артык", "Вакыт акча түгел, югалтсаң таба алмассың", "Җәүһәрне сатып алып була, вакытны сатып алып булмый" кебек мәкальләрдә вакытның кадерен белүгә, һәр эшне үз вакытында эшләү кирәклегенә басым ясала. Бу хакыйкать турыдан-туры тормышның үзеннән, хуҗалык-көнкүреш таләпләреннән килеп чыга. Чыннан да, бик борынгыдан ук килә торган кайсы гына кәсеп-шөгыльне алма: ашарга яраклы үләннәр, җиләк-җимешләр җыюмы, балык тоту һәм җәнлек аулаумы, терлек асрау яисә иген игүме – боларның һәркайсы уңышлы чыксын өчен, аларны башкаруның иң кулай срокларын сайлый белү хәлиткеч әһәмияткә ия. Шуңа күрә дә кешеләр элек-электән вакытның төгәл исәбен алып барырга, елларның һәм ел фасылларының, аерым айларның һәм хәтта көннәрнең ничек киләсен, аларда һава торышының, сунарчылык, терлекчелек, игенчелек өчен шартларның нинди буласын, шуңа бәйле рәвештә үзләре өчен нинди уңыш-шатлыклар яки бәла-казалар көтеләсен алдан ук белеп-чамалап торырга, тиешле чарасын-хәсрәтен күрергә омтылганнар. Шушы максатларда халык, табигать дөньсын күп гасырлар буенча күзәтеп, үзләштереп килү тәҗрибәсенә таянып һәм, әлбәттә, шактый гына хыял-фараз да катнаштырып, төрле календарьлар төзегән, юрау-сынамышлар, йола-ритуаллар иҗат иткән.

Календарьлар төзергә өйрәнү кешелек акылы яулаган мөһим мәдәни казанышларның берсе булып тора. Аның әһәмиятен, мәсәлән, язу уйлап табу белән тиңләп карарга мөмкин. Иң беренче календарьлар әле ерак бронза гасырында ук барлыкка килгәннәр. Моны яңадан-яңа фактлар раслый тора. Мәсәлән, күптән түгел генә вакытлы матбугатта Болгария археологы Стефан Чохаджаевның балчыктан ясалган һәм формасы белән хәзерге үтүккә охшый төшкән бер календарь табуы хакында хәбәрләр булды. Төрле сызыклар һәм билгеләр ярдәмендә 12 айны һәм 360 көнне күрсәтә торган бу календарьның яше 7000 ел чамасы дип исәпләнелә.

Календарьларның нигезен күк җисемнәренең хәрәкәтенә бәйле астрономик күренешләр: көн белән төн алмашыну, ай фазаларның үзгәреп торуы, ел фасылларының чиратлашуы тәшкил итә. Шушы җирлектә төрле дәверләрдә һәм төрле халыкларда

дистәләрчә календарьлар туган. Татар халкы да үзенең күп гасырлык тормыш-көнкүрешендә берничә төр календарьдан киң файдалган. Хронологик тәртиптә алганда, алар түбәндәгеләр:

1. Унике еллык хайван циклы.
2. Исламга кадәрге (мәҗүси) Ай-Кояш календаре.
3. Гарәп Ай һиҗриясе (Камәрия – Айга бәйләнешле).
4. Фарсы Кояш һиҗриясе (Шәмсия – Кояшка бәйләнешле).
5. Христиан (румия) календаре.

Һәр елы аерым хайван исеме белән аталган 12 еллык календарь Көнчыгыш һәм Көньяк-Көнчыгыш Азия халыкларында әле безнең эрага кадәр күп элек барлыкка килә. Ул Юпитер планетасы хәрәкәтенең астрономик циклларына нигезләнгән. Юпитер 12 (төгәлрәге 11, 862) елда Кояш тирәли тулы әйләнеш ясый. Календарь төзү өчен, менә шушы хәрәкәт түгәрәген 12 тигез өлешкә бүлеп, унике ел хасил иткәннәр һәм аларның һәркайсын бер хайван исеме белән атаганнар.

Бу календарьларның килеп чыгышы турында японнарда бер легенда да бар. Имештер, Будда дөньядагы барлык хайваннарны үзенә Яңа ел бәйрәменә чакырган, аларга бүләкләр вәгъдә иткән. Әмма мәҗлескә 12 генә хайван килгән. Будда сүзендә торган: аларның һәрбесенә берәр ел һәм берәр йолдызлык бүләк иткән. Шуннан бирле еллар Тычкан, Сыер (Үгез), Юлбарыс, Куян, Аждаһа, Елан, Елкы (Ат), Сарык, Маймыл, Тавык, Эт, Дуңгыз (Кабан) исемнәре белән атала башлаганнар...

Күп кенә язма чыганаклардан күренгәнчә, 12 еллык хйван календарен төрки халыклар да бик күптәннән куллана башлаганнар. Төрки каганлыгының атаклы каһарманы Күлтәгин каберенә 732 елда куелган Зур ташъязмада аның Сарык елында, тугызынчы айда, унҗиденче көндә үлүе, егерме җиденче көндә күмелүе, Бишин (Маймыл) елының җиденче аенда, егерме җиденче көнендә аның каберен хөрмәтләү турында хәбәр ителә. Хайван календарена караган шактый кызыклы мәгълүматлар XI йөзнең күренекле галиме Мәхмүт Кашгариның “Диване лөгат эт-төрек” (“Төрки телләр җыйналмасы”) сүзлегендә дә теркәлеп калган. “Төркиләр бу елларның һәркайсында бер хикмәт бар дип уйлыйлар. Мәсәлән, аларча Сыер елы керсә, сугыш күп була, чөнки сыер сөзешергә ярата торган хайван. Тавык елы керсә, азык-төлек күбәя, ләкин адәмнәрдә тәшвиш арта. Чөнки тавыкның ризыгы ашлык бөртеге булып, аны табып ашау өчен ул әйберләрне туздырып йөри. Крокодил елы керсә, явым-төшем һәм уңыш мул була, чөнки ул суда яши. Дуңгыз елы керсә, салкын, кар һәм фетнә күп була. Шул рәвешле һәр елга бер юрау кылалар”, - ди ул.

Унике еллык цикл борынгы болгарларга да яхшы таныш булган. Дөрес, Идел буе Болгар дәүләтендә исламга кадәрге календарьлар системасы хакында мәгълүматлар бик аз.

Ләкин монда кайбер өстәмә чыганаклар мәсьәләгә ачыклык кертүгә ярдәм итә. Мәгълүм булганча, VI – VII гасырларда Азов буе болгарлары “Бөек Болгар” союзы исеме белән билгеле булган беренче дәүләт берләшмәсе барлыкка китерәләр. Бу дәүләт таралгач, VII йөзнең икенче яртысында болгар кабиләләренең бер өлеше Дунай буйларына китә, анда соңга табарак славян кабиләләре белән бергәләп Дунай болгарлары дәүләтен төзи, ә икенче төркем Идел буйлап Кама тамагына килә һәм монда VIII гасырда Иделнең урта агымы яр буйларындагы районнарга урнаша.

Димәк, Дунай болгарларының борынгы телен һәм мәдәниятен гәүдәләндергән тарихи ядкарьләр буенча Идел буе болгарлары хакында да фараз кылырга җитәрлек нигез бар. Атап әйткәндә, бу календарьлар системасына да кагыла.

Татар халык календаре тарихын өйрәнүгә зур өлеш керткән В.М.Беркутов, күп кенә фәнни чыганакларга таянып, хайван циклы буенча ел исәпләүнең борынгы болгарлардан Дунай болгарларына да күчеп калуы һәм актив кулланылган булуы хакында яза. Циклдагы ун елның атамасы хәтта хәзерге заман болгар телендә дә сакланып калган. Менә алар: Сомор (?) (беренче ел исеме), Шегор (Сыер, Үгез – икенче ел), Вере (Бөри-Бүре – өченче ел, Барс елы урынына), Давшан (Тавышкан, Куян – дүртенче ел), Дилан (Елан – алтынчы ел), Морен (монголча Морин, Ат – җиденче ел), Кучи (Кучы, Кучкар, Сарык – сигезенче ел), Тохтол (Тоох, Тавык – унынчы ел), Этк (Эт – унберенче ел), Дохс (Тоңуз, Дуңгыз – уникенче ел).

Алтын Урда, Казан ханлыгы чорларның рәсми документларында, әдәбият әсәрләрендә даталарның еш кына 12 еллык цикл буенча да күрсәтелүе, археологик табылдыкларда (металл акчаларда, көзге һ.б.ш. көнкүреш әйберләрендә) хайван календаре символикасының чагылуы: аларга арыслан, аждаһа, сарык, әтәч, эт сурәтләре төшерелгән булуы – болар шулай ук әлеге календарьның Идел буйларында озак заманнар кулланышта йөргәнлеген раслыйлар.

1700 елда Петр I нең христиан ел исәбен кертүе һәм бу вакытта татар халкы кулланган календарьлар турында сөйләгәндә, мәшһүр тарихчыбыз Ш.Мәрҗани болай дип яза: “Ул заманнарда Казан мөселманнары унике хайванга бәйле төрки тарихын да белгәннәр һәм кулланганнар”.

Алда өйтеп үтелгәнчә, унике еллык хайван циклы белән янәшә татар халкы тагын дүрт төрле календарьдан файдалана. Болар – Кояш календарьлары, Ай календарьлары һәм Ай-Кояш календарьлары.

Килеп чыгышы ягыннан Кояш календаре бик борынгылардан санала. Мисырда, мәсәлән, ул безнең эрага кадәр өч мең ел элек кулланыла башлаган. Бу календарь буенча ел 12 айдан һәм 365 көннән торган. Әмма һәр айда 30ар гына көн булган. Артып калган биш

көн, бәйрәм көннәре рәвешендә, елның азагына кертелә барган. Грек тарихчысы Платон китергән бер легенда буенча, Мисыр алласы Тот, Ай алиһәсе белән шашка уйнап, алардан биш көн вакыт отып алган. Нәкъ менә шушы көннәрне ул, имештер, календарьга өстәмә итеп керткән.

Кояш календарьларының иң билгелеләреннән берсе – Юлий (Юлиан) календаре. Безнең эрага кадәр 46 елда Юлий Цезарь кушуы буенча борынгы Рим календарена реформа үткәрелә. Юлий календаре дип аталган бу яңа календарь безнең эрага кадәрге 45 елның беренче январеннан гамәлгә керә. Ел башы итеп 1 январь көне алына. Ә аңа кадәр римлыларда яңа ел 1 марттан башлана торган була.

Юлий календаре буенча елның озынлыгы 365 тәүлек һәм 6 сәгать дип исәпләнә. Уңайлылык өчен анда өч ел 365 әр, ә дүртенче (кәсибә) ел 366 көнле итеп алына. Ел 12 айга бүленеп, тәртип саннары так булган айлар 31 әр, ә тәртип саннары җөп булган айлар 30 ар көннән тора. Кәсибә елның феврале генә 29 көнле була. Цезарь айларның исемнәрен үзгәртми (январь, февраль, март, апрель, май, июнь, квинтилис, секстилис, сентябрь, октябрь, ноябрь, декабрь). Ләкин бер елдан соң сенат карары белән квинтилис ае Юлий Цезарь хөрмәтенә “июль” дип йөртелә башлый. Ә безнең эрага кадәр 8 елда, Рим императоры Октавиан Августка хөрмәт күрсәтү йөзеннән, секстилис аеның исеме “август”ка үзгәртелә. Шул ук вакытта озын һәм кыска айларның чиратлашу тәртибенә дә үзгәреш кертелә: февральдән бер көнне кыскарту хисабына август 31 көнлегә әверелә, ә сентябрьнең бер көне – октябрьгә, ноябрьнең бер көне декабрьгә күчерелә. Яңа эраның 325 елында Юлий календаре христиан чиркәве тарафыннан кабул ителә.

Кояш календарьлары белән беррәттән, татар халкының тормышында Ай календаре да күп гасырлар буена гаять әһәмиятле урын алып тора.

Ай календаре буенча бер ел шулай ук 12 айны эченә ала. Айның озынлыгы бер яңа Ай туганнан икенче яңа Ай туганга кадәрге вакыт арасы тәшкил итә. Ул 29 тәүлек 12 сәгать 44 минут 3 секундка тигез. Ләкин исәпләүдә уңайлылык өчен бу сан түгәрәкләнеп алына: тәртип саннары так булган айлары – 30 ар, тәртип саннары җөп булганнары 29 ар тәүлекле итеп санала. Шул рәвешчә, гади ай елында 354 була.

Ай календареның мәҗбүри бер таләбе шул: анда яңа елның беренче ае һәрвакытта яңа Ай туудан башланырга тиеш. Моңа ирешү өчен аерым елларда соңгы айга бер тәүлек өстиләр һәм мондый (кәсибә) ел 355 тәүлек тәшкил итә.

Ай календаренда гади һәм кәсибә елларның чиратлашуы Кояш календарендагыдан аерылып тора. Бу 30 еллык цикллар эчендә эшләнә: һәр циклның 2, 5, 7, 10, 13, 16, 18, 21, 24, 26, 29 нчы еллары, ягъни унбер елы кәсибә еллар, ә калган унтугыз елы гади еллар була.

Ай елын еш кына “Камәрия елы”, “Гарәп елы”, “Һиҗри елы” дип атыйлар. Чөнки бу календарь элек-электән үк гарәп илләрендә аеруча киң таралган. Гомәр хәлифә вакытында (637 – 639 еллар арасы) һиҗри ел исәбе рәсми мөселман календаре буларак кабул ителә.

Ай-Кояш календаре җирле климат шартларына, хуҗалык итү үзенчәлекләренә җайлаштырылган була. Бу календарьдагы ай исемнәре дә, табигый ки, әнә шул үзенчәлекләрне ачык чагылдырып торганнар.

**2. Өстәл календарьларының килеп чыгышы**

Каюм Насыйри башка өлкәдәге хезмәтләре белән беррәттән календарьлар төзүдә, аларда материаллар туплау, төрле темаларга язу буенча үзеннән соң киләчәк буыннарга зур мирас калдырган шәхес. К. Насыйри халыкка сабак бирүнең, белем-мәгърифәт таратуның бер ысулын таба. Ул да булса – еллык өстәл календаре чыгару. Календарь ярым журнал характерында була һәм “Казан календаре” дип атала. Каюм Насыйри бу календарьларны үз исәбенә елга бер тапкыр чыгара. Аның беренче саны 1871, ә соңгысы 1897 елда дөнья күрә.Ул календарьларын 24 ел буе чыгара. Шушы еллар эчендә календарьлар 1886, 1887 һәм 1895 нче елларда гына чыкмый кала. Календарьларның уртача күләме 40-70 бит тирәсе була.

Каюм Насыйри календарьлары төрле характердагы материалларга гаять бай була. Аның календарьларында ел саен кабатлана торган гади календарь материалларыннан тыш төрле темаларга караган фәнни һәм әдәби мәкаләләр урнаштырыла. Календарьлар шул ук вакытта ул чорда белешмә бирү өчен дә кирәк булган. Каюм Насыйри да үзенең календарьларында Казанда ничә почта бүлекчәсе хезмәт күрсәткәнлеген һәм аларның эш сәгатьләрен, нинди хатлар кабул итүен һәм аларга нинди маркалар ябыштырырга кирәклеген, аларның бәясе күпме булганлыгына кадәр язып чыккан. Димәк, аның календарьлары белешмә бирү ролен дә үтәгән.

**3. Түбән Каманың истәлекле урыннары буенча өстәл календары булдыру**

Түбән Кама турында белешмә бирү ролен үтәүче календарь төзү максаты белән, шәһәребезнең истәлекле урыннарын үзләштерә башладым. Календарь өчен мәгълүматны туплауны түбәндәгечә алып бардым:

1. Яшьтәшләрем, укытучылар, әти-әниләр фикерен тупладым.
2. Шул фикерләргә таянып, 12 урын билгеләнде.

- Гыйнвар ае – шәһәр турында кыскача мәгълүмат: Түбән Кама - Россиядә нефть химиясе сәнәгате үзәкләренең иң эресе. Өч тапкыр «Русиянең иң төзек шәһәре» конкурсында җиңүче була, 2002 елда «Идел буеның мәдәни башкаласы» булып таныла; 2007 елда «Социаль өлкәдә иң яхшы муниципаль берәмлек» Бөтенроссия конкурсында җиңә.

- Февраль ае – «Шинник паркы»: Гагарин урамында “Шинник” спорткомлексы белән янәшә урнашкан кечкенә генә яшь каеннар паркы. Ул күнекмәләрдән соң спортсменнарның һәм якын тирәдә яшәүчеләрнең яраткан ял итү үзәге. Паркның үзәгендә бик матур чәчәклек бар. Балалар өчен ясалган мәйданчык балалар өчен бик уңай.
- Март ае – «Экстрим паркы»: Түбән Каманың 45 яшьлек уңаеннан, яшьләр шөгылен исәпкә алып ачыла. Ул Яшьлек урамында аттракцион янында урнашкан. Исеменнән аңлашылганча, анда велосипед һәм скейтбордларда гадәттән тыш алымнар башкарырга мөмкин.
- Апрель ае – «Тукай паркы»: Химиклар һәм Яшьлек урамнары арасында урнашкан. Монда сөекле шагыйребез Г. Тукайга һәйкәл куелган, аның әсәрләреннән әкият геройлары урнаштырылган. Бу уку һәм ял итү паркы. Яңа буын китапханәсе шәһәр халкының яраткан урыны.
- Май ае – «Җиңү монументы»: 1985 елда Бөек Җиңүнең 40 еллыгына ачылган, 2005 елда төзекләндерелгән. Монументның авторы – архитектор Ф. Ханов. Монумент янында мәңгелек ут яна. Монда «ИС-2» танкы һәм «Д-29» гаубица пушкасы куелган. Мәрмәр плитәләргә сугышта һәлак булган якташларыбыз исемнәре язылган.
- Июнь ае – «Лимаев скверы»: бу шәһәр үзәгенең искиткеч матур урыны. Н.В.Лемаев – “Түбән Кама нефтехим” берләшмәсенең беренче генераль директоры. Аңа мәйданда һәйкәл куелган. Лемаев скверында “Җәлил” ял үзәге, кафелар бар. Мәйдан үзәгендәге зур фонтан тирә - юньгә ямь өсти.
- Июль ае – «Аттракционнар паркы»: Түбән Кама шәһәренең мәдәни һәм ял итү үзәге. Паркның төп үзенчәлеге – ул яшь үзенчәлекләренә туры килгән төрле күңел ачу аттракционнарының күп булуы. Бу парк 2012 елда төзекләндерелә һәм яңартыла.
- Август ае – «Гаилә паркы»: 2016 елның 20 август көнендә Түбән Каманың 50 еллык юбилеена, шәһәрнең үзәк “Гаилә “ паркы ачылды. Әлеге парк җиде төрле зонага бүленгән: «chill-out» - искитмәле музыка һәм тиеннәр вольеры, “spray-park” – Петр I ның легендар шаяру фонтаннарын искә төшерә, музыкаль һәм “коры” фонтаннар, велосипед юллары, футбол кыры, спорт зонасы һәм балалар уен мәйданчыгы.
- Сентябрь ае – «Кояшы аланы»: урман янәшәсендәге иң матур яңа паркларның берсе. Аның мәйданы 5,2 га. Анда төрле-төрле спорт тренажерлары бар. “Яшел келәм”дә баскетбол, волейбол, футбол уйныйлар. Кечкенә балалар да, зурлар да рәхәтләнеп велосипедта йөриләр.
- Октябрь ае – «Шәһәр музее»: 1976 елда ачыла. Музей Төзүчеләр урамында урнашкан. Бүгенге көндә музей фондларында 26 меңнән артык экспонат исәпләнә:

әйберләр, сәнгать әсәрләре һәм документаль чыганаклар. Музей компьютерлаштырылган һәм интернет челтәренә тоташтырылган.

- Ноябрь ае – «Изгеләр чишмәсе»: Түбән Каманың су капкасы. Чишмәнең тарихы XV гасырдан башлана. Бу урында икона табылган, шуңа күрә чишмә Изгеләр чишмәсе дип атала. Шәһәребезнең 35 яшьлек юбилее уңаеннан төзекләндерелә. Матур ял урыны. Ташлар өстеннән, челтерәп, кояшта ялтырап, су ага. Кич белән чишмә тирәсендә төрле-төрле утлар яна.
- Декабрь ае – «Нефтехимиклар паркы»: Тынычлык белән Сөембикә урамнары арасында 2011 елда төзелгән. Бу паркны зур фонтан бизәп тора. Анда бик күп уен мәйданчыклары, утырып ял итү өчен матур итеп эшләнгән эскәмияләр бар.

Шәһәремнең истәлекле урыннары буенча матур фотолар тупладым. шушы материаллар ярдәмендә 2023 нче елга Түбән Кама шәһәренә багышланган өстәл календаре барлыкка килде.

## III. Йомгаклау

Календарьларның килеп чыгыш тарихын өйрәнү барышында, аларның кеше тормышында бик күптәннән файдалануга кертелүен, кешеләр өчен уңайлы һәм кирәкле әйбер булуына инандым. Каюм Насыйри башка өлкәдәге хезмәтләре белән беррәттән календарьлар төзүдә, аларда материаллар туплау, төрле темаларга язу буенча үзеннән соң киләчәк буыннарга зур мирас калдырган шәхес. Аның бу өлкәдәге эшчәнлеге белән танышу минем өчен бик мөһим булды.

Үземнең шәһәрем турында мәгълүмати өстәл календары булдыру йөзеннән яшьтәшләрем, укытучылар, әти-әниләр фикерен туплап, быелгысы елга 12 айлык өстәл календары өчен материал барладым. Төрле чыганаклардан файдалынып, өстәл календарын матурлау максаты белән, шәһәребезнең фотоларын тупладым.

Түбән Кама шәһәренә багышланган 2023 нче елга өстәл календаре төзелде һәм бу календарь шәһәр хакимиятенә тәкъдим ителде. Шәһәребез елдан-ел үзгәрә, туристларны җәлеп итә. Шәһәребез турында мәгълүмат тарату өчен өстәл календаре бик яхшы ысул булыр дип уйлыйм.

## IV. Кулланылган әдәбият:


1. Х.Ш.Мәхмүтов “Ел тәүлеге – 12 ай”, Казан, 2010
2. Нижнекамск. История в 50 лет. Факты. События. Воспоминания. /Под общей редакцией Э.Р.Долотказиной. – Нижнекамск: ООО “издательско-полиграфический центр “Гузель”, 2016 – 512 с.
3. Балалар календаре. Татарстан китап нәшрияты, 1990 ел.

4. Каюм Насыйри. Сайланма әсәрләр (икенче том). Казан, Татарстан китап нәшрияты, 1975 ел.
5. Татар календаре 1996. Татарстан китап нәшрияты, 1996 ел.

*Хикматуллина Ляйсан, 5 нче сыйныф, Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районының "Аерым фәннәрне тирәнтен өйрәнүле 15 нче урта гомуми белем бирү мәктәбе" муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесе*
*Җитәкчеләре: Фатхуллина Гузял Фагимовна, Халикова Нурсина Далифовна, туган тел һәм әдәбияты укытучылары*

## Минем иҗатка кызыксынуым

### Туган телем

Бик яратам туган телне,
Сөйләшәм мин һәр көндә.
Бик аһәңле туган телем,
Укыйм татар телендә.
Әби – бабайда татарча,
Сөйлиләр әкиятләр.
Китаптан үзем укыймын,
Кызыклы хикәятләр.
И яратам, туган телне!
Туган телдә сөйләшәм.
Туган телне ишетсеннәр:
Мин бит шатлык өләшәм.
Энем дә минем сөйләшә,
Матур туган телендә.
Бер генә яшь булса да,
Биш сүз әйтә кимендә.
Без сөябез туган телне,
Хөрмәтлибез гел аны.

Туган телдә сөйләшүнең...

Артып торсын гел саны.

**Китап**

Китап укыйм, алам белем.

Язылган анда барысы.

Килә әле минем тагын,

Картинкалар карасы.

Укырга бик яратам,

Китапны саклап тотам.

Төрле ярышларда да,

Белгәнгә күрә отам.

Китапларым минем күп,

Барысын укып чыктым.

Дәрескә кирәкләрен,

Портфелемә мин тыктым.

**Кыш**

Бигрәк матур инде кыш!

Кар ява ап- ак булып.

Уйный балалар урамда,

Өсләренә кар тулып.

Шатланалар балалар,

Кар яуганга күп итеп,

Карый алар ис китеп.

Барлык агачлар ап – ак,

Әйтерсең күлмәк кигән.

Тирә – якны матурлап,

Менә шулай кыш килгән.

**Әнием**

Дөньяда иң якын кешем –

Ул бит минем әнием.

Тормышымны кояш кебек

Балкытучым ул минем.

Тәмле – тәмле ашлар белән

Сыйлый ул һәммәбезне.

Матур бәйрәмнәр уздырып,

Бизи гел өебезне.
Җырларга да, биергә дә,
Чигәргә дә ярата.
Аның җылы кочагында
Яшим шатланып кына.

**Мәктәбем минем**

Кулга- кул тотышып килдек
Әни белән без сиңа.
Мәктәбем, синдә укыйм,
Горурланам мин шуңа.
Мәктәбем, шатланамын
Синең уңышларыңа.
Яшә, мәктәбем, кушылып
Заман сулышларына.
Һәр көн саен яңа белем
Бирәләр мөгаллимнәр.
Рәхмәтебезне белдерергә
Җитмидер матур сүзләр.
Кулланырбыз иминлеккә
Синдә алган белемне.
Кайларга гына китсәк тә
Онытмабыз үзеңне!

**Туган тел**

Бик яратам туган телне,
Сөйләшәм туган телдә.
Туган телемне белгәнгә,
Бәхетле мин бу илдә.

*Хузин Данил,8 нче сыйныф,*
*Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районының "29нчы урта гомуми белем бирү мәктәбе" муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесе*
*Җитәкчесе: Чевачина Розалия Вакифовна, туган тел һәм әдәбияты укытучысы*

# Муса Җәлил һәм спорт

## Кереш

Татар халкының тарихи тамырлары бик тирән. Безнең халыка хезмәт сөючәнлек, тырышлык, үҗәтлек хас. Нинди генә авыр сынаулар килеп туган трагедик чорларда да халкыбыз баш имәгән, рух ныклыгын югалтмаган. Җир шарындагы һәр халыкның милли-мәдәни йөзе, беренче чиратта, энҗе бөртегедәй балкыган әдәби җәүһәрләре, горурлыгын, үткәнен һәм киләчәген билгеләгән иҗади мирасы белән бәяләнә. Олуг, бай һәм чал тарихлы XX йөз татар әдәбиятын үлемсез шигырьләре белән халык йөрәгендә мәңгеләшкән Муса Җәлил исеме дә бизи. “Моабит дәфтәрләре” белән татар шигъриятен дөнья киңлекләренә чыгарган, кыска гомерендә үзеннән соңгы буыннарга үлмәс иҗат мирасы калдырган, яшәү мәгънәсен туган иленә, газиз халкына хезмәттә күргән, аны батыр йөрәкле, үлмәс җанлы итеп таныткан, Ватан азатлыгы хакына җанын биргән, язмыш сынауларына бирешмичә, үлемен батырларча кабул иткән көчле рухлы шәхес ул.

Кешелеклелек сыйфатлары белән дә Муса Җәлил гаҗәеп шәхес буларак ачыла. Тоткынлыкта 791 көн уздыруга карамастан, рухи яктан сынмаган, фашистлар алдында баш имәгән, илен сатмаган. 1943 нче елның июнендә үлемгә хөкем ителеп һәр сәгате, минуты белән әҗәл көткәндә дә иленә, язмышына ләгънәт, бәддога укырга ашыкмый. Мондый вакыт өчен күз яшенә буылу, пессимизмга бирелү хас булса да, Җәлил үзенең рухи ныклыгы белән тетрәндерә. Бу яклап аның батырлыгын Прометей батырлыгына тиңләп булыр иде. Шуңа да Җәлил батырлыгын белгән төрле милләт вәкилләре үлемне җиңгән шагыйрь дип әйтәләр.

### I бүлек. Сәламәт тәндә – сәламәт рух

Җәлил – күпкырлы сәләткә ия булган шәхес. Кече яшьтән фантазиягә бай булган. Ул кыллы музыка коралларында, аеруча мандолинада бик оста уйнаган, акварель белән рәсем ясарга яраткан, моңлы итеп җырлый белгән, спорт белән шөгыльләнгән.

1924 нче елга кадәр язган хатларында Муса Җәлил еш кына үзенең сәламәтлегеннән зарланган. Моңа сәбәп булып, авыр балачак еллары, туйганчы ашамау, 1921 нче елгы ачлык тора.1923 нче елның җәендә ул малярия белән дә авырый. Рабфакта укыганда Мусаның кулына физкультураның файдасы турында бер китап килеп эләгә.Китапны укып чыккач, ул чын-чынлап үзенең сәламәтлеге турында кайгырта башлый: салкын су белән коена, гер күтәрә, волейбол уйный, Кабан күлендә көймәдә йөзә, һәр көнне иртән гимнастика ясый. Тиздән, чынлап та, аның сәламәтлеге яхшыра.[2]

1924 нче елдан башлап, Мусаның иртәнге гимнастиканы калдырган көне булмый. Хәтта Моабит төрмәсендә утырганда да бу шөгылен дәвам иттерә. “Камера тормышы бер көенчә уза торды. Иртәнге алтыда йокыдан уяталар. Муса беренче булып уяна. Уянгач, салкын су белән тәнен ышкый, юына һәм иртәнге зарядканы ясый”, - дип яза Андре Тиммерманс П. Чумакка язган хатында.

1941 нче елның февраль аенда шагыйрь Васильево санаториесендә ял итә. Аның шул чакта төшкән бер фоторәсеме дә сакланган. Тирә-юнь ап-ак кар белән капланган. Җәлил яланбаш, майкадан гына чаңгы шуарга чыккан. Аның өчен бу бер дә гаҗәп эш түгел. Бил тиңентен чишенеп яки майкачан килеш чаңгы шуу, иртә яздан алып кара көзгә кадәр салкын суда коену Муса өчен гадәти хәл саналган.

“Физик яктан Муса кебек сәламәт кешеләрне миңа сирәк очратырга туры килде, - дип яза Гази Кашшаф. – Ул сәгатьләр буе ишкәк ишеп көймәдә йөри ала, кичке ял вакытларында бертуктамый волейбол уйный, көнозын урманда йөри һәм ару-талуның нәрсә икәнен дә белми иде”.

Өйләнгәч, ял көннәрен ул күбрәк Мәскәү янындагы Загорянка поселогында, хатынының әти-әниләрендә уздыра. Монда килүгә, үзенә берәр эш эзләп таба: утын яра, су ташый, бакча казый.

Утызынчы еллар уртасында Җәлил Кырымда, Севастопольдә ял итә. Баштагы көннәрдә Муса санаторий тәртипләрен төгәл үти: комда кызына, төшке аштан соң ятып йоклап ала. Ләкин түземлеге күпкә җитми. “Аяк-кулларын бераз язарга” ниятләп, ул Севастопольдән Ялтага чаклы булган сиксән чакрым араны җәяүләп үтә. Кырым белән таныша, Ялтага яраткан язучысы Галимҗан Ибраһимов янына керә. Кайтканда да шул ук араны җәяү кайта.

Муса үзенең сәламәтлеге, физик көче белән мактанырга яратмый. Шуңа күрә бу турыда хәтта аның якын дуслары да белмәгән.

---

[2] Муса Җәлил турында истәлекләр// Төз. Мостафин Р.Ә.- Казан:Татар.кит.нәшр., 2006.

“Төне буе “Алтынчәч” операсын язып утырганнан соң, әсәрнең бер өзеге турында фикер алышу нияте белән Муса янына кердем, - ди Нәҗип Җиһанов. – Вакыт бик иртә булуга карамастан, Муса инде торган, гимнастик күнегүләр ясый иде”. Шагыйрьнең мускулларын, тыгыз итле тәнен күреп, ул чын-чынлап хәйран кала. Үз күзенә үзе ышанмыйча, копозитор Мусаның күпереп-калкып торган мускулларын капшап карый һәм, соклануын яшермичә, телен шартлатып куя. Аннан, кызыксынып:

-Шагыйрьгә мондый мускулатура нәрсәгә? - дип сорый.

-Кирәге чыгып куюы бар, - ди Муса, тәнен юеш сөлге белән сөртә-сөртә.

Шагыйрьнең Мәскәүдәге иң якын дусларыннан тагын берсе Әхмәт Фәйзи була. Мусаның өйләнгәнче яшәгән фатирын ул болай тасвирлый: “Бүлмәдә китаплар өелгән өстәлдән һәм бер урындыктан башка берни дә юк. Муса иске газеталар өстендә йоклый... Ул күп укый, спорт белән шөгыльләнә, кояшны бик ярата. Иң яраткан спорт төрләреннән берсе, шиксез, мылтыктан ату иде”.[3]

Муса шахмат уйнарга да яраткан. Җиңсә, сөенеп бетә алмый, җиңелсә, нык үртәлә торган булган. Андый чакларда үзен “грошмейстр” яки “гробмейстр” дип атаган.

Җәлилләрнең Столешников урамындагы фатирында чыгарылган “Шахмат бюллетене”нең өченче саны сакланып калган. Бюллетень Муса язган төрле мәзәкләр һәм эпиграммалардан тора, ул үзе ясаган юмористик рәсемнәр белән дә бизәлгән.

Муса физик яктан шактый нык, таза кеше булган. Иртән тору белән күнегүләр ясаган. Кулларын-аякларын гына селтәп түгел, ике потлы гер белән уйнаган. “Гер, җиңел бер уенчык сыман, очып кына йөри иде”, - дип сөйли Әминә ханым. Моннан тыш аның тимер гантельләре дә булган. Ул шулар белән үзенә зур бер рәхәтлек табып, шактый озак уйнаган.

Җәй көне туганнары янына Загорянка поселогын баргач, Муса бакчада эшләргә яраткан. Иртәнге алты-җиделәрдә торып, су коенырга йөгергән.

Кыш көне ул чаңгы шуарга яраткан.

-“Чаңгы шуарга ул февральнең иң салкын көннәрендә дә кайвакыт майкадан гына чыга иде, - дип сөйли Әминә ханым. – Кышкы кояш яктысында аның таза беләкләре кызынып, каралып бетә иде.

Кайвакыт, мавыгып китеп, Муса суык та тидергән.

-Җиңелчә генә салкын тидерсә дә, ул җылы пижамасын киеп, шундук урынга менеп ята иде, - дип сөйли Әминә ханым. – Без аның өчен җиләк суы кайнатабыз, куе итеп чәй

[3] Хусниев Насим. Спорт в жизни поэта// Магариф, №2, 2006.

ясап бирәбез, температурасын үлчибез, даруханәгә барып дару алып кайтабыз. Ә ул шул ыгы-зыгыга бик канәгать булып карап тора иде. Ул, нечкә күңелле кеше буларак, бераз иркәләнергә дә ярата иде...

Берзаман Муса чын-чынлап авырып китә. Бу болай була. Кыш уртасында Муса, бәләкәй чанага нәни Чулпанны салып, урамга алып чыга. Үзе дә шунда, чана янында, китап укып утыра. Чулпан саф һавада рәхәтләнеп йоклый. Шулар бер сәгать үтә, ике, өч... Муса, үзе туңса да, баланы уятырга теләмәгән.

Шул ук төнне Муса каты авырып китә, аяксыз кала. Врачлар, нерв тамырына салкын тидергән, дип әйтәләр. Моны ишеткәч, Муса хәтта елап җибәргән, инвалид булып калырмын дип уйлаган. Башта аның хәле чыннан да өметсез кебек тоела. Әмма берничә ай үтүгә Муса терелә, яңадан аяган баса.

-Авырып терелгәннән соң, аның холкы бер тамчы да үзгәрмәде, -дип яза Әминә ханым. – Ул элеккечә зарядка ясый, салкын суда коена, кышларын чаңгыда җиңелчә киенеп йөри иде.

Таза, нык булуы Мусаның күңел бөтенлеген көчәйтә, эчке бер ныклыгын күрсәтеп тора иде. Аның рухи ныклыгын физик тазалыгыннан килә дип әйтеп булмый иде. Әлеге каты авыру вакытында ул рухи гәүдәсенә буйсынмаганлыгын күрсәтте. Аның табигатьне яратуы, тормыштан аерылмыйча иркен күңел белән яши белүе рухи һәм физик яктан нык булуыннан килә иде. Ул күңеле белән гаять бөтен кеше, гел яшәр өчен, эшләр өчен, көрәшер өчен, сөенер өчен туган кебек иде.[4]

Шуны да әйтергә кирәк, Мусаның авыруы 1937 нче елның кышына – шагыйрьнең иң хәвефле чагына туры килә.

Истәлекләрдән күренгәнчә, Оренбургта яшәгәндә (1926 нчы ел) Муса аеруча су спортына өстенлек биргән. Ул суда үзен балык кебек хис иткән. Урал – киң, мул сулы елга, аның агымы бик көчле, төбе чокырлы-чакырлы. Ләкин Муса бернинди авырлыксыз елганы йөзеп чыгып, кире шул ярга әйләнеп кайта торган булган. Өйдә булганда һәр кичне йокы алдыннан су коенырга йөргән. “Ял көннәрендә яки кич белән без көймәдә йөри идек. Урал елгасының каршы ярында торучылар таза егетнең һәм аның белән нәни кызның спорт көймәсе “Чайка” да Урал дулкыннарын кыю кисеп йөзүләрен ярдан карап торалар иде” – дип язган шаыйрьнең сеңлесе Хәдичә.

---

Мостафин Р.Ә. Җәлилчеләр: Очерклар, җәлилчеләр иҗаты. – Казан, Тат.кит.нәшр., 1988.

Бер елны Муса дусты Әхмәт Исхак белән язучыларның Одесса янындагы иҗат йортында ял итә. Гадәтенчә, күп эшли, күп яза. Шул ук вакытта волейбол уйнарга, көймәдә йөрергә, кызынырга да вакыт таба.

Көннәрнең берендә, төш вакытында, алар диңгез култыгында су коенырга төшәләр. Көтмәгәндә көчле җил чыгып, тау-тау дулкыннар күтәрелә. Коенучылар ашыга-ашыга ярга чыга. Бер Әхмәт Исхак кына дулкын чыгуын сизми кала, рәхәтләнеп дулкыннар кочагында тирбәлә бара. Кинәт ул, дулкын көченә ияреп, ярдан ераклаша баруын сизә. Борылып, ярга таба йөзеп карый, ләкин диңгез аны һаман эчкә сөйри. Әхмәт Исхак ярдәм сорап кычкыра башлый. Яр буендагы халык үрсәләнеп арлы-бирле йөгерергә тотына. Үч иткәндәй, якын-тирәдә ни көймә, ни бау, хәтта гади бер такта кисәге дә табылмый. Хәлнең җитдилеген аңлап, Муса ярдагыларга, кулга-кул тотынып, тере чылбыр ясарга куша. Шул юл белән, бата язган язучыны ярга сөйрәп чыгаралар...[5]

1928 нче елның җәендә Мәскәү дәүләт университетының беренче курс студентлары хәрби җыеннарда катнашалар. Палаткаларда яшиләр. Җитәкчеләрнең максаты – алардан запастагы командирлар хәзерләү була. Шуңа күрә студентлар солдат тормышының кырыс мәктәбен үтәргә тиеш булалар. Көннәр хәрби әзерлек, атышу, походлар белән үткән. Студентларга әлеге режимга күнегү башта бик авырга туры килә. Ләкин Муса иң алдынгы солдатларның берсе була. Беркемдә аннан “арыдым”, “туйдым” кебек сүзләр ишетмәгән. Ул үзен һәрвакыт тыныч тоткан, командирның һәр әмерен җиренә җиткереп, төгәл үтәгән. Иптәшләре тәбәнәк буйлы, ябык гәүдәле солдатның көченә, түземлелегенә бик аптыраганнар. Авырга туры килгән чакларда да, Җәлил сер бирмәгән.[6]

Нәтиҗә ясап әйткәндә, шагыйрь, тәрҗемәче, оста оештыручы, җәмәгать эшлеклесе булган Муса Җәлил спорт белән дә даими шөгыльләнгән. Шуннан җанына сихәт алып, тулы канлы тормыш белән яшәгән.

**II бүлек. Физик тәрбия һәм спортның шагыйрь иҗатында чагылышы**

Спортка һәвәслеге Муса Җәлилнең иҗатында да чагыла. Мәсәлән, аның “Чаңгы эзләре”, “Чаңгы шуганда”, “Кавказда” кебек шигырьләре шул темага багышланган. Күпме оптимизм, тормышка, хезмәткә мәхәббәт хисе ул шигырьләрдә! Күңел төшенкелеге, эч пошу, елау-сыкрау – Җәлил иҗаты өчен ят нәрсә. Аның шигырьләре нык ихтыяр көче, ашкынулы дәрт белән сугарылган, аларда бәхеткә омтылу, яшәүгә мәхәббәт ярылып ята.

---

[5] Мостафин Р.Ә. Җәлилчеләр: Очерклар, җәлилчеләр иҗаты. – Казан, Тат.кит.нәшр., 1988.

[6] Муса Җәлил турында истәлекләр// Төз. Мостафин Р.Ә.- Казан:Татар.кит.нәшр., 2006.

Муса Җәлилнең табигатьне, чаңгы шуарга яратуы аның “Чаңгы шуганда”, “Чаңгы эзләре” шигырьләрендә ачык күренә.

*Чаңгы шуганда*

*Унбер яшьлек малай чаңгы шуа,*
*Текә ярдан оста сикерә.*
*Мин карыйм да исем китә шуңа:*
*Ничек шулай җаен китерә!*

*Аның эзе буйлап, ахры, мин дә*
*Яр башыннан түбән омтылдым.*
*Чаңгыларым китте, үзем җиргә*
*Лып иттереп килеп утырдым.*

*Чаңгы эзләре*
*Яшь балалар чаңгы шуа ала карда,*
*Агач башына килеп кунды ала карга.*
*Карга белән тик икәү без эшсез монда.*
*Шумыйбыз да, тик торабыз сүзсез генә.*
*Карга карый, мин дә карыйм:нинди кызык!*
*Чаңгы үтә тигез, матур сызык сызып.*[7]

Шагыйрьнең спортка булган мәхәббәте “Яшьлек” шигырендә ачык чагыла.
*Наян яшьлек, белмим нәрсәң белән*
*Якын булдың минем йөрәккә.*
*Әллә юкса... спорт сөючелек*
*Бәйләдеме сиңа күңелне?*
*Оныталмыйммы – иркен стадионда*
*Йөгерә-йөгерә футбол тибүне?*

Муса еш кына Ә.Фәйзине тирга чакыра торган булган. Ул үзе бик төз ата, ә дустының мишеньгә тидерә алмавыннан рәхәтләнеп көлә икән. Бервакыт Әхмәт Фәйзи, ачуы килеп, Мусаны иҗади ярышка чакыра. “Әйдә, оборона спорты турында шигырь язып карыйк. Кем җиңәр икән?” – ди. Ә.Фәйзи “Оптимистлар җыры” дигән шигырь яза. Бу шигырендә ул,

[7] Җәлил Муса. Әсәрләр. 5т., 1 том.- Казан:Тат.кит.нәшр., 2006.

шагыйрь өчен, мылтык ата белүдән бигрәк, әйбәт шигырь язу мөһимрәк, дип исбатларга тели. Аңа җавап рәвешендә Муса “Тирга” дигән шигырь яза.

*Әхмәт туган, ташла каләмеңне,*

*Әйдә киттек тирга, булмаса.*

*Төз атучы булдык җырда да,*

*Төз атарбыз, шиксез, тирда да,* -

дип тәмамланган шигырендә дә шул ук теманы үзенчә чишеп бирә.

Шагыйрьнең мылтыктан оста атучы булуы аның “Безнең кыз” шигырендә дә күренә.

*Менә шул кыз... нечкә кыйгач кашлы,*
*Ирене төсле алсу беретлы...*
*Бүген тирда атыш ярышында*
*Җиңеп чыгып, мине хур итте.*[8]

*Исемем белән кече лейтенант мин,*
*Оста гына атам шикелле...*
*Каушадыммы, белмим, “күз тидеме”,*
*Осталыгым әллә икеле?*

Шулай итеп, Җәлилнең физик тәрбия һәм спорт яратуы аның шигырьләрендә дә урын алган.

**Йомгаклау**

Муса Җәлил шигырьләре соклandыргыч. Сугыш темасы, Туган илгә эчкерсез мәхәббәт, фашист илбасарларының явызлыгын сурәтләгәндә зур уңышка ирештеләр. Ул – безнең яраткан фронтовик шагыйребез, татар халкының горурлыгы, бөек улы, каһарманы.

Шулай итеп, физик тәрбия һәм сәламәт тормыш рәвеше турындагы китапның очраклы рәвештә Җәлил кулына килеп керүе шагыйрьнең спорт дөньясы белән мавыгуына этәргеч бирә.

Сәламәт тормыш рәвеше алып бару һәм спорт белән шөгыльләнү организмны чыныктыруга, ныклы характер, ихтыяр көче тәрбияләүгә зур йогынты ясый. Ә бу үз чиратында бер елдан артык үлем хөкемен көтүдә, шундый авыр шартларда да шигырьләр язарга көч табуда чагыла.

[8] Җәлил Муса. Әсәрләр. 5т., 1 том.- Казан:Тат.кит.нәшр., 2006.

Шул рәвешле, талантлы шагыйребез М.Җәлил турында бик күп яңа мәгълүматлар тупладык. Аның көчле рухлы, тирән хисле, талантлы шәхес булуына тагын бер кат инандык.

Язманы чуваш халык шагыйре Педер Хузангайның шигъри юллары белән йомгаклыйсы килә:

***"Башым иям бу дәһшәтле чорда***
***Шундый уллар биргән халыкка.***
***Башым иям бу халыкның исемен***
***Мәңге үлмәс иткән шагыйрьгә".***

**Файдаланылган әдәбият исемлеге:**


1. Хусниев Насим. Спорт в жизни поэта// Магариф, №2, 2006.
2. Җәлил Муса. Әсәрләр.- Казан: Мәгариф, 2004.
3. Җәлил Муса. Әсәрләр. 5т., 1 том.- Казан:Тат.кит.нәшр., 2006.
4. Мостафин Р.Ә. Җәлилчеләр: Очерклар, җәлилчеләр иҗаты. – Казан, Тат.кит.нәшр., 1988.
5. Мостафин Р.Ә. Керсез дуслык, тирән сөю хисе//Мәйдан, 2006, №1.-40 нчы бит.
6. Муса Җәлил турында истәлекләр// Төз. Мостафин Р.Ә.- Казан:Татар.кит.нәшр., 2006.



*Шәмсивәлиева Ясминә, 5 нче сыйныф,*
*Татарстан Республикасы Түбән Кама*
*муниципаль районның "14нче лицей"*
*муниципаль бюджет гомуми белем бирү*
*учреждениесе*
*Җитәкчесе: Мифтахова Эльмира Флүр кызы,*
*Насыйрова Миләүшә Сәлмән кызы,*
*туган тел һәм әдәбияты укытучылары*


## Башы бер, мәгънәсе мең...

### (Галимҗан Ибраһимов "Кызыл чәчәкләр" повесте буенча)

### Кереш

Тормыш өзлексез үзгәреп тора. Ул үзгәрешләр телнең иң хәрәкәтчән өлкәсендә – сүзләр аша телдә чагылыш таба. Яңа төшенчәләр яңа сүзләр аша яисә булган сүзләрне яңа

мәгънәдә куллану аша белдерелә ала. Безне чолгап алган дөнья искиткеч бай, чиксез күптөрле. Аны танып белү мөмкинлеге дә чиксез. Әгәр һәр яңа төшенчәне яңа сүз белән атый башласак, сүзләр кирәгеннән артык күбәер һәм бөтен кирәкле сүзләрне кеше хәтерендә саклый алмас иде. Шуңа күрә кеше акылы иң экономияле юлны – бер сүзне яңа мәгънәләрдә куллануны сайлаган.

Яңа төшенчәне инде телдә булган сүз белән атаганда, без һәрвакытта алар арасындагы ниндидер бәйләнешкә таянабыз. Мәсәлән, самовар кайнаган кебек халык та кайный, башкача әйтмибез бит, селкенә димибез. Пешеп җитмәгән йомырка, бәрәңгегә охшатып, кайбер кешеләрне дә пешмәгән диләр.

Г.Ибраһимовның әдәби әсәрләренең телен һәм стиль үзенчәлекләрен күп кенә галимнәр өйрәнгәннәр. С.Ш.Поварисов аерым хезмәтләрендә Г.Ибраһимовның тел байлыгын лингвистик яктананализлый, шулай ук И.Б.Бәширова, Ф.М.Газизова, М.Ә.Сәгыйтов кебек галимнәрнең аерым мәкаләләре әлеге проблеманы берникадәр күләмдә өйрәнүнең мисалы булып тора.

Без дә Галимҗан Ибраһимовның аерым бер әсәрен алып, анда күпмәгънәлелек күренешен тикшерүне **максат** итеп куйдык.

Максаттан чыгып түбәндәге **бурычлар** билгеләнде:

- күпмәгънәле сүзләр турында төшенчәне табып теркәү;
- нинди функцияне үтәвен ачыклау;
- әдип әсәренә анализ ясау.

Тел белгечләрен язучыларның телен, аның “сер”ләрен ачуга һәм укучыга тәэсир көчен өйрәнүгә этәрә. Язучыларның телен өйрәнү хәзерге филология фәне үсеше таләп иткән әһәмиятле мәсьәләләрнең берсе булып тора. Шуннан чыгып, эшебезнең темасы бүгенге көндә **актуаль.**

**Фәнни эшнең өйрәнү объекты.** Фәнни эшнең өйрәнү объекты итеп Г.Ибраһимовның “Кызыл чәчәкләр” повесте алынды.

**Фәнни эшнең структурасы.** Фәнни эш кереш, төп өлеш, йомгак, кулланылган әдәбият исемлеген берләштерә. Төп өлеш ике бүлектән тора.

Әлеге тикшерү фәнни әһәмияткә ия.

## Төп өлеш

### Бүлек 1. Сүзнең яңа мәгънәләре ничек туа соң?

Телнең сүзлек составында бер генә мәгънәгә һәм берничә мәгънәгә ия булган сүзләр аерылып тора. Сүзнең төп мәгънәсе әйберне турыдан-туры, башка мәгънәләрне күз алдында тотмыйча чагылдыра: *китап, өстәл, алма, кояш*. Күчерелмә мәгънәдә әйбер шул ук сүзнең башка мәгънәләре аша чагыла: *якты бүлмә – якты уйлар, малай чаба – поезд чаба, тирән*

*су – тирән хөрмәт*. Сүзнең төп мәгънә белән беррәттән өстәмә мәгънәләргә дә ия булуы аның күп мәгънәлелеге (грек. *polis – күп, sema – билге,*) дип атала. Аралашуда еш кулланылган, тарихы зур булган сүзләрнең мәгънәләре аеруча күп була. Мәсәлән, “Татар теленең аңлатмалы сүзлеге”ндә *табу* сүзнең – 45, *төшү* сүзнең – 66, *бирү* сүзнең – 36, *булу* сүзнең – 39, *калу* сүзнең – 25, *төшерү* сүзнең – 28, *тарту* сүзнең – 37, *җибәрү* сүзнең 28 мәгънәсе күрсәтелгән.

Сүздәге аерым мәгънәләр атаманы бер әйбердән икенчесенә күчерү, тиңләү процессында барлыкка киләләр. Мәсән, *борын* – кешенең йөзендә алга чыгып тора торган әгъза. Географик *борын* да шуңа нигезләнеп ясалган, материкның диңгезгә чыгып тора торган өлеше ул. *Канат* – кош һәм бөҗәкләрдә очу өчен ярдәм итә торган әгъза. Самолет *канаты* да шушы вазифа җирлегендә барлыкка килгән.

Шулай итеп, сүзнең төп, беренчел мәгънәләренә нигезләнеп, икенчел мәгънәләре дә барлыкка килә. Беренчеләренең ни өчен шулай аталуын белү авыр яисә бөтенләй мөмкин түгел, икенчел мәгънәләрне исә аңлатып була. Без, мәсәлән, *ак* дигән сыйфатның ни өчен шулай йөртелүен ачыклый алмыйбыз, әмма *ак бәхет, ак күңел, ак юл, ак келәт, ак җан, акка күчерү, ак эш* кебек тезмәләрдәге *ак* сүзенең ни өчен кулланылуын әйтү авыр түгел.

Күчерелмә мәгънәләрнең иң актив төрләре - метафора.

Метафора - күчерелмә мәгънәләрнең иң киң таралган төрләреннән берсе. Ул - бер атаманың икенче атамага охшашлыгы нигезендә күчеше.

Метафора түбәндәгеләр нигезендә барлыкка килә:

1) әйберләрнең форма ягыннан охшашлыгы: яшел алма - күз алмасы, чыршы энәсе - тегү энәсе, кыңгырау чәчәге - кыңгырау шалтырады, балык тәңкәсе - тәңкәләр чылтырый; кеше борыны - көймә борыны.

2) әйберләрнең урнашу ягыннан охшашлыгы: хайван койрыгы - самолет койрыгы, өй түбәсе - баш түбәсе;

3) аваз охшашлыгы: җил улый - бүре улый, бала кычкыра - бытбылдык кычкыра;

4) эчке охшашлык, ассоциация: кара урман, кара ягу, кара көчләр, кара йөзләр, кара шар салу, кара мунча, кара яңгыр, кара халык, карадан күчерү, кара бояу, кара кайгы.

Метафораларның өч төре бар:

1) Гомумтел метафоралары - катып калган, образлылыктан азат, стандартлашкан, туры мәгънәдә кабул ителүче метафоралар. Мәсәлән, китап бите, тау түбәсе, урак теше, өстәл аягы, көймә койрыгы, сәгать суга, сәгать йөри. Мондый метафоралар сүзлекләрдә сүзнең күчерелмә мәгънәсе буларак теркәлә.

2) Гомумпоэтик метафоралар укучы, сөйләүче тарафыннан образ, сурәт буларак кабул ителәләр: көмеш тавыш, саф сөю, көлтә койрык, ак күңелле, ефәк чәч, дөнья җимерттереп яши һ.б.

3) Автор метафоралары - теге яки бу язучы яки шагыйрь тарафыннан тудырылган метафоралар: Мөхсиновның аркасыннан көтүе белән бозлы кырмыскалар йөгереште (Г.Бәширов). Зәңгәрсу күмер исе таралган класс бүлмәсендә Мәскәү татарының көчле бәрхет тавышы яңгырап-яңгырап китә, бөтен күзләр аңа текәлгән, ә ул классны гипнозлый бара (М.Мәһдиев).

## Бүлек 2

### 2.1. Галимҗан Ибраһимов әсәрләрендә күпмәгънәлелек

Г.Ибраһимов татар теленең сүзлек хәзинәсе белән оста эш итеп, аның лексик чараларының төрле үзенчәлекләреннән файдалана. Әдипнең дөньяга карашы, чынбарлыкны тасвирлавы, эстетик күзаллавы – аның сурәтләү чараларына бай булган образлы телендә чагыла. Бер үк сүзнең төрле сүзләр белән бәйләнешкә кереп төрле мәгънә күчешләрен бирүгә ярдәм итә. Тел белемендә күпмәгънәлелек дип йөртелгән мондый күренеш Г.Ибраһимов теле өчен аеруча характерлы. Язучы, сүз остасы буларак, үзлекләре белән төрле әйбер, предметларның гомуми билгеләрен күреп ала һәм шул рәвешле сүзне башка бер сүз белән бәйләнешкә кертеп, яңа мәгънә берлеге барлыкка китереп чыгара.

Метафораларны карап үтик. “Кызыл чәчәкләр” повесте: *“Без түбәннән, тормышның төбеннән күтәрелдек”,* дип башланып китә. Бу метафора әсәр геройларының күплеген һәм төрле социаль катламнарга каравын, вакыйгаларның катлаулы булачагын күрсәтә.

*“Язмыш дулкыннары* белән бер кавышып, бер аерылып яшәгән дүрт иптәшем дә шул авылның төрле урамнарында, байлыгы-төзеклеге төрлечә булган төрле өйләрдә туып үстеләр”, - дигән җөмләдә әдип төп геройның иптәшләренең тормышындагы үзгәрешләрен дулкыннарга тиңли, һәм шуны да әйтергә кирәк, алар диңгездәгеләргә караганда ачыграк, аянычрак булып күзалланалар.

“Моңарчы һичкая кузгалмаган Гыйлаҗи да *аякланды*” – дигән җөмләдә *аякланды* күчеп китте мәгънәсендә килә, гомумән, әлеге сүзтезмә сөйләмә телдә генә кулланыла.

“Шахталарга бара торган юл менә шул *тау итәгеннән* үтә”, “Таулар биек, агачлар матур, заводлар һәммәсе дә төрле тау араларыннан төшкән *елгаларның тамагында* буып ясалган зур матур күлләр тирәсендә утырганнар”. *Тау итәге, елга тамагы* – гомумтел метафоралары әйбернең форма ягыннан охшашлыгына нигезләнә.

“Егет ниндидер бер *кара пычрак җинаятьтә* гаепләнә”, “Бохарада, Фирганәдә булган *кара көчләр* өчен куркыныч *кызыл батырларның* берсе безнең Шаһбаз икәнен ул

җирдән кайтучылар сөеп сөйлиләр иде”, “Ниндидер бер бәйрәм – кайгылы бәйрәм, кара, бик *кара бәйрәм*”, “Ләкин Фазыл минем йөрәгемә *кара кан* сауарып китте” җөмләләрендә *кара көч, кара җинаять, кара бәйрәм, кара кан* метафоралары аша вакыйгаларга негатив төсмер бирелә.

“*Бәхет ишекләре* бер ачылса, гаҗәп була икән ул”, - дигәндә автор гомумхалык телендә һәм поэтик сөйләмдә еш кулланыла торган *бәхет ишекләре* метафорасын куллана.

Г.Ибраһимов әсәрләренең лексик-семантик системасында күпмәгънәле сүзләр мөһим йөкләмәне үти. Күпмәгънәле сүзләр куллану белән бергә аларның катлаулы семантикасы, бай мәгънә төсмерләре һәм стилистик үзенчәлекләре язучының осталыгын,әдби зәвыгын күрсәтеп бирә. Шул ук вакытта татар теленең бетмәс-төкәнмәс сүзлек хәзинәсенең байлыгын һәм гүзәллеген ачып бирә.

**2.2. Күпмәгънәлелек безнең тормышыбызда**

Без менә шулай гомер буе сүзләр белән аралашып яшибез. Сүзләр безне бәхетле дә, бәхетсез дә итә ала... Сүзләр әйтерсең лә кояш: алар һәркемнеке һәм һәммәбезнеке дә. Сүзләрне саклык кассаларында саклау мөмкин булмаса да, “сүзләр банкы”н булдыру гаять зарур. Мин үзем төрле сүзлекләрне әнә шундый сүзләр банкы диа саныйм.

Сыйныфташларым арасында анкета үткәрдем. Сораулар:

1. Сез “Татар теленең аңлатмалы сүзлеге” белән танышмы?

2. Сүзләрнең күпмәгънәле булуын беләсезме?

Нәтиҗә:

1. “Татар теленең аңлатмалы сүзлеге” белән барлык сыйныфташларым да таныш, ләкин алар бу сүзлекне игътибар белән карамаган. Татар теле дәресендә укытучы күрсәтеп китүе буенча гына таныш булганнар.
2. Сүзләрнең күпмәгънәлеген шулай ук дәрестә өйрәнеп кенә беләләр.

Минем эшем сыйныфташларымда кызыксыну уятты. Без сүзләрнең күпмәгънәлеге буенча проект эшләргә уйладык. Үзебез һәм алдагы сыйныфлар өчен бик кызыклы китапчыклар килеп чыкты.

**Йомгаклау**

Г.Ибраһимов – татар әдәбиятында гына түгел, татар тел белемендә, татар иҗтимагый фикер үсешендә җуелмас эз калдырган олуг шәхесләребезнең берсе. Аның иҗат мирасы күпкырлы алмаз кебек: һәр тикшерүче, һәр галим үзенең эзләнүләр кырын таба, һәрбер заман укучысы Г.Ибраһимов әсәрләреннән күңеленә якын нурлар ала. “Г.Ибраһимов әсәрләре инде өйрәнелгән, яңа ачышлар ясау мөмкин түгел”, - дип кем генә әйтә алыр икән?!

Без Г.Ибраһимов әсәрләрендә күпмәгънәле сүзләрнең стилистик кулланылышын өйрәндек. Һәм түбәндәге нәтиҗәләргә килдек.:

- күпмәгънәле сүзләрнең кулланыш сферасы бик киң;
- күпмәгънәле сүзләр Г. Ибраһимов иҗатында да, автор хикәяләвендә дә, герой – персонажлар сөйләмендә дә уңышлы кулланыла. Геройларның портретын, эчке дөньясын, рухи халәтен тасвирлауга зур ярдәм күрсәтәләр;
- Г.Ибраһимов күпмәгънәле сүзләрне уңышлы, оста куллануы белән әсәрне тагын да эчтәлеклерәк итүгә ирешкән.

**Кулланылган әдәбият**


1. Газизова Ф.М. Галимҗан Ибраһимов әсәрләрендә чагыштыру, эпитет һәм метафора //Ф.М.Газизова/ Татар теле һәм әдәбияты. – 5 кит. – ИЯЛИ, 1976. – б. 63-77
2. Г.Ибраһимов Сайланма әсәрләр. – Казан: Татарстан Республикасы “Хәтер” нәшрияты (Тарих), 2002. – 543 б.
3. Ибрагимов Г. Сайланма әсәрләр. 9т/ Г.Ибрагимов. – Т. Казан: Татар.кит.нәшр., 1975. – 616 б.
4. Поварисов С.Ш. Мәтәптә әдәби әсәрнең телен өйрәнү /С.Ш.Поварисов. – Казан: Татар.кит.нәшр., 1976. – 128 б.
5. Сәгыйтов М.Ә. Г.Ибраһимов әсәрләрендә сүз сәнгате //М.Ә.Сәгыйтов / Татар әдәбияты мәсьәләләре. – 6 җыентык. – Казан: КДПИ. 1974. – б.152-182
6. Сафиуллина Ф.С. Татар теленең лексикологиясе. – Казан, 1999. – 264б.



*Шәмсиева Алсу, 10 нчы сыйныф,*
*Татарстан Республикасы Түбән Кама*
*муниципаль районының "6 нчы урта гомуми*
*белем бирү мәктәбе" муниципаль бюджет*
*гомуми белем бирү учреждениесе*
*Җитәкчеләр: Җиһаншина Венера Гавис кызы,*
*Шәйдуллина Тәнзилә Рәхимулла кызы,*
*туган тел һәм әдәбияты укытучылары*


## Әдип Маликовның “Яшьлек утравым” повестеның поэтик ономастикасы

### Кереш

Барлык төр ялгызлык исемнәренең килеп чыгышын, үсешен, ясалыш һәм кулланылыш үзенчәлекләрен өйрәнү белән тел белеменең ономастика дигән тармагы шөгыльләнә. Бу фән безнең илебездә бик нык үсеш алды. Татар телендәге ялгызлык исемнәрен һәм аларның килеп чыгышын өйрәнү белән Г.Ф.Саттаров, Р.И.Хаҗиев,

Ф.Г.Гарипова, Ш.Мәрҗани, К.Насыйри, Һ.В.Йосыпов һәм башка галимнәр шөгыльләнәләр. Бүген дә татар ономастикасыннан фәнни-тикшеренү эшләренә зур игътибар бирелә.

Поэтик ономастика – матур әдәбият әсәрләрендәге барлык төр ялгызлык исемнәрен өйрәнә. Әдип Маликов татар прозасының поэтик ономастикасын үстерүдә матур үрнәкләр барлыкка китерә. Аның әдәби әсәрләрендәге атамалары, исемнәре, геройларның исемнәре мәгънәсенә туры килә, эчтәлекне дөрес һәм тулы ачарга ярдәм итә. Менә шуңа күрә Әдип иҗатындагы атамаларның, ялгызлык исемнәренең кулланылышын, аларның әдәби стильгә, әсәр теленә мөнәсәбәтен тикшерү һәм анализлау максатыннан фәнни-тикшеренү эшенең темасын "Ә.Маликовның "Яшьлек утравым" повестеның поэтик ономастикасы" дип алдык. Бу тема өстендә мәктәбебездә эшләделәр инде. Без исә, аны тагын да тулыландырдык. Эпонимик ясалышка ия атамаларны антропотопонимнарга аерып карадык.

Хезмәтнең **актуальлеге** – атамаларның, ялгызлык исемнәрнең аталу тарихын, ясалышын, кулланылыш һәм үсеш эволюциясен, мәгънәсен өйрәнеп, аларның ясалыш-төзелеш структураларын, лексик-семантик үзенчәлекләрен, этнолингвистик катламнарын тарихи-лингвистик яссылыкта анализ ясау.

Тикшерү **объекты** – Әдип Маликовның "Яшьлек утравым" повестендагы поэтик ономастикасы. Тикшерү **предметы** – Ә.Маликовның "Яшьлек утравым" повестендагы поэтик ономастикасын: атамаларның, ялгызлык исемнәрнең аталу тарихын, ясалыш-төзелеш структураларын, лексик-семантик үзенчәлекләрен, кулланылышын, мәгънәсен өйрәнү.

Әдип Маликовның "Яшьлек утравым" повестен, ономастика өлкәсенә керткән өлешен, әдәби әсәрендә атамаларның һәм ялгызлык исемнәренең кулланылыш үзенчәлекләрен өйрәнү, анализлауны фәнни эшнең **төп максаты** итеп куйдык. Максатка ирешүдә түбәндәге **бурычларны** үтәү күздә тотылды: Ә.Маликовның "Яшьлек утравым" повестенда исемнәрнең стилистик кулланылышын ачыклау, автор файдаланган поэтик антропонимнарга хас булган мәгънә үзенчәлекләрен билгеләү, атамаларның бирелүенә хас сыйфатларны ачыклау. Хезмәттә кулланылган **методлар**: эзләнү, тикшеренү һәм нәтиҗә чыгару методлары, ономастика турында китапханәдә, музейда, интернеттагы фәнни әдәбият белән танышу, өйрәнү, язмаларны редакцияләү.

**Төп чыганаклар** булып Маликовның Ә., Бәйрәмованың Ф.Ә., Гальцев-Безюкның С., Гарипованың Ф.Г., Саттаровның Г.Ф., Хаҗиевның Р.И. фәнни хезмәтләре торды.

Тикшеренүнең **әһәмияте**: ялгызлык исемнәрнең, атамаларның ясалыш-төзелеш структураларын, лексик-семантик үзенчәлекләрен, этнолингвистик катламнарын тарихи-лингвистик яссылыкта өйрәнеп, анализ ясау.

Ә.Маликовның “Яшьлек утравым” повестенда бик күп ялгызлык исемнәр очрый. Аларның күпчелек өлешен антропонимнар һәм топонимнар тәшкил итә. Язучы кулланган күп кенә герой исемнәре килеп чыгышлары белән төрле телләргә карый. Алар арасында ике компоненттан ясалганнары, хәтта беренче компоненты гарәп, икенчесе башка телдән булган исемнәр дә шактый. Әдәби исемнәр әсәр идеясен ачуда, геройларның холык-фигыльләрен һәм төп сыйфатларын күрсәтүдә әһәмиятле роль уйный. Үзләренә хас исем-фамилиягә ия булудан тыш, характерына, тышкы кыяфәтенә, шөгыленә туры килердәй кушаматларны да Ә.Маликов сүз-сурәткә әйләндергән.

Хезмәтнең **структурасы** кереш өлешеннән, төп өлешнең ике бүлегеннән, йомгаклау һәм файдаланылган әдәбият исемлегеннән тора.

**I бүлек. Әдип Малик улы Маликовның тормыш юлы һәм иҗаты**

***Әдип Малик улы Маликов*** (1921-2009) – татар шагыйре, прозаик.

1921нче елның 16нчы августында Башкортстанның Яңавыл районы Югары Чатавылында мөгаллим гаиләсендә туа. Башлангыч белемне ул үз әтисеннән ала, бишенче сыйныфтан башлап күршедәге Ямады авылы мәктәбендә укый. Сигез сыйныфны тәмамлагач, Пермь шәһәрендәге Татар педагогия училищесының икенче курсына укырга керә. Училищеда укыган чорда әдәбият белән ныклап кызыксына башлый.

1939нчы елда училищены тәмамлый. Ул Пермь өлкәсенең Барда районы Солтанай авылы җидееллык мәктәбенә укытучы итеп билгеләнә. Ләкин көзен аны армиягә алалар. Ватан сугышы башлану сәбәпле, Ә.Маликовның гаскәри хезмәт мөддәте җиде елга сузыла. 1945нче елның августында ул разведка төркеме командиры сыйфатында Сахалин утравының көньяк өлешен японнардан азат итү сугышларында катнаша. Бу операциядә үзенә йөкләнгән хәрби бурычны җиренә җиткереп үтәгәне өчен аны «Батырлык өчен» медале белән бүләклиләр. Ә.Маликов иҗат эшен дә онытмый, шигырьләр яза, дивизия газетасында очерк язмаларын даими бастыра. Аның шул дәвердә иҗат иткән зур шигъри әсәре – “Атаудагы хисләр” поэмасы (1945-1946). Армиядән кайткач, Татарстан радиосында әдәби-драматик тапшырулар редакторы булып эшли. 1949нчы елның көзендә Татарстан Язучылар берлеге аны Мәскәүгә М.Горький исемендәге Әдәбият институтына укырга җибәрә.

1955-1960нче елларда Әлмәт шәһәрендә әдәби иҗат берләшмәсе белән җитәкчелек итә. 1963нче елда Әлмәт Язучылар оешмасы барлыкка килә. 1965-1967, 1972-1982нче елларда ул бу оешманың җаваплы сәркатибе булып эшли.

Әлмәт шәһәрендә яшәү Ә.Маликовның иҗатын яңа темалар, яңа хисләр, төсмерләр белән баета. Мәсәлән, “Ташчы”(1956), “Фәрдәнә”(1958), “Гайшә апа”(1959), “Салкын Алан”(1967), кебек поэмалары һәм шигырьләре. “Сахалин язмалары” (1948), “Кайнар

эзләр”(1956), “Без кояшны юлда каршылыйбыз”(1964), “Кембригә юл салучылар”(1965), “Гашыйклар юлы”(1978) кебек китаплары, авторның солдат еллары белән бәйле Сахалин турындагы “Яшьлек утравым” исемле повесть-истәлеге (1972) заманның сәнгатьчә документаль елъязмалары буларак шул чор татар әдәбиятының үзенчәлекле бер сәхифәсен тәшкил итәләр.

Ә.Маликов – 1959 елдан СССР (Татарстан) Язучылар берлеге әгъзасы. Ә.Маликов 1945 нче елны “За отвагу” медаленә, 1981 елны “Знак Почёта” орденына һәм “Хөрмәтле Әлмәт гражданины” исеменә лаек була. Әдәбият өлкәсендәге хезмәтләре өчен Ә.Маликов 1979 нчы елда “Татарстанның атказанган мәдәният хезмәткәре” дигән мактаулы исемгә лаек була.

Ул 2009нчы елның 23нче апрелендә Әлмәттә вафат була һәм җирләнә.

## II. Әдип Маликовның “Яшьлек утравым” повестеның поэтик ономастикасы

### 2.1. Әсәрнең антропонимиясе

Тел белеменең ономастика дип йөртелә торган бер тармагы бар. Ул кеше исемнәрен, фамилияләрен һәм кушаматларны, күк җисемнәренең һәм географик урыннарның, елга-суларның, мифологик затларның һ.б. исем-атларын өйрәнә. Ономастика фәнендәге казанышлар тел тарихын өйрәнүдә, халыкның этник тарихын яктыртуда зур әһәмияткә ия. Поэтик ономастика – матур әдәбият әсәрләрендәге ялгызлык исемнәрен өйрәнә торган тармак.

Антропонимика – кеше исемнәре, ата исеме, кушамат, псевдоним, криптонимнарның (яшерен исем) килеп чыгышын, төзелеш-ясалыш, кулланылыш үзенчәлекләрен, үсеш-үзгәреш закончалыкларын, антропонимнар йөртә торган төрле мәгълүматны өйрәнә торган ономастиканың бер тармагы. Татар телендә антропонимика фәне XX гасырның 60-70 елларында үсә башлый. Моңа кадәр аерым мәгълүматлар тупланып килсә дә, тирәнтен фәнни тикшеренүләр Саттаров Г.Ф. тарафыннан башкарыла.

Маликовның “Яшьлек утравым” повестеның антропонимикасы бик бай.

**Әсәрдә төрки-татар чыгышлы исемнәр бар:** ***Биктимер*** – ир бала бәк кебек хаким һәм тимер кебек нык булсын дип теләп кушылган. ***Сөембай*** – Сөем бай, сөекле бай (бала). ***Тимеркәй*** – тимер сүзенә *-кәй* иркәләү-кечерәйтү кушымчасы ялганып ясалган исем. ***Targetташ*** – 1. Гранит, кыя ташы; 2. Так таш, ягъни ялгыз таш. ***Тукай*** – “тук” (туенган, тулы, бөтен) сүзенә *-ай* атау-эндәшү-боеру кушымчасы ялганып ясалган.

**Татар исемнәре дә кулланыла:** ***Йолдыз*** – йолдыз кебек якты, нурлы, күркәм. ***Миңлекәй (-вич)*** – *миңле* сүзенә *–кәй* иркәләү-кечерәйтү кушымчасы ялганып ясалган исем.

**Әсәрдә гарәп-фарсы теленнән кергән исем дә бар:** ***Мөхәммәтша (Брангулов)*** – “Мөхәммәт” + “шаһ” сүзләреннән барлыкка килгән.

**“Яшьлек утравым” әсәрендә гарәп теленнән кергән исемнәр бик күп:** ***Афзал*** – иң лаеклы, иң кадерле. ***Әхнәф*** – иң дөрес сүзле; сер саклаучы. ***Баттал*** – 1. Батыр, каһарман; фидакарь сугышчы; 2. Буш, эшсез. ***Габдулла*** – Аллаһ колы, Аллаһ бәндәсе. ***Гали Хуҗи*** – бөек, олы, югары дәрәҗәле; кыйммәтле; куәтле, көчле, кодрәтле; һәрнәрсәдән өстен һәм бөек. Аллаһының эпитеты. ***Кәрим*** – юмарт, рәхимле, киң күңелле; кадерле; асыл зат. ***Мәҗит*** – гарәп теленнән “куәтле, бик көчле” дигәнне аңлата. ***Миңнулла*** **–** Алланың миңлесе. ***Салих*** – яхшы, изге, игелекле. ***Сәйфи*** – кылычлы кеше. ***Тимергалин*** – “Тимер”+“Гали”, шушы исемнән Тимергалин фамилиясе ясалган. ***Фатих*** – ачучы, башлап җибәрүче; яулап алучы, җиңүче. ***Фәтхи*** – җиңүгә ирешкән; җиңү яулаучы; җиңү. ***Хәниф*** – тугры күңелле; чынны сөюче. ***Зөһрә*** – гарәп теленнән “ялтырый торган, якты”. ***Мәйсәрә*** – байлык, муллык; иминлек. ***Сәгыйдә*** – бәхетле, рәхәт яшәүче; мул тормышлы.

**Әсәрдә грек теленнән кергән исемнәр кулланыла:** ***Алексей*** – бу исем борынгы грек “алекс” сүзеннән килеп чыккан һәм яклау, саклаучы, ярдәмче дигәнне аңлата. ***Анатолий*** – “көнчыгыш”; чыгышы - Кече Азиядән. ***Аркадий*** **–** чыгышы белән Аркадиядән (Пелопоннес ярым-утравындагы өлкә). Русларга Византиядән христианлык белән килгән. ***Леонид*** – “арыслан нәселе”. ***Петр*** **–** исем борынгы грек “Петра” сүзеннән чыккан, “кыя, таш кисәге”.

**Әсәрдә славян теленнән кергән исемнәр дә урын алган:** ***Люба*** (***Антошина)*** – бу исем славян сүзе “мәхәббәт” сүзеннән килеп чыккан. ***Володя*** **–** урта гасыр җыелма исеме, славян сүзеннән хуҗа булу, тынычлык.

**“Яшьлек утравым” повестенда алынма исемнәр дә очрый. Француз теленнән кергән исем бар:** ***Марат*** – Француз буржуаз революциясенең юлбашчыларыннан берсе Жан-Поль Марат хөрмәтенә татарларда 1930 еллардан соң киң таралыш алган исем.

**Борынгы рим теленнән кергән исемнәр кулланыла:**

***Антон*** – Антонии нәселеннән борынгы рим исеме, шәхси исемгә әйләнгән. ***Валерий (Адмакин)*** – борынгы рим исеме (латинча “валериус” – “көчле”). Русларга Византиядән христианлык белән килгәннәр.

**Әсәрдә рус хатын-кыз исеме дә бар:** ***Нина (Заречная)*** – борынгы исем. 3000 елдан артык элек Двуречьеда документлаштырылган. Грузиядә әби патша исеме. Безнең эраның IV гасырында Грузиядә христиан динен керткән өчен аны әүлиялар исемлегенә язып куялар. XVIII гасыр ахырында йогынты ясау аркасында Грузия Россиягә кушылгач, бу исем русларга еш куела башлый.

**“Яшьлек утравым” повестенда кушаматлар да кулланылган:** ***“Болан, “Саескан”*** **–** разведчиклар, Сахалин дивизиясе солдатлары. Алар махсус уку йортын тәмамлаганнар, японча сөйләшергә өйрәнгәннәр.

Димәк, татар теле – бөтендөнья күләмендә кеше исемнәренә иң бай, кеше исемнәре хәзинәсе иң мул булган телләрнең берсе.

### 2.2. Әсәр топонимиясенә лексик-семантик анализ

Ономастиканың иң әһәмиятле тармакларыннан берсе – топонимика. Ул телебездәге географик атамаларны (авыл, шәһәр, урман һ. б. исемнәрен) тикшерә. Ә.Маликовның “Яшьлек утравым” повестенда урын алган топонимнарны бу төр үзенчәлекләре буенча 2 зур төркемгә аерабыз: 1) апеллятив лексикадан ясалган атамалар; 2) эпонимик ясалышка ия атамалар. Ономастика фәнендә күмәклек исемнәреннән ясалган ялгызлык исемнәрен апеллятив, ә килеп чыгышлары башка класска караган ялгызлык исемнәрен эпонимик ясалышка кертәләр.

#### 2.2.1. Апеллятив лексикадан ясалган топонимнар

Апеллятив лексикадан, ягъни уртаклык исемнәреннән ясалган атамаларның үзләрен берничә лексик-семантик төркемгә бүлеп карый алабыз: географик терминнардан ясалган атамалар; фитонимик терминнардан ясалган атамалар; халыкның тормыш-көнкүреше белән бәйле атамалар; гидронимнар.

##### 2.2.1.1. Географик терминнардан ясалган атамалар

Җирле географик терминнар бай сүзлек хәзинәсенең бер өлеше булып ята. Алар әйләнә-тирәнең табигате, халыкның теле, тормыш-көнкүреше, тарихы турында мәгълүмат бирәләр. Георгафик терминнарга нигезләнеп ясалган атамалар топонимиканың нигезен тәшкил итәләр, атамаларның эчтәлеген чагылдыралар.

Ә.Маликовның “Яшьлек утравым” повестенда *тау* орографик терминына нигезләнеп ясалган атамалар бар. ***Урал таулары.*** *Урал,* Ауропа һәм Азияне аерып торучы таулар системасы һәм шул исемдәге елга. Урал таулары атамасының килеп чыгышы турында сүз күп булса да, бәхәсләр әле тынмаган, һәм соңгы сүз әйтелмәгән. Безнеңчә, Урал атамасы борынгы сүз, һәм аны иске сүзләр китабыннан эзләргә кирәк. Мәсәлән *ор, ур, үр* сүзләре төрки халыкларда *холм, гора, возвышенность, берег, обрыв* һәм тагын әллә ничә төрле мәгънәдә йөргәннәр. *Әл* сүзе элек шул ук *ил* сүзен белдергән. Шулай итеп, *ор әл, ур әл, үр әл* – болар барысы да “горная страна”, “горный край” мәгънәсен аңлатканнар. Чыннан да, “Книга Большому Чертежу” дигән китапта (1627 ел) тауның исеме *Оральтова (Уральтова*) *гора* дип китерелгән. Монда йомшаклык билгесе “ә” урынына сүзне нечкәртү өчен куелган булырга тиеш. Димәк, *Урал (Үрәл) – Тау иле.* ***Альп таулары*** – 1760-1794нче елларда швейцар О.Соссюр белән өйрәнелгән Көнбатыш Европадагы таулар, кельт сүзеннән “биек тау”, “калкулык”. ***Набил таулары*** – нивхларның үзгәртелгән “нга-биль” сүзеннән алынган, русчага “большие нерпы” дип тәрҗемә ителә. ***Хинган таулары*** – нивхлар теленнән тәрҗемә иткәндә “агач кирәмәт”, кайбер халыкларның табыну урыны.

***Сихотэ-Алин таулары*** – маньчжур чыгышы - “яр умырткалыкны” аңлата; кытай риваяте буенча: “си” – көнбатыш, “хэ” – елга, “та” – зур һәм маньчжурның “алинь” – умырткалык.

**2.2.1.2. Фитонимик терминнардан ясалган атамалар**

Фитонимика – урман, аның төрләрен, агач һәм агачлыкны, үләнне һәм аның төрләрен белдерүче терминнарны өйрәнүче тармак.

Һәрбер төбәктә теге яки бу үсемлек, куаклык, яисә агачның күп булып үсүенә бәйле рәвештә төрле атамалар барлыкка килгән.

“Әдип Маликовның Яшьлек утравым” повестенда урман, аның төрләрен, агач һәм агачлыкны, үләнне һәм аның төрләрен белдерүче фитонимик терминнарга нигезләнеп ясалган түбәндәге топонимнарны күрсәтә алабыз. ***Камышлы тау*** – беренче күчеп килгән урыслар тау битләрендә котырып үскән бамбукларга камыш дип исем биргәннәр. ***Брусничная сопкасы*** – әсәрдә сурәтләнгән тау атамасы. ***Курил лимоннигы*** – Курил утравында үсә торган агач исеме. ***Алма-Ата*** – Казахстанның иң зур шәһәре, “Южная Столица” исеме белән танылган.

**2.2.1.3. Халыкның тормыш-көнкүреше белән бәйле атамалар.**

Әдип Маликовның “Яшьлек утравым” повестенда халыкның тормыш-көнкүреше белән бәйле атамалар бик күп. ***Себер*** **–** Россия Федерациясенең үзәгендә урнашкан зур географик регион. ***Татарстан*** **–** Россия Федерациясенең субъекты, республика. Идел буе федераль төбәгенә керә. ***Казан*** **–** Казан елгасының атамасы беренчел, ә Казан шәһәре исеме икенчел. Димәк, шәһәр исеме Казан елгасы атамасыннан алынган. ***Хәйхә шәһәре*** **–** Япониядәге шәһәр исеме. ***Маньчжурия*** **–** Кытайның Төньяк-Көнчыгышындагы тарихи өлкә. ***Харбин шәһәре*** **–** Кытайның төньяк-көнчыгыш өлешендәге шәһәр. ***Портсмут*** **–** Америка Кушма Штатлары шәһәре. ***Тойохара*** – шәһәр исеме, япончадан “муллык чыганагы”, “уңдырышлы кыр” дигәнне аңлата. ***Карафуто губернасы*** – японнар Сахалин утравын гасырлар буе Карафуто, дип атап йөрткәннәр. Карафуто – Көнчыгыш халыклары телендә “кара” – “черный” дигәнне аңлата. 1613 елны Сахалин утравының көньягында тикшерүләр үткәргән япон экспедициясе бу утрауны Татар иленең бер өлеше, дип уйлаган һәм аңа Карафуто исемен биргән. ***“Европа авылы”*** **–** самурайлар коллыгына төшкән татар авылы. ***“Госмания” мәдрәсәсе*** **–** Казандагы “Кызыл мәчет” (Солтан мәчете, Җиһанша бай мәчете, Госман мәчете, Сигезенче җамигъ мәчет) мәхәлләсенең мәдрәсәсе. ***Сахалин утравы*** **–** кайбер кытай чыганакларында Сахалин атавы Шуйдада, дип тә атала, бу да Ерак Көнчыгышта яшәгән борынгы татарларның бер атамасы, ягъни, “су татарлары” дигәнне аңлата. Сахалин утравының тагы борынгыдан маньчжур-татар телендә Сагалян ула, дип аталуы да билгеле, аның да тамырында саклар суы, сүзтезмәсе ята.

**2.2.1.4. Гидронимнар**

Гидронимика – топонимиканың бер тармагы. Су чыганакларының исемнәрен туплый, аларга тарихи-лингвистик яссылыкта анализ ясый. Гидронимнар ономастиканың иң борынгы тармагын тәшкил итәләр. Шуңа күрә аларны өйрәнү татар халкының килеп чыгышы мәсьәләләрен хәл иткәндә гаять әһәмиятле мәгълүматлар бирә.

Әдип Маликовның “Яшьлек утравым” повестенда гидронимик атамалар да бик күп. ***Тын океан*** – португалияле диңгез сәяхәтчесе Фернандо Магеллан 1520-1521 елларда 3 ай һәм 20 көн йөзү вакыты эчендә океанда тыныч һава торышы өстенлек иткәнгә күрә шундый исем кушыла. ***Кара диңгез*** – беренче фараз буенча: Азия илләрендә дөнья яклары төсләр белән билгеләнгәнгә, “кара” төньякны билгели, тиешенчә Кара диңгез – Төньяк диңгез. Башка фараз буенча: озак вакытка 150 м тирәнлектәге суга төшерелгән металл әйберләр хим күкертле водород аркасында кара төс белән каплана. ***Идел елгасы –*** болгар-татарларда “идел” термины “зур су, зур елга” төшенчәсен белдерә; елганың борынгы исеме – Итил, русчасы – “Волга”. Н.Исәнбәт **ат-ил** яки **ил-ат** (“ат менгән ирләр кулында идарә ителгән ил”) тәгъбиреннән Ат-ил мәмләкәте, Атил шәһәре һәм шул шәһәр янында диңгезгә койган Атил (Идел) елгасы атамаларын китереп чыгара. Әлеге тарихи мәгълүматлар, нигездә, чынбарлыкка туры килсә дә, Атил (Идел) елгасы атамасы **ат-ил** тәгъбиреннән алынган дип карау Атил гидронимы белән **ат-ил** тәгъбире әйтелешендәге охшашлыкка, аваздашлыкка, ягъни “халык этимологиясе”нә нигезләнеп фикер йөртүгә корылган. ***Поронай елгасы*** – айна телендә “Поро” – зур, “Най” – елга дигәнне аңлата. ***Одер елгасы*** – балтийский “ардас” сүзеннән – “бүлек, чик, бәхәс”. ***Синай-гава елгасы*** (елганың японча исеме). Харамитогэ тау итәге буйлап аккан саз елгасы. Авыр сугыш көннәрендә солдатлар аңа башка исем тагалар: Проклятая” – “йөзе кара”. ***Байкал куле*** – “бай күл”, төрки теленнән “бай” – “богатый” һәм “куль” – “озеро” сүзләреннән барлыкка килгән. Борынгыдан Байкал янында яшәүче һәр халык бу күлне үзенчә исемләгән: кытайлар – “Бэйхай” – “төньяк диңгез” дип, эвенклар – “Ламу” – “диңгез” дип, бурят-монголлары – “Байгаал-далай” – “зур сулык” дип атаганнар.

### 2.2.2. Эпонимик чыгышлы атамалар

Эпонимик ясалышка ия атамаларны түбәндәге төркемнәргә аерып карарга мөмкин: антропотопонимнар, этнопотопонимнар. Без исә, антропотопонимнарны карап китәрбез.

#### 2.2.2.1. Антропотопонимнар

Анторопотопонимнар – ул кеше исемнәренә нигезләнеп ясалган атамалар.

Атамаларның бер төре антропотопонимнарга нигезләнеп ясалганнар. Мондый типтагы атамалар шәһәр топонимиясе өчен бигрәк тә характерлы. Әдип Маликовның “Яшьлек утравым” повестенда антропонимик атамалар бик күп. ***Отомари (ягъни, хәзерге Корсаков шәһәре)*** – 1869 елның 31нче июлендә урысларның хәрби посты барлыкка килә, ул башта Муравьев исемен йөртә, аннан Корсаковкага алмаштырыла. Көнчыгыш Себер

генерал-губернаторы Корсаков Михаил Семеновичка (1826-1871) багышлап атала. ***Смирных шәһәре*** – Көньяк Сахалинны азат итүдә катнашучы Советлар Союзы Герое капитан Смирных Леонид Владимирович (1913-1945) хөрмәтенә аталган. ***Буюклы шәһәре*** – Көнъяк Сахалинны азат итү яуында катнашучы Советлар Союзы Герое Буюклы Антон Ефимовичка (1915-1945) багышлап аталган. ***Чехов шәһәре*** – 1890 елда Сахалинга сәяхәт ясаган рус язучысы Чехов Антон Павловичка (1860-1904) багышлап аталган. ***Хасан күле*** – риваять буенча Ерак Көнчыгыштагы сугышта җиңелгәннән соң Хасан Нурула гаскәре өйләренә кайта. Ирекле мародерлар табышы булмас өчен, яралы гаскәриләр чүлләр аша юл үтәләр. Авыр ярасына карамастан, Хасан Нурула үз гаскәрен коткаруны максат итеп куя. Бер төнне гаскәр күл янына чыга һәм шунда туктый. Төн салкын була, Хасанның яралары ялкынсына, гаскәриләр арасында табиб булмагач, озак газаплардан соң хан Хасан Нурула үлә. Икенче иртәдә гаскәриләр кабер казып, үзләренең җитәкчеләрен яр буенда күмәләр. Үлгән хан исеме белән алар шул күлне Хасан күле дип атыйлар.

## Йомгаклау

Барлык төр ялгызлык исемнәренең килеп чыгышын, үсешен, ясалыш һәм кулланылыш үзенчәлекләрен өйрәнү белән тел белеменең ономастика дигән тармагы шөгыльләнә. Бу фәннең тикшеренү өлкәсе ифрат бай һәм кызыклы. Ул кеше исемнәрен, фамилияләрен һәм кушаматларны, георгафик урыннарның, шул җөмләдән елга-суларның, мифологик затларның һ.б. исем-атларын өйрәнә. Ономастика шундый күпсанлы һәм төрле-төрле исемнәрне җыю, тәртипкә салу, аларның килеп чыгышын, тарихи җирлеген аңлату кебек мөһим бурычларны гамәлгә ашыра. Ономастика фәнендәге табышлар тел тарихын өйрәнүдә, халыкның этник тарихын яктыртуда зур әһәмияткә ия.

Топонимика белән антропонимика ономастиканың ике иң мөһим һәм иң зур бүлекләрен тәшкил итәләр. Топонимика барлык төр географик атамаларны (топонимнарны) өйрәнә. Антропонимика – кеше исемнәре, ата исеме, кушамат, псевдоним, криптонимнарның килеп чыгышын, төзелеш-ясалыш, кулланылыш үзенчәлекләрен, үсеш-үзгәреш закончалыкларын, антропонимнар йөртә торган төрле мәгълүматны өйрәнә торган ономастиканың бер тармагы.

Әдип Маликов татар прозасының поэтик ономастикасын үстерүдә матур үрнәкләр барлыкка китерә. Аның әдәби әсәрләрендәге атамалары, исемнәре, геройларның исемнәре мәгънәсенә туры килә, эчтәлекне дөрес, тулы ачарга ярдәм итә. Атамаларның, ялгызлык исемнәрнең аталу тарихын, ясалышын, кулланылыш һәм үсеш эволюциясен, мәгънәсен өйрәнү, аларның ясалыш-төзелеш структураларын, лексик-семантик үзенчәлекләрен, этнолингвистик катламнарын тарихи-лингвистик яссылыкта тирән анализ ясарга ярдәм итә.

Бу фәнни эштә Әдип Маликовның “Яшьлек утравым” повестен, ономастика өлкәсенә керткән өлешен, әдәби әсәрендә атамаларның һәм ялгызлык исемнәренең кулланылыш үзенчәлекләрен өйрәндек һәм анализладык. Максатка ирешүдә билгеләнгән бурычларны үтәдек: Ә.Маликовның “Яшьлек утравым” повестенда исемнәрнең стилистик кулланылышын ачыкладык, автор файдаланган поэтик антропонимнарга хас булган мәгънә үзенчәлекләрен билгеләдек, атамаларның бирелүенә хас сыйфатларны ачыкладык.

Ә.Маликовның “Яшьлек утравым” повестенда бик күп ялгызлык исемнәр очрый. Аларның күпчелек өлешен антропонимнар һәм топонимнар тәшкил итә. Повестьтагы атамалар, барлык төр ялгызлык исемнәре төп максатка ирешүгә – тормышны реалистик рәвештә сәнгатьчә югарылыкта сурәтләргә, дөрес һәм тулы итеп чагылдырырга ярдәм итә.

**Файдаланылган әдәбият исемлеге**


1. Бәйрәмова Ф.Ә. Сахалин утравы һәм татарлар. – Фәнни-тарихи язма / Ф.Ә.Бәйрәмова. – Казан: “Аяз” нәшрияты, 2014. – 264 б.
2. Гальцев-Безюк С. Топонимический словарь Сахалинской области / С.Гальцев-Безюк. – Южно-Сахалинск, 1992. – http://www.balonline.ru/slovar
3. Гарипова Ф.Г. Исемнәрдә – ил тарихы / Ф.Г.Гарипова. – Казан: Татар. кит. нәшрияты, 1994. – 264 б.
4. Гомәр Саттар-Мулилле. Татар исемнәре ни сөйли? (Татар исемнәренең тулы аңлатмалы сүзлеге). – Казан: “Раннур” нәшрияты, 1998. – 485 б.
5. Маликов Ә. Яшьлек утравым: повесть-истәлек / Ә.Маликов. – Казан: Татар. кит. нәшрияты, 1998. – 192 б.
6. Хаҗиев Р.И. Ата-бабаларыбыз мирасы: Монография / Р.И.Хаҗиев. – Яр Чаллы, 2010. – 203 б.
7. Хаҗиев Р.И. Татар ономастикасыннан фәнни хезмәт язуга методик кулланма (югары с. укучылары өчен)/Р.И.Хаҗиев.– Яр Чаллы, 2011.– 64 б
8. http://kitap.net.ru/hujin/9.php
9. http://tt.wikipedia.org/wiki/Антропонимика
10. http://tt.wikipedia.org/wiki/Әдип_Маликов

*Шарифуллин Данир,5 нче сыйныф,*
*Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районының Бакый Урманче исемендәге “2 нче гимназия” муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениясе*
*Җитәкчесе: Зарипова Аниса Газизулловна, туган тел һәм әдәбияты укытучысы*

# Халкым җәүһәрләре – зур мирас

## Кереш

Фольклор – күпкырлы һәм бай милли иҗат. Аның милли табигате сурәтле-сәнгатьчә фикерләвендә ачык чагыла. Гасырлар дәвамында татарларда төрле фольклор жанрлары формалашкан. Бу система халыкның яшәешен һәм күпкырлы рухи тормышын, шәхеснең тышкы һәм эчке дөньясын иңләп алырга һәм күптөрле формаларда гәүдәләндерергә мөмкинлек биргән. Хәзерге вакытта да халык бу гүзәл хәзинәләрдән файдалана. Әдәби уку дәреслекләрендә “Халык авыз иҗаты” дигән бүлекне өйрәнү - миңа бик мавыктыргыч булып тоелды. Әлеге бүлекне йомгаклаганда укытучымның “Татар халкының милли хәзинәләре” исемле проект якларга дигән тәкъдиме - мине тирән эзләнүләргә этәрде дә инде. Фольклорның милли-этник үзенчәлекләрен, милли йөзен һәм байлыгын өйрәнәсе килү теләге туды миндә.

**Фәнни - тикшеренү эшенең темасы:** «Халкым җәүһәрләре – зур мирас».

**Максат:**

- татар фольклор әсәрләре килеп чыгышын өйрәнү;
- фольклор, аның жанрлары турында кыскача бәян итү.

**Бурычлар:**

- фольклор темасына фәнни әдәбиятны өйрәнү;
- жанрларның килеп чыгышы, хәзерге көндәге ролен билгеләү;
- үземнең гаиләмдә татар фольклоры тоткан урынны ачыклау;
- замана балалары өчен татар фольклоры ролен ачыклау;
- “Татар халык авыз иҗаты” темасына лэпбук ясау.

**Тикшерү объекты** булып татар фольклор әсәрләре тора.

**Гипотеза:** хәзерге заманда яшьләр арасында татар фольклоры әсәрләренә кызыксыну кими.

Эзләнүләр барышында шундый **методлар** кулланылды :

- системалы анализ ясау;
- күзәтү;
- анкета үткәрү;
- әдәбият һәм интернет чыганакларны өйрәнү;
- килеп чыккан нәтиҗәләрне чагыштыру.

**Теманың актуальлеге:** татар фольклорында халкыбызның тарихы, тормыш-көнкүреше, йола-гадәтләре, авыз-тел һәм музыка иҗаты, бию-хореографиясе, шулай ук сурәтле-образлы фикерләве бирелгән.

Халкыбызның бай иҗатын тиешенчә җыйнау һәм фәнни өйрәнү хәзерге көннең иң мөһим бурычларыннан берсе булып тора.

## Бүлек 1. Төп өлеш. Фольклор әсәрләре тарихыннан

### 1.1. Фольклор төшенчәсенә билгеләмә.

Фольклор сүзе (инглизчәдән *folk+lore* – халык хикмәте, халык акылы) – XIX ахырында барлыкка килеп, төрле илләрдә киң кулланышка кергән халыкара атама.

Русларда ул, башлыча, халыкның сүз сәнгатен, ягъни авыз-тел иҗатын белдерүче термин буларак кулланыла.

Татар фән дөньясында да бу терминнарның мәгънәсе һәм кулланылышы руслардагы шикелле.Аның язма әдәбияттан аермалы, үзенә хас үзенчәлекләре, асыл сыйфатлары бар:

1) телдән-телгә күчеп яшәве белән аерылып тора һәм телдән сөйләнә яки телдән башкарыла торган иҗат;
2) коллектив-күмәк иҗат та, ягъни аны тудыруда һәм эшкәртүдә күп кенә халык вәкилләре катнаша. Тыңлаучыларның күңеленә хуш килгәндә, ул телдән-телгә күчеп китә, шомара, камилләшә;
3) күп вариантылылык. Телдән-телгә күчеп йөргәндә яки төрле кешеләр авызыннан сөйләгәндә, әсәрнең ниндидер бер тотрыклы вариантта гына яшәве мөмкин түгел. Ул төрле үзгәрешләргә дучар була;
4) фольклорда сүз төп рольне уйнаса да, ул сүздән генә торган иҗат түгел, бәлки аерым жанрларда сүзне, музыканы, биюне, театраль тамашаны бергә берләштерә торган синтетик иҗат та;
5) традиционлык һәм дәвамлылык-күчемлелек. Фольклор традиция рәвешендә буыннан-буынга күчеп килә;
6) милли характерда булуы. Бу үзенчәлек аның эчтәлегендә дә, шулай ук формасында бердәй дәрәҗәдә гәүдәләнә. Татар фольклорында үзәнчәлекле милли жанрлар да бар. Бәет белән мөнәҗәт менә шундый жанрлардан.

Фольклорның милли табигате бигрәк тә халыкның сурәтле-сәнгатьчә фикерләвендә ачык күренә. Чөнки фольклор әсәрләрендә кулланыла торган образ-сурәтләр һәр халыкның мифологик традициясенә, яшәеш - мохитенә, көнкүреш үзенчәлекләренә һәм эстетик зәвыгына туры килеп тора. Моңа ышану өчен борынгыдан килгән традицион символларның кайсы халыкта нәрсә белдергәнлегенә игътибар итү дә җитә. Мәсәлән, сары төс безнең фольклорда сагышны, мариларда мәхәббәтне, кытайларда бөеклек-затлылыкны белдерә; кара төс исә бездә кайгыны яки күңелсез-тискәре нәрсәне, ә японнарда шатлык-куанычны аңлата. Яки агачлардан каенны алып карыйк. Русларда сылу гәүдәле кызны, мариларда угылны, мордваларда һәм чувашларда кәләшне, удмуртларда яшь егетне символлаштыручы бу образ татар фольклорында еш кына кайгы-хәсрәт сагышны белдерү өчен хезмәт итә.

**1.2. Фольклор төрләре.**

Фольклорда, язма әдәбияттагы кебек үк, халык иҗаты әсәрләрен тормыш-чынбарлыкны чагылдыру үзенчәлегенә карап, өч төркемгә бүлү, ягъни, фәнни термин белән әйтсәк, өч төргә (русча «род») берләштерү кабул ителгән: эпоска, лирикага һәм драмага.

Татар халык иҗатының һәм традицион классик жанрларының төрләргә мөнәсәбәттә төркемләнүе түбәндәгечә:

- эпик жанрлар: әкиятләр, риваятьләр, легендалар, мәзәкләр;
- лирик жанрлар: уен-бию җырлары, такмаклар, мөнәҗәтләр;
- лиро-эпик жанрлар: бәетләр;
- драма башлангычы белән үрелгән иҗат төрләре: йола поэзиясе, халык уеннары һәм уен-бию җырлары, балалар фольклоры.

**Мәкальләр һәм әйтемнәр.**

“Мәкаль” һәм “әйтем” дигән төшенчәләр гадәттә бергә, янәшә кулланып йөртелә.Чөнки алар арасында охшашлык, уртаклык шактый зур. Алар икесе дә иң кечкенә күләмле халык иҗаты әсәрләре.  Мәкаль һәм әйтемнәрнең яшәү рәвешләре дә охшаш.

Ләкин мәкаль белән әйтем арасында шактый җитди аерма да бар. Бу аерма аларның эчтәлегендә дә, төзелешендә дә, шулай ук вазифа – функцияләрендә дә чагыла. Шуңа күрә дә алар икесе ике жанр булып исәпләнә дә.

Мәкальләрдән аермалы буларак, әйтемнәрдә фәлсәфи – дидактик хөкем чыгару, нәсыйхәт – киңәш бирү функциясе дә юк. Мәсәлән, нинди дә булса гафу итәрлек хата ясаган берәүгә карата «Дүрт аяклы ат та абына», «Кояшта да тап бар», «Үткән эшкә салават», «Беребез дә әүлия түгел» кебек әйтемнәр күңелгә килә. Ә менә теге яки бу эшне вакытында һәм җиренә җиткереп башкарырга кирәклеген түбәндәге мәкальләр искәртеп тора: «Калган эшкә кар ява »,«Бүгенге эшне иртәгәгә калдырма», «Җиде кат үлчә, бер кат кис», «Татарның

акылы төштән соң». Мәкаль һәрчак монологик сөйләмгә корыла, аерым кеше сөйләме составында гәүдәләнә.

**Табышмаклар.**

Табышмаклар текстларын төзүдә җорлык-тапкырлык һәм үткен акыллылык сорала. Бер үк вакытта әлеге жанрларның үрнәкләре, конкрет әсәрләре кечкенә күләмле булулары һәм шигырь-ритм төзелешләренең уртаклыгы буенча да бер-беренә якын торалар. Табышмак кара-каршы әйтешүне ягъни диалогик сөйләшүне һәм кимендә ике кеше (табышмак әйтүче һәм чишүче) булуын күздә тота. Табышмак ул – предмет яки күренешне читләтеп сурәтләүгә корылган һәм тыңлаучылардан шуның нәрсә булуын эзләүгә исәп ителгән башваткыч.

Табышмаклар баланың логик фикерләвен, зирәклеген, тапкырлыгын үстерүнең мөһим бер алымына әверелде. Бу инде, димәк, әлеге жанр, яңа шартларга ярашып, бүген дә яшәвен дәвам итә дигән сүз.

**Әкиятләр.**

Әкият – халык иҗатының бик борынгы жанры, шул ук вакытта әлеге жанрга караучы тылсым һәм могҗизалы уйдырмага нигезләнгән, яки маҗаралы һәм гадәттән тыш хәлләргә - вакыйгаларга корылган фантастик әсәр. Бүгенге көндә бу жанр киң кулланыла. Бала карында чакта ук хатын-кызлар туачак сабыйларына әкиятләр сөйлиләр. Һәр гаиләдә балалар йоклар алдыннан әкиятләр сөйләтә. Мәктәп яшендә, балалар бакчаларында әкиятләрне сәхнәләштерү һаман да дәвам итә.

**Мәзәкләр.**

«Мәзәк» төшенчәсе күп кенә халыклар теленә, шул исәптән русларга грек теленнән кергән «анекдот» дигән жанр атамасына туры килә һәм хәзерге татар фольклор фәнендә нәкъ шул мәгънәдә кулланыла. Хәзерге вакытта мәзәкләр күпчелек радиода кулланыла. “Яңа гасыр” радиосында көн саен мәзәкләр ишетергә, телевизордан “Көлкеханә”, “Шаян-шоу” тапшыруларын карарга мөмкин. Заманыбызның һәм җәмгыятебезнең тискәре якларын фаш итеп, ул бүген дә социаль гаделлек, кешеләр арасында мораль-әхлакый камиллек өчен көрәшә.

**Бәетләр.**

«Бәет» атамасы гарәп телендә ике юллык строфа төрен белдерүче «бәйт» сүзеннән алынган дип исәпләнелә. Бәет жанры фаҗигале һәм героик вакыйгалар, шулай ук гыйбрәтле һәм гадәттән тыш хәлләр уңае белән чыгарылган әсәрләрне берләштерә. Аларның тексты шигъри формада була һәм телдән әйтелә яки көйләп башкарыла.

**Балалар фольклоры.**

Балалар фольклоры – шактый күләмле һәм күпкырлы иҗат. Иң тәүге һәм иң популяры, әлбәттә, бишек җырлары. Аларның төп вазифасы – баланы йоклату, йокыга талдыру. Бүгенге көндә дә әниләр бу жанрдан киң куллана. Мавыктыргычлар, юаткычлар да хәзер дә кулланыла. Балалар тормышында иярмешләр, тел көрмәкләндергечләр, эндәшләрне куллану бүген дә очрый. Балалар иҗатының тагын бер төре - хәрәкәтле уен фольклоры. Монда сүз – текст хәрәкәтле уеннар белән үзара үрелеп килә. Мәсәлән, "Почмак алыш", "Сукыр тәкә", "Йөзек яшереш", "Әйлән-бәйлән" уеннары. Хәзерге көндә бу уеннарны балалар яратып уйный. Алар санамышларны бик яхшы беләләр, үз уеннарында еш файдаланалар.

**Йола фольклоры.**

Татар халык календаре, башка халыклардагы кебек, ел фасылларына һәм хуҗалыктагы эшләренә бәйле рәвештә барлыкка килгән. Шуларга бәйле рәвештә йола фольклоры да туган. Кыш көнендә уздырылган Нардуган уңаеннан нардуган җырлары башкарылган. Бу бәйрәм вакытында муллык һәм уңышлы ел килүен теләп, камыр ашлары пешергәннәр, төрлечә күрәзәлек иткәннәр, төрле уеннар уйнаганнар.

Яз көннәрендә үткәрелгән йола-бәйрәм – Нәүрүз. Бәйрәм вакытында авыл яшьләре йорттан йортка кереп, теләкләр теләгәннәр, бүләкләр җыйганнар, хуҗаларга төрле мөнәсәбәтләрен белдергәннәр.

Көзге бәйрәмдә уздырылган Сөмбелә бәйрәмендә халык мул сый-ризык әзерләп урамга чыккан, төрле уен-тамашалар уздырган.

Ә Сабан туе йолалары борын заманнан хәзергә кадәр үтәлеп килә.

Гаилә-көнкүреш йолалары, туй йолалары авыл җирендә сакланып калган. Авылларда бу йолаларга аеруча игътибар итәләр.

## Бүлек 2. Фәнни-эзләнү өлеше

### 2.1. Замана балалары өчен татар фольклоры роле .

Без замана балалары - халкыбызның киләчәге безнең кулда. Ә без үзебезнең үткәнебезне беләбезме соң? Татар фольклоры турында яшьтәшләремнең белемнәрен беләсем килде. Шушы максаттан чыгып, мин тикшереүемне өч буында үткәрергә булдым. Мәктәпкәчә яшьтәгеләр, сыйныфташларым, югары уку йорты студентлары минем тикшерү объектларына әверелде. Һәр буын вәкиленә анкета сораулары тәкъдим ителде (Кушымта 1). Сорау алуларны анализлап, диаграмма төзелде. Сорау алуны энем йөри торган балалар бакчасында, гимназиянең 5 г сыйныфында, әнием эшли торган көллияттә үткәрдем. Анкета нәтиҗәләре күрсәткәнчә, мәктәпкәчә яшьтәгеләр татар фольклоры әсәрләре буларак әкиятләрне, табышмакларны әйттеләр, күпләре бу сорауга җавап бирә алмады (Кушымта 2).

Сыйныфташларымның җаваплары бераз күңелгә җылылык өстәде. Татар фольклоры әсәрләре буларак әкиятләр, табышмаклардан тыш, мәкаль һәм әйтемнәрне, такмакларны, бишек җырларын, "Сөмбелә" бәйрәмнәрен атадылар. (Кушымта 3).

Сорау алулар аша көллият студентларының татар фольклоры буенча белемнәренең бай икәненә ышандык. Алда әйтелгәннәргә өстәп, алар бәетләр, йола фольклоры, балалар фольклоры турында да әйтеп уздылар. (Кушымта 4).

Анкета нәтиҗәләре шуны күрсәтә: татар фольклоры турында белемнәре кече яшьтән үк бирергә, фольклор үрнәкләре белән балачактан таныштырырга кирәк.

**2.2. Безнең гаиләдә татар фольклоры тоткан урын .**

Милли тәрбия ул гаиләдән башлана. "Ә безнең гаиләбездә татар фольклоры әсәрләре нинди урынны алып тора икән?" - дигән сорау белән эзләнүләр үткәрдем. Мамадыш районы Түбән Сон авылында яшәүче дәү әти һәм дәү әнием белән әңгәмәләрдән мин түбәндәгеләрне белдем: бишек җырлары белән әнием абыемны, мине һәм энемне йоклаткан. Дәү әнием үзенең кызыклы әкиятләрен сөйләп юаткан. Авыл җирендә исә, йола фольклоры зур үсешкә ия булуын аңладым. Моңа "Каз өмәсе" кичәләре, "Сабантуй" бәйрәмнәре ачык мисал булып тора.

Моңа минем күңелем сөенде, халкым өчен горурлык хисем артты. Димәк әле, авылларга кунакка кайткач, безнең буын балалары бу милли фольклор үрнәкләре белән таныша алалар дигән өмет бар.

**2.3. "Татар халык авыз иҗаты" темасына лэпбук ясау .**

Татар фольклоры турында белемнәре кече яшьтән үк бирергә, фольклор үрнәкләре белән балачактан таныштырырга кирәк. Татар телендә иҗат ителгән күрсәтмә әсбапларның аз булуын истә тотып, мин "Татар халык авыз иҗаты" темасына лэпбук ясарга булдым. Эзләнү вакытында табылган белешмәләрне бер җирдә туплау өчен бу бик уңайлы ысул булды. Әлеге хезмәтем минем балалар бакчасында тәрбияләнүчеләргә, башлангыч сыйныф укучыларына татар фольклоры әсәрләре турында белемнәрен киңәйтергә ярдәм итәр дип өметләнеп калам.

**Йомгаклау**

Хәзерге заманда яшьләр арасында татар фольклоры әсәрләренә кызыксыну кими дигән фаразлавым чынга ашмады. Фәнни-эзләнү эшем вакытында, мин шундый нәтиҗәгә килдем: шөгыльләрдә, музыка залында еш кына балалар табышмаклар әйтешә, төрле әкиятләр тыңлыйлар, татар халык уеннары уйныйлар, санамышлар, тел көрмәкләндергечләр өйрәнәләр. Сәнгать, гореф-гадәтләр, милли йолалар милләт тарихы белән тыгыз бәйләнгән.

Татар фольклорында халкыбызның тарихы, тормыш-көнкүреше, йола-гадәтләре, мифологиясе бирелгән.

Халкыбызның бай иҗатын тиешенчә җыйнау һәм фәнни өйрәнү хәзерге көннең иң мөһим бурычларыннан берсе булып тора.

Хәзерге вакытта милли йолаларга, гореф-гадәтләргә игътибар нык артты. Татар теле һәм әдәбияты дәресләрендә генә түгел, шулай ук башка дәресләрдә дә, милли йолаларны, татар фольклоры үрнәкләрен куллану уңай нәтиҗәләр бирә.

Без мавыгабыз, иҗат итәбез, эзләнәбез, димәк халкыбызның милли йолалары саклана әле, дигән өмет яши күңелләрдә. Шуны онытмаска кирәк: милли рух – акыл һәм гүзәллек, зәвык һәм әхлак, хезмәт һәм туган җиргә мәхәббәт тәрбияләү чарасы ул.

**Әдәбият:**


1. Акберова А.Г.Мәкальләр.-Алабуга, 2003

2. Бакиров М.Х. Татар фольклоры.- Казан: “Мәгариф” нәшрияты, 2008

3. Миңнуллин К.М., Кәлимуллин Җ.Х., Урманче Ф.И. Риваятьләр һәм легендалар.- Казан: “Мәгариф” нәшрияты, 2001.

4. Миңнуллин К.М., Кәлимуллин Җ.Х., Урманче Ф.И. Халык афоризмнары.-Казан: “Мәгариф” нәшрияты, 2002.

5. Хәбибуллина З.Н., Фәрдиева Х.Г., Хуҗиәхмәтов Ә.Н. Татар әдәбияты, 9 нчы сыйныф.- Казан: “Мәгариф” нәшрияты, 2005.

*Шәйхетдинова Рүзилә, 5 нче сыйныф,*
*Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районының "6 нчы урта гомуми белем бирү мәктәбе" муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесе*
*Җитәкчеләр: Җиһаншина Венера Гавис кызы,*
*Сабирова Ралена Даим кызы,*
*туган тел һәм әдәбияты укытучылары*

# Туфан Миңнуллин әсәрләрендә мифик образлар

## Кереш

Татар әдәбиятында бик күп мифлологик образлар кулланыла. Безнең көннәрдә мифларның төп яшәү рәвеше халык авыз иҗатында күзәтелә. Язучылар әсәрләрендә мифларны шактый күп кулланалар, алар ярдәмендә әсәр эчтәлеген ачалар.

Татар драматургиясендә күренекле урын тоткан язучы Т.Миңнуллин да мифик образларны кулланып, әсәрләренең эчтәлеген кызыклы итеп укучыга җиткерә.

Без фәнни-тикшеренү эшебезне “Туфан Миңнуллин әсәрләрендә мифик образлар” дип атадык. Теманың актуальлеге түбәндәгеләр белән аңлатыла.. Татар фольклоры, мифология халкыбызның гасырлар буенча тупланып килгән акыл хәзинәсе буларак, зур әһәмияткә ия. Шунлыктан, әдәбиятны аның чишмә башы – фольклор белән бәйләп өйрәнү мөһим.

Максатыбыз – Туфан Миңнуллин әсәрләрендәге мифик образларга күзәтү ясау.

Бурычларыбыз – әлеге темага караган хезмәтләр белән танышу, миф төшенчәсенә аңлатма бирү; мифологик образларны табу, аларның ролен билгеләү.

Без хезмәтебездә, төрле чыганаклардан, сүзлекләрдән, дәреслекләрдән, язучының 10 томлык “Сайланма әсәрләр” циклына тупланган китаплардан файдаланып, алдыбызда куелган бурычны үтәргә тырыштык.

Өйрәнү объекты итеп Т.Миңнуллинның берничә әсәре алынды. Өйрәнү предметы – әлеге әсәрләрдә мифологик образлар, аларның әсәрдә роле.

Хезмәт кереш өлештән, 2 бүлектән, 3 бүлекчәдән, йомгак, әдәбият исемлегеннән тора.

Хезмәтнең беренче бүлеге мифларның әдәбиятта кулланылышын өйрәнүгә багышланды. Беренче бүлекчәсендә без мифларның килеп чыгышы хакындагы карашларны

барладык. Мифларны төркемләүгә тукталдык. Икенче бүлекчәдә татар әдәбиятында мифлар чагылышын күзәттек, күзәтү нәтиҗәләрен куллану мөмкинлекләрен карадык.

Икенче бүлектәге бүлекчә Т.Миңнуллин ижатында мифик образлар кулланылышын ачыклауга багышланды. Драматургның мифик образлар аша әйтергә теләгән фикерләре ачыкланды.

Эшнең фәнни яңалыгы. Әлеге хезмәт – Т.Миңнуллин драматургиясендә мифик образларны татар әдәбиятында тикшерүгә багышланган беренче хезмәт.

## Бүлек 1 Миф һәм аның әдәбиятта кулланылышы

### 1.1 Мифларның килеп чыгышы. Мифларны төркемләү

Татарларда мифология фән буларак формалашкан дип әйтү мөмкин түгел. Чөнки мифлар халыклар формалашканчы ук барлыкка килгәннәр.

Татар мифларын өйрәнүнең төп чыганаклары: мифологик әсәрләр, нигездә хикәятләр; халык иҗатының кайбер жанрлары: табышмаклар, мәкальләр, дастаннар, әкиятләр; туган тел һәм тел берәмлекләре.

Мифлар күптән барлыкка килгәннәр. Кеше әле бу чорда үзен табигать белән бербөтен итеп караган, шуңа күрә үзенең сыйфатларын һәм туганлык хисләрен табигатьтәге бөтен җанлы һәм җансыз нәрсәләргә күчергән. Безнең ерак бабаларыбыз бөтен дөньяны “кешеләштергән”: җир, кояш, үсемлек, хайваннарны җанлы итеп кенә түгел, ә кеше кебек үк яшәүче, фикерли, хисләнә белүче тереклек ияләре итеп, кеше белән үзара кардәш затлар итеп күз алдына китергән һәм мифларын да нәкъ шундый фикерләүгә нигезләп иҗат иткән.

Нәтиҗә ясап әйткәндә, мифларны түбәндәге төркемнәргә бүлеп карыйлар:

1. Хайваннар белән кешеләрнең үзара мөнәсәбәтләрен чагылдырган мифлар;
2. Галәм, Җиһан төзелеше, Ай, Кояш, Йолдызлар белән бәйле мифологик күзәтүләр;
3. Алла, алиһәләр һәм мифологик персонажлар белән бәйле хикәятләр;
4. Түбән мифология персонажлары.

Борынгылар күп санлы фантастик образлар Һәм хикәяләр тудырганнар, Без исә хезмәтебездә Түбән мифология персонажларына тукталырбыз.

### 1.2 Татар әдәбиятында мифлар

Мифология әдәбиятның барлыкка килүенә, үсешенә йогынты ясаган. Әдәби әсәрләрдә мифик образлар бик еш кулланыла. Габдулла Тукайның “Шүрәле”, “Су анасы” әсәрләре, убырлы карчык, дию пәрие, албастылар, җен-пәриләр, өй ияләре турындагы әкиятләр шуңа мисал булып тора.

Кайбер әсәрләрнең эчтәлеге легендаларга барып тоташа, алар гомуми образларны чагылдыралар. Шулай ук халыктан килгән убырлы карчык, су анасы, шүрәле, дию пәрие образлары әдәбиятта, шул исәптән Туфан Миңнуллин әсәрләрендә дә, киң кулланыла.

Төрле халыклар мифологиясен чагыштырып өйрәнү, укучыларның эстетик культурасын, танып белүен, зәвыгын үстерергә, үз халкының, башка халыкларның сәнгатенә ихтирам тәрбияләргә ярдәм итәчәк.

## Бүлек 2 Туфан Миңнуллин иҗатында мифик образлар

### 2.1 "Җанкисәккәем", "Җен алыштырган", "Кәрлә – мәктәп баласы", "Гафият турында әкият" әсәрләрендә мифик образлар бирелеше

Т.Миңнуллинның "Җанкисәккәем" әсәренә тукталыйк. Татар милли мифологиясендә: "Шүрәле – йонлач тәнле, маңгаенда мөгезе булган, кул-бармаклары бик озын ир кеше кыяфәтендәге урман заты", – дип сурәтләнә.

Шүрәле исеме белән бәйле мифологик хикәятләр татар халкында киң таралган. Т.Миңнуллин исә, бу әкият героен үзенчә сурәтли: "шүрәле – урманга сыеша алмаган хыялый җан иясе, әкият герое". "Жанкисәккәем" әсәренең беренче юлларыннан ук шүрәлегә икенче бер караш күзәтелә. Әсәрдәге төп персонажлар – Шүрәлия, Шүрәлинә, Шүркә, Шүрик. Язучы бер шүрәледән генә дә күпме шүрәле исеме чыгарган һәм шуны да әйтергә кирәк: язучы бу әсәрендә аларны шыксыз, килбәтсез итеп түгел, ә матур, тәрбияле, акыллы итеп сурәтли. Бик ямьсез кызны да шүрәле "син матур, синең күңелең матур", дип мактый. Кешеләр дөньясында үз урынын таба алмаган кыз, урманда шүрәлеләр арасында үзенә яклаучы таба. Г.Тукай "Шүрәле"сендә урман сарыгы булган бу җан иясе, без караган әсәрдә киңәш бирүчегә әйләнә.

Т. Миңнуллинның балалар өчен язылган "Җен алыштырган" исемле пьесасында да Шүрәле урман затлары һәм адәм балалары арасында дуслык җебе тоташтыручы тәрбияле образ итеп тасвирлана. Халык хыялында туган шүрәледән аермалы буларак, монда урман хуҗасы кети-кети уйнарга да, кешеләрне алдап, кызык итәргә дә ашкынып тормый. Киресенчә, ул кешеләргә хәленнән килгәнчә ярдәм итәргә тырыша.

Т. Миңнуллинның "Кәрлә – мәктәп баласы" әкият-пьесасында түбән мифология персонажлары (Дию, Убырлы карчык, Кәрлә, Шүрәле) һәм кеше балалары (бу очракта мәктәп директоры Былтыров һәм аның укучылары Шәвәли белән Гөлчәчәк) бар. Бу әсәрдә дә Шүрәле төрле мифик затлар белән кешеләр арасында дуслык-кардәшлек җепләре тоташтыра, явызларны туры юлга бастырырга йөри. Мәсәлән, Диюнең кешеләр булып киенеп, авылга укырга барырга дигән ниятен ишетүгә үк, моңа каршы чыга. Бер карасаң, уку бер дә явыз эш түгел. Ләкин Диюнең теләге бер дә изге түгел шул.

Әлеге әсәр Т.Миңнуллинның “Җен алыштырган” пьесасы белән охшаш. Монда да шүрәле кешеләр янына барып, аларны кисәтергә, урман явызларын күрсәтергә тырыша. Ләкин бу әсәрдә шүрәленең эшен кайсыдыр дәрәҗәдә әләкләү, бергә гомер иткән дусларыңа хыянәт итү, дип уйлап, аңа тискәре яктан да карый алабыз. Ләкин менә шул әләкләү аркасында Дию белән Кәрләнең чынлыкта кем икәнлекләре беленә һәм алар кешеләр белән дуслашып, начар эшләреннән баш тарталар.

Т.Миңнуллин әсәрләрендәге тагын бер персонаж – Убырлы карчык. “Җен алыштырган” әсәрендә дә Убырлы карчык очрый. Монда ул безгә башта ук этикет кагыйдәләрен белүче буларак ачыла. Шуңа да карамастан, бу персонаж укучыларында тискәре эмоцияләр тудырмый. Ә киресенчә, аңа карата нindidер җылы хисләр, елмаю гына барлыкка килә. Нәни укучыларның күңелләренә аның җырлавы, шаярулары бик ошый.

“Гафият турында әкият”тәге геройлар үзләренең төрле булуы белән аерылып тора. Ник дигәндә, монда әкиятче, Гафият, Былтыр исемле кешеләр, Мәче, Куян, Бүре кебек җәнлекләрдән, Шүрәле, Дию, Убырлы карчык, Юха елан, җеннән тыш тагын татар халык әкияте геройлары Үги кыз, Камыр батыр һәм рус әкиятләреннән Балда, Буратино, Карабас-Барабас та бар. Әсәрнең төп герое – Гафият. Ул бик масаючан һәм әкиятләргә ышанмаучы малай. Явыз затлар Гафиятне явызлыкка өйрәтергә тырышалар. Урманда очратып, аны җәнлекләрне рәнҗетергә, үсемлек, кош-кортларга зыян салырга чакыралар. Гафиятнең җырлаганын Шүрәле тыңлап тора, моңа бик кәефе кырыла. Шуннан соң Шүрәле ничек тә булса адәм баласын үзенең бар икәнлегенә ышандырырга, акылга утырту юлын эзли башлый, башка шүрәлеләр янына килеп, ярдәм сорый. Түбән мифология персонажлары, бик явыз булып күренсәләр дә, бу әсәрдә дә Шүрәле уңай образ буларак тасвирлана. Кыяфәте, яшәгән урыны белән халык хыялындагы шүрәле белән туры килсә дә, Т.Миңнуллин аны эчкерсез, ярдәмчел табигать законнарын саклаучы итеп бирә.

Т.Миңнуллин пьесаларында мифик затларны актив куллана. Бу персонажлар балаларда кызыксыну хисен арттыру, китаплар укуга мәхәббәт уяту, татар халык авыз иҗаты, аның мифик затлары белән таныштыру һәм фантазияне үстерү максатыннан әсәрләрдә биреләләр.

Нәтиҗә ясап әйткәндә, Туфан Миңнуллин “Җанкисәккәем”, “Җен алыштырган”, “Кәрлә – мәктәп баласы”, “Гафият турында әкият” әсәрләрендә шүрәле, дию, убыр, юха елан кебек мифик образларны уңышлы кулланган. Алар бүгенге кешеләрдәге сыйфатларны тирәнрәк ачу өчен хезмәт итәләр, әсәрләрнең мавыктыргыч булуын күрсәтәләр.

**Йомгак**

Безгә максатка ирешү өчен күп кенә әдәбият, төрле газета-журнал мәкаләләре, башка язучыларның китаплары, интернеттан төрле сайтлар карау, халык ижаты, фольклор

әсәрләре җыентыклары белән эшләргә туры килде. Шулай ук Туфан Миңнуллинның 10 томлы “Сайланма әсәрләр” циклы төп чыганаклар булып торды.

Хезмәтнең беренче бүлеге мифларның әдәбиятта кулланылышын өйрәнүгә багышланды. Аның беренче бүлекчәсендә без мифларның килеп чыгышы хакындагы карашларны барладык. Мифларны төркемләүгә тукталдык. Алга таба без Туфан Миңнуллин иҗатында түбән мифология персонажларының күп булуын ачыкладык. Икенче бүлекчәдә татар әдәбиятында мифлар чагылышын күзәттек.

Икенче бүлек Туфан Миңнуллин иҗатында мифик образлар кулланылышын ачыклауга багышланды. Туфан Миңнуллин “Җанкисәккәем”, “Җен алыштырган”, “Кәрлә – мәктәп баласы” “Гафият турында әкият” әсәрләрендә шүрәле, дию, убыр, юха елан кебек мифик образларны уңышлы кулланган. Алар бүгенге кешеләрдәге сыйфатларны тирәнрәк ачу өчен хезмәт итәләр, әсәрләрнең мавыктыргыч булуын тәэмин итәләр, дигән нәтиҗәләргә килдек.

Туфан Миңнуллин үз әсәрләрендә мифик затларны актив куллана. Бу персонажлар балаларда кызыксыну хисен арттыру, китаплар укуга мәхәббәт уяту, татар халык авыз иҗаты, аның мифик затлары белән таныштыру һәм фантазияне үстерү максатыннан әсәрләрдә биреләләр.

Туфан Миңнуллинның әсәрләре халыкчан булуы белән укучы күңеленә бик якын. Шул рәвешле, Т.Миңнуллин үз иҗатында татар халык авыз иҗаты берәмлекләреннән бик урынлы һәм уңышлы файдаланган.

Нәтиҗә ясап әйткәндә, Туфан Миңнуллин әсәрләрендәге мифик образлар актив кулланылышта һәм алар әсәрләрнең эчтәлеген тирәнрәк җиткерүдә зур роль уйныйлар.

**Кулланылган әдәбият исемлеге:**

1. Миңнуллин, Т. Сайланма әсәрләр: 10 томда / Т. Миңнуллин. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2002.
2. Гыйльманов, Г. Татар мифлары: ияләр, ышанулар, ырымнар, фаллар, им-томнар, сынамышлар, йолалар / Г. Гыйльманов. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1999. – 432 б.
3. Татар халык риваятьләре һәм легендалары. – Казан: Раннур., 2000
4. Урманче, Ф. Татар халык иҗаты / Ф. Урманче. – Казан: Мәгариф, 2002. – 335 б.
5. Урманчеев, Ф.И. Татар мифологиясе // Фәнни эзләнүләр юлында / Ф.И. Урманчеев. – Казан: Фикер, 2000. – 288 б.
6. Шүрәле //Татар халык әкиятләре. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1989. – Б. 389.

*Юнысова Ралия, 4 нче сыйныф,*
*Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районының «32 нче гимназия» муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесе*
*Җитәкчеләр: Мөбарәкшина Рузилә Рәшит кызы, туган тел һәм әдәбияты укытучысы*
*Авдошина Нина Александровна, башлангыч сыйныфлар укытучысы*

## Татар хатын-кыз баш киемнәренең милли-сәнгати үзенчәлекләре

### Кереш

Татар баш киемнәренең милли-сәнгати үзенчәлекләре, тарихи дәверләр һәм аерым төбәкләр белән бәйле вариантларының күптөрлелеге хатын-кыз киемнәрендә аеруча ачык чагылыш таба.

Минем эшемнең актуальлеге милли баш киемнәренә, татар халык һөнәрчелеге тарихына һәм гореф-гадәтләренә кызыксыну уяту белән бәйле.

Гипотеза: татар халкының традицияләрен саклау аны баетуга китерә.

Хезмәтемнең темасы – "Татар хатын-кыз баш киемнәренең милли-сәнгати үзенчәлекләре".

Тикшеренү объекты – татар хатын-кыз баш киемнәре.

Тикшеренү предметы – татар хатын-кыз баш киемнәренең тарихы һәм үзенчәлекләре.

Эшнең максаты: татар баш киемнәренең килеп чыгу тарихын өйрәнү, баш киеменең төрлелеге турында белү, калфакны тегү.

Максатка ирешү өчен түбәндәге бурычлар куелгды:

1. Фәнни әдәбиятны өйрәнү.
2. Милли баш киеме тарихын өйрәнү.
3. Калфак җитештерүнең технологик эзлеклелеген тикшерү.
4. Классташлар арасында социологик сораштыру үткәрү.

Тикшеренү эшен башкарганда түбәндәге ысулларны кулландым: әдәбиятны өйрәнү, тасвирлау, чагыштыру, гомумиләштерү, алынган нәтиҗәләрне системалаштыру, социологик сораштыру.

Мин тәкъдим иткән иҗади эш татар халкының мәдәнияте тарихы белән кызыксынучы барлык кешеләргә дә кызыклы булачак.

Эш кереш сүздән, төп өлештән, йомгаклаудан, әдәбият исемлегеннән тора. Әлеге эшкә кушымтада татар милли калфагын әзерләү процессының фотосурәтләре күрсәтелгән.

I **Татар хатын-кызларының баш киемнәре**

**1.1. Татар хатын-кыз баш киемнәренең тарихы**

XIX йөзнең икенче яртысында кызлар арасында “ак калфак” кию аеруча киң тарала – озынлыгы 70 см га кадәр булган конус рәвешендәге калфаклар ак киҗе-мамык җептән бәйләнә. Аны маңгай бәйләвече – чуклы укалы тасма (“укачачак”) белән йөртәләр. Мондый төр калфакны чачаклы очын артка җибәреп яки кырын салып кияләр. XIX-XX йөзләр чигендә ул кулланылыштан чыга, әмма әле авылларда яшәп кала.

Калфак ул – Урта Идел буе һәм Урал яны татарларының традицион хатын-кызлар баш киеме. Бәйләнгән яисә тукымадан (ешрак бәрхеттән) тегелгән.

Соңрак шәһәр хатын-кызлары читтән китерелгән төрле төстәге буй сызыклар төшкән ефәк трикотаж тукымадан тегелгән калфакларны артыграк күрәләр. Конус рәвешендәге традицион форманы саклаган хәлдә, бу калфаклар кыскарак була (50 см тирәсе), әмма бай бизәлеше белән аерылып тора.

XIX йөзнең икенче яртысынан ука белән тигез чигү (укалы калфак), сәйлән, энҗе тезеп чигү (энҗеле калфак), тәңкәле аппликация (тәңкәле калфак) белән бизәлгән каты кырпулы бәрхет калфакларның популярлыгы арта. Аларны кызлар да, кияүдәге хатыннар да, эчтән киелә торган баш киеме буларак, яратып кияләр. Аның өстеннән гадәттә фабрикада эшләнгән яулык ябалар. Калфаклар тегү һөнәрчелеге алга китә. XIX йөз ахыры – XX йөз башында зур бәрхет калфаклар урынына кечкенә калфаклар (мөгез калфаклар) кулланыла башлый. Алар да яулык, япма яисә ефәк шәл астыннан кадап калдырыла.

XX йөз башында калфак төрләре күбәя: кечкенә калфаклар, кәттәҗиләр, ярымкалфаклар, түбәтәйгә охшатып ясалган калфаклар барлыкка килә. Ирләр түбәтәе дә берникадәр үзгәреш кичерә.

Калфакны бизәү өчен төрле техника ысуллары, әсбаплары, тукыма кулланылган. Мисалга, алтын җепләр белән чигелергә мөмкин. Маңгай өлеше алтын җепләр белән тасма рәвешендә бизәлә, ә түбәсе чигелергә яисә чигелмәскә мөмкин. Сәйләннәр, мәрҗәннәр, энҗе мәрҗәннәр кулланыла. Калфакларны куе тонык кызыл, зәңгәр, шәмәхә, яшел төсле бәрхеттән ясыйлар.

Унтугызынчы гасыр урталарында “ушковая” техника кулланган. Ефәк ленталардан колак формасында ясалып бергә җыелып чәчәк формасында беркетелә. (Кушымта 1)

Калфакларны бизәүдә тагын бер техника – махсус бәрхет җеп (русча “синель”) белән бизәү. Ялтыравыклы пайеткалар, сәйлән, энҗе мәрҗәннәр дә кулланырга мөмкин. Калфак һәм түбәтәйләр көмеш яисә алтын белән йөгертелгән каты чыбык “бить” белән бизәлгән. Шулай ук, энҗе-мәрҗәннәргә охшатып, өрелгән пыяладан ясалган мәрҗәннәр белән бизәгәннәр. (Кушымта2)

Яшүсмер кызлар **“кәттәҗи”** исемен йөрткән баш киеме кигән. Алар маңгайның уртасына төшерелеп киелә. (Кушымта 3)

### 1.2. Укалы калфакның сәнгати үзенчәлекләре

Калфак - төрки халыклар көнкүрешендә киң таралган баш киеме. XVIII-XIX гасырларда «маңгайлык» рәвешен алган калфакның юл башы болгар чорында, аннан да элегрәк елларда кулланылган гади һәм йомшак баш киемнәренә барып тоташа.

Борынгыдан килгән бизәк-төсмерләрне калфакның түбәнге, каты өлеше ныграк саклаган. Мондагы нәкыш-чигешләр үсемлекләр дөньясын сурәтләү белән беррәттән, хәрефләр һәм сүзләр язылышын хәтерләтә. Элегрәк бу бизәкләр урынына төрле теләкнамәләр, хатын-кызны күз тию ише нәрсәләрдән, яман көчләрдән саклаучы догалар, тылсымлы сүзләр язылган булса кирәк. Халык телендә «маңгайга язылган» дигән тәгъбир дә, мөгаен, нәкъ менә шуңа ишарәлидер.

Төрле төстәге бәрхеткә алтын һәм көмеш җепләр чигеп ясалган калфак XIX гасыр урталарында бизәнү әйберенә әверелә башлый, хатын-кызның башка төрдәге баш киемнәре арасында нәкъ менә шул сыйфат та өстенлек итә.

Калфак җыйнаклана, камилләшә, күркәмрәк була бара. Аның килеш-килбәте, укалап чигелгән бизәк-гөлләре калфак иясенең күңел рухын, эчке кичерешләрен, хис-тойгыларын чагылдыра. Бәрхет өстенә яткан чигешләргә игътибар итсәк, анда күбесенчә чәчәк бәйләмнәрен, ай-йолдыз балкышларын, урман кошларын, үлән яфракларын, үсемлек сабакларын күрербез. Болар барысы да табигатьнең яшәү сулышын, яшәү көчен зурлый. Аларда тормышның гади һәм бөек фәлсәфәсе - туу-яңару, чәчәк ату, саргаю һәм шиңү, яңа үсентеләр, яңа бөреләр калкып чыгу кебек мәгънәләр сурәтләнә.

Шунысы игътибарга лаек: калфакта төп кыйммәт тукыманың яки җепләрнең ни дәрәҗәдә кыйбатлы булуында түгел, ә бәлки бизәк-сурәтләргә салынган мәгънәнең, хис-тойгыларның юнәлешендә һәм үзенчәлегендә.

Әйтик, төнге күк йөзен хәтерләткән бәрхеткә чигеп ясалган ярымтүгәрәк ай, балкып, җемелдәп торган йолдызлар, төннең серле һәм сихри матурлыгын сөйли, яшьлек хисләрен, яшьлек хатирәләрен чагылдыра.

Шулай итеп калфак, көнкүрештә кулланылган баш киеме булудан бигрәк, затлылык, нәфислек, хәтта күпмедер дәрәҗәдә көязлек билгесе булып әверелә.

Гомумән, калфак баш киеме буларак та, бизәнү әйбере буларак та, татар хатын-кызларының рухи матурлыгын, күңел байлыгын, тегү-чигү эшенә осталыгын, дөньяны танып-белүдә нечкә сизгерлеген, зәвыгын чагылдырган сәнгать җәүһәре ул.

Күз нурларым салып калфак чигәм,
Бизәкләре шуңа чын кебек.
Бик яратып, сөеп чиксәң генә,
Чәчәкләргә була җан өреп.

Кулларыңа алсаң бу калфакны,
Син дә кара шулай яратып,
Йөрәгеңнең кайнарлыгын кушып,
Чигешләрен кабат яңартып.

Элек-электән шундый баш киемнәрен алтын куллы осталар бәйрәмнәргә; уңган киленнәр бөтен күңел җылысын, мәхәббәтен биреп, яраткан кияүләренә — туйга әзерләгәннәр. Бу матур гореф-гадәтләребез әйләнеп кайтыр, нәфис һөнәрчелек традицияләребез көннән-көн яңара барыр дип ышанып калам.

**II Татар хатын-кыз баш киемнәренең үзенчәлекләре**

2.1. Татар хатын-кызларының милли баш киеме калфакны тегү

Кечкенә һәм аны заманча күлмәк белән килештереп киеп булганлыктан, калфак бүгенге көндә популярлаша бара. (Кушымта 4) Мин дә үземнең яраткан күлмәгемә туры китереп калфак тектем.

Мин түбәндәге материалларны кулландым:

1. Катыргы
2. Бисер
3. Җеп һәм энәләр, кайчы
4. Карандаш һәм линейка
5. Тукыма (бәрхет)

Нигез итеп катыргыны алдым. Катыргыдан 10 см диаметрлы түгәрәк, озынлыгы түгәрәк озынлыгына тигез булган полосаны, киңлеге 4 см. кистем. Детальләрне бәрхет белән тышладым, күренми торган тегү ысулы белән тоташтырдым. Калфакны бисер белән бизәдем. Миңа калфак тегү бик ошады.

(Кушымта 5, 6)

**2.2. Социаль сораштыру**

Татар хатын-кызларының баш киеме безнең сыйныфташларыбыз арасында популярмы? Бу сорауга җавап бирү өчен мин сораштыру үткәрдем. Сораштыруда Түбән Кама шәһәре 32 нче гимназянең 4 нче сыйныфында укучы 52 бала катнашты.

Сораштыру нәтиҗәләре:

- 90 % укучы милли мәдәниятне сакларга һәм үстерергә кирәк дип саный;
- 85 % укучы милли мәдәният халыкны берләштерә, ата-бабалар традицияләрен бүгенге һәм киләчәк буыннар белән бәйли дип уйлый;
- 95 % соратыруда катнашучы татар хатын – кызларының баш киеме-милли мәдәниятнең бер өлеше дип саный;
- 50 % укучы татар хатын-кызларының баш киеме бүген көндәлек тормышта популяр дип уйлый;
- 68 % укучы татар халкының хатын-кыз баш киемнәре турында күбрәк белергә теләкләрен белдерде;
- 50 % укучы татар хатын-кызларының традицион баш киеме ничек аталуын, нинди материалдан тегелә, татар милли хатын-кыз баш киемнәрендә нинди бизәкләр кулланылуын белә.

Сораштыру нәтиҗәләреннән чыгып, мин безнең буын ерак гасырлардан килгән традицияләрне онытмавын, милли киемнәребез белән кызыксынуын белдем.

**Йомгаклау**

Бу эшне башкарып, мин безнең көннәрдә борынгы хатын – кызларның баш киеме – калфакны театр сәхнәсендә, эстрада мәйданчыкларында һәм музейларда гына түгел, көндәлек тормышта да күрергә мөмкин дигән нәтиҗәгә килдем. Әйтик, аны «Ак калфак» татар иҗтимагый хатын-кызлар оешмасының символы буларак кулланалар. Күпчелек дизайнерлар бәйрәм киеме элементы буларак калфак тәкъдим итәләр. Кечкенә һәм шул ук вакытта аны заманча күлмәк белән килештереп киеп булганлыктан, калфак бүгенге көндә популярлаша бара.

Мин татар халкының милли баш киеме калфак тегү серләренә өйрәндем. Куйган максатыма ирештем, бурычлар үтәлде, гипотеза расланды, дип саныйм.

**Кулланылган әдәбият исемлеге:**

1. Валеев Ф.Т. Сибирские татары: культура и быт. – Казань: Татарское кН. Изд-во, 1993. – С.11

2. Валеев Ф.Т., Томилов Н.А. Татары Западной Сибири. История и культура. Т.2. – Новосибирск: Наука, 1996, 1996. – С. 9.

3. Воробьев Н. И. Казанские татары: (Этногр. исследование материальной культуры доoktóбрьского периода) / проф. Н.И. Воробьев, д-р ист. наук заслуж. деятель науки

ТАССР; Акад. наук СССР. Казан. филиал. Ин-т языка, литературы и истории. - Казань: Татгосиздат, Ред. науч.-техн. лит., 1953. - 383с.

4. Воробьев Н. И. Материальная культура казанских татар (опыт этнографического исследования)/ Н. И. Воробьев; Дом татарской культуры. Казань: Издание Дома татарской культуры: Издание Академического Центра ТНКП, 1930. - 480 с.

5. Суслова С.В. Татарский костюм: историко-этнологическое исследование / Светлана Суслова. – Казань: Татар. кн. изд-во, 2018. – 239 с.

6. В.А.Тишков - М.: Большая Российская энциклопедия. 1994. с.321-3252.

7. «Татарская народная одежда». Татарское книжное издательство. Казань, 1997 ел.

Интернет чыганаклар:

1.http://tt.wikipedia.org/wiki/.

2.danif.narod2.ru/clients/kiemnr_m_bizn_iberlre/

*Яковлева Карина,* 8 нче сыйныф,
*Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районының» инглиз телен тирәнтен өйрәнү белән 33 нче урта гомуми белем бирү мәктәбе " муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесе*
*Җитәкчесе: Нургатина Раиля Раифовна, туган тел һәм әдәбияты укытучысы*

## Иҗат җимешләре

### Ак каен

Инеш буенда
Ак каен үсә.
Сыйпап агачны,
Йомшак җил исә.

Яз көне оя
Коралар кошлар.
Моңая каен
Җиткәндә кышлар.

Ялгызы кала
Көз җитү белән.

Үзенә аның

Күңелсез, беләм.

Челтерәп ага

Янында инеш.

Юата аны:

«Моңайма!»

Имеш.

«Мин синең дустың,

Челтерәп кенә

Җырлап торырмын

Күңелле генә.

**Җирәнкәй**

Әбинең җирән песие

Мактанырга ярата.

Мыраулый, сырпалана,

Зарын шулай тарата.

Тычкан тотарга яратмый:

«Мин матур», - диеп яши.

Актырнак көн-төн сакта,

Җирәнкәйгә ул дәшми.

Песи явызлыгы белән

Дан тотып яши бирә.

Аннан куркып, терлекләр

Ояларына керә.

Җиһан терәге диярсең,

Патшадай үзен тота.

Алдына килгәнне песи

Чәйнәмичә дә йота.

Дөнья бит ул гел тоташ

Шатлыктан гына тормый.

Бүген белән яши Җирән,

Алга планнар кормый.

Песи тычкан тотмагач,

Әбекәй капкын куя.

Җирән шунда эләгеп,

Акылын беркөн җуя.
Шулчак песигә ярдәмгә
Дошманы Акбай килә.
Булышам дип, Җирәнгә
Дуслык тәпиен бирә.
Шушы көннән башлап Җирән
Дуслык кадерен аңлый.
Актырнак та песине
Җан дусты кебек саклый.

**Яңа дус**

Алмазны беркөн дуслары
Никтер кире кагалар.
Футбол командасына да
Башка малай алалар.
Алмазга күңелсез була,
Малайлар уйнамыйлар.
Алмазга кыендыр диеп,
Нигәдер уйламыйлар.
Алмаз бераз уйлана да,
Бер дус ясый үзенә.
Зәңгәр сәдәф тегеп куя
Уенчыкның күзенә.
Яңа дусты матур чыга,
Сөйләшә дә белә ул.
Сау бул дигән вакытта
Болгый дусты аңа кул.
Уенчыкка Зигби дип
Исем дә куша Алмаз.
Дуслары, Зигбины күрсә,
Артыннан аның калмас.
Футбол уйнау малайларга
Бервакыт ялыктыра.
Ә Алмазның күңеле
Шатлыктан тулып тора.
Яңа уенчык белән

Һәркем уйнарга тели.
Футболчылар Алмазга
Гафу сүзләре сөйли.

Билгеле,Алмаз дусларын
Кичерә, гафу итә.
Бергәләп,уйнап-көлешеп,
Чын дуслык дәвам итә.

**Кайчы**

8 нче мартка диеп,
Сеңлем бер курчак теккән.
Курчагы килеп чыкмагач,
Кабаттан аны сүткән.

Яңадан теккән вакытта,
Кайчысы юкка чыккан.
Үзе дә сизмәстән аны,
Курчак эченә тыккан.

Укытучы белән бергә
Кайчыны эзләгәннәр.
Кая гына булды диеп,
Бар җирдән күзләгәннәр.

Йомшак курчагы сеңлемнең
Каты булып тоелды.
Ачып җибәрсәк эчен,
Аннан кайчы коелды.

Кызык булды барыбызга,
Рәхәтләнеп, без көлдек.
Шуңа яңа курчакка
“Кайчы” дип исем бирдек.

**Үскәч кем булырга?**

Үскәч кем булырга диеп,
Бүгеннән уйга калам.
Хыялларымны үземнең
Көн дә тәртипкә салам.

Укытучы булсам ничек?
Көн дә эшкә барасы.

Дәфтәрләрне тикшереп,
Өйгә кайтмый каласы.

Тәрбияче булсам әгәр,
Балаларны карыйсы.
Артларыннан чабып йөреп,
Хәлдән таеп арыйсы.

Сатучы булыйммы әллә?
Акча белән эшлисе.
“Өстемә чыкты” диеп,
Аннан терсәк тешлисе.

Заводка әгәр урнашсам,
Физик хезмәт куясы.
Өйгә кайтып: “Уф, ардым” дип,
Акылларны җуясы.

Пешекче булсам әгәр дә,
Торт, пирог ашап ятсам,
Бик күп акча эшләр идем,
Аларны әгәр сатсам...

“Дәресеңне кара әйдә,
Хыялланып утырма.
Кирәкмәгән уйлар белән
Баш миеңне тутырма!”

Әинең сүзләреннән соң
Кулыма китап алам.
“Кем булам инде үскәч дип”,
Борчулы уйга калам...

**Куян баласы**

Кыр казлары артыннан
Җылы якларга диеп
Чыккан куян баласы,
Киез итеген киеп.

Очып кына китә алмый,
Бик озак талпынса да,
Әнисе дә өйрәтә алмый,
Үтенеп ялынса да.

Йомшак куян баласына
Әнисе хак сүз сөйли.
Аңламагач нарасые,
Җырга салып, ул көйли:

«Кошлар очу өчен туа,
Балыклар – йөзү өчен.
Ә менә без-куянкайлар –
Сикереп йөрү өчен».

**Ял көне**

Бүген минем ялым диеп,
Әти диванда ята.
Телефоннан озак кына
Әтием «гайбәт сата».

Ятып аргач берадан
Кухняга чыгып ашый.
Хәзер нишлим микән диеп,
Әтием башын кашый.

Күрше дуслары янына
Урамга чыгып керә.
Бармакка бармак сукмый,
Ялның тәмен ул белә.

Әнинең дә ялы бит,
Ә нигәдер тик тормый.
Ничек ял итим диеп,
План да әни кормый.

Су сибә гөлләренә,
Тәмле ашлар әзерли.
Минем белән бергәләп
Әни дәрес хәзерли.

Энемне йокларга сала
Фәрештә кебек саклап.
Токмачын да кисеп куя
Бик нәзек итеп ваклап.

Әнием керләрне уа,
Идәннәр дә ялт итә.

Савыт юа, өйне җыя,
Сөйләсәм, исең китә.

Кич җитү белән әти
Ардырды бүген диеп,
Йомшак мендәренә ята
Йокы күлмәген киеп.

Әтиләргә рәхәт икән,
Бары акча эшлисе.
Ә өйдәге бар хезмәтне
Тик әнигә «чүплисе».